# КАЗАН УТЛАРЫ

12. 1990



# ТАТАРСТАН ССР ЮГАРЫ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

## Татарстан ССР Дәүләт флагын, Дәүләт гербын, Дәүләт гимнын булдыру буенча конкурс турында

**1. «Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турында Декларация» кабул ителү уңаеннан, Татарстан ССР — Татарстан Республикасының Дәүләт флагын, Дәүләт гербын, Дәүләт гимнын булдыру буенча конкурслар игълан итәргә һәм бу конкурсларны 1991 елның 1 февраленә төгәлләргә.**

**2. Татарстан ССР Югары Советының Конституцион комиссиясенә белгечләр катнашында конкурсларга йомгак ясарга һәм 1991 елның 15 февраленә кадәр Югары Совет Президиумының раславына кертергә.**

**Татарстан ССР Югары Советы Рәисе М. ШӘЙМИЕВ**

## Конкурс шартлары

Дәүләт флагы, гербы һәм гимны Татарстан Республикасының дәүләтчелек атрибутлары булып торалар һәм, «Татарстан ССРның дәүләт суверенитеты турында Декларация»гә бәйле рәвештә, Татарстан ССР территориясендә яшәүче халыкларның милләте, социаль чыгышы һәм хәле, дине, сәяси карашлары нинди булуга карамастан, тигез хокук һәм ирек, шулай ук татар һәм рус телләренең, дәүләт телләре буларак, тигез кулланылышын гарантияләүче суверен дәүләт идеясен көчле, кыска һәм ачык белдерергә тиешләр. Татарстан ССРның Дәүләт символлары монда яшәүчеләрнең күпмилләтле булуын һәм республиканың башка үзенчәлекләрен, республикага исем биргән халыкның мең еллык дәүләтчелек тарихын, аның күп гасырлык мәдәни традицияләрен исәпкә алырга тиеш.

Флаг һәм гербның эскизлары төсле итеп, кимендә 30 х 20 сантиметрлы калын кәгазьдә эшләнергә һәм размерларын күрсәткән, шулай ук символларның мәгънәсен җентекләп тасвирлаган аңлатма теркәлергә тиеш.

Гимн буенча конкурска түбәндәгеләр кабул ителә:— текстсыз музыкаль әсәрләр (ике данәдә клавир яки партитура. Тизлеге күрсәтелгән магнит язмасын да бирергә мөмкин).

Конкурслар ябык. Әсәрләр девиз астында җибәрелә, ә конверт эчендә авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, эш урыны һәм өй адресы күрсәтелеп, машинкада яки кулдан ачык итеп язылган текст булырга тиеш.

Дәүләт символының һәркайсына конкурс аерым уздырыла һәм җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр бирелә.

Әсәрләрне түбәндәге адрес буенча җибәрергә: Казань, Кремль, Верховный Совет Татарской ССР, с пометкой «Конкурс: Госсимволы Татарской ССР».

Кабул итүнең соңгы көне — 1991 елның 1 феврале.

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ЖУРНАЛЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1990

12

(818)

ТАТАРСТАН ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*

ЯЗУЧЫЛАР СҮЗЕ


Язучы-депутатларның ТССР Югары Советындагы чыгышларының стенографик отчеты. (Р. Фәйзуллин, Ф. Бәйрәмова, Р. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Вәлиев) . . . 3


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Рәшит ӘХМӘТҖАН. Ант. *Шигырьләр* . . . 13

Г. ҮЗИЛЕ. Гыйфрит. *Роман-дилогия* . . . 19

Ф. САФИН. Ышан, кардәш! *Шигырьләр* . . . 79


СӘХНӘ ӘСӘРЛӘРЕ


Р. МИНГАЛИМ. Кунак кызы гел килмәс. *Лирик комедия* . . . 82


ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ


Ф. ЯРУЛЛИН. Күкертле чишмә . . . 98

З. ХӨСНИЯР. Кичү . . . 104

Р. ХИСМӘТУЛЛИН. Чылбырлар . . . 115


ХӘСӘН ТУФАННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ


Г. МИНСКАЯ. Газиз мирас . . . 125

Хәсән Туфанның бер шигырь-хаты . . . 128

Г. Хәйям робагыйлары *(Х. Туфан тәрҗемәсе)* . . . 129


САЛИХ СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ


Ф. СӘЛИТОВА. Соңгы моңнар . . . 135

Татар шагыйрьләре Сәйдәш турында . . . 138

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. Кыйммәтле истәлек . . . 139


ПУБЛИЦИСТИКА


И. САЛАХОВ. Томаннарга төренгән яшьлек турында . . . 140

А. САДЫЙК. Шахмат алиһәсе . . . 153


ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Н. НӘҖМИ. Сибгат Хәким мәктәбе . . . 156

М. ВӘЛИЕВ. Батырлык . . . 160


КИТАП КҮЗӘТҮ


Ф. БӘШИРОВ. Затлылык . . . 168

ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

И. МӨХӘММӘТШИН. Керәшен татарлары турында . . . . . . . . . . . . . 172
Ф. ШӘРИФУЛЛИНА. Кострома татарлары . 174

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА

Р. ВӘЛИЕВ. Революция улы . . . . . . . 176

Гарәп әлифбасы нигезендә татарча уку күнекмәләре . . . . . . . . . . . . . . 180

УКУЧЫ СҮЗЕ

Ш. ХАСИЯТУЛЛИН. Татар теленә — киң хокуклар! . . . . . . . . . . . . .182

Китаплар дөньясында. . . . . . . . . . 183
«Казан утлары»нда 1990 елда басылган әсәрләр исемлеге . . . . . . . . . . . . . 184
Котлыйбыз! . . . . . . . . . . . . . 188
Мәдәният тормышы көндәлеге . . . . . . .189
Тышлыктагы сурәтләр . . . . . . . . . 192

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Стенографический отчет выступлений писателей: народных депутатов на сессии Верховного Совета ТССР (Р. Файзуллин, Ф. Байрамова, Р. Миннуллин, Р. Мухамадиев, Р. Валиев).
«Поэзия и проза»: новые стихи Рашита АХМЕТЗЯНОВА, Ф. САФИНА; окончание романа Г. КАШАПОВА «Чудовище».
«Драматургия»: лирическая комедия Р. МИНГАЛИМОВА «Девушка-гостья».
«На конкурс»: рассказы Ф. ЯРУЛЛИНА «Сернистый родник», З. ХУСНИЯРА «Переправа», Р. ХИСМАТУЛЛИНА «Цепи».
В номере отмечается 90-летие поэта Х. Туфана и композитора С. Сайдашева: воспоминания, стихи, письма, фотографии.
«Публицистика»: статья И. САЛАХОВА «Молодость окутанная туманами»; очерк А. САДЫКА «Шахматная богиня».
«Литературная критика»: воспоминания Н. НАДЖМИ «Школа Сибгата Хакима»; статья М. ВАЛИЕВА «Мужество».
«Библиография»: рецензия Ф. БАШИРОВА на книгу Ф. Миннуллина «Затлылык».
«Татарский народ: в различных регионах страны и мира»: статья И. МУХАМЕТШИНА «Крещенные татары»; статья Ф. ШАРИФУЛЛИНОЙ «Костромские татары».
«К истории культуры»: статья Р. ВАЛИЕВА «Сын революции». Навыки чтения на основе арабской графики.
«Слово читателя».
Список произведений, опубликованных в 1990 году.
Хроника.
На наших обложках: татарские надмогильные камни Оренбуржья; известный писатель, лауреат государственной премии ТССР имени Г. Тукая М. Хасанов.

*Баш мөхәррир*

РАВИЛ ФӘЙЗУЛЛИН

*Редколлегия*

ГАРИФ АХУНОВ
МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ФЛҮС ЛАТЫЙФИ
*(җаваплы сәркатип)*
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
ФӘРВАЗ МИННУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
МАРАТ МӨЛЕКОВ
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
РАШАТ НИЗАМИЕВ
*(баш мөхәррир урынбасары)*
ГӘРӘЙ РӘХИМ
КОЯШ ТИМБИКОВА
*(бүлек мөхәррире)*
МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ
ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
*(бүлек мөхәррире)*
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-07-09.

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

*Бүлек мөхәррирләре:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин.
*Мөхәррирләр:* Нияз Акмалов, Шамил Маннапов, Җәүдәт Миңнуллин, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Хезмәткәрләр:* Р. Вафина, Л. Гатауллина, Г. Моратова, Ф. Сабирова, Т. Сибгатуллина.

Производствога бирелде 10.11.1990 ел. Басарга кул куелды 26.12.1990 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 83044. Заказ Д-509. Бәясе 90 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1990 ел.

# ЯЗУЧЫЛАР СҮЗЕ

**Татарстан Югары Советы сессиясе 30 августта Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында декларация кабул итте.**

**Түбәндә әлеге сессия утырышларында депутат язучыларыбыз чыгышларын сөйләгән тәртиптә, стенографик язмада урнаштырабыз.**

## Татарстан ССР халык депутаты Равил Фәйзуллин:

Хөрмәтле депутат иптәшләр!

Бу сессиядә халкыбыз өчен тарихи мөһим мәсьәлә — аның суверенлыгы, мөстәкыйльлеге мәсьәләсе хәл ителә. Бәйсезлеге, үз дәүләтчелеге булган халык кына чын мәгънәсендә тулы канлы халык дип исәпләнә ала.

Ихтимал, залда утыручы рус депутатларының күбесе өчен Татарстанның суверенлык мәсьәләсе, иң әүвәл, матди яки хокукый хәлнең ныгуы белән бәйле булса, безнең халык өчен бәйсезлек — киләчәгебезнең булу-булмавын билгеләүче төп шарт, тормыш алга куйган иң кирәкле хаҗәт, җан-вөҗдан эше. Чөнки күп миллионлы татар милләтенең (гәрчә халкыбызның фәкать чиреге генә бездә яшәсә дә) язмышы бүген биредә — Казанда хәл ителә... Ниһаять, безнең халык та, кайчандыр зур дәүләтчелеге булганын онытып, берничә гасырга сузылган сәяси йокыдан соң,— һәрхәлдә, миңа шулай тоела,— үзенең суверенлыгын урнаштырырга карар итте. Бу — һәр җитлеккән милләтнең табигый ихтыяры, аның мөстәкыйль үзбилгеләнүгә табигый хокукы. Бу — табигатьтән, кем әйтмешли, ходайдан бирелгән хокук. Бу хокукны, тәрәккый кешелек кануннары буенча фикерләсәк, бәхәскә, бернинди тавышка-фәләнгә куймыйча гына танырга, кабул итәргә кирәк иде дә бит... Ләкин без үзенә бер төрле сәяси системада яшибез, һәрхәлдә, моңа кадәр яшәп килдек. Анда элементар демократик башлангычлар тоталитар структуралар белән бәйләп-төйнәп куелган иде. Һәм без әле күбебез хәзер дә искечә фикерләү рәвеше белән яшәп киләбез. Суверенитет турындагы Декларация проекты игълан ителгәч, бөтен халыкта давыллы реакция кузгалды. Матбугатта бигрәк тә. Мин татар һәм рус матбугатында йөзләрчә мәкаләләр, аерым чыгышлар белән таныштым. Темасы бер үк булса да, проблема төрле яссылыкта яктыртылды. Кызганычка каршы, сүз фикерләр плюрализмы турында гына бармый. Еш кына фикерләрнең төрлелеге телләрнең төрлелегенә, милли психология үзенчәлекләренә, фикерләү рәвешенә бәйле иде. Татар матбугатындагы чыгышларны, милләттәшләремнең телдән чыгышларының эчтәлеге күпчелек русларның һәм рус телендә сөйләшүчеләрнең дә аңына барып җитә алмавы бик кызганыч. Ә татарларның абсолют күпчелеге русларның фикерен, нигездә, белә. Һәм кайвакыт үз сүзләренең рус иптәшләр тарафыннан укылмый да, ишетелми дә калуына үпкәлиләр дә. Мондый хәл үзара аңлашып җитмәүгә китерә. Һәр якның аргументлары белән җентекләбрәк танышканда, бер-беребезне яхшырак белә алыр идек. Ә бер-беребезне аңламыйча безгә бүген мөмкин түгел. Шунсыз үзара консенсус, килешү була алмый. Турысын әйтим, Декларация турында фикер алышулар барышында русча матбугатта кайбер шовинистик рухлы мәкаләләр дә күренде. Һәм алар республикада сәяси атмосфераны күпмедер дәрәҗәдә кискенләштерүгә китерде. Суверенитетка каршы чыгучыларны нәрсә куркыта соң?

Мин үзем өчен анализ ясадым һәм аларны якынча өч төркемгә аердым. Беренчесе — Татарстан, үзенең суверенитетын урнаштырган хәлдә, Федерациядән аерылыр, дип курку. Икенчесе — суверенитет булганда, башка милләт халыкларының мәнфәгатьләре кысылыр, дип шикләнү. Өченчесе — суверенитет урнашкан очракта, бүгенге партократия яңартылган дәүләт системасында үзе өчен яңа структура, җылы урыннар әзерләр, аппарат тагын да ишәер, дип уйлау.

Хәзер шул өч моментка тәфсилләбрәк тукталып узыйк. Мөстәкыйльлеккә чыгу — кубарылып дөнья чынбарлыгыннан аерылу, япа-ялгыз гына үзбаш яшәү дигән сүз түгел. Без федерациягә кердек-чыктык (сүз уңаеннан әйтеп узыйк: без Россия составына солых төзеп кергән халык түгел) дип керделе-чыктылы сөйләшә алмыйбыз. Биредә мәсьәлә андый яссылыкта куелмый да. Сүз — «өлкән туган, кече туган» мәгънәсендә түгел, тигезлек, тигез хокуклылык (дуслыкның нигезе — тигезлек), мөстәкыйль булып, бергә-бергә ярдәмләшеп яшәү турында бара. Мәгълүм хакыйкать: рус халкы белән безнең мең елдан артыкка сузылган уртак тарихыбыз бар. Бер уйласаң, рус тарихы — ул байтак дәрәҗәдә рус һәм татар халкы тарихы ләбаса. Моннан мең елдан артык элек булган вакыйга турында бер язма искә төшә. Милади белән 985 ел. «И заключил Владимир мир с булгарами и клятву дали друг другу, и сказали булгары: «Тогда не будет между нами мира, когда камень станет плавать, а хмель тонуть». («Повесть временных лет»). Хикмәтле, гыйбрәтле сүзләр болар. Димәк безнең бик борынгы бабайлар бүтән халыклар белән менә дигән дуслык килешүләре төзи белгәннәр бит! Нәрсә, суверен Татарстан бүтән республикалар белән һәр якка да файдалы килешү-договорлар төзи алмас микәнни?

Тагын шуны да искәртеп узасы килә: Бар «Русь», бар «Россия», бар «РСФСР»; онытмыйк — алар тәңгәл төшенчәләр түгел. РСФСР — ул рус халкының гына түгел, башка милләтләрнең дә тарихи территориясе. Хәзерге бу административ берәмлектә сан ягыннан руслардан гына калыша торган татар халкы өчен бу фактор аеруча мөһим. Без үзебезнең тарихи җирлекләрдән керәбез-чыгабыз дип әйтә алмыйбыз бит инде. Бу мәсьәлә хакында сүземне йомгаклап болай дип әйтәсе килә: Татар халкы тулы суверенитет алса, тигез булсак,— рус халкы белән дуслык һәм хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре тагын да ныгыячак кына.

Икенче момент. Суверенлык алынгач, республикада яшәүче башка халыкларның мәнфәгатьләре кысылырмы? Болай дип шикләнүләр бөтенләй нигезсез. Татарстан суверенитет алгач, татарлар өчен кибетләр, шифаханәләр аерым булыр, шәбрәк йортлар төзелер яки квалификацияле кадрларны төп халыктан булган квалификациясезрәк кадрларга алмаштыру башланыр дип уйларга бернинди дә нигез юк. Нәрсә, әллә татар телен көчләп укыту башланырмы? Әллә рус мәктәпләре эшләүдән туктармы? Рус халкының, теленең йогынты сферасы тараермы? Юк, безнең реаль тормышыбыз моны расламый. Киресенчә, безнең — җирле халык рухи дөньясының бүгенге хәлләре күпкә хөрти әле! Гасырларга сузылган, изүне кичергән халык икенче бер халыкны кимсетүче залимга әверелә ала алмый. Тарихта Казан җире, киресенчә, бүтән халыкларның мәдәниятын үстерү бишеге булып килгән. Моны чуваш халкы мисалында да ачык күреп була. Заманында Казанда чуваш театры оеша, шагыйрьләр, язучылары формалаша, газеталар чыга... Татарстан ирек алса, бу — анда яшәүче башка халыкларның да ирегә үсү булачак.

Һәм өченче. Суверенитетка каршы чыгучыларның бер ялгышы шунда: алар булачак үзгәрешне бүгенге партаппарат вәкилләренең гамәлләре белән генә бәйлиләр. Табигый: дәүләт булгач, идарә системасы да булыр. Әйтик, яшәү шартлары һәм рәвешләре безнекеннән күпкә яхшырак булган союздаш республикаларда да идарә аппараты булган һәм бар ич. Идарә аппаратының күләме — дәүләтнең мөмкинлекләренә, хокукларына, вазифаларына бәйле. Хәзергә прогрессив һәм демократик саналган РСФСР Югары Советы да байтак яңа структуралар — министрлыклар, комитетлар һ. б. төзи бит. Хикмәт — эш башында кемнәр, нинди акыл ияләре торуда! Анысы инде сездән, бездән — депутатлардан, халыкның үзеннән тора.

Кайберәүләрдән шундый сүзләр дә ишетелгәли: янәсе, шушы декларацияләр, неформаллар, җәмәгать оешмалары аркасында төрле борчулар, республика җәмгыятендә киеренкелек башланды, элек бөтенесе тыныч иде, диләр. Әйдәгез, иптәшләр, шунысын да истә тотыйк. Сталин заманында демократия мәсьәләсендә, гомумән, бик тыныч, хәтта артык тын, шомлы тынлык иде... Халыкның уяну, үзаңы үсү, үзенең дәрәҗәсен тоюы, үсү процессы — котылгысыз процесс. Моны онытырга ярамый.

Ә хәзер Декларация турында. Ике субъектлылыкның бернинди киртәгә кермәве турында кабатлап тормыйм — бер муенга ике камыт кидермиләр, бер башта ике бүрек булмый. Яхшы гаиләдә ана белән ата да икешәр булмый. Шунлыктан, биредә чыгыш ясаучыларның күпчелегенә кушылып, мин ике субъектлылыкны абсурд саныйм. Халыкларның хокуклары «Матрешка» (берсе эченә берсе урнашкан уенчык) системасына сыя алмый хәзер. Андый катлы-катлы буйсынуга инде кайту булмаска тиеш. Киләчәк — академик Сахаров әйтмешли, федерациянең горизонталь структурасы, ягъни һәр халык бертигез хокуклы булып, үзара килешүләр төзеп яшәү юлы.

Хөрмәтле иптәшләр!

Биредә үз сайлаучыларының мәнфәгатен якларга алынган кешеләр утыра. Безнең алар алдындагы вазифаларыбыз, җаваплылыгыбыз турында онытырга хакыбыз юк. Сайлау алдыннан сайлаучыларыбызга шактый күп вәгъдәләр бирдек без, республикада яшәүче халыкның материаль һәм рухи тормышын яхшыртуның бер юлы итеп союздашлык

статусы алу дип аңлаттык. Беләсез, күпчелек халык бай яшәми, очын-очка ялгап яшәүчеләр байтак, тормыш өчен иң кирәк әйберләр дә житешмәгән замана... Бүгенге көннән, дөнья барышыннан разый булмаганнар да житәрлек. Төп җирле халык суверенитетлыкка ышанып, киләчәк тормышы яхшыруын аңа бәйләп карый икән,— әйдәгез, без аларның өметләрен сүндермик! Сессия исеменә суверенитет таләп итеп илнең төрле төбәкләреннән меңнәрчә телеграммалар килде. Урам-мәйданнарда «Азатлык!» дип оран салган ватандашлар бихисап. Шундый киеренке атмосферада, без-депутатларга, нинди милләттән һәм нинди сәяси кыйблада булуыбызга карамастан — зирәк акыллы булып, үзара аңлашып, төп халык интересын чагылдара торган Декларация кабул итү кирәк. Кайбер депутатларга, замана барышын тоеп, империячел фикерләүдән арынырга вакыт. Ленинның милли мәсьәләдә, биреп җиткермәүгә караганда, тулырак итеп бирү отышлырак, дигән хикмәтле сүзен дә онытмыйк. Азатлык, милли суверенитет мәсьәләсендә халык ихтыярына каршы килеп маташу әхлаксызлык булыр. һәммәгезне дә, тигез хокуклы булуыбызны тоеп, чын дуслыкка, ихлас туганлыкка, нәтиҗәле хезмәттәшлеккә чакырам.

## Татарстан ССР халык депутаты Фәүзия Бәйрәмова:

Татар халкының газиз баласы, язучысы, депутаты буларак, Татарстан дәүләтенең суверенлыгы мәсьәләсе — минем өчен иң мөһим, төп мәсьәлә.

Депутат буларак, мин шуны әйтә алам — безнең дәүләт суверенлыгын игълан итәргә тулы хокукыбыз бар, бу очракта бөтен халыкара хокуклар да безнең якта. Без, татар халкы, ата-бабаларыбызның төп Ватанында үз дәүләтебезне яңадан торгызыр өчен көрәшәбез, һәм, милләт буларак, үзбилгеләнергә тулы хокукыбыз бар. Илдәге күп милләтләр, шул исәптән руслар да, бу халыкара хокуктан файдаландылар һәм үз дәүләтләренә суверенлык яулап алдылар. Башка чит милләтләр аларның эчке эшләренә катнашмады. Россиянең суверенлыгын яклап татарлар да тавыш бирде. Инде килеп Татарстан, татар халкы үзенә суверен дәүләт алыр өчен йөри икән, моңа каршы төшәргә бер генә милләтнең дә һәм юридик, һәм әхлакый яктан хакы юк. Бу — бер милләтнең икенче милләт эшенә катнашуы булачак һәм, шулай итеп, халыкара хокуклар тупас рәвештә бозылачак.

Бу җир, тел, иман безгә, татарларга, ходай тарафыннан меңнәрчә ел элек бирелгән. Без бирегә килеп кемне дә булса басып алмадык һәм басып алырга да җыенмыйбыз. Без бары тик хокукларыбыз, милләтебезне саклап калыр өчен генә көрәшәбез. Дәүләт һәм тел мәсьәләләрен референдумга куюу да халыкара хокукларны тупас рәвештә бозу булачак, һәм без яклауны дөнья җәмәгатьчелегеннән сорарга мәҗбүр булачакбыз. Без үз җиребездә сөйләшергә тел сорап референдум уздырыйкмы, динебез өчен референдум уздырыйкмы, суларга һава, эчәргә бер йотым су сорап референдум уздырыйкмы?! Үз җиребездә гүргә иңәр өчен өч аршын җир сорап та референдум уздырыйкмы?!

Авылдан сайланган депутат буларак, татар авылларының аянычлы хәле турында да әйтми кала алмыйм. Татарстандагы татарларның 70 процентка якыны авылларда яши. Бу авылларда тормыш әле һаман 18—19 гасыр дәрәҗәсендә, җиреннән талап, ертып нефть алалар; итен, маен, ашлыгын суырып торалар, ә халыкның ягарга — утыны, йөрергә юлы юк. Газ, асфальт юл татар авылларының төшенә дә керми. Халык, тәүлегенә 4-5 сәгать йокы күреп, илне ризыклы итә, без, Татарстаннан тыш, Мәскәү, Төмән, Свердловск өлкәләрен дә ит-сөт продуктлары белән тәэмин итеп торырга тиешбез. Без итне дә, сөтне дә РСФСРның күп өлкәләренә караганда, артыграк җитештерәбез икән! Ә җан башына туры килгән авыл хуҗалыгы җире — бездә аларга караганда ике тапкыр кимрәк! Татарстанда рус авыллары бетте диярлек, инде татар авыллары да бетсә, безне кем ашатыр — Мәскәүме, әллә, татарларга дәүләт кирәкми, дип кычкырып йөргән ялган демократлармы?!

Бүген бөтен Россияне тәмәке, аракы бунтлары тетрәтә. Чиләбе, Вологда, Пермь һәм башка шәһәрләрдә милли мәсьәлә юк. Ләкин урам уртасында руслар Россия флагларын яндыралар, райкомнарга һөҗүм итәләр, гаеплене эзлиләр, үтереш, кыру бара. Сәбәбе — Россиядә халыкның ашарына, өс-башына юк, кыйммәтчелек. Татарстанда да күбесе юктыр. Ләкин бездә иң мөһиме — ашарга бар. Икмәк һәм макарон ризыклары белән без үзебезне 100 процентка, ярма һәм кузаклы ризыклар белән — 100, бәрәңге белән — 100, сөт продуктлары белән — 100, йомырка белән — 100, ит белән — 98 процентка тәэмин итәбез икән. Менә шуңа күрә дәүләт турында сүз чыкканда, кем ризыгын ашаганыңны да онытмаска һәм рәхмәт әйтә белергә дә кирәк. «Татарларга дәүләт бирмәскә!»— дип кычкырып йөрү, ул — ашаган табагыңа төкерү, дигән сүз.

Язучы буларак, мин шуны әйтә алам: бирердә — Татарстан җирендә — татар милли

мәдәниятының язмышы хәл ителә. Без, татар язучылары, дөньяда бары тик бирегә генә үзебезнең китапларыбызны бастырып чыгара алабыз, биредә генә безнең укучыларыбыз бар. Татар әдәбиятына туу өчен җирлек бары биредә генә. Ләкин без, татар язучылары, соңгы вакытта зур куркыныч астында калдык — рус мәктәпләрен тәмамлаган татарлар үз ана телләрендә укый да, яза да алмас хәлгә килделәр, миллэт телсез калды. Милләтне яңадан терелтер, телле, иманлы, мәдәниятлы итәр өчен дәүләт кирәклеген, мөстәкыйльлек кирәклеген без тагын бер тапкыр аңладык.

Татар милләтеннән аермалы буларак, Татарстан җирендә рус милләтенең, рус мәдәниятының язмышы хәл ителми, бу җирдә аерым русларның язмышы хәл ителә. Руслар биредә күбрәк экономик яктан гарантияләр таләп итәләр, көн тәртибендә — торак, ашау-эчү, көнкүреш мәсьәләләре. Татарлар исә тел, мәктәпләр, театрлар, газета-журналлар таләп итәләр. Әгәр биредә рус милләтенең яки мәдәниятының язмышы хәл ителсә, биредәге русларны да шул мәсьәләләр борчыр иде. Рус милләтенең язмышы Мәскәүдә, Ленинградта, Вологдада, Псковта, Новгородта яки башка шундый борынгы рус җирләрендә хәл ителә, бөек рус әдәбияты һәм мәдәнияты да шунда туа. Кайда милләтнең, милли мәдәниятның язмышы хәл ителә, шунда аның дәүләте булырга тиеш. Бу — бөтен дөньяда шулай. Милләт бар, димәк, аның дәүләте дә булырга тиеш. Татар мәдәниятына яшәү һәм үсү өчен Татарстаннан башка урын юк, димәк, аның бәйсез дәүләте дә биредә булырга тиеш.

Тарихны өйрәнүче язучы буларак, мин шуны әйтәм,— 1552 елдан бирле без Россия белән солых төземәгән килеш яшибез, тарихта безнең ирекле рәвештә Россия составына кучүебез турында бер генә документ та юк, формаль яктан без Россия белән — әле һаман сугыш хәлендә.

Экономик яктан килеп, Татарстан республикасының хәлсезлеген, суверен дәүләт булсак, авыр хәлдә каласыбызны да исбатларга тырышырлар. Әйе, без хәзер хәлсездер. Инде бирәсен биреп бетердек, ярлыландык, зәгыйфьләндек. Ләкин гасырлар буе таланган халыкның ирекка, бәйсезлеккә хакы юкмыни?! Кайда язылган ул закон?

Татарстанда яшәүче русларга да берничә сүзем бар. Ни хәл итәсең, менә ничә гасыр инде без — татар җирендә руслар белән тарих карынында бергә формалашкан ике халык. Без шулхәтле бергә укмаштык ки, кайсыдыр буында, Сиам игезәкләре кебек, берберебезгә ябышып үсә башлаганбыз. Башта бу гайре табигый хәл кызык, тамаша кебек тоелса да, ике халыкның укмашып, бер-берсен йотуы — ул милли фаҗигагәнең башы инде. Нәтиҗәдә, без ике зур мәдәниятны, ике милләтнең гүзәл сыйфатларын да югалта барабыз. Тамырсыз, миһербансыз, ни рус, ни татар булмаган имансыз затлар хәзер Казан урамнарында кеше үтереп йөриләр. Алар — милләтсезләр. Ике милләт тә үзенең асыл сыйфатларын җуя бара. Безгә Сиам игезәкләре булып кабергәчә бергә барыргамы, әллә аерым ике милләт булып үз тарихи юлыбыз белән китәргәме? Мин — аерым милләт булып үсү ягында. Ләкин һәр милләтнең, һәр кешенең бу мөстәкыйль дәүләттә хокуклары гарантияләнгән булырга тиеш. Руслар суверен Татарстан дәүләтендә үзләре теләгән телдә сөйләшә алырга, үзләре теләгән җирдә яшәргә, үзләре теләгән урында эшләргә, үзләре теләгән тормыш корырга тулы хокуклы! Шушы ук демократия, ирек татарлар өчен дә, руслар белән бер дәрәҗәдә, тигез кулланылырга тиеш. Шул чагында гына Татарстан илендә тынычлык, татулык булачак.

Хәзер аерым руслар тарафыннан Татарстанны Казан өлкәсе итәргә, Казанны исә Татарстан буйсынуыннан чыгарырга дигән мәгънәсез фикерләр әйтелә. Татарлар мондый вәхшилеккә беркайчан да юл бирмәячәкләр.

Мин, күп балалы гаиләдә үскән гади көтүче баласы, бу югары трибунадан дәүләт турында үз сүземне әйтү өчен 438 ел буе тарихымнан кан-яшь аша килдем. Әгәр дә упкын читенә килеп җиткән халкым бүген дәүләтсез кала икән, иртәгә минем өчен яшәүнең мәгънәсе юк. Халкымның төп теләген үти алмасам, миңа депутатлык мандаты йөртүдән дә мәгънә юк.

## Татарстан ССР халык депутаты Роберт Миңнуллин:

Хөрмәтле мәҗлес рәисе!

Хөрмәтле халык депутатлары!

Сессия алдыннан мин мондыйрак күренешне күз алдына китергән идем. Фойе. Утырышлар залы. Менә-менә сессия башланырга тора. Совет Татарстанының, татар халкының язмышы хәл ителәчәк. Зал тулы журналистлар. Күрше республикалардан, күрше өлкәләрдән килгәннәр. Мәскәүнең, чит илләрнең танылган журналистлары — фотокорреспондентлар, тележурналистлар, репортерлар депутатлардан интервью ала... Ни өчен

дисәң, ил күләмендәге тарихи вакыйга гына түгел бу. Олы бер халык, олы бер республика бәйсезлек яулый! Әмма юк шул... Бирегә килгән журналистларның һәммәсе дә — үзебезнең Казанныкылар, Матбугат йортында эшләүче минем коллегаларым. Күреп торасыз, безнең бүгенге республикабыз, автономия буларак, дәүләт берәмлеге буларак, хәтта Союз күләмендә дә бернигә дә тормый, беркемне дә кызыксындырмый. Бу — чыннан да шулай!

Безнең татарлар 70 ел буена, «совет кешесе» сыйфатында, коммунизм төзеде, Бөек Ватан сугышында, Әфганстанда «рус солдаты» псевдонимы белән сугышты. Хәтта зур юбилейларда да, бәйрәм тантаналарында да без фәкать күзәтүче сыйфатында гына катнаша алдык, чөнки анда иң «лаеклы» халыклар һәм милләтләр генә — унбиш союздаш республика вәкилләре генә хуҗа иде. Ә инде дөнья җәмәгатьчелеге өчен без, гомумән, беркем дә түгел. Безнең барлыкны белмиләр дә, белергә дә теләмиләр. Бу бер дә без бәләкәй халык яисә бәләкәй республика булганнан түгел, ә республикабыз хокуксыз булганга күрә шулай. Лихтенштейн дигән бер ил бар. Карлик ил. Шушы көннәрдә генә аның БМО әгъзасы булачагы турында хәбәр булды. Шунда мин үзебезнең бернинди дә хокукы булмаган Татарстаныбызны уйладым, гарьләнү һәм кимсенү хисләре кичердем. Миңа калса, дәүләт суверенитеты турындагы Декларациягә менә мондый әһәмиятле пунктны, һичшиксез, өстәргә кирәк: «Татарстан ССР үзенең вәкаләтханәләрен ССР Союзында, союздаш республикаларда, шулай ук чит илләрдә ача ала». Моңа мохтаҗлык бүген үк бар инде.

Мин биредә классикларыбызның, җәмәгать эшлеклеләребезнең суверен республика файдасына әйтелгән яисә язылган сүзләрен, фактларны, саннарны китереп тормыйм. Соңгы айларда матбугат битләрендә алар күп булды. Декларация проектын тикшерү кискен төстә барды. Бу мәсьәләгә битараф калучы, мөгаен, булмагандыр. Суверенитет турындагы фикерләр саллы да, төпле дә, эмоциональ дә, шул ук вакытта каршылыклы да. Бәйсезлеккә каршы язылган мәкаләләрдә еш кына, минем карашымча, сәер бер сүзтезмә очрый. Янәсе, «шәхсән мин үзем суверенлык яклы, ләкин...» Шуннан соң инде контрдәлилләр санап кителә. Ул субъектив һәм бик тә шикле фикерләр минем үземне дә, сайлаучыларымны да берничек тә ышандыра алмаслар. Ни генә булмасын, без бу сессиядә суверенитет турындагы Декларацияне игълан итәргә бурычлыбыз. Соң кайчан да булса без дә цивилизацияле нормаль бер илдә яшәргә тиештер бит инде?!

Барыбыз да белә: соңгы вакытта көтмәгәндә-уйламаганда безнең белән Мәскәүдәге иптәшләр кызыксына башлады: төрле галимнәр, политологлар, социологлар, төрле партия лидерлары. Хәтта республикага Б. Н. Ельцин үзе килеп төште. Баксаң, без әле бөтенләй үк беткән халык түгел икән. Баксаң, без әле кемнәргәдер кирәк тә икән. Ләкин ни өчен кирәк без аларга? Аларның ни өчен килүләре безгә аңлашылды инде. Бигрәк тә Россиянең беркемгә дә охшамаган лидеры үз эшен эшләми калмады. Республика халкының бер өлеше «Ельцин синдромы» белән авырый башлады. Минем үземә Борис Николаевичның: «Күпме булдыра аласыз, бәйсезлекне шул кадәр алыгыз!»— дигән сүзләре хәтергә сеңеп калды. Башкортстанда да шул ук сүзләрне кабатлады ул, ләкин аз гына үзгәртебрәк: «Күпме «йоталасыз»,шул кадәр суверенитет алыгыз!» Ирексездән Пугачевныңмы, әллә Разинныңмы (төгәл генә исемдә калмаган) әйткән сүзләре хәтеремә төште: «Мин сезгә ирек алып килдем!» Кызыкмалы сүзләр, шулай бит?! Ә безгә, чыннан да, күпме бәйсезлек кирәк соң? Безне фәкать тулы бәйсезлек, чын азатлык кына канәгатьләндерә ала. Суверенитет — порцияләп алырга, ит тә, сөт тә түгел. Менә шуңа күрә Татарстан язмышын Ельцин белән генә бәйләү, йомшак кына итеп әйткәндә, житди түгел. Лидерлар, патшалар, президентлар киләләр дә китәләр, ә халык һәм дәүләт кала. Шуны онытмаска кирәк.

Аннары Россиянең зур һәм кечена милләтләре бездән башка да хәттин ашкан. Алар белән дә күпме мәшәкать, күпме проблема! Шуңа күрә, әйдәгез, үз проблемаларыбызны үзебез чишәргә тырышыйк! Үзеңнең бөтен житешсезлекләреңне, эшлисе эшләреңне башкалар җилкәсенә өю, бертуктаусыз сорану, теләнү безне бер дә бизәми. Шул кадәр дә булдыксызмыни без?! Шушы экономик, политик, социаль кризистан үзебез генә чыга алмабызмыни? Башкалар ярдәменә генә таяну, шикләнү-шөбһәләнү, өметсезлеккә бирелү — начар юлдашлар.

Аннары тагын бер нәрсә. РСФСР составында калуны яклаучы кайбер депутатлар: «Республика Министрлар Советының бүгенгә экономик концепциясе юк, алар әле базар экономикасына күчәргә әзер түгел»,— димәкчеләр. Без бит әле базар экономикасына күчү турындагы докладны тыңламадык. Аларның нәрсә белән сөендерәселәрен, йә булмаса, нәрсә белән көендерәселәрен белмибез. Шунлыктан, андый фикерләр белән алдан ук сату итмәскә кирәк, дип уйлыйм.

Тагын бер әйберне әйтәсем килә. Суверенитет идеясен юкка чыгарырга тырышучылар фикеренчә, ул, янәсе, югарыдан төшкән идея. Шулай булса икән ул! Әгәр дә бу мәсьәләне ниндидер бер лидер кузгаткан булса, ул инде сиксән бишенче елның апрелендә

үк хәл ителәр иде. Шуңа да карамастан, һәр милләт, һәр республика иртәме-соңмы үзенең милли проблемаларын хәл итәргә тотыначак. Бу процесс кузгалды инде. Аны туктату мөмкин түгел. Республикалар бер-бер артлы суверенитет турында Декларацияләр кабул итә. Күршебез Башкортстанда да зур әзерлек бара. Башкортстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең БАССР Югары Советы Президиумы әзерләгән проектында беренче пункт менә нинди: «Башкортстан Совет Социалистик Республикасы — суверен совет дәүләте, ССР Союзы субъекты». Бу юлларны укыганнан соң миңа күңелсезрәк булып китте. Күршеләрнең проекты безнекенә караганда шактый кыюрак. Бер үк вакытта СССРның да, РСФСРның да субъекты булу — элекке хәлдә калу дигән сүз ул. Арыслан бер үк вакытта иректә дә, читлектә дә яши алмый. Аны яисә ирекә җибәрергә, яисә читлеккә ябарга кирәк. Соңгысын без инде үз җилкәбездә күп татыдык. Башкача телимибез! Әгәр дә без, чыннан да, азатлык телибез икән, әгәр дә икеләтә изелү астында яшәү безгә ошый икән, әйдәгез, элекке килеш калыйк. Аның өчен суверенитет турында Декларация кабул итү мәҗбүри түгел. Үз-үзебезне алдамаска кирәк. Әгәр дә суверенитет безнең өчен һәм политик, һәм экономик, һәм милли мәҗбүрият икән (ә бу чыннан да шулай), Декларацияне кабул итү безнең намус эшебез. Безнең бу карарны күршеләребез дә түземсезлек белән көтәләрдер, дип уйлыйм.

Без кичә депутат Р. Хафизовның докладын тыңладык. Декларация проектына кертелгән шактый төзәтмәләр белән килешмичә булмый. Алар — эшлекле һәм кирәкле төзәтмәләр. Дәүләт символикасы турындагы яңа пункт та, һичшиксез, кирәк. Теләсә кайсы дәүләт иң элек гербтан, флагтан һәм гимннан башлана. Республикабызга килгән рәсми кунакларны чәкчәк белән генә күпме каршыларга була инде?! Алдагы сессияләребездә утырышларны Татарстан республикасының дәүләт флагын хөрмәтләү тантанасы белән башларбыз, шәт.

Декларация проектын тикшерү, миңа калса, эшлекле төстә бара. Күңелдә бераз өмет тә уянды: күптән көтеп алган суверенитет турындагы Декларацияне без мөгаен, кабул итәрбез. һәм шул чагында гына без бер-беребезнең күзләренә туры карый алачакбыз. Ләкин бу әле кабул иттек тә шуның белән эш бетте дигән сүз түгел. Киресенчә, барысын да әр-яңадан башларга туры киләчәк. Безнең барыбызны да яңа проблемалар, яңа авырлыклар көтә. Аларны безгә хәл итәсе!

## РСФСРның халык депутаты Ринат Мөхәммәдиев:

Иптәшләр! «Әгәр кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә кагылышлы булсалар, хәтта геометрик аксиомалар да кире кагылыр иде» дигән бик тә мәгънәле гыйбарә бар. Чыннан да, кайбер депутатларның кыланышына игътибар иткәч, аларның республикабыз суверенлыгына юл куймас өчен генә дә чиктән ашып тырышуларын, әллә нинди сылтау-сәбәпләр эзләп маташуын күргәч, әлеге гыйбарәнең дөреслегенә тагын бер кат ышанып куясың. Ә бит, югыйсә, сталинизмның кара чорларында да (кәгазьдә генә булса да) дәүләт буларак яшәгән, үз конституциясе һәм Югары Советы булган республикабызның суверенлык мәсьәләсе беркемдә дә шик тудыра алмаска, бәхәссез булырга тиеш кебек. Шулай, хөрмәтле депутат иптәшләр, күрәсең, кайчак бәхәссез аксиомалар да шик астында кала ала икән...

Әмма барыбер — иртәме-соңмы — хаклык һәм хакыйкать өскә калкып чыгар, аксиомалар аксиома булып калыр, татар халкының гасырлардан килгән өмет-омтылышлары ниһаять тормышка ашар, безнең республикабыз да башкалар белән беррәттән тигез хокуклы булыр, бүтән союздаш республикалар арасында үзенә лаек урын табар дип ышанасы килә. Чөнки барлык халыкара килешүләрдә, хокук турындагы халыкара документларда һәр милләтнең үзбилгеләнү хокукы акка кара белән ап-ачык итеп язылган.

Моннан ике ай ярым элек мин, РСФСР халык депутаты буларак, һичбер икеләнүсез Россиянең суверенлыгын яклап тавыш бирдем. Чөнки ирекә, мөстәкыйльлеккә каршы тавыш бирү, тирән ышануымча, иллә дә зур әхлаксызлык булыр иде. Үз мәнфәгатьләреңне нинди дә булса халык мәнфәгатьләреннән өстен кую, аның рухи ирекә, суверенлыкка омтылуына каршы тору мөмкин дә түгел, минемчә. Әгәр шулай булмаса, безнең демократия шартларында һәм хокукый дәүләттә яшәргә теләвебез дә уйдырма бер вәсвәсәгә генә кайтып калыр иде түгелме?

Минемчә, үзен демократ дип атап йөрткән, әмма чынлыкта әле һаман да империячел карашлардан арынып җитмәгән һәм шул карашлардан чыгып эш итәргә тырышкан депутатлар үз максатлары, үз юнәлешләре турында ныклап уйланырга, үз сүзләрен тагын бер кат үлчәп-бәяләп карарга тиеш. Империячел максатлар һәм

демократия — бер-беренә капма-каршы булган төшенчәләр һәм алар бер үк кеше җанында берьюлы һичничек тә сыеша алмый. Бу мөһим мәсьәләдә безнең һәркайсыбыз ныклы, төпле һәм табигый фикергә килер дип ышанам!

Бүген без Татарстанның язмышында, аның тарихында гаять зур әһәмияткә ия булган юл чатында торабыз. Юк, сүз монда нинди дә булса административ территориянең хәле турында гына түгел, ә бәлки кешелек дөньясының аерылгысыз бер өлеше булган зур бер халыкның, күп гасырлар традицияләре булган мәдәниятның һәм әдәбиятның, әйтеп бетергесез әһәмияткә ия булган үзенчәлекле телнең язмышы турында бара. Мәсьәләнең әнә шул мөһим ягын күрмәмешкә салышу, аннан читләшергә тырышу гафу ителмәслек бер хәл булыр иде. Нинди генә дәрәҗәгә ия булып, нинди генә эш башкармасыннар, кайсы гына милләттән булмасыннар — барлык депутатлар да иң беренче чиратта вөҗдан тавышына колак салырга, гуманлылык, кешелеклелек һәм интернационализм принципларыннан эш итәргә тиеш дип уйлыйм. Республика халкының язмышын, аның киләчәген билгеләячәк мәсьәләләрне хәл иткәндә тәкәбберлек тә, эгоизм да, империячел фикерләр дә кискен рәвештә кире кагылырга, партиягә һәм карьерага бәйле максатлар арткы планга күчерелергә тиеш.

Казанның демократик партия тарафдарлары үзләренең басма органнары булып әверелеп барган «Вечерняя Казань» газетасы битләрендә татар халкын һәм халык депутатларын суверенлык идеясеннән шактый нык куркытып-читләштереп килергә тырыштылар. Алар фикеренчә, имеш, үз-үзебезне туендырып тору да, халык кулланышы товарлары белән тәэмин итү дә безнең үз көчебездән генә килмәячәк, имеш, бездән нефтьне сатып алмаячаклар һәм, гомумән, депутат Колесник әйтүенчә, безнең белән сәүдә мөнәсәбәтләрен өзәчәкләр. Янәсе, раковина һәм юынгыч кебек кирәк-яраклар үзебездә җитештерелмәү сәбәпле, без хәтта торак йортлар да төзи алмаячакбыз. Күрәсез, иптәшләр, кайбер депутатларның фикере, әгәр моны куштырнаклар эчендә әйтсәк, үтә дә «төпле һәм саллы» яңгырый.

Болар әле мәсьәләнең экономик ягына кагылышлы сүзләр генә. Ә менә татар халкының киләчәге, рухи офыклары ничегрәк күзаллана соң? Монда инде, әгәр әлеге дә баягы газетаның сүзләренә ышансак, бөтенләй дә упкынга төшәбез, караңгы базга килеп керәбез икән. Аерым җөмләләрдән мисал китерәм: «Язучылар, русчаны һәм татарчаны болгатып, агач тел белән язалар. Шуңа күрә аларның китаплары кибет киштәләрендә тузан җыеп ята... Татарлар үз балаларын туган телдә укытырга теләмиләр... Культураның югалуына һәм югала баруына татар түрәләре һәм татар эшмәкәрләре үзләре гаепле...» Бер сүз белән әйткәндә, ахырзаман җиткән, иптәшләр.

Бу әле — соңгы вакытларда милли мәдәниятка, татар халкының тарихына, республикабызга шушы газета битләре аша ягылган төрле яла һәм уйдырмаларның берсе генә. Андый мәкаләләрнең авторлары нинди максат белән эш итәләрдер — билгесез, әмма әлеге вәсвәсәне бик тә белеп туплап бирүче редакциянең максаты ачык күренеп тора: Татарстанның колониаль коллык кысаларыннан котылуына аяк чалу, татар халкының милли үзаңы уянуга, милли горурлыгы үсешенә ничек кенә булса да тоткарлык ясарга маташу.

Шундый житди һәм гап-гади бер сорау туа: республиканың төп халкы ихтыярын санламаган, шул халыкның үзенә һәм аның рухи омтылышларына, халык тарафыннан танылган иҗат әһелләренә, тулы бер иҗат берлекләренә каршы ачыктан-ачык пропаганда алып барган газетаның үзен «халык газетасы» дип атарга хакы бармы?

Соңгы вакытта референдум үткәрү зарурлыгы турында да сүз куертучылар булды. Аерым алганда, депутат Косулин һәм Воробьев иптәшләр икесе дә бертавыштан референдум үткәрүне яклап сөйләделәр. Хәер, моңарчы безнең илдә андый акцияне әле беркемнең дә үткәргәне булмады. Россия дә, Төрекмәнстан да, Молдова да, Литва да, шул исәптән үз территориясендә бары тик 30 проценттан чак кына артыграк җирле халкы булган Казахстан да — ягъни үзен суверен дип игълан иткән республикаларның барысы да әлеге мәсьәләне парламент юлы белән хәл кылды. Бу беренчедән! Икенчедән, Татарстанның язмышы референдум үткәрү юлы белән хәл ителгән очракта, моны илдәге барлык татарлар катнашыннан башка уздыру ярамас һәм мөмкин дә булмас иде. Чөнки Татарстаннан читтә яшәүче татар халкы үз туфрагыннан, ата-бабалар җиреннән үз теләге белән түгел, ә бәлки хәерчелек нәтиҗәсендә, өзмәс-куймас золымнар, кимсетелүләр һәм рәнҗетелүләр нәтиҗәсендә аерылган. Аллага шөкер, милләтләрнең үзбилгеләнү хокукын әле беркем дә тартып алмаган.

Күпләрне, суверенлык алган очракта, республикабызның базар экономикасы шартларында яшәп алу-алмау мәсьәләсе борчый. Безне төрле яклап кысәргә тырышалар: әгәр дә Россия нефть үткәргечләрен ябып куйса, йә булмаса безнең су транспортларын үз шлюзлары аша үткәрмәсә, тимер юлларга һәм һава юлларына кертә корса, нишләрбез, янәсе. Җавап бирәм, депутат иптәшләр: демократик һәм хокукый дәүләт буларак, Россия мондый нәрсәләргә бара алмый. Барлык мәсьәләләрне көч һәм диктат

ярдәмендә генә хәл итү заманнары инде артта, тарих ызаннарында калды. Россиянең Югары Советы рәисе иптәш Ельцин үзе дә РСФСРның Татарстан игълан иткән һәртөрле суверенлыгын һәрьяклап хуплаячагы, төрле кул сузучылардан катгый яклаячагы турында күп тапкырлар белдерде. Үзен суверен дәүләт дип игълан итеп, Татарстан һичкем белән, бигрәк тә Россия белән каршылыкка керми. Татарстаннан читтә, әмма РСФСР территориясендә 3 миллионнан артык татар, ә Татарстанда 1,5 миллион рус кешесе яшәү факты үзе генә дә андый турыдан-туры каршылыкка илтер мөнәсәбәтләрнең була алмаячагын күрсәтеп тора. Үзара дуслык һәм аңлашып яшәү хисе — һәркем өчен дә газиз, сулар һава кебек үк зарур һәм уртак нәрсәләр.

Үзара тигез хокуклы мөстәкыйль республикалар алдында моңарчы күрелмәгән мөмкинлекләр — экономик, мәдәни һәм сәяси хезмәттәшлек юллары ачыла. Суверен республикалар арасында төзелгән килешүләр аларны үзара тагын да якынайтачак, халыклар арасында чын, әчкерсез, демократик мөнәсәбәтләр тууына уңай шартлар булдырачак.

Ә инде халык кулланышы товарларының җитенкерәмәү куркынычы мәсьәләсенә, ягъни чынаяк-кәстрүл, раковина-юынгыч кебек товарларны җитештерә алу-алмавыбыз турындагы сүзгә килгәндә, аларның әле хәзерге көндә дә зур дефицит икәнлеген иң беренче чиратта әйтү кирәк. Икенчедән, республикабыз территориясендә оборона промышленносте корылмаларының шыплап тутырылган булуына республика үзе, аның халкы гаепле ме? Монда җитештерелгән һәртөрле товар һәм продукциянең үзәк тарафыннан уңга-сулга чәчелүенә безнең халык гаепле ме? Әйтик, Ирак кына да безгә инде 6 миллиард сумга әҗәткә кергән... Ә Әфганстанга күпме байлык түгелгән? Эфиопиягә һәм Суданга? Болар өчен Россия халыклары һәм шул исәптән Татарстан халкы гаепле ме? Ә бит бер генә суверен республика да алга таба мондый башбаштаклыкларга юл куймаячак һәм үз байлыгын теләсә кая, теләсә ничек таратырга ирек бирмәячәк.

Татарстанны ике федерация субъекты буларак күзалларга тырышып әзерләнгән декларация проектына килгәндә, моның инде бөтенләй мәгънәсез бер нәрсә икәнен ачыктан-ачык әйтү кирәк. Бу инде хәтта Сталин заманы конституциясеннән дә түбәнгәрәк тәгәрәү, Татарстанны ике хуҗаның бер ишәге хәлендә калдыру булыр иде. Җитмәсә, андый икеләтә буйсынуны Татарстан үзе теләп алган очракта, кемгә дә булса үпкә белдерергә, зарланырга да урын калмас иде. Кыскасы, әлеге декларация проектында чын суверенлыкның исе дә, төсе дә юк.

Ә инде суверенлык мәсьәләсендә башка ярым-йорты тәкъдимнәр турында шуны әйтәсе килә, хөрмәтле халык депутатлары: суверенлык ул бер генә төрле — йә бар ул, йә юк. Һәм, гомумән, бер упкын аша сикергәндә ике тапкыр омтылыш ясап булмый. Бер омтылыштан ук сикереп чыга алмасаң, икенче омтылыш инде упкын эченә алып төшеп китәргә мөмкин.

Һәрхәлдә, мин халык депутатларының Татарстанның вәкаләтле вәкилләренең сәяси әзерлегенә, акыл-зиһененә чын күңелдән ышанам!

## Татарстан ССР халык депутаты Разил Вәлиев:

Мөхтәрәм кардәшләр!

Хөрмәтле депутатлар!

Мин сезнең каршыда үземнең туган телемдә — татарча чыгыш ясарга җыенган идем. Ләкин бүген сүземне татарлар гына түгел, урыс туганнар һәм урыслашкан милләттәшләрем дә ишетүен һәм аңлавын телим. Әгәр алар белән бүген урыс телендә дә аңлаша алмасак, киләчәктә безгә бер-беребезне аңлау тагын да кыенлаша төшәр дип шикләнәм.

Шуралар берлеге һәм Рәсәй федерациясенең таркалуга хөкем ителүен һәм аларны яңадан сүтеп җыярга кирәклеген бераү дә инкарь итми торгандыр. Ләкин безнең арада әле эчтән генә «бөек империя»не саклап калу хыялы белән янучылар да байтак. Нәкъ менә шуңа күрә дә Татарстанда һәм башка милли республикаларда СССРның һәм РСФСРның, колониаль политикадан ваз кичеп, үзләренә ирек бирүләренә ышанып бетмиләр. Һәм шул сәбәпле алар, бәйсезлекнең «күктән төшүен» көтмичә, үзләренә суверенитет яулау юлына басалар.

Татарстанның РСФСР һәм СССР берлекләренә керүе бүгенге көнгә кадәр берминди законлы актлар һәм килешүләр белән ныгытылмаган иде, һәм шуңа күрә хәзер безгә, ниһаять, бу гаделсезлектән котылыр чак җитте. Республикабыз зыялылары, татар язучылары һәм мәдәният хезмәткәрләре Татарстан мөстәкыйльлеген яклап

көрәшүче һәммә сәяси көчләрнең, җәмгыятьләрнең һәм аерым шәхесләрнең фикерен яклый һәм бу өлкәдә лаеклы өлешен кертергә тырыша. Бу турыда без-татарлар гына түгел, башка милләт вәкилләре дә белергә тиеш. Чөнки аларның күбесе Татарстаннан китәргә җыенмый һәм шулай ук безнең белән пычакка-пычак яшәүне дә максат итеп куймый торгандыр. Ә инде 150 миллионлы урыс халкы белән 7 миллионлы татар халкының сан һәм көч нисбәтләрен күз алдына китергән кеше өчен кайберәүләрнең Татарстанда «азчылык» дип саналган урыслар хокукы кысылудан куркуы бөтенләй көлке булып тоела башлый.

Күптән түгел матбугатта Татарстан Югары Советы президиумы раслаган Декларация проекты басылып чыкты. Кызганычка каршы, ул халыкның күпчелеген канәгатьләндерерлек дәрәҗәдә түгел. Ә инде Декларациянең Татарстанны Рәсәй һәм СССР субъектлары дип игълан иткән беренче статьясы бернинди мантыйк кысаларына да сыеша алмый. Киләчәктә республиканың Югары Советы җитәкчеләре, мондый мөһим документларны әзерләгәндә, игътибарлырак һәм таләпчәнрәк булсын, аның карарлары халыкара хокук таләпләренә тәңгәл килерлек итеп эшләнсен иде.

Мөстәкыйль Татарстан Республикасын мин бары тик демократик җәмгыятьле җөмһүрият итеп кенә күз алдына китерәм. Ләкин бүгенге Югары Советтагы һәм министрлар кабинетындагы сәяси көчләрнең республиканы демократик булмаган юлдан алып китү мөмкинлеге дә бар бит. Һәм, шулай ук, Татарстан мөстәкыйльлек алмый торып, безнең республикада демократик җәмгыять төзү дә беркатлы буш хыял булып кына калыр иде.

Минемчә, мөстәкыйль дәүләтчелеккә омтылуның бүгенге чорында иң беренче эш итеп Татарстан Республикасының яңа Конституциясен төзи башларга кирәк. Төп Законны бөтенхалык тикшерүенә куйганнан соң, референдум үткәрү юлы белән кабул итү шарт. Зинһар, дөрес аңлагыз, суверенлык статусын түгел, ә Конституцияне кабул иткәндә референдум үткәрү мәгъкульрәк булыр. Депутатларның күбесе үзләренең сайлау алды программаларында Татарстанга союздашлык статусы алу өчен көрәшергә вәгъдә биргәннәр иде. Димәк, Татарстан халкы безне сайлаганда республика суверенитетын да яклап тавыш бирде. Россия, Украина, Белоруссия, Молдова һәм башка республикалар да, безгә үрнәк күрсәтеп, үзләренең мөстәкыйльлекләрен референдум үткәрмичә генә, Югары Совет сессияләрендә раслап куйдылар.

Әгәр дә Төп Законны референдум хөкеменә куеп кабул итсәк, моның белән без республикабызның мөстәкыйльлеген башка дәүләтләр тыкшына алмаслык итеп ныгытыр идек. Бу инде суверенитет турындагы Декларацияне тормышка ашыру юлында тәүге адымыбыз булыр. Мөстәкыйль дәүләт төзү — бер көнлек, хәтта бер еллык кына да эш түгел. Хыялдагы суверенлыктан гамәлдәге бәйсезлеккә күчү өчен күпчелек тавыш белән Декларация кабул итү генә җитми, моның өчен безгә җәмгыятебезнең ныклы экономик, сәяси һәм социаль нигезен корырга кирәк булачак. Бездәге «товар — план — товар» формуласын көнбатыштагы «товар — акча — товар» формуласына алыштырып кына җәмгыятебез муеннан кереп чумган баткаклыктан чыга алмаячак.

Бүген без, депутатлар, һәммәбез дә халык каршында, тарих каршында имтихан тотабыз. Бүгенге фикер алышулар, бәхәсләр һәм исемләп тавыш бирүләр барышында үзебезнең сәяси кыйблабызны гына яклап калмыйча, вөҗданыбыз, намусыбыз, сайлаучыларыбыз каршында да сынау узачакбыз. Яшерен-батырын түгел, халык арасында Югары Советны консерватив парламент дип атаучылар да шактый. Димәк, бүген безнең Югары Советыбыз, өр-яңа парламентыбыз, беренче мәртәбә халыкка чын йөзен ача, һәм бүген, ниһаять, безнең арада ничә демократ, ничә консерватор, ничә шовинист һәм ничә милләтпәрвәр, ничә ватанчы һәм ничә сталинчы булуы ачыклана. Үземә калса, мин бигрәк тә... теленнән, яисә дененнән язган, ата-баба иманыннан йөз чөергән маңкорт милләттәшләрем өчен борчылам. Кем әйтмешли, алар һәрчак каш ясыйм дип, күз чыгарырга «оста» бит. Урыслашкан гөрҗи Иосиф Джугашвили юкка гына карагруһ шовинистларның рухи атасына әверелмәгәндер инде...

Сугыш бетеп 15 көн үткәч, 1945 елның 24 маенда, Сталин Кызыл Армия командирлары хөрмәтенә оештырылган мәҗлестә котлау нотыгы тота һәм шунда тантаналы төстә урыс халкын дөньядагы иң бөек халык дип атый!

Мин үзем дөньядагы бер халыкны да иң бөек дип атамасам да, урыс халкының мәдәниятына һәм тарихына әле моңа кадәр хөрмәт саклап килдем. Шунысы кызганыч, соңгы арада татар халкының аяк астына салып тапталган хокукларын кире кайтару турында сүз чыга башлагач, шактый гына урыс туганнарыбызның интернациональлек рейтингы күзгә күренеп төшә башлады. Әгәр дә «мәңге бүленмәс Россия»гә табынучы депутатлар бу сессиядә Татарстан мөстәкыйльлегенә турындагы Декларациягә каршы килсәләр, мин алардан бөтенләйгә күңелем кайтыр дип шикләнәм. Бу хәл бер мине генә түгел, татар халкы һәм Татарстан республикасы язмышын үз язмышы итеп

санаган бик күпләрне борчый. Шунысы да кызганыч: бер-беребезгә үпкәләшеп, ачу саклап йөрүдән тегеләр дә, болар да отмаячак...

Мин үзем бу сессиядә ни-нәрсә өчен тавыш бирергә җыенам соң? Билгеле, иң беренче нәүбәттә «субъект» һәм «составында» дигән сүзләр кермәгән чын мөстәкыйльлек өчен. Аннан килеп, исемнәрне атап тавыш бирүне һәм аның нәтиҗәләрен матбугатта бастырып чыгаруны яклап чыгачакмын. Аннан тагын мин суверенитет һәм базар мөнәсәбәтләре шартларында яшәү өчен хөкүмәт программасын ашыгыч рәвештә төзүне таләп итеп тавыш бирәчәкмен. Әгәр дә хөкүмәтебез бүгенге кризистан чыгу юлын һәм киләчәк тормыш өчен үзенең мөстәкыйль экономик политикасын тәэмин итә алмый икән, димәк, ул берсүзсез отставкага китәргә тиеш.

Кайберәүләр, Татарстанда суверен дәүләт белән идарә итәрлек лидерлар юк, дип ышандырырга тырышалар. Әйе, чыннан да, моңа кадәр бездә халыкны демократик юлдан, мөстәкыйльлек юлыннан әйдәп барырлык чын лидерлар булмады. Моның сәбәбе бик гади: чөнки моңа кадәр безнең мөстәкыйль, суверен үз дәүләтебез юк иде. Андый дәүләт булмагач, дәүләт белән идарә итәрлек лидерларга да мохтаҗлык тумады. Велосипед алмый торып, берәү дә велосипедта йөрергә өйрәнә алмаган кебек, республикага мөстәкыйльлек алмыйча, аның белән идарә итәргә дә өйрәнеп булмаячак. Суверенлык юлына аяк баскан Татарстан җөмһүриятендә менә дигән яшь һәм талантлы җитәкчеләр пәйда булуына минем аз гына да шигем юк.

Үзен хөрмәт иткән теләсә-кайсы халык тигезлеккә һәм хөрриятккә омтылырга тиеш. Бу — доньядагы һәммә җан иясенең табигый халәте. Ә башка халыкларның тигезлек таләп иткән законлы хокукларын танырга теләмәү — әле кайберәүләрнең демократик цивилизациядән шактый ерак торуы, хаким милләтләрнең күңел тарлыгы, халыкара хокуклар белән исәпләшмәү, үз ишләреңнең: дустыңның, күршеңнең, яисә менә шушы Югары Совет залында утыручы иптәшеңнең кешелек дәрәҗәсен санга сукмау дигән сүз.

## Рәшит Әхмәтҗан

### Ант

*Фатих Кәрим истәлегенә*

Әткәм-әнкәм теле! Балаларың
Җир җимертеп эшли — тик ятмыйлар.
Бер-берсеннән уздырышып, хәзер
Мая туплый күпләр, мал саклыйлар.

Керфек какмый мал саклаган чакта
Балаларның «кемдер» телен кискән;
Тукай туганнарын таркаталган
Рухи юлбасарлар һаман исән.

Милли нигилистлар өммәтенә
Берләшкәннәр хәтер караклары,—
Таһирларны суга агызганда
Сандыкларын шулар кадаклады...

Яшәмәүне дәвам итсеннәрме,
Яшәүнеме әллә дәвам итик?!
Телдән төшкән сүзләр, уяныгыз,
Тукай дошманнарын таптап китик.

Телне саткан көмеш тиеннәргә
Алган киемнәргә төренгәнне
Чишендереп, шәрә калдырыйк без,
Үзе булыр — күзгә күренгәне.

Яндыр, телем,
Җаным яктылыгын
Каплап торганнарның күләгәсен!
Имансызлар хәзер ярты сүз дә
Безнең исемнәрдән сөйләмәсен.

Онытканның, телем, төшенә кер,
Хәтәр чорны бергә узыйк, хәтер!
Шулай булса гына, яшәүләрнең
Киләчәккә кеше серен әйтер.

---

Рәшит ӘХМӘТҖАН *(1941) — шагыйрь, «Гомер чишмәсе», «Кавышыр көн», «Йөрәк бәйрәме» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Дошманыңның, телем, канына кер,
Йөрәгенә кадал, йөзенә яз...
«Китмибез»не[1] кабат укысыннар —
Кемнәр әлифбаңны таный аз-маз.

...Читлекләргә яптырсаң да мине,
Мылтыклардан аттырсаң да мине,
Бүген менә, Фатих Кәрим кебек,
Атакага мин күтәрәм сине!

Синең өчен, туган илем өчен,
Балам өчен бүген утка керәм.
Ышан, телем, һәрбер авазыңны
Азат итәчәкбез берәм-берәм!

❁

Болан күзе сыман моңлы итеп
Карый ласа монда һәр тамчы!
Шулай карап торачаклар әле
Бар җансызлар сулыш алганчы.

Дөнья йоклый.
Болар хәрәкәттә,
Болар инде былтыр уянган.
Арган җаным өчен җемелдиләр:
— Үлем диганнәре — шыр ялган!..

Яшәтәләр! Җаның күпме тели —
Шул кадәрле җирдә син яшә.
Акыл булып таралачак алар —
Акылсызлык беткән көнгәчә.

Шулай багып торачаклар әле,
Кемдер килеп агу салганчы.
Кеше җаны кебек — яклауларга,
Саклауларга мохтаҗ һәр тамчы.

Бездән соң да һәрбер һәлакәткә
Болар әле каршы торачак,
Кеше җанын яклау кирәккәндә
Бездән кыюрак булачак!

Күпләр өчен дөнья хәрәкәтсез.
Болар тере, болар моңлана...
Уйланам мин: болан күзе белән
Ниләр бага икән дөньяга?

❁

Йөри-йөри шулай, сары яфрак
Яктысына калдым. Һай, кыен.
Һәр яфрагың, җирем, кыңгырауга
Әйләнә дә... чыңлый бар уем.

Уятырмын чыңлап кешеләрне —
Минем уйлар бүген кыңгырау.
Әйтер сүзне сөйләп кенә түгел,
Сайрап бирәм — барсы саңгырау.

Дөрләгәнне — өреп сүндерәләр,
Очсаң — күндерәләр көтәргә.
Нигә болар ирек бирми миңа
Сөюемдә янып бетәргә?!

Сүндерәләр — сүнеп баручылар,
Күндермәкче була — күндәмнәр.
Ә бит, җирем, синекеләр элек
Ут күзенә бергә кергәннәр.

Сүнгәннәре —
Шуңа күнгәннәре
Күбәяме әллә?— Дәшмисең.
Балалары хәмер эчеп үлгән
Аналардай моңсу яшисең.

Азмы, җирем, асыл ирләр синдә!—
Йөрәкләре җырлы кыңгырау.
Туйдырмасмы икән аларны бер
Саңгыраулар өчен — яңгырау?

---

[1] Г. Тукай шигыре.

*

Дөнья тып-тын. Җир охшаган күккә,
Күк охшаган җиргә... Җиңеллек.
Шушы җиңеллектән җан шикләнә:
Без кайдадыр, ахры, җиңелдек.

*

Утлар салдым Идел бозларына,
Алып китсен әле дулкыннар.
Алдан барып сиңа бу дулкыннар:
Сагына, дип, әйтеп куйсыннар.

Кил, язларда яши башлыйк, ярым,
Бергә янсын әле йөрәкләр.
Бергә янса гына бу йөрәкләр —
Бәхет белән дөнья бүләкләр.

Кайталмабыз инде илләргә, дип
Киткән кошлар кайтып киләләр.
Сагышларын салсаң көймәләргә —
Су астына китәр көймәләр.

Кил, язларда яши башлыйк, ярым,
Сагынулар бигрәк саргайтты.
Кошларның да яшел яфракларга
Кагылды бит инде канаты.

Кавышырга соңга кала күрмик,
Башка ярлар миңа — салкын кар.
Күңелдәге бозны эретергә
Язым булып кайт син, сөйгән яр.

Кил, язларда яши башлыйк әле,
Язлар сиңа каршы йөгерде.
Узарсыңмы? Упкын өсләренә
Күпер итеп сузам гомерне.

## Күрмәдең

Мондый язлар барын белми идем,—
Ярый әле сине күргәнмен...
Бөтен яме син булгансың икән
Судай агып киткән көннәрнең.

Мондый болын барын белми идем,—
Гомерләре үткән кемнәрнең?..
Исемеңне синең телгә алгач,
Күз яшьләрен күрдем гөлләрнең.

Мондый сагыш барын белми идем,—
Кылганнарын тарый үрләрнең...
Башка чара барын белмәдем мин,
Шул үрләргә менеп дөрләдем.

Мондый гомер барын белми идем,—
Мәхәббәттән чак-чак үлмәдем...
Гашыйк булып озак яшәдем мин,
Тик син генә мине күрмәдең.

❀

Вак кешеләргә бай заман, хуш инде,
Синдә бүген минем урын буш инде.

Шактый гына туры килде түзәргә,
Көн бирмәдең шигъри ләйсән тезәргә.

Уйлар күгеңнән егылып төштеләр,
Кулларымны тотты көчле кешеләр.

Бар җыйганым, бар тапканым түгелгән,
Калганнарын таладылар күңелдән.

Алар шулай кол булырга өйрәткән...
Ничек качыйм үземнең хөр йөрәктән?!

Ияреп ул имансызлар артыннан,
Ничек качыйм ирек сөйгән халкымнан?!

Күпме генә утны җанга төрмәдек,—
Өзелмәде халык белән бергәлек!

Вак кешеләргә бай заман, хуш инде,
Безне аскан мәйданнарың буш инде.

Кеше саткан базарларың таралган,
Сатканнарның йөзе күптән каралган.

Бар кәрваннар сиңа каргыш ташыган...
Мә шигырьне! Киләчәккә ашыгам.

❀

Гомер агачымның җимешләре
Бүген генә гүя өлгерде:
Тәмамладым сине, и шигырем,
Була күрмә кыска гомерле.

Туйган инде кыска гомерләрдән,
Кайгы калдыралар киткәндә,—
Кичтән озатам да, әнкәм таный
Алмас хәлдә булам иртәнгә.

Көнлекчеләр килеп юаталар:
Имеш, җирдән ниләр китмәгән?!
Әй, читкәрәк китегезче миннән,
Чикле гомерләрдән шикләнәм.

Бер шигырем үлсә — куанышып
Көндәшләре көлә гомернең.
Юкка шатланалар, халкым өчен
Шактый җырлар язып өлгердем.

Кыска гомерлесен — әзер бит мин
Үз кулларым белән сызарга...
Тудыр, халкым, яңа Тукайларны,
Без батырдык сине моң-зарга.

*

И туган тел!
Сине Әнкә итеп
Йөрәгендә саклый бу халык.
Таралган ул... Әгәр Син булмасаң,
Бетәр иде күптән югалып.

Югалмадың,
Югалтмадың безне —
Халык исән калган Син барга.
Бу дөньяга күзебезне ачтың,
Хакыбыз юк кабат йомарга.

Ләкин күпләр үз йортыннан куды
Бүген Сине — үзенең Әнкәсен.
Үз әнкәсен йорттан куган кеше,
Туган илем бар, дип әйтмәсен!
Әйтмәсен!..

## Алдану

Изгеләрдән кай җирем ким, дия-дия,
Җирдәге яхшы-яманны барладым.
Яманлыклар бетәренә ышандырып,
Кешеләрне мин дә шактый алдадым.

Бетәселәр бөгелеп тә тормадылар,
Туп-турыдан үрләделәр югары.
Күз алдымда бар дөньямны тар-мар итеп,
Минем җаным аша узды юллары.

Күрмәмешкә салышырга туры килде
Кайберсенең качып-посып калганын;
Мин барыбер көне-төне җирдән кудым,
Көне-төне мин аларны каргадым.

Гомер шулай уза торды, туза торды...
Килеп җитте кеше булып калыр көн.
Каргышларың әгәр кылыч булалмаса,
Кеше булып калмавың да бик мөмкин.

*

Мең тәгълимат тузды — искермәде,
Исәннәргә бара ул һаман.
Исәннәрне исәпләгән чакта
Сөю мине таба алмаган.

Әллә мине тузган тәгълиматлар
Күздән яшергәнме ул көнне?
Яшәргә һәм яшәтергә туган
Җанны яшерергә мөмкинме?!

Йә күндереп кара ул халәткә
Бер сәгатькә генә... Кабынып!—
Тузганнарның бөтенесе шундук
Үзләренең көлен ябынып.

Тагын көл өстендә калган җаным
Исәннәргә барыр... Барачак!
Көн дә, Рәшит, бөек могҗиза көт —
Сөю сине эзләп табачак.

## Өмет — сездә!

Буйсынып без төрле әмерләргә,
Сыеп бетә яздык каберләргә.

Җир-күк белән бергә бәргәләндек:
«Ник үләргә дошманыңнан элек?!»

Бәргәләндек шулай «Сүнмәскә!» дип,
Бәргәләндек шулай «Үлмәскә!» дип.

Бәргәләндек шулай берәм-берәм,
Бәргәләндек бергә халык белән.

Янап торды үлем көпә-көндез...
Яшәтегез илне, яшәртегез!

Дәверләрнең килә яңалары,—
Халык улы! Өмет синдә бары.

Халык кызы! Өмет синдә генә,—
Әнкә бул син илнең йөрәгенә.

Гел давылдан торган дәверләрне
Безнекеләр имин үтәрләрме?

Шул турыда сорар идем җирдән —
Җир үзе дә шактый җимерелгән.

Шул турыда сорар идем күктән —
Күк эндәшми инде җиргә күптән.

Халык кемнең йөрәгендә яшәр?—
Шуны сорыйм бүген сездән, яшьләр.

Бирә халык сезгә яңа әмер:
— Җиңелгәнне көтә — җиде кабер...

Таралдыгыз читкә күпләрегез,
Тарайгандыр җир-су, күкләрегез.

Идел буйлап илгә агылыгыз,
Кирәк миңа сезнең акылыгыз.

Зирәк сәләтегез кирәк бүген,
Йөрәгегез — миңа йөрәк бүген.

Җанлансын бер изге уйларыгыз —
Ил кызлары, илгә җыйналыгыз.

Илгә җыйналыгыз, ил уллары!—
Көтә яңа дәвер давыллары...

Бөтен өмет — сездә генә бары!

## Чәчмә әсәрләр

# Газиз Үзиле

# ГЫЙФРИТ

РОМАН-ДИЛОГИЯНЕҢ ИКЕНЧЕ КИТАБЫ

5



әскәү, гадәттәгечә, миллионнарча утлары белән җемелдәп каршы алды Тынчуринны. Инде ничәмә-ничәнче тапкыр ул менә шулай башкала аэропортына килеп төшә. Ничәнче тапкыр ошбу кала белән очрашу вакытында дулкынлану һәм яшерен күтәренкелек сизә ул. Нәрсәсе бардыр, әмма һәр килүе яңача тоела Сәйдәргә. Һәр килүендә нинди дә булса яңалык ача, нинди дә булса көтелмәгән очрашуга юлыга. Бу юлы да ул кешеләр төркеме белән бергә, башкалага килүдән җанланып сөйләшүләрен тыңлый-тыңлый, аркылы-торкылы сызыклар төшерелгән бетон мәйданчыктан атлый. Кеше күп йөрүдән тузмасын-таралмасын дип тимер почмаклар сугылган баскычтан күтәрелә. Әйләнмәле тимер ишектән узып, шул ук кешеләр белән: «Нишләп китермиләр икән инде»,— дия-дия, чомаданын көтә... Хәер, күпвакыт аңа бу эшне эшләргә туры килми, чөнки аның кулында ярыйсы гына әйбер сыйдырышлы зур дипломат була. Шуңа күрә халык ташкынына керү белән ул, үзе дә сизмәстән, башкала кешеләре яши торган ашыгуга кушылып китә, вокзал алдына чыга, көтеп алып, йомшак, җылы автобуска кереп утыра.

Сәйдәр турыдан-туры министрлыкка барырга уйлаган иде, автобус «Үзәк парк» тукталышына килеп җиткәндә генә сәгатенә күз төшереп алды. Ул барып җиткәнче министрлыктагылар төшке ашка таралышачак. Димәк, аңа кунакханәгә урнашып, өстен-башын тәртипкә китерергә вакыт бар. Алдан сөйләшеп куйганча, урын «Россия»дә булырга тиеш.

Менә бит нинди дәрәҗәләргә ирешә авылдашлары адым саен «Аю Хәлил малае» дип мыскыллаган Сәйдәр Тынчурин! Күрсеннәр иде алар, күрсеннәр иде аның нинди кыяфәт белән Мәскәүнең иң данлыклы, иң заманча кунакханәсенә килеп кереп, фамилиясен әйтүгә, «Рәхим итегез, иптәш Тынчурин, сезнең өчен аерым номер алдылар»,— дип каршылауларын... Номеры нинди диген әле! Кы-

---

Ахыры. Башы 11 санда.

зыл мәйдан, Спасс манарасындагы бөтен ил карап торган төп сәгать, астарак күренекле капка... Дөрес, ул капкадан Сәйдәр Тынчурин әлегә сәяхәтче булып кына кереп чыга. Теге яктанрак кереп, Съездлар сараенда күп тапкырлар булганы бар аның. Килгән саен шунда концерттыр-нидер карый... Ни генә әйтсәгез дә, авылдашлар, Сәйдәр Тынчурин сезнең мыскыллы күзләрегездән өстен инде. Сез аның нинди дәрәҗәгә ирешүен башыгызга да китерә алмыйсыз. Сезнең тирескә, бәрәңге бакчасына һәм тагын шул чөгендер басуына гына карый торган күзләрегез шуннан арысын күрә аламы соң?! Сез бит кешедән көләргә генә беләсез...

Сәйдәр Тынчурин, шулай уйлый-уйлый, кунакханә бүлмәсендә өстен-башын тәртипкә китерде. Вакыт бар иде әле. Сәйдәр шундагы күп санлы буфетларның берсендә ашыкмыйча гына ашап-эчеп алды. «Бик шәп булды бу»,— дия-дия, кунакханәдән чыгып китте.

Мәскәүгә килгәндәге күтәренкелек Сәйдәрне ташламады, аны җитәкләп дигәндәй йөртте. Ул министрлыктагы кайбер эшләрен җиңел генә башкарды, кирәсе җирләргә керде, әмма иң мөһиме,— министрның беренче урынбасарына керү ике көн аша унбиш сәгатькә билгеләнгән икән. Шулай итеп, Сәйдәрнең байтак кына вакыты буш булып чыкты. «Нишләргә,— дип сорады ул үзеннән-үзе, министр урынбасарының кабул итү бүлмәсеннән белешкәч.— Кая барырга, нинди планнар корырга соң? Мәскәү хәтле Мәскәүгә аның беренче килүе түгел, әлбәттә, танышлары да бар... Танышлар дигәннән... Тынчурин бу очракта, билгеле ки, хатын-кыз затын истә тота иде.— Танышлар дигәннән, әгәр дә мәгәр Розалия янына барсаң... Булуын була инде дә... Үзен чакырырга да мөмкин. Телефоны бар. Юк, Розалиягә, үзе әйтмешли Розага бит инде хәзер кырык биш тулып килә...» Эх-ма, вәт аңгыра сарык,— дип уйлап алды Сәйдәр бераздан үзен-үзе битәрләп.— Менә сиңа сала күмәче... Әле генә министр урынбасарының секретаре аңа елмаеп кулын сузды... Ничек итеп сузды әле, ничек итеп сузды... Ул бит аның авыз турына диярлек китереп куйды кулын. «Үп» дигән иде бит, шулай иде... Ә ул, җебегән нәмәрсә... аны тартып алды да кысты, күреште-саубуллашты... Шулаймы икән? Ай-һай, мондый нәмәрсәне замминистр абзагыз калдырыр микән? — Сәйдәр Тынчурин үз каланчасыннан фикерли иде.— Туктале, торып тор әле, иптәш Тынчурин,— диде ул кинәт.— Әгәр дә мәгәр теге юлы килгәч танышкан марҗа янына барсам... Чертановода дигән иде бит... Барып белешү мөһим, аннары кунакханәгә алып килергә дә була...»

Бу максат Сәйдәр Тынчуринның хәрәкәтләренә тизлек өстәде. Һәм ул такси тукталышына таба китте.

«Вәт, сабакалар,— дип уйлады Сәйдәр, сүгенеп, беренче һәм икенче, аннары өченче буш такси да туктамагач.— Кай җәһәннәмгә ашыгалар соң болар, нигә туктамыйлар?» Ләкин алтынчы такси, тормозларын шыгырдатып, Тынчуринның алдына ук килеп туктады.

— Кайсы якка илтеп ташларга, атакай? — диде егерме биш яшьләрдәге яшь-яшь шофер егет.

Тынчурин ди ярыйсы гына шомарган кеше, аның мондый оятсыз танауларны гына күргәне бар, әлбәттә; шуңа ул бөтен гәүдәсе белән машина утыргычына сеңгән егеткә табарак борылып:

— Бабай диген, тешләреңә йомшаграк булыр, шеф,— диде.— Яле, бабай диген...

— О-го, син, атакай, сала күмәченә охшаган булсаң да, безнең агай-энене ярыйсы гына беләсең, ахры.

— Сезне дә белмәгәч...

— Ярый, ярый, телеңә бик салынма, кайсы якка тотарга боерасың? — диде шофер, күптәнге танышына дәшкән сыман итеп.

— Чертаново дисезме әле? Менә шунда тот...— Сәйдәр бераз

дәшмичә барды, аннан өстәп куйды: — Мин кереп чыкканны көтеп торырсың, бәлки, өйдә туры килмәс.
— О'кей... атакай.
Әйтерсең, Сәйдәр Тынчуринның килгәнен көтеп торганнар, ул кыңгырау төймәсенә кулын тидерергә өлгермәде, ишек ачылды.
— Рәхим итегез, сез безгәме, сезгә кем кирәк? — диде йокылы-уяулы, талкыган җитен төсле чәчләрен җилкәләренә туздырып салган ханым. Сәйдәр аны шундук танып алды: ул теге юлы танышкан ханым иде.
— Миңа Наташа... Жеребцова кирәк иде.
— Мин булам — кем син?
— Без сезнең белән...
— А-а-а, керегез, кер... Мин хәтерләдем сезне. Сез...
— Хәзер,— диде Сәйдәр иркен сулап.— Хәзер керәм, тик анда мине такси көтә...
— О-о-о... Җибәрегез сез аны, җибәрегез... Бүген инде мин сезне сыйларга тиеш... Шундый итеп сыйларга... Җибәрегез...

Сәйдәр әйләнеп кергәндә ханымның кыяфәте бермә-бер үзгәргән, аның йокылы-уяулыгының эзе дә калмаган, ул инде үз-үзен тәртипкә китерергә өлгергән иде.
— Утырыгыз... Нинди җилләр сезне башкалага ташлады?
— Командировка... Министрлыкка,— диде Сәйдәр йомшак диванга, ханым янына янәшә утыра-утыра.
— О-о-о!.. Күрәм, сез бик югары очучы кошка охшагансыз.
— Тырышабыз... На-та-ша...
— Әйбәт, әйбәт. Безнең илдә тырышларны яраталар, билгеле...
Сәйдәр инде бүлмәне дә, аннан битәр хуҗабикәне күзәтеп, аның ир-атны кызыктырырлык өстенлекләрен чамалап өлгергән иде, шуңа күрә Наташаның янәшәсенә үк килеп утыруын, аның үзенә генә хас хушбуй исен сизеп алды һәм моны «иркенрәк тот үзеңне» дигән ишарә икәнлеген аңлады.
— Кофе эчәбезме, чәйме? — Наташаның чәч учмасы Сәйдәрнең борын төбеннән үк узып китте һәм Сәйдәрнең болай да йомшарган ихтыярын тагын да йомшарта төште. Аның инде хәзер ничек кенә булса да үзен Наташа кебек асыл ханымга лаек икәнлеген, үзенең сала агае түгеллеген, кайбер нәрсәләрне белүен күрсәтәсе килде.
— Теге юлы, Наташа... син кофе белән чәйдән әйбәтрәк әйберне дә табып була дигән идең? Ничегрәк соң ул хәлләр?
— О-о-о!..— дип сузды Наташа.— Син, күрәм, бик үк куркаклардан түгел.— Монысы да тәҗрибәле ханымның алдан ук уйлап, ир-атның күңеленә сугып, аны кытыклап ала торган алымы иде.— Син, күрәм, үгезне мөгезеннән тотарга яратасың.
— Үгезне мөгезеннән, ә хатын-кызны...
Сәйдәр туктап калды, Наташага таба борылды һәм, диван артына кулын куйган булып, аның җилкәсенә кагылып китте.
— Соң, кофе эчәбезме, чәйме яки...
— Яки?... Яки нәрсәме? О-о-о! — диде Наташа сузыбрак, өлгер тәнен уйнатып алды, урыныннан торды да, япон видеомагнитофонын кабызып, аңа заманның иң танылган рок-группасы «Битлз» язмаларын куеп җибәрде.— Күп, бик күп акча кирәк бит аның өчен, кадерле...
Сәйдәр инде сизеп тора иде, Наташа аның исемен хәтеренә төшерә алмады, шуңа күрә әйтеп җибәрде:
— Сайдар.
— Кадерле Сайдар, ак-чааа? — һәм ул аңа таба борылып, биюче оста шикелле, бармакларын шартлатып алды.— А-а-а-кча!
Сәйдәр урыннан торды, Наташа янына килде һәм җилкәсеннән кочаклап:

— Акча булыр, «яки»гә дә, башкасына да...

— О-о-о!..Атом станциясе төзелешендә акчаны күп бирәләрме? — диде, ниһаять, Сәйдәрнең кайсы яктан искән җилләр ташлаганын исенә төшергән ханым.— Ях-шы-ы-ы...

Сәйдәр хатынны үзенә таба кысты, ләкин тегесе шулай буласын сизеп торган диярсең, өлгеррәк булып чыкты, бармагын иренenә куеп:

— Тс-с-с!.. —диде.— Ашыкмагыз. Мин телефоннан шалтыратырга һәм «яки» булган кеше белән сөйләшеп алырга тиеш...— һәм ул җиңел генә атлап, бәләкәй өстәл өстендәге телефон янына барды да андагы төймәләрне күз иярмәс тизлек белән һәм, ул төймәләрне күрсәтмичә бармаклары белән каплап, кирәкле саннарны җыйды.

— Һәлло... Сәлам, сэр, исән-саумы?... О-о-о!.. Әйе... әйе... Юк, һич юк... Һәрвакыттагыча — юк... Юк, юк, иртәнге якта... Унбердә... Хоп, сэр...

Наташа сөйләшеп бетереп трубканы куйды, Сәйдәргә таба борылып елмайды һәм:

— Менә булды да,— дип куйды.— Хәзер инде кофе эчәргә туры килер...

Сәйдәр инде болай да исергән иде. Наташаның телефоннан сөйләшүен күреп, аның ялт-йолт уйнаган тәннәренә карап тора-тора аның ихтыяры тәмам бәйдән ычкынган иде, ул тагын хатын янына килде...

Аннары алар сигарет кабыздылар... Әллә нинди баш әйләндергеч, күз алларын гына түгел, аңны да томалый иде бу сигаретның төтене,— Сәйдәр моны ике-өч суыруга сизде. Әмма ул, үлемгә хөкем ителгән бака баласы елан авызына таба барган сыман, ихтыярсызлык күрсәтеп, үзенең һәлакәтенә таба яңа адымнарын ясый иде...

## 6

— Фирәзә...

— Искәндәр...

Бу ике сүз, ике исем берьюлы диярлек төзелеш мәйданының кышкы һавасына атылышып чыктылар да, берсен-берсе җылытып, берсенә-берсе көч өстәп, кара-каршы омтылдылар. Алар өчен тирәюньдәге кешеләр, төзелеш мәйданы, кышның салкынлыгы, аяк астындагы кар шыгырдавы, җирнең актарылып-актарылып ташланган борынгы катламнарыннан чыккан кантарлар юк иде шикелле. Аларның һәркайсы чынбарлыкта түгел, ә әкияттәге сыман зәңгәр диңгез артындагы өрфия томаннарга күмелгән кебек еракта-еракта иде. Әгәр дә мәгәр тагын бер, нибары бер генә мизгел шулай торган булсалар да... Бәхеткә каршы, термослар бушатучы шоферның:

— Фирәзә апа...— дигән тавышы ишетелде. Шушы тавыш, һаваның салкын дулкыннарына кушылып, Фирәзә белән Искәндәр арасына керде, аларны хәтер диңгезе эчендәге давыллы хисләрдән аерып алды да җир өстенә кайтарып бастырды. Шундук Фирәзә куш учы белән авызын каплады. Ул, әйтерсең, үз авызыннан чыгарга тиешле: «Мин сине көтәм, мин сине сагынам, Искәндәр»,— дигән сүзләрне тыеп калырга өлгерде.

Искәндәр Фирәзәгә таба талпынды, әмма ми җепселе буйлап юлга чыккан бу боерык урынына иренчесе «Син нишлисең, Искәндәр? Тукта! Тукта-а...» — дигәне килеп җитте. Ул, чайкалып торган агач кәүсәсе шикелле, баскан җирендә калды.

Төзүче егетләр дә ни хакындадыр әрепләшә-әрепләшә машина янына килеп җиттеләр, вагонга керергә әзерләнә башладылар.

— Болай булгач, Искәндәр абый,— диде Револь Вәлиев авызын ерып,— кеше хәтле кеше үлеме өчен җавап бирергә туры килми сиңа... Хөкем эскәмиясе бу юлы читләтеп үтә...

— Һе, сөйләп торган буласың тагын, Саламторхан,— диде аның артыннан ук килеп чыккан Остап Безбожный.— Кайда, кайда соң ул ачтан үләсе кеше?...

— Ничек?.. Оста-а-ап Остапыч, сез ул кешене күрмисезмени? Сез начальствога ярарга тырышасыз,— дип карулашмакчы иде дә Револь, әмма Остап аңа ирек бирмәде:

— Вәт бит, ә, эшкә дисәң, урыныннан кузгатып булмый, ә аш исен сизгәч нишли бу эрәмтамак,— диде ул һәм, Револьне төрткәли-төрткәли, вагон болдырындагы термослар янына алып барды, берсен аңа алырга кушып ымлады, ә икенчесен үзе эләктерде.

Егетләр аш табыны янында иркенрәк тә утырмакчылар иде, әмма Искәндәр реактор чокыры янынннан тагын бер КамАЗ үзбушаткычының килеп чыгуын күрде. «Да-а-а, бирәләр болар кирәкне»,— дип уйлап алды һәм, вагон эченә кереп, шау-гөр килеп утыручы егетләргә:

— Тизрәк тотыйк, егетләр, тагын берәү килде,— диде.

Барысы да ашарга ябыштылар, бары тик Револь генә:

— Көненә бер тапкыр рәхәтләнеп ашарга да бирмиләр,— дип куйды. Остап аны тагын җавапсыз калдырмады:

— Авызыңны ачып торма, югыйсә моннан да коры калуың бик ихтимал,— диде. Револь, күрәсең, Остапның шаяртмавын белә иде, авызын чапылдатып ашарга кереште. Илдар Корбанов, урыныннан кубып:

— Мин булдым, Искәндәр абый, утыр монда,— диде.

Ул арада башкалар да берәм-берәм кузгалдылар, ничек ашыгып кергән булсалар, шулай ук ашыга-ашыга чыгып та киттеләр. Кышкы суыкларда измә-бетон белән шаярырга ярамаганны бик яхшы беләләр иде алар.

Искәндәр бөтен җаны-тәне, аркасының һәр миллиметры белән тоеп торды; менә Фирәзә савытка ботка салды, менә ул күзләрен күтәреп аңа таба карады, менә ул беренче адымын атлады һәм менә ул аның артына килеп тә басты... Белеп, тоеп торды, әмма Фирәзә үз янына килеп:

— Мә, Искәндәр,— дип савытны сузгач та куырылып куйды. Савыт үзе аның алдына төшеп утырды һәм аны тотып китергән кул — Фирәзәнең балдаклы кулы — каядыр артка таба чигенә башлады. Искәндәрнең күзләре, шушы кулга төбәлгән килеш, аңардан калмыйча бардылар. Менә әлеге кул хәзер каядыр китеп югалачак, югала... Искәндәр ирексездән, нindидер бер кодрәт хөкеменә буйсынып, сул кулы белән шушы кулны тотып алды, башта аны өстәлгә куйды, әмма шул ук секунд эчендә яңадан күтәреп үзенең сул битенә китереп басты...

— Фирәзә...

— Искәндәр...

Нибары берничә мизгел, ахыр чиге, унбиш-егерме секунд шулай торды алар, әмма бу мизгел алар өчен дистәләгән елларга тиң иде.

— Искәндәр,— диде Фирәзә күзләрен йомган килеш, бары тик иреннәре белән генә: — Искәндәр... син, син мине... кич-чер, Искәндәр, яме...

— Фирәзә, Фирәзәкәем-Хыялым син минем,— диде Искәндәр, Фирәзә кулының битен яндырып-яндырып алуын тоеп.— Мин сине гомерем буена эзләдем, эзләдем бит...

— Ә мин сине, бары тик сине генә көттем, Искәндәр,— диде Фирәзә икенче кулын да Искәндәрнең уң битенә куеп.— Мин сине көттем... Син кичерерсең, дип уйлаган идем... Мин, Искәндәр, шушы

бала җәзасын гомерем буена татыдым. Мин ул җәза шәрәбен гомерем буена эчтем, Искәндәр...

— Мин дә гомерем буена сине сагындым, Фирәзә...

Тыштан болдырга кемнеңдер менгәне ишетелде; Фирәзә, кулларын Искәндәрдән алып, термослары янына кучеп басты. Искәндәр исә, ничек утырса, шул хәлдә алдына куелган ботка тулы тәлинкәгә карап торды.

Ишек ачылып китте һәм, салкын парларына уралып, шофер егет килеп керде.

— Термосларны чыгарабызмы, Фирәзә апа? — диде ул һәм шул чагында гына ашап утыручы бригадирны күрде.— Ә-ә... Ярар, алайса, термосларны чыгарыйм... Минем әле аэропортка да барасым бар...

Фирәзә нәрсәдер эшләргә, термосларны җыярга керешкәндәй итте.

— Ниш... Нишлисең инде син, Фирәзә апа? — диде шофер.— Чәй өстенә саласың бит ботканы...

Хәле киткәнне сизеп, янәшәсендәге эскәмиягә утырды Фирәзә. Аның йөрәге күкрәк читлеген ватып-җимереп чыгардай булып тибә, күз алларында ниндидер кара таплар йөзеп-йөзеп йөри иде.

Искәндәр утырган урыныннан сикереп торды, ләкин Фирәзә алдында шофер егет басып тора иде инде.

— Фирәзә апа!

Бу тавыш Фирәзәне чынбарлыкка кайтарды. Ул күзләрен ачты, тирән итеп сулыш алды, шофер егеткә күтәрелеп карады, аннары аны читкәрәк тибәрде дә:

— Бар әле, чыгып тор әле, Фәрит...— диде.— Чыгып тор әле... Хәзер үтә, үтә ул...

Шофер егет әле Фирәзә апасына, әле бүлмә уртасында басып торган Искәндәргә карады, ни әйтергә белмичә, җилкәләрен җыерыбрак алды һәм машинасы янына чыгып китте.

Фирәзә утырган урыныннан салмак кына торды, күзләрен тутырып Искәндәргә карады. Ул күзләрдә, таный белгән кешегә, ниләр генә юк иде! Искәндәр аларны күрде һәм анда язылган барлык нәрсәләрне — сөю хисләрен, бая ишетелгән рәнҗү-үкенү-сагыну давылларын бөтен җаны-тәне белән тойды. Бу тойгылар аңа кыюлык өстәде һәм ул шушы караш белән ике арадагы бушлыкны атлады.

Фирәзә моны көткән иде булса кирәк. Ул да, үзен артык тыеп тора алмыйча, Искәндәрнең күкрәгенә капланды.

Үкседе дә үкседе ул...

Искәндәр аның аркасыннан, җилкәләреннән сөйде, аннары битләреннән, чигәләреннән сыйпап узды һәм, ниһаять, үзе дә сулкылдап куйды.

Бу минутларда ни генә булмасын,— тыштагы шофер килеп керсен, тагын бүтәннәр килеп карап торсыннар, әмма инде иллегә якынлашып килүче бу ике кешене бер-берсеннән аерып ала торган көч табылмас кебек иде...

## 7

Тынчуринның мондый ук хәлгә калганы юк иде әле. Ул — янды, дөрләп-дөбердәп янды! Казанда, Чаллыярда ничәмә-ничә тапкыр янардай эшләр эшләде — янмаган иде.

Ниһаять, янды, янды Сәйдәр Тынчурин...

Наташа Жеребцовадан алып кабызган сигарет Сәйдәр Тынчуринны ике көн һәм ике төнгә чыгырыннан чыгарды. Шушы ике төн, ике көн эчендә ул үзен һәлакәт төпсезлегенә илтеп ташлаячак агулы матдә колына әверелде.

Болар барысы да Тынчуринның хәтерендә өзек-төтек булып сак-

ланып калган иде. Шулай да ул үзенең нинди халәттәдер министр урынбасары янына баруын, аның белән эш турында сөйләшүен хәтерли. Димәк, министр урынбасарына кереп эш турында сөйләшерлек хәлдә булган, югыйсә аны уздырмаслар, югыйсә министр урынбасары аның белән сөйләшмәс иде...

Кунакханә алдында аны тагын яңа дусларының берсе каршы алды. Бу очрашуны Сәйдәр бик яхшы хәтерли, бөтен вак-төягенә хәтле исенә төшерә ала иде.

— Хэлло, Сайдер,— диде Сәйдәргә ир уртасы кеше.— Хәерле көн...

Көн бик үк хәерле түгел иде. Алай гынамы — хәерсез көн иде бу.

— Хэлло, әллә инде танымыйсың дамы, Сайдер? Нихәл?

Бары тик шунда гына Сәйдәр Тынчурин бу кеше белән ике көн бергә булуын искә төшерде.

— Тыныйм, Георг, таныйм...

— Нигә борыныгыз җиргә тия язган соң, Сайдер? Сөйләшү сезнең файдага булмадымы әллә?

Юк, министрлыкта хәл ителергә тиешле мәсьәләләр моңарчы бер генә тапкыр да шулай уңышлы килеп чыкмагандыр. Яңа елда трестка беренче реактор нигезен кору өчен бер йөз дә ун миллион сум акча бирелде... Георг белән исәнләшеп торганда аның башыннан шушы уй узып китте. Ләкин Тынчуринның күңеленә бу уңышлы сөйләшүдән бер мыскал да шатлык юк иде.

— Керәбезме, Георг,— дип ияге белән кунакханәгә күрсәтте Сәйдәр.— Рәхим ит...

— Кабызып җибәр, Сайдер?

Сәйдәр каршы килмәде һәм алар икесе бергә сигарет кабыздылар. Ләкин кунак-Георг Сәйдәрне бер, ә үзен икенче кесәсеннән алынган сигарет белән сыйлады.

Тынчуринның кәефе күзгә күренеп ачылды. Аның күзләренә нур иңде, баядан бирле теләр-теләмәс сөйләшкән теле телгә йокмый, министрлыкта булган сөйләшүне, анда үзен ничек «акыллы» тотуы турында сайрапмы-сайрый башлады.

Аннары алар тагын Наташаларга киттеләр... Бу төн тагын татлы сөйләшү, күңел ачу һәм әледән-әле сигарет тартудан туган рәхәтлеккә күмелеп узды. Бу юлы инде аңа зәһәрле агуны мактап, аның кеше сәламәтлегенә китерә торган шифалары турында язылган китап белән дә сыйладылар. Дөресрәге, аның кесәсенә салып куйдылар, кайткач бик җентекләп укып чыгарга куштылар. Ә иртәгәсен кунакханәгә кабат килгәч, Георг аның биш йөз сумына ун кап «затлы» сигарет бүләк итте.

Иртәнге самолет кичке алтыларда гына килеп төште һәм менә хәзер Сәйдәр Тынчурин, юлда очраган машинага утырып, Көмеш Аланга якынлашып килә иде.

Көндез арчылган юлга кар көртләрен дыңгычлап тутырган иде инде, шуңа күрә җиңел «Жигули» Ширәмәттән чыккач та озын һәм ярыйсы гына текә үрне менеп җитә алмады, аерата зур бер көрт эченә кереп чумды. Шофер артка-алга биреп караган булды, кая ул, машина селкенми дә. Җитмәсә бу төштә «җен оясы» икән, әйләнеп-бөтерелеп кар бураны дулый. Төшәргә туры килер, ахрысы...

Сәйдәр Тынчурин машинадан чыкты. Көчле җил аның битенә салкын кар бөртекләрен китереп сылады. Яңадан эчкә кереп китәсене китерде. Нишләп тә булмый, төртешергә кирәк... Шулай да, чыгып карагач, Сәйдәр күрсәтмә бирмичә булдыра алмады. «Казырга, тәгәрмәч асларын чистартырга кирәк»,— диде ул үзенең тәнендәге хәлсезлеккә исе китеп. Күрәге бар икән, шофер казырга керешә. Сәйдәр исә, җилгә арты белән борылып, көтеп торды.

Ниһаять, чыктылар. Тауның каршы җирендә туктамас өчен «Жигули» алга таба менеп китте, «тегендәрәк күтәрмен» дип булса кирәк, «пип-пип» кычкыртып алды. Сәйдәргә аның артыннан атлаудан башка чара калмады.

Бераз алга бөгелебрәк атлаганда, кар-буран арасында Фирәзә басып торган кебек күренде аңа. Сәйдәр ашыгып барып Фирәзәне тотмакчы иде, ләкин куып җитә алмады. Тагын кутәрелеп карады, Фирәзә тагын алдарак басып торган сыман тоелды. Сәйдәр туктап калды, күзләрен күн перчаткалары белән угалады, тагын алга карады, анда «Жигули» эзе буйлап шофер агай каршы килә иде.

Машинага кереп утыргач та тынычлана алмады Сәйдәр, һаман да шулай борчылуында булды. «Их, Фирәзә, Фирәзә,— дип уйлады ул,— нигә, нигә соң яратмадың син мине?» Китәсе көнне купкан тавыш исенә төшкәч кенә Тынчурин чынбарлыкка кайтты, тагын да ныграк борчылырга керешге. Әгәр дә мәгәр китеп барган булса? Соңгы вакытларда, бигрәк тә соңгы ике ай эчендә ул бер генә дә түзеп тора алмый башлады. «Китәм, китәм, китәм»,— дип тәкърарлап торды. Яратмады ул аны, Сәйдәрне... Хәер Сәйдәр үзе... яраттымы соң аны?.. Мәктәптә чагында ук ул Фирәзә белән бары тик класста бер матур булганы өчен, шушы матурны у з е н е к е итәсе килгән өчен генә йөрергә тырышты бугай.

Ул арада «Жигули» Көмеш Аланның вакытлы автовокзалы янына килеп җитте. Тынчуринга төшәргә кирәк иде. Бу агайның кайтып китәсе дә бар. Алдан ук сөйләшкәнчә, Сәйдәр ике унлыкны чыгарып агайга бирде. Әмма «Бәла-казасыз кайтып җит»,— диярге онытты. Каршысында калкып, буран аша күренеп торган өйләргә таба атлады.

Өенә кайтмакчы иде ул, аяклары Динә квартирының ишек төбенә китереп бастырган булып чыкты.

Ишектән керүгә, Динәнең үзен-үзе әллә ничегрәк тотуын сизде, юка иреннәре читендәге мыскыллы елмаюны күрде Сәйдәр. Динәнең усалланганда гына шулай елмаюын белә иде ул. «Уз, әйдә»не көтеп тормыйча гына, өстен салды. Әчкә узды. Монда ул үзен иркен, үз өендәгедән иркенрәк тота иде. Монда — Динә. Ә Динә баштанаяк аның иркендә. Бу аның — Сәйдәр Тынчуринның икенче өе дисәң дә ялгыш булмас, чөнки Динәнең мондый квартира алырга, кем әйтмешли, «башы яшьрәк»...

Сәйдәр бүлмәгә керде, диванга утырды һәм... шундук үзендә искиткеч хәлсезлек сизде. Күңеле сыкранып-сыкранып алды. Җитмәсә Динә дә һаман шулай әллә ничек карап тора, мыскыллы елмаюын йөзеннән алмый иде.

— Йә, нәрсәгә исең китте, Динәкәй? — диде, ниһаять, Сәйдәр үзендәге хәлсезлекне, үзе сөйләгән сүзләргә битарафлыкны тоеп, ләкин ихтыярының иң соңгы көчен туплап.— Ни булды? Нәрсәгә исең китте? — диде.

«Элек булса мин аны кочаклап ук алган булыр идем»,— дип уйлап алды Сәйдәр, ләкин урыныннан кузгалмады. Аның үзенә дә аңлашылмый торган бер көч бөтен гәүдәсен шушы диванга тартыпябыштырып куйган диярсең.

Сәйдәр салмак, теләр-теләмәс хәрәкәт белән уң кулын пинжәк кесәсенә тыккан иде, әйтерсең, кулына тигән сигарет кабы электр тогы булып башына сукты! Ул үзенең ни өчен хәлсез һәм битараф икәнлеген аңлады. Аның шушы сигаретны аласы, кабызасы килә ләбаса. Ничек ул, шуны аңламыйча, машинада тумран шикелле утырып кайтты, ничек итеп ул хәзер Динәнең өстенә карап та аны күрмичә тора соң?

Сигарет кабы Сәйдәрнең кулына ияреп чыкты. Ул, калтыранган бармаклары белән бер сигаретны тартып алып, авызына капты,

кабызгычыннан «чырт» иттереп ут элде һәм бөтен күкрәген тутырып төтен сулады... Хикмәт!.. Төтен аның үпкәләрендә урнашып өлгермәде, ләкин Сәйдәр үз тәненә көч кайта башлаганны сизде. Күз алларындагы томан бетте, дөньяга битарафлыгы кими башлады. Ул, ниһаять, каршысындагы Динәне мөлаем кыяфәттә күрде, аны үзенә тартып китерде...

— Йә, ни хәлләрең бар, Динә җаным? — диде.— Ниләр бар безнең трестта? Угрюмов кайттымы Япониядән? Әллә мин әле һаман да «башкаручы»мы?

Динә, аның тезләренә менеп кунаклаган килеш, баягы елмаюыннан арынмаган хәлдә, әле генә Сәйдәр кесәсеннән чыккан сигарет кабын алды, андагы рәсемне карады һәм... кызыл-көрәнгә буялган тырнаклары белән бер сигаретны эләктереп, иренәнә куйды. Ул инде байтактан тәмәке көйрәтә иде. Сәйдәр, аны-моны уйлап тормастан, кабызгычын «черт» иттерде. Динә дә әлеге ят каптагы сигареттан күкрәк тутырып төтен суырды... Сәйдәр аның бу хәрәкәтен күреп торды, ләкин аны-моны әйтмәде, Динәне тыймады. Ә Динәнең тәненә ул арада рәхәт бер җиңеллек йөгерә иде инде...

— Йә, ник дәшмисең, ниләр бар Көмеш Аланда? — диде Сәйдәр, уң кулы белән Динәнең башын үзенә таба борып.

Динә тагын сигареттан төтен суырды, гаҗәпләнеп, нечкә бармаклары арасындагы сигаретка карап-карап алды һәм:

— Ишетмәдеңмени? — диде.

— Нәрсәне?

Динә тагын сигаретын авызына капты.

— Йә, нәрсә сузасың? Нәрсәне ишетмәдеммени? — Бу юлы инде Сәйдәрнең тавышы корычланды, анда усаллык төсмерләре чагылып китте: — Нәрсәне ишетмәдем?

Динә аның тезләреннән купты, бүлмә уртасынарак китеп басты һәм һәрбер сүзен суза төшебрәк әйтте:

— Сөекле хатыныңның синнән киткәнен...

Динә Сәйдәрнең күзләренә карап шулай диде. Ул аның йөзендәге үзгәрешне, курку чаткыларын күрергә, шушыны күреп үзенә ниндидер бер канәгатьләнү табарга уйлаган иде булса кирәк. Ләкин... Ләкин Сәйдәр бу хәбәрне ишеткәч тә Динәгә төбәлеп карап торуында булды. Аның күзләрендә дә, йөзендә дә үзгәреш әсәре күренмәде. Ә инде тагын бер мизгелдән ул:

— Ха-ха-ха...— дип кычкырып көлеп җибәрде.

Динәнең дә каефе күзгә күренеп үзгәрә иде. Ул да үз авызыннан чыккан сүзләрнең Сәйдәргә нинди үзгәрешләр китерәсен онытты һәм... шулай ук Сәйдәргә кушылып көләргә кереште.

— Ничек китте, кая китте? — диде Сәйдәр бераздан гына, Динәне кочаклавын дәвам итеп.— Ә син, син китмисеңме соң миннән? Син китмисеңме соң?

Динәнең яшьлектән ташып торган дәрте, кайнарлыгы аларның икесен дә тойгылар дулаган чоңгылга тартып төшергән иде инде.

Тышта көчле җил-буран. Ул ә-ә-әнә теге яктагы Кара урман өстеннән атылып чыга да, яңа йортлар арасындагы бушлыкны узгач, Калатауның текә ярыннан борынгы елга өстенә ташлана иде.

## ӨЧЕНЧЕ БАШЛАМ

### 1

Җылы яз көннәре килеп җитте. Көмеш Алан каршындагы Калатау һәм Текәяр кояш нурларында коена башлады. Озакламый

аларны инде яшел юрган каплап алды. Тиздән тау башында беренче чәчәкләр: сап-сары үги ана яфраклары, ап-ак җил чәчәкләр калкып чыкты, аларга миләүшә һәм кызгылт-зәңгәрсу чәчәкле күкебашлар кушылды.

Өмет Наурның берсеннән-берсе уңганрак егетләре бульдозер һәм скреперлар ярдәмендә һаман-һаман тирәнгәрәк төшә, җирнең борынгы катламнарына тимер пычакларын батыра барган көннәрдә барлык эшне туктату куркынычы туды: җир куеныннан су фонтаны бәрә башлады! Тегеләй иттеләр, болай иттеләр, ләкин берниндн чара таба алмадылар. Куәтле насослар китергәч кенә, ниһаять, бу кыенлык җиңелде.

Апрель урталарында Көмеш Аланның яңа гына өлгертелгән клубында төзелештә катнашучы барлык оешмаларның берләштерелгән партия-хуҗалык активы җыелды. Партия өлкә комитетының төзелешләр буенча эшләүче секретаре Самвелов ясаган кереш сүздән соң, җитәкче иптәшләр аптырашта калып, ни җавап әйтергә дип баш ваттылар. Берничә кеше чыгып: «Тегеләй эшлибез, планнарны фәлән-фәлән хәтле үтибез»,— дип мактана башлаганнар иде, залдагылар дәррәү кул чаба башлап, аларга сөйләп бетерергә ирек бирмәделәр.

Чынлап та, соңгы бер-ике айда Татарстан атом электр станциясендәге эшләр бик нык аксый иде. Оештыру эшләре җитеп бетмәгәндерме — төзелешкә кирәк-ярак бөтенләй диярлек килми башлады. Баш инженер хезмәте кирәкле проект кәгазьләрен булдыра алмады. Моның өстәвенә, төзелә торган АЭС дирекциясе белән төзүчеләр арасында низаг чыкты. Ләкин болары әле аның, ни әйтсәң дә, бик тырышып көчәнгәндә җиңмәслек кыенлыклар түгел иде.

Соңгы айларда, гомумән, бу атом станциясен төзү-төземәү мәсьәләсе кузгатылды. Аерым кешеләр тарафыннан гына булса, билгеле, дәшмәсләр, аннары төрле сәбәпләр табып сузарлар, ә ул вакыт арасында төзелешкә мөмкин хәтле күбрәк көч салырлар, миллионнарны түгәрләр иде дә, ахыр килеп, фәлән-фәлән байлык салынды, дип эшне хәл итәрләр иде. Хәзер исә халыкның теле ачылып китте. Газеталар дисеңме, радио, телевидение дисеңме — ни генә сөйләмиләр дә ни генә язмыйлар. Менә төзүчеләр белән республиканың кайбер оешмалары арасында да АЭСның кирәклеге турында бәхәс башланып китте. Бу җыелышта ул мәсьәләгә кагылмаска тиешләр кебек тә, кем белсен хәзер кемнең нәрсә белән авыз чайкый башлавын. Әнә бит Фидаяров төзүчеләр арасында күркә кебек ничек кабарынып утыра. Мөгаен, тагын берәр гаеп табып сөйләргә җыенадыр. «Менә бит рәхмәтсез бәндә,— дип уйлады Тынчурин.— Мин аны бер уч төбе хәтле белешмә кисәге белән эшкә урнаштырдым. Ә ул, яннарына барган саен, йә теге, йә бу яктан гаеп таба. Бигрәк тә аңа АЭСка куелачак реактор ошамый. Ничә тапкыр шул хакта сүз кузгатты инде. Беркөнне, төзелешкә газета хәбәрчесе килгәч, аның бригадасына алып барганнар. Янган утка май сибеп җибәргән. Ни тырышты Тынчурин аның фикерен килгән кешеләргә ишеттермәскә, юк бит, парткомын әйтер идем. Яхшы эшлиләр, дип, тәки шулар янына алып барган хәбәрчене. Хәзер инде менә ничә йөз мең тираж белән «ТатАЭСка куелачак реактор ышанычсыз, аны куйдырмаска кирәк», дип язып чыктылар. Бу тавышның көт тә тор бик зурга китүен, олы гауга кузгатуын...»

Тынчурин залга карады. Нишләптер чыгып сөйләргә теләүчеләр күренми иде әле. Фидаяров та уйга талып, уч төбе белән башын терәп утыра бирә. Бәлки, тавыш куптармас әле. Беркөнне бит аңа ярыйсы гына анык итеп әйтелде...

Җыелыш рәисе кешеләрне кыстап-кыстап карады, трибунага чыгарга ашкынып торучылар барыбер табылмады. Кешеләр бер-берсенә карарга кыймыйча утыра бирделәр. Чөнки хәтерләре яхшы эшли һәм алар элекке елларда җитәкчеләргә туры әйтүчеләрнең нинди

«рәхәтләр» кичергәннәрен бик әйбәт беләләр иде.

— Миңа сүз бирегез әле,— дигән тавыш, шуңа күрәдер инде, тын залда өреп тутырылган резин куык шартлавын хәтерләтте.— Рөхсәтме?

Җыелышны алып баручы трест парткомы секретаре, яшьлегенә карамастан чәче коелып, пеләше баш түбәсеннән артка таба узып киткән Фәргать Батыев, мондый уңайсыз хәлдән чыгаручы табылганга шатланып:

— Рәхим итегез, иптәш...— диде һәм иптәшнең фамилиясен атый алмыйча тотлыкты. Ул, ярдәм көтеп, трест җитәкчесе Юрий Борисович Угрюмовка, аннары ул «белмим» дип җилкәләрен җыерып күрсәткәч, Тынчуринга карады.

Тынчурин чыгып килүченең кемлеген яхшы, бик яхшы белә иде, әлбәттә, ул Батыевка борылып:

— Комплекслы бригада җитәкчесе Фидаяров,— диде, ләкин аның тавышы, микрофонга якын утырганга, бөтен залга ишетелде.

Искәндәр халык арасыннан чыгып сәхнәгә таба барган арада залда җанлану ишетте, кайберәүләрнең үзара пышылдашуларын күрде. Ләкин аны инде мондый вак-төяк кенә туктатып кала алмый иде.

— Безнең бригадада сиксән ике кеше хәзер,— дип башлап китте Фидаяров сүзен, кесәсеннән кәгазь-фәлән чыгармыйча гына. Бу аның тәҗрибәле оратор икәнлеген һәм мондый чыгышлар аңа ят нәрсә түгеллеген күрсәтә иде.— Турысын әйтим, безнең бригадада эшнең ничек оештырылуы кебек мөһим нәрсәгә битараф караучылар да бар. Аларга нәрсә, аларның үз өсләренә яумый да таммый да; маташып алыгыз әле, карап карарбыз, дип тыныч күңел белән йөри бирәләр. Хәтта: «Андый хәлләр күп булды инде, файдасы гына тимәде, һәр нәрсә һаман да шулай үз урынында кала килде»,— диючеләр бар. Алар элегрәк тә шулай диләр иде. Менә хәзер, эшкә карап түләүгә, хуҗалык исәбе белән эшләүгә килеп терәлгәч, андыйлар телләрен тешләде...

Искәндәр, сүзеннән туктап, тагын залга карады; аннары, яны беләнрәк борылып, президиумга күз төшерде. Битараф кеше юк, аны игътибар белән тыңлыйлар, димәк, ул кирәкле сүз сөйли.

— Безнең эш авыр, киләчәктә, реактор нигезен бетонлауга күчкәч тә шулай булса, андый авыр эшне күтәрүчеләр сирәгәер. Нәрсә исәбенә күтәрелер икән соң безнең эш хакы?

Зал җанланды, аннары берьюлы әллә ничә төштә әйтелгән сораухуплаулар ишетелде, кемдер «а-га» диң тә куйды. Ләкин бу соңгы «а-га» бары тик бер мәртәбә генә, ул да булса ничектер салмак, канаты сынган кош сыманрак кына талпынды да тынды.

— Тагын шуны әйтәсе килә, безнең трестка әле яңалыкларның кергәне юк. Әле һаман да элеккечә, барыбызны да бер тырма белән тырмалатып яшибез. Безнең авыздан чыккан сүзне ишетергә теләмиләр әлегә. Ишетмәмешкә салыналар... Әлегәчә бер генә үзгәреш тә юк бездә. Бөтен нәрсә имеш-мимешкә корылган. Әгәр дә мәгәр үзебезнең бурычыбызны ныклап белмибез икән, белмәмеш эшкә бездән нинди мөнәсәбәт көтәргә мөмкин? Күрәсең, трестның инженер-техниклары һәм җитәкчеләре дә башкарыласы эшләр белән аннан-моннан гына таныштыр. Резервтагы җибәрү котельныен корабыз коруын да... әлегәчә проектсыз корабыз? Моны аңлавы бик кыен, иптәшләр. Атом станциясен чама белән, проект документлары булмый торып салуны мин күз алдыма китерә алмыйм. Бу — искиткеч җавапсызлык...

«Бәлки... тагын юкка әзлимдер мин хаклыкны?» — Бу уй Искәндәрне тотлыктырып алды, ләкин ул аны шунда ук җиңде. «Юк инде, Фидаяровның алай гына җиңелергә исәбе юк әле. Берәүне дә сатмыйм, ләбаса, үзебез өчен сөйлим».

— Иптәшләр! — дип дәвам итте ул.— Безнең АЭСны төзү-төзе-

мәү турында бәхәс кыза бара. Инде шулай де-факто куелганбыз икән, Татарстанның кеше иң күп яши, ил уртасындагы иң олы ике елга буена әлегә көче дә, ышанычлылыгы да,ниләр китерәсе дә нәмәгълүм гыйфрит торгызабыз икән, без беренче чиратта аны сыйфатлы итеп эшләргә тиешбез. Чөнки аны бездән соң берәү дә жиренә житкерә, тагын да ышанычлырак итә алмаячак. Проектта каралган РБМК реакторы ышанычлы түгел. Илдә ул типтагы реактор куелган АЭСларда аварияләр булгалап тора... Мин үземнең эш тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: бу реактор фән казанышы булудан ерак. Киләчәк өчен корыла торган АЭСта ул урнаштырылмаска тиеш! Бу бик мөһим! Безнең илдә үк хәзерге көндә ышанычлырак саналган, МАГАТЭ аша уздырып яхшы дип табылган ВВЭР, ягъни водно-водяной энергетический реактор бар. Без төзи торган АЭСта шул куелырга тиеш. Мин бу хакта баш инженер Тынчурингa да, АЭС директорына да әйттем. Алар миңа карап көлемсерәделәр генә. Республика газетасыннан килгән хәбәрче дә ярымйорты итеп кенә чыгарды минем фикерне. Ләкин, иптәшләр, илдә башланган хәбәрдарлык үз эшен эшләр: халык безнең эшне белеп алыр, дип уйларга кирәк. Без — төзүчеләр,— нәрсә төзүебезне истән чыгармыйк һәм киләчәк буыннарның, туган җиребезнең куркынычсызлыгы, ахыр чиктә, яшәү-яшәмәве турында да уйларга бурычлыбыз. Әгәр дә без торак йортларның ярык-ертыкларын калдырып кеше кертәбез икән, бу начар нәрсә һәм бу хәл ничәмә гаиләнең үзәгенә үтә. Ә инде АЭС реакторының кимчелекләрен күрә торып та аны оясына куябыз икән — бу инде, гафу итегез, бөтен кешелеккә каршы котырынган гыйфритне шешәдән чыгарып җибәрү белән бер. Ишеткәнегез бардырмы-юктырмы, әйдәгез, мисалларга мөрәҗәгать итик: Америкадагы «Тримайл Айленд» атом электр станциясендәге һәлакәттән соң чит илләрдә мондый типтагы реактордан файдаланмыйлар инде. Көнбатыш илләре шушы һәлакәттән соң куркынычсызлык чараларына сигез йөз миллион сумлык акча бирделәр. Ә без... безнең ни кырганыбыз бар? Мең тәңкә бирсәк, ун меңлек тавыш кубарабыз да, аннары «кирәк» җиргә тотабыз ул акчаны...

Шулвакыт Тынчуринның көчле тавышы залны ярды:

— Демагогия бу, иптәшләр, мәгънәсезлек. Совет фәненә, илебезнең атом энергетикасына ташланган коточкыч гаеп. Корткычлык бу!— диде ул президиумдагы урыныннан сикереп торып.— Ни сөйлисез сез, Фидаяров?

Әмма залдан:

— Бүлдермәгез, сөйләп бетерсен! Нигә бүлдерәсез кешене? Дөрес сөйли!— дигән сүзләр яңгырады.

Тынчурин урынына утырды да, янәшәсендәге Угрюмовка нәрсәдер сөйләргә кереште.

— Ярый, иптәшләр, мине монда әллә ниләр әйтеп гаепләргә дә өлгерделәр. Бетерәм алай булгач. Ләкин шуны әйтәм: без инде битарафлык, хуҗасызлык һәм атом станциясе кебек мөһим объект төзелешендәге сыйфатсызлыкка түзеп тора алмаячакбыз. Безнең моңа хакыбыз юк...

Фидаяров трибунадан төшеп китте. Залда баягыдан да тирәнрәк тынлык урнашты.

Ниһаять, сәхнәгә Тынчурин күтәрелде, дөресрәге, президиумдагы урыныннан чыкты. Искәндәр үз урынына килеп утыргач, янәшәсендәге Остап, сары мыекларын уйнатып:

— Ну бирә хәзер үзеңә, Искәндәр абый, түзеп кенә тор,— диде.

Искәндәр дәшмәде, кулъяулыгын чыгарып маңгаендагы тир бөртекләрен сөртеп-сөртеп алды да тыңларга кереште.

— ...ны бик хуплап тыңладыгыз. Ләкин аның бик дөрес кебек тоелган сүзләрендә, иптәшләр, не-ком-пе-тент-ность (ул шулай иҗек-

ләп, басым ясып әйтте) ята. Хәзер безнең кайбер акыллы башлар үзләрен бик белдекле итеп күрсәтә башладылар. Акыл һәм белем җитмәүне халыкның тойгысына сугып, югары пафос белән тутырмакчы булалар.

Залдагылар бу сүзләрдән бераз гына шаулашып алдылар да, тагын нәрсә әйтер икән дип көтә башладылар. Остап Безбожный исә Искәндәргә борылып, «Әйттем бит»,— дигән мәгънәне сиздерде.

— Шул ук вакытта үзләренең кем икәнлекләрен оныттылар. Уйлап карасаң, төзелештәге хәлләр турында сөйләргә, бигрәк тә хөкем чыгарырга хаклары бармы соң аларның?.. Искәндәр Фидаяров минем авылдашым, сабакташым һәм мин аны үзебезнең төзелешкә, гафу итегез, иптәшләр, арты б..лы килеш алдым. Кеше бәлки аңлар, үзенең элекке «чыгышларыннан» соң берәр нәрсә төшенер дип өметләнгән идем... Менә хәзер мин сезгә Фидаяровның артыннан килгән (дөресе — Тынчурин соратып алган иде) «эшлекле» кәгазьләр арасыннан берсен укып күрсәтим әле.

Тынчурин пинжәгенең эчке кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь алды да (алдан ук әзерләнеп килгән!) ут яктысына табарак борылып укырга кереште:

«...Төзелеш идарәсе җитәкчесе булып алгач та гражданин Фидаяровның җинаятьләре аеруча киң колач җәйде. Ул, үзенә якынайтылган берничә кеше белән дәүләткә каршы, аңа материаль зыян китерә торган эшләр оештырды. Мәсәлән, төзелеш идарәсендә моңарчы әйбәт кенә эшләп килгән инженер һәм белгечләрне кысрыклап чыгару массовый төс алды. Моннан тыш Фидаяровның җинаятьчел төркеме төзелешкә кайтарылган кыйммәтле әйберләрне һәм шулар аша күп мең сумнар белән исәпләнгән акча үзләштерүне оештырды. Шуның өстәвенә, Фидаяровчылар ришвәт алудан да тартынмадылар. Мәсәлән, Фидаяровны туган көне белән котлап, идарә аппаратында эшләүчеләр аңа биш йөз сумлык кыйммәтле бүләк — япон магнитофоны биргәннәр. Моның белән ул төзелеш идарәсенә әхлакый зыян да китерде».

Бу урында инде зал умарта күче кебек гөжелди башлаган иде. Аннан да, моннан да: «Нәрсә сөйли ул?», «Нигә кешегә яла ягa?»— дигән сораулар ишетелде. Сәйдәр тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин залдагылар дәррәү кул чабарга керештеләр. Өлкә комитетының беренче секретаре Тынчуринга борылып нәрсәдер әйтте. Халык кул чабудан туктарга уйламады. Тынчурин үзен тыңларга теләмәүләрен аңлады һәм президиумдагы урынына барып утырды.

• • •

...Башта Фидаяровны партиянең шәһәр комитетына чакырдылар. «Намуслы эшче» исеменнән язылган хатны үзенә күрсәтмичә генә тикшергәннәр иде.

— Нишләп соң ул хатны миңа укытмыйсыз? Нигә документлар буенча тикшермисез? Элек эшләгән төштәге кешеләрдән сорамыйсыз?— дигәч, эшем кешеләре:

— Тикшербез!..Табарбыз!..— дип ышаныч белдерделәр.

— Ярый, алайса, тикшереп бетергәч чакырырсыз. Сезнең дәлилсез гаепләүләрегезне кире кагып утырырга минем вакытым да, теләгем дә юк,— дип чыгып китәргә туры килде. Аның артыннан:

— Булыр, озакламый вакытың булыр әле,— дигән янаулы тавыш ишетелеп калды.

Шул ук кичне, эштән кайтып килгәндә, аның машинасын юл чатында туктаттылар. ГАИ хезмәткәрләре белән бергә шәһәр прокуроры үзе һәм аның тикшерүчесе дә бар иде. Шунда ук пүнәтәйләре дә табылды.

Искәндәр аңлады: аның өстенә чып-чын кара корт килеп кунды! Ләкин үзенең беркайчан бер генә кадак та алып кайтмаган һәм кайтмаячагын белгәнгә күрә, машинасыннан тыныч күңел белән чыгып басты.

ГАИ машинасындагы ике лейтенант Искәндәр янәшәсенә килеп бастылар. Тагын бер мизгелдән инде аларның махсус күнегүләр ясый-ясый чыныктырылган куллары Искәндәрнең беләзегеннән һәм терсәгеннән эләктереп алды. Бу шул хәтле көтелмәгәндә булды ки, Искәндәрнең тәне каршылык күрсәтергә дә өлгерә алмады. Аның беләкләрен салкын тимер кысты. Кул богаулары чыртлап бикләнде.

— Бу сезнең дипломатмы? — диде шәһәр прокуроры (теге вакытта телефоннан дефицит әйбер сораган тавыш иде бу), Фидаяров машинасының арттагы буш креслосында ятучы күн тышлы дипломатка күрсәтеп.

— Әйе.

Машинаның ишекләре ачык иде инде. Прокурор агай бөгелебрәк машина эченә керде һәм ике куллап дипломатны утыргычтан күтәреп алды. «Күр әле, ничек кадерләп тота. Кара, кара, табарсың анда ишәк чумарын»,— дип уйлап алды Искәндәр, машинасы тирәсендә ыгы-зыгы килүчеләргә карап елмайган килеш.

Елмаясы булмаган, әлеге кешеләрнең осталыгын таныйсы булган икән.

— Әйе, бу минем эш кагәзләре йөртә торган дипломатым,— диде Искәндәр.

— Бик әйбәт,— диде аның тавышына охшатыбрак шәһәр прокуроры.— Бик әйбәт. Ачып карарга рөхсәттер бит?

— Куллары богаулы кешедән рөхсәт сорыйлармы соң? — диде Искәндәр.— Ачыгыз соң, теләгегез шул гына булса, ачыгыз, карагыз.

— Якынрак килегез, иптәшләр,— диде прокурор пүнәтәйләргә таба борылып,— игътибар белән карап торыгыз...

Һәм ул дипломатның ике ягындагы билдәмәнең ялтыравык каптыргычларына басты. Шомарып беткән җиз каптыргычлар чыртчырт итеп ачылдылар. Хуҗасының һәр хәрәкәтен алдан күрергә өйрәнгән ярдәмче хатын-кыз, перчаткалы бармакларын сузып, дипломат капкачын ике яктан тотып өскә күтәрде.

Капкач яртылаш ачылгач та күрде Искәндәр: дипломат эчендәге кәгазьләр өстендә ят бер төргәк — газетага пөхтәләп төрелгән нәрсә ята иде. Моңарчы куркуның ни икәнлеген белмәгән ир-ат йөрәге кысылып-чәнчешеп куйды, чигәләрен әллә нинди бер кыскыч кыса башлады.

Ул арада хатын-кызның перчаткалы куллары әлеге төргәкне үрелеп алды да тирә-юньдә басып торучыларга күрсәтебрәк:

— Күрәсезме бу төргәкне? — диде.

— Күрәбез, күрмичә ни, күз алдында бит,— диде пүнәтәйләрнең берсе.

— Күзебез чыкмаган лабаса,— диде икенчесе, күпереп торган кара мыеклысы.

Искәндәр хәлнең җитдилеген, һәлакәт упкынының төпсез караңгылыгын күргәндәй булды. Аның тамак төбе чатнап-ярылып киткәндәй булды, теле исә кайрак сыман кытыршыланып, аңкавына ябышты. «Нәрсә бу? Сез нәрсә эшлисез? Минем андый әйберем юк иде. Кайдан килгән ул?»— димәкче булды Искәндәр, ләкин өлгерә алмады. Баягы куллар гаять осталык белән төргәкне сүтәргә керeште. Искәндәр исә тораташ булып торып калды. Бары тик күзләре, моңарчы беркайчан да сынатмаган зирәк күзләре генә перчаткалы кулларны күзәтте.

Ниһаять, төргәк сүтелеп бетте. Һәм аннан... саргылт-көрән төстәге дүрт төргәк йөзлек һәм тагын дүрт төргәк куе яшькелт илле сумлыклар килеп чыкты.

— Ого-го-го!— дип куйды Искәндәрнең ике ягында басып торучы милиционерлар беравыздан.— Менә сиңа мә! Шәп яши бу!

— Күрдегезме?. Барыгыз да күрдегезме, иптәшләр!— диде прокурор, шатлыгын яшермичә.— Тәгәл күрдегезме. Бу ришвәтченең чын йөзен, кылган эшен күрдегезме?

— Ялган... Ялган акчалар болар. Минем андый акчаларым юк,— диде Искәндәр алга ыргылып.— Ялган... Про-во-кация бу! Законсызлык!

Ләкин аны көчле, махсус күнектерелгән ир-егетләр үзләренең тимер кысаларында элеккечә үк нык тотып тора иде. Шуның өстәвенә, уң якта басып торучы милиционерның буш кулы, кискен хәрәкәт ясап, Искәндәрнең күкрәк астына тиеп китте.

Көтелмәгән, башкара белеп башкарылган бу хәрәкәттән Искәндәр тынсыз калды. Аңа һава җитми иде.

— Хәзер, хәзер күрсәтәбез сиңа бу акчаларның кемнеке икәнлеген,— диде прокурор һәм, үзенең машинасына барып, күн папка алып килде. Тирәсендәгеләргә күрсәтеп ачты һәм аннан кыстыргычлар белән беркетелгән, машинкада язылган кәгазьне алды да укый башлады:

«...Шәһәр прокуратурасына килеп әйтүне үземнең намус эшем дип саныйм. Миңа белгән кешеләр әйттеләр: Фидаяров ришвәт хакына төзү материалларын теләсә кемгә сатып җибәрә, диделәр. Ә безгә, эшебез тоткарланмасын өчен бик күп материал, шул исәптән, чит илдә эшләнгән ленолиум, бизәгеч плитәләр һәм башка төрле нәрсәләр кирәк иде. Мин берничә көн элек Фидаяровның эшкә килгәнен көтеп тордым да, ул машинасын җибәргәч, янына килеп: «Хөрмәтле иптәш Фидаяров,— дидем. Ул минем кемнән килүемне аңлады, күрәсең, «Ни йомыш?»— диде. Мин аңа: «Фәлән-фәлән нәрсәләр кирәк»,— дидем. «Ярый, уйлап карарбыз»,— диде Фидаяров. Мин: «Кайчан сезне күреп булыр икән»,— дидем. Мине күрергә кирәкми, минем машинада «дипломат» ятыр, ишек ачык булыр»,— диде. Соңра, уйладым-уйладым да, намусыма каршы бара алмыйча, вөҗдансыз ришвәтчене фаш итәргә булдым һәм сезгә шул хакта үз теләгем белән килеп белдерү ясадым...»

— Нахак, бу эшләрегезнең барысы да ялган. Сез үзегез дә ялганчылар!— диде Искәндәр, нәфрәтеннән буыла язып. Ул бөтен көчен куеп, җилкәләре белән янәшәдәге милиционерларның берсенә, анары икенчесенә төртте. Тегеләр көтелмәгән хәрәкәттән икесе ике якка мәтәлеп үк киттеләр. Искәндәр, ни эшләгәнен белештермичә, богауланган куллары белән прокурор алдындагы кәгазьләргә сукты... Соңыннан аның җан ачысы белән ясаган бу хәрәкәтен «кулга алганда милиция һәм прокуратура хезмәткәрләренә каршылык күрсәтте» дип язып куячаклар.

Ләкин ачык авызлык күрсәткән баягы милиционерлар икесе берьюлы аңа килеп ябыштылар һәм, бу юлы инде яшеренеп-нитеп тормыйча, бөтен көчләрен куеп, сугар урыннарны бик яхшы белеп суктылар.

Искәндәр ыңгырашып куйды да җиргә сыгылып төште...

## 2

Ямьле, җылы май бәйрәме килеп җитте...

Ләкин, бәйрәмгә берничә көн кала, Көмеш Аландагы атом электр станциясен һәм аның янәшәсендәге кала коручыларны, бөтен ил халкын, алай гынамы, бөтен кешелек дөньясын тетрәнергә мәҗбүр иткән вакыйга — моңарчы күрелмәгән афәт килде...

Фирәзә ашханәдә эшләүче хатын-кызларын җыеп бәйрәм көннәрендә ничек эшләү, кемнәр эшләячәген һәм тагын кырыкмаса кырык төрле мәшәкатьләре турында киңәшеп утыра иде. Кызларның кайсыдыр, кулы тик тормаганга күрәдер инде, өстәлдәге радионы кабызып җибәрде һәм шул ук мизгелдә бүлмәгә Казан радиосыннан «ТАСС хәбәре тапшырабыз» дигән сүзләр ишетелде. Бу хәбәр кешене кайда һәм нинди халәттә генә куып җитсә дә шомландырып җибәрә... Чөнки дөнья тыныч түгел... Әлеге кыз, үзенең хатасын аңлап, тиз генә радионы сүндермәкче иде. Фирәзә һәм аның белән бергә утыручылар: «Сүндермә!» — диделәр... Ул арада дикторның шомландыргыч тавышы яңгырады:

> Инде хәбәр ителгәнчә, Киев шәһәреннән төньякка таба 130 километр ераклыктагы Чернобыль атом электр станциясендә һәлакәт чыкты. Һәлакәт урынында дәүләт комиссиясе эшли. Әлеге, тулы булмаган мәгълүматларга караганда, һәлакәт 4 нче энергоблокның бер бинасында чыкты һәм реактор бинасы корылмаларының ишелүенә, беркадәр радиоактив матдәләрнең тирә-юнь мохиткә таралуына китерде. Калган өч блок туктатылды. Алар исәнимин хәлдә һәм файдалану резервында торалар. Һәлакәт вакытында фаҗигале үлемнәр булды. Зыян-зарар күрүчеләргә ярдәм күрсәтелде. АЭС поселогында һәм аның тирәсендә яшәүчеләр эвакуацияләнде...

Бүлмә тынып калды. Әллә каян гына килеп кергән шөпшәнең гүләве, чыгарга урын таба алмыйча бимазалануы ишетелде. Хәбәрне аңлаучылар бер-берсенә карашып утыруларында булдылар. Бу тынлыкны рус кызлары бозды. Алар: «Нәрсә булды, нинди хәбәр? Нигә әйтмисез?»— диешә башладылар. Фирәзә шунда гына тын алып:

— Бәхетсезлек, кызлар, бәхетсезлек!— диде.— Киев янындагы атом станциясендә һәлакәт булган.

Шул ук секундта кемнеңдер «Ah!» дигәне ишетелде, барысы да шкаф артынарак утырган Надяның ни еларга, ни шыңшырга белмичә тынсыз торуын күрделәр. Инде хәзер алар: «Ни булды, Наденька?»— диешеп урыннарыннан күтәрелделәр, кызый янына туплашдылар. Фирәзә килеп, Наденьканың кулларын битеннән алды да: «Әйт, ни булды?»— диде. Шуннан соң гына инде күзләреннән мөлдерәп-мөлдерәп яшь агучы Наденька:

— Анда... Чернобыльдә... минем... этием белән әнием яши... Сеңелләрем дә... — диде.

Шулай итеп, шомлы хәбәр, әллә кайдагы куркыныч булып кына калмыйча, Көмеш Аландагы ашханәдә, иң тыныч эштә эшләүчеләрнең дә борчу-кайгысына әверелде.

Шулай да әлеге һәлакәтнең зурлыгын, нинди куркыныч янавын кешеләр аңлап ук бетермиләр иде әле. Хәзер дә шулайрак килеп чыкты, хатын-кызлар бераз кайгырыштылар, Наденьканы: «Елама әле, әнә бит андагы бөтен кеше чыгарылган, диделәр. Хәбәрләре килеп тә җитәр, тукта, Наденька»,— дип юаттылар да, тагын бәйрәм көннәрендәге мәшәкатьләренә күчтеләр...

Бу һәлакәтне хәтта белгеч кешеләргә дә аңлар, аның бөтен тирәнлеге белән күз алдына китерер өчен вакыт һәм Чернобыльнең үзен, аңардан килгән зыянны кабат ишетү кирәк иде әле...

Фирәзәнең хатын-кызлар тулай торагына күчеп, ялгызы гына бер бүлмәдә яши башлавына дүрт ай инде. Шәрифуллин агайга рәхмәт, якташ итеп кенә мондагыдай шартларда да аерым бер бүлмә юллау җаен тапты, югыйсә эшләре бик үк шәптән түгел иде Фирәзә-

нең. Баштагы көннәрдә ул үзенең дөрес эшләве-эшләмәве турында нык уйланды. Шикләнгән-икеләнеп калган минутлары да булмады түгел. Әмма көннәр үтү белән, аннан да бигрәк Сәйдәрнең Мәскәүдән кайтып, Фирәзә киткәнне белүгә, Динә янына күчеп яши башлавын ишеткәч тә...

Бер уйласаң, исләрең китәрлек: егерме елдан артыграк бер куышта яшәгән, бер урынга ятып йоклаган, бер-берсе турында кайгыртырга күнеккән ике кеше берсен-берсе күрергә дә теләми. Моңа ышануы кыен. Ләкин, нишләмәк кирәк, бер куышта яшәсәң дә, бер урында егерме ел йокласаң да, булмаган мәхәббәтне акчага сатып алып булмый икән шул... Кайберәүләр әйтер: тамаклары туйганга, тормышлары яхшы булганга, кайгылары беткәнгә күрә майларына чыдый алмаганнар, дип. Хәлбуки, беркатлы фикерләү бу. Мәхәббәттән башка ир белән хатынны бер-берсенә бәйләп тотып булмый икән ул.

Искәндәр... Нихәтле шатлык, нихәтле кайгы-хәсрәт китердең син шушы Фирәзә дигән «башсыз» хатынга... Фирәзә әле бүген дә, инде чирек гасыр үткәннән соң да оныта алмый бит син аңа китергән горурлык, шатлык тойгыларын һәм... үзенә-үзе каршы килеп кылган тискәрелекләрен дә оныта алмый. Ничек онытасың ди аларны? Алар бит кемнәрнеңдер тормышында булып, синең өчен җиде кат йозак артында калган нәрсәләр түгел, алар синең белән бергә яшиләр. Алар синең белән генә дөньядан китәчәк...

Әйтә иде Фирәзәнең әбисе: «Язмыштан узмыш юк, кызым»,— дия иде. Күрәсең, чынлап та, әбисенең халык теленнән алып әйткән бу сүзләрендә дөреслек бардыр. Фирәзәнең карынында җан иясе ярала башлагач, Искәндәр белән тормыш сукмагыннан кулга-кул тотынышып китәргә тиешләр иде кебек... Юк бит, алай булып чыкмады. Әбисе әйткән «язмыштан узмыш юк» дигән нәрсәнең уйнап-уйнап алуыннандыр,— алар тагын бер шәһәргә килеп чыктылар. Алар тагын бер-берсен көтеп, очрашулардан, хәтта күз карашларыннан да тәм табып яши башладылар.

Әй, Искәндәр, Искәндәр!.. Фирәзәнең сине көткәнен, сине уйлап төннәр уздырганын белмисең, ишетмисең, сизмисеңмени соң син? Сизәсеңдер, ишетәсең, беләсеңдер... Үзең дә бит көн саен ашханәгә кереп чыкмыйча калмыйсың... Юк, юк, тамак туйдырыр өчен генә түгел... Син бит Фирәзәне күреп чыгар өчен керәсең, әйеме, Искәндәр?..

Фирәзәнең әбисе әйтә торган иде: замана ахыры җитә башлагач, кем турында уйлый башласаң, шул кеше алдыңа килеп чыгар, дип... Дөрестер, ахрысы... Фирәзә, бүлмәсенә ишек шакуларын ишетеп:

— Керегез, әйе, әйе...— дип өстәл артыннан чыга башлаган иде... Ишектә күренгән кешенең Искәндәр икәнлеген танып тынсыз калды, тез асларына суктылармыни, чүгеп куйгандай итте.— Ис...кән...дәр...

Искәндәр артына борылып ишекне ныгытып япты.

— Беләсеңме, Фирәзә, мин... сине авылга кайтырга чакырмакчы идем... Кайтабызмы?

Фирәзә бу тылсымлы күренештән айный алмыйча:

— Бе-е-лмии-ии-м,— диде.

— Мин бер яхшы кешедән авылга кайтып килергә машинасын сорап тордым. Монда эшкә урнашып яши башлагач та авылны кайтып күрермен, дигән сүзем бар иде,— диде Искәндәр, Фирәзәнең күзләренә туры карарга тырышып.— Сүзне тотарга кирәктер ич. Көннәр дә менә дигән. Аннары, аннары бит минем, кем... Авылда сөйлиләр иде бит әле, теге бер бабай... Типан кушаматлы бугай, авылга утыз ел читтә йөргәннән соң кайткан, дип. Шуның кебек. Утыз ел ук тулмады әле тулуын... Юл күрсәтүче дә кирәк.

— Яхшы булырмы соң, Искәндәр? Кеше сүзе бар... Беләсең

бит, безнең авыл кешеләренең теленә бер тарыма, бер тарысаң арыма, диләр.

— Түзәрбез... Элек тә сөйләмәделәр түгел. Курыкмый идең бит.

Фирәзәнең бит алмаларына алсулык йөгерде. Ләкин ул үзен бик тиз кулга алды. Кискен хәрәкәт белән чәчләрен артка чөйде дә:

— Кайчан кайтабыз соң, Искәндәр?— диде ул икеләнергә урын калдырмыйча.— Ничәсендә кайтабыз?

— Берсекөнгә, демонстрациядән соң кузгалырбыз. Ярыймы?

Фирәзә сүзсез генә баш какты.

— Бик яхшы. Мин сине тулай торак яныннан утыртып китәрмен.

— Ярый, Искәндәр, ярый.— Һәм Фирәзә икенче мизгелдә авызыннан чыгып кош шикелле иреккә очкан сүзне тыеп кала алмады: — Җа-а-ным...

Искәндәр аны күкрәгенә тартып китерде дә рәхәтләнеп кочаклады.

Фирәзә карышмады.

## 3

Кояшлы җылы көн туры килде. Күк йөзендә ник бер болыт әсәре күренсен. Зәңгәрдән-зәңгәр гөмбәз Искәндәр белән Фирәзәне иркәләп кенә алып кайтып килә иде. Алар юлга чыгар алдыннан ук: «Зәй аша китәбез, Чистай аша кайтабыз»,— дип сөйләштеләр. Үзенеке булмаса да, үзенеке кебек үк тоелган ак «Жигули» күкрәген киереп, җиңел сулап, тигез генә гүләп Искәндәрнең һәр яңа хәрәкәтен җиренә җиткереп үтәп бара. Аның ачык тәрәзәсеннән җылы, тыгыз җил кереп Искәндәр белән Фирәзәнең чәчләреннән сыйпап-сыйпап уза, битләрен иркәләп-иркәләп ала. Сулыш алуы рәхәт, дөнья иркен һәм ул инде бервакытта да начар якка үзгәрмәс, һәрвакыт шулай гына торыр сыман тоела.

— Ис...кәндәр,— диде Фирәзә бераз тотлыгыбрак.— Сөйләле, үткән тормышың, хатының турында сөйләле... Ба-а-лагыз турында да... Кызың турында... Язамы ул?

Искәндәр тагын бер кавым дәшмичә барды. Аның кашлары җыерылган, карашы алга, юлның бер ноктасына төбәлгән һәм ул, әйтерсең, Фирәзәнең соравын да, үзенең аңа җавап бирергә тиешлеген дә оныткан иде.

Фирәзә үзенең соравын яңадан кабатламады. «Ишетмәгәндер яки сөйлисе килмидер»,— дип уйлады ул. Ә бәлки аңа да хатыны белән аерылуны сөйләве җиңел түгелдер.

Ләкин Искәндәр Фирәзәнең соравын онытмаган булып чыкты. Ул чираттагы машиналарны узып-узып китте дә, юлда бүтән машина күренмәгәч, иркенгә чыкты һәм тизлекне арттырды. Машина сиртмәгә беркетелгән бишек сыман чайкалып кына бара башлады.

— Кем белсен, бәлки әнә шундый хәлләрдән соң да бергә торып калган булыр идек. Ләкин... Юк, Фирәзә, син уйлама. Мин хатыннарны теләсә-теләмәсә дә, яратса-яратмаса да ирләренә бәйләп тотуны яклаучы кеше түгел. Аерылышу да, бүтәнгә чыгу да ихтимал. Тик бу кешечә булырга тиеш. Хыянәт... ителмәсен. Хыянәтне кичерүе кыен.

Бу сүзләрне әйткәндә әгәр дә мәгәр Фирәзәгә борылып караган булса иде Искәндәр... Ләкин Искәндәрнең үз хәле дә бик үк шәптән түгел, ул борылмады, акрын гына, тешләре аша сыгып кына сөйли бирде:

— Ике-өч көн үтмәде, минем бөтен түземлегемне бетергән, җанымны тетрәндергән хәл булды; элек яшәгән калада техникумда

укып йөргән кызыбыз... кызыбыз... Нәзирәне...

Искәндәр сөйләп китә алмады, ул үз сүзенә үзе буылып калды. Шулай да Искәндәр дәвам итте, ул бары тик Фирәзәгә күрсәтмәс өчен сулгарак борылган һәм юл читендәге нәрсәләрне караган булды, күзләреннән бәреп чыккан яшь тамчыларын гына сөртеп алды.

— Нәзирәне көпә-көндез... машина таптады... Без барып җиткәндә җаны чыккан иде инде... Скорыйга тиз генә хәбәр итмәгәннәр. Техникум яңа районда, бушлык аша үтәргә кирәк. Юл аша чыкканда... Машинаны күрүче булмаган, эзләвен дә эзләмәделәр юньләп. Хәер, аны эзләп тапканнан гына...

Машина урман арасындагы юлдан бара иде инде. Юл читендә Фирәзә яраткан чәчәкләр күренеп-күренеп калды. Башка вакыт булса, билгеле, Фирәзә машинаны туктатыр, Искәндәр белән бергәләп чәчәкләр җыйган булыр иде. Әмма хәзер, Искәндәр шундый фаҗигале вакыйганы сөйләгәч тә...

— Аннары сиңа беркадәр мәгълүм. Минем өстән тикшерүләр уздырырга керештеләр һәм озакламый мине алып та киттеләр. Судта мин каршы төшәргә, законлагыча үз хокукларымнан файдаланырга тырышып карадым. Кая ул? Мине бары тик җинаятьче итеп кенә карарга тиеш иделәр андагы хөкемдарлар. Ул якларда, Фирәзә, кешенең гаепләме-түгелме икәнлеген тикшереп тормыйлар иде ул вакытта. Әнә бит... Ишеткәнсең... Карамусаев үзен әмир итеп хис итә башлаган ришвәтче, алдар һәм карьерист бәндәнең иң якыннарыннан иде. Ярый инде, хаклык ул барыбер җирдә ятмый. Барыбер өскә чыга. Ярый әле ил җитәкчелегенә яңа кешеләр килде. Югыйсә, кимендә тагын ике ел БАМ тайгаларын кисәсе бар иде.

— Карале, Искәндәр... синең зур төзелеш идарәсе начальнигы, аннары СМУда баш инженер булып эшләвеңне, тәҗрибәле төзүче икәнлегеңне беләләрме соң биредә? Син бит партиядә дә булгансың?

Искәндәр байтак кына дәшмичә барды, аннары ирен читләре белән генә көлемсерәп куйды. Ләкин бу елмаю ниндидер үкенечле елмаю иде.

— Эш соң андамыни? Кесәңдә билетың булуда гынамыни, Фирәзә?— диде Искәндәр, машина рулен ике кулы белән салмак кына боргалый-боргалый.— Әлбәттә, мин партия члены идем. Ләкин бит минем хөкем астында булуымны беләсең.

— Эшкә урнашканда бу хакта әйттеңме соң, парткомга кердеңме? Сине бит аклаганнар, вакытыннан элек чыгарганнар. Син инде, Искәндәр, беткә ачу тотып тунны утка якма.

— Сәйдәр бу хакта сорады.

— С-с-сәйдәргә ышансаң! Сәйдәр бәлки әле? Юк, юк, син уйлама, Искәндәр, үзе аерылып китәргә мәҗбүр булган ирне яманлый дип уйлама. Башкалар аны белми. Син дә белмисең әле. Ул әле... сиңа да, миңа да... Карамусаевыңнан ким күрсәтмәс. Ул искиткеч мәкерле кеше, Искәндәр, сак бул син аңардан, сак бул...

Инде хәзер Фирәзә битләрен каплап еларга ук кереште.

Искәндәр аны юатмады, бер генә нәрсәне дә кайтарып сорамады, машинасын зур тизлектә алып баруын белде. Ул арада тагын бер борылыш ясадылар, тагын бер чатка җиттеләр. Ниһаять, Карурман башланды, алар урманы. Монда инде асфальт юк, элеккечә үк гапгади урман юлы. «Жигули»ның юлы кыенлашты. Йөк машиналарының зур һәм авыр тәгәрмәчләре салган эзләр күбәйде. Берничә урында Искәндәргә машинадан чыгарга, барып юлны карап-чамалап килергә, аннары бераз арткарак чигенергә һәм яңадан керергә туры килде.

Шулай тырышып-тырмашып килә-килә, Җиләкле аланына җиттеләр.

Искәндәр дә, Фирәзә дә үз аланнарын бер карауда танып алдылар. Аннары икесе берьюлы күзгә-күз карадылар.

Һәм, сүзсез генә, бер-берсенең кочагына тартылдылар.

Якындагы каен ешлыгында сандугачның өзелеп-өзелеп сайравы ишетелде. Ул бичара, күрәсең, ялгызы гына иде һәм шуңа күрә аның сайравында сагышлы моң тулы иде. Аның артыннан ук ике пар сыерчык каеннарга тияр-тимәс узып китте. Аларның эшләре ашыгыч, бик ашыгыч иде, күрәсең, туктап торуны, бушка вакыт уздыруны кирәк санамыйча, канатларын җилпеп яңа тизлек һәм юнәлеш алдылар, яңа ярылган яфраклар арасыннан өскә, зәңгәрдән-зәңгәр күккә таба атылдылар.

Искәндәр белән Фирәзә боларның берсен дә күрмәде, әлбәттә. Алар бер-берсенең кочагына ташланган мизгелдән соң әллә кая, ерак-еракта калган, ләкин хыялларында яшәгән яшьлек кайнарлыгына, мәхәббәт диңгезенең тирән төпкеленә чумып югалдылар...

Моны күреп торган агач яфраклары, үлән сабаклары, карт имәннең гасырдан артык дөньяны күзәтеп торган авыр ботаклары, ялгыз сандугач, гомумән, урмандагы барлык җан иясе тынып, ни булыр дигәндәй гаҗәпләнеп калды. Баш очындагы зәңгәр күк йөзе, яңару шатлыгыннан яшел хәтфәләрне көнләп түгел, сәгатьләп үстергән бәрәкәтле җир шулай ук тынсыз торды.

Вакыт дигән нәрсәнең кирәге юк, ул инде хәзер ике йөрәкнең тирбәлеш-тибүенә карап үлчәнә иде.

Озакламый аларның барысы да: ерактан күгелҗемләнеп күренгән Карурман, Җиләкле Алан, күпне күргән карт имән һәм сылу кызлар кебек ефәк күлмәк кигән яшь каеннар язгы караңгылык белән капланды.

Тагын беравыктан иксез-чиксез күк йөзенә түм-түгәрәк ай йөзеп чыкты һәм бөтен нәрсә дә үз урынындамы, кичә мин калдыргандагычамы, дип җирне күзәтергә кереште...

Алар икесе дә җирдәге чынбарлыктан ерак китеп, сихри тылсымга уралган җиләк сабакларының борыннарны кытыклап торган хуш исләренә күмелгән хәлдә мәхәббәт тантанасын кичерделәр. Ләкин Фирәзә, Искәндәрдән аермалы буларак, әлегә бер нәрсәне, гомере буена хыялланган, кайчандыр үз теләге белән ваз кичкән бәхетнең үз карынында яңара башлаячагын белми, белми иде. «Әйе,— дип уйлады ул бу бәхетле мизгелдә,— әнә тегендә, биектәге күкнең йөзендә, Җир шарын каплап торган гөмбәздә һәркемнең бары тик үз йолдызы гына йөзә. Әгәр дә мәгәр шушы бердәнбер йолдызыңны таба алмыйсың икән, бу инде зур үкенеч. Димәк, син тормышны япа-ялгыз гына кичеп чыгарга дучар ителгәнсең. Димәк, син — бәхетсез...»

## 4

Искәндәр белән Фирәзә кеше гомеренә бары тик бер генә тапкыр туры килә торган бәхетле мизгелләрне кичергән мәлдә борынгы Карурман өстеннән иңрәп-улап самолет очып үтте.

Ул Чаллыяр аэропортына турылап оча иде.

Аның салонында моннан берничә көн элек коточкыч фаҗигале тетрәнү кичергән, өйләреннән нибары бер сумка, өсләрендә ни булса шул хәлдә чыгып китәргә дучар ителгән берничә хатын-кыз һәм бала-чага йокымсырый иде.

Алар котырынган һәм бернинди авызлыклы йөгәнгә-дилбегәгә дә буйсынырга теләмичә, үзенең таш капчыктагы оясын туздырыпшартлап чыккан куәт-көч, ихтыяр, дөньядагы бөтен тереклекне юк итәргә хәленнән килгән атом-төш һәлакәтеннән ерагаялар иде. Ул һәлакәт меңләгән кешене туган-үскән, яшәгән җиреннән санаулы

минутлар эчендә кубарылып, чит-ят җирләргә китәргә мәҗбүр итте.

Кешелекне сыйдырган җир шары бу көннәрдә сагаеп, тынын кысып тора, тагын да ниндидер фаҗига булмагае дип көтә иде.

Берничә көн элек исеме бик аз кешегә генә мәгълүм булган, ләкин үз эчендә җәһәннәм көчләре кайнаудан алынган яктылыкны, җылыны кешеләргә биреп торучы Чернобыль атом электр станциясе күпләрнең язмышын парә-парә китерде.

Искәндәр белән Фирәзә генә түгел, җир шарының төрле якларында яшәгән биш миллиардка якын адәм баласы бу кечкенә генә кала янындагы дүрт реакторның нибары берсе шартлаганнан соң нихәтле бәхетсезлек, үлем килгәнлеген аермачык күз алдына китерә алмыйлар иде, билгеле.

Анда — Чернобыльдә, үз эчендә җәһәннәм иясе — гыйфрит көчләрен җыеп алган һәм ул көчләрне кешегә хезмәткә куйган Дүртенче блок бар. Бар иде. Шушы Дүртенче блок кешеләр тарафыннан саксызлык-акылсызлык күрсәтүдән хурланып шартлый.

Һәлакәт! Һәлакәт! Һәлакәт!

Бу сигнал атом электр станциясенең янгын сүндерүче лейтенантлары В. Правик һәм В. Кибенок сугышчан әзерлектә торган сәгатьләрдә яңгырый башлый.

Бу вакытта атом станциясендә эшләүчеләр һәм аны төзүчеләр, шулай ук ил халкы тирән йокыда була.

Бу егетләр үзләренең иптәшләре белән әнә шушы Дүртенче блокта яшеренеп, үз сәгатен көтеп яткан гыйфритка каршы атлыйлар һәм шартлаудан соң дөрләп яна башлаган машиналар залы түбәсендәге көчле ялкынны сүндерергә керешәләр, тагын да көчлерәк фаҗиганың юлына аркылы төшәләр.

Бу ялкын телләре башка реакторларга да үтеп керсә ни буласын алар бик яхшы белә. Ләкин инде булган шартлау да аларның гомерләрен кисәргә җитә, бик җитә.

Бу егетләрнең кирза итекләре югары температурадан кайный башлаган битумга бата һәм бер адым атлавы да алар өчен кеше ышанмаслык авырлыкка әверелә.

Бу егетләр ут кайнарлыгыннан һәм радиация нурларыннан һәр минут саен гомерләре кыскара, үлемнәре якыная барганны беләләр.

Аларга тын алуы торган саен кыенлаша. Бөтен тирә-юнь корым һәм төтенгә, көл һәм радиациягә күмелгән була.

Әмма алар, рәхмәт яугырлары, бер адым да артка чигенмиләр.

Бу егетләрнең күз аллары томалана, һәр яңа мизгел аларның көчен суыра, суыра, суыра һәм алар берәм-берәм үлемсезлек кочагына егылалар.

Бәлки, әнә шушы егетләрнең йөрәгендәге кайнарлык, җирдәге халыкка тугрылык һәм бирелгәнлек көче җиңгәндер. Бәлки алар шушы хис-тойгылар белән Ил һәм Җир халкын һәлакәтләрнең һәлакәтеннән, моңарчы берәү дә күрмәгән-ишетмәгән, күз алдына китерә дә алмаган иң соңгы һәлакәттән коткарып калганнардыр!

Соңыннан бу батырлыкка һәм бу һәлакәткә багышланган күп кенә баллада, шигырь һәм поэмалар языла...

Әмма әле болар берсе дә Искәндәр белән Фирәзәгә билгеле-мәгълүм түгел иде. Алар баш очларыннан узып барган ак тәнле самолетның гүләвен дә ишетмиләр. Әмма бу самолет инде аларның киләчәк язмышына турыдан-туры бәйле иде.

Самолет үтте дә китте, аның гөрелтесе дә югалды, ишетелми башлады. Урман яңадан сихри тынлыкка, төнге йокыга талды. Юк, урман йокламый иде әле. Анда төнге җан ияләре яши иде. Менә аларның берсе, пырхылдап оча-оча, юлын һәм юнәлешен югалтып булса кирәк, май үләннәре өстенә җәелгән япма өстендәге Искәндәр белән Фирәзә өстенә килеп кунды... Һәм шундук, үзенең ялгышын аңлап,

оятыннан нишләргә белмичә, яңадан очып китәргә карады. Тик соң иде инде, Искәндәрнең җитез куллары төнге кошны — мәче башлы ябалак иде ул — тотып алды. Ләкин кошның һәлакәткә юлыгасы килми иде. Ул, үзенә куркыныч янаганны сизеп, җан ачысы белән тыпырчынырга, канатлары белән Искәндәрнең кулларын кыйнарга керешә.

Искәндәрнең уенда усаллык юк иде, әмма ләкин бу җан иясе моны кайдан белсен?

Тыпырчынуы, канатларын бәргәләве белән ул үзенең ниятен аңлатты бугай. Искәндәр аны җибәрде. Мәче башлы ябалак, куркудан коты очып, карт имәннең калын һәм корыган ботагына менеп кунды.

Табигать һәм Кешелек яшь иде әле.

## 5

Чернобыль һәлакәтен күргән балаларны Казанга, аннан Чаллыяр аэропортына китереп төшергән самолетны Көмеш Алан кешеләре каршы алды. Йөздән артык бала һәм аларның укытучыларын Көмеш Аланда яңарак кына салынган, Май бәйрәме көннәрендә төзүчеләрне кертергә әзер торган ак йортларга урнаштырачаклар иде.

Бу хәл Беренче Май демонстрациясе тәгәлләнгәч тә, Искәндәр белән Фирәзә чыгып киткән минутларда билгеле булды.

Көмеш Алан җитәкчеләре: поселок Советы, шәһәр һәм Татарстан җирендә Чернобыль гыйфритенең яңасын коручы төзүчеләр, партия өлкә комитетыннан шалтыратып әйтелгән бу хәбәрне ишеткәч, бер-ике минут аптырап тордылар торуын. Эш шунда иде ки, яңа салынган йортларга керергә тиешле кешеләр фатирларына күченәләр иде инде.

Төзелеш җитәкчесе Юрий Борисович Угрюмов — яңарак кына илле яшен тутырган, кара чәчле, каратут йөзле һәм нык бәдәнле, җитез хәрәкәтле кеше, баш инженер Сәйдәр Тынчурин, партком секретаре Фәргать Батыев, төзелеш җитәкчесе урынбасары Шәфигулла Шәрифуллин һәм тагын башкалар демонстрациядән соң трест бинасы янында җыелышып торалар иде.

— Юр-рий Борисович, Юр-рий Борисович,— дип кычкырды икенче катның ачык тәрәзәсеннән ни өчендер бәйрәм көнне дә эшкә чыккан Динә.— Сезне Казан чакыра. Телефонга. Тизрәк керегезче.

Биш минуттан каратут йөзе бөтенләй каракучкылга әйләнгән Угрюмов җыелышып төрле юк-барны сөйләшеп торучылар янына чыкты һәм:

— Иптәшләр... — диде.— Барыгыз да эштә саналасыз. Хәзер үк, ишетәсеңме, Фәргать Рәшитович, барыбыз да эшкә керешергә тиешбез. Яңа йортларга кергән кешеләрне яңадан элекке урынына күчерергә. Ул квартираларны Чернобыльдән киләчәк балаларга һәм кешеләргә әзерләргә. Шәрифуллин, син ике-өч автобус әзерләп, Чаллыяр аэропортына барырга, Чернобыльдән килүчеләрнең беренче төркемен каршы алырга тиешсең. Аңа хәтле яңа квартираларны җиһазлап куярга кирәк булыр...

Бу хәбәрне ишетүчеләр тынып калды. Якты кояшлы май көнендә мондый хәбәрне ишетү бик үк күңелле түгел иде. Чөнки җыелышып торучылар арасында да яңа квартирага керергә әзерләнүчеләр бар иде.

Әллә нинди, күңелләрне шомландыра торган хәбәр иде бу.

Чынмы бу? Әллә бер-бер яман төш кенәме?

Ул арада яңа хәбәр Көмеш Аланның иске урамы урынына са-

лынган берсеннән-берсе матуррак яңа йортларга, тулай торакларга таба бара иде инде.

— Безгә, иптәшләр, бик җитди эш кушылды,— диде Угрюмов, бүлмәсенә кереп утыргач та.— Безнең төзелештән осталарның махсус отряды... — Ул шулай диде дә, ни өчендер туктап калды, урыннан торып ишекле-түрле йөреп килде һәм: — Күбрәк бетон салучыларны, кыскасы, комплекслы бригада кешеләрен җыеп, иртәгәберсекөнгә үк Чернобыльгә җибәрү кирәк,— дип сүзен әйтеп бетерде.

Фәргать Батыев, мондый киеренке вакытларда күзләрен еш-еш йомгалап, пеләшен кашырга керешә иде, ләкин бу юлы әлеге гадәтен онытып, авызын ачыбрак, Угрюмовка карап тора бирде. Ә Тынчуринның ни өчендер йөрәге кысылып-кысылып куйды. Бер дә гена юкка булмаган икән. Чөнки Угрюмов:

— Бу төркемне тәҗрибәле инженер-белгеч җитәкләргә һәм эшчеләрнең бу эшкә барулары ирекле булырга тиеш,— диде.

Тынчурин ни әйтәсен үзе дә белмичә авызын ачты һәм Угрюмовны бүлдереп:

— Бүген-иртәгә ял көне бит, төзүчеләрнең күбесе, мөгаен, якындагы авылларына таралгандыр,— дип куйды.

Угрюмов кашлары астыннан гына аңа карап алды.

— Бүген үк китәргә түгел бит, Сәйдәр Хәлилович. Җыярбыз. Минемчә, Фәргать Рәшитович, бу төркемне җитәкләүне дә Тынчуринга, баш инженерга тапшырырга кирәк булыр. Ничек? Каршы түгелме син, Сәйдәр Хәлилович?

Фәргать Батыев, кинәт кенә исенә төшеп, башындагы ялтырап торган утрауны ышкый башлады.

«Эх-ма, авызыңа сугарга иде дә бит синең бу сүзләрең өчен,— дип уйлады Тынчурин.— Сизә идем, сизә идем мин синең кырын каравыңны. Алганда да берләшмә җитәкчесенең сүзенә каршы килергә кыймыйча гына алдың бит син. Менә хәзер инде мине җәһәннәмгә җибәреп котылмакчы буласың. Ләкин карышмаска кирәк хәзергә. Аннары күз күрер...»

— Мин каршы түгел,— диде Тынчурин бөтен түземлеген-сабырлыгын туплап.— Кирәк икән, барырбыз...— Шулвакыт Сәйдәрнең башына бик шәп булып тоелган уй килде һәм ул Угрюмовка карап өстәп куйды: — Әгәр рөхсәт итсәгез, Юрий Борисович, мин хәзер резервтагы җибәрү котельные төзелешендә эшләүче Фидаяров бригадасы белән сөйләшер идем?

Угрюмовка бу фикер хуш килде бугай:

— Теге... актив җыелышында барыбызны да туздырган Фидаяровмы ул?— дип сорады.— Шулмы?

— Әйе, шул үзе.

— Соң бит аны җыелышта үзең сүктең. Утырып кайткан кеше, партиядән чыгарылган кеше, хәтта безнең яшәешкә каршы кеше, дидең. Андый җаваплы эшкә җибәрүне хупларлармы? Аның белән барырга курыкмыйсыңмы?— Угрюмов шулай диде дә сул кулының баш бармагын түшәмгә таба күтәреп күрсәтте.— Ул ягына ничегрәк карыйсың, Сәйдәр Хәлилович?

— Ә нигә, минемчә, анда нәкъ шундый кешеләр барырга тиеш тә беренче нәүбәттә. Чөнки аларга үзләренең тугрылыгын исбатлау кирәк. Әгәр дә мәгәр алар шундый гадәттән тыш вакыйгалар булган урында үзләрен күрсәтмәсәләр, тагын кайда күрсәтерләр?

— Әйе шул, дөрес әйтәсең, Сәйдәр Хәлилович. Кем булган соң ул?

— Төзүче инженерлар институтын бетергән ул, Юрий Борисович, һәм безнең трест зурлыгындагы төзелеш идарәсе начальнигы булып эшләгән. Аннары, ул бит АЭС реакторлары турында күп белүен күрсәтте. Менә... тәҗрибәсеннән файдалансын.

— О-го... Болай ук булгач... Син, Фәргать Рәшитович, нишләп аның белән кызыксынмыйсың? «Дело»сын соратыргадыр, бәлки.

— Беркөнне өлкә комитеты секретаре да аның белән шул хакта сөйләште. Мин ишетеп үк бетермәдем...— диде Фәргать Батыев.— Ачыкларга мөмкин.

— Ачыкларсың... Ә хәзер, иптәшләр, эшкә... Син, Сәйдәр Хәлилович, кешеләр туплауга, аларны, авылларга киткән булсалар, кичекмәстән чакырырга, кыскасы, иртәгә кичкә әзер булырга тиешсең. Кузгалдык.

— Кузгалуын кузгалырбыз, Юрий Борисович, минемчә, Фәргать Рәшитович тагын бер нәрсәне эшләсә... Безнең өчебезнең исеменнән Чернобыльдәгеләргә телеграмма сукса, бигрәкләр дә шәп булыр иде,— диде берләшмәдә чагында рапортлар оештырып, тыныч кына яшәгән вакытларын искә төшергән Тынчурин.— Бу безнең теләктәшлегебезне һәм хәлне дөрес аңлавыбызны да күрсәтер иде.

Угрюмов «Кузгалдык» дип урыныннан торган һәм ишек ягына таба бер адым атлаган иде инде, Тынчуринның тәкъдимен ишеткәч, яңадан борылып үз урынына кереп утырды, нәрсәнедер исенә төшергәндәй, башын чайкап алды һәм көлеп җибәрде.

— Молодец, Сәйдәр Хәлилович,— диде ул кулларын өстәленә салып.— Эшлекле һәм бик вакытлы әйтелгән тәкъдим бит бу. Карап-карап торам да, Сәйдәр Хәлилович, эшнең мондый якларын оештыруда синең тәҗрибә бик бай икәнлеген күрәм. Берләшмәдә бер дә юкка утырмагансың икән... Әйдәгез соң, ничек язабыз? Мә, Фәргать Рәшитович, кәгазь-ручкаң бармы? Йә, Сәйдәр Хәлилович, тәҗрибәдән чыгып син берничә җөмләне тәкъдим итеп карале.

— Минемчә, «Кадерле чернобыльлеләр!»— дип башларга кирәктер инде...

Тагын ярты сәгатьтән телеграмма тексты әзер булды, Фәргать Рәшитович аны ак кәгазьгә пөхтәрәк итеп күчереп язды һәм:

— Динәгә бирим әле, басып кертсен,— дип чыгып китте.

Телеграмма язганда җанланып утырган Тынчурин шулвакыт үзенең күңелен искиткеч бер төшенкелек биләп алганны тойды. Чөнки һәлакәт булган урынга бару аның ниятләренә туры килми иде. «Ничек, ничек соң әле мин бу хәлдән җайлап кына чыгып ычкына алмадым»,— дип уйланды ул. Әгәр дә мәгәр тагын бер-ике минут шул хәлдә утырса, сүзендә тора алмаячагын сизеп алды.

— Син, Сәйдәр, акылыңнан яздыңмы әллә? Патриот булып күренәсең киләме?— Динә әйләнмәле урындыгыннан аерылмыйча гына Сәйдәргә таба борылды.— Син кая барып әләгүеңне чамалыйсыңмы соң бераз?

Сәйдәр җавап бирергә өлгерми калды, ишек ачылып, анда Фәргать Батыев күренде.

— Булдымы, Динә?— диде ул ишектән керә-керешкә үк.— Мин, Сәйдәр Хәлилович, тулай торакка кешеләр җибәрдем, кала коручыларга да хәбәр салдым. Хәер, аларны Шәрифуллин ду китерә башлаган инде анда.

Динә урыныннан торды, машинкасындагы кәгазьне алып, күчергеч битләрен аралады да, Сәйдәр аша үрелеп, Фәргать Батыевка тоттырды.

Чернобыльгә җибәрә торган кайгы уртаклашу телеграммасы ярыйсы гына заманча рухлы булып чыккан иде.

«Кадерле чернобыльлеләр!— диелгән иде анда.— Сезнең батырлыгыгыз белән горурланабыз һәм сезнең өскә төшкән кайгыны уртаклашабыз. Без, Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр, тагын да яхшырак эшләргә, әлегәчә файдаланылмаган резервларны да эшкә җигәргә һәм шуның белән илебез энергетикасының яңа гигантын тизрәк өлгертүгә үзебездән лаеклы өлеш кертергә сүз бирәбез...»

— Булган бу, иптәшләр, бик әйбәт булган,— диде Угрюмов.— Тик менә бер җире генә... Коллектив белән килешеп үк эшләнмәде инде...

Тынчурин урта бүлмәгә, Динә янына чыкты, ләкин ул чыгып килгәндә Динә Угрюмов бүлмәсенә кереп китте. «Карале моны, ни кылана, карале,— дип уйлады Сәйдәр.— Туктале, туктап тор, кич җитсен әле, күрсәтермен мин сиңа күрмәгәннәреңне, күрсәтермен».

Тулай торак янында Фидаяров бригадасыннан нибары өч-дүрт кеше көтеп тора иде. Күрәсең, башкалардан да шулайдыр. Монда эшләүчеләрнең байтагы Чаллыяр, Зәй һәм Түбәнъярдан, тирә-як район-авыллардан тупланганга күрә, ял көннәрендә мондый хәл гадәти иде. «Инде нишләргә,— дип уйлап алды Тынчурин, ашыйлар бит башымны. Ул җәһәннәмгә бармый калуның берәр хәйләсен табаргадыр. Әллә соң чирләргәме? Юк инде, шаярма, иптәш Тынчурин, диярләр, Угрюмов андыйларны авызлыклый белә ул». Тынчурин үз эчендә әлегә хәтле булмаган салкын бер калтырау туа башлавын тойды. Ул әлегә бөтенләй үк түзә алмаслык түгел, әмма инде ерак офыктагы куркыныч, кара болыт сыман, аның йөрәгенә таба үрмәли иде.

— Ни хәлләр, егетләр?

— Исәнмесез. Әйбәт әле, иптәш Тынчурин,— диеште егетләрнең кайсыберләре. Күлмәк кесәләренә, чалбарына һәм тагын беләзегенә дә ялтыравык металл чылбыр-беләзекләр аскан-такканы әйтте.

— Ничек, ничек инде әйбәт булсын? Указыгыз белән башыгызны капларга... Магазинда ник бер нәрсә булсын,— дип мытырдады. Аны сары мыеклы берәү бик тиз туктатты.

— Син нәрсә, кем алдында басып торганыңны беләсеңме, Револь?— диде.— Юкны сөйләмә, тагын премиядән мәхрүм итәр.

— Премиясе дә, бүтәне дә бик мул булачак хәзер, егетләр,— диде Тынчурин кинәт кенә башына килгән бу уйдан шатланып.— Анда аны теләсәң күпме алырга булачак. Эш чыгып тора бит әле, егетләр...

— Эшкә дисәң, конечно, без булмыйча кем?— диде тагын Револь дигәннәре.

— Заманы шундый, егетләр, илнең терәге без хәзер.

Тынчурин күкрәгендә аңлашылмас борчылу сизде. Баягы курку болыты күзгә күренеп диярлек кабарып килә иде. Ләкин Тынчурин кирәк чагында ихтыяр көчен таба белә иде. Ул тырышлыгын шуңа туплады.

— Ишеттек, күптән ишеттек мондый сказкаларны... Эшкә барсаң, все как бабайлар заманындагыча. Ник бер механизация булсын, «бери больше, кидай дальше» белән эшлибез.

— Булды, Револь, телеңне тый,— диде бу юлы Сарымыек. Ул Остап Безбожный иде.— Нәрсә кирәк, нинди эш бар, иптәш Тынчурин?— дип елмайды ул.— Тик безнең менә шушы биш кеше генә хәзер Көмеш Аланда, барысы да авылларга таралдылар. Чаллыярга киттеләр.

— Җыярга кирәк егетләрне, кичекмәстән җыярга. Без сезгә бик җаваплы эш тапшырмакчы булабыз. Бик җаваплы!— дип Тынчурин бармагын өскә күтәреп күрсәтте.— Би-ик!

— Дудки, би-иктер инде,— диде Револь сүзгә кушылып. Күрәсең, ул бераз гына «кабып» өлгергән иде.

— Сезгә, егетләр, һәлакәт булган Чернобыльгә барырга тәкъдим итәбез. Дөрес, анысы, бу эш ирекле. Иртәгә кичкә әзер булып, берсекөнгә иртә белән Киевка очарга тиешбез.

Егетләр тынып калдылар. «Хәзер, әлеге тәти егет үзенең беләзекчылбырларын чаңгылдатып, беренче булып баш тартыр әле»,— дип уйлап куйды Тынчурин.

— Ишеткәнсездер бит, егетләр, бу хакта?— диде ул егетләрнең дәшмичә торуларына шатланыбрак.— Газета укыйсызмы соң сез?

Револь тагын:

— Сезнең ул газетагыз, иптәш... кем ...безнең общагага дүрт көннән генә килеп җитә бит. Беләсезме? Ну, откуда же?

Сарымыек:

— Без, мондагылар, бу изге эшкә риза, иптәш Тынчурин. Әмма да ләкин бригаданың бөтен кешесе исеменнән әйтүе кыен. Шуңа күрә без болай итик, хәзер үк егетләргә телеграмма сугыйк. Сез почтага шалтыратыгыз, алар анда селкенә төшсеннәр,— диде.

«Әй, бу мәхлуклар андагы куркынычны, анда нәрсә булганын беләләрме соң?— дип уйлады Тынчурин китәргә җыенып.— Аларның бугазына Указ* ятты, хәзер әнә нишләргә дә белмиләр».

Ул ихтыярсыздан кулын кесәсенә тыкты һәм аннан тәмәке савыты чыгарып бер сигарет алды. Револь, әрсезлек күрсәтеп, баш инженер «ризыгын» авыз итмәкче булып үрелгән иде, әмма Тынчурин аны күрмәгәнгә салынып читкә карады, тәмәке кабын кесәсенә шудырды. «Шул гына җитмәгән иде тагы,— дип уйлап алды ул,— сиңамы соң, адәм актыгы, мондый затлы нәрсәне авыз итү...»

Егетләр Револь хәрәкәтенең нәтиҗәсезлегеннән көлешеп алдылар.

## ДҮРТЕНЧЕ БАШЛАМ

### 1

Шомлы хәбәрләргә төренгән майның егермесе җитте.

Кояшлы, җылы яз инде байтак вакыт хакимлек итә, агачлар күптән инде яфрак ярган, үлән сабаклары шаулап буй үстергән, алмагач һәм шомыртларның ап-ак чәчәккә күмелгән бер мәле иде.

Узган бер айга якын арада ил халкы гына түгел, Европа, хәтта Җир шарында яшәүчеләрне тетрәндереп, барлык-барлык телләрдә нибары ике сүз йөрде:

— Чернобыль! Һәлакәт! Чернобыль! Һәлакәт!

Шушы көнгә хәтле якага-яка килеп, уртак тел таба алмыйча берберсе өстенә атом-төш бомбаларын ташларга әзер торган даирәләр сагаеп калды. Дүртенче реактор өстендә хасил булган радиация нурлары халыкара чакматашка корыч кисәге тидереп алгандай ялтырап китте һәм ул чаткыларның дөньякүләм һәлакәткә китерәчәген моңарчы күрмәскә тырышучылар да күрергә мәҗбүр булдылар.

Көмеш Аландагы төзүчеләрнең Тынчурин җитәкчелегендә Чернобыльгә килгән унҗиде ир-егетнең уналтысы иртәгә Дүртенче реактор астындагы җәһәннәм оясына бетон түшәргә төшәчәк иде. Аларның монда килүләре нindидер сәбәпләр аркасында сузыла килде. Йә тегеләй, йә болай, диделәр. Егетләрнең күңеле иләс-миләсләнгән иде. Шуңа күрә, эшкә чыксалар да, күбрәк барасы җирләре турында сөйләшә торган булып киттеләр. Алар әледән-әле: «Искәндәр абый, әйт инде, кайчан китәбез?»— дип йөдәтә башладылар. Баштарак Искәндәр, трест җитәкчеләренең сүзен кабатлап, «Иртәгә, яки берсекөнгә» дип котыла иде, ләкин көн арты көн узып, атна-ун көннән соң алар моңа ышанмый башладылар. Искәндәр, теләсә теләмәсә дә, көн саен диярлек трестка кереп чыгарга тиеш булды.

---

* Алкоголизм һәм эчүчелеккә каршы көрәш турындагы мәгълүм указ хакында сүз бара. (Автор искәрмәсе)

Ниһаять, кҿне җитте, алар Чаллыяр аэропортыннан очтылар да борынгы Киев каласына килеп төштеләр.

— Кабахәт, менә бит нинди кабахәт,— диде Илдар Корбанов, ачуына буыла-буыла, Фидаяров янына килеп.— Качты... Күз алдында качып китте бит!

Чернобыльгә ярдәмгә килүчеләр зур-зур бинаны хәтерләткән чатырлар шәһәрчегендә яшиләр иде, аның эчендәге эңгер-меңгердә Илдарның тавышы аеруча көчле һәм нәфрәтле булып яңгырады. Искәндәр, урыныннан торып, караватт читенә утырды һәм:

— Ни булды, Илдар?— дип сорады.— Нигә болай сүгенәсең?

Ул арада алар артыннан ук кергән Остап Безбожный белән Револь Вәлиев янәшә килеп бастылар. Аларның да күзләре ачулы елтырый, йөзләрендә әллә нинди рәнҗү чаткылары чагыла иде.

— Ни булды, егетләр?— дип кабатлап сорады Фидаяров.— Кем кабахәт? Тавышыгыз үзегездән зур,— дип сүзне шаяртуга борган булды.

Турысын әйткәндә, Фидаяров бу минутларда бары тик бер нәрсә турында уйлап алды: егетләр, мөгаен, бәлагә тарыган кала тирәсендәге берәр каракны күргәч шулай кызганнардыр. Чөнки бөтен ил халкы шушы кайгыны кичереп яшәгәндә дә ыгы-зыгыдан файдаланып калырга, җиңел генә кесә калынайтырга тырышучылар юк түгел икән ләбаса...

— Кем булсын? Шул... Безне доброволецлар сез, как это, батыр сез, сезгә ордена бирә... Сез вкалывайте, дия-дия кем привез?— диде бу юлы Револь Вәлиев алгарак чыгып.— Помните ли вы, безнең бригадага килеп добровольцев язганда ул себя язмаган иде...

Болай да татарчаны ватып-сындырып, ике сүзнең берендә рус сүзе кушып сөйләүче егет, дулкынлануы көчәйгән саен русчага күчә бара иде, хәзер исә ул бөтенләй заман телендә генә нәфрәтен сибәргә керешә...

Искәндәр аңлады: сүз, әлбәттә, Тынчурин турында бара иде. Чөнки ул аларны — Көмеш Алан төзүчеләренең беренче төркемен җитәкләве белән бик һаваланып йөрде. Озатучылар төркеме алдында да: «Без үзебезнең изге бурычыбызны үтәргә, ил халкы белән бергә булырга барабыз»,— дип төчеләнеп сайраган иде... Ни булган?

— Ягез әле, егетләр, юньләп кенә сөйләп бирегез әле? Ни булды? Нишләде Сәйдәр Хәлилович?..

Бу юлы Искәндәрне Остап Безбожный бүлдерде:

— Син, Искәндәр абый, ул кабахәтне олылап әйтәсең әле. Ул... ул бит безнең күз алдыбызда... Күз алдыбызда...

Аны тагын Илдар туктатты. Ул инде бераз тынычланган, сүзен җайлап сөйләрлек хәлгә килгән иде бугай.

— Китте, билет алды да кайтып китте. Ыштыр бит...

— Ничек китте?— Фидаяровның күңеле әллә нишләде. Аның өстенә, әйтерсең, ушат-ушат пычрак су сиптеләр. Әйтерсең, Тынчурин белән узган яшьлегенә, аның иң кадерле хисләренә — Фирәзәгә саклаган мәхәббәтенә берничек тә, беркайчан да аклап булмастай яла пычрагын сыладылар. Дөрес соңгы вакытларда Тынчурин белән аралары суынды. Суынды гынамы? Бу тегә җыелыштагы чыгыштан соң бигрәк тә сизелде, май бәйрәменә авылга кайтып килгәннән соң, Фирәзә бүлмәсенә күчеп яши башлагач, бөтенләй дошманлашуга әверелде. Ләкин Фирәзә Сәйдәрне ташлап чыккан, Сәйдәр үзе дә Динә белән ачыктан-ачык яши башлаган иде. Шуңа карамастан... Хәер, шиңгән үләнне ашаган мал шиңгәк булмыйча нинди булыр икән соң?

— Шулай... Кит-те... Бәргәләнде-суккаланды, күзләре атылып чыгар хәлгә җитте һәм безгә: «Киттем мин. Мәскәүгә. Анда миңа

үләргә ирек бирмәсләр. Анда минем даруым бар. Монда сезнең кебек шыр дураклар белән үземнең харап буласым юк!» — дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Фидаяров тынычлана башлаган иде, Сәйдәрнең мондагы кискен, хәтта куркыныч урыннан качуы хакында «Булуыннан булмавы яхшы» дия башлаган иде инде, әмма монысын ишеткәч, калтыранып куйды... Сәйдәрнең шушы хәлгә җитүе?.. Хәер, ул аның сәерлекләрен сизгәләгән, хәтта уйлап та алган иде.

— Бул-мас, егетләр, бул-мас...

Ләкин шул ук минутта аның күз алдыннан Сәйдәрнең отыры сәер вакытлары, тик торганда әллә нишләп китүләре, күзләренең агын әйләндереп карый башлаулары, шунда кесәсеннән сигарет алып тарта башлавы, бер-ике тапкыр суыргач та кеше төсенә кереп элекке, табигый халәтенә кайткан чаклары тагын бер кат үтеп китте. Фидаяровның андыйларны, куе чәй эчүдән күзләре әйләнеп чыгарга җиткән «чефирист»ларны, аннан да бигрәк гашә суыручыларны күргәләгәне бар иде. Ләкин ул аларга һәрвакыт кызганып карады, аларны авыру кешеләргә хисаплады, шуңа күрә алар белән аралашмаска тырышты. Әмма бу очракта... Трестның баш инженеры, аның яшьлек иптәше, ахыр чиктә, начармы-яхшымы, авылдашының шундый хәлгә төшүе... Болай булса, бирэдәгеләр «көтүчесе нинди — көтүе шундый» дия башламагайлары.

— Без аның сүзләренә ышанып ук бетмичә, китмәс бу, дигән өмет белән аэропортка да бардык, Искәндәр абый. Ул билет алган иде инде, регистрациядә басып тора иде... «Әнә үзегез шикелле бер дурак бар анда, ә мин — пас, ул сезнең зу-ур начальник булган кеше. Зу-ур кеше булган кеше», — диде ул безгә һәм пассажирлар белән бергә самолетка таба китеп барды.

— Ярый, егетләр, чүп үләне җир сайламый инде ул, — диде Искәндәр. — Ачыкларбыз. Беренче сменага әзерләнегез. Йоклап алыгыз.

Егетләр теләр-теләмәс кенә урыннарына таралыша башладылар.

— Безгә нәрсә, без әзер, — диде Револь. — Безгә сөрергә булсын...

— Ул кабахәт, барыбер, урнашыр... Акланыр. Аның бит, Искәндәр абый, ачмаган ишеге, кермәгән тишеге юк, диләр, — диде Илдар, нәфрәтен баса алмаган Револь сүзенә куәт өстәп.

Искәндәр көлмәген кия-кия ишеккә таба юнәлде, көн яктысына чыгышлый: «Китсен, алдыннан арты яхшы, киткән кешегә ишек ачык, юл такыр», — дип уйлады. Әмма тамак төбенә тыгылган ачы таш төер кузгалырга теләми иде.

Язгы кояш моңарчы мең еллар буена җылы нурларын ничек сипкән булса, хәзер дә — һәлакәттән байтак көннәр узганнан соң да һаман елмаеп җиргә карап тора. Тирә-юнь элек ничек яшеллеккә күмелгән булса, хәзер дә шулай ук ямь-яшел иде. Әнә тегендәге биналар ничек басып торган булса, хәзер дә шулай тора бирәләр. Кешеләр... Юк, кешеләр, кешеләр алай түгел, кешеләрдә күрер күзгә күренми торган әллә нинди үзгәреш бар. Дөрес, мондый үзгәрешне сизүе кыен; моның өчен тәҗрибәле күз, моның өчен элекке көннәрдәге хәлләрне белү кирәк иде.

Ә бит... ә бит бөтен нәрсә үзгә хәзер. Әнә теге алмагачлардагы чәчәкләр, аларның яфраклары һәм кәүсәләре, җирдәге үлән сабаклары, хәтта юлдагы тузан да үзгә хәзер... Элеккеге, нибары моннан егерме көн элеккеге табигать юк инде ул хәзер... Аңарда, табигать җисемнәрендә, һәрбер нәрсә һәлакәтнең күзгә күренмәс, тузанын, бары тик сизгер, бик сизгер приборлар гына «күрә» белгән нурларны йоткан... Ә тегендә... Тегендә исә бу минутларда аяусыз көрәш бара. Гыйфрит авызыннан сибелгән төкрекләрне зарарсызландыру өчен, яңалары чыкмасын өчен көрәш бара. Бөтен илдән килгән фидакярләр, үз-

үзләрен аямыйча, һәлакәт калдыкларын бетерү, яраланган, канга, дөресрәге, радиоактив тузанга һәм нурга манчылган нәрсәләрне зарарсызландырырга тырышалар. Әнә, әле аннан, әле бу яктан күк йөзендә йөзеп-йөзеп йөрүче вертолетлар каһәр суккан Дүртенчене күмәргә тырышалар, бүксәләренә арканнар белән аскан йөкне шунда ташыйлар.

Искәндәр күрәзәче булып чыкты: монда шартлаган реактор — галимнәрнең кайберләре кисәткән, инде берничә АЭСта вак-төяк һәлакәтләр китергән РБМК канал тибындагы зур куәтле реактор иде.

Искәндәр, бүтәннәр кебек үк, һәлакәт турындагы хәбәрне ишетте, ләкин үзенең дә озакламый шушы җирдә булачагын башына да китермәде. Әмма, авылдан телеграмма белән чакырып китергәч тә, трест тәзүчеләре җыелышында ярдәмгә бару тәкъдимен беренчеләрдән яклап чыкты.

Чернобыль һәлакәте безнең ил һәм кешелек акылын галимнәр һәм гадиләр күз алдына да китермәгән, янсә томан һәм болыт аша гына төсмерләгән бер чорга — аек фикерләүгә алып керде. Һәлакәттән соң, дөньядагы яшәешне икегә бүлгән көчләрдән тыш, без әлегәчә әр-яңа көчләр барлыгын аңладык һәм шушы капма-каршы торудан бер-беребезгә таба якынаю дәверенә аяк бастык. Һәлакәт дигән нәрсә адәм балаларының өстенә, кайсы илдә һәм кайсы материкта булуын аермыйча, державаларның яшерен амбарларында саклана торган атом янгыры булып ява. Алар Җир өстенә төшеп шартлый башлагач, тоташ кара төнгә әвереләчәк көннең бер өлешен күзаллау мөмкинлеге бирде. Адәм затының камиллеккә ирешкән аңына күмәк үлем дигән явызның тәме, төсе һәм бернинди дә исе булмавы, аны бары тик җансыз приборлар белән генә билгеләнүен белү аяныч, бик аяныч иде, әлбәттә.

Кемнәрдер үз абруйларын яклап калыр өчен куйдырган Дүртенче реактор астындагы җәһәннәм оясын казуда, аңа бетон түшәүдә катнашачак берничә бригада җитәкчесен, шул исәптән Фидаяровны да урынга алып бардылар.

Чатырлар шәһәрчегендә һәлакәтнең зурлыгын кешеләрнең йөзенә чыккан газап, йокысызлык һәм, иң мөһиме, чарасызлыктан интегүләренә карап та чамаларга мөмкин иде инде. Хәер, андагысы...

Үр өстендә гөлбакчага күмелеп утырган шәһәрнең исә үлем тынлыгына уралып, ком чүлендәгедәй бушлыкка төренеп калуын күргәч... кешене моңа хәтле кичермәгән көчсезлек, һәлакәткә дучар ителгәнлекнең чынбарлыгы кебек сәер тойгылар биләп ала.

Шәһәр хәтле шәһәрне кешедән башка күз алдына китерә алабызмы?

Бу безнең акылга сыярлык нәрсәме?

Хәер... Шәһәр бөтенләй үк җансыз түгел икән әле. Әнә, пристань алдына ярты ягы чаларган, кайчандыр кара төстә булган эт йөгереп чыкты һәм, кешеләрне күрү шатлыгыннан нишләргә белмичә шыңшый-шыңшый, килүчеләрнең аяк астына томырылды. Хуҗалары ашык-пошык җыенып чыгып киткәннән соң да ул, бичара, үзенең һәм хуҗасының өен саклый, постын ташламаган... Әмма ул, мәхлук җан иясе, радиация нурыннан шундый сәер төскә керүен белмидер, әлбәттә. Аны бигрәк тә ачлык куа, ачлык дигән нәрсә ул сиңа туган апаң түгел...

Шушы уйлардан арына алмавына аптыраган Искәндәр, яңадан чатырга кереп, үзләре урнашкан якка таба атлады. Егетләр йоклагандыр дип уйлаган иде, ләкин алар йокламаган һәм тынычланырга уйламаганнар да, киресенчә, кызып-кызып бәхәсләшәләр булып чыкты.

— Әһә, шулайдыр шул, как же,— ди Револь Вәлиевнең унга

бер татар сүзе кушып җибәргәләгән тавышы.— Ка-а-кой перестрой-ка, кем аны күргән? Син, Илдар, юкны сөйләмә, яме. Без бит синең белән күрдек үзебезнең төзелештәге хәлләрне, күрмәдекме? Әлек әнә резервтагы котельный төзелешендә күрдек. Измә-бетонны китерсәләр китерделәр, китермәсәләр юк. Алай да түзәрлек иде әле. Ә инде Искәндәр абый теге җыелышта сөйләгәннән соң, монда китәр алдыннан, күпме вакыт нишләргә белмичә эшкә барып йөрдек? Нәрсә? Бүтән җиргә? Как бы не так? Потому что безнең бригадир, үзегез беләсез, куркаклардан түгел. Тотты да трибунага чыгып әлеге куркак җаннарның авызына сукты. Менә бит ничек. Искәндәр абый белә, что безнең җирдә АЭС төзергә ярамаганны, ә үзе төзи. Куда денешься? Э-э-э! Ник дәшмисең? Шулай шул, дөрес сүзгә, как это, җавап юк. Яшь булсам да, бик яхшы беләм. Хәзер әгәр дә жить хочешь икән, умей вертеться. Ничек? Ә менә шулай. Әнә безнең трестның баш инженеры кебек. Җыелышта берне сөйлисең, алай гына да түгел, үзең оештырып йөрисең. Ә инде иң кирәк чакта — тю-тю... в кусты! Ул бер кеше, только лишь бер түгел — ике. Мин үзем дә шундый ук. Мин үзем дә, пример, ике кеше хәзер. Берсе кайдадыр грудьның эчендә...— Револь шулвакыт үзе сөйләгәннәрне тыңлап торучы Искәндәр абыйсын күрде. Тыны бетеп бераз туктап торды, иреннәрен ялап алды, ә аннары, «ни булса шул булыр» дигәндәй, янындагы һаваны кистереп сул кулын болгап алды да яңадан сүзен дәвам итте:— Минем сосед егете вот, школны насилу бетерде, ә этисенең дуслары шәп булгачтын да сразу горком комсомолда инструктор булып эшли башлады. Бер ел да үтмәде, ул инде — горком комсомол секретаре. Эш чиста. Күрерсез дә торырсыз әле менә, озакламый комсомолныкы гына түгел, горкомның да первые булыр. Сезнең белән минем эшләрне өйрәтеп яшәр. Как это — эше күпнең көче дә күп аның. Мин моны точно әйтәм. Бабай говорил так. Безнең теге трус нинди иде тегендә? Не подходи! Юньләп сөйләшми дә иде. Ә сез аңа моннан качып кайткач та чего-нибудь булыр дисезме? Ну да... Ни шиша не будет. Нәрсә булса да бик килештереп ялганлар ул. Бюллетень алыр, черт его белсен. Тагын чего-нибудь придумает. Ә без...

«Дөрес бит, шайтан алгырысы, иш-ишен тапмыйча калмый ул,— дип уйлап алды Искәндәр Револьгә карап. Минем әби әйтә иде «Ишәк — ише белән, дуңгыз түше белән»,— дип. Безгә Тынчурин беркайчан да үрнәк булмады, без аңа ияреп яшәргә килмәдек бу дөньяга, безнең үз юлыбыз, үз язмышыбыз бар».

Шулвакыт Остап Безбожный, сары мыекларын бөтерә-бөтерә, Револь янына ук килеп басты һәм аны зур, йонлач кулының бер хәрәкәте белән сүзеннән туктатты.

— Син нәрсә, щенок, сүз боткасы куертасың әле монда? Син кайсы якка таба борасың сүзеңне? Ә? Нәрсә без? Безгә ни булган?— диде.— Карагыз әле моны, ничек сайрый? Искәндәр абый, килегез әле, ишеттегезме? Бу бит безне нәрсәгә үгетли?

Револь иптәшенең болай кызып китүен, нилектән шулай аның борын төбендә йодрыгын уйнатуын аңлап ук бетермәгәнгә күрә, күзләрен мелт-мелт ачып-ябып торды, аннары, тегенең кызып китүенең сәбәбен уйлап, кычкырып көлеп җибәрде.

— Син Остап, Сарымыек, ни-ни... Мине кемгә саныйсың? Килдек, и эшлибез дә! Без генәме монда? Что син? Вон сколько яшьләр... Сөйләшергә дә ярамый что ли? Хәзер уйлаганымны әйтәм, потому что полный ирек хәзер... Де-мо-кра-тия!— һәм тагын, тагын Искәндәрнең исен китереп, саф татарча аңа сүз өстәде.— Исс-лаах!..

Остапның кызуы сүрелә төште, ул Револь янына утырып:

— Однако син, давай, Револь, сүзеңне чамалабрак сөйлә. Ятларның ишетеп калуы бар,— диде.— Аннары Искәндәр абыйларына

таба борылды да: — Шулай бит, Искәндәр абый, безнең Татарстан маркасына тап төшермәбез, әйеме?— дип өстәде.

2

Чаптар ат кебек ашкын тормыш дәвам итә, аның туктап тын алырга да вакыты юк.

Июнь аеның унбишенче көне узып бара. Калатау куенына сыенып утырган Көмеш Аланның дистәләгән машиналар йөрүдән, төрле-төрле канау-траншеялар казыганда әле анда, әле монда булачак биналар өчен актарылып ташланган урамнарындагы җир өемнәре арасыннан узып йөрерлек була башлаган иде, тик кичәге яңгыр тагын җебетеп ташлады. Шулай да Фирәзәнең күңеле күтәренке, күкрәгендә әлегә берәү дә белми торган шатлыгы бар сыман иде. Дөрес, шушы соңгы бер-ике көнгә хәтле Фирәзә үзенең тәнендә сизелер-сизелмәс кенә башланган үзгәрешләргә бөтенләй диярлек игътибар итмичә килде. Һиһаять, кичә, яшенле яңгыр вакытында, кинәт кенә күңеле болганып алды. Баштарак Фирәзә монысына да игътибар итмәгән иде, «Кан басымы күтәреләме?»— дип уйлап куйды. Әмма аннары, йокларга җыенгач та, төнге күлмәген кияргә дип чишенгән чагында... Фирәзә ирексездән артка чигенеп, караватына «лып» итеп утырды. «Йә аллам, йә аллам,— диде ул үзенә.— Ни хәл соң бу? Чынмы соң бу? Ай тулып узды түгелме соң? Йә, ходаем. Әллә соң миңа да... миңа да... кырыктан узганнан соң булса да, югалган бәхетемне... ана булу бәхетемне кайтарасыңмы? Чынлап микән? Ялгышмыйммы икән? Мин бит, мин бит бу эшләрдә бик үк тәҗрибәле кеше түгел. Әллә соң берәрсе белән киңәшеп карыйргамы? Тик... мондый нәрсәне кем белән уртаклашырга мөмкин? Кемгә ышанырга мөмкин? Дөрес, телефоннан шалтыратырга була.— Әмма бу уйны Фирәзә бик тиз куып чыгарды.— Юк,— дип пышылдады ул ирексездән тәнен сыйпаштыргалап. Шулвакыт Фирәзәнең башына җирдәге кешеләрнең барысына да иртәме-соңмы килә торган бер уй килде. Әйе, кешенең бөтен гомере, аның яшәү рәвеше, кылган һәм кылачак эшләре, холкындагы үзгәрешләр, тагын бик күп, бик күп нәрсәләр мәхәббәт дигән гап-гади нәрсәгә бәйләнгән ләбаса.— Юк, берәүгә дә әйтмим. Бары тик аңа, Искәндәргә генә... язармын. Киткәннәренә инде атна тулып узды, ник бер хәбәре килсен? Әй, ходаем, аларны анда әллә нинди куркыныч эшләргә кушарлар микәнни? Әнә бит, аннан килүчеләр ни генә сөйләми? Йә, ходай, нишләргә соң миңа, ни кылырга икән?»

Шушы шатлыклы-борчулы уйлары белән бимазаланып ята-ята ничек йоклап киткәнен дә сизмәде Фирәзә. Бүген иртә белән уянгач та әле нишләптер кичәге уйлары исенә төшмәде аның. Бары тик хәзер, Көмеш Алан урамыннан атлаганда гына, эченә тулган шатлыкның күңелен җилкендереп торуын аңлагач кына, барган җиреннән кинәт туктап калды. «Ah»,— дип көрсенеп куйды.

— Ни булды, нигә сыкрандыгыз?— диде аның артыннан килгән таныш түгел бер хатын.— Ярдәм кирәкмиме?

Җавап бирергә кирәк иде бу хатынга, ләкин Фирәзә тамагына килеп тыгылган төердән ничек арынырга белмичә, күзләрен тутырып әлеге хатынга карап торуында булды. Ул аның татарча сәеррәк сөйләшүенә игътибар иткән булса, бәлки, каршысында к е м басып торганлыкны тизрәк аңлаган булыр иде. Тик Фирәзә ул сүзләрне түгел, аның йөзен, килеш-килбәтен, өстендәге киеменең дә мондагыча түгеллегенә төбәлеп торды. «Эшкә килгәндер,— дип уйлап алды Фирәзә.— Ерактан килгән, күрәсең, моңарчы әле безнең Көмеш Аланда бу хатын килгән яклардан берәү дә күренмәгән иде...»

— Юк, юк, борчылмагыз... Үтә... үтәр... Болай гына,— диде ул теге хатынга тагын бер тапкыр күзен тутырып карады.— Үтәр әле...— дия-дия барасы юлына атлады.

Ул да түгел, арттан машина кычкырткан тавыш ишетелде. Фирәзә ары карады, бире карады, ләкин бетон плитәләр түшәлгән юл — «прошпект»ның ике ягында да канау казыганда өелгән тау ятканга күрә, кая барырга белмичә, читкәрәк чыгып басты. Билгеле ки, Көмеш Аланда эшләүчеләр арасында Фирәзәне белмәүче юк иде. Шоферлар бигрәк тә күп белүчән халык, алар мондагыларның, кем әйтмешли, этен дә, бетен дә беләләр. Бу юлы да шулай килеп чыкты, машина Фирәзәгә якынлашкан саен акрыная төште һәм, аның турысында туктап, тузган башлы берәү:

— Әйдә, Фирәзә апа, апбарам,— дип кычкырды, тәрәзәсеннән башын чыгарып.— Юкса бу «прошпект»тан барып җиткәнче бөтенләй танымаслык буласың. Хәзер ялт иттереп столовой болдырына илтеп төшерәм үзеңне.

Фирәзә бүген әллә нишләгән иде. Ул үзенең кул астында эшләүчеләрнең сүзен ишетүен ишетте, ләкин ике-өч тапкыр кабатлап сорамыйча әйтелгәннәрнең мәгънәсе аның зиһененә барып җитмәде. Анда барып тотынды, монда килеп сугылды да, аптыраганнан нишләргә белмичә, бүлмәсенә кереп утырды.

«Чынмы-дөресме? Бармы-юкмы икән?»

Бу уй, Фирәзәнең башыннан чыкмыйча, әледән-әле искә төшеп бимазалый да тора иде. Ә бит аның күпме уй-хыяллары ничәмәничә тапкыр көтеп тә акланмады, чынга ашмады. Ул көтте, ничәмәничә еллар буена бала көтте. Врачларның нindиләрендә генә булмады. Ахыр чиге инде кайбер «күпне белгән» хатыннар бердәнбер дөрес киңәш бирделәр. Нишләмәк кирәк, чар-нәчар риза булды: Сәйдәреннән яшеренеп кенә берничә әби-карчыкка да барып карады. Тегеләр аны ышандырдылар: «Була, һичшиксез, була»,— диделәр. Фирәзә шуннан соң бер ай, ике ай һәм тагын яңаларын көтте. Ләкин чыбыркы белән сугып балта түтәсен сындырып була димени соң? Юк. Булмады. Аннары бер сердәше хәтта: «Фирәзә җаным,— диде,— сиңа менә дигән шәп кеше табып бирәм. Үкенмәссең. Балаң булыр аңардан. Урыны да, үзе дә хур булырлык кеше түгел. Бергә яшәмәсәгез яшәмәссез, аның каравы балаң булыр...» Хәер, Фирәзә үзе дә күрә, белә иде: күпме кызлар кыз килеш картаймас өчен генә бала таба. Аларның үзләренә күрә исемнәре дә бар инде. «Ялгыз аналар» дип атыйлар аларны. Фирәзәнең хәле андыйлардан түгел иде. Аның ире бар иде һәм ул, мөгаен, әгәр дә мәгәр кеше теленә кермичә генә кемнән дә булса авырга узып бала тапса, шатланган гына булыр иде. Һәрхәлдә, кырык ел көтү көтеп тә үзе чыбыркы шартлата белмәгәч, нишләсен, кеше алдында бала атасы булып йөрер иде ире. Икәүдән-икәү генә калган минутларда аның пычрак теле, билгеле, тик тора алмас иде ансы... Әмма Фирәзә андый юлга басмады, ул үзен үзе андый юлга басарга мәҗбүр итә алмады.

Кем белсен, әгәр дә мәгәр Көмеш Аланда Искәндәр кайтып күренмәгән булса,— кем әйтмешли, лачын булып лачын да кояштан югары очалмый,— Фирәзә, бәлки, беркайчан да шундый катгый карарга килә алмас иде. Сәйдәрдән китмәс иде. Кем белсен... Бәлки... китәр дә иде. Чөнки ике арадагы мөнәсәбәтләрнең шартлап өзелер чагы җиткән иде.

Искәндәр!..

Яшьтән үк белә иде ләбаса Фирәзә, белә иде: әллә генә нинди сөйкемле сөяге бар иде шушы горур үҗәтнең. Нәрсәседер яраттыра... Инде яратмыйм, онытам, син миңа кирәкмисең, дигән минутлардан

соң да яраттыра иде ул үзен. Ничәмә ничә тапкыр Фирәзә аның тарту көченнән ычкынырга, котылырга, азат булырга тырышып карады. Хатын-кызның бернинди логикага буйсынмый торган холкы үзенекен итә килде. Аның Искәндәр белән араны өзеп, Сәйдәргә чыгуының төбендә дә бәлки әнә шушы тискәрелек, үзенә калса, Искәндәр ихтыярыннан котылу нияте ята иде бугай... Булмады. Барып чыкмады. Үз тормышын үз куллары белән утка, гомерлек утка салды. Шуның өчен ул җәзасын да алды. Аның баласын карынында үтергәннән соң да язмыш Фирәзәне баласыз яшәргә дучар иткән булып чыкты, канына гомерлек сагыш салды.

Әйткән иде Карловы Варыдагы карт доктор, әйткән иде... «Бары тик бик зур тетрәнү, йөрәкнең чын тетрәнүе генә бер-бер хәл кылырга мөмкин. Кем белсен бу хатыннар затының серләрен һәм яшерен мөмкинлекләрен,— дигән иде.— Өметеңне өзмә»,— дигән иде. Ләкин җил исмичә кура селкенәмени соң ул?..

«Йә, ходаем, чын гына була күрсен, булсын, булсын гына,— дип пышылдады Фирәзә, үз-үзе белән сөйләшә-сөйләшә.— Булсын, олыгайган булсам да түзәр идем... Ни генә булса да түзәр идем. Булсын иде, балам гына булсын иде... Мәчетләргә, карт-корыга сәдакасын калдырмас идем. Хуҗалар тавына барып изгеләргә атап сарык чалдырыр идем»...

Шулвакыт өстәлдәге телефон озын-озын итеп чылтырый башлады. Фирәзә сискәнеп китте, чак кына урындыгыннан егылып төшмәде. Нәрсәнең, ни өчен һәм кайдан шулай чылтыравын аңлый алмыйча торды... Телефон икәнлеген аңлагач та кычкырып көлеп җибәрде, телефон трубкасына үрелде. Күрәсең, трубканы күтәргәндә дә әле көлә торган булгандыр, трубканы колагына куйгач ук:

— Күңелле сезнең анда, Фирәзә, бик күңелле ахрысы. Гомумән, соңгы вакытларда бик күңелле яшисең диләр әле монда... Нигә шул хәтле ярыласың?— диде теге баштан Шәрифулла Шәфигуллин агайның тупасрак тавышы.— Шатлыгыгыз эчегезгә сыймый бугай...

Фирәзәнең йөрәге әле дә булса кайнап чыккан салкын чишмә суы кебек ярсып-ярсып тибә иде. Шуңа күрә ул Шәрифулла агайның сүзләрен ишетте, әмма аңлап җиткермәде. Хәер, кем белсен, аның ни өчен шулай тупасланганын, аның җилкәсендә бөтен бер төзелешнең мәшәкатьләре... Аның үзен дә адым саен әрләп-кыздырып кына торалар.

— Әйе, шул, Шәрифулла абый, күңелле бездә,— диде Фирәзә.— Бик күңелле, хәтта елыйсы килә...

Шәфигуллин агай аны бүлдерде:

— Ярый, ярый,— диде ул.— Чәпчергә генә торасың. Хәзер үк кереп чык әле монда. Йомышым бар.

Фирәзә, арттагы ишектән генә чыкты да, трест аппараты урнашкан бинага таба китте.

Трест бинасы ишегендә ул, аны-моны абайламыйча барган килеш, кемгәдер барып бәрелде. Бу бәрелешү шулкадәр көтелмәгәндә булды ки, Фирәзә ирексездән артка чигенеп, тышкы якка ук чыкты. Аның артыннан ук «ай-вай-вай» дия-дия ул бәрелгән кеше дә чыкты. Фирәзә аны шундук танып та алды: бая килгәндә очраган каратут йөзле хатын иде бу.

— Гафу итегез, зинһар,— диде Фирәзә ни әйтергә дә белмичә.— Берәр төшегез авыртмадымы?

Әлеге хатынның күзләре Фирәзә моңарчы беркемдә дә күрмәгән нәфрәт чаткылары белән тулы иде. Ул чаткылар, әйтерсең, хатынның күзләреннән сибелеп-сибелеп төшәләр дә Фирәзәнең тә-

нена гена түгел, турыдан-туры йөрәгенә барып кадалалар иде.

— Башта сугып-бәреп миңгерәтәләр дә аннары тагын оятсызланып, гафу үтенгән булалар,— диде теге хатын Фирәзәнең алдына ук чыгып басып.— Сезнеме? Сезне берничек тә, беркайчан да гафу итмәячәкмен, белеп торыгыз,— дип өстәде ул.— Шакал белән бер бит сез. Сез... кабахәт җан... Сез... син...

Әйе, бу хатынның үз-үзен тотышын тиз генә аңларлык түгел иде.

Менә ул, атылып килеп, һич көтмәгәндә, Фирәзәнең күкрәгенә ябышты, чәчләренә үрелде. Ләкин бу хатын үзенең мөмкинлеген чамалап ук бетермәгән һәм кайчандыр Фирәзәнең спорт белән дә ярыйсы гына шөгыльләнүен, аннары әтисе янында трактор тирәсендә дә яхшы гына ныгыган булуын, гомумән, әле үз яшенә карағанда таза һәм нык сакланганлыгын исәпкә алмаган иде. Фирәзә аның начар ниятен аңлагач та бер адым артка һәм тагын бер адым читкә атлады, теге хатынның үз күкрәгенә ябышкан кулларына сукты. Теге хатын мондый усаллыкны көтмәгән иде, билгеле, бернинди каршылык күрсәтмичә аяк киемнәре юарга куелган тимер тагаракка сузылып төште...

Фирәзә аяк астындагы юештә яткан хатынны шул ук мизгелдә кызганып та куйды.

— Имгәнмәдегезме соң?— дип, хатынның кулбашларыннан тотып, торырга булыша башлады. Тегесе берьюлы йомшарып төшкән, аның баягы усаллыгы әллә кая югалган иде инде. Фирәзәнең ярдәме белән аякка басты. Һәм... көтмәгәндә, сулкылдап, Фирәзәнең күкрәгенә капланды.

— Нәрсә булды сезгә, кем сезне болай кимсетте? Каян килеп чыктыгыз сез монда?— диде Фирәзә чамасыз аптыраудан.— Тынычланыгыз, зинһар өчен, ягез инде, тынычланыгыз...

Фирәзә як-ягына каранып алды. Бәхеткә каршы, тирә-якта бер генә кеше дә күренми иде. Дөрес, Фирәзә трест бинасының икенче кат тәрәзәсенә таба күз салмады, шуңа күрә Динәнең ишек алдындагы бу кәмитне бик кызыксынып карап торганын күрмәде. Аның йөзенә бары тик буталып йөрүче җил генә килеп бәрелде, әмма Фирәзә аны да бөтенләй диярлек сизмәде.

### 3

Табигать...

Табигатьтән соң иң югары камиллеккә ирешкән Адәм баласы! Баш миенә, Йөрәк һәм Күңел дигән төшенчәне берләштергән, электрон-хисаплау машиналарыннан да камилрәк аңга ия булган Адәм баласы... Нигә, нигә соң син үзеңне тудырган Табигатькә, Җиргә, Яшәешкә һәм, ниһаять, үз-үзеңә шулкадәр битараф икән соң? Нигә, нигә?

Искәндәр Фидаяров һәлакәт булган урынга килгәндә беренче көннәрдәге җинаятьчел ыгы-зыгы инде кимегән, коточкыч җавапсызлык тудырган битарафлык зарарсызландырылган иде.

Һәлакәт нәтиҗәләрен киметү эше бер җайга салына башлаган, аның белән инде идарә итәләр, төп максат билгеләнгән иде.

Ләкин мондый олы һәлакәткә каршы көрәш Җир шарында беренче тапкыр оештырыла һәм бу акылга сыймый торган килделекиттеле нәрсәне, кабахәтлекне тиз генә җиңү, аңардан арыну җиңел түгел иде. Билгеле, мондый һәлакәт атом-төш коралын башлап уйлап табучылар һәм аны башлап халык тулы ике шәһәргә ташлаучылар өстенә төшәргә тиеш иде кебек... Халык телендә бит «үзең казыган базга үзең төшәрсең» дигән сүз бар. Аннары тагын «үз

башыңа булсын» дигән каһәрләү дә яши. Әмма, тормышта алай гына булмый, күрәсең...

Әлеге гыйфрит — Дүртенче реактор — бирешергә, авызлыкланырга, ахыр чиге бәхетсезлек чыганагы булудан туктарга тиеш иде кебек. Һәлакәттән соң бер ай вакыт узуга да карамастан, ул бирелергә җыенмый, аны буйсындыру моңарчы бер җирдә һәм бер илдә дә күрелмәгән киеренкелекне, кеше ышанмаслык тырышлыкларны даулый иде әле.

Искәндәр егетләренә, башта кушылганча, Дүртенче реактор астына казыла торган шахта-тоннельне бетон белән ныгыту, гыйфрит чәчкән нур-укларын һәм агулы тузанны җир куенына, тирәнгә җибәрмәү максатыннан чыгып салына торган «мендәр» түшәүдә эшләргә туры килмәде. Иртә белән алар эшкә җыенгач та бурычны үзгәрттеләр. Аларга һәм башка яклардан килгән бик күп ирекләләргә Куркыныч зона эчендә беренче карашка гап-гади кебек тоелган эшне — капчыкларга ком төяргә куштылар. Бу комга кургаш һәм бор кислотасы бутыйлар да шуны вертолетлар белән реактор өстенә, әлегә хәтле сизелер-сизелмәс карасу төтен саркып торган төшкә — аждаһаның авызына ташлыйлар иде. Ләкин салынган көч һәм тырышлык тиешле нәтиҗәне биреп бетерми. Алай гынамы? Ул инде берничә тапкыр, сиек төтенне куертып, янартау атылгандагы сыман төкеренергә тотынды. Бу хәл һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү белән шөгыльләнүче хөкүмәт комиссиясен борчый, хәлбуки, мондый хәл җирдә беренче мәртәбә булганга күрә, тәҗрибә җитеп бетми. Бу эшне авызны пешерә-пешерә, туктаусыз янган куркыныч белән кара-каршы басып башкарырга туры килә иде.

Әйе, мондый кайгының юлы төнлә дә якты бит аның...

Бүген Фидаяров егетләренең өчесе инде эшкә чыкмады. Дөресрәге, чыга алмады. Аларны махсус тикшерү вакытында аралап алдылар да шифаханәгә алып киттеләр.

Смена бетеп килгәндә Фидаяров үзе дә башын тотып-тотып карарга, маңгаен уа-уа киеренкелекне киметергә тырышкан иде. Җитмәсә, баш авыртуына күңел болганy да кушылды, аякларындагы көч кимедеме, әллә тагын башка берәр нәрсә булдымы — тез буыннары сыгылып-сыгылып куя башлады. Тамак төбен, кышкы салкында боз ашап салкын тидергән диярсең, нәрсәдер кытыкларга кереште.

Искәндәр сәгатенә күз төшереп алды, смена бетәргә тагын ярты, нибары ярты сәгать вакыт калган иде.

«Ничава,— дип тынычландырырга тырышты ул үз-үзен,— озакламый вертолет килер һәм без... һәм без... һәм без...» Искәндәр сизеп тора, аның чәчен хәвефле сәмум җилләре ялап үтте, аңына нидер булды. Ул башлаган уеның очын-дәвамын, кайчандыр әбисе үзе ураган йомгакның очын югалткандагы кебек, югалтты... Ирексездән җиргә тезләнде. Берничә генә мизгелгә аңы ачылгандай булып торды.

«Тор, хәзер үк торып бас, Искәндәр!»— дип боерды ул үз-үзенә.

Аның моңарчы бер генә тапкыр да сынатмаган тәне шушы боерыкны үтәде, ул яңадан аягына басты.

Ләкин...

Аның алдындагы бар нәрсә — ерактарак сизелер-сизелмәс төтен бөркеп торган янартау, берсен-берсе алмаштырган җитез кош-вертолетлар, дәһшәткә каршы атлаганда сакланыр өчен кигән килбәтсез киемле, битләрен маймыл йөзедәй битлек белән каплаган кешеләр томан эченә яшеренә баралар иде. Менә инде үзеннән нибары ике адымда эшләгән Илдар Корбанов, Остап Безбожный һәм Револь Вәлиев бер-бер артлы шушы томан эченә кереп югалдылар.

Әмма әйтмәгәнне кем белә дә, ачмаганны кем күрә соң аны?

Бу юлы инде Фидаяровның аңы томаланган, ми җисеме таркау, хәтта уй кисәген дә тотып тора алмый иде.

Тагын беравыктан бүген генә үз аяклары белән җирдән нык атлап эшкә килгән, башкалар белән иңен-иңгә куеп вертолетка менеп утырган, ниһаять, уңны-сулны белмичә ярсып эшләгән Искәндәр Фидаяров, үткен чалгы кисеп ташлаган үлән сабагыдай, соргылт ком өстенә авып төште...

«Юк, минемчә, иң авыр минутларда да үз-үзен авызлыклап тота белгән, беркайчан да өметен югалтмаган кешеләр кадерле», дигән аңгәмә тавышы Фидаяровны күзләрен ачарга мәҗбүр итте. Хәер, ул әле күзләрен ачканчы ук, аңы кайта башлауга ук ишеткән иде бу тавышны. Үзенчәлекле, якын һәм таныш тавыш. Искәндәр: «Кайда һәм кайчан ишеттем соң мин бу кешенең сөйләвен?»— дип уйлап алды.

Бүлмәдә эссе һәм бөркү иде. Искәндәр өстендәге ак җәймәне бер читкәрәк әйләндереп салды. Әмма аның бер кулы гына хәрәкәтләнә, ә икенчесен беләк турысыннан нәрсәдер чәнчеп тора һәм беләзегеннән салкынча нәрсә тоткан иде.

Искәндәр күзләрен ачыбрак шушы якка карарга тырышты. Шундук үзенең кайда икәнлеген аңлап алды, чөнки аның алдында ялтыравык металлдан эшләнгән, авыруларга шифалы дару яки кан җибәргәндә файдаланыла торган җайланманың сузылып төшкән сары көпшәләре асылынып тора иде.

«Мин хастаханәдә ятам икән. Димәк... артыграк нурланганмын... Туктале, нигә болай булды соң? Минем янымда башкалар да бар иде ләбаса,— дип фикер йөртте Искәндәр. (Ул афәтле шартлаудан соң тирә-юньдә радиактив нурлар сибеп ята торган матдәләрнең яшеренеп калганын белми иде әле). Ә, егетләр... алар ни хәлдә икән?»

— Юк, юк, кадерлем Яремчук, Дүртенче реакторга ком тутыру, аны төрле кушылмалар белән генә күмеп кую мөмкин булмаячак. Бу турыда академик Велихов бик дөрес уйлый. Әмма без хәзергә шуны эшләргә мәҗбүрбез. Ләкин моны туктаусыз эшләп булмый, аннары... үзегез күрәсез бит, кадерлем, беренче шартлаудан соң да тагын өченче тапкыр янар тау пошкырып куйды. Аннары, реактор астындагы ныгытма чыдамаска мөмкин. Әгәр дә мәгәр реакция бара торган матдәләр ишелеп төшсә? Әлегә аның астына бетон мендәр ясалмаган,— дип озын итеп сөйләде теге таныш тавыш. Шул арада Искәндәр хәтта бер-ике тапкыр онытылып та торды бугай. Ул тагын, игътибарын җәлеп итеп, бүлмәдә яңгыраган сүзләрнең мәгънәсен аңларга тырышып ята башлады.

— Ниндидер бүтәнчә, нәтиҗәлерәк чара күрергә кирәк булачак. Слушай, э-э-э! Бу хакта Велихов кына түгел, бик күпләр, шул исәптән, без дә, мондагы төзүче инженерлар да уйлыйбыз, кадерлем...

Ниһаять, Фидаяров тавышның хуҗасын таныды: Карамусаев берләшмәсендә баш инженер урынбасары булып эшләгән Григор Карапетян иде бу.

— Озак уй-лый-сыз, «Слушай-кадерлем» Григор Карапетян... оз-зак,— диде Фидаяров тотлыга төшебрәк.— Мм-м-минемчә, күптән инде... Дүрте-енчене бет-тон кол-пааак белән томалау чарасын күрә башларга кирәк иде.

Караватларында яткан килеш салмак кына сөйләшеп, монда да шул гыйфритне дөмектерү турындагы уйларыннан арына алмыйча фикер уртаклашып ятучылар, икесе берьюлы, урыннарыннан шуып-шуып төштеләр дә Фидаяров янына килеп бастылар.

— Ха-ха,— диде Карапетян,— без тагын аны кызганып, икен-

че көн аңына килмичә ята, мескенкәй, дип кычкырып сөйләшергә дә куркып торабыз, а? Нихәл, кадерлем Фидаяров? Кара син аны, тавыштан да танып алдың әле.

— Ну, Карапетян, сине кем танымасын, ди? Син бит безнең төзелеш берләшмәсендәге баш инженерның әрмәннәрдән бердәнбер урынбасары идең.

— Слушай, сиңа болай ук такылдарга ярыймы соң әле, а?— диде Карапетян як-ягына карангалап.— Син, кадерлем Яремчук, бу хакта ничегрәк уйлыйсың? Бу татарга ирек бирсәң... хәзер үк минем бөтен биографияне сөйләп чыгачак. Теле ачылды моның хәзер, слушай, а?..

Тегеләрнең хәле инде савыгу сукмагыннан таза адымнар белән бара иде бугай, икесе берьюлы көлеп җибәрделәр. Шулвакыт палата ишеге ачылып китте һәм анда ак халатлы берәү күренде.

— Иптәшләр, Карапетян, Яремчук. Бу ни хәл инде? Тынычлык сакларга дигәнне ишетмәдегезмени?— диде ул.— Ятыгыз хәзер үк урыныгызга!— дип тә боерды.

Карапетян белән Яремчук икесе дә, көлүләреннән туктап, караватлары ягына киттеләр.

Слушай, а, доктор,— диде Карапетян телен тыярга ашыкмыйча.— Ничәмә-ничә ел күрешмәгән дус белән исәнләшергә дә ярамыймы, слушай, а? Бу бит безнең Фи-да-яр-ров...— Ул шулай диде дә баш бармагын өскә тырпайтып күрсәтте.

— Ярый, ярый, Карапетян, сезнең әле рәхәтләнеп сөйләшерлек вакытыгыз бар биредә. Кеше бераз рәткә керә башласын инде.

Күрәсең, Карапетян монысына риза иде инде. Ул Яремчукка таба борылды да, «Менә, менә» дигәндәй ымлап куйды, аннары җитез адымнар белән тәрәзә янына барып басты.

Анда рус шәһәрләренең анасы — борынгы Киев җәйрәп ята иде. Һәркайда яшеллек, һәркайда җәйге кояш нурларына төренгән чәчәкләр. Борынгы каланың күкләргә ашып алтынга манчылган манаралары күз карашына аеруча бер горурлык бирә, матурлыкка сокланырга мәҗбүр итә иде. Шушы мәңгелек манзарага карап, берәү дә: «Бу шәһәр инде бер айдан артыграк фронт алды шәһәре сыман киеренкелектә яши»,— дип әйтә алмас иде. Ә әйтерлек, әйтерлек бит... Нибары 148 чакрымда моңарчы берәү дә, беркайда да күрмәгән һәлакәтнең аяусыз радионуклид дигән зәхмәт саклаган радиактив тузанын җилләргә һәм болытларга кушып еракларга җибәрүче Дүртенче реактор... Анда һәр көн, һәр сәгать тагын да куркыныч шартлау ихтималы бар... Дөрес, анысын аның фидакарьләр бастыра, тыя, авызлыклый. Әмма... Киләсе минутларының берсендә гыйфрит авызыннан нинди коточкыч дәһшәт сибелә башлавын кем инкяр итә ала! Күпме михнәт һәм күпме басып алучыларны, күпме кан һәм күпме үлем дәһшәтләрне күргән борынгы Киев үзенең уяу тормышы белән яши... Хәер, әгәр дә мәгәр гыйфрит бөтен көченә берьюлы дүрт төштән төкергән булса... Каланың мәңгелек бастионнары, таш биналары калган булыр иде булуын. Бары тик кешеләр, Җирне җир итеп торучылары гына булмас иде.

Бу — гади кешенең фантазиясе җитәрлек күренеш түгел иде, билгеле. Моннан, өченче кат тәрәзәсеннән, яшеллеккә күмелгән урамнардагы хәрәкәтнең элеккечә үк түгеллеге, әнә тегендәге йортларның бизәге — ишегалларында ыгы-зыгы килүче бала-чага тавышы быел ишетелми диярлек. Кешеләр, нәниләр һәм олылар быел шомландыргыч кырыслыкта яшиләр.

— Нихәлләр, хөрмәтлем Карапетян, бу якларга сине нинди җилләр китереп ташлады?— диде, ниһаять, доктор чыгып киткәнне белгертеп, тамызгычлардан арынган Фидаяров.— Мин сине инде бөркет биеклегендә очасыңдыр, дип уйлаган идем?

— Син, Фидаяров, слушай, үзеңне генә хаклык өчен көрәшүчегә исәпләмә, яме, кадерлем,— диде Григор Карапетян, тәрәзә янынан Искәндәр яткан караватка күчә-күчә.— Бер син генә Карамусаев белән бәрелешмәдең, слушай, ул якларда... Синнән соң ул гыйфритнең нәфрәтенә эләккән кеше мин булдым, кадерлем. Тик мине йотарга өлгерә алмый калды ул, мин яңа бер төзелешкә ычкынып өлгердем...

Ул тынып торды, теге вакытларда кичергәннәрен искә төшереп алды бугай. Аннары караватт янындагы урындыкка утырды да, ике кулы белән тезләренә шапылдатып сукты:

— Вообще то, син ишеткәнсең инде, Карамусаевны урыныннан алып, партиядән чыгарып, хөкем эскәмиясенә утырттылар. Дөрес, хөкем карары чыгарырга өлгерә алмый калдылар. Ул төрмәдә үзен-үзе бетерде, дөресрәге, кан тамырын кискән...— Карапетян тагын туктап торды. Аның кара кашлары җыерылып тора иде. Карамусаевның мордар китүе турында әйткәндә алар тартышып куйдылар һәм ул:

— Ай, слушай-кадерлем, нигә соң без шушы шакал турында сөйләшеп торабыз әле бирәдә?— диде.— Син вот, үзең турында сөйлә, булмаса. Хәлең ничек? Сөйләшерлекме?

Фидаяров күзләрен йомып кына «сөйләшәм бераз» дигәнне белгертте. Чынлыкта исә аның хәле бер генә дә әйбәт түгел. Тәнендә энә селкетерлек тә дәрман юк сыман иде.

— Мин нәрсә... мин... утырдым... БАМда.

Карапетян аны бүлдерде:

— Ай, слушай, өченче көн һәлакәт нәтиҗәләрен бетерү штабы каршында «Молния»гә күзем төште. Анда «ТатАЭСстрой» трестыннан килгән Фидаяров бригадасы бик авыр шартларда удар хезмәт үрнәкләре күрсәтте»,—дип акка кызыл белән язып куйганнар. Ну, кадерлем, мин әйтәм, бу татарны, монда да килеп җиткән икән, дим. Кайдан табарга соң, дим. Шул ук кичне монда алып киттеләр. Без какраз, слушай... син бу хакта ишеткән идеңме соң? Без бит әнә шушы син әйткән «калпак» турында. Без аны «Саркофаг» дип атадык. Шуны коруны проектлаштыручылар... Ну, слушай, син әле төзүчелек осталыгыңны югалтмагансың. Ә син анда, үзегезнең төзелештә кем соң? А, слушай-кадерлем?

Аның тагын шулай янәшә килгән, бу кешенең кушаматына әверелгән әлеге сүзләрдән, Фидаяров, аңына килгәннән соң беренче мәртәбә елмаеп куйды. Иреннәрен ялап көч туплагандай итте:

— Юк, Григор, мине тиз генә ычкындырмый әле Карамусаев нәфрәте... БАМнан кайткач, мине гади төзүче итеп тә алмыйлар иде. Ярый инде, бер сабакташ очрады. Так что, про-о-текциясез... Мин — бригадир...

Карапетянның кара кашлары тагын баягы кебек җыерылып килделәр дә үр куяны шикелле сикерешеп алдылар:

— Слушай, нишлибез соң без, ә? Ә бит илдә полный ход үзгәртеп кору бара, диләр. Неужели без шундый тәҗрибәле белгечләргә баедык, кадерлем, а? Синең кебек кыю егетләр кирәкми, күрәсең, безнең яңа җитәкчеләргә?

— Ну, җитәкчеләргә кирәктерме-юктырмы, ләкин илдә кирәк без. Бу точно, Григор. Җитәкчеләр алар килә дә китә, ә без, эш кешеләре, калабыз.

— Ну бит, слушай, сине язмыш дигән нәрсә болай да хаксызга рәнҗетте. Сиңа Карамусаев шакал булып ябырылды. Слушай-кадерлем.

Ләкин аның соңгы сүзләрен Фидаяров ишетеп бетермәде. Аны тагын шыксыз хәлсезлек били башлады. Ул әле: «Шулай да, Карапетян, мин үземнең язмыш-йолдызымны башка бер генә кешенекенә

дә алыштырмыйм. Нинди генә зур урыннар, нинди генә данлыклы бүләкләргә төреп китерсәләр дә, миңа кеше йолдызы кирәкми, миңа үз йолдызым булсын... Карапетян»,— дип уйларга өлгерде ул.



4

Яшеренгән куе болытлар Кама ягыннан килэләр дә, Калатау белән Текәтау арасындагы үзәнлектә җәйрәп яткан Көмеш Аланның тугыз катлы яңа йортларына тия язып, ары таба узып китәләр иде. Алар атом электр станциясе корылачак Түбән мәйданда инде калкып-калкып чыккан, металл конструкцияләрдән торгызылган корылмаларны урап-урап узалар. Ә биредә, шушы «җәһәннәм оясын» төзүчеләр һәм анда эшләүчеләр яшәячәк яңа каланың беренче йортлары арасындагы асфальт мәйданчыкларда, бигрәк тә мәктәп бинасы алдындагы тигезлектә яңарак кына явып узган көчле яңгыр хасил иткән күлдәвекләр елтырашып ята. Багана төпләрендәге үләннәр һәм мәктәп ишегалдындагы чәчәк түтәлләренә озынча лампалардан төшкән яктылыкта көмеш тамчылар җемелдәшеп куя. Яңгыр вакытында качып калган, әмма аннан соң кичектергесез йомышлары белән сәяхәткә чыккан чыпчыклар, адәм заты якынлашып килгәнне тоеп, пырхылдашып очып-очып китәләр.

Баярак яңгыр болытлары килгән Кама ягыннан салкынча җил исә.

Мәктәп ишегалдын уратып алган тимерчыбык челтәр янәшәсеннән барган асфальт сукмак кинәт өзелде. Аяк астында ничәмә-ничә тапкыр казып урыныннан кузгатылган кызгылт балчык пычрагы чупылдый башлады. Монда инде багана башындагы лампаларның яктысы килеп җитми, шуңа күрә сукмактан баруы читенрәк. Аяклар әледән-әле сукмак читендәге көпшәкләнгән җиргә басалар. Анда баскан саен туфлиләргә өем-өем балчык ябышып өлгерә һәм алардан арынып өчен аякларны селеккәләп алырга туры килә. Бу хәл болай да караңгы чырайлы Тынчуринның йөзен тагын да караңгырак итә, ачуын чыгара, һәм җирдәге пычрак өстенә авызыннан сибелгән пычрак сүзләрне дә ташлата иде. Бәхеткә каршы, бу хәл озакка бармады, ялтыравык сукмак тугыз катлы йорт бинасы нигезенә ябыштырып салынган асфальт тасмасына килеп терәлде. Бәхетсезлеккә каршы, моңа хәтле узган кешеләр асфальт тасмасына юеш пычракны байтак күчергән булып чыкты, шуңа күрә анда басуга туфлиләр таеп китте һәм Тынчурин, «Һе-еек» дигән тавыш чыгарырга өлгереп, кулларын як-якка җәйгән килеш, кираркан әйләнеп төште. Кулындагы дипломаты ике-өч адым арырак очып җиргә бәрелде һәм ачылып китте.

Бу очраклык Сәйдәр Тынчуринның түземлеген тәмам чыгырыннан ук чыгарды. «Бөтен дөньясы миңа каршы бит аның,— дип сүгенде ул, таянып урын эзли-эзли.— Аннары аэропортка килүче автобус Түбәньяр борылышына туктамыйча узып китте. Инде, ничек җитте шулай кайтып җиттем дигәндә генә, үзле балчык пычрагына чукынып төштем. Юньлегә түгел бу, мөгаен, юньлегә түгел».

Нишләмәк кирәк, салкын җирдә ятып булмый. Тынчурин үрмәләп торды, дипломатыннан сибелгән әйберләрне яңадан тутырды һәм ишегалды ягына чыкты...

Ишек төбендә янып торган тоныкут яктысында Тынчурин сәгатенә күз төшереп алды. Төнге ике тулып узган иде. «Димәк, озаклямый яктыра башлаячак. Ни котә мине монда? Нигә дип мин монда кайттым? Хәзер мин монда кем? Минем Чернобыльдән кимонда кайттым? Хәзер мин монда кем? Минем Чернобыльдән китерәтүемне Фидаяров хәбәр иткәндер инде. Бу бит аңа файда китерәчәк.— Фидаяров исенә төшүгә, ул теш арасыннан гына «черт» иттетүемне Фидаяров хәбәр иткәндер инде. Бу бит аңа файда китерәчәк.— Фидаяров исенә төшүгә, ул теш арасыннан гына «черт» итте-

реп төкереп куйды.— Каян гына минем башка кайтып төште соң ул? Ничек кенә соң мин ул төрмә калдыгына шундый йомшаклык күрсәттем. Кара инде син аны, бернинди документсыз, нибары белешмә кисәге белән эшкә урнаштырдым. Үзем үк, кем икәнлеген белә торып, өемә алып кайттым. Әмма ишәкнең түшәк кадерен беләсе бармы? Тормышында бернәрсәгә дә ирешә алмаган көндәшем алдында мактанам, имеш. Көчемне күрсәтәм, тормышымның муллыгы, урынымның зурлыгы белән горурланам, имеш. Эх, җүләр баш, җүләр баш! Шуның аркасында бөтен тынычлыгымны җуйдым, ышанычымны югалттым. Ну!— дип тагын «черт»ләтеп төкерде Сәйдәр.— Ә хәзер нәрсә? Ничек соң мин, бөтен түземлегемне югалтып, йөрәккә кереп урнашкан куркуымны тыялмадым? Хәер, тыеп булырлыкмы соң анда? Ничәмә-ничә кешене больницага озаттылар бит. Барысы да боламык кебек изрәп төшкән.— Бу юлы инде Сәйдәр Тынчуринның чырае бераз ачыла төште.— Чынлап та, әгәр дә мәгәр анда калган булсам. Каһәрләнгән зонага эшкә кертәселәрен көт тә тор иде. Аннан нинди хәлдә чыгасы билгеле түгел әле. Аларның пропагандасына ышансаң.. Әнә бит, һәлакәт булганнан соң чыккан газеталарны укып кара син. Ал да гөл. Ә чынында ни күрдең? Үз күзләрең белән күрдең бит. Геройлар! Барысы да яхшы, бөтен нәрсә ал да гөл. Ә чынлыкта исә андагы хәлләр, туганкаем; ярый әле кайтып китәргә башым җитте. Хәер, «запасым» да бетте. Анда минем җаным да, тәнем дә авырта башлады. Миңа Мәскәүгә барырга кирәк иде. Дөрес, Наташа аны бу юлы инде үз оясына кертүен кертмәде. Ну, черт с ней. Минем әнә берәүгә дә алыштырмаслык Динәм бар. Иясенә күрә биясе, ул мине көтә-көтә көтек булып беткәндер инде. Ул мине теләсә нинди хәлемдә дә кабул итә. Ул теге киребеткән Фирәзә дә түгел».

Фирәзәсе искә төшкәч, аның инде үз хатыны түгеллеген белсә дә — алар май бәйрәменнән соң никахларын өзделәр,— Сәйдәрнең йөрәге кысылып-кысылып куйды, ни генә әйтсәң дә, иренең әнә шундый үргә күтәрелүендә Фирәзәнең дә тырышлыгы юк түгел иде. Ул аның ихтыярсыз башын бәйдә тотып килде. Алай гына да түгел, тормыш юлына алып чыккан сукмакларны, анда очрый торган кыенлыкларны аның белән киңәшеп узганда Сәйдәр Тынчурин ышанычлы атлап барды. Тормышларының шулай килделе-киттелегә әйләнүенә бер нәрсә — бала булмау гаепле. Әтисе һәрдаим: «Балалы йорт ул, улым, базарын базар, тик баласыз йорт — кабер», дип бер дә юкка сөйләнмәгән икән шул.

Шушы уйлар Сәйдәр Тынчуринны камчылап куалады, подъезд ишеген ачып керергә, аннары тиз-тиз атлап баскычтан күтәрелергә мәҗбүр итте. Бирегә яңгырдан соң җиргә төшкән салкынча юеш һава кереп җитешмәгән диярлек: баскыч басмалары коры иде. «Биредә җәйге көннең бөркү сулышы сакланган»,— дип уйлап алды Сәйдәр, Динә ишегенә якынлашкан саен күңеленең күтәрелә баруын тоеп. Ул хәтта иреннәрен бөрештереп ишетелер-ишетелмәс кенә сызгыргалап та куйды. Пинжәк кесәсеннән ачкычлар алды, дипломатын ишек төбенә куйды һәм кирәклесен бармаклары белән капшап табып алды, ачкычын йозак тишегенә кертте. Ишетелер-ишетелмәс кенә «шырт» иткән тавыш ишетелде. Сәйдәрнең баягы күтәренкелеге иң югары чиккә җитте. Ул, дулкынлануын тыярга тырышып, тавышсыз ачылган ишектән эчкә атлады.

Атлавын атлап керде Сәйдәр, әмма шул ук мизгелдә аның күкрәк эчендә, шикле шикләнер, кара чикмәнен бөркәнер, дигәндәй, әллә нинди шомлы калтырану барлыкка килде. Ул нишләптер ут кабызгычның шнур очын таба алмый капшанып торды, аннары тартып җиткермәде, шунлыктан коридорда ут кабынмыйча торды. Ниһаять, Сәйдәр шнурны бармагына урап, ачу белән ныграк итеп

тартты. Ут кабынып китүен китте, әмма шнур кисәге бармагында уралган килеш өзелеп калды.

Сәйдәр җиңел курткасын эләргә үрелмәкче иде, шулвакыт күз карашы аяк киемнәре куя торган тартма янында торган ир-ат ботинкасына терәлеп калды... Шулай да ул моңа әллә ни игътибар биреп җиткермәде әле. Үзенең пычрак туфлиләрен алар янына куеп, ванна ягына таба атлады. Ләкин зал ишегеннән:

— Бу ни хәл? Нигә кеше квартирына рөхсәтсез кереп барасыз? Безобразие!— дигән сүзләрне ишетте. Бу Динәнең йокылы-уяулы тавышы иде. Сәйдәр аякларының юнәлешен үзгәртте һәм Динә тавышы килгән якка таба борылды.

— Бу мин,— диде нигәдер үзалдына тотлыгыбрак Сәйдәр.— Бу бит мин — Сәйдәрең, Динәкәй, мин бу.

Сәйдәрнең күзләре Динәгә төбәлде. Бүлмә эңгер-меңгерендә чамалады ул: Динә анадан тума килеш чыгып баскан иде. Аның чәчләре тузгып җилкәләренә төшкән, үзеннән күңелне кытыклый торган әллә нинди җылы хуш исләр бөркелә иде. Сәйдәр моны, чынбарлыкта тоюдан битәр, элек хәтеренә сеңеп калганга чамалады. Ул үзенең куллары, өс-башы пычрак икәнлеген онытып, Динәгә таба атлады.

— Динәкәй... мин... мин сине сагынып кайттым. Ә син ничектер сәер каршылыйсың,— диде һәм Динәне кочакларга үрелә башлады.

«Шоңкар юкта ябалак мәйдан тотар»,— ди халык. Шуны раслагандай:

— Эт-то еще что такое?— дигән ят, куркыныч һәм шуңа күрә түшәмнән ишетелгән сыман тавыш сискәндереп җибәрде. Сәйдәрнең Динәгә үрелгән куллары, ярты юлда тукталып, хәрәкәтсез калдылар.— Кем бу һәм ни кирәк сезгә монда?— дип өстәде йокы бүлмәсеннән Сәйдәрнең үз халатын кия-кия якынаеп килгән берәү. Дөрес, ул залга ук чыгып басмады, башта ишек катында туктап, яшькелт-күгелҗем абажурлы лампаны кабызды.

Баягы тавыштан арынып бетмәгән Сәйдәр, әгәр дә мәгәр шушы минутта идән плитәләре шартлап икегә ярылса, ул шушы упкынга чумса, яки тагын берәр тузга язмаган шундый куркыныч нәрсә килеп чыкса, болай ук тораташка әверелмәгән, тын алырга көч табалмыйча тормаган булыр иде, әлбәттә. Әмма моннан ике атна элек кенә үзе чыгып киткән йокы бүлмәсеннән, үзе салып калдырган кыйммәтле халатны ябынып зал бүлмәсеннән чыгып килгән кешене таныгач та... Әйе, һич кенә дә шик юк: бу — күптән түгел генә Көмеш Алан поселок Советы рәисе итеп сайланган Шаров үзе иде.

— Поз-воль-те... Ни бу? Кем бу?— диде, ниһаять, бераз телгә килә башлаган Тынчурин.— Ни бу дим, Динә? Аңлатып бирерсең, бәлки?

— Ха,— диде әле дә булса йокы бүлмәсе бусагасында басып торган шәүлә-Шаров.— Башыңа ат типкәнме әллә? Аңламыйсыңмы? Ану-ка, да-вай!.. Ачык ишеккә кем дә керә аны. Әмма әүвәл кергәннең хакы күбрәк була. Понял?

Бусы инде артыграк иде. Бусы инде бөтенләй тузга язмаган һәм дөньяда күрелмәгән кабахәтлек иде. Аю Хәлил малае Тынчурин өчен чамадан ашкан нәрсә иде. Һәм бу хәл аның нәселдән-нәселгә күчеп тамырларында яткан кан бабасына Аю кушаматы бирдергән кыюлыкны хәрәкәткә китерде. Икенче секундта ул инде Динәне кочакларга үрелгәч тә сузылып калган кулларын Шаров ягына таба борды. Аяклары үзеннән үзе шул якка таба атлады. Сәйдәр ишекне томалап диярлек торган Шаров-халатны ике яклап бөтереп алды, тавышсыз гына урта бүлмәдән коридорга этеп чыгарды. Артта бүленеп калган Динәнең: «Ah!.. Син нишлисең?»— диюе аңа яңа көч өстәде. Сәйдәр халат якасының бер ягын җибәрде, икенче ягын тоткан килеш Шаровны зырылдатып әйләндереп кием эченнән чыгарды. Шул арада ул ишекне тибеп ачарга өлгерде. Аннары кулларын болгаштырып кары-

шырга маташучы Шаровны баскыч мәйданчыгына томырды. Шундук аның аркасына Динә атылып килеп бәрелде. Ләкин Сәйдәр аягында нык, моңарчы беркайчан да булмаганча нык басып тора иде. Динә бәрелүдән ул хәтта селкенмәде дә, ашыкмыйча гына ишекне япты, инглиз йозагының бикләгеч телен төшерде. Хәтта ишекнең өстәмә биге-чылбырны оясына ташларга да онытмады. Шуннан соң гына, артына борылып, сул кулының бармаклары белән Динәнең чәч төбеннән үк тотып алды. Шаровны алып чыккандагы кебек үк йокы бүлмәсенә өстерәп керде. Нибары бер мизгел арасында гына Динәнең күкрәгеннән «А-а-һ» дигән аваз чыкты, ләкин ярты юлда өзелеп калды. Шундук Сәйдәрнең саллы йодрыгы Динәнең муен тамырына коточкыч көч белән килеп кунды. Бу юлы Динәдән ни бер тавыш чыкмады, ул тиз арада йомшарып калды. Сәйдәр моны сизмәде, Динәнең чәч тамырларыннан тоткан килеш, үзенә таба әйләндерде. Баягыдан да яманрак көч белән ике атна элек кенә үзе сыенып яткан күкрәк йомырылары арасына китереп сукты.

Яхшымы-яманмы, ләкин озын гомер кичкән әтиең сиңа: «Казанга янтайсаң — карасы йогар, яманга янтайсаң — бәласе йогар»,— дип юкка гына әйтми иде бит.

Эх, Сәйдәр, Сәйдәр...

Кешенең һәлакәт чокырына төшә башлавы кайчан һәм нинди мизгелдән башлана соң?

Ни өчен тормышта сизелерлек үрләр яулаган, ярты гомерен җитәкче буларак кеше арасында уздырган берәү көннәрнең берендә ерткыч җанварга әверелә дә куя?

Моның сәбәбе кайда, нинди генә серле сандыкта яшеренгән ул?

Яралы ерткыч булып ташланырга, кызгану-шәфкать дигән төшенчәләрдән бөтенләй-бөтенләй ваз кичәргә нәрсә мәҗбүр итә кешене?

Көнләшүме?

Кешеләргә нәфрәтме?

Мин-минлекнең чиктән тыш кабарган куыгымы?

Нәрсә???

## 5

Нәкъ шушы фаҗигале минутларның берсендә томанлы һәм борчулы шомлану Фирәзәне татлы йокысыннан уятты. Алай гына да түгел, аның йөрәге дөпе-дөпе сикеренә, чәнчеп-чәнчеп алгалый иде. Бу хәл хатынны куркытып җибәрде.

«Ни булды икән соң, ходаем,— дип, ул карынында яралып яткан җан иясен исенә төшерде.— Ул-бу булмагае... Нишләргә икән соң?— Бу уй Фирәзәне айнытып җибәрде.— Юләр, и-и, юләр дә соң инде мин. Аңа нәрсә булсын, мин исән-сау, сәламәтлегемә зарланмыйм». Теге көнне трест бинасы янында таныш булмаган хатын белән бәрелешкәннән соң, аның кем икәнлеген белгәч, Фирәзәнең йөрәге чәнчеп-чәнчеп алды алуын. Өстенә карчыга сыман очып ташланган Нәркизәне — Искәндәрнең хатынын — шушы хәлдә күрү әрнетте аны. Ләкин андый гына борчылу хатын-кызда булгалап тора инде ул. Ярый әле Шәрифуллин агай, араларына килеп кереп, Фирәзәне ашханәдәге бүлмәсенә озатып куйды. Аннары инде Фирәзә, көтмәгән-уйламаган төштән машина алып, Чаллыярга балык заводына кайтып китте. Чөнки Нәркизә белән тагын да очрашулары ихтимал иде. Урам уртасында басып, бөтен кешегә дә үзенең гаепсез икәнлеген аңлатып тормассың бит инде.

Фирәзә йокысыннан тәмам арынды, урынына торып утырды. Одеялы идәнгә шуып төшкән иде, тик Фирәзә моны тоймады, күз-

ләрен төн караңгылыгына төбәп утыра бирде.

Ул урыныннан торды, капшанып кына йомшак башмакларын эзләп тапты һәм шул чагында ишек төбендә кеше барлыгын тоеп алды. Аның йөрәге атылып чыгардай булып тибенде, тез буыннары калтыранды һәм ул, төнге күлмәктән килеш, бүлмә уртасына чыгып басты.

Әллә нинди эчке бер көч аны ишек төбенә үк китерде. Ул колак салып тыңлап торды һәм, анда кем барлыгын инде төгәл белгән килеш, ирексездән йозак ачкычын борды. Ишек шыгырдабрак ачылды.

Чынлап та Сәйдәр иде анда.

Фирәзә ирексездән куллары белән битен каплап артка чигенде.

Ишек төбендә яртылаш шәрә, пычракка һәм канга буялып беткән Сәйдәр башын күтәрде...

— Фир-рәзә,— диде Сәйдәр,— Фир-рә-зә... мин... мин... ке-е-еше үт... үт-үтердем... Ди-и-инәне...

Фирәзәнең күргәне бар иде Сәйдәрнең чучка баласы хәленә төшеп пычракта аунаган, исергән чакларын. Мондый хәл бергә яшәгән дәверләрендә икеме, өчме мәртәбә булды. Аны берәү дә белмәде. Хәзер дә Сәйдәр лаякыл исерек иде.

Фирәзә кулларын битеннән аерып алды һәм ишек төбендә кызганычның кызганычына әйләнгән Сәйдәргә ни әйтергә белмәде. Әмма аның йөрәге «дерт» итеп куйды. Ни генә әйтсәң дә... алар бит чирек гасырга якын бергә яшәделәр, бер урында йоклап, бер табактан ашадылар, бер һаваны суладылар, бердәмлеккә омтылган минутлары да аз булмады.

— Кит аннан?— диде Фирәзә, ниһаять, телгә килеп.— Ничек? Үт-үт-ердең? Чынлапмы?

Фирәзә тиз генә җылы халатын алып киде. Ләкин аның калтырануы болай гына бетәрлек түгел иде. Киресенчә, хәзер инде аның теше тешкә бәрелеп-бәрелеп ала, чатлама суыкта кышкы урамга чыгарып ташланган көчек сыман шыңшыйсы килә иде.

Ниһаять, әле генә Сәйдәр авызыннан чыккан сүзләрнең мәгънәсенә төшенеп җитте Фирәзә.

«Булыр, синнән булыр. Андый эшкә сәләтле идең син. Мине дә... теге вакытта... Синең күзләреңдәге нәфрәтне күргән саен куырылып-куырылып куя идем»,— дип уйлап алды Фирәзә һәм, ихтыяри көч белән калтыравын басарга тырышып, ишек куышында басып торган Сәйдәргә кычкырды:

— Кабахәт! Син!.. Син!— Ул бугазыннан чыккан сүзләргә буылып торды.— Шундый эшеңнән соң ничек итеп минем ишегем төбенә килергә батырчылык иттең? Син... син!..

Фирәзәнең сүз запасы бетте, аның теле дә әйләнерлек түгел иде. Ирексездән нәрсәдер әйтергә тырышып авызын ачса да, аңардан әллә нинди ыңгырашу, мәгънәсез авазлардан башка нәрсә чыкмый иде.

Ә ишек төбендә Сәйдәр исә:

— Фирәзә... мин... син мине коткар. Син бит мине гел коткара идең. Мине төрмәгә утыртма, яме? Минем... минем яшисем килә. Коткар, яме,— дип пышылдый, аның күзләреннән яшь ага, авыз читләре төкерек-күбеккә манчыла бара иде.

6

Искәндәр бу якларның табигатен, бигрәк тә латыш халкының табигатькә, гомумән, безнең якларда вак-төяккә саналган нәрсәләргә — җирдә аунап яткан ташларга, сынган агач ботакларына, агач тамырларына мәхәббәт белән карауларын килгән көннәрдән үк яратты. Элек аңа ничектер бу якларга килергә юл чыкмаган иде.

Белмәгәч-күрмәгәч, нишлисең, килергә теләге дә булмагандыр инде. Ә бит бик кызганыч, мондагы яшәү рәвешен, кешеләрнең бер-берсенә, табигатькә, тарихка, үз гореф-гадәтләренә, борынгы биналарга, риваятьләргә мөнәсәбәтен күрмәү-белмәүдән бик күп нәрсә югалтабыз. Без, татарлар, мондый бай үрнәкне байтак кына туплар идек монда.

Чынлап та, гаҗәеп киң күңелле, әкият-риваятьләргә бала сыман табыну яши биредә. Һәр нәрсәгә: тауга-үзәнгә, елга-ерганакка, чокыр-чакырга исем биреп, алай гына да түгел, һәр нәрсәнең үзенә матур-матур риваять-әкият уйлап чыгаралар. Иң гаҗәбе шунда: үзләре үк шушы әкиятләргә ышанып, алар турында җанлы нәрсә кебек итеп сөйләшәләр, күз карасы кебек кадерләп саклыйлар.

Кичә Искәндәр төшке аштан соң Сигулды үзәнлегендәге тау куышына барып чыкты. Болай караганда бер генә ис китәрлек нәрсәсе дә юк шикелле. Безнең һәрнәрсәгә битарафланган, тауга — таш өеме, куышка — тау тишеге, агачка — утын, дип карарга күнеккән күңелләргә генә шулай икән бит ул. Шул ук куышны алыйк, андагы чишмәне алыйк. Үзенә күрә тарихы-риваяте бар. Имеш, хәзер Искәндәр ял итә торган санаторийның төп бинасын зур бер граф сөекле кызына салып биргән. Ул бина бик борынгы, хәзер әнә биек-биек диварлары гына тырпаешып торган, 1220 елларда салынган замок хәрабәләреннән алынган кирпечтән төзелгән. Имеш, кайчандыр әнә шушы замокның хуҗасы сугышларда озак йөргән бер вакытта моның яшь хатыны, ялгызлык газабына түзә алмыйча, моңа хыянәт иткән. Ул кайткач, берәү эшне хуҗага җиткергән. Хуҗа исә, моңа бик нык ачуланып, үз намусына тап төшерүне күтәрә алмыйча, яшь хатынын менә шушы тау олтанына чокыр казытып терелэй күмеп калдырган, имеш. Терелэй күмелгән хатын ачынып-ачынып елаган-елаган, аның күз яшьләре тау олтанындагы чокыр-каберне тишеп-бәреп чыккан, имеш. Шуның күз яшьләре әле һаман да чишмә булып чыга, имеш. Аның суы кышын да, җәен дә бер үк температураны саклый икән. Тагын шунысы хак: хәзерге ир-егетләр, хатыннары хыянәт итмәсен өчен, шушы чишмәдә битләрен юып китәләр ди, имеш...

Менә бит гап-гади тау куышына карата нинди матур риваять уйлап чыгарганнар. Ә бит шушы риваятькә кешеләрнең ышанасы килә. Бу безнең битарафланган күңелебезне табигатькә якынайта, эш-шөгыль, уй-тойгыларга шифа сибеп тора.

Риваятьне бер латыш карты сөйләде. Һәм Искәндәрнең күңел биреп тыңлавын күргәч: «Әгәр дә мәгәр ошаса, иртәгә кичкырын менә шушы күперчек өстендә очрашырбыз. Мин сезгә Турайд Розасы һәлак булган чишмә һәм тау куышын гына түгел, ул Розаның каберен дә күрсәтермен. Бер уңайдан андагы таш сыннар күргәзмәсен һәм Турайд замогының яңартып торгызылган кадәресен дә күрсәтермен, яңа легендалар да сөйләрмен»,— диде.

Искәндәрнең уйлары әллә кайларга китте, табигать һәм яшәеш турындагы уйларга барып тоташты.

Күз алдына АЭС төзелешендәге вакыйга, реактор чокыры уңаеннан туздырылган авылның ялгызак агае белән булган вакыйга аерымачык килеп басты. Ул агайны кемнәр генә сүкмәде дә, нинди генә ялган-уйдырма вәгъдәләр белән чокыр уртасында япа-ялгыз тырпаеп калган өеннән чыгарырга тырышмады. Ә ул чыкмады, ата-бабалары утырган нигезне ташларга теләмәде. Кем белсен, бәлки ул алай гына уйламагандыр... Бәлки ул агай бүтән авылдашлары бөтен уңайлыклары булган таш тартмаларга барып кергән чагында үз авылының туздырылуына, ата-бабасы нигезен кемнәр тарафыннандыр мәсхәрәләнүенә, ата-баба кадеренең актарылуына, атом дигән гыйфрит оялауга каршы протест белдергәндер?

Шулвакыт Искәндәр туктап калды. Аның башына беренче тапкыр: ә нигә кирәк соң ул Илләргә, Җиргә, халыкларга үлем газабы белән янаучы атом станцияләре? Нигә кирәк? Алардан башка да ничәмә-ничә гасырлар яшәгәннәр ич? Үлем чәчүче Гыйфрит ничек инде прогресс булсын икән? Ә бәлки әле без ул атом-гыйфритен хәвефсез итеп файдалы эшкә җигәрлек аң югарылыгына ирешмәгәнбездер? Бездәге җавапсызлык, битарафлык әнә нинди олы һәлакәткә китерде. Фәлән кеше генә үлде дип үз-үзебезне тынычландырырга тырышабыз да бит, ләкин бу нәрсә Искәндәр күргәннәрдән бик ерак, хаклыкка туры килмәслек ерак. Нәрсә бу? Битарафлыкмы? Әллә? Искәндәр җавап эзләде. Әгәр дә һәлакәтнең бөтен зурлыгын, ул китергән бәла-казаларны бары тик утыз чакрым әйләнәсендәге җирләргә генә кайтарып калдырырга тырышу аңлы рәвештә, югарыдагы җитәкчеләрнең хуплавына таянып эшләнсә?..

Искәндәр кесәсеннән кулъяулыгын алды да маңгаена бәреп чыккан салкын тир тамчыларын тырышып-тырышып сөртергә кереште. Ул, үз-үзен тыеп, фикерләвен каршылыксыз юнәлешкә кертеп җибәрмәкче иде. Ләкин кая инде ул бер җирдән эз салып ага башлаган чишмәне туктату? Киресенчә, Искәндәрнең фикер агышы үзе күреп белгән нәрсәләрне, аңында яткан дәлилләрне берәм-берәм тартып чыгарырга кереште һәм, ниһаять, беренче нәтиҗәне ясады: халыкның соңгы елларда хезмәткә битараф каравы, һәркайда тантана кылып килгән гаделсезлек, кеше хокукларын тартып алу илне беркайчан да күрелмәгән җавапсызлыкка, хуҗасызлыкка китереп терәде. Югыйсә, атом-төш реакторына Чернобыльдәгечә мөнәсәбәткә юл куюны ничек дип әйтергә? Һәлакәт булганнан соң берсеннәнберсе югарырак урыннарга бары тик эшәкелек аркасында гына үрмәләп менгән булыр-булмас кешеләрнең сәләтсезлеге, ихтыярсызлыгы, куркынычны яшерергә омтылу, халыкка, илгә күрәләтә ялган хәбәр бирүне җинаять димичә, ни дип әйтергә мөмкин?

Ә үзебез яшәгән табигатькә мөнәсәбәт, аны ерткычларча туздыру, күрәләтә агулауны, суларга һава булмаган шәһәрләрдә халыкны алдап-йолдап тагын, тагын, тагын яңа химия гигантлары торгызуны ничек бәяләргә?

Умарта күче сыман гөжелдәгән бу уйлар-сораулардан Искәндәрнең җәһәннәм нурларында коенып алган һәм әле ныгып җитмәгән тәне искиткеч хәлсезлек тойды. Иң мөһиме, Фидаяровның күкрәгендә типкән йөрәккә, баш миендәге фикерләү җисеменә, маңгаеннан дөньяга карап торган күзләренә әллә нәрсә булды. Аларның тирәюньдә, илдә, җирдә булган нәрсәләргә борчу-аптыраулы карашлары ачылып киткәндәй булды.

— Юк, болай ярамый,— диде, ниһаять, Искәндәр үз-үзен кулга алып.— Болай тиктомалдан бөтен нәрсәне дегет янәшәсенә салып бутарга ярамый. Уйларга, өйрәнергә, асылына төшенергә кирәк бу сорауларның...

Фидаяров, үзәнлектәге һәрнәрсәгә — каштан агачларына, алар белән кочакланышып утырган таныш һәм күңелгә аерата якын каеннарга, аз гына арырак «Без дә монда синең кебек ял итәргә килеп адаштык», диешкәндәй моңаешып утырган биш-алты усакка, үзе белмәгән-танымаган чәчәкләргә яңача карый-карый тигез асфальт сукмактан атлый бирде.

Ул инде хәзер һәлакәт булган җирдән еракта, Гарәбә диңгез янындагы оҗмах-бакчада сәламәтлеген ныгыта.

Ә егетләр, аның егетләре, аждаһа тирәсендә эшләгәннән соң тиешле дәвалауны узып, Көмеш Аланга кайтып эшкә керешкәннәрдер. Алар искә төшкәч, Искәндәр шатланып куйды. Егетләрне илкүләм, хәтта дөньякүләм бәхетсезлек аерата нык чыныктырды, беректерде. Хәзер инде Револь кебек җилбәзәк кеше дә, башына ат типмәгән

булса, яшәү мәгънәсе турында уйланыр. Ә бит чынлыкта Револь назлы сөяк булып үсүенә карамастан, ярыйсы ук нык егет булып чыкты. Дөрес, теле аның фикереннән алданрак йөгерә, әмма бу кимчелектән арыныр ул. Егеткә ярдәм кирәк, яшәүнең мәгънәсен аңларга юнәлеш кирәк. Элегрәк Искәндәр Ватан сугышы ветераннарының бердәмлегенә, дивизияләре, армияләре, фронт командующийлары аша уртаклык табулары, үзләре гомергә бер тапкыр күрмәгән кешеләрне арадашчы итеп бер-берсенең күңеленә юл ачуларына беркадәр гаҗәпләнеп карый һәм: «Болар ихластан түгелдер»,— дип уйлаштыргалый иде. Хәзер инде ул белә: уртак кайгы, бергәбергә кичергән сынаулар кешене якынайта, туганлаштыра, аларның дуслыгын гомер-гомергә җитәрлек итә.

Чернобыльдә нибары атна-ун көн бергә эшләгән кешеләр дә әнә гомерлек туганга әверелделәр. Искәндәр шифаханәдә яткан арада гына да Илдар, Остап, Револь ничә тапкыр килеп киттеләр. Хәзер инде Искәндәргә алардан да якын кеше юк сыман. Ярый, алар инде Искәндәр белән бергә килгән, аның кулы астында эшләгән кешеләр, ди. Ә бит аның янына бөтенләй таныш булмаган кешеләр дә килде, үзләренең канын бирде.

Әйе, Фидаяров туган, утыз көн уразаның бер бәйрәме булмыйча калмый, синең тирәңдә һәрвакыт яхшы кешеләр яшәде. Син шулар белән бергә үстең. Шуларга таянып кеше булдың. Дөрес, алар белән бер эздән йөргән бәндәләр сине БАМга, тайга урманнарын кисәргә җибәрде. Анысы инде аның кеше гомеренә сирәк очрый торган хәл... Алары булмаса, яхшы кешеләрнең барлыгын кайдан белер идең?

Кинәт Искәндәр шатлыгыннан авызын ерып, көлеп җибәрде. «Ничек соң әле мин онытып торам»,— диде ул һәм чыгып киткәндә генә пинжәгенең эчке кесәсенә яшергән, Чернобыльгә адресланган, әмма, рәхмәт төшкере, Карапетян монда юллаган хатларны алды.

Аларның берсе — Фирәзәдән, икенчесе партия контроле комитетыннан иде.

Искәндәр Фирәзә хатын ачмакчы, иң әүвәл аны укымакчы иде, ләкин нәрсәдер аның кулыннан тотты шикелле. Ул ирексездән Фирәзәнең хатын аска куеп, партия контроле комитетыннан килгән рәсми хатны өскә чыгарды. Аны әйләндереп-тулгандырып карады. Әйтерсең, ул хатның конвертында ук мөһим, гаять кирәкле сүзләр язылгандыр да, Искәндәр аларны күрмичә-укымыйча калырга тиеш түгел иде. Кирәк бит... Дүрт ел буена БАМ ягының иксез-чиксез урманнарын кискән чакта ничек зарыгып көтте бит ул шул хат кисәген. Ә бит ул чагында... Ул чагында япа-ялгызы калып, бер җылы сүзгә мохтаҗ иде. Әгәр дә мәгәр ул чагында килгән булса иде шушы хат! Нахак яла үзенең хыянәтен танып гафу үтенгән булса... Искәндәр белә, ул, һичшиксез, яла ягучыларны гафу иткән һәм алар янына кайткан булыр иде. Әмма аның урынына БАМ тайгасындагы зонага хатыны Нәркизәнең никахтан ваз кичү турындагы рәнҗетүле язуы гына килде. Искәндәрнең җаны телгәләнмәдеме соң ул чагында? Әле ничек, ничек кенә телгәләнде. Ул нәрсәләр күңелгә чуерташ булып утырган инде. Бәхеткә каршы, гомерлек түгел икән ул юшкын. Армиядәге командиры: «Чуерташ булып оешкан кайгыны вакыт дигән нәрсә тарттырып он итә аны»,— дип әйтә торган иде шул.

Искәндәр, күңел түрендәге бер кылның тартылып-тартылып куюына карамастан, партия контроле комитетыннан килгән хатны укымаска, соңгарак калдырып торырга булды.

Тагын бераз хатка карап торды да, кискен хәрәкәтләр белән Гәрәбә диңгезгә таба ашкынучы Гауя елгасы аша салынган күпер такталарын сыгылдырып, урта бер җиргә кереп басты, суга төбәлеп тора башлады.

Агымсу! Әй, агымсу, дәртле, сафлык-чисталыкка омтылучы агым-

су! Син һәрвакыт җитез, кыю һәм төрле хөсетлекләрдән өстен, мәрхәмәтле. Күр әле, сиңа нинди генә кирәкмәс нәрсәләрне ташлыйлар? Ләкин син алардан арыну серен беләсең. Син аларны ерак-еракларга алып китәсең, әллә нинди фильтрлар аша уздырасың, юасың, төбендәге төпкелләргә, чокыр-чакырларга тутырасың, үз-үзеңне һаман шулай сафландырасың. Кеше заты да шулай бит! Аны да нинди генә нахак ялаларга салып, нинди генә әшәкелекләргә коендырсалар да, ул барыбер үз йөрәгенең чисталыгын, гаделлеген, вөҗданының пакьлеген саклау юлларын таба. Һәрхәлдә, туктаусыз шуңа омтыла. Искәндәр белә: кеше җанын сафландырып торучы нәрсәләрнең берсе — мәхәббәт тойгылары, аның бернинди нахакларга да бирешми торган көчләре...

Искәндәр кулындагы икенче хатны ачты.

«Искәндәр! Искәндәрем — Киребеткәнем минем!— дип башлана иде Фирәзә хаты.— Югалган яшьлегем, табылган мәхәббәтем минем. Киткәнеңнән бирле ни гомер узды инде. Ник бер хат кисәге килсен? Йокларга ятсам, күзләремә йокы керми, табынга утырсам, тамагымнан ризык үтми. Сиңа сөйлисе сүзләрем, әйтәсе серләрем Урал таулары хәтле... Нигә язмыйсың? Беләм, беләм инде, вакытың юктыр. Аннары бит син больницада ятасың ди, имеш. Ә минем нинди хәлдә икәнлегемне уйлап карамадыңмы син? Бәлки, бәлки инде син минем барлыгымны да оныткансыңдыр? Ярый, ярый, иркә кайда — юләр шунда дигәндәй, бераз иркәләнүем генә бу. Онытмаганыңны, һушларыңнан язып больницада ятканыңны, барысын да беләм мин, Искәндәр, беләм. Сез киткәннән бирле ниндидер кайгы талады йөрәгемне... Анда булган егетләрең дә берәм-берәм больницада ятып чыкканнар икән. Алар инде эшләренә керештеләр. Син аларга сөйләмәскә кушкансың, ләкин, гафу ит, Илдарның телен ачтырдым. Остап белән Революң икесе беравыздан: «Бар да әйбәт, Фирәзә апа, әйбәт. Ул анда әллә нинди тәкъдимнәр белән йөри, шуңа гына калды»,— дигән булалар, азаматлар.

Искәндәр! Сиңа языйммы-юкмыдыр, төгәл генә белмим, бәлки сине борчуга салырмын. Ләкин инде бездәгеләрнең барысы да белгән, ничәмә-ничә көн телләреннән төшермәгән коточкыч бер хәлне сөйлим, әй-лә, язам мин сиңа... Иә, ходаем... Кулым да бармый...

Кыскасы, Искәндәр, сезнең яннан качып киткән Сәйдәр... Динәне үтереп ташлаган.

Без, 3ез, дим. Син бит белмисең әле. Сез китеп озак та узмады, көннәрнең берендә мин иртәнге бер мәлдә үземдәге үзгәрешне сиздем. Мин ул хәлнең дөреслегенә ышанырга да, ышанмаска да белмичә борчыла башладым. Һәм ул борчылуым урынлы да... Чөнки үзебезнең саф мәхәббәтебезгә хыянәт итеп, аның җимешен харап итүнең җәзасын кичереп яшәдем. Озын сүзнең кыскасы, ул... бар! Әйе, әйе, бар бит ул, синең дәвамың бар. Хәзер инде мин аны күземнең карасыдай саклаячакмын... Син, Искәндәр, һәрвакыт минеке идең. Иң башлап минеке булдың бит син. Көлмә, елмайма, күңелемдә барын, чынын язам. Җиләкле аланындагы көннән бирле син минеке идең. Бер кынга ике кылыч сыймый диләр диюен, ләкин син минем йөрәгемдә һәрвакыт яшәдең. Инде син ничәмә еллардан соң монда килеп эшкә урнашкач та мин үз бәхетемнең мине ташламавын, язмыш бабайның ихтыяры белән кабат яныма килүен аңладым...

Күп яздым инде, Искәндәр, укый-укый да арыгансыңдыр. Ләкин бит ничәмә-ничә елдан соң мин сиңа беренче хатымны язам. Әгәр дә мәгәр син беркайчан да алмаган, үзем язып-язып та ахыр чиге ертып ташлаганнарын санамасаң. Көлмә! Шундый хәлләрне дә кичерергә туры килде Фирәзәңә... Әйе, Искәндәр, булды минем дә андый чакларым... Чөнки син минем йокысыз төннәрем, сагышларым һәм моңнарым булып бик озак, бик озак вакытлар яшәдең. Менә хәзер дә әле язмам, хатлар язып сине борчулы уйларга салмам дигән идем, үземнең исталек хатирәләрем белән бәйләнчекләнмәм дигән идем. Менә... түзеп булмады. Күңелемнең әллә кайдагы ерак бер түрендә сиңа булган назлау хисләре, сине сагынып-сагынып көтүем һаман саен кытыклый да тора.

Кайт, Искәндәр, савык та кайт, җаным. Без сине икәүләшеп көтәбез, яме, җаным. Кайт инде...

Яшьлегебез Карурманындагыча сагынып.

Фирәзәң-Киребеткәнең»

— Да-а-а, хәлләр дисәң дә хәлләр!— диде Искәндәр, савыгуга таба барса да, әлегә ныгып җитмәгән тәненнән көч-куәтнең китә башлавын тоеп.

## I

Кичә генә һәр тарафта әбиләр чуагының алтынсу төсләргә күмелгән бер көне иде. Көзге көннең сүрән кояшы әллә ни җылытып тормаса да, үзенең яктылыгы белән күңелгә бертөрле җиңеллек өстәп, өметләрне яңартып җибәрә иде.

Бүген исә күк йөзен тутыя сыман авыр болытлар томалап алган. Аларның иге-чиге күренми, офык үзе дә, гадәттәгечә, күз нуры барып җитәрлек ераклыкта түгел, ә менә монда, якында гына. Бик телисең икән, йөгереп барып тотарга да мөмкин. Моның өчен бары тик машинаның һәр ягы тимер-томыр белән уратып алынган тартмасыннан чыгарга гына кирәк.

Ләкин бу мөмкин эш түгел.

Моның өчен иректә кеше булу кирәк. Беркайчан да югалмастай тоелган ирек юк хәзер Тынчурин өчен. Ул кайдадыр еракта, әнә теге юл читеннән күп булса йөз илле, ике йөз аршин арасында җиргә ябырылып яткан офык артында.

Шулвакыт асфальт тасмасыннан тигез генә барган махсус машина — халык арасында каһәрләнгән, утыз җиденче елларда ук «кара козгын» дигән хәвефле исем тагылган ябык арба — як-якка чайкалып-талпынып алды, аннары рәттән икеме-өчме тапкыр сикертеп куйды. Моңарчы шома гына барганга күрә, саклану чарасын күрмәгән, әрҗә идәненә беркетелгән эскәмиягә тотынмаган Тынчурин башта утырган урыныннан әллә ни аерылмаса да, икенче тапкыр сикерткән вакытта аның башы түбә калаена ук менеп төртелде һәм ул «кара козгын»ның шундый ук тимер идәненә тәгәрәп китте. Беравыктан ул: «Тор, нәрсә тәгәрәп ятасың, а?..»— дигән тавыштан күзләрен ачарга мәҗбүр булды.

Тормакчы булып талпынды Тынчурин, күнегелгән гадәт буенча кулларына таянмакчы итте. Ләкин аның куллары корсак өстендә сузылып яталар, аларны ни сәбәпледер аерып алып булмый иде.

«Тор, хәзер үк, үләксә!»— дигән тавыш та Сәйдәрне идәннән кузгата алмады.

Тимергә тимер чыкылдаганы, аннары тавыш килгән яктагы ишекнең шыгырдап ачылганы аңлашылды.

Тирә-юнь берьюлы яктырып китте, Тынчурин үзенең читлек тартмасында икәнлеген, ә тавыш иясе, конвойчы хәрбинең аңа таба иелеп үрелгәнен күрде.

«Качарга! Качарга кирәк!— дигән уй утлы яшен сыман ялтырап алды.— Качарга! Богауланган кулларны мә, ярдәм ит, тотып торгызчы», дип хәрбигә сузарга да, ул бөгелгәч шушы богау белән бар куәткә баш чүмеченә кундырырга!.. Ишек ачык, юлда яңгыр пычрагы... Артка сикереп төшәргә, аннары канауга тәгәрәргә!..»

Ләкин чиктән ашкан тәвәккәллек белән Тынчуринның баш миен ярып чыккан бу фикер ничек кинәт яралган булса, аннан да кинәтрәк икенче белән алмашынды.

«Әгәр дә... әгәр дә күрсәләр?.. Кабинадагылар күрсә?» Шунда ук атып үтерәчәкләр бит, кабахәтләр. Аларга акланырга менә дигән сәбәп ич бу. Болай да конвойның өлкәне Сәйдәргә: «Син минем бөтен уй-планнарымны бозып ташладың, адәм актыгы! Ялга китәсе идем, кулга төшкән билетны синең аркада тапшырырга туры килде»,— дип берничә тапкыр сүгенде. Хөкем залыннан алып чыккан араларда бер-ике тапкыр бәбәкләрен алартып терсәге белән кабыргасына кадап-кадап алды...

Конвойчы шул арада җитез хәрәкәт белән мәхбүснең якасыннан

элэктерде һәм бер талпыну белән аны иданнән кубарып эскәмиягә ташлады. Теге мескен аркасы һәм баш чүмече белән эскәмия аркасына, машинаның тимер кыршавына барып бәрелде. Аның күз аллары томаланып куйды. Кычкырудан ярдәм юклыгы ап-ачык иде. Моны Тынчурин кулга алынып СИЗО[1]га китерелгән көнне үк аңлады. Дөресрәге, аңлаттылар.

... Аны шундый ук машинада алып киттеләр. Тәнге тетрәнүләрдән һәм Динәнең җан ачысы белән кычкырганда ачылган авызы, акайган күз алмалары онытыла төшкәч, Тынчурин, нәрсә эшләгәнлеген аңлар-аңламас хәлдә, ләкин баш миендәге ниндидер җепселләр кушуына буйсынып, йортлар төзү-монтаж идарәсендәге бүлмәсенә барып керде һәм, диспетчер белән каравылчының котын алып, Ширәмәттәге бүлекчәгә шалтыратты. Ләкин телефоннан:

— Дежурный сержант Ибраев тыңлый,— дигән шыксыз сүзләрне ишетүгә, сул кулының канга манчылып тутык төсенә кергән бармагын аппарат төймәсенә басты.

Шундук аның уң кулы, пинжәк кесәсенә кереп, «тәмле» сигарет тутырылган тартманы эзләп тапты. Хуҗасына буйсынырга теләмәгән бармаклары белән берсен алып авызына капты. Кабызгычын эзләрлек хәле юк иде. Каравылчы агайга акаеп карады. Трестның баш инженеры Тынчуринны шундый куркыныч хәлдә күргән диспетчер хатын өстәлдә яткан шырпы кабын аңа таба шудырды.

— Ни булды, Сезне нишләттеләр, иптәш Тынчурин, кыйнадылармы әллә ходаем?— диде дә тагын сүзсез калды. Тынчуринның үзенә төбәлгән ямьсез карашыннан телен үк тешләде.

Ул арада, бүлмәдәгеләрнең өчесен дә сискәндереп, өстәл өстендәге телефон аппараты үзчире тоткан кешедәй буыла-буыла шылтырарга кереште. Диспетчер хатын, итәгенә ут капкан сыман ашыгып, телефон көпшәсен күтәрде.

— Әйе, әйе, Көмеш Алан тыңлый,— диде ул.— Көмеш Ал...

Телефоннан килгән тавыш, төнге тынлыкта аеруча көчле яңгырап, бүлмәдәгеләрнең барысына да ишетелде:

— Син нәрсә дип әле минем белән шаярасың, иптәш Камаева. Ә? Ни булган, янгын чыкканмы, әллә сезнең төзелеп бетмәгән һәм бетәсе дә күренмәгән атомыгыз шартлаганмы дип торам.

Диспетчер хатын милиция кизүенең һөҗүмен көтмәгән иде, аның утсибәрдән чәчелгән сүзләре арасына бер сүз кыстыра алмыйча торды. Ләкин Камаева диспетчер булып юкка гына эшләми, төзүчетранспортчылар һәм төзү кирәк-ярагы эшләп чыгаручы заводлардагы ишләре белән тел чарларга, талашырга-ызгышырга яхшы ук остарган иде ул.

— Мин түгел сиңа шалтыратучы, Ибраев, кирәгең бар иде. Потың бер тиен,— дип үртәште һәм сержант яңадан утсибәрен көйләгәнче әйтеп салды: —Менә иптәш Тынчуринны үтерә язганнар, канга батырып кыйнаганнар...

Тынчурин шулвакыт телефон көпшәсенә үрелде, кан укмашкан бармакларына карап укшып куйды һәм:

— Ибраев, тизрәк, тизрәк килеп җитегез... Мин... Мин... кеше үтердем...— диде.

Ибраев төзелешнең баш инженеры Тынчуринны яхшы белә иде, шуңа күрә мондый хәбәрне тиз генә баш мие аппаратыннан эшкәртеп чыгара алмады бугай.

— Ша-ша-шаяртмагыз, иптәш Тынчурин... Сезгә бәйләнделәрме? Исерекләрме?

Тынчурин аны тыңлап бетермичә бүлдерде:

[1] СИЗО — следственный изолятор.

— Ашык, Ибраев. Мин... кеше үтердем. Килеп кулга алыгыз...
Ибраев һаман да ышанып бетә алмады, ахрысы:
— Нич-ч-чек, ничек үтердегез, иптәш Тынчурин?
Сәйдәр тагын:
— Килгәч күрерсез... — диде дә телефон көпшәсен өстәлгә бәрде. Ләкин янәшәдә торган диспетчер хатын аны өстәлгә төшеп җитте дигәндә генә тотып алырга өлгерде.
Баштагы ике тәүлектә аны Ширәмәттә тоттылар. Түбәнъярдан килгән прокуратура тикшерүчесе Гадилә Шибанскаяны ул элек тә белә иде. Нык гәүдәле, ирләр арасында һәм җинаятьчеләр белән эшләүдән булса кирәк, ирләрнекенә охшаш тавышлы бу хатынның килеш-килбәте, эш-хәрәкәтләре дә беркадәр тупасланган иде. Ул Көмеш Аланга элек тә еш килеп йөрде, әледән-әле кылынган җинаятьләрне тикшерде. Трест җитәкчеләренә дә кергәләде.
Баштагы көнне Тынчурин тикшерүче Шибанскаяга нәрсә сөйләгәнен, сорауларына нинди җавап биргәнен томанлы рәвештә генә хәтерли.
Динә яшәгән квартирага алып барып, җинаятьне ничек кылуын күрсәтеп-сөйләп бирергә куштылар бугай. Ул күрсәтте, сөйләде, бер генә нәрсәне дә кире кагарга, яшереп калдырырга тырышмады. Аннары Тынчуринны тикшерү астында ятучылар зинданына илтеп яптылар.
Беренче төнне үк күрмәгәнен күрде, ишетмәгәнен ишетте Тынчурин. Ул инде бераз аңыша төшкән иде, зиндандагы бүлмәгә кертеп япкач, үзенең нинди хәлгә калуын да тирәнрәк аңлагандай булды. Менә аны таш зинданга алып керделәр. Тимер ишекләр аның алдында шыгырдамый-нитми ачыла бардылар. «Майлаганнар» дигән уй каядыр китеп олакты. Ул арада борынга әчкелтем-тынчу ис килеп бәрелде. Бу ис шундук таныш сигаретны хәтерләтте. Ирексездән кулларын кыймылдатып куйды, кичекмәстән кесәсенә керәсе килде. Ләкин тимер богаулар... «Хәер,— дип уйлап алды ул,— менә хәзер үземә тиешле таш капчыкка керәм. Неужели шул килеш кертерләр? Мөгаен, салдырырлар. Рәхәтләнеп тартып җибәрермен». Бу уй Тынчуринның кәефен күтәрде.
Дөрес икән, ишек төбендә кулларындагы богауны салдырдылар...
Таш капчыкны әллә нинди соргылт-кызгылт яктылык томалап алган иде. Тынчурин бусагадан керүгә аптырап, алга таба атламаска теләгәндәй, тартелеп калды. Ләкин тимер ишек аның артына ярыйсы гына көчле итеп төртте һәм тоткынны ике адым алга атларга мәҗбүр итте. Йозак шылтырап бикләнде.
Тынчурин бүлмәдәге эңгер-меңгергә охшаш яктылыкка күнегә төште. Шундук аның борынына тагын да әчерәк, гадәттә, әберәкәй тирәсендә була торган ис килеп капланды. Ул ирексездән борынын җыерды, шундук төчкереп тә җибәрде.
— Карагыз әле бу адәм актыгына,— диде ярыйсы гына юан тавышлы берәү.— Безнең аппартаментның саф һавасын ошатмаган була тагын... Әйдүк, әйдүк, ип-п-п-тәш Тынчурин, рәхим итеп түрдән уз...
Яңа тоткын бу сүзләрнең үзенә төбәлгәнлеген аңламыйчарак торды, әмма тагын бераздан шул ук тавыш:
— Әйдүк, дим бит, Тынчурин, башыңны Көмеш Аландагы кебек югары тотып атла!— дип кабатлады.
Шунда гына Сәйдәр Тынчурин ике катлы рәт-рәт сәндерәләрне һәм анда утыручы тоткыннарны, бүлмәнең урта бер җирендә кырылган-чокылган һәм тагын әлләниләр эшләтеп бетерелгән өстәл, аның өстендә домино шакмаклары һәм таш идәннән кимендә ике метр биеклектәге тимер рәшәткәле, тар тәрәзәне күрде.
— Әйдүк безнең янга рәхим ит, Тынчурин,— диде тагын бер тапкыр шул ук бер тавыш. «Каян беләләр монда минем кем икәнлекне?»—

дип гаҗәпләнде Тынчурин.— Нинди «хата»га эләккәнеңне беләсеңме икән соң син, ә, начальник?— Мәхбүс дәшми-тынмый гына торуында булды.— Әй, әллә инде син шундый шәп «хата»га эләгүеңә шатланып телеңне йоттыңмы? Бар әле, «Серый», телен ачтыр әле шуның, сөйләшерлек ит әле.

Сул яктагы сәкедән матрос тельняжкасы кигән берәү торып басты да, киерелеп-иснәнеп алганнан соң, ишек катында басып торган Тынчурин янына атлады. Аның кан баскан күзләре усал елтырый, сул як битен урталайга бүлеп торган кызгылт-күксел җәрәхәте селкенеп-селкенеп ала иде.

— Йә, күрешик, сау-сәламәт килеп җиттеңме?— диде «Серый» ике кулын берьюлы күрешергә сузып.

Тынчурин күрешүнең халык арасында гадәти бер нәрсә икәнлеген белгәнгә, аны-моны уйламыйча, шулай ук ике кулын сузды һәм... шул ук мизгелдә аяк асты һәм күкрәк тирәсендә искиткеч авырту тойды. Аннары ул алга таба бөгелеп төште, ләкин шунда ук аның маңгаена яңа көч килеп бәрелде һәм ул артка каерылып аварга керешә. «Нигә, ни өчен?»— дигән беркатлы уй теленә килмәкче иде бугай, әмма баш чүмече тагын нәрсәгәдер бәрелүдән бермәлгә аңын югалтып торды. Бу хәл озак дәвам итмәде, берничә секундтан Тынчурин авырлык белән булса да аякларына торып басты. Менә аны ниндидер бер көч җилтерәтеп алга таба алып китте һәм, ниһаять, ул үзенең артында урын барлыгын сизеп, чүгәләп утырырга кереште...

— Йә, сәрхүш, татлы-затлы ризыгыңны безгә алып кердеңме? Уртаклаш, әйдә...

Мәхбүс Сәйдәр үзеннән нәрсә таләп итүләрен төшенмәде. Баш чүмеченнән аска таба кыймылдап төшкән җылыны тоеп, ирексездән кулын муенына куйды. Бармаклары юешкә тиде... «Кан, кан бит бу, башымны тишкәләр бит бу зиндан кортлары»,— дип уйлап алды ул һәм, күз аллары караңгыланып, чигәсендә әллә нинди бер кылның зыңгылдап тартылганын сизде. Шул ук мизгелдә ул әлегәчә күкрәгеннән кемнеңдер көчле кулы тотып торганны шәйләде һәм... көтмәгәндә генә сикереп торды, торган уңайга баярак кына богаулардан арынган кулларын йодрыклап каршысындагы «Серый»ның корсагына төртте. Мондый кискенлекне көтмәгән, каршылык күрсәтер, дип уйламаган, «Серый» каршыдагы сәке астына кираркан барып төште.

— Ого-го!— диде теге юан тавыш.— Молодец егет икәнсең. Юкка гына начальник булып йөрмәгәнсең. Туктагыз! Туктагыз дим бит сезгә! Яле, яле. Ах, анагыз... Урыннарыгызга! Егылганны типкәләмиләр...— дип кычкырды ул Сәйдәргә ташланган ике әзмәвергә.

Тынчурин соңрак белде: мондагы тикшерү астында тотылучылар төрмәсендә генә түгел, байтак кына лагерьларда да үзенең хәйләкәрлеге, миһербансызлыгы белән танылган «Барин» тавышы иде бу. Ләкин шушы минутларда Тынчурин аңа рәхмәтле күзләре белән карады, чөнки ул халык телендә йөргән «сөймәгәнгә сөйкәлмә» дигән хак сүзләрне белми иде. Мәхбүсләр, теләр-теләмәс кенә, «җаны уч төбенә китмәс әле» диешеп, канәгатьсезлек белдерә-белдерә үз урыннарына таралган булдылар.

Халык әйтмешли, һәр төкерек алтын түгел. Тынчурин әлегә рәхмәтле булса да «Барин»ның төлке шулпасы әчертүен кайдан белсен, белми иде ул әлеге бәндәнең үзенә нилар күрсәтәсен.

— Йә, Сәйдәр Хәлилович, хәлләр ничек анда? Көмеш Алан шәһәр түсенә кереп барамы?— дип сорады ул, Тынчурин беравык тын алгач.

«Каян беләләр болар мине?»— дигән уй тагын бер кат Тынчуринның башына килде, әмма аңына барып җитмәде. Хәер, моны әле шушы таш капчыкта ятучылар да белми иде. Гомумән, бик серле бүлмәләр-

нең берсе иде бу. Әгәр дә мәгәр Тынчурин белсә иде үзен кемнәр янына һәм иң түбән ният белән, кешелегенең иң соңгы тоткаларын сындырырга керткәннәрен... Алай гынамы, «Барин» кичә үк, һава сулап кергәннән соң, бүлмәсендәге мәхбүсләргә: «Иртәгә безгә яңа кош килә, аны сындырырга, бер сүзгә дә каршы килмәслек итәргә кирәк булыр»,— дип боерык биреп куюын каян белсен соң? Зинданнарда ята-ята кыргый ерткычка әйләнгән бу бәндәләр, намусларын яшереп, законнарны таптау юлы белән югарырак үрмәләргә тырышучы зинданчылар ясаган ташламалар хакына теләсә кемне сындырышырга, теләсә кемнең вөҗданына төкерергә, хәтта җәһәннәм төбенә олактырырга әзер иделәр. Тикшерү астындагы мәхбүсләрнең таш капчыкта кылынган золымнарын язар өчен стеналар да, сәке такталары да житәрлек түгел иде шул.

— Ярый, син начальник булып йөргән чакларда, Сәйдәр Хәлилович, тәмле сигаретлар тартасың, дигәннәр иде. Әгәр дә мәгәр зиндан кортлары кесәләреңне актарганда алып калмаган булса, рәхим итеп сыйлап җибәр әле...

— Рәхим итегез, рәхим итегез,— диде яклаучы табылудан күңеле нечкәрә башлаган Тынчурин.— Бер-ике булырга тиеш.— Ул кесәсенә тыгылды, ләкин гаҗәп, анда ник бернәрсә булсын, хәтта кулъяулыгы да юк, кесә төпләре тап-такыр иде.— Белмим, бар иде, алганнар бугай,— диде Тынчурин, гаепле кеше сыман тавышын мескенләндереп. Ләкин шул ук мизгелдә соңгы айларда рәхәтләр кичертеп яшәгән гашиш-эфьюнның исе аның борынын кытыкларга кереште. Ул ирексездән як-ягына каранып алды.

— Ярый, ярый, бу кыргый тәкәләр шаярганнардыр. Алар шулай бераз күңел ачып алырга яраталар инде,— диде «Барин» тамак төбе белән көлеп.— Әйдә, утыр, минә минекен кабыз... Кабыз да, ни кылдың, таш капчыкка ни өчен каптың, сөйләп бир, бер тамчысын да яшермичә. Синең ихласлыгыңны белик. Аннары, аннары бит кешегә бушанып алу да кирәк. Сөйлә, күңелеңдә төен булып ятып калмасын.

«Барин»ның тамак төене тычкан кебек сикергәләп, уртлары уйнаклап ала, күзләрендәге шәфкатьсезлек тышка чыгарга әзер иде. Ләкин, нишләмәк кирәк, кем арбасына утырсаң, шуның көен җырлый башлыйсың шул инде.

— Мин Мәскәүдән кайтып төштем...— дип башламакчы иде Тынчурин, баягы «Серый» аны бүлдерде.

— Алдашма, начальник, дөресен сөйлә... Син җәһәннәм булган урыннан, Чернобыльдән, безнең кебек беркатлы эш ишәкләрен ташлап, аучыдан качкан куян кебек калтыранып кайтып бара идең.

«Каян беләләр болар?»— дип уйлады Тынчурин исе китеп, үз тирәсенә тупланыбрак утырган кешеләргә ирексездән игътибар белән карап. Ләкин алар арасында ул белгән, аның күзенә чалынган «эш ишәге» юк иде.

Тынчурин тирән итеп бер-ике тапкыр тәмәке суырды һәм шул ук мизгелдә «Барин» сигаретының да кибеттә сатыла торганнар кабыннан булмавын аңлады. Аның баш миенә кайнарлык менә башлады, күзләренә төс кергәндәй булды һәм, иң мөһиме, күңелендә ниндидер башбаштак барыберлек, алай гына да түгел, яңа бер тәвәккәллек кузгалып китте. Һәм ул үзе кылган җинаятьне, хәтерендә калганча, үз каланчасыннан торып, һәрбер төлке үз койрыгын мактар дигәндәй, сөйләргә кереште.

Әйе, үзен агулаган эфьюннән авыз иткәч, теле ачылды аның. Башбаштак миңгерәүләнү вакыт-вакыт әрнеп куйгалаган җанны майлап куйгандай итте. Түгелгән тулы булмас, кылынган эш кире кайтмас, дип белмичә әйтмәгәннәр, күрәсең. Тынчурин, әле кайчан гына горурлыгы чиктән ашкан, тәкәбберлек һаваланулыннан чыкмаган Тынчурин, хәзер таш капчык «Барин»ы алдында гына түгел, ул әйтмешли,

кыргый тәкәләр алдында да тәчергәләнеп сөйли башлады.

Тыңлый беләләр икән, бүлдермәделәр.

Ниһаять, ул тынып калды, сөйләп бетерде, ләкин күңелендәгесен бушату аңа тамчы да җиңеллек китермәде. Әфьюн агуына томаланган акылы астында: күкрәк эчендә ниндидер чуерташ кыймылдап алгалады. Үзе сөйләгән коточкыч вакыйга да аңының иң ерак бер җиреннән саташулы төш шикеллерәк кенә үтеп китте.

Кичке аш китерделәр. Тынчурин урыныннан кузгалмады: чөнки ул баягы ят әфьюннан соң аңлашылмас битарафлык хөкемендә иде әле. Шуңа карамастан, «Серый» аның алдына савыт китереп куйды, кулына кашык тоттырды. Сәйдәр ирексездән кашыгына әлеп ботка алды, әмма мондый ботканы моңарчы бер мәртәбә дә ашамаганга күрә, тамагыннан төшерә алмады. Бераз шулай әвәләгәч, Тынчурин ботка төерен авызыннан кашыгына чыгарды һәм төмсәләнеп савытка куйды.

— Һе, начальник, безнең ботка тамак төбегезгә төер булып утырамыни?— диде «Серый», аның кабыргасына төртеп.— Бармыймы? Дина-матурны теге дөньяга кунакка җибәргәнче уйлыйлар аны. Ахмак, бүтән вакытларда соң ул, син Мәскәүләрдә кәеф-сафа корып йөргәндә, әллә буш утырган, сине көтеп байлыгына богау салган дисеңме? Ул чагында яраган бит, хәзер дә чуртым да булмаган булыр иде. Тегесен куып чыгаралар да, икеләтә үчен алалар аның...— шулай диде дә ихахайлап көлеп куйды «Серый». Аңа башкалар кушылды: «Исе киткән икән, кара син аны нинди нәзберек»,— диештеләр.

Эт йөгереген төлке сөймәс, авыру кеше көлке сөймәс, дигән борынгылар, Тынчуринда аларга кушылу уе юк иде.

Ниһаять, кичке барлау узды, барысына да йокларга боерык бирделәр. Утның да әллә нindие кабынды, таш капчык бүлмәсе, бигрәк тә сәкеләр тирәсе сәер караңгылыкка күмелде. Хәер, Тынчурин өчен бу гадәти хәлдер кебек тоелды...

Барысы да урнашып беткәч, «Барин»ның шөбһәләндергеч, аңлашылмый торган боерыгы ишетелде:

— «Серый», синең чират бу юкәнең курысын төшерергә,— диде ул.

Тынчурин янәшәсендәгеләрнең җанланып куюларын, көлешеп алганнарын тойды. Ул да түгел, аның кулларын каппап тоттылар, башына нәрсәдер каплап сәкегә таба идерделәр, бастырыклап ук куйдылар. Тәҗрибәсез Тынчурин карышмакчы булып селкенгәләп карады, ләкин, кая инде ул — корычтай нык куллардан ычкыну мөмкин түгел иде. Кычкырмакчы, кемнәрнедер ярдәмгә чакырмакчы иде Тынчурин, тик үз тавышын үзе дә ишетмәде, сыер мөгрәгәндәй тавыш кына чыгаргалады. Шулай да ул кемнеңдер кайсыдыр җиренә җилкәсе белән төртергә өлгерде. Шундук башына япкан нәрсәне ачтылар һәм авызына сасы чүпрәк бәйләме тутырдылар. Моннан соңгысын инде ул коточкыч төш кебек кенә хәтерләде. Кемнәрнеңдер шәфкатьсез куллары аны чалбарыннан тартып чыгарды, йөзтүбән туңкаерга мәҗбүр итте...

Ул һушыннан язды...

Берзаман башына япкан нәрсәне алуларын, авызындагы сасы чүпрәкне тартып чыгаруларын, аннары тагын кулларын һәм аякларын ычкындыруларын тойды.

— Тор, ягъни мәсәлән, урыныңа барып ят, начальник, товарыңның бәһасе төште,— диде кемдер күкле-яшелле тавыш белән хихылдап.— Йә, «Серый», начальник-каләшең һәйбәтме, уңдыңмы аңардан?

Бәхетенә каршы, төннең икенче яртысында аңа бәйләнүче булмады. Ләкин Тынчуринның мәсхәрәләнгән тәне әллә нинди бер чоңгыл төбенә ташланган кебек бөтерелә, йөрәге йә кысыла, йә бөтенләй диярлек дуларга керешә, биредәге золымны кабул итәргә теләми иде.

Байтак вакыт бимазаланып ятканнан соң Тынчурин йокымсырый башлады, хәтта йоклап киткәндәй булды. Тик аның күзләре генә йомылды, әфьюн белән агуланган баш мие бер генә мизгелгә дә уйланудан туктамады.

Ниһаять, соңгы өч көндә Тынчурин үзе кылган җинаятьне күрде. Үз хәленең кызганыч бәхетсезлеге турындагы уйлар өере аның җанын калтыранып-тетрәнеп куярга мәҗбүр итте. Мондагы зиндан ерткычларының үзен имгәтеп ташлау ихтималлыгы бөтен тулылыгы белән чынбарлык булып алдына килеп басты.

Бу бәндәнең зиһенендә дә, ниһаять, мәгънәле сораулар бер-бер артлы калкып чыктылар.

«Ә элек соң син, Тынчурин, шәфкать-иман турында уйлап та карамыйча кешеләрне ялган шикаятьләр белән, үз юлыңнан түнтәрә барганнарыңны, ул кешеләрнең тормышларын вату-җимерүдән тәм табып яшәгәндә син бер дә «вакланып», кылган эшләреңнең нәтиҗәсе, кемнәргәдер җәбер-золым кылуларың хакында уйлап та тормадың. «Янәшәңдәге иптәшләреңә «мөгез куюдан» ләззәт табу, аларның вөҗданнарына хыянәт итүне бернигә дә санамаган хатыннарын җиңүдән танавың югары йөрде. Син нишләп соң ул вакытта чырайсыз ябалак шикелле караңгыланып утырмадың? Ул чагында син рәхәттә, канәгатьлектә идең, үзең казыган базга үзең төшәсеңне уйлап та карамадың. Син бит Динәне дә вөҗдан белән санашмаска өйрәттең, соңрак әфьюн кабарга күндердең, ахыр чиге инде аның үзенә һәм атаанасына кадерле җанын кыйдың. Ул чагында син намус-шәфкать, кылганнарың өчен ярлыкау эзләү турындагы уйларга кадәр барып җитмәдең. Җайлы сылтау таба белдең. Хәзер генә синең җаның уч төбендә тора, кая барып бәрелергә белмичә, куак төбендәге куянныкы кебек дерелди. Дөрес, синең үзеңнең дә мин-минлегеңә гомер буе сугып яшәүче табылды. Син аның тәнен үзеңнеке иттең итүен, әмма җанына сукмак таба алмадың. Син анда, эшеңдә, үзеңә урын яулар өчен берсен көйләп, икенчесен сөйләп ышандырдың, ахыр чиге сыналган алымыңны кулландың — шикаять язарга керештең. Дөрес, анда да син астыртын эш иттең, кулыңны куймадың. Ләкин заманасы шундый иде аның, шикаятьләргә, ачыктан-ачык әйткән сүзгә караганда, күбрәк ышаналар иде. Әмма Фирәзә исемле хатынның ихтыяры сине бәйдә тота, тугарылырга ирек бирми иде әле. Ул сине кеше арасында кеше итеп яшәтә, синең эчеңә яшеренгән ерткычлык, гайре табигый тойгыларны тышка чыгармау серен белә иде. Ә инде Фирәзә сиңа кул селтәп, язмышның кулына ташлагач та син каты кура кебек сындың, югалдың, һәм шушы йомшаклыгыңны ерткычлык, куркаклык тойгылары җиңде...»

— Торырга, йокыдан торырга! Барыгызга да торырга! — дигән тавыш яңгырады.

Тән җәзасын, аннан да бигрәк җан җәфасын кичереп яткан Тынчурин яңарак кына тынычлана башлаган, хәтта инде йокымсырый башлаган иде, әмма аның ми җисеме бик тиз уянып китте. Аның күзләрендәге ачуны күргән теге шакаллар шундук:

— О, ирекле илнең тикшерү астындагы ирексез гражданнары, карагыз әле безнең яшь киленебез дә күзләрен ачты. Тик идәнгә төшәргә — кеше күзенә күренергә оялып тора, әдәп саклаган булып кылана,— диештеләр һәм араларыннан берсе ихахайлап көлә башлады. Аңа башкалары да кушылдылар.

«Барин»ның кәефе шулай ук начар түгел иде бугай, ул шешенке кабаклы күзләренә елмаю әсәре кертергә тырышып әйтте:

— Яшь киленне идәнгә төшермиләр, «Хилый», аны күтәреп барып башын-битен юындыралар...

Тынчуринны шундук урыныннан тартып төшерделәр, ләкин ул идәнгә басарга өлгермәде, җилкәсенә сикерделәр, умыртка сөяге генә

түгел, муен тамыры да әллә нишләде. Ул сыгылып төште, кайдадыр эчтә нәрсәседер өзелгән кебек булды һәм, күз аллары караңгыланып, идәнгә ауды. Ләкин бәхете бар икән Тынчуринның, бу юлы аны имгәтергә өлгермәделәр, ишекнең теге ягында тимергә тимер бәрелде. Комарланып җитмәгән мәхбүсләргә шул җитә калды, алар күз ачып йомган арада берни булмагандай шым булдылар.

Сыкранып кына ишек ачылып китте, күзәтүче һәм аның артында тагын да бер шәүлә барлыгын абайладылар.

— Ни хәл бу?— диде күзәтүче корычтай яңгыраган тавыш белән.— Нинди тәртипсезлек биредә?

Барысы да «Барин»га таба карадылар; ул, бары тик ул гына җавап бирергә тиеш иде, күрәсең.

— Юк, гражданин начальник, нинди ыгы-зыгы булсын?— диде «Барин» җилкәләрен җыерып.— Безнең «хата»да тулы тәртип. Әнә, зекалыкка кандидат — гражданин Тынчурин ятагыннан сикереп төшмәкче иде дә, аягы таеп егылып китте.

— Алай гына булса, ярый,— дип, күзәтүче Сәйдәргә төбәлде.— Чыгыгыз бирегә, Тынчурин.— Аннары аптырап калган мәхбүскә карап: — Селкен, диләр. Охшап киттеме, чыгасы килмиме әллә,— дип ашыктырды. Аның ирен читләрендә мыскыллы елмаю эленеп калды. Күзәтүче аны уздырып җибәрде һәм, артыннан чыгып, ишекне бикләргә керешге.

Аны тикшерүче Гадилә Шибанская каршы алды. Күрәсең, ул биредә беренче тапкыр гына түгелдер инде, Тынчуринның өстен-башын, килеш-кыяфәтен күрүгә, төнлектән чыккан кеше кебек йөзе каралып китте.

— Кем кушты, иптәш күзәтүче, тикшерү астындагы кешене таш капчыкның ул бүлмәсенә ябарга? Сез соң тәртипне белмисезмени?— диде ул. Алар янына капитан киемендәге берәү килеп басты. Хәзер инде Гадилә Шибанская аңа карап әйтте: — Нигә кирәк иде соң сезгә Тынчуринны «пресс-хата»гызга ябарга. Ул болай да кирәгеннән артыгын, бөтен вак-төяге белән сөйләп бирде ич инде.

Капитан көлеп куйды:

— Мин юк идем, кизүдәге иптәш яңа эшли башлаган кеше, белмәгәндер, иптәш Шибанская,— диде ул акланып.— Артык булмас кеше үтерүчегә...— дип өстәде аннары.

— Белегез, иптәш капитан, бу эшләрегез бервакыт фаш ителер, кайберләрегезне себереп үк түгәрләр,— диде Шибанская ачуын яшермичә.— Бу хакта бит инде күптән сүз бара, без капчыкта ятмый.

— Ярый, ярый, иптәш тикшерүче, законның һәр хәрефенә ябышып ятуыгызны беләбез. Әйткәннәрегезне киләчәктә истә тотарбыз, гаепле кешене җәзага тартырбыз,— диде ул астыртын елмаюын яшермичә.— Үзегезгә җиңелрәк булсын, дип тырышуыбыз бит югыйсә...

Сорау алудан соң һәм аннары хөкем буласы көнгәчә Тынчуринны ике кешелек махсус мәхбүсләр бүлмәсенә ябып тоттылар.

Ниләр генә уйламады, ниләрне генә башыннан кичермәде дә, нинди генә планнар кормады Тынчурин тикшерү барган көннәрендә. Аның кәефе әлек тә бер карасаң өтек, икенче карасаң — төтек була торган иде. Монда да шушы сыйфаты үзенекен итте. Берара ул хәтта кылган җинаяте өчен җәзасын алгач та моннан тизрәк качып кайту һәм көндәше Искәндәр Фидаяров белән элеккеге хатыны Фирәзәдән үч алу уе белән янды. Берничә көннән аның башын: «Кеше үтергәнең өчен үзеңә дә атып үтерү җәзасын бирүләре ихтимал»,— дигән уй бораулапмы бораулый башлады. Бу фикер аның башына шулхәтле көтмәгәндә килеп керде ки, хәтта ул берничә көнгә ашаудан калды. Ләкин Тынчурин күптән белә иде: суны меңкат кайнатсаң да куермый. Бу халәттән дә ярыйсы гына тиз чыкты. Әмма... күңелгә коткы салып торучы теге нәмәрсәдән алай җиңел генә котылулары

гаять авыр икән. Тынчуринның баштагы көннәрдә аңын югалтып, тәмам чиргә сабышырга җиткән чаклары да булды. Санчастька мөрәҗәгать итәргә туры килде. Баш авыртуына, йокысызлыкка бик каты зарлангач, аңа хәлен бераз җиңеләйтердәй дару алырга рөхсәт иттеләр. Алар гына, билгеле инде, Сәйдәрнең әфьюнгә өйрәнеп җиткән нервларына уңай тәэсир ясый алмаган булыр иде. Көтмәгәндә... Ике кешелек камерада ятуының бишенчеме көнендә аңа, «Барин» кушуы буенча, «посылка» китереп тоттырдылар... Шулай итеп, таш капчыкның беренче тетрәндергеч сынауларын узган Тынчурин: «Монда да яшәп була икән лабаса»,— дигән фикергә килде һәм киләчәктә үзе дә «Барин»га әверелергә ант итте. «Серый» сыман җәлладларга бирешмәскә, үзенең дә к е м икәнлеген танытырга карар кылды.

Ниһаять, хөкем көне җитте...

Тынчуринның үз тырышлыгы белән дә өлгертелгән һәм яңарак кына, ул инде тикшерү астында утырган көннәрдә, файдалануга бирелгән мәдәният сараеның зур залы халык белән шыгрым тулы иде.

Динәнең ата-анасын, туган-тумачаларын ул залга кертеп утыртуга танып алды. Кайберләрен күргәне бар, кайсыларын күрмәгән иде, ләкин барыбер аларын да таныды. Йөзләренә бәреп чыккан тирән кайгыдан таныды ул аларны. Шул ук залда баш инженер кул астында эшләгән кешеләр дә килеп утырганнар. Әмма аларның йөзендәгене укый алмады Сәйдәр: кызгану яки кызганмау хисләрен битарафлык битлеге каплаган иде.

Тынчуринны махсус ясалган урынга утыртуга, залдагылар арасында пышылдап сөйләшүләр китте. Ул сүзләрнең байтагы тын бүлмәдә ярыйсы гына ачык ишетелә иде.

— Кабахәт, күр әле син аны, йөзе караны, бер генә дә үкенергә охшамаган моның килеш-килбәте...

— Минә карарбыз, стенага терәп атарга алып чыга башласалар, йөзе үзгәрер әле...

— Үлем җәзасы бирмәсләр, карга күзен карга чукымый аны. Әллә кайчан сатып алгандыр әле...

Беравыктан, хөкем башланыр алдыннан була торган ыгы-зыгы узгач та, Тынчурин каш астыннан гына залдагы кешеләрне барларга керәште. Танышларының карашы белән очрашканда ул үзенең элек-электән оялуны белмәгән күзләрен бик тиз читкә яшерергә өлгерде. Байтак кына шулай утыргач, гаепләү нәтиҗәләрен укып бетергәннән соң, эзләгән кешесенең залдагылар арасында юклыгына ышанды ул.

«Юк, килмәгән, күрәсе килмәгән, димәк...»

Шулвакыт хакимнәр һәятенең башлыгы:

— Шаһитларны тыңлый башлыйбыз. Фирәзә Фидаярованы кертегез,— диде.

«Кара син аларны, ничек тиз тотканнар! Кай арада Фидаяровага әверелеп өлгергән ул?»— дип уйлап куйды Тынчурин аптырап.

Тагын ярты минут уздымы-юкты, залга башын гадәттәгечә югары тотып, кибаранә кыяфәттә Фирәзә килеп керде. «Карале бу кысыр кындыракны...»— димәкче иде Тынчурин, әмма аның карчыга күзләре Фирәзәнең гәүдәсе ярыйсы гына тулыланып, корсагы исә шар сыман түгәрәкләнеп киткәнлеген күрде һәм телен тешләде. Дөрес, тагын бер мизгелдән аларның күзләре очрашты. Баярак, аны чакырырга кушкач та: «Берәр җылы сүз әйтер, бәлки»,— дип уйлаган иде, хәзер исә Фирәзәнең нәфрәтле карашын, аннан да бигрәк тәмам түгәрәмләнеп җиткән корсагын күргәч, Тынчурин күңелендәге өмет чаткылары капыл сүнде. Шуннан соң инде ул Фирәзә ягына карамаска тырышты. Ләкин бу аның хәленнән килә торган эш түгел икән. Әмма Фирәзә күзләренә туры карарга җитәрлек көч юк иде аңарда.

Шаһитлар белгәннәрен сөйләделәр, артыгын әйтмәделәр, ләкин

ник берсе Тынчуринны аклау турында сыңар бер сүз ычкындырсын. Җитмәсә, трест исеменнән җәмәгатьчелек яклаучысын да хөкем башлангач кына чакыртып алдылар. «Көймәң комга терәлсә, тиз генә котылулары кыен инде ул,— диде аңа эчке бер тавыш.— Чынлап та, бүре хәтле бүредән бүрек ташлап кына котылырмын дип өметләнмәскә икән».

Хәер, Тынчурин мондагыларның, бигрәк тә хатын-кызларның, үзен яклап сүз әйтмәсләрен белә иде. Чөнки ул үзе кышын кар сораган кешегә кар бирмәс булып кыланды. Кешенең бит аның матур-матур сүзләренә генә карамыйлар, эшләренә карап тиешле бәясен бирәләр. Кая инде ул адвокат хәтле адвокатның да яклау сүзендә хөкем ияләренең күңелен йомшартырлык авазлар ишетелмәгәч... Мактаганнар иде, акчасын да алдан ук алганнар иде, ә чыгышы, чыгышы төссез, яклау ягына китергән дәлилләре йомшак, аклаудан битәр, гаепләүчеләргә өстәмә дәлил булырлык иде. Шуңа күрә залдагыларны да, хөкемчеләрне дә ышандырмады салкын сүзләр. Тынчуринның хөкем алдында яңартылган тормыш рәвеше, кешеләргә һәм вазифаларына мөнәсәбәтеннән хасил булган сурәте, ахыр чиге, аның үз гаебен тулысынча танып торуы шул хәтле ачык һәм кире кагылгысыз иде ки... Борынгылар юкка гына: «Качып китсәң дә чәчеп кит»,— димәгәннәр шул. Тынчуринның исә үзе артыннан чәчелгән басу калдырырга вакыты да, теләге дә булмады.

Ниһаять, хөкем карарын укыр минут та җитте.

— Торыгыз, судьялар килә!— дип кычкырдылар.

Тынчурин баштарак бу боерыкка буйсынмаска уйлаган иде, эмма әллә нинди сихри бер көч аны урыныннан торып басарга мәҗбүр итте. Залдагылар аягүрә басканнар иде инде. Менә эскәмия артлары, утыргыч такталары бәрелгән тавышлар, йөткеренүләр дә тынды.

Тынчурин үз язмышындагы хәлиткеч минутларда кечерәебрәк калган, баскан урынына сеңә төшкән, җилкәләрен кысып, куырылыбрак калган иде. Бу вакытта ул үзенең йөзен, анда хасил булган яңа җыерчыкларны, чаларган чәчләрен күрсә, билгеле ки, аптырап калган булыр иде. Чынлап та, адәм затын эш картайтмый, кайгы картайта, дип белмичә әйтми халык. Хакимнәр һәятенең башлыгы күзләгән рәтләп, кулындагы кәгазьне тәртипкә китереп, җайлабрак торткан арада Тынчурин үзе дә сизмәстән кайчандыр әбисе өйрәткәндә күңеленә сеңеп калган доганы кабатларга кереште.

Үзе кылган җинаятьнең бөтен тирәнлеген аңласа да, иң югары җәза бирмәсләр әле, дип өметләнә иде Тынчурин. Әмма гаепләү актын, шаһитларның сүзләрен ишетеп, залда утыручыларның нәфрәтен тоеп, бигрәк тә Динәнең ата-анасы, туган-тумачаларының күз яшьләрен тыя алмауларына карап утыргач, прокурорның җинаять статьяларын санап чыгып, җинаятьче Сәйдәр Тынчуринны үлем җәзасына хөкем итүләрен сорагач, аның йөрәге куркынып китте, өмете киселә башлады.

Шуңа карамастан, хөкем карарының иң мөһим җөмләсен ни хәтле зарыгып көтмәсен, әйтелгән мизгелендә аны аңлап өлгермәде Тынчурин. Бары тик «УНӨЧ ЕЛ» дигән сүзләр генә аның ми җисеменә барып бәрелде һәм тәнен кайнарлыкка, иксез-чиксез шатлык эченә ташладылар.

...Менә хәзер — хөкемнән соң таш капчыкка сөрелгән Тынчурин конвойчы ишегендәге бәләкәй тәрәзәдән карап бара. Якты дөньяга карап бара. Ә дөнья бигрәкләр дә матур икән ләбаса. Машина Ширәмәт урыннан күтәрелә бугай. Әйе, әйе, шушы таудан менеп бара. Элек ул бу тауга менгәндә дә, төшкәндә дә тирә-яктагы хозурлыкны, матурлыкны күрми иде. Сәйдәр күз алмаларын авырттырганчы текәлеп карады. Ул туктаусыз яуган ымдык яңгыр аша борынгы авылның каралып калган йортларын күргәндәй булды. Аның артында, әнә

теге якта. Тынчурин үз юлының иң ачы сәхифәләрен язган яңа кала — Көмеш Алан салынып ята. Хәзер инде аның Тынчуриннан башка гына зур шәһәр булып үсүе артык борчымый, чөнки ул кайчан да булса шунда кайтачагына ышана иде.

Вак тамчылар, ара-тирә ялтыравык кар тәңкәләре белән аралашып, юл буендагы агач яфракларына төшеп-төшеп куналар, ләкин аларның саргылт төсен агарта алмыйлар.

— Бик онытылып укыдың,— диде карт йомшак кына,— озак көтеп алган хат иде, ахрысы?

— Әйе шул,— диде Искәндәр, һәм ничектер ачылып, хатның кемнән булуын, анданиләр язылганын сөйләп китте. Үзе хатны пөхтә генә бөкләп конвертына тыкты, аннары карт белән бергәләп ул күрсәткән якка таба атлады. Ярты юлга җиткәч тә: — Без бит замок һәм Турайд Розасының каберен карарга барырга сөйләшкән идек,— дип картның исенә төшерде. Карт аның бу дөнья һәм бу төштәге табигать хәлләреннән еракта икәнлеген аермачык күреп тора иде бугай.

— Ярый, алайса, драуг, әйдә, шунда таба юнәлик,— дип, Искәндәрнең яңадан хаттагы хәбәрләрне сөйли башлавына игътибарын юнәтте.

Ә Искәндәр сөйләде, үзенең соңгы елларда ниләр кичерүен, Көмеш Аланга кайткач та үзенең сабакташын һәм яшьлек мәхәббәте Фирәзәне очратуын сөйләде. Аннары Чернобыль һәлакәте, андагы хәлләргә күчте. Ахырдан үзенең у л ы булачагын әйтте. Карт бу соңгы сүзне ишеткәч тә елмаеп куйды, ләкин Искәндәргә каршы төшмәде, йомшак тавышы белән: «Йа, йа, йа»,— дип, аның сүзен хуплый-хуплый атлады. Чөнки ул күзләрендә сагыш чаткылары хөкем сөргән бу кешене кичә үк якын итеп өлгергән иде инде. «Шулай була бит ул,— дип уйлап барды карт эченнән генә.— Кайчагында, бигрәк тә күңелең тулып, бугазыңа таш төере утырган чакларда кемгә дә булса эч серләреңне сөйлисе, йөрәгеңә баскан авыр уйлардан арынасы килә. Һәм бервакыт килеп җитә ки, син шуларны, эчең тулы сагышларны юлыңда очраган һәм синең карашыңча сер сыйдырырлык дип табылган кешегә актарасың... Шулай иткәндә генә синең күңелең бушап кала, җан газапларыннан бары тик шулай итеп кенә арынасың. Кешегә кеше кирәк, кеше кешегә дару, дип әйтүләре хак икән шул...»

Ниһаять, Искәндәр сүзеннән туктады. Янәшәдә атлаган картка гаҗәпләнебрәк карап барды, аннары, үзалдына елмаеп-көлеп:

— Таныш булыйк әле, игелекле агай, минем исемем Искәндәр була,— дия-дия ике кулын сузды.

Карт аның артыннан кабатларга тырышып карады:

— Ис-ис...кан-кан...деер,— диде ул.— Нәрсәне аңлата бу исем? Ниндидер бер таныш төсмере бар бу исемнең.

— Искәндәр, ягъни, Александр, бөек полководец Македонскийны Көнчыгыш халыклары шулай атаганнар,— диде Искәндәр.— Ә синең исемең ничек, игелекле агай?

— Син мине, драуг, Ис-ис-искандер, Тралмакс бабай диярсең. Монда мине һәммәсе шулай дип атый.

Алар, сөйләшә-сөйләшә, асфальт юл читендәге сукмактан тауга таба атладылар. Бераз баргач, яшеллеккә күмелеп утырган тирән ерганак төбенә төшеп җиттеләр, шул ук сукмак белән өскә күтәрелделәр дә, ниһаять, һәр ягын тирән чокыр-ерганаклар хасил иткән тауга менделәр.

— Менә ул безнең халыкның бик күп риваятьләренә кергән Турайд тавы,— диде Тралмакс бабай.— Ул безнең тарихның буеннан-буена килгән, азатлык өчен көрәшләренең үзәге булган урыннарның да иң изгесе. Турайд тавы — Турайд Розасының кабере.

Тралмакс бабай, шактый гына юл килүенә, таулы-чокырлы җир-

дән атлавына карамастан, тигез сулый иде. Дөрес, Искәндәр дә бик үк бирешмәскә тырышты. Ул да инде озакка сузылган авырудан соң ныгый башлаган, әмма аның сулышы Тралмакс бабайныкы кебек тигез түгел, ул барыбер кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, маңгаендагы тир бөртекләрен сөртеп-сөртеп ала, еш-еш сулый иде.

— Халык хәтерендә сакланган риваятькә караганда, Искәндер драуг, әнә шушы юкә төбендә Роза исемле бер кыз ята. Аны без, латышлар, риваять итеп түгел, ә чынбарлыкта яшәгән итеп саныйбыз.

Ул арада юкә төбендәге кара мәрмәр янына ук килеп бастылар. Анда, чынлап та, кайчандыр яшәгән һәм үлгән кешегә таш куелган һәм туган-үлгән еллары да язылган иде.

— 1601 елда бу кальга янында, поляк белән шведлар сугышкан бер вакытта, Турайд замогының хат йөртүчесе якын-тирәдәге мәрхүм бер хатынның нәни баласын асрамага алган. Бу хәл яз көне май аенда була һәм шуңа күрә ул кызның исемен Майя кушалар, ягъни май аенда туган, май кызы... Ниһаять, еллар үтә, кыз үсеп буйга җитә. Якын-тирәдә генә түгел, хәтта тирә-күрше патшалыкларда да андый гүзәл кыз булмый. Шуңа күрә ул кызга яңа исем — Роза исеме бирәләр. Егетләр, билгеле инде, шундый гүзәл кызга үлепләр гашыйк булалар. Ләкин Роза бу замокта бакчачы булып эшләгән Виктор исемле егетне йөрәгенә якын итә. Җәйге кичләрдә алар Гутман куышында очрашалар икән, 1620 елның көзендә алар кавышырга тиеш булалар. Ләкин Майя тарафыннан кире кагылган берәү, поляк армиясеннән качып киткән офицер Якубовский, кызны үзенеке итәргә карар кыла. Ул кызны 6 августта төшке аш вакытында Гутман куышына килергә чакыра. Виктор булып яза. Куышта кызны әлеге явыз һәм аның дусты Скудриц каршы алалар. Кыз каршылык күрсәтмәкче була, ләкин моның файдасыз икәнлеген бик тиз төшенгәч, хәйлә кормакчы итә. Усалларга булачак киявенең бүләге — кызыл ефәк яулыкны күрсәтә һәм: «Бу яулык тылсымлы көчкә ия. Ул кешене яраланудан саклый»,— ди. Якубовскийга шушы яулыкны алырга һәм үзен җибәрергә куша. Ләкин теге усал мондый нәрсәгә ышанмый. Эшнең кирегә борылуын күргәч, Майя әлеге яулыкны муенына урый да Якубовскийның кылычына күрсәтеп: «Ышанмасаң, орып кара»,— ди. Поляк икеләнә, әмма кызның муенына кылычы белән ора... Кыз шундук егыла да ярасыннан аккан кан эчендә үлә. Моны күргәч, Якубовский вөҗдан газабына түзә алмый — урманга кереп асылына. Җинаять урыныннан бакчачы Викторның балтасын табып алалар. Майяны үтерүдә гаепләп, аны Ригага алып китәләр. Ләкин полякның дусты Скудриц, хөкем алдына килеп, эшнең ничек булганлыгын бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Бакчачы егетне азат итәләр...

Искәндәр латыш карты сөйләгән риваятьне, аннары борынгы замокны ничек торгызулары, аның тарихын бик озак тыңлап йөрде. Латыш халкының үз тарихына, иҗатларына булган мөнәсәбәткә сокланды. Шуның белән бергә, үз халкының мондый нәрсәләргә битарафлыкка, дияргә, игътибар итмәвен исенә төшерде. Борынгы бөек Болгар иленең башкаласы булып исәпләнгән Болгар һәм Биләр хәрабәләре аның күз алдыннан, бөтен фаҗигасе белән үттеләр.

Татарстан җирендә генә дә дисталәгән яңа кала, КамАЗ һәм Түбән Кама Нефтехимнең сансыз корылмаларын салдык. Шушы котсыз корылмалар белән мактандык, аларның бөтен тирә-юньгә агу сибеп торучы икәнлеген искә дә кертеп чыгармадык. Ә үз тарихыбызның көзгесе булырдай хатирә-хәрабәләрне яңартырга, аларны эзләп-эзләп табарга, музейлар оештырырга беребезнең дә башына килмәде... Бу якларда, әнә нинди замокларны яңартырга йөзәр мең сум акча таба белгәннәр. Ә без туздырылган, таратылган тарихи истәлегебезнең кыйпылчыкларын булса да җыярга иренәбез. Яңа калалар төзибез, заводлар корабыз. Шулар белән мактанабыз. Табигатькә төзәлмәс

яра салабыз... Хәзер исә тагын да хәтәррәген — гыйфритнең әнә ниндиен үз өебезгә кертергә җыенабыз. Моны күрәләтә эшлибез. Елан авызына үзлегеннән кергән җан ияләре диярсең...

Әле менә Чаллыярның ничәмә-ничә йөз еллар буена йөрткән исеме дә алыштырып җуя яздылар...

Искәндәр борынгы замок башнясының әйләнмәле баскычыннан менеп барганда әнә шул уйларыннан арына алмады.

Ниһаять, алар түгәрәк башняның иң өстәге күперчегенә менеп җиттеләр. «Ярык кайда — җил шунда», дигәнне раслагандай, биредә үтәли җил сызгыра иде.

Җир өстенә инде кичке караңгылык ябырылган, яшеллеккә сыенып утырган Сигулданың анда-санда гына ялтыраган утлары, бу бина биеклегеннән тоник кына күренәләр иде.

Искәндәр югарыга таба, күкнең иксез-чиксез йөзенә карады. Анда инде йолдызлар кабынган иде. «Чынлап та,— дип дәвам итте ул үзенең баягы уйларын,— төн никадәр караңгы булса, йолдызлар шулхәтле якты яна. Әнә бит, күк йөзендәге йолдызлар да җирдәге халыклар кебек: бер ишесе яктырак яна, матуррак җемелди, ә икенчеләре, нишләптер, тоныграк күренә. Аларның бер ишесе ялтырап кешеләргә юл күрсәтә, ә икенчеләре күзгә күренер-күренмәс тора. Ә инде өченчеләре... әнә, әнә бит... Яна да яна, күк йөзенең салкынлыгын җылытырга теләгәндәй эзләр сала-сала, җиргә таба ыргыла... Аларның беришесе ерак, шуңа күрә дә тоныграк күренгән сыман тоела. Ләкин моңа карап алар йолдыз булудан туктамый. Алар барыбер үз тормышлары белән яши бирәләр. Кешеләр йолдызларны үзләренең юл күрсәтүчеләре итеп саныйлар. Һәр кеше үз йолдызын сайлый һәм гомер буена шушы йолдызны якын итеп яши. Теге көнне, дөресрәге, төнне, алар — Искәндәр белән Фирәзә — яшьлек хыялларында гына калган Җиләкле аланда нәкъ шул хакта сөйләштеләр ләбаса. Бәлки, Фирәзә дә күк йөзенә карый-карый үз йолдызын эзлидер...

Шулвакыт Искәндәрнең күз алдына Фирәзәсе килеп басты.

Фирәзә, бәхетле һәм сагышлы елмаюын саклап, үзенең салмак, җиңел адымнары белән, гәүдәсен нәкъ яшьлектәге кебек төз тотып, Искәндәр янында йөри иде. Аның килешле тегелгән күлмәге тәненә ятып, озын һәм шәфкатьле кулларын каплап тора. Сагышлы бәхет төсмерләре аның карашындагы серлелекне көчәйтә генә. Кашларының тигезсезлеге, алар арасындагы тирән җыерчык, сул кашының сизелер-сизелмәс кенә фаҗигале бөгелүе һәм агарынган иреннәре янындагы бер пар сагыш сыры, аның йөзенә хәзер дә сафлык һәм гүзәллек өстәп тора иде...

Искәндәр ихтыярлы-ихтыярсыз: «Син, Фирәзәм, хәзер дә минем өчен яшьлектәге кебек гүзәлләрнең гүзәле булып кала бирәсең. Тик ул вакытта минем өчен бердәнбер гүзәл чәчәк иде. Хәзер инде сине чәчәкләрнең иң гүзәле белән чагыштырып булмый, хәзер син, чәчәктән бигрәк, көзге ак каенга охшагансың! Кышкы салкыннар тимәгән, карала башламаган көмешлеге, алтынсу нурлар сибелгән яфракларның кабатланмас гүзәллеге сыман сокландыргыч син! Син — алдагы тормышымның ышанычлы йолдызы.

Хәзер инде Искәндәр төп-төгәл белә: яшәвеңнең максаты булырга тиеш. Кеше бары тик максатка омтылырга бурычлы. Хәзер аңа зур максатыннан борылырга да, артка чигенергә дә ярамый. Моңа аның хакы юк. Чернобыль корбаннары кичермәс. Шушы максатка ирешкән очракта гына яшәүнең чын мәгънәсе булачак. Шул чагында гына үтә алмаслык карурманнарны, менә алмаслык кыя тауларны яуларга мөмкин. Тормыш каршылыклар кичереп яшәгәндә генә матур вә кыйммәтле ул.

*Дубулты-Малеевка-Чаллыяр. 1986—1989.*

# Фәннур Сафин

## Ышан, кардәш!

Көч-хәл белән таптым сине
Кара төн уртасында.
Һәм сорадык төннән шунда:
— Син бездән куркасың ла?

Нур бөркелде микән бездән,
Әллә соң инде төннән
Караңгырак караңгылык?..—
Төн булды тездән түбән.

Безнең аяк астында төн
Шыңшый, гүя әнчек бер:
Юл бирсәң, ул — әзер, кабат
Илең буйлап йөгерер.

Җилкәләргә пычак аткан
Мәлнеме ул сагына?
Кайтмакчымы бабайларның
Колдан түбән чагына?

Мәскәү астында яшәгән
Күселәр өеренә
Әйләнмәсен ул кара төн,
Ышан, кардәш, көченә!

Бу төн, җанны кытыклаган
Фахишә чәче кебек,
Ничәмә гасыр тирәндә
Сәрхүши йөрде көлеп.

Йөрде-йөрде дә капланды,
Гел эреп килә әнә.
Тыкшыналмый хәзер җанга,
Керә алмый кесәңә.

...Дәвамы булыр көннәрнең
Йолдызлы кичләр генә:
Әверелер яңа кеше
Җир шары кучәренә!

## Сынау

Дөнья буйлап йөзә сынау —
Югалтма мәхәббәтең!—
Кем яхшырак белә халкын,
Хәятен һәм сәнгатен?

Кем белә тарих юлларын —
Бөеген, боекларын,
Хәзер инде тузан баскан
Оҗмахын — туган ягын?

Кем хәтерле таш юллардан
Аккан елга — каннарны,
Сөембикәгә кушылып
Үксегән урамнарны?

Кемнәр белә — ирек өчен
Шәһитләр исемлеген?
Кем эндәшә:
— Сез бездән дә
Бәхетсез мәллә, энем?!

...Тату яшик, вәгъдәләшик,
Бер сүздә булыйк, яле:
Үзебезне дә белмәсәк,
Без кеше микән әле?!

---

Фәннур САФИН (1948) — шагыйрь, «Кеше юлга чыкса», «Сез кемнәр», «Тынлык» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.

## Гомер мизгелләре

### Үксез үксү

Чулпы чеңләгәндәй көлүеңне
Якты бер моң итеп хәтерлим.
Үксүләрдән ачы көлемсерәү
Булып калгансың бит хәзер син.

### Аксакал сүзләре

Җырладылар туегызда: «Әй, икегез, икегез!..»
Сез, чыннан да, Таһир белән Зөһрә кебек идегез!..
Инде бүген хөкемзалга — балалар бүләргәме,
Ятим калган мәхәббәтне күмәргәме килдегез?!

### Ба-ла-а-м!..

Язгы суда йөзеп барам.
Боз өстендә калган балам.

### Шәһре Болгарда

Шәһре Болгар хәрабәләреннән
Үзем куркам, үзем очрашам.
Ул үзенең яшәү хакын даулый
Чиркәү астындагы һәр таштан...

### Мәхәббәт турында поэма

Мәхәббәт турында күп язылды,
Тагын язуйк, димен, каләмгә.—
Мәхәббәт таң җиле канатында
Оча — китә, бирми сәлам дә!

### Ялгызлык

Берүзе калырга теләп, күңел
Ялгызлыкка очар чагында,
Дөньяда тол кала күрмә, диеп,
Озатам аны туган ягыма.

### Балачак

Мин эткәмне көтәм бугай.
Тынлык көтә — нәрсәдер?!—

Тынлык кѳтә... Чынлык шушы:
Тынлык — минем яшьтәдер?

## Йѳрәк сүзе

Очырыгыз мине Азатлыкка,
Бирегез миңа Ирек!
Дүрт йѳз утыз сигез ел катламын
Чыгалмаммыни җиңеп?!

## Яшьлек гомере

Күзем йомсам, синең яшьлек — янда,
Ачсам, алда — тере күләгән.
Үткән кѳннәр ѳчен безнең яшьлек
Үз гомере белән түләгән.

## Сѳйләшү

— Бѳтен халык изге иде элек,
Бәхете дә бүген — бары хәтер;
Батырлык юк, мыскал матурлык юк!
— Минем дә күз начар күрә хәзер...

## «Күрми» уздым

Тѳштә күрдем, кулым суздым,—
Авыр булды тѳнге тѳшем...
Ѳндә күрдем, «күрми» уздым —
Тѳштә елмаймавың ѳчен!

## Соңару

Тѳнгә кердек ил белән,
Бергәләп чыга алдык.
Әнкәйләрне кадерләргә
Әз генә соңга калдык...

## Бәлки...

Чикерткә дә сайрый, сандугач та...
Кырмыска да әле сайрыйдыр?
Һәм бозау да, бәлки, нәрсәнедер
«Көл итәм!..» дип тешен кайрыйдыр.

Бүкәннәр дә әле шуышадыр —
Гүя бѳгәрләнгән елан бер.
Таш бәгырь дә бәлки:
— Ѳзелеп сѳям!..
Оныталмыйм!..— дия торгандыр.

ДРАМАТУРГИЯ

**Рөстәм Мингалим**

# КУНАК КЫЗЫ ГЕЛ КИЛМӘС

ЛИРИК КОМЕДИЯ, ИКЕ БҮЛЕКТӘ

Катнашалар:

| | |
|---|---|
| КАРТ | БӘЧЕЛИ (Василий) |
| ӘБИ | ТӘСЛИМӘ |
| ҖӘГҮР (Егор) | ӘРИНӘ (Орина) |

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

**«Кызлар жыры»ның дәртле көе ишетелә. Пәрдә ачылганда, көй тына. Авыл чите. Яшеллек. Кайдадыр елга күренә. Әби йортта керләр элеп йөри. Ул әле шактый нык һәм җитез. Тамашачыга Бану әбинең өй эче дә күренә. Койма, зур капка, утын өеме, кайдадыр — эскәмия, арт капка — һәммәсе авылча.**

Әби *(тукталып).* Менә бит, ә... Ничә ел узгач... Ике төн рәттән төшемә керде, мәрхүм. Кичә дә, бүген дә. Бер үк төш. Ап-ак эчке киемнән генә. Петровкага таба китеп бара... Әй Әндри, Әндри. Күптән бу дөньядан киттең шул инде... Картаеп та беттем инде. *(Тагын кер элә башлый, әкрен генә җырлый):*

Безнең дә генә урам киң лә урам,
Почтавайлар,
Почтавайлар үтә лә туктамый...
Сез туганкайларны уйлый-уйлый.

**Тәслимә килә, кулына кечкенә чемодан тоткан. Әби кызны күрми.**

Күп төннәрем,
Күп төннәрем үтә лә йокламый.

Тәслимә. Әбием!

Әби *(Тәслимәне күреп).* Кызыкаем, килдеңмени?! Сагынып беттем үзеңне. Йөз ел күрмәгән кебек. Хәзер менә шуны гына әләм дә... Мин сагынганны белдеңме, үзең сагынып килдеңме? *(Әллә каушап, әллә кере — юрган тышлыгы — шактый зур булганга, әби аны тиз генә элә алмый тора).*

**Койма янына ике егет килә. Аларны Тәслимә дә, әби дә күрмиләр.**

Тәслимә *(кыска көйгә шаярып җырлый):*

Аргы яктан килмәдем шул,
Бирге яктан килдем мин.
Син сагынганны белмәдем,
Үзем сагынып...

**Егетләр юри калын тавыш белән җырга кушыла:**

Килдем мин.

Тәслимә *(кычкырып җибәрә).* Әби-и-и!

Әби *(кере җиргә төшеп китә).* Бүреләр! Керемне төшердегез.

Егетләр. Әбкәй, гафу итә күр. Зинһар... *(Тәслимә белән әби бер-берсенә каршы баралар).*

Әби. Итәрмен мин сезне **гафу!** Баланы куркыттыгыз! *(Тәслимәне кочаклап.)* Исән-сау гына **килдеңме,** балакаем?!

Тәслимә *(әбисен үбеп).* Исән-сау килдем шул, әбекәем!

Җәгүр *(Бәчелигә карап.)* Бала...

Бәчели *(Җәгүргә).* Ярый адашмаган, балакай.

Әби. Барыгыз да таза-саулармы?

**Тәслимә.** Тимер кебекләр. Кочак-кочак сәлам әйттеләр. Кочаклап үбәргә куштылар.

**Җәгүр.** Әллә безне дә?

**Бәчели.** Безне дәме?

**Әби.** Тел бистәләре! Керемне төшердегез. Кызымны куркыттыгыз. Хәзер, кызым, хәзер. Чәй куеп җибәрәм. Күңелем сизгәндер. Казанда ашым кайный.

**Җәгүр.** Бану әби!

**Бәчели.** Ашың безнең өчен кайныймы?

**Әби.** Кунагым өчен кайный. Тәслимәм өчен *(Аркасыннан сөя)*. Матуркаем, бөрлегәнем.

**Җәгүр** (шаяртып). Карлыганым.

**Бәчели** (шаяртып). Карлыганнар, бөрлегәннәр — Кай ара өлгергәннәр?

**Әби.** Керемне төшердегез, малай актыклары.

**Тәслимә.** Борчылма, әби. Яңадан чайкармын. Кая, калган керләреңне дә үзем элим әле. *(Егетләрне үртәп, кер савытын берсенә суза, икенчесенә бирә... Кер элә.)*

**Әби** *(егетләргә)*. Иә, йомышыгыз ни? Әйтегез дә юлыгызда булыгыз. Күрмисезмени, оныгым килде. Арып килгән.

**Җәгүр.** Күрәбез шул, әбекәй.

**Бәчели.** Их, әбекәй...

**Әби.** Күрәсезме?! Хәзер күрмәссез. Кызым, Тәслимә. Бар әле, ашны кара. Ташый күрмәсен. Хәзер чәй дә өлгертеп җибәрәбез.

**Тәслимә.** Булды, соңгысын эләм *(соңгы керне элә)*. Ә бусы *(төшкән керне карап)* пычранмаган. Мондый чирәмдә кер пычранамыни. Шулай да яңадан чайкармын. *(Җиргә төшкән ак керне ала, чемоданын тота. Кереп китә...)*

**Егетләр кызга карап кала.**

**Тәслимә өйдә — чемоданын бер читкә куя, көзгә ала, чәчләрен рәтли h. б.**

**Аш-су бүлмәсенә керә. Егетләр әби янына керергә омтыла.**

**Әби** *(егетләргә карап)*. Иә?

**Җәгүр.** Бу... Шул Тәслимәме? Килгән иде... Үзгәргән...

**Бәчели.** Күптән килгәне юк иде...

**Әби.** Нәкъ шул Тәслимә инде. Нәкъ үзе. Йомышыгыз ни?

**Җәгүр.** Печән кибәнгә кунды. Ашлык амбарга тулды...

**Әби** *(аны бүлеп)*. Тулып бетмәде шул әле *(эскәмиягә утыра)*.

**Бәчели.** Тулып бетәр! Эш аз калды. Җәгүр яшьти белән без бүген ял итәбез *(әби янына киләләр)*.

**Җәгүр.** Хуҗа рөхсәте белән. Сер итеп кенә әйтәм, әбекәй. Бүген хуҗа үзе дә ял итә. Күрше колхозга илтеп кайттым.

**Әби.** Булмас, Сандыр эш белән йөридер анда. Башында бер-бер планы бардыр.

**Бәчели.** Бардыр, бардыр.

**Җәгүр.** Анысы да бардыр... Ни... Әбкәй...

**Бәчели.** Без, әбкәй... Сиңа тагы бераз утын кирәк булыр дип уйлыйбыз.

**Җәгүр.** Әйе, шуны сөйләшергә килдек.

**Бәчели.** Кереп... Шуны киңәшләшеп алыйкмы әллә?

**Әби.** Китергәнегез җитәр. Былтыр да җитәрлек булды. Анысы өчен рәхмәт. Колхозга рәхмәт. Яшьләргә рәхмәт. Бик ярдәм итәсез. Ярар, инде барыгыз... Тәслимәм килгән бит. *(Кереп китә. Бәчели әби киткән якка бара. Тәслимә касә чайкаган суын сибә, су Бәчелинең битенә элэгә.)*

**Җәгүр** *(эскәмиягә сузылып көлә)*. Әләктеме?!

**Бәчели** *(битен сөртә. Эскәмиягә килеп утыра)*. Әләкмәде. *(Тәслимәләр ягына карап)*. Утыныгыз җитмәс кебек?!

**Җәгүр.** Җитмәс кебек, әбекәй.

**Әби.** Җитәр кебек, балакай.

**Бәчели** *(шаяртып җырлый)*:

Әбекәй!
Якын дуслар идек ләбаса,
Бүген безне нигә куасың, куасың?
Кунак кызы сыйган өйгә,
Кунак кызы сыйган өйгә
Җәгүр белән Бәчели генә сыймасмы?
Җәгүр белән Бәчели генә сыймасмы?

**Әби.** Бәбекәй!
Бүген генә куам ләбаса,
Һич юк иде болай куасым, куасым.
Ничек инде аңламыйсыз,
Кунак кызы сыйган өйгә
Җәгүр белән Бәчели бергә сыймасын?
Җәгүр белән Бәчели бергә сыймасын?

**Бәчели һәм Җәгүр.**
Әбекәй!
Бәлки, кунак кызың өчен дә
Яхшы булыр безне кумавың, кумавың.
Әле, бәлки, сайлап алыр
Йә Җәгүрне, йә Бәчелине...

**Җәгүр** *(үзе генә)*.
Бәлки, мине сайлап сөяр кунагың!

**Бәчели** *(үзе генә)*.
Бәлки, мине сайлап сөяр кунагың!

**Бәчели, Җәгүр** *(икесе бергә)*.
Бәлки әле сайлап сөяр кунагың!

**Әби** *(әллә шаярып, әллә ачуланып)*:
Шулаймы?
Чыгармагыз минем ачуны, ачуны!

**Бәчели белән Җәгүр.**
Ачулана күрмә, әбекәй, әбекәй.

**Әби.** Аңа диган яр түгел сез,
Оныгыма пар түгел сез,
Берегез зур, икенчегез — балакай!

*Кереп китә).*

Берегез зур, икенчегез — бәләкәй!

Бәчели. Карале, Җәгүр. Бәләкәе мин булдыммы? Синме? Бу уй бер дә башыма килгәне юк иде.

Җәгүр *(тагын көлә башлый).* Эләктеме?

Бәчели. Эләкмәде шул. Юк, әләгәчәк бу кыз миңа. Күңелем сизә.

Эби *(бүлмәдә, сөйләнә).* Хәзер, кызым. Ашап-эчеп алырбыз да... Теләсәң ял итәрсең. Теләсәң су буйларын карап кайтырбыз. Әй, суларның яктылыгы! Көннәрнең матурлыгы! *(Кызның чемоданын каядыр күчереп куя. Ашсу бүлмәсенә китә).*

Җәгүр *(паузадан соң).* Синең күңел дөресен сизми.

Бәчели. Ник?

Җәгүр. Чөнки ул дурак.

Бәчели. Нәрсә? *(Үпкәләбрәк һәм ачуланыбрак та).* Син нәрсә?

Җәгүр. «Уралта да бер уй уйлый,
Яшь күңел дурак бит ул»,

— дип җырлыйлар. Ишеткәнең бармы шундый җырны?

Бәчели. Булса соң?

Җәгүр. Шул дөресме?

Бәчели. Дөрес булса ни?!

Җәгүр. Ә менә минем күңел — дурак түгел. Минем күңел, яшьти, дөресен сизә... Тәслимә минеке булачак.

Бәчели. Җәгүр! *(Эскәмияне тартып ала. Җәгүр егылып кала.)*

Җәгүр. Нәрсә, яшьти?

Бәчели. Минем мылтык бар. Иодрык хәтле ядрәләр белән корылган.

Җәгүр. Атасыңмы?

Бәчели. Ике дә уйлап тормыйм. Минем күңел дурак, үзең дә әйттең... *(Эскәмия белән селтәнә. Җәгүр чигенә. Аш-су бүлмәсеннән Тәслимә чыга. Өстәл әзерли.)*

Җәгүр *(эскәмиянең икенче башын тотып ала).* Яшьти, синең куян атканың бармы?!

**Карт килә. Ул егетләрнең сүзен ишетеп килә, эскәмияне тота.**

Бәчели. Кеше атканым юк. Сине атам.

Карт. Җирне бүләсезме, күкнеме?

Бәчели. Җәгүр яшьти бозылды әле. Күкне дә, җирне дә үзенә генә алмакчы. Минем белән санлашмый башлады. Шуның өчен үзен атарга уйлыйм.

**Тәслимә тагын аш-су бүлмәсенә китә.**

Карт. Уйнап та алай сөйләшмәгез *(егетләр кулыннан эскәмияне суырып ала)!*

Бәчели. Бабай, менә син кешегә аткан кеше инде...

Җәгүр. Бану әбидә бераз сыйланган идек... Җитте, дибез, һаман сыйлый да сыйлый.

Карт *(Бәчелигә).* Аттым. Миңа да аттылар. Мин син түгел, миңа атучылар Җәгүр түгел иде... Так, что...

**Әби белән Тәслимә чыгып, өстәл әзерлиләр.**

Җәгүр. Бәчелигә артыграк булды.

Карт *(Бәчелигә карап).* Артык булгач, кайтып ятарга кирәк. *(Өйгә юнәлә.)*

Җәгүр. Китәбез, бабай. Ятабыз. (Китә башлый).

Карт. Әбиегез үзе генәме?

Бәчели *(Җәгүргә ияреп).* Үзе генә.

Карт *(йортка керә, ярты лаш ачык калган ишек каршында туктый).* Галиябану!

Җәгүр *(Бәчелигә).* Әйдә булмаса кибеткә... Тәслимәгә кагылмасаң, үзем алам.

Карт. Галиябану!

Бәчели *(тукталып).* Җәгүр! Әйтте диярсең, бабай әбине атарга йөри.

**Егетләр читтәрәк торып картны күзәтә.**

Карт. Галиябану! *(Ул, әлбәттә, өйдә Бану әби үзе генә дип белә, җырлый):*

Билемдәге ак билбавым
Тормый кыстырган җирдә.

**Тәслимә чыга, кемдер килүен әбисенә әйтергә уйлый... Тик җырга игътибар итеп, тукталып кала.**

Карт. Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым, иркәм,
Чыкмый чакырган җиргә.

Җәгүр. Шаярып җырлавымы? Әллә...

**Тәслимә бу хәлгә аптырабрак та тора булса кирәк. Бәлки шактый матур яңгыраган җырны бозасы килмидер... Экрен генә ишеккә бара... Аш-су бүлмәсеннән Бану әби чыга, картның тавышын таный.**

Карт.
Үзе чакыра, үзе кача
Галиябану, сылуым, иркәм...

Бәчели. Валлаһи, ата... Гашыйк булган, башы югалган. Минем хәлдә калган. Әйдә *(китәләр).*

Эби. Әй, карт җүләр, карт җүләр...

Тәслимә *(картка каршы чыгып).* Әйдә, бабай, кер.

Эби *(ул да чыгып өлгерә).* Уз, әй-

дә. Көпә-көндез... Җырлап тора. Кайчан сиңа акыл керер?

Карт. Үсә төшкәч, үсә төшкәч...

Әби. Кеше әллә нәрсә уйлар... Кызым килде бит, Тәслимәм.

Карт *(күрешеп)*. Исәнме, кызым. Ай-һай озак көттердең. Әбиең үзеңә инде үпкәләгән иде.

**Өйгә керәләр.**

Тәслимә. Үпкәләмәскә кирәк, бабай. Дөнья бит бу. Мәшәкате күп.

Карт. Мин дә шулай дим дә. Галиябану аңлап җиткерми ул дөньяны.

Тәслимә *(картка)*. Өстәл янына рәхим ит, бабай. *(Аш-су бүлмәсенә китә).*

Әби. Утыр, Исмәгыйль абзый. Дөньяны син аңлап җиткермисең аны. Һаман малайлар кебек җырлап йөрисең.

Карт *(утырып)*. Үзең дә җырлыйсың...

Әби. Синең ишек төбендә җырламыйм.

Карт. Алай ук кистереп әйтмә. Кем белә...

Тәслимә *(картка аш чыгара)*. Тыңлап торам... Тавышыңны хәтерлим дә, хәтерләмим дә кебек. Үзеңне күргәч, кинәт исемә төште. Мин әле университетның икенче курсын гына бетергән идем. Өстәл дә шушы иде.

Карт. Мәҗлес?

Тәслимә. Яшьләр, картлар... кара-каршы җырладылар. Мәҗлес ахырында син «Шахта» көенә гармун уйнап, җырладың... Күзләреңдә яшь иде. Шуны күреп, минем күзгә дә яшь килде. Яшемне кеше күрмәсен дип, йортка чыгып киттем. Менә, бабай, ипи.

Карт. Алайса, укытучы булдың?

Әби. Укытучы булды, балакай.

Тәслимә. Булдым дияргә иртәрәк. Документ кына алдым. Ә балаларны әлегә тыңлата белмим. Мәктәптә узган практика дәресләре шуны күрсәтте. Инде куркып торам.

Әби. Син курыкма, кызым! Өйрәнерсең!

Карт. Кайда инде ул сине куркыткан балалар?

Тәслимә. Казанда.

Карт. Шәһәр балалары... Башка алар... Син авылга кил. Урман-кырларда йөгереп, үлән арасында кайнап, иген кырларында эшләп үскән балаларның күңеле үзенә башка. Алар сине тыңлар, аңлар.

Тәслимә. Әнием дә шулай киңәш итә. Район мәктәбендә урын бар...

Әби *(аны бүлеп)*. Уйла әле, кызым. Син безнең авылны уйла.

Карт. Син уйлама да! Кил!

Әби. Әйе. Ул хәтле инде... Район мәктәбе дип...

Тәслимә. Анда Әринә исемле дус кызым бар. Керәшен кызы. Инде бер ел укытты. Уку-укыту шартларын бик мактый.

Карт. Әбиеңне тыңла. Авылыбыз зур, үзе матур. Балалар күп, укытучылар кирәк. Так что... Урып-җыю буенча беренче урында торабыз...

Әби. Кил, кызым. Миңа иптәш булырсың... Мәктәп — бакча эчендә, сандугачлар тавышы эчендә.

Карт. Директоры — алтын кеше, первый сорт керәшен. Үзе җырлый, үзе скрипкада, гармунда уйный... Өздерә инде.

Тәслимә. Сандугачларыннан өйрәнгәндер ул.

Карт. Авылдашларыннан, керәшеннәреннән өйрәнгән.

Әби. Суына бит, ашагыз әле. Җәгүр белән Бәчелине өйгә кертмичә җибәрдем. Үпкәләп киттеләр микән...

Карт. Ник кертмәдең?

Әби. Тәслимәмә күз тидерерләр дип курыктым.

Тәслимә *(алтыраудан көлеп)*. Сиңа кашык китермәгәнмен ләбаса, бабай. Әйтмисең дә. Хәзер. *(Аш-су бүлмәсенә китә.)*

Әби. Мин дә күрми торам.

Карт. Ашап кына килдем.

Әби. Әллә кайчан узган мәҗлесне хәтерли бу кыз.

Карт. Хәтерли.

**Музыка — «Шахта» көе... Карт әкрен генә җырлый.**

> Шахтер егет күмер кисә
> Вак-вак итеп кисәген...

**Тәслимә килә. Җыр тыңлый, кушыла.**

> Гомерем булып, таш басмаса,
> Ташламам, җан кисәгем.

Әби *(җырдан соң)*. Җылап утырдыңмы?!

Карт. Җыласа ни... Сәбәбе булгандыр. Так что...

Тәслимә *(картка кашык биреп)*. Менә. Әйдә, җитеш әле, бабай.

Карт. Рәхмәт. *(Уйланып.)* Җырлап утырганмын... Узган гомерләр искә төшкәндер. Күңел тулгандыр...

Тәслимә. Көжмәдә җырлау гаеп түгел, бөтенесе җырлый.

Әби. Җырлау гаеп түгел. Ә җылау?! Җебеп утыру...

Тәслимә. Әби-и?!

К а р т *(Тәслимәгә).* Бер күрмәгәне мин булдым. Яратмый, кызым, мине Галиябану. Исемем Исмәгыйль булганы өчен яратмый.

Т ә с л и м ә. Әз генә дә?

К а р т. Юк. Алыштырам паспортны. Хәлил дип яздырам.

Э б и. Исмәгыйль абзый! Чамалап шаяр. Бала әллә нәрсә уйлар.

К а р т. Уйламас. Әнә ул хәзер нинди булган.

**Капкага Җәгүр белән Бәчели килә.**

Б ә ч е л и. Басып керик. Сизми дә калсыннар.

Җ ә г ү р. Тс-с-с!

Б ә ч е л и. Син алданмы, минме?

Җ ә г ү р. Син. Әби тибеп чыгарырга уйласа, синең артка эләгүе хәерле.

К а р т. Тәслимә хәзер уенны чыннан аерырлык.

Б ә ч е л и. Ишек төбенә басабыз да җырлыйбыз. Исмәгыйль бабай шулай керде. Бергә башлыйбыз.

Т ә с л и м ә. Тормышта чын белән уен бик чуалган бугай шул.

**Ишек янына ук киләләр. Бәчели, килешенгәнчә, команда бирә — бер, ике, өч. Дәртле җыр башлыйлар. «Бану әби, туганай» җыры:**

Иортларында керләре,
Тәрәзәдә гөлләре...

**Кинәт әби белән Тәслимә торып басалар. Әби, егетләрне ачуланырга уйлап булса кирәк, ишек ягына бер-ике адым ясый да тукталып кала... Тәслимә елмаеп тора. Карт өстәлгә терсәк чәнчеп, башын кулына куйган, нидер уйлана.**

**Җыр дәвам итә:**

Гөлләр аша карап кына
Күрә икән кемнәрне?
Бану әби, туганай,
Бану әби, тулган ай —
Хәтерли ул кемнәрнедер
Каршылаган көннәрен.
Ачык икән ишеге,
Иркен икән түрләре...
Түрләренә тукталып, ул
Уйлый икән кемнәрне?
Бану әби, туганай,
Бану әби, тулган ай —
Хәтерли ул кемнәрнедер
Каршылаган көннәрен.
Турагандыр икмәген,
Юкадыр телемнәре...
Телем-телем теленәдер
Аның да көнелләре.
Бану әби, туганай,
Теленә ул тулган ай —
Хәтерли ул кемнәрнедер
Каршылаган көннәрен.

**Әби йөзе белән залга борылмый, бәлки аңа җыр авыр тәэсир иткәндер, аш-су бүлмәсенә китә. Аның артыннан Тәслимә дә китә. Ишеккә карт бара.**

К а р т. Нәрсә, бозык тәлинкәләр? Керегез. Әллә күтәреп керткәнне көтәсезме? *(Урынына барып утыра).*

Җ ә г ү р. *(Ишектән кереп).* Ә хуҗалар? Бану әби кайда?

К а р т. Озата китте, утырыгыз. Мин монда ярты хуҗа, әбиегезгә өеннән зур мунча салып биргән кеше мин... Так, что... Әллә минем белән генә күңелсез булыр дисезме?

**Пауза. Җәгүр тәрәзә янына барып баса.**

Иоклап булмадымы?

Җ ә г ү р. Иоклап булмады.

Б ә ч е л и. Кунак кызын якыннан күрәсе килде.

К а р т *(елмаеп).* Китте шул.

Җ ә г ү р. Ничек инде...

Б ә ч е л и. Кай арада китте?

К а р т. Юлы ашыгыч булган. Тизтиз чәй эчте дә вакыты җитте. Аннан... Китте... Шулай инде ул, вакыт җитсә.

**Бәчели икенче тәрәзә янына барып баса. Егетләр бер-беренә карап, берни дә аңламыйча торалар, көлә башлыйлар. Тагын да ныграк көләләр...**

Җ ә г ү р. Әй, Исмәгыйль бабай! Исмәгыйль бабай!

К а р т. Нәрсә булган Исмәгыйль бабаңа?

Б ә ч е л и. Бер үзең җырлап утырасыңмы?

К а р т. Җырламыйм... Так что...

**Егетләр тагын көлешә башлый. Алар үз хәлләреннән һәм карт хәленнән дә көләләр бугай.**

**Аш-су бүлмәсеннән Тәслимә чыга. Егетләр кинәт тынып кала.**

Т ә с л и м ә *(кулындагы ризыкларны өстәлгә куя. Өстәл янына урындыклар китерә).* Рәхим итегез, утырышыгыз... *(Карт янына утыра.)*

Б ә ч е л и *(кыз янына утырып).* Бик кунакчыл кыз икәнсең...

Т ә с л и м ә. Әби кушты.

Җ ә г ү р. Нәрсә кушты? *(Утыра.)*

Т ә с л и м ә. Сезгә хөрмәт күрсәтергә. Дөньяның бер дигән егетләре, ди.

Б ә ч е л и. Дөрес әйткән.

К а р т *(егетләр белән таныштыра).* Бусының исеме Җәгүр, бусы — Бәче-

ли. Бәчели Җәгүрдән яхшырак. Җәгүр Бәчелидән әйбәт... Авылда болардан әйбәтләре дә — муеннан. Так, что...

Җәгүр. Рәхмәт, бабай.

Бәчели. Бик зурладың.

Әби *(аш-су бүлмәсеннән килә)*. Минем егетләрне кыстамыйсыз! Балалар!

Тәслимә. Кыстыйбыз. Ашы бетсә ите бар, хәзер кайнар чәй чыгар... Бәчели абый, Җәгүр абый...

Җәгүр. Ашарга дип кенә килмәдек.

Карт. Ник килдегез?

Бәчели. Ашарга дип кенә килдек. Үзең, бабай... ник килгән идең соң?

**Карт ни өчендер Әбигә карап тора.**

Әби *(аның карашына игътибар итеп)*. Нәрсә? *(Шул арада ике егет кыз каршына ике шоколад куялар.)*

Карт. Әллә... Мәҗлес булгач, мәҗлес булсынмы дим?

Әби. Мин дә шулай дим шул. *(Стена буенда торган сандык янына бара.)*

Бәчели, Җәгүр. Кирәкми, әби...

Җәгүр. Без алып килдек аны. *(Шешә чыгарып куя.)*

Бәчели *(шешә куя)*. Бер кая булмаган, бүген генә, безнең кибеткә генә кайткан йөзем суы. Кунак хөрмәтенә.

Карт *(Тәслимәгә)*. Кызым, бар әле... Әбиеңнең күптән эшсез яткан рюмкалары булырга тиеш. *(Тәслимә рюмкалар китерә. Әби сандыктан төргәк ала, төргәктән гармун чыгара...)*

Карт *(гармунны күреп)*. Юк, юк. Гармун уйнамыйм.

Әби. Уйна инде?! *(Кулына гармун тоткан килеш, сандык янында тора.)*

Җәгүр. Ал гармунны, Исмәгыйль бабай!

Бәчели. Җибәр сайратып!

Карт. Бүген... Юк... Бармакларым тыңламый. Агач кебек катып торалар. Соңгы вакытта әллә нәрсә булды... Куй аны, куй, Галиябану.

**Әби гармунны куя. Беразга тынлык урнаша. Һәркем җайсызрак, киеренкерәк бер халәттә.**

Әби. Исмәгыйль абзый, алып биримме?

Җәгүр. Уйна әле, Исмәгыйль абзый?

Карт. Әйттем бит. Кулларым тыңламый әле. Агач кебек катып торалар. Әллә нәрсә булды үзләренә.

Бәчели. Бер генә көй?

Тәслимә. Минем өчен генә.

Карт. Синең өчен... уйнарбыз... так, что...

Тәслимә. Кайчан?

Җәгүр *(картка)*. Кунак кызы гел килмәс.

Бәчели. Әллә тегесен... берәрне генә чеметеп куябызмы, әби. Синдә бардыр ул.

Әби. Чеметермен менә мин сине!

Бәчели. Тәслимә?

Тәслимә. Мин эчмим шул, Бәчели абыкаем.

Җәгүр. Нигә?

Тәслимә *(урыныннан торып)*. Эшләрем күтә... Сез төшергән керне чайкап эләсем бар.

Әби. Исмәгыйль абзый, алып кит син... Гармуныңны... Күптән монда ята... Бөтенләй... уйнарга онытырсың.

Карт. Монда торсын. Мин бит ул монда булган өчен... Киләм...

**Тагын тынлык. Һаман барысы да җайсызрак, киеренкерәк бер халәттә.**

Бәчели. Бабай, бу — теге поп гармуны бит. Әллә мәйтәм... Син побын дөмектереп, гармунын...

Әби *(урыныннан торып)*. Бәчели! Куып чыгарам.

Карт. Син үзең поп гармуны!

Җәгүр. Дөрес, бабай!

Бәчели *(шаярып Җәгүрнең иңбашына суга)*. Нәрсә дөрес?

Җәгүр *(гармун ягына күрсәтеп)*. Соң?.. Гармунны әйтәм... Попны...

Әби *(ачуланып)*. Болай кыланып утырсагыз! Кая әле минем уклау. *(Аш-су бүлмәсенә китә.)*

Карт *(урыныннан торып)*. Галиябану?!

Бәчели. Әби чәй китерә.

Тәслимә *(утыра)*. Нинди поп ул? Нинди гармун?

Җәгүр *(торып)*. Бетә икән башлар.

Бәчели. Күптән булган хәл ул, Тәслимә, революция көннәре алдыннан... Моннан алтмыш чакрымераклыкта Кләүбе дигән авыл бар. Урыс авылы. Боларның чиркәвендә яшь поп эшли башлаган. Башта попның үзен дә, тавышын да, эшен дә авыл бик яраткан. Ә бервакыт сүз чыккан: имеш, яшь поп татар икән, төннәрдә күрше авыл мулласына бара икән, татар динен тота икән, дигәннәр *(барып гармунны ала)*.

Җәгүр *(Тәслимәгә)*. Жулик дигәннәр.

Бәчели. Жулик инде...

Карт *(ачуланып тора, йөри)*. Жулик түгел! Ул бит поплыкка укып

килгән кеше... *(Йөри).* Хрестиан дине каршында аның күңел чисталыгын шик астына куючылар, яшь попның чын йөзен фаш итәргә теләүчеләр булган. Аны үтерергә үк теләүче изгеләр табылган: фанатиклар...

Бәчели. Менә шул, көннәрнең берендә, кичке эңгер төшкәч, яшь поп кайдадыр эчеп, «Шахта» көенә уйнап, татарча җырлап, атын атлатып кына, авылга кайтып кергән. Дини картлар ашыгыч рәвештә киңәшкә җыелган. Төнлә попның өенә килгәннәр. Әкрен генә тәрәзәне шакыйлар икән, аннары ныклап — ишекне... Поп арт тәрәзәдән — урамга... Тиздән аның дөбердәп кузгалуы, атын куалаган тавышы гына ишетелеп калган. Шулай яшь поп та, аның гөнаһлы гармуны да югалган. Яшь поп урынына килгән карт поптан Келәүбеләр уңмаган. Аннан тагы бер карт поптан уңмаганнар. Яшь попларын сагынып эзли башлаганнар... Тапмаганнар... Җитмәсә — аның алып качкан яхшы аты бер байныкы, кыйммәтле арбасы икенче байныкы, акчасын да түләп өлгермәгән булган.

**Яшьләр таралып баскан. Карт — бер якта.**

Әби *(уклау тотып килә).* Сез ник карт кешене болай мыскыл итәсез?

Тәслимә. Ул поп чынлап та татар булганмы?

Бәчели. Хикмәт шунда, ул поп безнең хөрмәтле Исмәгыйль бабай булган. *(Әбидән качып йөри. Бер җай табып, гармунны куя.)*

Әби. Чыгып кит, Бәчели...

Җәгүр. Булган, диләр.

Бәчели. Келәүбе авылыннан ике урыс миңа моны чукынып раслады. Петровка базарында.

Әби *(Бәчелине куып).* Чыгып кит!

Җәгүр *(әбинең уклавын алырга чамалый).* Бир, әби. Үзем кыйныйм мин аны.

Бәчели *(әбидән кача, өстәл тирәли йөри).* Әби? *(Картка күрсәтеп.)* Соң, үзеннән сорагыз. Үзе белән идек.

**Җилкәсеннән алып Җәгүр Бәчелине утырта.**

Әби *(Бәчелигә).* Сыртыңны тунап чыгарам.

Тәслимә. Бир, әби. Миңа бир. Үзем туныйм *(Әбинең уклавын ала.)*

**Әби, арып, утыра. Җәгүр белән Тәслимә Бәчели янына утырганнар. Бәчели башын бик түбән игән хәлдә... Уңайсыз тынлык. Тәслимә уклау белән үрелеп, башкалар күрмәгән арада, Бәчелинең башын күтәрә.**

Карт *(әкрен генә килә).* Петровка базары... Ике урыс... Раслаган... Ә закон?! Раслаганмы? *(Ничектер кинәт йомшарып, урынына утыра.)* Әллә кай заманнарның әкиятләрен искә алып, өй ямен җибәреп... Нәрсә инде? Егетләр, кызлар? Нәрсә инде бу?

Әби. Нәрсә инде бу? *(Пауза).*

Карт *(үз-үзенә җырлагандай, моңлы җыр башлый — «Түгәрәк күл генә...» җыры):*

Үзәннәрдә якты көннәр күрдек,
Көннәреннән, көннәреннән
якты ла күл күрдек.
Көннәреннән, көннәреннән
якты да күл күрдек.

Кушымта *(Җырга башкалар кушыла):*

Түгәрәк күл генә —
Үрдәк өчен юл гына,
Юлың булса янәшәмдә,
Кулларыңа — кулгынам.

Карт.

Күлләр күзе иде ике үрдәк,
Күлләр күзе,
күлләр күзе лә пар үрдәк.
Күлләр күзе,
күлләр күзе икән дә пар үрдәк.
Түгәрәк күл генә —
Үрдәк өчен юл гына.
Юлың булса янәшәмдә,
Кулларыңа — кулгынам.

*(Карт урыныннан тора. Башкалар тынып кала, карт ялгыз җырлый).*

Китәме үрдәге,
Саргая ла камышы. *(Китә.)*
Камышларга җил киселә,
Җанга үтә тавышы.

*(Башкалар да әкрен генә таралышалар. Караңгылана... Китеп барган картның ялгыз җыры гына ишетелә.)*

Камышларга җил киселә,
Җанга үтә тавышы...

Караңгылык.
Кичеш.

**Яңа күренеш. Кич. Бану әби өе, өйдә ут яна. Өй эче тамашачыга күренми. Тәрәз пәрдәләре дә ябык. Кер бавында Тәслимә яңадан чайкап элгән кер генә калган.**

Бәчели *(ерак түгел генә тора. Әкрен генә, узалдына).*

Элгән кере бавында,
Чыкмый гына алырга.
Шулай булгач, сиңа, Бәчели,
Кала китеп барырга.

Шунысы әйбәт, кызның күңел төбендә миңа карата нидер барлыгы сизелде. Безгә укытырга да килсә?!

Үзе белән генә тәгаенрәк сөйләшеп булмады шул... Җәгүр генә комачаулады. Әби генә комачаулады. Бабай гына комачаулады *(китә).*

**Койма янына Җәгүр килеп туктый.**

Җ ә г ү р. Әһә, алмаган... *(Үзалдына, әкрен генә).*

Элгән кере бавында,
Чыгар әле алырга.
Шулай булгач, сиңа, Җәгүр,
Кирәк көтеп калырга...

Шунысы шәп, кызның уенда миңа карата нидер барлыгы сизелде. Әгәр безгә укытырга килсәме?! Үзе белән генә элегә сөйләшеп булмады. Бәчели генә комачаулады. Бабай гына комачаулады. Әби генә комачаулады.

**Әкрен генә ишек ачыла. Җәгүр яшеренә.**

Ә б и *(комган тотып чыккан).* Әй, дөньялар матурлыгы! Мәңге яшәп туймаслык... Сөйлиләр шул. Поп булган диләр. Булыр да, әллә нинди язмышлар бар... *(Эленгән керне тотып карый, китеп югала... Яңадан килә.)* Килер Тәслимәм, килер. Мондый авылга ничек килмәсен? Ялгыз яшәү кыенрак шул... Ярый әле күршеләр бар... Ничек инде Исмәгыйль абзый поп булсын? Булмас. Юкны сөйлиләрдер... *(Өйгә кереп китә).* Юкны гына сөйлиләр...

Җ ә г ү р *(яшеренгән җиреннәр чыгып).* Котым очты. Керен алып китә дип торам. *(Бераз ишеккә, тәрәзәләргә карап торганнан соң, бауга эленгән кер белән сөйләшә.)* Аппагым, китә күрмә. Шунда гына эленеп тор. Җилфер-җилфер килеп тор. Әкрен генә кибеп тор. Тәслимәне чакырып тор. Чыгасын да белеп тор. Чыкмас микән? Әйтмисең?! Син — кибәсең генә?

Кич тә чыгар көткәне
Көтә белгән кешегә.
Төнлә чыгар көткәне
Көтә белгән кешегә.
*(Паузадан соң):*
Бу көтүгә чыкмый калса,
Шайтан керсен төшенә...

Эленеп кенә... кибәбез шул. Авыр безнең хәлләр, аппагым. Инде безне баудан төшерүче булмас кебек. Бәлки булыр да. Көтик әле. Көтик.

**Кинәт гармун тавышы — «Кызлар җыры»ның дәртле көе ишетелә. Җәгүр яшеренеп калырга җыена. Гармун тавышы якыная, көчәя... Караңгылык.**

ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

**Беренче бүлек дәвамы, шул ук — кичке күренеш.**

Җ ә г ү р *(өй янында, тәрәзәдән карый).* Чыкмады. Карчыклар җыелды... *(Китәргә җыена.)*

**Ишек ачыла. Тәслимәнең кычкырып көлгәне ишетелә. Җәгүр кая яшеренергә дә белми тора. Ниһаять урын таба, баудагы кер артына чүгәли.**

Т ә с л и м ә *(ишектән чыккан уңайга).* Әй, Ауди әби! Җәгүрегез бушлай да кирәкми. Юньле булса, ул күптән өйләнгән булыр иде... Бер аягы кыскарак сыман йөри, бер күзе кылыйрак бугай. Әле борыны да кыеграк. *(Үзалдына нидер көйли...)*

**Баудагы керне ала башлый, качып торган кешене шәйләп ала... Кулындагы керне аның башына каплый...**

Әби-и-и! Карак бар, карак! *(Атылып өйгә керә.)*

Җ ә г ү р *(эленеп торган керне тизтиз башыннан ала, үзалдына сөйләнә).* Бер аягы кыскаракмы? Күзе кылыйракмы? Борыны кыегракмы? *(Кулындагы кергә.)* Киттек, аппагым... Исталеге булырсың... *(Йөгереп китә.)*

Ә б и *(чыга).* Болай булганы юк иде.

Т ә с л и м ә *(артыннан чыга).* Әбекәем, йөрмә анда?

Ә б и. Җә, кычкырма. Кеше җыясың бит. Мондый хәлнең булганы юк иде. Ярар, үзебезнең кеше алгандыр. Рәхәтен күрсеннәр.

Т ә с л и м ә. Керик, әби, керик... Әйдә.

**Кереп китәләр. Беразга тынлык урнаша.**

**Әкрен генә караңгылана... Бану әбинең тәрәзә утлары гына янып тора. Бик ерактан гармун моңы ишетелә... Бу хәзер өйдә ниндидер тормыш баруга — күпмедер вакыт үтүгә дә ишарә. Гармун тына... Бану әби өеннән керәшен татарларының моңлы озын көе ишетелә башлый. Анда шулай кычкырмыйча, сабыр гына, сак кына итеп карчыклар җырлый:**

Сузылып кына суга, һай, төшәрбез,
Колачларны җәеп лә йөзәрбез...

**Карт килә. Ул җыр тыңлый.**

Әнә карабодай ла тарата,
Күңелләрем сезне лә ярата.
Кычкырыр ла, кәкүк, сайрар,
былбыл,
Шул чагында ничек лә түзәрбез...

**Җәгүр белән Бәчели килә. Сиздермичә генә карт янына җитәләр. Карчыклар җыры дәвам итә.**

Әнә карабодай ла тарата,
Күңелләрем сезне лә ярата.

Бәчели *(картка)*. Менә бу инде әйбәт түгел.

Җәгүр. Бер дә яхшы түгел.

Карт *(егетләрнең килүенә артык игътибар бирмичә генә)*. Бик яхшы җырлыйлар.

Бәчели. Төнлә кеше тәрәзәсеннән карап йөрүне китап мактамый бит, бабай. Күзәтүче, ди.

Карт *(карчыкларның яңадан җырлавын көтеп)*. Мин тыңлыйм. Так, что...

Җәгүр. Тыңлап йөрүчеләрне шпион ди китап.

Карт *(үзалдына)*. Бәлки тагы җырларлар әле. Кая юл тоттыгыз?

Җәгүр. Кызлар янына.

Бәчели. Әйдә безнең белән.

**Өйдә тагы җыр башлана:**

Базарларга барсаң, ал яулык ал,
Ал яулык ал миңа ла, шәл түгел.

Бәчели *(бабайга)*. Киттек!

Карт. Тыңлагыз!

*(Җыр дәвам итә):*

Әнә карабодай ла тарата,
Күңелләрем сезне лә ярата...

Җәгүр. Ярамый, киттек.

Бәчели *(картның иңенә тотынып)*. Әйдә, бабай, әйдә.

Карт *(иңеннән Бәчелинең кулын кагып төшерә)*. Тыңла, урыс малае...

Бәчели. Урыстан оста чукындым, бабай. Барыбер керәшен диделәр.

Карт. Шулай да булгач, нигә үз җырларыңны тыңламыйсың? Мин менә ниләр күрмәдем, кайларда йөрмәдем дә... Шушында килеп, шушы җырлар өчен... калдым. Үләргә калдым.

Җәгүр. Үлмисең син, бабай. Алдыйсың гына.

Карт. Җыр ул күтәреп йөртә... Тартып китерә. Так, что... Ул яшәтә дә... Үтерә дә...

**Өйдә яңа җыр башлыйлар. Юка пәрдә аша яшь кыз силуэты гына күренеп тора... Ул Тәслимәдер, үзе ишетелгән моңнардан яралган рәсем дә кебек.**

Кара бөдрә чәчкәйләре —
Шомарадыр тараса, һай, тараса.
Үзәкләрне өзәдер
Бер елмаеп караса, һай, караса.
Әкрен кирәк, иплән кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.
Гөлләрендә сандугачлар
Тибрәләдер кичләрдә, һай, кичләрдә.
Күптән инде күргәнем юк,
Белми йөрим нишләргә, һай,
нишләргә.
Әкрен кирәк, иплән кирәк
Ишетергә сандугач сайрауларын.

Карт *(Җәгүргә)*. Әнә алар, керәшеннәр. *(Җыр тынып кала.)*

Җәгүр. Беләбез.

Карт. Күбрәк белсәгез дә артык булмас иде. *(Тәрәз ягына карап)*. Җырламыйлар.

Бәчели. Үзем җырлап күрсәтимме? *(Карт аларга битараф... Тәрәзәгә карап тора.)*

Җәгүр *(картка ишарәләп)*. Тыңларга теләми.

Бәчели. Җыр тыңларга түгел... Бану әбине күзләргә килгән ул.

Карт *(үзалдына)*. Их, гомерләр... Кала шул, кала...

Бәчели. Карчыклар каламы?

Җәгүр. Кызлар кала...

Карт. Җырлар кала.

**Ишек ачыла. Карт та, Җәгүр һәм Бәчели дә яшеренәләр. Картайган бөгелгән йә таякка таянган карчыклар китә, йөзләре күренми... Караңгылана...**

Әби *(тавышы гына ишетелә)*. Керәсез, хәлемне беләсез. Ходай исәнлекләр генә бирсен үзегезгә.

**Керләрдән бушап калган бау күренә.**

Җәгүр. Киттеләр.

Бәчели *(үзе генә белгәндәй сөйләнеп)*. Чыгып алган.

Җәгүр. Алган.

Карт. Әйдәгез, кызлар янына *(китә башлый, аңа егетләр ияртә)*.

Бәчели. Син каравыллаган сыерларны хәзер шулай диләрмени?

Карт *(тукталып)*. Син каравыллаганнарны шулай диләр.

Җәгүр *(картка)*. Кунак кызын каравыллыйбыз...

Карт. Бер дигән кыз.

Җәгүр. Әнә шул бер дигән кыз миңа кирәк иде. Буе да нәкъ миңа туры килә дә бит...

Бәчели. Күзе миңа туры килә. Гомерем буе шундый күзләр эзләдем... Кич белән чишмәгә суга төшеп бара. Хәерле кич, Тәслимәкәй, дим тегеңәргә.

Җәгүр. Нахал бит син.

Бәчели. Син үзең нахал. Минем

өчен генә туып үскән кызны тартып алмакчы буласың. Җитмәсә дус кеше. Ах, Җәгүр. Җылармын да...

Җ ә г ү р. Җылама, Бәчели. Кыз сиңа.

Б ә ч е л и *(шаярып, аны кочаклый).* Чынлапмы?

К а р т. Шаулашмагыз. Кайсыгызга да ярарлык. Бану әбиегез мактап бетерә алмый үзен.

Б ә ч е л и. Хәерле кич, Бәчели абый дигән булды теге. Ул елмаюы. Ул атлап баруы. Ул көянтәсе, чиләкләре...

Җ ә г ү р *(әллә үзе үртәлеп, әллә Бәчелине үртәп).* Беләсеңме? Синең күккә күтәрелгән борын көчкә-көчкә генә кызның күкрәгенә җитә.

Б ә ч е л и. Күкрәгенә?

Җ ә г ү р. Әйе!

Б ә ч е л и. Валлаһи диген.

Җ ә г ү р. Валлаһи.

Б ә ч е л и. Борын шунда җитсә, миңа булды да. Миңа шул гына кирәк тә. Егет кешегә тагы нәрсә? Шулай бит, бабай.

К а р т. Ялгыз картаю кызык түгел. Шуның өчен сыерлар каравыллыйм бит. Төннәрдә сыерлар белән сөйләшәм... Сезгә дөресен әйтим *(пауза)*... Галиябану әбиегез минем белән торырга риза түгел.

Б ә ч е л и. Оһо! *(Җәгүргә.)* Әйткән идемме?

Җ ә г ү р *(картка).* Сөйләшеп карадыңмы?

К а р т. Күптән сөйләшеп карадым.

Б ә ч е л и. Молодец, бабай. Тот бишне *(ирексезләп картның кулын кыса.)* Син өйләнерсең, әле сиңа соң түгел. Бик ашыкмасаң да була. Сөйләш әле әби белән. Башта мине Тәслимәгә өйләндер. Аннан Җәгүр, Тәслимә, мин — бергәләп сине Бану әбигә өйләндерәбез.

К а р т. Берегезне... өйләндерик. Так, что...

Җ ә г ү р. Бәчели Тәслимәгә өйләнсә, мин дә сыерлар каравылларга керәм.

Б ә ч е л и. Дөрес эшлисең. Руль артында утыру сиңа килешеп тә җитми.

Җ ә г ү р *(Бәчелине изүеннән ала).* Дөрес эшлимме?

К а р т. Җүнләп кенә, Җәгүр!

Б ә ч е л и. Яшьти, Җәгүр, җибәр. Буасың бит.

Җ ә г ү р. Борынгы дус булмаса... *(Җибәрә.)*

Б ә ч е л и. Мин бит болай гына. Кыз сине тели икән, сиңа.

Җ ә г ү р. Мине теләми шул.

К а р т. Каян беләсең?

Б ә ч е л и. Алайса миңа, килештек...

Җ ә г ү р. Сине дә теләмәсә?

Б ә ч е л и. Авылдан алам. Күздә тотканым бар, ике куллап риза.

Җ ә г ү р. Ник икенчегә, Тәслимәгә ябыштың?

Б ә ч е л и. Берсе запаска кирәк иде.

К а р т. Авылда үзебезнең кызлар да житәрлек тә...

Җ ә г ү р. Күңел ерактан эзли. Әллә каян килгән бер гадәт.

К а р т. Бәхетсезләрдән безгә калган мирастыр ул, бәхетне ерактан эзләү.

Б ә ч е л и. Ә бәхет янәшәдә.

Җ ә г ү р *(карчыклар озата чыккан әбисен каршыларга китеп баручы Тәслимәне күреп ала. Шатланыпмы, әллә шаярыпмы, йодрыгы белән Бәчелигә төртә һәм ялгыш катырак та төртә бугай... Тәслимә артыннан чаба).* Сау бул, бәхетле Бәчели. Мин киттем!

Б ә ч е л и *(башта бөгелеп тора, аннан тураеп).* Яшьти! Җәгүр! *(Җәгүр артыннан чаба.)*

К а р т *(аларны карап кала).* Үпкәләшмәсләр. Килешерләр. Менә Галиябану минем белән яшәргә риза түгел. *(Китә башлый. Кунакларын озатып, кайтып килүче әбине күрә.)* Галиябану!

Ә б и. Ходаем. Нишләп кеше куркытып йөрисең?

**Карт аның янына килә.**

Ә б и *(артка чигенеп).* Килмә, килмә монда. Тәслимә күрер. Кеше күрер.

К а р т. Так, что! Инде ничә ел көтәм. Кайчан мине тәрәзәңнән тартып аласың?

Ә б и. Исмәгыйль абзый?!

К а р т. Яшәүнең кызыгы бетте.

Ә б и. Кешедән оят. Әйттем ич. Картлар бит инде без.

К а р т. Әнә Җәприм белән Үкчи торалармы? Торалар. Гөргөри белән Сандра, Симун белән Әмписә. Нинди матур яшиләр. Алар яшьләрме?

Ә б и. Алар бергә картайганнар.

К а р т. Без дә бергә картайыйк.

Ә б и. Бар, эшеңә бар.

К а р т. Яныңа керәм. Сүзем бар.

Ә б и. Иртәгә көндез сөйләрсең.

К а р т. Бүген сөйләргә телим. Көндез дә шуны сөйләргә кергән идем. Ач.

Ә б и. Иөрмә малайлар кебек. Тәслимә чыгар.

К а р т. Сиңа гына сөйлисе серем бар. Гомер буе үземдә саклаган сер *(кесәсеннән алып, чәчәк бирә).*

Ә б и. Урам тулы кеше *(каранып куя, кесәсеннән сак кына алып, кулъяулык бирә).*

К а р т. Алай дисәң, соңрак киләм. Төнге 12 дә чыгарсыңмы? Зинһар, Галиябану? Бүген генә сөйли алам. Мин... Әндри...

**Аларны гармун тавышы бүлә: ерактан «Шахта» көе ишетелә...**

Ә б и *(югалып кала, чигенә)*. Әндри, Әндри...

К а р т. Киләм, йоклама *(китә)*.

Ә б и *(хәтта ничек өенә кереп китәргә белми тора)*. Әндри түгел. Шайтан син. Син шайтан. Кит, шайтан!

Т ә с л и м ә *(кайта)*. Кайттыңмы, эби... Әйдә, кер.

Ә б и *(кай якка кузгалырга белмичә)*. Кызым...

Т ә с л и м ә *(каршы килеп ала)*. Нәрсә, эби. Әйдә, керәбез.

Ә б и. Әллә күземә шайтан күренә.

Т ә с л и м ә. Әйттем ич мин сиңа... Карак бар дип... *(Капкан бикли, кереп китәләр. Өйдә ут сүнә. Берәм-берәм авыл утлары сүнеп бетә... Караңгылык. «Шахта» көе тына... Бәчели белән Җәгүр киләләр.)*

Б ә ч е л и. Иокы туйдырырга да вакыт җитәр. Әле 12 дә тулмаган.

Җ ә г ү р. Юкка сиңа әйттем лә. Ул мине танып өлгермәде.

Б ә ч е л и. Танымасын да ди, Казанына кайтып, бер-бер кешегә Көҗмәләр элгән керләрен дә урлашып яши дип сөйләсә? Ояты бөтен авылга кайтып җитәр.

Җ ә г ү р. Хәзер, хәзер урынына элеп чыгам *(капка янына килә, ачарга маташа)*. Ачылмый бу... Гомер биксез капка...

Б ә ч е л и. Узган атнада аңа Исмәгыйль бабай бик ясап маташкан иде *(капкага килә)*. Әбине... урлап китәрләр дип курка башлагандыр. *(Капканы ачарга маташа.)* Әллә ничек бикләнгән бу.

Җ ә г ү р. Бәчели, кемдер килә. Әйдә...

**Яшеренәләр. Карт килә. Капканы ул да ача алмый. Әкрен генә капшап карый... Койма аша керергә җай эзли. Утын өеме яныннан коймага менә. Нидер сына, карт йорт ягына егылып төшә. Бераз тыныч кына ята. Торып утыра. Ыңгырашып куя. Аякка басмакчы була, тагы ыңгыраша. Җәгүр белән Бәчели коймага менәләр.**

Җ ә г ү р *(әкрен генә)*. Бабай!

Б ә ч е л и *(әкрен генә)*. Син исәнме? *(Йорт ягына төшкәч.)* Бар, Җәгүр. Элеп куй тизрәк. *(Карт янына килә.)* Нәрсә булды?

К а р т. Торып булмый. Менә бу ягым авырта. Кабырга.

Җ ә г ү р *(юрган тышлыгын кер бавына аркылы гына салып килә)*. Менә бит, ул ташка төшкән.

Б ә ч е л и *(картка)*. Шушында гына кунасыңмы? Әбигә кертикме?

К а р т. Өйгә кайтам.

**Бәчели белән Җәгүр яралыны күтәрү алымы ясап кулларын тотышалар.**

Җ ә г ү р. Утырасыңмы?

К а р т. Хәзер, хәзер. *(Ыңгырашып куя.)* Булмый бит әле. Капка бикле.

Б ә ч е л и. Бик куймаска иде.

К а р т. Бер галошым төшеп калган.

Җ ә г ү р. Хәзер ачам *(ачып килә, галошын китерә)*.

Б ә ч е л и *(эскәмия китерә)*. Носилка ясыйбыз. Әйдә, тот әле, Җәгүр...

**Күтәреп алып, картны эскәмиягә йөзтүбән яткыралар.**

К а р т. Авырттырасыз.

Җ ә г ү р. Түзәргә туры килер, бабай.

Б ә ч е л и *(картның башына тотып)*. Башың да бәрелгән ич, канаган.

К а р т. Әй, эшләпәм, эшләпә...

Җ ә г ү р *(картның эшләпәсен җирдән алып кия)*. Эшләпә исән.

**Бәчели юрган тышлыгын ала, аның белән картны каплап куя.**

Җ ә г ү р. Нишлисең син?

Б ә ч е л и *(Җәгүр башыннан эшләпәне ала, карт өстенә куя)*. Кеше күрмәсен. Киттек.

**Картны күтәреп китәләр.**

К а р т *(җырлый)*.
Камышларга җил киселә,
Җанга үтә тавышы.

**Караңгылык.**
**Кичеш.**
**Яңа күренеш. Бану эби өе. Өй эче тамашачыга күренә. Тәслимә белән эби чәй эчәләр.**

Ә б и. Әйбәт кеше иде Әндри бабаң... Мәрхүмнең миңа өйләнүен яратмадылар. Аер, диделәр. Керәшен кызы димләделәр. И-и, ул чаклар...

**Беразга тынлык урнаша.**

Т ә с л и м ә. Эби!

Ә б и. Нәрсә, балам?

Т ә с л и м ә. Яңалык әйтимме?
Ә б и. Әйт әле, кызым, әйт.
Т ә с л и м ә. Мин сезнең мәктәпкә килергә булдым.
Ә б и. Менә рәхмәт, балам. Миңа иптәш булырсың. Кил генә...
Т ә с л и м ә. Әби!
Ә б и. Нәрсә?
Т ә с л и м ә. Җәгүр абый әйбәтме, Бәчели абыймы?
Ә б и. Икесе дә әйбәт. Тырышлар... Керәшеннәр ачык күңелле, эчләрендәге — тышларында...
Т ә с л и м ә *(бүлеп)*. Икесе дә әйбәттер. Син берсен генә әйт. Бер-сенге-нә!
Ә б и. Берсен генәме? *(Үзгәреп.)* Кызым, сине ялгыш үз яныма чакырам бит әле. Мин инде ялгыз торырга өйрәнгән кеше.
Т ә с л и м ә. Менә сиңа мә, килергә өметләнеп беткәч кенә...
Ә б и. Әллә нинди уйларың бар кебек. Кияүгә чыгар вакытың да җиткән.
Т ә с л и м ә. Мин кияүгә чыкмаячакмын.
Ә б и. Татар авылына урнаш. Үз кешеңә чык.
Т ә с л и м ә. Әби, син гомер буе ничек керәшеннәр арасында тордың соң... Алар үз кеше булмагач...
Ә б и *(бүлеп)*. Алар үз кеше, бик үз кеше. Әйттем бит инде, мине Көҗмә колач җәеп каршылamады. Бөтенесен сиңа сөйләп тә, аңлатып та булмас. Туган авылым да мине аңламады. Ничә еллар кайта алмый йөрдем.
Т ә с л и м ә. Ул чакларда — тормыш башка...
Ә б и *(бүлеп)*. Ул чакта да, бу чакта да тормыш йөрәк аша уза, эзен калдырып уза. Шуңа әниеңне татар кешесенә бирдем.
Т ә с л и м ә. Ул үзем таптым ди тагы...
Ә б и. Анысын да дөрес әйтә дә... Татар авылына урнаш. Киңәшем шул, сиңа татар егете кирәк.
Т ә с л и м ә *(көлә-көлә)*. Сиңа керәшен егете кирәк идеме?
Ә б и *(ачуланып)*. Мине тикшереп утырма! Керәшеннәр дә — татарлар, аларның ни гаебе бар?! Мин матур яшәдем.
Т ә с л и м ә. Шаярам гына инде, әби!
Ә б и. Әнә, Казанга урнаш.
Т ә с л и м ә *(үзалдына сөйләшкән кебек)*. Казанга урнашсам, рус егетенә чыгарга туры килә...
Ә б и. Әй, куркытма ла, чык... Әтиең мине гаепләве бар.
Т ә с л и м ә. Ник сине гаепләсен?
Ә б и. Көҗмәгә урнашсаң.
Т ә с л и м ә. Көҗмәне ярата ул.
Ә б и. Килсә, ничектер, үзен Көҗмәләрдән өстен куеп сөйләшә. Шул гадәтен ошатмыйм.
Т ә с л и м ә. Ярата ул, әби, Көҗмәне. Кешеләрен дә ярата. Аның сөйләшүе шундый, мактанчыграк ул...
Ә б и. Шундый чибәрлегең бар...
Т ә с л и м ә. Яшь вакытта син дә...
Ә б и *(аны бүлеп)*. Мин яшь вакытта да җен шикелле ямьсез идем, беләңме? Яратучы булмас дип, көзгеләргә карап җыладым.
Т ә с л и м ә. Син әле дә чибәр, миңа бик ошыйсың, әби. Аннан миңа Бәчели абый ошый, аннан Җәгүр абый. Аннан Исмәгыйль бабай *(әбисен үбеп ала)*.
Ә б и. Кит янымнан *(торып китә. Каядыр җыена)*.
Т ә с л и м ә. Исмәгыйль бабайны әйтәм. Аның турында чынлап та шулай сөйлиләрме?
Ә б и. Кеше сөйли инде ул.
Т ә с л и м ә. Поп булган диләр?
Ә б и. Булган, диләр... Белмәгәне юк. Урысчасы — урыстан әйбәт, бәлки шуның өчен генә сөйлиләрдер. Бәлки *(пауза)*. Элегрәк инде. Авылга килгән елларында. Хәзер алай бик сөйләмиләр.
Т ә с л и м ә. Әби! Тагын бер яңалык әйтимме?
Ә б и. Әйтмә.
Т ә с л и м ә. Кичә сиңа Исмәгыйль бабай гашыйк булды.
Ә б и *(ачуланып килә)*. Булмаганны сөйләп утырсаң *(үрелеп Тәслимәнең артына шактый нык суга)*.
Т ә с л и м ә. Ой, ой... Әнигә әйтәм мин сине. Кыйнады дим. Куып җибәрде дим.
Ә б и. Әтиеңә әйт. Без сөйләшкәннәрнең барын да әйт. Фикла дустым янына кереп чыгыйм әле... Онытма. Эринаңне каршылыйсың бар.
Т ә с л и м ә. Онытмам ла инде, әбекәй.

**Әби чыгып китә. Тәслимә тиз-тиз өстәл җыя. Көзге ала. Карый. Бизәнә. Гөлләргә су сибә, нишдидер көй сызгырынып йөри.**
**Машина тавышы ишетелә. Тәслимә тәрәзәдән карый. Җәгүр белән Эринә килә. Тәслимә каршыларга чыга.**

Җ ә г ү р *(җитди)*. Кабул ит, Тәслимә. Хәерле көн!
Т ә с л и м ә. Хәерле көн, Җәгүр абый. Рәхмәтләр яусын үзеңә. *(Эринә белән күрешеп.)* Иртән уянгач та сине уйладым...

Эринә. Килмәс дип уйладыңмы?

Тәслимә. Килер дип уйладым. Синең сүздә торуыңны күптән беләм.

Җәгүр. Уянгач, мине дә искә алмадыңмы соң?

Тәслимә. Сине кичтән, йокларга ятар алдыннан искә алдым.

Җәгүр. Ничек итеп... Искә алдың?

Тәслимә. Бикләр генә дә яхшы итеп инде, Җәгүр абый.

Җәгүр. Бер аягы кыскарак дип искә алдыңмы?

Тәслимә *(аптырабрак, кичке хәлләрне хәтерләп).* Аягы кыскарак дип түгел, кулы озынрак дип искә алдым, Җәгүр абый. Карак дип искә алдым.

Эринә. Тәслимә?!

Җәгүр. Бу фикерең ялгыш.

Тәслимә. Ялгыш түгел. Карак, әйдә, өйгә кер. Коймак белән чәй эчерәм.

Эринә. Әйдә, Җәгүр абый.

Җәгүр *(сәгатен карап).* Очып керер идем, күрше авылдан хуҗаны алып кайтасы бар. Инде соңгарак та калдым. Әби өйдәме?

Тәслимә. Чыгып китте шул.

Җәгүр. Аңа сүзем бар иде.

Тәслимә. Миңа әйт, тапшырырмын.

Җәгүр. Үзенә генә әйтә торган сүз. Ярый, хәзергә... *(Китеп бара.)*

Эринә *(кычкырып).* Рәхмәт сезгә, Җәгүр абый!

**Эринә белән Тәслимә өйгә керәләр.**

Юлым уңды: кул күтәрсәм, Кузьминовка машинасы. *(Пауза.)* Безнең Көҗмә авылы кебек матур авыл дөньяда юк, ди.

Тәслимә. Җәгүр абыймы?

Эринә. Әйе. Укытучылар кирәк, безнең мәктәпкә кил, ди.

Тәслимә. Җәгүр абыймы?!

Эринә. Әйе. Телгә бик оста икән.

Тәслимә. Ул эшкә дә бик оста күренә...

Эринә *(тәрәзәдән карап).* Матур авыл. Зур да... Район үзәгеннән бер дә ким түгел.

Тәслимә. Мин шушында килергә булдым, директорларын күреп сөйләшәм дә... Әби дә чакыра.

Эринә. Әллә миңа да Җәгүр абыйны тыңларга, шушында күчәргә микән? *(Гөлләрне карап.)* Бергә гөлләр үстерербез.

**Тәслимә эндәшми. Пауза.**

Гашыйк итә язды!

Тәслимә. Җәгүр абыймы?

Эринә. Әйе инде. Үзе... *(Пауза).*

Тәслимә. Эринә, сөйләсәң сөйлә!

Эринә *(Җәгүргә үпкәләгән кебек).* Үзе сиңа гашыйк икән.

Тәслимә. Каян беләсең?

Эринә. Әйтте. Татар кызы Тәслимәгә гашыйк булдым ди.

Тәслимә. Җәгүр абыймы?

Эринә *(елмаеп).* Ул, ул, Тәслимә. Ул әйтте.

Тәслимә. Сөйләмә юкны, Эринәкәем. Җүләр ул. Башсыз. Ахмак... Дивана, тиле, тинтәк. Иләс-миләс. Карак.

Эринә. Нәрсәңне урлады?

Тәслимә. Күңелемне... Күч, Эринә, Көҗмәгә. Бергә гөлләр үстербез. *(Гөл яфракларын тоткалап карый. Шат.)*

Эринә *(җырлап, Тәслимә янына бара. Бу — «Кызлар җыры»).*

Тәрәзәбез төпләрендә
Гөлләр буйга җиткән,

**Икесе бергә заманча-җиңел көйгә бииләр.**

Гөлләр буйга җиткән.
Гөлләр сыман чакларыбыз
Тик бер генә икән...
Тик бер генә икән...

Тәслимә.

Гөлләремә көннәр карый,
Көнгә карый гөлләр,
Көнгә карый гөлләр.
Истә калсын, гөлләр булып,
Бергә узган көннәр.
Бергә узган көннәр.

Эринә.

Гөлләребез сусамасын,
Сулар сибик әле.
Сулар сибик әле.
Гөлләр кебек көннәребез,
Сайлап сөик әле.
Сайлап сөик әле.

**Җыр ахырында әби кайта.**

Эринә. Исәнме, әби!

Әби. Аллага шөкер, кызым. *(Тәслимәгә.)* Кунакны ашаттыңмы?

Тәслимә. Вакыт юк. Җырлыйбыз.

Әби. Җырламагыз шул.

Тәслимә. Сиңа ни булды, әби?

Әби. Кунакны җыр белән генә сыйламыйлар. Аш әзерлә...

Тәслимә. Ни булды, әби?

Эринә. Мин ашап кына килдем.

Әби. Килеп яхшы иткәнсең. Көтә идек.

Тәслимә. Хәзер пешерәбез.

Әби. Исмәгыйль бабаңның хәле

начар ди. Төнлә фермада бик җайсыз егылган. Иртән Җәгүр үзен районга — больницага алып киткән икән.

**Тәслимә.** Җәгүр абый яңа гына монда кереп чыкты.

**Әби.** Бер нәрсә дә әйтмәдеме?

**Тәслимә.** Әбигә сүзем бар ди.

**Эринә.** Районнан мин аңа утырып килдем.

**Әби.** Олы кеше бит. Әллә нәрсә булып чыкмасын. Җәгүр берни дә әйтмәгән... Бәла аяк астында гына йөри. Аш куегыз әле, балалар. *(Тәслимә белән Эринә аш-су бүлмәсенә китәләр. Әби тәрәзәдән карап, моңаеп тора. Гөлләрен карый. Аннан әкрен генә барып сандыгын ача, бик еракtan «Шахта» көе ишетелә башлый... Көй, бәлки, әбинең хәтерендә генә яңгырыйдыр, ул төргәген чишә, гармун карый...)* Юкны сөйлиләр... Юкны гына сөйлиләр. Бәчелиен кара. Поп гармуны, ди. Нишләп бу поп гармуны булсын? Миңа әйтер иде. Әллә әйтмәс тә микән. Берәр төрле гаебе дә бар микән? Булыр да аңардан. Тәмәке тарта. Карт башы белән. Аракы эчә. Бергә торыйк, ди. *(Гармунны кабат төрә, аны урынына куя. Сандыгын яба. Ерактан ишетелгән «Шахта» көе тына.)* Малайлар кебек... егылып йөриләр димени инде?! *(Бераз уйланып торгач.)* Тәслимә, кызым!

**Тәслимә** *(аш-су бүлмәсеннән чыгып).* Нәрсә бар, әби?

**Әби.** Җәгүр кая китте икән?

**Тәслимә.** Күрше авылдан хуҗаны алып кайтам диде.

**Әби.** Сүзем бар диме?

**Тәслимә.** Сүзем бар иде ди шул. Миңа әйтмәде.

**Әби.** Ярар, алайса. Кайткач, керер. *(Тәрәзә янына барып баса.)*

**Җиңел машина тавышы.**
**Тәслимә аш-су бүлмәсенә керә. Капка янына Җәгүр килә. Әби каршы ала. Аш-су бүлмәсеннән «Кызлар җыры», кызлар шаярганы ишетелә.**

**Җәгүр.** Хәерле көн, әби!

**Әби.** Исәнме, улым. Сине күрше авылга китте дигән булалар тагы...

**Җәгүр.** Хуҗа үзе кайтып җиткән... Кунакларның кәефе ничек?

**Әби.** Сайлап сөярга кирәк дип, биеп-җырлап йөрүләр шунда.

**Җәгүр.** Биесеннәр, әби.

**Әби.** Биесеннәр дә... Исмәгыйль бабаңның хәле ничек?

**Җәгүр.** Менә ул әлегә бии алмый. Өч кабыргасы сынган. Башы да бик нык бәрелгән.

**Әби.** Терелер диләрме?

**Җәгүр.** Терелер диләр, ләкин...

**Әби** *(әллә куркып, әллә ачуланып).* Нәрсә «ләкин»?

**Җәгүр.** Тиз үк булмас. Кабырга башына бер айдан... больницада ятуы бар.

**Әби.** Врачлар шулай диме?

**Җәгүр.** Врачлар җиңелрәк карый. Бер-ике айдан чыгар диләр.

**Әби.** Үзе ни сөйли, үзе?

**Җәгүр.** Галиябануга гына сөйлисе сүзем бар, ди.

**Әби.** И-и-и, бөтенләй җүләрләнгән икән. Карт кеше шул, терелә генә күрсен.

**Җәгүр.** Галиябану әбиегез хәлемне белергә килмәсә, бер айдан да, ике айдан да, өч айдан да чыкмыйм, терелмим, үләм ди. Шуны сиңа әйтергә кушты.

**Әби.** Җүләрләнгән. Җүләрләнгән.

**Җәгүр.** Юк, акылына зыян килмәгән. Үтенечен тапшырдым. Инде китәм. Хуҗа көтә.

**Әби.** Ярый, улым. Бар. Исән-сау йөрегез. *(«Кызлар җыры» ишетелә).*

**Җәгүр** *(киткән җирдән борылып).* Үзем алып барырмын, әби. Әйтерсең. Әзерлән.

**Җәгүр китә. Машина тавышы. Ул ерагая. Әби капка төбендә уйланып тора.**
**Караңгылык.**
**Күчеш.**
**Яңа күренеш. Бану әби өе. Өйдә күп медер үзгәреш: Көзкмә мәктәбенә килгән укытучы кызлар өчен өстәл арткан.**

**Әби** *(өйдә үзе генә, ниндидер төенчек бәйли, карт янына барырга җыена).* Барыйм әле, барыйм. Дөнья хәлен кем белә, кеше белән ни булмас...

**Җәгүр белән Бәчели килә.**

**Бәчели.** Бармастыр ул.

**Җәгүр.** Үз алдында әйтте ич. Кереп алыгыз, диде.

**Бәчели.** Беренче әйтүе түгел. Үзе бармый кала.

**Җәгүр** *(өйгә узуга).* Машина әзер.

**Бәчели.** Булдымы, әби. Җыендыңмы.

**Әби урындыкка утыра, эндәшми.**

**Җәгүр.** Сине алырга кердек.

**Бәчели.** Чирләп торасыңмы?

**Әби.** Чирләмим. Кешедән оялам, балалар.

**Бәчели.** Әллә сезнең Исмәгыйль

бабай белән бер-бер гаебегез бармы?
Җ ә г ү р. Бәчели!
Б ә ч е л и. Оялам ди бит.
Ә б и. Безнең нинди гаеп булсын.
Җ ә г ү р. Сандра әби барды. Үкчи әби белән Әмписә әби бардылар. Бөтенесе бара.

**Әби уңайсызрак бер халәттә.**

Б ә ч е л и. Әллә соң без аны төнлә алып барыйкмы?
Ә б и. Төнлә?!
Б ә ч е л и. Төне буе икәү генә... рәхәтләнеп сөйләшерсез.
Ә б и *(урыныннан торып)*. Оятсыз икән син, Бәчели улым. Мин тагы сине кешеләргә мактыйм. Кызларыма...
Б ә ч е л и. Үләм ди бит Исмәгыйль бабай. Сине көтә.
Җ ә г ү р *(әбигә)*. Ул оятсызлыкның аргы ягына чыккан. Мактама син аны кызларыңа. Әйдә, көндез барыйк әле, көндез.
Б ә ч е л и. Күреп калырсың, әби.

**Аны әйдәкләп алып чыгып китәләр. Караңгылык.**
**Күчеш. Кайдадыр кызыл әләм як тыра, бүген Октябрь бәйрәме. Еракта да, якында да кебек ишетелеп тынган көйләр, өннәр авылда бәйрәм киче булуын ачык сиздерә... Күмәк җыр, аны дәртле бию көе алыштыра.**
**Бану әби өе.**

Ә б и *(клубтан кайта, ут ала, өсләрен сала, узалдына сөйләнә)*. Кыш та килеп җитәр. Хәере белән килсен... Балакайлар! Бигрәк матур җырладылар. *(Уйланып-моңланып ала)*. Клуб яңгырап тора. Яшьләр шул, яшьләр. Бигрәк матур биеделәр. *(Тәрәзә төбендәге гөлләрен карый.)*

Олы юлдан атлар уза,
Безгә кала тузаны,
Алда гомер бардыр барын
Сагындыра узганы...

Кызларым кайтып җитәр. Чәй куйыйм әле. Коймак пешерим, бәйрәм бит. *(Аш-су булмәсенә юнәлә, туктала.)* Булмас. Алдап сөйлидер ул.

**Больница киеменнән карт кайта.**

К а р т *(ишекне шакымыйча керә)*. Исәнме, Галиябану!
Ә б и. Исәнме, Исмәгыйль абзый. Уз әле, утыр.
К а р т. Исән-сау. Качып кайттым. Так, что...
Ә б и *(нинди сүз, йә нинди эш башларга икәнен дә аңлый алмыйча)*. Хәзер, хәзер.

К а р т. Җәгүр өйләнә.
Ә б и. Кемгә?
К а р т. Тәслимәгә, Бәчели Эринәгә өйләнә.
Ә б и. Бәчели авылдан ала иде бит...
К а р т. Кыз — риза түгел, Бакалыга чыгарга җыена икән.
Ә б и. Кем әйтте?
К а р т. Җәгүр.
Ә б и. Шаярып әйткән ул.
К а р т. Шаярмый да, алдамый да. Так, что... Без һаман ялгыз яшикме? *(Кыза барып.)* Юк! Минем белән яшәргә риза түгел икәнсең, өеңә соңгы керүем. Әнә, Тимапи Нәчтүгенә өйләнәм. Синнән ун елга яшь.
Ә б и. Исмәгыйль абзый... Ни бит... Теге көнне сөйләдең бит...
К а р т *(ачуланып)*. Сөйләсәм бит. Сөйләсәм ни булган? Мин сине ярaтып, сиңа ышанып сөйләдем... Мин шахтер! Мин революция солдаты! Фашистларны кыйнап орден алган кеше! Сиңа кем кирәк?! *(Әбигә таба атлап.)* Мин үлгәнне көтәсеңме? Әйт!
Ә б и *(чигенеп)*. Ничек инде? Ничек син үлгәнне? *(Чигенә торгач, бәрелә, утыра.)*
К а р т *(һаман әбигә таба барып)*. Үлмим. Мин әле яшим. Икәү яшибез. Җитте сиңа, Галиябану!
Ә б и. Ярар. Ярар.

**Ул арада ишеккә яшьләр килә.**

Т ә с л и м ә *(егетләргә)*. Әгәр әби сезне кертмәсә?
Э р и н ә. Әйе?
К а р т *(әбине кулыннан сыйпап)*. Галиябану...
Б ә ч е л и. Бездә аның ачкычы бар. *(Җәгүргә.)* Яшьти! *(Кулын өч тапкыр селтәп боерык бирә. Егетләр «Бану әби туганай»ны җырлап ишеккә бара. Аларга кызлар кушыла.)*
Ә б и. Кайттылар.
К а р т *(урындыкка утыра)*. Кайттылар.
Ә б и *(бераз җыр тыңлагач, узгәреп, яшьләрне каршылап)*. Әйдәгез, балалар.
Т ә с л и м ә *(ишектән керүгә)*. Исәнме, бабай?!
К а р т. Исәнмесез, яшьләр!
Э р и н ә. Исәнмесез.
Җ ә г ү р. Ура-а-а, бабай кайткан!
Ә б и *(урындыклар куеп)*. Утырышыгыз, узыгыз.
Б ә ч е л и *(күрешеп)*. Исәнме, Исмәгыйль бабай... ничек болай...
К а р т. Кичә баш врачка кердем. Хет Октябрь бәйрәме белән хисаплашыгыз, дим. Иртәгә авылда бәйрәм,

мин монда ничек түзим? Киләсе атнада уйлашырбыз, ди.

Әби *(аш-су бүлмәсенә китү уңаена)*. Бүген качып кайткан.

Эринә. Дөрес эшләдең микән, бабай?

Җәгүр. Дөрес!

Тәслимә *(картка)*. Ничек башыңа килде?

Карт. Бер малай... кайгырма, качып кит син, бабай, ди. *(Бәчелигә карап.)* Бәләкәй генә башлы булса да, акыллы малай булып чыкты.

Бәчели *(тәрәзәдән карап)*. Ак халаттан... Киләләр, милиция белән.

**Кызлар алданып тәрәзәгә карый.**

Җәгүр. Бәчели!

Карт. Бармыйм. Киемнәрен бирен җибәрәм. Так, что...

**Аш-су бүлмәсеннән әби чыга.**

Бәчели. Әби, тыңла. Сүз Җәгүргә бирелә!

Җәгүр. Бүгенге бәйрәм уңае белән хатын-кызларны котлыйбыз! *(Сумка ача. Карт та, әби һәм башкалар да әлегә берни аңламый тора.)* Сезгә бүләгебез! *(Яхшылап төргән шоколад тартмасы чыгара.)* Тәслимәгә! *(Тәслимә ала, ни әйтергә дә белми тора. Бәчели сумкадан икенче төргәк чыгара...)* Эринәгә! *(Эринә ала.)*

Бәчели. Әбигә! Икәү... *(Әйбәтләп төргән ак җәймә һәм әбинең юрган тышлыгын чыгара.)*

Җәгүр. Кая, үзем бирим. *(Әбигә илтә.)*

Әби *(алыргамы, юкмы дигән сыман тора)*. Нигә миңа... Икәү?!.

Бәчели. Ал, әби. Каушама. Аның берсе — үзеңнеке.

**Тәслимә белән Эринә дә бүләкләрне әбигә бирәләр.**

Тәслимә *(Эринәгә)*. Икесе дә карак.

Бәчели *(Тәслимәне ишетеп)*. Мин — коткаручы!

Карт *(кыю итеп)*. Галиябану, китер әле теге... Поп гармунын.

Бәчели. Менә! Менә!

Әби *(әйберләрне сандык өстенә куя)*. Кагылмыйм да гармуныңа. *(Аш-су бүлмәсенә китә.)* Коймак пешерәсем бар.

Бәчели. Менә! Ишеттегезме?!

Җәгүр. Үзе әйтеп тора.

Тәслимә. Бабай?!

Эринә. Чынлапмы? Исмәгыйль бабай?

Карт. Әйе. Булган ул поп. Исеме дә аның Исмәгыйль түгел. Әндри. Әндри булган, керәшен булган ул... Борыслан шәһәрендә ат белән арбасын аткарган. Шул акчага... иленә кайтып үләргә җыенган бер Себер егетенең документларын сатып алган. Донбаска барып, шахтага урнашкан. Аннан революциягә кушылган... Менә шул кеше... мин булам инде... Так, что... Гармун үземнеке, үзем белән бергә картайды. Китер әле, китер! Галиябану!

Бәчели. Әби!

Тәслимә *(егетләргә)*. Рәхмәт сезгә, кунаклар. *(Егетләрнең бүләкләрен сандыкка куя. Гармунны алып картка бирә. Карт русча бию көе уйный башлый.)*

Әби *(аш-су бүлмәсеннән чыга, ачуланып килә)*. Нишләп үзебезчә уйнамыйсың, карт җүләр?!

**Гармун кинәт тына.**

Тәслимә. Әби, өйдән хат алдым. Сиңа бик күп сәлам әйткәннәр... Җәгүргә дә...

**Бәчели Җәгүрнең кулын кыса.**

Карт. Исемем Исмәгыйль булганга яратмый. Үзем дә бер биер идем Галиябану белән. Кулда гармун гына бар. *(Үзе уйнап, «Шахта» көенә җыр башлый.)*

Шәп булсын дусларыгыз да
Шат булсын уйларыгыз:

**Карт янына башкалар килә, җырга егетләр кушыла.**

Кайсы йолдызлар астыннан
Үтсә дә юлларыгыз.

Карт *(уйнавын өзеп, уйланып)*. Кала шул, кала...

Бәчели. Калмас, бабай...

Әби. Уйна?!

Җәгүр. Уйна әле.

Тәслимә. Нәрсә, бабай?

Эринә. Нәрсә кала?

Карт *(күп мәгънәле итеп, егетләргә карап)*. Калса, калыр инде *(пауза)*.

Кунак кызы гел килмәс.
Кунак кызы көн дә килмәс,
Үбеп җибәр бер килгәч.

*(Дәртләнеп «Кызлар җыры» көен уйный башлый, үзе җырлый, аңа башкалар кушыла; Җәгүр белән Тәслимә, Бәчели белән Эринә парлап бииләр.)*

**Пәрдә.**

Казан, 1984 ел.

## Фәнис Яруллин

# КҮКЕРТЛЕ ЧИШМӘ

Безнең өйдә бүген иртәдән бирле ыгы-зыгы. Әни чыж да пыж таба ашлары пешерә. Кухнядан бәреп чыккан кызган май, кызган суган исләренә чыдый алмыйча, аяк астында песи урала. Ләкин аңа әһәмият бирүче юк. Сәрбиназ апа өйне җыештыра. Ул миңа туган апа түгел. Ул кайчандыр мине карап үстергән, ә инде мин ай үсәсен көн үсеп, чын-чынлап адәм рәтенә кергәч, Сәрбиназ апа бөтен көчен тузан белән көрәшкә түгә башлады. Аның кулында һәрвакыт ике чүпрәк булыр: чүпрәкләренең берсе юеш, берсе коры. Әгәр дә көзгеләр, тәрәзә пыялалары ышкыганга туза торган булсалар, безнең өйдә тишелмәгән көзге, ертылмаган тәрәзә өлгесе калмаган булыр иде.

— Җил тегермәне белән сугышучы Дон Кихот син,— дим мин аңа.

— Шулайдыр, шулайдыр,— дип килешә ул һәм үз эшен дәвам итә. Кайвакыт мин, аның ачуын чыгарырга тырышып, бер бүлмәдән икенче бүлмәгә футбол тубы куалап йөри башлыйм. Тубымны матурлап өеп куелган мендәрләргә дә юнәлтәм, шкаф башына да кундырам. Ул коты очып миңа карап тора, ләкин ачуланмый. Әйберләрне ватмый- җимерми генә туктасам, җиңел сулыш алып куя.

— Мин начар малай, әйеме? — дим мин аңа.

— Алай димә, наныем,— ди ул, сүзләремне чын күңеленнән кире кагып.— Яхшыдан яман тумас. Әти-әниләрең бик әйбәт кешеләр бит синең. Ходай үзләренә гомер генә бирсен.

Сәрбиназ апага безнең әти фәрештәләрнең фәрештәсе булып тоела. Чөнки әти аңа үзебезнең йорттан ук бик шәп фатир алып бирде. Аның фатиры миңа да бик ошый, чөнки ул иң югары катта. Аның балконыннан бөтен Казан күренә. Сәрбиназ апа, үзенә фатир алып биргәннән бирле, әтигә рәхмәт укудан туктамый. Хәтта бер көнне, мәчеткә барып, әтигә багышлатып коръән укытып кайткан.

Без өчәүләшеп җылы якларга ялга киткән чакларда яки җәйләрен дачада яшәп ятканда өйдә Сәрбиназ апа кала. Гомерен безгә багышлап, үзе кияүгә дә чыга алмады, бичара. Ә бит элек бик чибәр иде ул. Аның белән урамга чыксак, борылып карамаган кеше калмый иде. Ячылап та карамадылар түгел үзен, әмма әтинең шундый тугрылыклы хезмәтчене һич тә кулыннан ычкындырасы килмәде бугай.

— Әйбәт кеше синеңчә нинди була? — дип сорыйм мин Сәрбиназ

---

Фәнис ЯРУЛЛИН (1938) — *купсанлы шигырь һәм проза китаплары авторы, Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты. Казанда яши.*

ападан. Ул, кулындагы чүпрәкләрен әвеш-тәвеш китереп, уйланырга тотына.

— Әйбәт кешеме? Әйбәт кеше бервакытта да көчсезләрне рәнҗетми, ярдәмчел була. Хәрәм ризык ашамый, алдашмый. Синең этиең төсле инде...

Сәрбиназ апаның әйбәт кешене тасвирлавы шуның белән тәмамлана. Мин дә артыгын төпченмим.

Безнең эти, Сәрбиназ апа әйтмешли, бик зур кеше. Һәм ул бүген тагын да зуррак булып кайтачак. Нигә дисәң, бүген — сайлау көне. Илнең иң югары органына депутат булып сайланачак безнең эти. Аның сайланачагына беребезнең дә күңелендә шик юк. Шулай да Сәрбиназ апа, пошынып:

— И ходаем, сайлаулар әйбәт кенә үтсә ярар иде инде! — ди. Аңа беребез дә сүз әйтмибез, һәркем үз уйлары белән мәшгуль. Ә Сәрбиназ апа, күңелен юатыр өченме, сөйләнүен дәвам итә:

— Бар да әйбәт булыр әле, алла боерса. Фәрештәдәй кешене сызып ташларга кемнең кулы барсын? Габдрахман Зарипович, дип бөтен кеше үлеп тора бит. И-и, аны белеп кенә бетермиләр әле. Белсәләр, Мәскәүнең дә иң биек җирендә утыра торган кеше ул Габдрахман Зарипович!

Әтине күрше-тирәләр дә ярата. Кайда да аны мактап торуларын ишетәсең. Машинасы ишек төбенә килеп туктауга, күршеләр берсен-берсе уздырып: «Берәр ярдәм кирәкмиме, Габдрахман Зарипович?» — дип йөгереп чыгып җитәләр. Әгәр этинең бер-бер әйберен күтәреп кертсәләр, ул көнне этигә ярдәм итә алган кеше үзен бәхетле саный. Хәер, күршеләргә мондый бәхет еш эләкми. Чөнки, эти тегене-моны алса, аның шоферы ук ялт кына өйгә кайтарып китә. Күршеләр түгел, үзебез дә күпвакыт сизми калабыз аның нәрсә китереп киткәнен. Эти Ирек абыйның менә шушы сыйфатын мактап бетерә алмый.

Дөньялар шулай барган чакта әллә каян гына үзгәртеп кору дигән сүз килеп чыкты, этинең чырае караңгыланып китте. «Кара халык ул — кара сарык, ә кара сарыкка чыбыркы гына кирәк»,— дип сөйләнде ул. Бигрәк тә, өстәгеләргә өстенлекләр бетсен, дип кычкыручыларга ачуы килде аның.

— Бу иң юләр сүз инде! — диде ул, бервакыт өйдә сүз кузгалгач.— Өстәгеләрнең ничек инде өстенлеге бетсен? Өстә утыру — үзе өстенлек.

Шулай да, үзе энигә әйтте:

— Бүгеннән һәр нәрсәне шәһәр кибетләреннән алырсың, өргән этләрнең авызы тыгылсын,— диде. Эни аны-моны әйтмәде, бары тик бераз көлемсерәп кенә куйды. Энине безнең тирәдәге кибет сатучылары яхшы беләләр, әгәр ул кибеткә килеп керсә, ни кирәк тә ни кирәк, дип, янында бөтерелергә генә торалар.

Беркөнне эни хәтта болай дип тә сөйләнеп алды:

— Бу кибетчеләрне әйтәм әле, нәрсәгә шулай ялагайланалардыр. Җир тишегеннән булса да мин сораган әйберне тапмый калмыйлар. Кибетләрдә әйбер юк дибез, бар икән бит ул әйбер. Мин ул кибетчеләргә беркем дә түгел бит, югыйсә.

Эти энигә бармак янап куйды:

— Син шаярма, энкәсе, халык бик хәйләкәр ул. Аларның үз тактикасы бар. Туктале, ди ул, хатын белән ир — бер ишекнең ике тоткасы, кайсы тоткадан тартсаң да, шул ук ишек ачыла. Син тотынган тоткадан тартып, алар минем ишекне ачарга тырышалар. Әмма минем ишек бик калын, алай тартканга гына ачылырлык түгел. Ә алар тартсыннар, керү юлын эзләсеннәр. Мин нәкъ менә шуңа исәпләп, махсус кибеттән баш тарттым да. Урының югары булганда аның нигә кирәге бар? Болай хәтта шәбрәк тә. Иә әйт әле: элеккегә караганда начарайдымы синең тормышың?

— Соң шуны әйтеп торам бит,— диде эни.— Фәлән нәрсә әзерләп куйдым дип өйгә дә шалтыраталар.

— Шулай шул! Ә кайбер юләр башларның өстенлекләрдән арынырга көче җитми... Ә-ә, мин сиңа шуны да әйтергә онытып торам икән: хәзер без дәваланырга махсус поликлиникага йөрмәячәкбез. Мин үз поликлиникабызның баш врачына шалтыратып куйдым. Ул, кирәк булса нитсә үземә әйтерсез, диде.

Ләкин этинең эчен пошырган бер нәрсә турында әйтми китсәң ярамастыр. Ул да булса бер округтан өч кешенең бер үк урынга сайлануы. Бер казанга, әлбәттә, өч тәкә башы сыймаячак, эти әйтмешли. Көчең җитеп, башкаларны этеп төшерә алсаң гына ул урынга син хуҗа булачаксың.

Этинең көндәшләреннән берсе зур заводның директоры икән, ә икенчесе — гап-гади бер укытучы. Җитмәсә, әле хатын-кыз. Бусы этине куркытмады. Укытучыларны җырларда мактап җырласак та, аларны түр башына менгерергә беркемнең дә ашкынып торганы юк. Исемен журналистлар бераз иләп йөртерләр дә, төшеп калыр. Ә менә икенчесе этине чын-чынлап куркыта. Завод директоры уен эш түгел ул. Заводы нинди диген әле: безнең республикага гына түгел, Мәскәүнең үзенә буйсына торган завод. Мондый кеше белән бил алышу җиңел булмаячак.

Сайлаучылар белән очрашуга барган саен, этинең кәефе кырылып кайта. Хәтта ябыга ук башлады. Төннәрен сикереп тора да әрле-бирле йөрергә тотына. Имезлеккә өйрәнгән баланы имезләктән аерсаң чиргә сабыша, этинең дә хәле менә шундыйрак иде.

Бик теләгән кешенең учына йолдыз төшә, диләр. Безнең эти дә, күрәсең, бик теләгәндер инде, аның да учына йолдыз төште!

Болай булды ул: теге завод директорының бер кызы нинди дер начар юлда йөри икән. Менә шуны журналистлар каяндыр белеп алган да, үз кызын да тәрбияли алмаган кешенең депутат булырга хакы юк, дип, газетага язып чыктылар. Сайлаучылар белән очрашулар вакытында этинең ышанычлылары да бу хәбәрне бик оста кулланды, ахры. Теге директорның баш очында давыл куерганнан-куера барды. Һәм ул, бичара, көннәрдән бер көнне үзенең кандидатурасын алырга мәҗбүр булды. Моны ишеткәч, этинең шатланганын күрсәгез!

— Туганда ук авызыңа бәхет җимеше кабып тугансың ахры син, Габдрахман,— диде әни, сөенеченнән балкып.

Берничә көн этинең йөзеннән шатлык нуры китмәде. Әмма, баштарак ниндидер бер укытучы үзенә көндәш була алмас дип санаса да, тора-бара эченә шик йөгерә башлады. «Хәзерге заман кешесен белмәссең,— дип сөйләнде ул,— бөркетне тавык чукып атарга да мөмкин. Хәзер бүрегә көчек ташлана торган чак, чөнки көчекне өстереп торучылар була. Нәрсәдер эшләргә, вакыт үткәнче нидер кылырга иде».

— Әллә үзе белән әйбәтләп күзгә-күз сөйләшеп карарга микән, әнкәсе, ә? Ниндирәк кеше икән, син белмисеңме аны?

— Юк шул,— диде әни.— Без бит кеше белән аралашмыйбыз. Аралашсаң да, шәһәр тиклем шәһәрдә кемне генә белеп бетермәк кирәк.

— Мин беләм аны, эти,— дидем мин сүзгә кушылып.

— Син?

— Әйе, мин.

— Сезнең мәктәптә укытмыйдыр бит?

— Юк, ул кайдадыр француз теленнән укыта бугай.

— Нишләп соң әле син беләсең аны?

— Кайчагында сез белмәгәннәрне дә беләм мин шулай,— дип, этиләр алдында мактанып куйган булдым. Ә аннары Кадрия Сабитовна белән ничек танышканымны сөйләп бирдем.

Узган ел, Май бәйрәме алдыннан, берничә малай күрше йортның ишегалдында Айратның мопедын рәтләп маташа идек. Шулай мопед белән мәшәкатьләнеп ятканда безнең янга бер апа килеп басты. Тавышланасыз, дип безгә вәгазь укый башлар инде бу дип көткән идек, тик ул безне сүзсез генә күзәтүендә булды.

— Моның уе җүнлелектә түгел инде,— диде Айрат минем колакка,— әллә читкәрәк таябызмы?

Без, өч малай, мопедны өстерәп читкәрәк китә башладык. Шулвакыт теге апа безнең каршыга басты да:

— Егетләр, туктагыз әле,— диде.

Без туктап калдык. Теге апа ашыгып сөйләргә тотынды:

— Сез әйбәт малайларга охшагансыз. Сезгә минем бер үтенечем бар иде...

Үтенеч сүзен ишеткәч, безнең чырайлар бозыла башлады, бер урында таптанып куйдык. Өлкәннәрнең уен белмәссең: кечкенә генә үтенеч дип, әллә нинди эшкә кушарлар.

Безнең күңелдә нинди шикләр уянганы йөзләребезгә язылган иде, ахрысы, әлеге апа безне тынычландырырга ашыкты:

— Танышыйк әле башта,— диде ул.— Мин Кадрия Сабитовна Зөфәрова булам. Укытучы. Менә сезнең кебек егетләргә француз телен өйрәтәм. Минем дә сезнең кебек улым бар, ләкин ул авыру, урамга чыга алмый. Иртәгә менә Май бәйрәме. Берәр сәгатькә генә булса да шуның янына кереп утыра алмассызмы дигән идем. Мөгаен сез гитарада уйныйсыздыр, магнитофоннарыгыз да бардыр. Уйнагыз, җырлагыз, теләсә нәрсә кыланыгыз, тик аның күңелен ачыгыз бераз. Зинһар өчен...

Кадрия Сабитовна, сумкасыннан егерме биш сум акча алып, Сашага сузды:

— Үзегез тигезләп бүлерсез шунда. Ә без менә монда торабыз.— Ул ике катлы, ис̆кереп беткән бер өйгә күрсәтте һәм квартира номерын атады.— Тик зинһар Артурга — минем улымның исеме Артур — үзегезне мин чакырганны әйтмәгез. Шушы ишегалды малайлары буларак, хәл белергә генә кердек, диегез.

Кадрия Сабитовна, безне кире уйламасыннар диптер инде, ашыга-ашыга китеп барды.

Май бәйрәме көнне без Артурларга киттек. Кадрия Сабитовна безне бик гаҗәпләнгән булып каршы алды.

— Улым Артур,— диде ул, дулкынлануын яшермичә,— синең яныңа егетләр килгән. Берге-бергә күңелле генә утырыгыз.

Кадрия Сабитовна өстәл әзерләде. Нindидер тәмле-тәмле ризыклар пешергән иде, һәрберебезне кыстый-кыстый ашатты. Артур гел ятып кына тора икән. Кулларын да бик авырлык белән генә кыймылдата. Кадрия Сабитовна аның аркасына берничә мендәр куеп, шуңарга улын сөяп утыртты. Безнең тартынып утыруыбызны күреп, Кадрия Сабитовна чыгып китте.

— Сез утырыгыз, егетләр, минем бер җиргә барып кайтасым бар,— диде ул.

Мин Әтигә, кыска гына итеп, шуларны сөйләп бирдем. Әти минем сүзләрдән соң җанланып китте. Аның күңелендә нindидер план туды, ахрысы.

— Әйдә, җыен,— диде ул,— Кадрия Сабитовналарга барабыз. Магнитофоныңны да ал, Артурга калдырып торырсың.

Без, тиз генә киенеп, Кадрия Сабитовналарга киттек. Озак-озак звонок биреп торсак та ишек ачучы булмады.

— Артур өйдә үзе генәдер,— дидем мин әтигә,— башка вакытта килербез.

Без китәргә җыенып торганда Кадрия Сабитовна кайтып керде.

— Әллә безгә кунаклар килгән инде,— диде ул, бер — әтигә, бер миңа карап.— О-о, кунакларның да нindие икән әле. Габдрахман Зарипович! Караңгыда танымый да торам. Әйдәгез, әйдә, өйгә узыгыз.

Кадрия Сабитовна, ишеген ачып, безне алга уздырды да коридорларының утын кабызды. Әти, эшләпәсен салып, чөйгә элде.

— Менә кайда яшәп ята икән безнең булачак депутатыбыз. Күршеләр үк икәнбез бит.

— Депутат булулар безгә тәтемәс инде ул. Сезнең кебек көндәшләр барында бездәй гади бәндәләргә тавыш биреп тормаслар,— диде Кадрия Сабитовна.

— Алай димәгез, Кадрия Сабитовна, укытучылар булмаса, без беребез дә юк. Кем әйтмешли, дөньяда иң галим, иң гүзәл кеше сез. Кая әле, кая, эчкә дә үтик. Ничегрәк яшәп ятасыз икән.

Эти эчкә узды. Күптән белгән кешесе итеп, Артур белән дә исәнләште. Аның шулай кеше белән тиз арада уртак тел табуына гаҗәпләнеп карап тордым.

— Матур гына икән дөньягыз,— диде ул, бер бүлмәле фатирны баштан аяк күз йөртеп чыкканнан соң.— Кая карама пөхтәлек, чисталык. Ничек шулай барысына да өлгерәсез, Кадрия Сабитовна? Авырдыр бит? Укытасыз, өй мәшәкатьләре, тагын менә депутат та булып китсәгез...

— Җиңел түгел инде,— диде Кадрия Сабитовна көрсенеп.— Ә депутатлыкка килгәндә, коллектив сүзенә каршы килмим, дип кенә ризалыгымны биргән идем. Аннары күрәш, ничектер, үзенә тарта башлады. Күңелгә төрле уйлар килде. Нигә әле, мин әйтәм, гел бер үк кешеләр генә сайланырга тиеш? Без алардан киммени?! Иң ачуны китергәне шул: үзең сайлап куйган депутатка йомыш белән дә керә алмый башлыйсың. Озак торса бал да ачый дигәндәй, гел бер үк кешеләр сайлана килгәч — бозыла шул. Заманның болгануы да менә шуннан бит, Габдрахман Зарипович.

— Әйе, әйе,— диде эти,— эш-эш дип, кешеләрне онытып җибәрәбез.— Аннан соң эти як-ягына каранып куйды:

— Әллә телефоныгыз да юк инде, Кадрия Сабитовна?

— Әй ул телефон! — диде Кадрия Сабитовна, авыр көрсенеп.— Телефон гына түгел, бәгырьгә утырган таш булды ул. Күпме җирләргә яздым, күпме түрәләрнең бусагасын таптадым — юк, диләр, өегезгә кабель кермәгән, диләр.

— Ничек инде шушындый хәлдә телефонсыз яшәргә мөмкин? Әгәр төнлә «ашыгыч ярдәм» чакыртырга кирәк булса? Ялгыз калган чакларда авыру кешегә нәрсә кирәк булмас.

Эти бик озак тузынды, соңыннан:

— Нигә соң аны миңа язмадыгыз? — диде.

— Яздым, Габдрахман Зарипович, сезгә дә яздым. Хәтта бер генә мәртәбә дә түгел.

Кадрия Сабитовна тиз-тиз шкаф тартмаларын актарырга тотынды. Тартмадан кулъяулыкка төреп куелган бер төргәк хатлар тартып чыгарды.

— Менә алар, Габдрахман Зарипович, болар бар да телефон куеп булмый дип, килгән җаваплар!! Монда сезнең кулыгыз куелганнары да бар.

Эти бик үкенгән кыяфәт белән хатларны караштырып утырды.

— Эш, эш дип бер әйләнешкә кереп китәбез дә кешеләр язмышы турында кайгыртырга вакытыбыз калмый,— диде эти, хатларны хуҗасына тапшырып.— Ярар, соң булса да уң булсын ди бит халык. Иртәгедән сезгә телефон кертерләр. Үземнең өй телефонын сезгә күчерттерермен. Ярамый болай, ярамый. Тешлерәк тә булырга кирәк, Кадрия Сабитовна. Хәзер заманы шундый. Бар нәрсәсе җитеш кешене генә тыйнаклык бизи.

Эти, кешеләрдә миһербан, шәфкать бетеп бара, дип, озак кына сөйләнде. Киткән чакта мин Артурга магнитофонымны калдырдым. Ул тарткалашып маташты, алмаска теләде. Эти әйткәч кенә ризалашты.

Өйгә кайту белән эти кемнәргәдер шалтыратты: берәүләрне эт итеп сүкте, икенче берәүләргә урыныннан очыру белән янады. Ахыргы сүз шул булды: «Хәзер үк минем өемә ике телефонистыңны җибәр, минем номерны әнә Зөфәровага күчер. Алар йортына кабель кермәгән дисең-

ме? Ә син безнең йорт белән алар йорты арасында ничә метр ара икәнен беләсеңме? Вәт шул! Кабель кермәсә, түбәдән чыбык сузарсыз. Бер түбәдән икенче түбәгә мәче сикерерлек ара, шуңа җитәрлек кенә чыбык табарсыз, дип уйлыйм. Әйе, әйе, дөрес аңлагансың. Нәкъ менә минем телефонны Зөфәровага керт, башкасы турында соңыннан сөйләшербез».

Бер сәгать үткәндерме-юкмы, безгә монтерлар килеп тә керде. Түбәдән чыбык сузып безнең телефонны Кадрия Сабитовналарга күчерделәр.

— Монысын ничек аңларга инде? — диде әни.

— Шаулама, әнкәсе, шаулама. Димәк, шулай кирәк,— диде әти.

Ул тагын берничә мәртәбә Кадрия Сабитовналарга барып кайтты, ә тиздән Зөфәрованың үз кандидатурасын кире алуы турында газеталарда хәбәр иттеләр.

— Карале, Габдрахман,— диде әни соклану һәм гаҗәпләнү белән.— Син бөтен кошларны этеп төшереп, чит ояда хуҗа булып калган күке баласына охшап киттең. Хәзер барлык җим синең авызыңа гына эләгәчәк.

— Дөнья ул үзе дә зур бер оя, әнкәсе. Анда һәркем берсен берсе этеп төшерергә тырыша. Кем көчлерәк — ояга шул хуҗа. Әмма оядан этеп төшерүнең дә үз җае бар. Үзең этеп төшергән кош баласы түбәнгә тәгәрәгәндә бөтен кошка караганда да ныграк кычкыр, җәллэгән бул, күз яше түк. Бүтәннәр синең өзгәләнгәнеңне күреп, үзеңне җәлләсеннәр. Вакытын, җаен туры китереп үз ризыгыңны бүтәннәргә бир, саранланма. Синең бер юмартлыгың бервакыт мең рәхмәт булып үзеңә кайтачак.

Әти рухланып озак кына сөйләнде. Аннары болай дип сүзен тәмамлады:

— Ә теге Кадрия Сабитовна хәзер гомере буе рәхмәт укыячак. Малаена коляска табуда булыштым. Хәзер ул үзе үк минем кандидатураны яклап кешеләрне агитацияләчәк. Хәер, агитацияләргә өлгерә алмастыр да, чөнки аның малаена ике айлык путевка таптык. Икәүләп санаторийга китәчәкләр.

Менә, ниһаять, бүген — сайлаулар көне. Әтиебезнең сайлануына беребезнең дә шиге юк. Тиздән ул өйгә балкып кайтып керер. Инде табын әзер. Затлы ризыклар, татлы шәраблар белән өстәл тулган. Сайлау нәтиҗәләре билгеле булуга, әтинең дуслары котларга килә башлар. Кичә телефон куярга дип тә килгәннәр иде, ләкин әти әлегә куйдыртмады. Чөнки моннан берничә көн элек кенә әтинең үз телефонын бер инвалидка керттерүе турында газетага зур итеп мәкалә язып чыкканнар иде. Менә шул шаукым бераз сүрелсен, шуннан соң барысын да эшләтәчәк безнең әти. Безнең әти ул тау астыннан бәреп чыккан күкертле чишмә кебек. Андый чишмәне таш белән бастырып куеп кына агуыннан туктатып булмый. Бастырсаң — таш астыннан чыгар, юлын бусаң — урап үтәр. Аның суы эләккән барлык үсемлек саргаеп калыр, үсүеннән туктар, ә чишмә агар да агар...

## Зиннур Хөснияр

# КИЧҮ



Узара шаярышып, бер-берсе белән уйнаган төсле генә күренгән кара сыртлы дулкыннар, килеп җитәрәк, сыртларын тагын да кабартып, дәррәү ярга ташланалар. Һәр яңа дулкын өере килеп бәрелгән саен комлы яр, сыкранып-сызланып кына артка чигенәдер, дулкыннар аны авызларын чапылдата-чапылдата, кабаланмыйча, түмен белеп кенә ашыйлар, кимерәләрдер шикелле. Су чәчрәгәннәнме, әллә чарасызлыктанмы, ярның маңгае юешләнеп, тирләп чыккан кебек.

Яр буенда баш сөякләре таралышып ята. Адәм башлары, бу рәвешле аунап ятуларына хурлангандай, ярга бәрелгән дулкынга ияреп, әчкә тәгәриләр. Чираттагы дулкын аларны кире кагып чыгара.

Баш сөякләре диңгез кебек бу зур суның Мөхәммәт атлы малай яшәгән аргы ягында да күп. Халык аларны, җыеп, зиратка илтеп күмә. Ләкин алар һаман пәйда булып тора, башларны җыеп бетерә торган түгел...

Өстенә кыска соры кожан кигән, тәбәнәк буйлы, җыерчыклы, ләкин чиста, күркәм йөзле карттан кала, яр буендагыларның берсе дә аунап яткан баш сөякләренә игътибар итми кебек. Карт, баш сөякләренең әле берсенә, әле икенчесенә озаклап карап тора-тора да, авыр көрсенеп, карашын югары күтәрә, аннары су кырыена ук килеп, буш кулын каш өстенә куйган килеш, Зур Су өстен күзли.

Картның аркасында соры киндер капчык. Нәрсә тутыргандыр — капчык хәйран авыр күренә, карт аны авырлык белән генә бер иңбашыннан икенчесенә күчереп тора. Җиргә генә куйса инде кана!

Мөхәммәт атлы малай, шул турыда әйтергә теләгәндәй, аңа таба тартыла. Ләкин кулыннан әтисе кысып тоткан, җибәрми.

Капчыклының яр буендагы көймәче карт янына килеп аңа нидер әйтәсе дә килә шикелле. Менә борылды, хәтта аңа таба бер-ике адым атлап та куйды, тик бармады, арырак яткан баш сөякләрен карарга кереште.

Мөхәммәтләр монда килгәндә әлеге карт көймәче белән ни хакындадыр кызу-кызу сөйләшә иде. Кешеләр килгәч, сүзләре бүленде, ахрысы, туктап калдылар. Көймәче аңа:

— Кит әле, кит. Комачаулама! — диде. Ачуланып әйтмәде, болай гына, үз итеп кенә куалады.

Көймәче карт көймәнең моторын кабызып азаплана. Мөхәммәт атлы малай яшәгән кырык йортлы авылның барча сыерына да берьюлы башак болгатып бирерлек агач тагарак хәтле бу көймәнең кузгалып киткәнен тагын өч кеше түземсезләнеп көтә. Икесе — ак якалы, галстуклы, күн тужуркалы кырык-кырык биш яшьләрдәге пеләш маңгайлы абыйлар. Өченчесе — Мөхәммәтләр белән бергә килгәне — кәләпүшле, түгәрәк ак сакаллы карт. Мулла бабай.

Көймәче карт мотор бавын бар көченә тарта. Мотор төчкергәндәй итенә дә тагын тына. Күн тужуркалы абыйлар көймә хуҗасын ашыктыралар, берсе, өлкәнрәге һәм түгәрәк корсаклысы, әледән-әле сәгатенә карый, янә көймәчене ашыктыра.

— Бу абыең шушы җирләрнең, бу Зур Суның хуҗасы, — ди

этисе Мөхәммәткә һәм үзе аңа сүз кушарга, аның белән сөйләшергә бик теләсә дә, кыюлыгы җитми, уңайсызлана, читтәрәк торырга тырыша. Аның район башлыгына әйтәсе сүзе бар. Колхозга кайткан яңа тракторга председатель тагын үз туганының кияven утыртмакчы. Югыйсә, чират Мөхәммәтнең этисендә иде.

Хуҗаның кәефе юклыгы йөзенә чыккан. Аскы ирене кысылган, кулындагы сәгатенә еш-еш карый. Тиздән аның районына Мәскәү кешеләре, Казан җитәкчеләре килеп төшәчәк. Әүвәл алар Зур Суның бу ягына килергә кушылган иде. Районның барлык җитәкчеләре дә таң тишегеннән үк бу як ярга җыелды. Ныклап, зурдан кубып, кунакларны көттеләр.

Ярты сәгать элек кенә яңа хәбәр ирештерделәр: җитәкчеләр әүвәл теге ярга, райүзәккә киләселәр икән.

Моннан теге якка күпер аша әйләнеп чыгу өчен өч сәгатьлек юл үтәргә кирәк. Ә җитәкчеләр исә сәгать унбердә, ягъни тагын нәкъ бер сәгатьтән райүзәктә булачаклар. Самолетка күпер кирәкми, ул туры юлдан оча. Моторлы көймәдә исә Зур Суны кырык минутта кичеп чыгып була. Хуҗа кеше үзенең ярдәмчесе белән иң ышанычлы көймәне сайлаган иде. Каһәр суккан мотор һаман кабынмый!..

Теге карт, капчыгын җиргә куеп авызын чиште дә, иелеп, яр буеннан бер адәм башы сөяген алды һәм капчыгына салып куйды. Ул баядан бирле шул баш сөягенә текәләп карап торган иде. Хуҗадан кала бу хәлгә игътибар итүче дә булмады. Тирә-юнь кешеләренең яр буеннан адәм башлары җыеп йөрүләре хәзер табигый хәл иде. Моннан бер ел элек байтак авыллар, зиратлары белән бергә, Зур Су астында калды. Яр буенда калкан каберлекләргә Зур Су һаман-һаман тынгылык бирми.

Кешеләр бәләкәй генә елгадан Зур Су ясаганда аны бу кадәр үк зураер, киңәер дип башларына да китермәгәннәр иде.

Мөхәммәт атлы малай өчен дә гадәти күренеш иде инде бу. Чөнки аларның мәктәбендә адәм башы сөякләрен җыеп яңа урынга күмү буенча ярыш оештырылды.

Мәскәүлеләр килер алдыннан Хуҗа яр буенда бер генә баш сөяге дә калдырмаска дигән әмер биргән иде. Бу эшне оештыру янәшәсендә басып торган ярдәмчесенә кушылган иде. Хуҗа, тотып ашардай булып, ярдәмчесенә карады. Тегесе куырылып килде, кечерәеп калды, борын очы тирләп чыкты.

Хуҗаның нерв җепләре өзелердәй булып киерелгән иде, ярдәмчесен әрләп яки баядан бирле көймә койрыгында маташкан картны сүгеп берәр сүз әйтсә, ул җеп өзеләчәк һәм аннары ни кылачагын, моның ахыры ни белән бетәчәген ул күз алдына ачык китерә иде. Шуңа күрә бар ачуын эченә җыйды.

Көймәче тагын мотор бавын тартты. Мотор төчкерде, пошкырды да янә сүнде. Хуҗаның түземлеге төкәнде. Көймәчене дорфа гына бер читкә этәрде дә бауны үз кулына алды. Бер аягын көймәгә терәде, икенчесен арткарак шудырды һәм бар көче белән тартып җибәрде. Мотор төчкереп алды да тырылдап эшләргә кереште. Хуҗа кулыннан ычкынып киткән бау бөтерелеп читкә очты һәм капчыклы картның муенына килеп уралды.

Көймәгә беренче булып Хуҗа сикерде, аның артыннан ярдәмчесе үрмәләп менде, аннан соң Мөхәммәтләр утырышты.

Мотор кабынуга ук, муенындагы бауны кулында тоткан килеш, ашыга-ашыга капчыклы карт та килеп җитте һәм капчыгын көймәгә куярга маташты. Көймәче аны читкә этәрде:

— Кит, дидем бит инде. Әйләнеп узам, бүген дә бармыйм. Күрәсең ич көймәдә бала бар, — диде. Ул бу юлы да җикеренеп, ачуланып түгел, бик якын кешесенә яхшы киңәш биргәндәй әйтте. Карт

капчыгын көймәгә салып өлгергән иде инде, көймәченең сүзләренә колак та салмады. Бу сәер сөйләшүне көймәгә кереп урнашкан кешеләр ишетмәдеме, ишетмәгәнгә салыштылармы, сүзгә кушылучы булмады. Аларны тыңлап торган бер Мөхәммәт кенә, күзләрен кыса төшеп, борынын тартып куйды.

Көймә кузгалып китте. Йөзләргә эреле-ваклы тамчылар чәчрәде, дымлы җил, киемнәрне салдыргандай итеп, тәннәрне кытыклады.

Яр да, баш сөякләре дә артта калды.

— Турыдан, түлке турыдан гына! — дип әмер бирде күн туҗуркалы Хуҗа.

Көймәче, сүзен әйтер алдыннан, әүвәл күккә күз ташлады, аннары аның карашы көймәдән читкә чабышкан дулкыннар өстеннән сикереп узды. Зур Суга иялэнмәгән, күнекмәгән кешегә аның холкын белү кыен иде. Кайчандыр көймәче, Зур Суның зурлыгыннан куркып, үзе дә нәкъ менә көймәнең дә шактый зурын ясаган иде. Аның әле һаман Зур Суның табигатенә төшенеп җитә алганы юк. Ул янә күккә карады. Болытлар бик тиз хәрәкәт итә, күктә — Зур Судагы дулкыннар чагылышы. Зур Су өстеннән торып Күкнең дә «телен» аңлый алмады көймәче карт. Күкне аңлау өчен аяк астында җир булуы кирәк иде аңа.

— Турыдан ярамас. Чоңгылны әйләнеп үтәргә кирәк. Җил көчәя, шуңа әйтүем.

Хуҗа нидер әйтергә җыенган иде — дәшмәде, килеште ахрысы. Алайса үзең кара, дигән кебек урынына җайлабрак урнашты, аякларын сузып җибәрде.

Көймәгә әледән-әле шап-шоп килеп бәрелгән дулкыннар аны сәламлидер кебек. Әнә теге чыелдавык су өсте кошлары бу Суның, бу биләмәләрнең хуҗасы хөрмәтенә очалардыр сыман. Бу Зур Су монда аның көче белән барлыкка килде. Бу диңгезне, өстәгеләрнең әмере белән, аның кулы һәм йокысыз төннәре ясады.

Бүген аның бу зур эшен күрергә Мәскәүнең үзеннән үк киләчәкләр. Аны тагын да югарырак күтәрелү көтә. Бу изге эш хакына ул үзенең туган нигезен дә Зур Су астында калдырды. Адәм баласы кайда яшәсә — нигезе шунда, дип уйлый иде Хуҗа.

Аның ата-бабалары гомерләре буена Зур Су күрмәгән. Алар күрмәгәнне балалары күрсен. Суның алыптай көче миллиардларча сукыр лампа уты белән чагыштыргысыз яктылык бирәчәк, хезмәт куячак.

Хуҗа бөек уйларыннан капылт кына аерылырга мәҗбүр булды: бер көйгә генә тырылдап эшләгән көймә моторы бер-ике мәртәбә йөткереп алды да, шым булды. Барысы да койрыкта утырган көймәче картка таба борылдылар. Көймәче, берәүгә дә игътибар итмичә, акрын гына күтәрелде дә моторның капкачын ачты, башын чайкый-чайкый беркавым карап торды да кире япты. Аннары, кабызгычка бау урап, кисәк тартып җибәрде — өмет күренмәде. Тагын тартты, тагын — юк. Каушап калган көймәче карт Хуҗага гаепле караш төбәде:

— Бетте бу. Кабынмый. Минем аны күптән эшләткәнем юк иде. Мин шул ишкәкләр белән генә инде...

Хуҗа урыныннан кузгалып өлгергәнче, Мөхәммәтнең этисе, үзе ярдәм сорап барачак җитәкчегә яхшатланыпмы, җәһәт кенә мотор янына килде дә бауны уң кулына урады. Көймә чайкалып китте, мотор сәер тавыш чыгарып пырхылдады, Мөхәммәтнең этисе кулындагы бауны кире чорнады, янә аны үзенә таба йолкыды. Әмма мотор кабынмады, ә Мөхәммәтнең этисе моторга күкрәге белән капланды да башы белән суга чумды.

Бу көтелмәгән хәл көймәдәгеләрне өнсез итте, бик нык каушатты. Мөхәммәт шырыйлап кычкырып, этисен коткарырга дип көймә кырыена менеп атлангач кына, аңнарына килделәр. Хуҗа малайны

кырыйдан каерып алды, аның ярдәмчесе белән көймәче карт Мөхәммәт әтисенә көймәгә менәргә булыштылар.

Көймәче карт, ишкәкләрне алып, ике якка беркетте. Бары капчыклы карт кына, капчыгын тиз өстенә утыртып, берни булмагандай, ирен читләре белән елмаеп утыра.

— Синең нигезең монда иеме әллә? — дип сорады ул беркавымнан Мөхәммәтнең әтисеннән.

— Нинди нигез?

— Авылың дим, шушы урында ие мәллә? — диде капчыклы карт суга таба ымлап.

Мөхәммәтнең әтисе су астында калган әтисе авылының кайда икәнлеген тәгаен генә белми иде, күрәсең, иңбашларын гына сикертеп куйды.

— Алай... — дип сузды капчыклы карт. — Нигезең чакыра микән әллә дигәнием.

Мулла бабай көймә төбенә тезләнеп, күзләрен күккә төбәде, авыз эченнән медер-медер дога укырга кереште.

— Нишлисең, алла ялчысы! Безне кемнәргә саныйсың син! Туктат! — дип җикеренде Хуҗа, аннары, борылып, ачу белән суга төкерде.

— Мулла бабай бит ул! Мулла бабай! — диде Мөхәммәтнең әтисе исем кушучы бабайның бу кыланышын акларга теләгәндәй.

— Мулла?! Нинди мулла ул? Нинди мулла ди ул безнең заманда?

— Хуҗа бу сүзләрен баягы шикелле җикеренеп тә, кычкырып та әйтмәде. — Мулла булса, намазлыгында гына утырсын.Ниемә дип йөри ул?

— Минем малайга исем кушарга бара ул. Мин алып кайтып барам аны, — диде Мөхәммәтнең әтисе, төп гаепнең үзендә икәнлеген Хуҗага аңлатмакчы булып.

— Син коммунистмы?

— Кандидат, — диде Мөхәммәтнең әтисе кыюсыз гына.

— Һе... Кандидат. Бер кесәңдә Корьән, икенчесендә партбилет йөртергә уйлаган идеңме? Кайтуга кандидатлыктан чыгарга гариза язган бул! Алайса сине партиягә алган кеше үз партбилетыннан колак кагачак! Аңладыңмы?

«Аңладым. Анысы синең эш, теләсә ни кыл. Барыбер үз теләгем белән кермәгәнием. Түлке миңа яңа трактор гына бирдерттер, — дип уйлады Мөхәммәтнең әтисе. Аннары: — Ай-һай! Яңа тракторны бирмәс бу адәм», — дип офтанды.

Хуҗа аңа кырын күз белән генә карап куйды. Мөхәммәтнең әтисе бу караштан куырылып килде. Әтисен җылытыйм дип, нечкә беләкләре белән аның муеныннан кочаклаган Мөхәммәт суга чыланган тәндә җиңелчә генә дерелдәү тойды.

Үз карашының тәэсирен Хуҗа да яхшы күрде.

— Иә, ярый, туңасың, җылын бераз, әнә кулыңа ишкәкләрне ал, — диде ул һәм күн тужуркасын салып Мөхәммәтнең әтисенә сузды. — Мә, ки моны.

Хуҗаның «ярый» дип ни турында әйткәнлеген Мөхәммәтнең әтисе төшенеп җитмәде, кайтарып сорарга исә уңайсыз иде. Ул эчтән генә үзен мулла артыннан аргы якка чыгарып җибәргән хатынын орышты. Исем кушарга кирәк, имеш. Исеме бар бит инде аның, акка кара белән язылган!..

Ишкәк белән генә дә җитәкчеләр килгәнче аргы якка чыгып җитеп була иде әле. Шуңа күрә Хуҗа тыныч. Мулла бабайга да бүтән бәйләнмәде. Тик ишкәк көенә генә барган көймәнең акрынаюына бераз эче пошты бугай, ара-тирә Мөхәммәтнең әтисенә күз төшереп ала. Һәр караш саен көймә кызулагандай итә кебек.

Мулла бабай медер-медер капчыклы карт белән сөйләшә, дө-

ресрәге, үзе генә сөйли. Капчыклы аны тыныч кына тыңлап утыра.
— Инешләр елгага, елгалар диңгезгә әверелә. Җир өстен су баса, коры җир тарая. Дөнья имансыз бәндәләр белән тулган. Алланы санга алучы, аннан куркучы кеше калмады.
— Әһе, — ди капчыклы карт аның сүзләре белән килешкәнлеген аңлатып.
«Ә мин Алладан куркаммы соң?» — дип уйлый Мөхәммәт атлы малай.
— Адәмнәрнең табынып нәрсәләре калмады, шуңа күрә халык бозылды хәзер. Ата-бабасының каберен җуйган кеше ничек итеп иртәге көне турында уйлый алсын инде. Нигезләрне, каберлекләрне су юып алып китте.
— Әһе, әһе! — диде капчыклы карт бу юлы.
Мулла бабайның сүзләре көймәдәгеләрнең һәммәсенә дә ишетелгән икән. Хуҗа аңа таба караган килеш урынында кымшанып куйды һәм:
— Их, бабай, бабакай! — дип мыскыллы көлемсерәде. Аның аскы ирене бер якка тартышып куйды. «Бетте! Әләгәчәк хәзер бу картка!» — дип куркынып уйланды Хуҗаның гадәтләрен яхшы үзләштергән ярдәмче. Әйе, аскы иреннең чалшаюы юньлегә түгел икәнен белә иде ул. Ләкин Хуҗа беренче мәртәбә үзенең гадәтенә каршы барды: җикеренмәде, кычкырмады, «өстәл» сукмады. Күрәсең, мулла бабайның томаналыгы аның күңеленә чынлап тигән иде, ул үзе инанган нәрсәгә шушы картның да ышануын, аның катып калган фикерләрен җебетергә тели иде. Шуңа күрә, менә-менә чыгырдан чыгам дигәндә генә, холкының дилбегәсен тарта төшеп, сүзен тыныч кына дәвам итте:
— Инде җитмеш ел яңа тормышта, яңа заманда яшибез ләбаса! Нуҗәли синең башка һаман барып җитә алмый. Алла дисең, иман дисең... Нигә безгә булмаган әллә нинди аллага ышанып, булмаган нәрсәгә табынып яшәргә ди. Дураклар што ли! Җиргә кеше үзе хуҗа. Алла — без ул, кеше үзе алла ул, беләсең килсә!
— Тфү! Кит, кяфер! Тфү! Авызыңнан җил алсын!..
Мулла бабайның тавышы бик зәгыйфь чыкты, гәүдәсе бөтенләй бөрешеп, кечерәеп калды. Әзмәвер яшь ир каршында ул тагын да бәләкәй иде. Иөзәрләгән кешелек зур залларда утлы чыгышлар ясап, аларның дәррәү кул чапканнарына күнегеп беткән Хуҗа иренеп кенә елмайды да дәвам итте:
— Син бераз аңлап калмассың микән, дип кенә сөйләвем, бабакай, ачуланма. Менә мин, мәсәлән, үземә үзем алла. Шулай булмаса, казлар гына коена торган елгадан шушындый диңгез ясый алыр идекмени? Теге чакларда чыра яктысы, сукыр лампа яктысы синең күзеңне бетергән, күрмисең син, менә шул! Иман дисең, минем иманның нәрсә икәнлеген әйтимме соң (Хуҗа, ике кулын да җәеп җибәреп, Зур Суга күрсәтте). Менә шушы минем хезмәтем, йокысыз төннәрем! Бу Зур Су кешеләр өчен, менә синең өчен кирәк! Ә син алла, алла дип сөйләнәсең... Аллаң алай бик тә кодрәтле, акыллы булса, монда инеш түгел, Зур Су ясаган булыр иде. Бу эшне безгә калдырмас иде!
Мулла бабайның күзләре зур булып ачылган иде, ул, көймә төбенә тезләнде дә, ашыга-ашыга дога укырга керешә.
— Кяфер син! Имансыз икәнсең!
Хуҗа тагын көлеп җибәрде, көймәдәгеләргә күз ташлады. Әмма бу юлы нигәдер аңа кушылып көлүче булмады. Карт белән сүз көрәштерү Хуҗаның үзенә дә ошамаган иде. Ул үзенең ваклануын тойды. Бер аягы гүрдә торган карт белән мәктәп баласы кебек бәхәскә керү аның өчен килешә торган гамәл түгел иде. Хуҗа моны яхшы сизде. Гаепле икәнлеген тойган чакларда гел нинди дә бул-

са аклану эзләргә гадәтләнгән бу кеше, шактый ук кәефе кырылса да, гадәтенә тугры булып калды: «Бу очракта мин дәшми калырга тиеш түгел идем бит. Коммунист буларак та, җитәкче буларак та. Әйе, дәшми калырга тиеш түгел идем. Минем үз иманым, минем үз хакыйкатем бар ләбаса. Үземнеке генә түгел, миллионнарныкы...»

Җил исеп куйды. Көймәгә бәрелеп югары сикергән су тамчылары, аның хакыйкате булган Зур Суның берничә тамчысы, Хуҗаның битенә кунды. Шәлперәйгән карт белән сүз көрәштереп утыруына әле һаман эче пошса да, салкын тамчылар аның кызган йөзенә рәхәтлек бирде, кәефен күтәреп җибәрде.

Бу вакытта Мөхәммәт атлы малайның да үз уйлары иде. Өлкәннәрдән күргән, ишеткән һәр нәрсәне үз иләгеннән чыгарып, шулардан үзе өчен дә сөземтә табарга яраткан бу хыялый малай үзенең иманы бармы-юкмы икәнлеге турында баш ватты. Ул моның ни икәнен бигүк аңламаса да, күңеле белән тоя, сизә, аны аңларга азаплана иде. Нәрсә икән соң аның иманы? Тапты... тапты! Ул велосипед турында хыяллана, шул хакта бик еш уйлый. Әтисе һаман алып бирми дә бирми. Тагынмы? Энесе тизрәк үсеп җитсен дә, бергәләшеп менә бу Зур Суга балыкка йөрерләр иде.

Мөхәммәт атлы малайның күзләре елтырап китте, ирексездән авызы ерылды. Әменә «Хуҗа» дигән абыйның иманы, ай-һай, зур икән! Диңгез хәтле! Шушы Зур Су — минем иманым, диде бит...

Әтисенең иманы нәрсә? Ул, Су астындагы нигезләрендә бабайлардан калган бер чүлмәк алтын булырга тиеш, ди. Элек казый алмаган иде. Хәзер менә алтынны Зур Су үзе казып чыгаргандыр. Тик ничек төшеп аласы? Әтисенең иманы шул чүлмәк эчендә микәнни?!

«Юк! — диде аннары Мөхәммәт атлы малай үзалдына катгый итеп. — Иман болай булмый ла ул! Мулла бабай аны бик зур итеп, серле итеп әйтте. Алайса мин иманның нәрсә икәнен белмим икән».

Мөхәммәт атлы малай, күңелсезләнеп, Зур Су өстендә куышкан дулкыннарны күзәтергә керешге. «Хуҗа абыйның иманы барыбер зур икән шул», — дип уйлады ул.

Дулкыннар һаман чабыша. Мөхәммәт атлы малайның, шуларга кушылып, куышлы уйныйсы килә башлады. Ул дулкыннар аның өчен тере, җанлы кебек иде.

Баш өстеннән генә аргы якка таба самолет очып узды. Хуҗаның дерт итеп сискәнүеннән тагарак-көймә дә чайкалып киткәндәй булды. Ул күзләрен зур ачып ярдәмчесенә карады. Тегесе исә «белмим шул» дигәндәй иңбашларын сикертте, аның карашы да самолетны озата бара иде.

— Турыга чыгабыз! Турыга! Турыга! — дип боерды Хуҗа. — Өлгермибез! Турыга.

Көймә борылды. Капчыклы карт тез өстендәге капчыгын күкрәгенә кысты. Йөрәге дөп-дөп тибә, капчык кочаклаган куллары калтырый иде. Димәк... димәк, юллары аның нигезе турысыннан узачак. Аның хыялы, сиксән ике яшьлек картның теләгәне, күңеленә кереп оялаган уе, ниһаять, кабул булырмы икәнни? Иншалла!..

Су өстендә дулкыннар ишәйде, көймәгә берөзлексез шап та шоп сугып торган кара сыртлы дулкыннар зурайды. Бая ук, болар баш сөякләре аунап яткан ярдан кузгалып киткән чакта ук, Зур Су өстендә тиздән булачак Давыл турында хәбәр бар иде инде. Аны Зур Су үзе хәбәр итте. Ләкин гомерләре буе Зур Су күрмәгән, аның телен аңламаган, белмәгән картлар да, бу Зур Суны ясаткан Хуҗа да якынлашып килгән Давыл хәбәрен аңламадылар.

Ишкәкләр һаман Мөхәммәтнең әтисе кулында иде әле. Ул үз янында утырган малаена күз салды. Аның беләкләре көч белән тулды, ул ашыга-ашыга ишге.

— Турыга чыгарга ярамый. Анда, алда чоңгыл бар. Давыл килә бугай, — диде көймәче. Бу сүзләрне әйткәндә ул ни өчендер, малай белән киңәшкәндәй, Мөхәммәткә карады.

— Турыга! — диде Хуҗа, тешләрен кысып. Көймәдәгеләр, син әйтеп кара әле, сине тыңламас микән дигән кебек, ярдәмчегә төбәлделәр.

— Турыга кирәктер. Бәлкем, давылга кадәр чыгып җитәрбез әле. Әйләнечтән чыгып өлгереп булмас.

— Турыга! — дип кабатлады Хуҗа.

Давыл гына түгел, тагын әллә ни кузгалса да курыкмый иде ул. Бу аның үзе ясаган суы, бу суны дөньяга ул китерде. Үз суы аны йотмаячак...

«Шөкер! Турыга...» — дип уйлады Капчыклы. Аның күңеле йомшарды. Калтыранган куллары белән кабалана-кабалана капчык бавын чишеп җибәрде һәм аннан адәм башы сөяге алып, Хуҗага таба сузды.

— Мә.

Хуҗа, чирканып, артка тайпылды:

— Кит! Миңа ниемә ул! Нәрсә ул!!!

— Атаң башы...

Картның үзенчә аңа яхшылык кылуы иде бу.

Көймәдәгеләр, куркуларын да онытып, карт белән Хуҗага төбәлделәр.

— Исәр карт! Шашкан карт!!!

— Юк, энем. Үз акылымда мин. Чынлап та синең атаң башы бу. Кормашныкы бит син, Галиулла малае, ялгышмасам, — диде карт һәм суга таба күрсәтте. — Менә сезнең авыл бу урында иде. Әтиең урман каравылчысы иде, башына атып үтерделәр. Гәүдәсен урманда без таптык аның. Менә маңгаенданы җәдрә чокырларын күрәсеңме? Җәдрә тишекләре.

Көймәдәгеләрнең колаклары үрә торды. Хуҗаның йөзе каралып чыкты. Ул берара әйтер сүзен дә әйтә алмыйча утырды, капылт кына урыныннан торып, карт кулындагы баш сөяген үзенә алды. Хуҗа берничә мизгелгә генә югалып калды, аз гына вакытка гадәттә боз-төймәгә охшаган күзләре, бөтенләй үзгәргән шикелле булып, гөнаһсыз сабый малайныкына охшап калды. Аның бу халәтен капчыклы карттан кала берәү дә күреп өлгермәде, чөнки аларның карашлары Хуҗа ни кылырга да белмичә кулында тотып торган баш сөягендә иде.

Яшен уты кабынып сүнәрлек вакыт арасы узды микән, аның күзләрендәге малайлык сүнеп юкка чыкты. Һәм алардан тагын бакыр салкынлыгы сирпелә башлады. Капчыклы карт ул караштa, бая яктырып алган караштa, бу кешенең элек үзенә таныш булган Галиулла исемле атасын танып калган иде...

Сүз-кыяфәте белән йөзләрчә кешене сәгатьләр буе сулатмыйча да тотып торырга сәләтле Хуҗа бары берничә мизгелгә генә үз халәтенә хуҗа була алмады.

Ул баш сөяген ачу белән дулкыннар арасына томырды...

— Тфү, черт! Шашкан карт!!!

Көчәя барган дулкыннар бу сүзләрне үз кочагына суырып алдылар да аннары кире өскә чөеп җибәрделәр, кайтаваз тонык кына булып ишетелде:

— Шашкан... ш-ш-шшаш-ш-шка-а-а-а-аан...

— Шашкан! — дип кабатлады Зур Су хасил итәм дип маңгай чәчләре пеләшләнгән Хуҗа.

Көймәгә зур-зур дулкыннар килеп орды. Көймә бала бишегедәй чайкалырга, тирбәнергә кереште.

Мөхәммәтнең этисе арыды, талчыкты, әмма ишкәкләрне кулыннан ычкындырмады. Ләкин монда көч кенә түгел, осталык, Зур Суда зур осталык та кирәк иде. Көймәче ишкәкләрне үзенә алды, гомер иткән чал картның Зур Суда бер еллык кына булса да тәҗрибәсе бар иде.

Мөхәммәтнең этисе малаен кочагына алды һәм, котыласыларына ышаныр-ышанмас, аргы ярга төбәлде. Яр буе күренми, аргы ярда пәри туе, ярны тузан болыты баскан иде...

Мулла бабай, көймә төбенә тезләнеп, алладан ярдәм сорый. Ике кулын да күккә сузганлыктан, көймә чайкалганда, ул егылып китә, башы белән көймә кырыена бәрелә. Мөхәммәтнең этисе буш кулы белән аның чабуыннан тотып, егылудан сакларга тырыша.

— Баягы сүзләрең ходайга барып иреште. Синең аркада гына бу! — ди кинәт Мулла бабай. — Ярлыка диген! Нәзер әйт!

Ул моны Хуҗага карап әйтмәсә дә, кемгә ишарәләгәне яхшы аңлашыла.

— Алга! Турыга! — ди Хуҗа ярсып.

«Ходайдан гафу сора!» — ди Мөхәммәтнең этисе эчтән генә.

«Карышма инде, мәлгунь!» — дип уйлый көймәче карт.

— Нигез кычкыра! — ди капчыгын кысып тоткан карт.

— Алга! Турыга!

— Иманың юк синең! — ди Мулла бабай. — Гафу сора!

— Синең ул гафуың белән генә котылып булыр дип беләсеңме әллә син, алланың кашка тәкәсе! — дип җикеренде Хуҗа һәм ишкәкчене читкә этәреп, аның урынына үзе утырды. — Көч кирәк монда, баш кирәк бу афәттән котылу өчен!

Ул каерылып-каерылып ишә башлады. Көймә бераз тынычлангандай булды.

— Нигез кычкыра! Нигез чакыра! — диде капчыклы карт. Аның элекке авылы нәкъ чоңгыл турысында иде.

Ишелеп-ишелеп килгән дулкыннар көймәне йомычка урынына чөеп йөртә башлады. Көймәче карт Хуҗа кулындагы ишкәкләрне тартып диярлек алды, үзенең бу кыланышын аклагандай:

— Дулкынга борыны белән тотарга кирәк, борыны белән! — дип кычкырды.

Котылуга әллә ни ышаныч күренми иде. Көймә чоңгылга килеп керде. Һәм, шырпы тартмасы кебек, бер урында әйләнергә кереште. Ишкәкләргә Мөхәммәтнең этисе утырды. Әмма йомычка урынына бөтерелгән тагарак-көймә ишкәкләрне генә санларлык түгел иде инде.

— Ходайның ярлыкавын сора! — диде Мулла бабай.

— Тыңла сүзне! — дип кычкырды көймәче карт.

Бу вакытта аның бәләкәй гәүдәсе үсеп киткәндәй булды, әзмәвер кебек Хуҗа, киресенчә, кечерәеп, бөтерешеп калды.

Капчыклы карт, көймә кырыена тотынып, аягына торып басты да айкала-чайкала койрык турысына китте һәм, шактый авыр капчыгының бавын җәһәт кенә муенына куйды да, суга егылып төште. Көймәче авызын ачкан килеш катып калды.

— Нигез кычкыра! — диделәр көймәне йомычка урынына йөрткән дулкыннар.

Бу хәлне күреп торган көймәдәгеләр берни дә кыла алмадылар.

— Коткарыйк! — дип кычкырды, ниһаять, хушына килгән Хуҗа.

Ул үзе йөзә белми иде.

Ул Зур Суда йөзәргә өйрәнмәгән иде...

— Файдасыз! — дип кычкырды көймәче. Дулкыннар шавы арасыннан бу тавыш тагын да дәһшәтле, куркыныч булып ишетелде. — Коткарырга кирәкми аны! Ул үзе котылды инде. Соң инде, соң... Капчыгында таш иде аның! Мин беләм...

Көймәгә таба тагын да зуррак дулкыннар ишелеп килә башлады.

Көймәгә су тулырга кереште. Көймә кырыена ике куллап ябышкан Хуҗа күзләрен чытырдатып йомды. «Иа, Хода!» — дип офтанды Хуҗа. Һәм шулчак күзәнәкләре аша нидер суырылып чыгып, күккә ашты кебек. Гәүдәсе дер-дер калтырарга кереште, ул туңа башлады — гүя тәнендәге җылысы аны ташлап чыккан иде. Бу сәер халәттән аерылып, дөньялыкка кайтасы килде аның, күзен ачмакчы булды... Юк... үлем шулай көтмәгәндә, гади генә килергә тиеш түгел, түгел иде. Тик әнә ул якынлаша бугай... Әнә... куллары, аяклары, башы шыр сөяктән генә икән. Хуҗа үзен инде үлгәндер кебек хис итә башлады. Ләкин үлгән кеше уйлый алмый... Ул уйлый, ул исән әле. «Ю-ю-ю-ююкк!!! Үләсе килми... килми-и-и-и!!! Коткарыгыз мине! Кем?.. Кем?!! Кем коткара ала мине!!! Коткара күр, зинһар!!! Син!!! Син генә!!! Бирмә! Бирмә бу Суга мине! Бары син генә коткара аласың! Көчле диләр, кодрәтле диләр бит сине!!! «Иа, Хода! Ярдәм сорыйм синнән! Үләсем килми бит минем! Алла, Алла, Аллам... бисмилләһи-ррахмани...». Ул Аллага ничек мөрәҗәгать итәсен белми иде. Шуңа күрә бертуктаусыз: «Аллам, Аллам!» — дип кабатлады. Бу изге сүз аны коткарачак, бары шушы сүз генә аны үлем авызыннан йолып калыр сыман иде. Тик... тик... кабул булсын өчен, кычкырып әйтергә кирәктер аны.

— Иа, Хода! Ярлыка син минем гөнаһлы җанымны!!!

Ул, ниһаять, күзләрен ачты, күзләрен зур итеп ачып күккә төбәлде. Янә ашыга-ашыга:

— Аллам, аллам! — дип кабатлады.

Мөхәммәтнең әтисе ишкәкләр белән дулкыннарга каршы көрәште. Дулкын таулары тагарак-көймәне чоңгылдан этеп чыгардылар да аннары үзләре кинәт кенә юашланып калдылар. Мөхәммәтнең әтисе каерып-каерып иште, көймә күндәмләнде, ишкәкләрне тыңлый башлады. Ләкин бу тәмам котылу түгел иде әле...

Шулай да көймәдәгеләр бераз җиңел сулыш алдылар, чөнки аргы ярдагы тузан болыты басыла төшкән, яр буйлары да шәйләнә иде инде. Җирне күргәч, бүтәннәр кебек шатланасы урынга, Хуҗаның гадәттәге кызыллыгы кайта башлаган йөзе янә кара коелды. Алда — яр буе, алда — Зур Су өстендә купкан Давылдан котылу иде; шул өркетте Хуҗаны, шул маңгай чәче пеләшләнгән башын кара кайгыга салды. Бетте!.. Моннан соң бар да бетте! Инде кеше булдым, гомер буе барган максатка менә-менә ирешәм дип кенә торганда! Аны, җиргә аяк басуга (ярдәмчесенең ярдәме белән), урыныннан алып ташлаячаклар! Аллага табына, ходайга ышана торган коммунист җитәкче!.. Их син, Зур Су, йотмадың да ичмаса! Хурлыгы булмас иде!..

Зур Су көймәне һаман кага. Күңелләр болгана, башлар әйләнә. Хуҗа тагын күзләрен йомды. Ул күзен ачып җибәргәндә, әлеге хурлыклы хәбәр әллә кайчан кайтып җитеп, аны анда партбилетыннан, яраткан эшеннән, яшәеш рәвешеннән колак кактырырга әзерләнеп торалардыр шикелле тоелды — ул, куркынып, күзләрен ачты.

Зур Суның дулкыннары шап та шоп көймәгә кага. Аның хәлен аңламый, аны мыскыл итә кебек Зур Су! «Тукта! Ашыкмагыз! Тотыгыз капчыгыгызны, яме!!! — дип тешләрен кысты Хуҗа. Аннары кинәт айнып киткәндәй: «Карале... Мине шул сүз өчен урынымнан алып ташлаячаклармы? Минеме?.. Туктале... Мин аллага ышанмый идем ич? Ник бая ышандым? Ышандыммы соң? Ие... Әллә...»

Хуҗа кистереп уйларга җөрьәт итмәде. Чөнки алар әле һаман су өстендә иде... Ул бары кемгәдер янагандай эченнән: «Тотыгыз капчыгыгызны!» — дип кенә куйды.

Мөхәммәтнең әтисе һаман дулкыннар белән көрәшә. Ярга якынлашкан саен дулкыннар вагая бара, ләкин алар һаман ишле һәм көчле әле.

Мулла бабай һаман ходайдан коткаруын үтенә.

— Син, син! Син белә торып, кеше кадәр кешенең суга сикерүенә юл куйдыңмы?!! — дип җикеренде Хуҗа көймәче картка.

Хуҗаның тавышы бик көр чыкты. Чөнки бу вакыйга, капчыклы картның су астына китүе, аның акланырдай бердәнбер ышанычы иде. Бу вакыйга калганнарын күмеп, каплап китәрлек зур хәл иде...

Көймәченең әллә ни исе китмәде. Әлеге сүзләрне ишетмәгән дә кебек иде ул. Дулкыннар тавышы белән әллә чынлап та ишетмәде инде? Әллә юри ишетмәгәнгә салышамы? Хуҗа тагын телгә килде:

— Аның үлемендә син гаепле!

Ишеткән икән көймәче карт, әнә, акрын гына башын Хуҗага таба борды.

— Аны Зур Су үтерде, — диде ул кипкән иреннәрен ялап һәм: — Ул үз авылы зиратында үзенә урын сайлаган булган, шунда китеп барды, — дип өстәп куйды. Әйтерсең, кеше кадәр кеше үлеме турында түгел, һава хәлләре хакында сөйләшә иде.

— Син! Белә торып!..

Мөхәммәт атлы малайга көймәче кызганыч булып китте. Чарасыз, мескен, ташландык бер картка охшап калган иде ул бу минутта.

— Теге баш сөяге чынлап та синең атаң башы иде ул, энем, — диде карт тыныч кына. Әйтерсең, ниндидер бер уенчык хакында сүз бара.

— Син җаваплылыктан котылмакчы буласыңмы, карт шайтан!

— Җиргә алып чыгып күмәргә иде атаң башын, улым. Мин үземнекеләрнең сөякләрен яр буйлап күпме эзлим инде, һаман таба алганым юк. Ә син, кулыңа тоттырганны кире суга ташладың. Әй, энем, энем...

—Ә синең башың төрмәдә чериячәк!

— Әллә кайчан ук инде мин, су астында калачак зиратыбызда ук, карчыгым янында урын алып куйган идем инде. Су басты бит каһәр, шуңа күрә үлә алмыйча йөрим. Бу Зур Су китмәсме икән моннан, ә? Сез белмисезме, сез укыган кешеләр бит, ә?..

Көймәче карт шаяртмый иде, аның кысылган күзләреннән ике генә бөртек яшь тамчысы саркып чыкты да битендәге җыерчыклар арасына кереп күмелде.

Мөхәммәтнең әтисе, көймәне тизрәк бу Зур Су кочагыннан коткарырга теләгәндәй, көчәнеп-көчәнеп ишә. Тагарак-көймә, кара сыртлы дулкыннар өстендә бала бишегедәй тирбәлә-тирбәлә, Зур Җиргә таба йөзде.

Мулла бабай, көймә төбендә утырганлыктан, Җирне күрмәгән икән. Күргәч, янәшәсендәге Мөхәммәтнең башыннан сыйпады һәм калтыранган тавышы белән:

— Бәхетең бар икән, балакай. Аллаһе тәгалә син гөнаһсыз сабый хакына коткарды безне, — диде.

Хуҗа боларның берсенә дә игътибар итмәде. Ул гасабиланып иреннәрен чәйни, саркып чыккан канны ачу белән әледән-әле суга төкерә иде. Ярдәмчесе дә дәшми ичмаса. Авызына су капкандай тик утыра. Мөгаен эчтән генә тантана итә торгандыр. Хәзер хуҗасының дилбегәсе аның кулында бит...

Көймә борыны яр кырыена килеп бәрелде.

Мөхәммәтнең әтисе әүвәл улын, аннары аяк буыннары сыекланган Мулла бабайны җиргә төшерде. Көймәдә көймәче карт ялгызы гына утырып калды.

Җиргә аяк басуга, алдан сүз куешкандай борылып барысы да Зур Су өстендә биешкән дулкыннарга күз ташладылар. Баягы куркулар, бугаздан ала язган һәлакәт Зур Су уртасында калды, аларның барысын да Зур Су үзенә йотты.

Хуҗа, Мөхәммәт атлы малайның башына кулын куйды да, һәммәсенә дә ишетелерлек итеп:

— Ну, энекәш, синең хакка хәтта абзыйларың да аллага мөрәҗәгать иткән булып шаяртты, ә! — диде һәм көчәнеп көләргә кереште. Аңа кушылучы булмады.

Мөхәммәтнең этисе көймәче картка:

— Давыл тына хәзер. Чоңгыл аша чыкма, әйләнеп уз! — дип кычкырды.

Көймәче кулын гына селтәде һәм:

— Минем авыл да чоңгыл турысында бит! — дип, әллә шаяртып, әллә чынлап җавап кайтарды.

Хуҗа, эре адымнар белән җиргә нык басып, үзен көтеп торган машинага таба китте. Күктә самолет тавышы ишетелде. Мотор гөрелтесен дә басып, яр кырыена кара сыртлы дулкыннар шап-шоп бәрелә иде.

Мөхәммәтнең этисе, малаен җитәкләп, Мулла бабайны култыклаган килеш, берара җир киткәч, Зур Суга таба әйләнеп карады.

Ярдан ераклашкан көймә артыннан, зәңгәр утларын балкытып, сары билле моторлы көймә томырыла иде.

Дулкыннар һаман тынычлана алмый әле, алар һаман дәррәү ярга ташланалар. Һәр яңа дулкын өере килеп орынган саен комлы яр, сыкранып-сызланып кына, артка чигенәдер, дулкыннар аны авызларын чапылдата-чапылдата, кабаланмыйча, тәмен белеп кенә ашыйлар, кимерәләрдер шикелле...

## Рахмай Хисмәтуллин

# ЧЫЛБЫРЛАР

Автобус, иске агач күпер аша чыгып, сул як ярдагы калкулыкка үрмәләде. Карт агачлар каплаган зират турысына җиткәч, ниһаять, Бастырык авылы күренде. Айдар, автобусны зират турысында туктаттырып, бик азга гына аның карасу-көрән коймасына сөялеп басып торды. Хатынының, димәк, балаларының бер як тамыры шушыннан. Онытылган меңләгән ерак чыбык очы әби-бабалары, туфрак-тамырлары шушында чәчелеп-сибелеп ята. И-и адәм балалары, и-и язмышлар... Ул бик белергә теләгән серләрне бу туфрак-тамырлар да алып киткәннәрдер шул.

Каяндыр арган, карлыккан козгын тавышы ишетелде. Әнә теге корыган, кабыксыз шәрә калган карт өянкедән, ахры. Шом-сәерсенүләр тагын да куера төште. Кузгалгач, авылга карап бара-бара, аның йөрәге ниндидер билгесез бер тойгыдан кысылып-кысылып куйды.

Элгәре, моннан ун ел элек кайткан чакларында, ул зиратына да, авылына да болай ук игътибар итми иде. Нибары үзенең билгесез бер адәм, хәтта «Жигули»сыз кияү булуыннан гына читенсенә иде. Инде менә ул — бөтен республикага танылган җырчы — хатынының туган авылына концерт куеп китәр өчен кайта. Исеме-тавышы радиодан да шактый еш яңгырый. Аны инде биредә хәзер, шәт, яхшы беләләрдер. Бәлки әле күрше-күлән, таныш-белешләре өйдән-өйгә кунак итеп тә йөртерләр; табын саен, үз киявебез дигән булып, җырлавын да үтенерләр...

Ышанасы да килми, ун ел буена шушында бер кайтып китәргә ара чыкмасын инде. Инде менә бу юлы ул биредә башкача йөреп китәр, авылның чишмәләрен тыңлар, урманнарында ял итәр. Карт-лардан, әбиләрдән авылның тарихын сораштырыр, инде күптән җанны тәмам аптыратып-йөдәтеп, бәгырьгә таш булып каткан бер сорауга җавап табар: кем булган аның хатынының нәсел-нәсәбе? Борынгы әби-бабаларының холыклары нинди булган? Бәлки, шуннан соң гына аның сусыны бераз басыла төшәр.

Авыл ун ел эчендә нык үзгәргән иде. Әнә каршы сыртта ак болыт көтүләре сыман шифер түбәләр ерактан ук күренеп тора. Элекке мескен агач клубларын да таш культура сарае алыштырган. Урамга кергәч, ул «Айдар Сагындыков җырлый» дип язылган афишалар эленгәнен күрде.

Тик, мәһабәт таш клуб төбенә килеп туктагач, ни өчендер каршылаучы булмады. Ишектә тутыккан иске зур йозак иде. Шушындый гастрольләрдә иң кыены — клуб мөдирен көтеп утырулары. Әмма ул бу юлы көтмәячәк, әнә башкалар көтсен...

Хатыны туган йорт нигезенә таба урам буйлап җәяүләп үткәндә аны танып алып исәнләшкәләделәр. Тик нигәдер колач җәеп, килеп хәл сораштыручылар булмады. Ул йортларның төзелешенә, тәрәзә, кәрниз бизәкләренә күз салды. Нишләптер, элек бер дә игътибар итми торган нәрсәләр күзгә чалына иде. Йортлар бизәлешендә

---

Рахмай ХИСМӘТУЛЛИН *(1934) — прозаик һәм шагыйрь. «Сусау», «Дөньяга көлеп чык!», «Яшенле тау» һәм башка китаплар авторы. Чаллыда яши.*

ул бер дә зәвыклы төсмерләр таба алмады. Тәрәзә йөзлекләрендә, гүя кайчандыр боларга тәреләр өләшеп, бик каты чукындырылганнарына ишарәләгәндәй, мокытлык, басынкылык тойгысы гына калдыра торган «каз тәпиләре» иде. Бирегә Балтач якларының тылсымлы осталары бер дә килеп чыкмадылар микәнни соң?

Менә, ниһаять, аның тормышына әллә никадәр авыр сынаулар китергән йорт нигезе... У-уу, ташландык нигездән дә хәсрәтле, үзәк өзгеч берни дә юктыр бу дөньяда! Ә инде синең тормышыңны өзгәләп үткән кешенең тузган нигезе бигрәк тә тетрәндергеч икән ул... Ярсу бәхәсләрдән тетрәп торган нигез бөтенләй юк, юк... Вакыт дигәнең бәхәсне хәл иткән дә ташлаган.

Кызлары белән ничек кенә этле-мырлы яшәмәсен, әби-бабайның каберләрен дә зиярәт кылмыйча китү һич ярап бетмәс...

Рәттән торган ике кабер өстендә узган елгы корыган тигәнәкләр җәйге сүрән җилдә хәлсез генә кыштырдаша иде. Ул бабасы кабере очындагы калкуда иске үлән-яфракларга чорналып беткән берничә чылбыр күреп алды. Ныклабрак караса, әбисенең аяк очында да, өзгәләнгән елан сыман, шундый ук чылбырның берничә буыны җил һәм кояш, яңгыр һәм вакыт таптавы астында череп, бәйләрен югалтып, табигать яшьләренә, тутыкларга батып, зар иңрәп яталар иде. Хатынының этисе Зәйнулла, бер карасаң, йомшак күңелле, юаш, тыйнак холыклы кеше иде, җаны оҗмахта булсын. Ләкин, каһәр, ни хәл итмәк кирәк, хәтергә аның җанны бик каты рәнҗеткән чаклары күбрәк сеңеп калган.

Берзаман, хатыны белән аралар түзә алмаслык булып бозылышкач, Зәйнулла бабай үзе килеп төште. Айдар, аңардан нинди дә булса бераз яклау табарга өметләнеп, хәлне чын йөрәгеннән аңлатырга тырышкан иде:

— Хәлләр начар бит әле, бабай, яшәп булмас, ахры, болай, яшәп булмас...

Үзе турында сүз сөйләшүне җене сөймәс Гөлзар шунда ук йокы бүлмәсенә кереп бикләнде. Айдар аның балаларга акыру-бакыруларын, ашарга пешермәүләрен, иртәгесен балаларның ашамыйча мәктәпкә китүләрен, инде тормышларының соңгы чиккә җитүен, аерылышуның өсләренә басарга торуын аңлатып азапланды. Ләкин мескен Айдар ул чагында бу хәлләрнең сәбәпләрен аңламавын әле үзе дә белми иде. Зәңгәр күзләренә, ак чыраена, чал чәчләренә кайгы-хәсрәт тулган мескен бабайның да үз туксаны туксан иде:

— Их, шахтаңны шартлатыйм, — дип иреннәрен чапылдатып куйды ул. — Тәки кызымның кадерен белмәдең. Бер дигән чибәр кыз бирдем мин сиңа, егерме биш мең тәңкәлек! Менә ничә ел инде син аңардан зарланасың. Ир булырга кирәк, хатын-кызны тота белергә кирәк. Син үзең йомшак. Мин каты идем, кирәк чакта минем кулда тимер чылбыр булырые анасына.

Айдар, моңа ышангандай булып, шым гына тыңлады, ә уенда әче итеп көлде: «Һи-ии, мескен бабай, кая инде сиңа чылбыр?! Үзеңнең өркәк холкыңнан сикереп чыгарга маташкан буласың. Хатын тота белгән ир кул астында үссә, кызың шулкадәр кирәмәт булыр идеме соң?!»

— Мин как ищу тота белдем аның анасын. Ә син тота белмәдең, кадерен белмәдең!

Айдар шул сүздән кызып китте:

— Туктале, бабай, нишләп син монда гел мине генә гаепләргә килдең соң әле? Акылың булса, хәлне аңлар идең син, бераз киңәш бирер идең кызыңа. Нишләп син бу хәлнең сәбәпләре белән кызыксынмыйсың? Нинди гаебем бар соң минем: эчәммe, эшсез ятаммы? Нишләп соң син гел мине генә битәрләү ягын карыйсың? Гаиләләрнең өчтән бере аерылыша хәзер. Әмма минем аерылышасым кил-

ми иде, балаларны үзем үстерәсем килә иде. Әгәр инде ул үзен үзгәртмәсә, аңламасагыз, без аның белән башка яши алмыйбыз. Җитте, уф! Болай буласын белсәм, мин дөньяга да тумаган булыр идем!

Айдарның җәһәннәм утларында бәргәләнеп януы күренеп тора, тик «аерылырга туры килер», дип өркетүе чынга ашмас бер янау гына иде. Ул үзе, җиде яшьтән үк атасыз калып, бигрәк тә моңлы җан булып үсте. Ахры, шул җырчы итте дә. Әнә шуның аркасында инде ул хатынына да чын ирләрчә каты куллы, кырыс була белмәде. Ул, вакыт-вакыт күңеле нечкәреп, хискә-моңга бирелә, хатыны каршында, балаланып, җебеп, ачылып китә. Ә хәләл җефете аны шул минутта ук җәтмәсенә эләктереп ала да үз кубызына биетә башлый. Әлеккәч, ул кызу канлыланып кычкыра, ярсый, чәбәләнә, ләкин инде соң була, ирләр кырыслыгын, каты йөгән барлыгын тоеп тормаган хатын тәртәне гел үзе теләгән якка каергалап алып кереп китә.

Зәйнулла агайның күңеле йомшарып китте, ахры, кирелеген тыя төште:

— Бирәм мин аңа киңәшне, бирә-әм, һәрчак әйтеп торам, юньле торыгыз, дип.

— Әйтмисең шул, атасы акыл биргән кыз шулай була ди мени?!

Зәйнулла агай үзенең сыртына тимер чылбыр төшкәндәй дерт итеп куйды. Аннан соң, сыйпагандай, йомшак кына итеп, күрше бүлмәгә дәште:

— Чык әле, кызым, монда чык әле!

Йөзе ямьсез каралган Гөлзар залга чыкты.

— Кара әле син, кызым, аш пешер, идән ю, кер ю, аш пешерү ирләр эше түгел, кызым, үз эшеңне бел син.

Бу шулкадәр көчсез, мескен әйтелде ки, аның тәэсире, кабынып китә алмаган учак төтене сыман, шунда ук юкка чыкты. Гөлзар моны шәүлә кебек кенә тыңлап торды да, бер сүз дә дәшмичә, кырт борылып кире кухняга кереп китте.

— Ни бит, кияү... син бит... үзең... ие... Башка ягы да бар бит әле аның.

Әйе, болары әле аның төп сәбәп тирәсендә читләп-салулап, кыйпылап-хәйләләп йөрүләр генә иде. Иң үтергече шул иде: Гөлзарның кулы гел үз ягына кәкре булып чыкты. Инде менә ничә еллар буена үзенең эшләп алган акчасын һич кенә дә гаилә хаҗәтенә тотарга теләмәде, уртакка салмады, күз бугандай, яшертен генә гел каядыр юкка чыгара барды.

— Ие, башка ягы да бар бит әле аның, — дип дәвам итте Зәйнулла карт. — Син, кияү, менә хатыныңнан зарландың. Әйт әле, син хатыныңны туйдыра беләсеңме соң?

Айдарның йөзе бер кызарды, бер агарды. Йөрәге чәнчеде, бәгыре өзелде. Менә сиңа юаш бабай! Менә сиңа тыйнак ба-ба-ай! Ай-яй...

Айдарның ачыргаланулы уйларын каяндыр ерактан, зиратның икенче ягыннан, козгын кычкыруы өзде, гүя ул: «Җитә-әәрр инде, җитә-әәрр инде», — ди кебек иде.

...И бабай, бабакаем, кайда синең бетәшеп җыйган акчаларың? Кемнедер укытырга, кемнедер рухи үстерергә, бөек итәргә тотылмаган акча — тирес бит ул, каһәр генә бит ул! Әнә, кызың кебек үк тыңлаусыз, акча яраткан карчыгың кабере өстендә дә корыган тигәнәкләр, алабуталар гына шомлы кыштырдыйлар. Әбинең «бөкресен» кабер төзәтәдер дә, ә менә Гөлзарның үҗәтлеген, чирли-чирли акчага табынуын берни дә төзәтә алмады. Мин ул кара мәхшәргә мәңгегә хөкем ителгәнмен икән һәм ул әллә нинди тирән бер сер булып, ачылмаган яман бер чир булып бәгырьдә утырып калды. Тик мин, бабай, барыбер җырчылыгымны ташламадым, ташлый алмадым. Гафу итегез инде, бәхилләшә алмый калдым. Мин фин татарлары янында гастрольләрдә йөргәндә икегез дә бер-бер артлы дөнья

куйгансыз. Нишлисең бит, тәкъдир... Аллаһы әкбәр... Бәхил булыгыз...

Айдар каберстаннан йөрәге мөлдерәмә сагыш тулып кузгалды. Аның бөтен гомере бушка, заяга узган сыман тоелды. Кызганыч, үтереп кызганыч: ул бу картларга үзен яхшы кеше итеп, якын туган итеп, җырчы эшенең дә әйбәт эш икәнлеген таныта алмады. Кара туфрак араларны мәңгелеккә өзде... Зираттан кайтканда ул авыр сусау, шушы әби-бабай турында кем беләндер бер сөйләшеп утыруга, эчен бушатуга теләү, сулышны буарлык сәер бер сусау тойды. Элек Айдар бабайларына килгәндә-киткәндә ике як күршеләре үз капка төпләрендә утырырлар иде. Тик нигәдер ул, ниндидер бер эчке читенсенү тоеп, кара иске бүрекләр, җәлпәк кәләпүш кигән шул күршеләр белән бер сөйләшеп алырга кыюлык таба алмый иде. Чөнки әби-бабасы да күршеләр белән бер дә ачылып китеп дәшешмиләр. Хет, ичмасам, менә бүген берәрсенә кереп чыгарга кирәк.

Сул як күрше карчыгы, бер-бер кеше килеп чыгуга чиксез сөенеп ахры, сөйләнә-сөйләнә урыныннан торды:

— Менә бит, менә бит, раббым, безне дә зурлаучы табылды...

Айдар, исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашты да:

— Әби-бабаларым нигезендә җилләр генә исә инде хәзер. Менә сезгә хәер бирел чыгарга кергән идем, — дип, әбигә өчлек сузды. Тәмам хәлсез калып, дөньяны инде тәрәзәдән генә карап утырган, шәүлә сыман тоелган әби гел җебеп төште.

— И балакаем, — диде дә үксеп елап җибәрде. — Игелекле җан икәнсең, әби-бабаңның, ата-анаңның җаннары җәннәттә булсын. Тупсамны атлап керүең дә бәхет ие әле, балакаем. Безгә керүчеләр юк бит инде хәзер, и-и-и... — Әби, артыш агачы кебек корып кипкән бармаклары белән күзләрен сөрткәләп, дога кылырга керешге.

— Әби, китап үлгәннәрне искә алырга кушкан бит. Син безнең бу әби-бабайларны искә алгалыйсыңдыр әле... Күршеләр идегез бит...

— Искә алам инде, балам, кышкы озын төннәрдә гел шулар күз алдымда. Килен булып төшеп, илле биш ел күршеләр булып яшәдек, бер дә ачуланышмадык, тик ныклап аралаша алмыйча гына калдык, и-и, гомер җитмәде. Бигрәк тә мин әбиеңнең әнисе Тәңкәсылуга шаккатаем. Бигрәкләр дә күңелдә калды ул. Бик әйбәт кеше ие. Ул мәрхүм кырга чыкса — чәчәк, су буена төшсә — тимертомыр җыярга яратучы беркатлы мәзәк кеше ие, үзен гел тәңкә белән бизәп бетерер ие. Мин аның шул тәңкәләренә кызыгаем, тик бабаң аны сатып җибәрде бугай шул. Бай булдылар бабаңнар, рәхәтен генә күрә алмадылар.

— Шулай да, әби, читен булса да сөйлә әле син, ни өчен туганнары белән үзара йөрешмиләр иде? Ни өчен аларның берсенең дә менә миңа кунакка килгәннәре булмады икән?

Әби каушап, куркып ук калды ахры, сәерсенеп, Айдарга карапкарап алды. Ә үзе кулындагы өчлекне бөтәрләде.

— Дөресен сөйләсәм, бик читен булмасмы соң, балам? Гөнаһ шомлыгы үземә булсын, аларның ихатасы саңгыраурак иде. Үкенеч менә хәзер: без дә алар белән, күршеләр була торып, беркайчан да ашка-суга йөрешмәдек. Серле кешеләр иде алар. Әбиеңә үзенең туган авылыннан туганнары да кунакка йөрешмиләр иде. Хан заманыннан ук калган бер сүз йөрде, бик ерак әбиләре ниндидер бер патшаның казна сакчысы булган, имеш. Шулай берзаман, сакчыларны үтереп бетереп, казна басарга кергәннәр. Карыйлар: сандык өстендә бер хатын ята икән. Муенына пычак салганнар. Ләкин пычак муенны кисмәгән, дүрт-биш кат тәңкә муенса коткарып калган, имеш. Теге хатын шундый яман итеп кычкырып җибәргән, караклар шыр җибәреп качып котылганнар. Ә бу хатын аларның әнә шул ерак әбиләре булган. Шуннан соң аларның буынында барысы да төнлә йоклаганда саташып кычкырып җибәрә торган булып калганнар.

Гөнаһысы үземә булсын инде, балам, синең җәмәгатең дә шулай иде бит, ахырысы.

Авырткан җирнең нәкъ үзәгенә басты бу әби. И-и, бу дөньяда яшерен берни дә юк икән, юкка гына без авыруларыбызны яшереп маташкан булабыз икән...

Икенче як күршедә кетәклек кадәр генә йортта яшьләренең исәп-хисапларын да югалткан бер әби белән бабай торалар иде. Исәннәр бугай әле, ишекләрендә йозак-фәлән күренми. Җил капканы ачып кереп ишек шакуга, кипкән гөмбә кебек бөрешеп беткән йөзле, ап-ак сакаллы бөкре карт чыкты. Шулай ук бөкрәйгән әби дә, нидер карап, кыйшайган өстәл янында утыра иде. Ул алдындагы төенчеген яшереп куймакчы булып кабалана башлагач, карт дәште:

— Ярар, карчык, хафаланма. Менә бик әйбәт булды әле, күрсәтик әле менә без аларны белемле кешегә. Менә әйтсен әле ул алар турында, берәр ничек йөртеп булмый микән аларны. — Карт кунакны өстәл янына утыртып, иске чүпрәк төргәкне сүтеп, инде кырыйлары бурсый башлаган затлы кәгазьләр чыгарып салды. Бу иске, йөрми торган акчаларны күрү белән Айдарның күз алдында заманалар, дәүләтләр, бәяләр һәм бәясезлекләр, кадерләр һәм кадерсезлекләр бергә буталып калды. Ә карт сөйләнә бирде:

— Менә, гафу итсеннәр инде бабаңнар, син дә без юләрләрне гафу ит, кияү балакай, теләсәң, үзеңә алып китә аласың бу кәгазьләрне. Безнең гаеп юктыр. Ягарга беткәч, бабаңнар нигезендәге ырымлы соңгы ниргә бүрәнәләрен актарырга туры килде. Шуның акчаларые. Бала чакта ук ишетеп калганыем шундый әйбернең барлыгын, тик искеләр шул хәзер, йөрми торганнар, Зәйнулла бабаңның бабасы Сәпәй карт яшереп калдырган инде боларны. Бакыр рудникларында череп эшләп җыйган да менә, бер файдасызга гел җилгә очкан инде.

— Әйе шул, хәзер болар йөрмиләр, — диде Айдар. — Берни дә эшләтеп булмый. Йөрми, яшәлми калган гомер шул инде болар. Хәзер боларны йә утка ягасы, йә шунда берәр музейга бирәсе...

— И алла, һәр нәрсәнең үз заманасы шул инде. Сәпәй бабай менә акчасын тота алмый киткән. Ә мин менә, яшьлегем үтеп китеп, картаеп беткәч кенә өйләнеп, бер баласыз калдым. Безнең авылныкылар әллә ничек яшәгәннәр шул, әллә ничек шунда, һич аңламассың... Синекеләр дә китте бит инде, кияү, җаннары оҗмахта булсын. Алар да менә җүнле ашамый, җүнле киенмичә акча җыеп калдырганнарые, балаларын гына сугыштырып бетерделәр.

Күршеләргә кереп сөйләшүләр шактый вакытны алды.

Клубка кайтканда концерт башланырга бер сәгать чамасы гына калып бара иде. Башка авылларда ни мәшәкатьле чаклар булмасын, авыл кешеләре концерт алдыннан чәйгә чакырып торалар иде. Ә биредә, нишләптер, беркем дә дәшмәде. Айдар үзе, шушы авыл кияве буларак, башта бу турыда сүз кузгатырга кыенсынып торды. Әмма юкны көтеп утырып та булмый иде. Администраторга кушып, кибеттән каты-коты китертте. Хәерсез, пәрәннек-фәлән тамакны гына камаштырды. Чыгыш алдыннан һәйбәт итеп ясалган сөтле чәй эчеп алса, шәп буласы иде дә бит. Ә тамак һаман җанны тынгысызлады. Юк, бу кадәрле четерекле хәлдә калырга ярамый, концертны өзеп куюың бар. Ул клуб мөдиренә йөз суын түкте:

— Сеңелем, бик читен булса да, берәр чынаяк чәй алып килә алмассыз микән?

— Ярар, абый, карарбыз, — диде мөдир кыз һәм җитез генә күздән юк булды. Бераздан ул, кулына зур чиләк тоткан бер егетне ияртеп, сәхнә артына килеп тә керде.

— Менә, абый, эчегез рәхәтләнеп! — дип, суны чайпалдыра-чайпалдыра урындыкка китереп куйды. Ат эчерә торган иләмсез олы

чиләктәге салкын кое суына карап, Айдарның тәннәре чымырдап китте. Ул үзен, әллә ничек, авыр йөкне тауга таба тартырга тырышып та, һич кенә кузгатып алып китә алмаган кызганыч бахбай итеп тойды. Салкын су! Чәй урынына чайпалып торган бер чиләк салкын су! Туктале, нәрсәне хәтерләтә соң әле бу аңа?

Еракта, томаннар артында сәер истәлекләр шәйләнде...

Ул чагында баянчы әтисе бер җырчы абый белән авыллар буйлап концертлар куеп йөри иде. Бервакыт алар Айдарны да үзләре белән ияртгеләр. Бер авылда, җырчы абый чәй сорагач, аңа да шушылай ат эчерә торган чиләк белән салкын су китереп биргәннәр иде. Көлгән иде дә елаган иде, елаган иде дә көлгән иде җырчы абый. Әйе-әйе, авылдан чыгып киткәндә бер җыр да җырлаган иде бугай әле. Ничек соң әле?..

Бастырык, Бастырык,
Киттек синнән ач торып...

Айдарның тырнак төпләренә хәтле тетрәнү йөгерде. Кит аннан, шушы ук авылда булды микәнни ул?!

Ничек болай кабатланды соң әле бу? Аннан соң бит инде егерме биш кыш китеп, егерме биш яз килгән, егерме биш тапкыр табигать яңарган. Егерме биш ел эчендә, әнә, өй түбәләрендәге саламнар шиферга, калайга алышынган, шыгырдап торган нарат бүрәнәләрдән, таш-кирпечләрдән өр-яңа йортлар, яңа мәктәп, яңа клуб, тагын әлләниләр калыккан. Өй түбәләрендә антенналар урманы... Элек печәнсалам ташыган «уфалла»ларны хәзер музей өчен дә эзләп таба алмассың.

Ә нишләп кунакка һаман да ат чиләге белән салкын су?

Әгәр дә хатыны шушы авылдан булмаса, ул бу кадәре коелып та төшмәс иде. Яшәлгән гомере эчендә хатыны аңа камыр ашы күрсәтмәде, нидер пешермәкче булып алып кайткан оннарын һәрвакыт кортлатып чүп чиләгенә чыгарып түкте. Әллә нинди гарчел, кәнчел Гөлзары табыннарда беркайчан да кеше җырына кушылмады. Айдар әз генә кешегә ярдәм иткәләсә дә, теге һәрчак кара янып чыкты, өч-дүрт көн буена дәшми йөрде. Иренең кешеләргә изгелеген үзенә явызлык итеп кабул итеп яшәде. Гөлзар бөтен холкы белән шушы туган авылын хәтерләтсә дә, бичаракай, ни өчендер ул үзе бирегә кайтырга яратмады.

Кыскасы, ат сатып алганда тешенә кара, кызны анасына карап коч, дисәләр дә, юк, алай гына түгел, авылына карап та кочарга кирәк икән. Тормыш бугазыңа китереп баскач кына аңлыйсың икән шул аны.

Айдар, гомеренең заяга үткәнен сизсә дә, белеп торса да, үз хәленең өметсезлегенә әле һаман ахыргача ышанып бетә алмый иде. Бишектәге бишкә төрләнә, аюны да биергә өйрәтәләр, үзгәрер, үзгәрми калмас, дип, үз-үзен юаткан булып, ниндидер бер могҗиза көтеп яшәде. Ә гомер чишмәсе болганганнан болганды. Гөлзар ни беләндер бик каты авырый кебек иде. Ләкин ни белән?... Ул сирәкмирәк бик азга гына ачылып киткәли, көлә, уйный, шаяра, шаян сүзләр сөйли дә көтмәгәндә тагын авыр караңгылыкка бата, гүя кара болыт астына кереп китә. Ни өчендер бу хәл гел генә «акча» сүзе ишетелгәч шулай була иде. Ул төннәрен дә гел кычкырып саташты. Ниһаять, гомер буена талашып яшәүнең карасы балаларда да калкып чыга барды, алар әллә ничек бик боек булып үсеп киләләр иде. Өметләр сула, киселә барды. Гүя, Айдарның бөтен тормышы су астында калды, рухы-ихтыяры чоңгылга батты, тыны кысылды. Җырчы буларак та бу хәл көне-төне аның бәгырендә мең сызлавык булып рәнҗеде, канын катырды, җанын изде, иҗатын аркылы сыза килде. Инде менә ничә еллар буена бер үзгәреш оч-

кыны да күренмәгәч, бер үк хәсрәтнең эчне җен шикелле кимереп утыруына, шау-шуларга, талашларга түзәр әмәл калмагач, ул гастрольләргә чыгып «олаккан» иде.

Ә менә монда... гомер чишмәсе шушы чиләктәге салкын сулар сыман тагын ярсып, күзгә, йөзгә, җанга чайпалды...

— Айдар абый, Айдар абый! Сезгә чыгарга вакыт, сезгә чыгарга вакыт! Айдар абый! — Концертны алып баручы кызның хафалы тавышы аны сискәндереп, айнытып җибәрде. Бәй, ничек чыгар икән соң ул? Ничек җырлар? Күңелдә бернинди ашкыну юк! Бушлык... Шул бушлыкта, эчне яндырып, утлы үкенеч бөре булып улады. Ни җырлар соң ул? Кызлар, хет ичмасам, сез ярдәм итегез!

Залдан аңа мәңге дә бернинди елмаю белмәгән сыман катып калган йөзләр, әллә нинди нурсыз, җансыз күзләр төбәлгән иде. Ябык йөзләрдә чокыраеп берегеп баткан ул күзләр: «Иә, тыңлап карыйк инде, без түләгән бер тәңкә хаклык җырлый алырсың микән?» — дияләр сыман иде. Менә хәзер, менә шушы тамашачы сиңа ничек кенә түбәнсетеп карый сыман тоелмасын, син шушы сәхнәне, шушы гавәмне ташлап, беркая да китә алмыйсың! Ни әйтсәң дә, шагыйрьләр сокланып шигырь язган, син илһамланып җырлаган сөйгән халкыңның кайсыдыр бер тамчысы залда утыра. Әгәр булса синдә шундый көч-куәт, син шушы салкын тамчыны да ярат, юат, чистарт, рухландыр, югары күтәр! Һәм Айдарга әллә ни булды...

Ком бураны каты була,
Каты булса җил көче.
Без давылдын курыкмыйбыз,
Үзебез давыл төсле.

...Начар җырлады микәнни соң? Берән-сәрән сыек кына кул чапкалап алдылар. Ул җырчы булып күп авылларны, күп өлкәләрне гизде, ләкин моңарчы мондый ук битараф, мондый ук салкын тамашачыны беркайда да күргәне булмады.

Әмма Айдар үз халәтен, үз бәхетсезлеген залга күчереп ялгыша, ахры. Залда зур бер халыкның, рухи манаралары кистерелеп тә, китаплары яндырылып та, гасырлар буена сыртлары таяк белән суктырылып та, кытлыклар, ачлыклар белән җәфалап, авыр эшләр белән гарипләндерелеп тә әле һаман миңрәүләндерелеп бетерелә алмаган, әмма өннәре эчкә кереп качарга мәҗбүр ителгән бер газиз өлеше утыра иде. Берзаман аларның тән-тоемнары, җан-рухлары бер кычкырып елап уянып, таш биналарны, таш дөньяларны дер селкетәчәк иде әле.

Нинди генә авыллар күрмәде Айдар гастроль юлларында. И ул борынгыдан каһәрләнгән, кара баганалы, кара язмышлы авыллар... Аларның исемнәре үк халыкның холык-фигылен, тарих яраларын әйтеп тора сыман: Теләнчеләр, Куыклар, Аюлар, Кирәмәтләр, Янганнар, Качкыннар, Бастырыклар... Бер ишләрендә — мәңге кысынкылыкка чыдый алмыйча, ялган сөйләп, шапырынып, мәңге ат караклары булып бөтен тирә-якларны дер селкетеп, чарасызлыктан шәфкатьсезләнеп, башларын давайлыкка, дуамалыкка салып көн күргәннәр. Икенчеләрендә — бу фәкыйрьлекләрнең сәбәбе дәүләтеңне югалтудан икәнлеген аңламыйча, олысыннан алып кечесенә чаклы йә чабата, йә катык сатып булса да баю хыялы белән ярсып-агуланып, комарланып акча җыеп, дөнья йөзенә чыгарга омтылганнар. Болар, күршеләреннән мәңге уздырырга тырышкан булып, ару-талчыгулардан йөзләре саргаеп, тәннәре кибеп, тәмам йончып беткәннәр. Алар бу сукыр саранлыкта кунакка йөрешүләрнең үзе бер байлык, үзара сөйләшеп утыру, кысташу, сыйлашуларның зур бәхет икәнлеген оныттып, чит-ят кешеләргә бөтенләй дәшмәс, туганнары белән дә кунакка йөрешмәс, күзләре якты дөнья матурлыгын күрмәс дәрәҗәгә җиткәннәр.

Айдар «Зая гомерләр» дигән тетрәткеч бер җыр башлап җибәрде. Залда гүя гомерләр, тапталган күңелләр, тарих тәгәрмәче астында изелеп-сытылып калган җаннар рәнҗеште, сыкранышты, ятып-тәгәрәп елады. Бу җырдан соң, ахры, ниндидер яшерен төеннәр чишелеп эреп китте, куе гына кул чаптылар. «Юк, барыбер уятам әле мин сезне, барыбер кузгатам, кояшлы аланнарга алып чыгам, әбәк-чәбәкле уйнатам, чәчәкләргә хозурландырып, моңга табындырып елатам әле мин сезне!» Айдар кабына, кызулана барды, бер урында басып тора алмаслык булудан бии-бии, дәртләнеп «Күбәләгем»не сипте, күкрәгеннән мең төрле аллы-гөлле күбәләкләр очырды. Зал диварлары да аның белән бергә җырлый, бии иде сыман. Инде кайбер тамашачыларның йөзләрендә елмаю төсмерләре кабынган иде. Җырчының зал белән бергә бәхәсе тагын да кыза төште. Гүя ул үзенең бөтен газаплы үткән гомере, үзәгендә шушы авыл җимеше булган хатыны торган йөрәк газаплары белән дә соңгы көрәшкә-бәхәскә ташланды. «Юк, барыбер уятам әле мин сезне, барыбер шаштырам!.. Сез беләргә тиеш, сез аңларга тиеш: сезнең тормыш болай булырга тиеш түгел! Сез белмисез генә: бар бит ул башка төрле авыллар да. Чиста, саф рухлы авыллар. Урамына барып керсәң — биш яшьлек баладан алып сиксән яшьлек ак сакаллы картына кадәр — таныш булмаган кешеләргә дә кечелеклелек белән хөрмәтләп «Исәнмесез!» дип дәшәр. Бер стакан су сорасаң, йә әйрән, йә кайнар чәй чыгарып бирерләр анда, ә тагын да юмартраклары, мосафир бит бу, юлаучы, дип, сине бер тиенсезгә ашатып, чәй эчертеп чыгарырлар. Бу шәфкатьтән сиңа Урал тауларына очып менәрлек куәтле канатлар үсеп чыгар...

Мондый авылларда җырлаганда якты йөзләрдән, елмаюлардан клуб эченә кояш чыга, кул чабулардан стеналар дер селкенеп тора. Сезнең күкрәкләрегездән дә шул елмаю, шул тормыш шатлыкларын актарып чыгарам әле мин!»

Ул шушы уйларын куәтләп, гәүдәсен төз, дәртле, батыр тотып, әллә нинди тирән моң һәм җиңүле тантана белән, сабан туйларын искә төшереп, «Шахта» көен җырлап җибәрде. Шундый биек, шундый якты итеп җырлады ки ул аны, гүя бөтен дөнья шахталарына, рудникларына, заводларына сибелгән татар балалары бер мәйданга чыгып бастылар да, җырда гына булса да беренче мәртәбә шушылай бергәләп җыелып күрешүдән, үзләренең күплегеннән, батырлыкларыннан хәйран калдылар сыман. Шахта... Шахталар... Безнекеләр анда күпме күмер ваттылар. Күпмеләре мәңге шунда таш булып ятып калган...

«Шахта»... Бу җыр бастырыклыларның күңелендә нәрсәнедер ватты, кубарды, җимерде... Әнә шундый җыелу, күрешү, аңлашу бәйрәме булырга мөмкин дә ул, ләкин ул мәңге дә булмаячактыр шул... Бу дөньяда һәркем үзенә аерым бер газаплы юл узарга хөкем ителгәндер...

Бу җыр дулкыны залда утыручыларны да үзенә ияртеп, рухи якты биеклеккә алып менеп китте. Күпләрнең күзләре дымланды, уңайсызланып, башлары түбән иелде. Нигә иелмәсен соң?! Бу якларның да моңлы чишмә-таллары, сагышлы карт өянкеләре, шаулы урманнары, туктап хәйран калырлык офыклары, артышлы зират артыннан калкучы сандугачлы таңнары бар ич! Аларның да күңелләрен барыбер шулар тибрәткәндер ич... Тик шулай да әш базыннан, тормыш изүеннән рух яктылыгына сикереп чыгарга аларның нәрсәседер җитешеп бетмәгән: кушканны тыңлаган, сораганны биргән, әмерләрне үтәгән... Шушы кадәрле зур авыл үзеннән бер генә дә югары белемле кешесен үстереп чыгара алмаган, йортларын матур бизәкләр белән бизәргә өйрәнә алмаган, белемне-китапны, җырнысәнгатьне читкә куеп, яшелчә-витаминга, ял-уенга көлеп карап, акча-байлык туплау культын алгы планга чыгарып, бил күтәрмичә гел

төшемле эшкә генә баш игән. Баш игән дә кибә барган. Авылда буыннан-буынга тапшырылып барырга тиешле изге чыганаклар сакланмаган. Алар, хәтерләрен җуйган манкортлар шикелле, бабаларының бу авыл урынына кайсы яклардан кайчан килеп утыруларын да хәтерләмиләр иде.

Тәҗрибәле антрополог, этнограф, психолог бу авыл кешеләре йөзендә гасырлар буена бер урыннан бер урынга куылып, җирсезлектән, җәбер-золымнардан тәмам иза чигеп хәлсезләнгән, җырмоңнары таланган бер кабиләнең ярчыгын танып алыр һәм гасырларның сикәлтәле, тузанлы, канлы юлларыннан үткәндә аларның башларын күтәреп дөнья офыкларына, зәңгәр күкләргә карарга, чишмә агышларын, кош сайрауларын ныклап тыңларга беркайчан да вакытлары-мөмкинлекләре булмавын аңлар иде. Алар, үзләре күргән тарихи хәсрәттән, кысу-рәнҗетелүләрдән, кимсетелүләрдән күз яшьләре кибеп, җаннары коргаксыганын, йөзләре саргаеп, ул саргаюның тәннәренә дә күчә баруын чамалар иде. И аллам, Айдарның Гөлзары да нәкъ шушы дөнья җимеше бит инде. Миңрәүләтелгән бу ыруг-кабиләнең борынгыдан килгән каһәре, үҗәтлек-кирелеге Гөлзарда да җитәрлек тупланып калып, сәер авыруга әверелеп, ничә еллар буена аның нервыларын телгәли дә телгәли иде. Менә хәзер, менә шушы минутларда җырчының бөтен бәгыре үзен аңларлык гомер юлдашы таба алмаганга каты әрнеп сулкылдый иде.

... Энҗе лә мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Гүя залдагыларның барысы да нәкъ шушы Айдар кебек үк бәхетсезләр иде. Җырчы гасырлар буена түгелгән күз яшьләрен хәсрәт көлләре астында күмелеп яткан иң нечкә кылларын эзләп табып, сызландырып чиертеп җибәрде. Һәм алар барысы берьюлы шушы җырчының йөрәк-моң кылларына тотынып, теге каһәрдән, теге битарафлыкның чылбыр-богауларыннан ычкынып, котылып чыктылар да ачылдылар, аңладылар — алар озак гасырлар буена караңгы базларда яшәгәннәр икән ич. Күңелләрен яктырта-яктырта нурландырып, кайнар сагыш, утлы моң, чиксез пакьлек ташкыны түгелде. Бу бер йөрәктәге бөек, якты утның башкаларга күчеп, аларны моң чылбырына тоташтырып китүе иде.

Җыр тәмамланды. Зал, өнсез калып, беразга һушына килә алмыйча торды. Һәм берзаман йөзләре алсуланып киткән кешеләр дәррәү тетрәнеп, клубны күтәреп китәрдәй итеп кул чаптылар. Бу аның үз гомерендә иң биек тантанасы, иң биек җиңүе иде. Ул туң, битараф кешеләрне дә уятты, аларга үзенең тирән кайгысын җиткерә алды сыман.

Җырчының эче тулы кайнарлык иде. Аның янудан салкын суларга сикереп төшәсе, суынасы килде һәм ул, үз-үзенә исәп-хисап биреп бетермәстән, йөгереп чыгып, бер кружка суны ут бөркеп торган тамак төбенә койды.


Зал котырынды, шаулады, җырчыны кабат-кабат дәште.

Ә сәхнә артында Айдар, кайнар шатлык һәм чиксез югалту хәсрәте уртасында калып, үкси-үкси елый, сыкрый, тирән-тирән итеп тыелгысыз сулкылдый иде.

Кайчандыр тиенгә бетәшкән бастырыклылар, аягүрә баскан хәлдә, җырчыга бар мал-мөлкәтләрен бүләк итәрдәй булып, әле берни дә белмичә, аңламыйча, аны кире залга чакыралар иде.

Ләкин бу көнне Айдар Сагындыковның сәхнәдә соңгы тапкыр җырлавы иде. Әллә салкын судан, әллә киеренке кичерешләренең шушы ноктада берьюлы кисешеп шартлавыннан, аны чиктән тыш ярсытуыннан ул үзенең моңлы тавышын җуйган иде.

*1979—88*



**(1900—1981)**

*Рәссам Мансур РӘХИМОВ эше.*

*Хәсән ага Туфанның үземдә калган, әле дөнья күрмәгән хатларын, шигырьләрен кабат-кабат укып, барлап утырам.*

*Шулчак күз алдыма Хәсән ага Туфан үзе килеп баса. Гүя көлә, гүя елмая. Гадәте буенча: «Сәңлем»,— ди, аркамнан сөя. Күрешергә кулын суза. Аның ирләр кулына хас булмаган йомшак кулларын учыма алу исемә төшкән саен үзенә аерым бер тоемлау кичерәм. Аны онытү мөмкин түгел. Мин Хәсән ага Туфанны, аралашып йөргәнгә күрә, шактый яхшы беләм.*

*Шуның өстенә ирем, язучы Габдрахман Минский һәм аның миңа кадәр булган мәрхүмә хатыны Сәлимә апа белән алар озак еллардан бирле бер-берсенә тугрылыклы яшьлек дуслары булганнар. Миңа бу турыда Габдрахман Минский бик еш сөйли торган иде.*

*Моңа Х. Туфанның илленче елларда Себердән Сәлимә апага язган хатлары да ачык мисал була ала.*

*«...Сезнең йөрәкта җанны җылыта ала торган урын барлыгына ышана торган идем. Ялгышмаганмын,— дип яза Хәсән ага бер хатында.— Сагындыра Сәлимә, шул көннәр сагындыра. Хәтерлисездер, ул чорда Калининдагы (Минскийлар яшәгән урам. Г. М.) бәйрәмнәр, рәсемгә төшү — безнең үз бәйрәмебез бар иде. Әдәбият түгәрәге кичәсе көнен кадерле бәйрәм көткән кебек көтеп ала идек. Ул кабатланмас көннәрне Такташыбыз, Кутуебыз һәм башкаларсыз кабатлап була мени инде аларны!»*

*Минскийлар белән Хәсән абыйларның гаилә дуслыгы, Хәсән Туфанны халык дошманы итеп гаепләсәләр дә, өзелмәгән. Бер-берләренә булган якынлыкларын, ышанычлы дуслыкларын дәлилләүче мисаллар Хәсән Туфан хатларында күп.*

*Мин журналның бу санында бирелгән хатның эчтәлегенә тукталмыйча, үземдә калган хатларның, шигырьләрнең кайберләреннән өлекләр генә китерәм:*

*«Менә шул, әкренләп җыеп, сезгә төрле циклдан аларның кайбер үрнәкләрен җибәрәм,— дип яза Хәсән абый.— Алар әле, бәлки, үзгәрерләр. Кайчан булса да бер чагыштырып каравы күңелле булыр. Икенчедән, мин байтак җуйдым, югалттым. Бу исән калганнарының, хәзергә минем кулдагы дәфтәрдәгеләрнең югалуы, әйтик, юлда, поездда югалуы-урлануы яки үземнең уйламаганда үлеп калуым мөмкин. Ә минем дәфтәрләр бар да каралама (черновик) хәлендә...»*

*Хәсән ага Туфанның Габдрахман Минскийга, Сәлимә апага язган хатлары чук-чук сәламнәрдән генә тормый. Аның һәрбер хаты үзе бер документаль повесть кебек:*

*«...Әгәр, Сәлимә, без — Нәҗми, Такташ, Кутуй, мин h. б. — әдәбиятка килеп кергән чагыбызда ук нормаль юлдан йөзгән булсак, Маяковский, Блок, Есениндагы яңалыклар белән мавыкмаган булсак, бүген үтелгән юлга борылып карагaнда кызарырга, оялырга туры килмәгән булыр иде... Тукай исән калган булса, ахыр чиктә Ш. Бабич исән булса да,— бәлки алар безгә азынмаска, тузынмаска кирәкне искә төшергән булырлар иде. Бәлки без Тукайдан читкә китәргә базмаган, аның янында калган булыр идек».*

*Хәзерге татар дөньясындагы проблемаларны Хәсән Туфан моннан 35-40 еллар элек күргән. Үзенең карашларын язган:*

*«Милли театр әсәрләре, әдәби әсәрләр... Ләкин пьесалардагы тел халыкчанлыгы белән проза теленнән байтак аерыла инде. Телнең халык белән турыдан-туры катнашуы, табигый буларак, аны халыкчанлыкка юнәлтә... Вакытлы матбугат та тормыш белән турыдан-туры эш итә. Аны тормыш үз юлына бик нык этәрә, тарта. Шуңа карамастан, газеталар теле белән халык теле арасында шактый зур аерма бар һәм матбугат теле файдасына түгел».*

*Хәсән аганың Сәлимә апага язган хатлары Габдрахман Минскийларның Бакудан яңадан Казанга күченеп йөргән елларына туры килә. Бала белән Сәлимә апа алдан кайта. Берничә айдан соң Габдрахман Минский үзе кайта. Шуңа күрә Хәсән ага Туфан хатны Сәлимә апага юллагандыр.*

*Аннан соң, замандашларының сөйләвенә карaганда, Сәлимә апа югары белемле врач һәм, гомумән, киң белемле кеше булган. Шулай булгач, Хәсән аганың, үз фикерен аның белән уртаклашуы да бик табигый. Аның өстенә, Хәсән ага Туфан хат язып кына җибәрмәгән. Икенче хаты белән дүрт шигырен дә җибәргән.*

*Күптән түгел мин редакция өчен Сәлимә Алимова архивында сакланып калган Хәсән Туфан хатларын гарәп хәрефләреннән хәзерге укылышка күчереп чыктым. Аларның гади хатлар гына түгел, искиткеч тирән, мөһим эчтәлекле хатлар икәнен тагын бер тапкыр инандым.*

*Хәзер укучыларга шул хатларның берсен тәкъдим итәбез. Бу хат Хәсән Туфанның Себердән кайтырга әзерләнгән көннәрендә язылган.*

**Галия МИНСКАЯ**

20 июнь 1956 ел

Бүген бездә иртәдән бирле, Сәлимә, көньягыннан җылы җил исә. Беренче җылы җил. Бәлки, далалар аша Каракомнан килә торгандыр.

Нигәдер ул ярсып, гүяки үксеп исә.

Аңа сүз кушасы, сорыйсы килә:

— Нигә син шулай ярсыйсың, үксисең, җил? Бәлки, мин уртаклаша ала торганмындыр, әйт син, җил әйт миңа!

Һавада, җил өстендә — күксел сөрем. Кояш сөрем пәрдәсе артында моңсуланып утыра, кайдадыр, горизонт аръягында, йөзләрчә чакрымнарга сузылган камышлыклар — Бараба камышлары яна булыр.

Һавада төтен исе...

Миңа шунда хат китерделәр. Тормыш, әдәм баласын җәфалый-җәфалый да гүя уйга кала: «Ә нигә мин шулай итәм?»

Ул менә (тормыш) минем янда хәзер. Чал башымны сыйпый: «Булдыра алсаң,— ди ул,— гафу ит син мине, Туфан: сине җәфалауларымның берсе дә үз ихтыярым белән түгел ич... Мин мәңгелектә матдәнең,— ни өчен икәне әле безгә билгеле булмаган,— серле кануннары буенча каядыр барам. Мин үзем дә белмим, кая барам? Нигә барам? Нигә шулай? Мине дә ниндидер язмыш шулай әвәрә итә. Гафу ит син мине. Кеше, менә мин сиңа бүләк алып килдем»,— ди ул гүя.

Конвертта бүләкнең кемнән икәне, адресы бар. Ләкин мин аны танымаска (укый алмаска) тырышам. Нигә шулай? Белмим, тик хис итәм: шулай яхшы, шулай күңелле.

Тыштагы җил тавышы ишетелми инде. Ул гүя, тынычланып тынып кала. Әйтерсең, үзенә йөкләнгән миссияне үтәгән дә, инде ял итә. Аның тавышы, хатның беренче юлларыннан ук минем йөрәккә килеп кергән җылырак җил, кадерлерәк җил сулышы белән күмелә:

«Җил, сәламнәр бармы, дип
Җилдән сәламнәр сорадым...»

Танышлар болар, танышлар. Тик алар әллә үскәннәр, әллә яшәргәннәр. Әйтерсең, ирләр кулы белән җыелган чәчәкләр, кызлар кулы белән җыештырылганнар. Хатның тик шул төшендә туктыйм да (хат уку бәхетен, янәсе, озынгарак сузыйм), Себер иләндәге нәни өйчекнең болдырына җилләр янына чыгам. Җил инде сабыр, уйчан. Бу җилдә, бәлки, еракта калган көннәрдә очраган җилләрнең — «хәбәр бирмәгән, хәлне белмәгән» җилләрнең атомнары бардыр...

Хат мине менә Кутуй булмәсенә алып керә. Кутуй миңа бервакытны үзенең якын ике дусты турында — берсе Казанда, ә берсе Казанда түгел, Чаптагы хәл турында сөйләгән иде. (Аларны мин дә бераз белә идем). Берәр серне хәбәр итәр өчен түгел, ә тормышның матурлыкларын ярата белүче Кутуй: «Менә бит, Туфан, яшәүнең нинди ямьле яклары бар аның!» — дигән фикерне әйтер өчен генә сөйләгән иде.

— Казандагысы әйтә: «Кайтсын гына, кайда гына күрсәм, шунда — хет мәйданда, урамда, хет театрда — бөтен халык алдында тотам да үбәм мин аны!..»

— Беләсең, Кутуй,— дим, мин аңа,— бу нигә шулай матур? Чөнки бу табигать кебек табигый, ул менә (табигать) көпә-көндез һавага ниндидер, без танымаган алтын сүзләр яза да, беркем белән дә исәпләшеп тормыйча, бөтен Казанны гөрселдәтеп, тота да күкри, яисә Казанның кырый өйләре тирәсендәге шомыртлар, сиреньнәргә

ак һәм зәңгәр чатырлар кора: язын үтеп барышлый тукталгалап ял ал, янәсе, янсә ул гөләпләр, миләүшәләрнең хуш исләре аша безнең җаныбызга Нида кыла, кычкыра һәм җырлый. Аның (Казандагысының) ул сүзе — табигатьнең шундый яклары белән бертуган, аерылгысыз бертуган лабаса!

Бу — 27 нче елларда иде.

Кутуй белән бу турыда без тагы да бер искә алып утырдык. Бусы инде 39 нчы елларда иде.

— Кайбер теләкнең, Кутуй, үтәлгәне түгел, үтәлмәгәне, рияллашканы түгел, идеал хәлендә калганы матуррак. Шулай булганда ул озагырак яши, әйтерсең, үлемсезгә әверелә.

Бер җыр бар: «... Исле гөлләр булып исләремә төшәсең!»

Халык моңы, Кутуй, үзенең рияллашмаган идеалы турында әйтә бугай, рияллашканы турында аның, бәлки, моңардан да матуррак шигыре, поэтик сүзе бардыр. Мин анысын белмим. Ишеткәнем юк, ә бусын беләм.

Кутуй Пушкинның Керн (А. Керн)га багышланган шигырен искә-телгә ала. Шуннан, без (Я помню чудное мгновенье) дән матурлык, эчке матурлык проблемасына күчәбез. Бу дусыбыз да, азмы сөйләшкән, тормышның матурын да, матур түгелен дә бергә кичергән Кутуй да юк инде... Менә шулай, Сәлимә, искә ала-ала, хатны укып чыктым.

Тормыш гүя, «бәхиллисеңме, гафу итәсеңме мине бу бүләгем өчен!» дигәндәй, җавап көтеп тора өстәл янында. Мин аңа әйтәм: юк, сиңа рәнҗемим, кил син, кил, тормышым, якынрак. Әгәр шулай туры килә икән, тартынма, җәфала син мине. Тик син гомернең калган алдагы ягында тагын берничә кат шундый бүләк алып кил миңа.

Сез минем һаман күз алдымда. Нигәдер җирдә түгел, һавада, уйга калган хәлдә басып торасыз. Сез дәшмисез, мин дә дәшмим. Гүя без ятсынабыз. Озак шулай эндәшми торганнан соң, Сезнең шул образыгыз алдында күңелгә килгән сүзләрне әйтәм, башны күтәреп, Сезгә карап:

Әйт син купкә, озак исталеккә
Бер җылы сүз әйт син булмаса:
Бу чиге юк озын мәңгелектә
Бер генә кат яшибез ләса...

Сезнең бу хатыгыз әнә шул җылы сүзне алып килсен миңа.

Мин шуны, Сәлимә, Сезнең хатны алган көндә 11 нче майда язып куйган идем. Бу һич хат түгел әле, бу минем җанның монологы гына. Ә минем Сезгә хат язасым килә. Күпме көннәр үтте инде. Һаман яза алмыйм. Ә Сез бит анда аллә нишә тапкыр инде, хат юкмы икән, диеп кереп чыккансыздыр. Нигә соң ул язмый? Сез менә аны ярты сүздән дә аңларсыз: Сезнең хат — страшно яхшы хат минем өчен. Гадилегендәге гадилеге (беөклеге) белән страшно. Шуны Сезгә әйтәсе, туганнарча уртаклашасы килә. Ә аны әйтергә ярамый. Сез үзегезнең хатның искиткеч матур хат икәнен белмисез һәм Сез аны белмәскә тиешсез. Белдегез исә Сезнең гадилектәге (непосредственное) матурлыкның өркүе, тартынуы, югалуы мөмкин. Сез уйлагыз: минем хат гадәти бер хат. Анда артык искитәрлек бер нәрсә дә юк. Болар бар да Туфанның фантазиясе, башка берни дә түгел һәм Сез миңа ышаныгыз. Мин җүләрлек белән рәттән торырга ярардай фантаст.

Билләһи менә шулай!

Моңарга да ышанмасагыз, менә бары бер факт. Әгәр дә Габдрахманга язган хатны укый алсагыз (мин ул хәрефләр белән чиксез начар язам), Сезнең хаттагы кайбер фикерләр һәм сүзләрнең инде минем йөрәк аша чагылганын күрерсез. Аларның берсен Сез имәннәр турындагы шигырьдә тоярсыз, икенчесе Гөлүси* турындагы сүздә икәнне мин Сезгә әйтмим. Кайда икәнне үзегез табыгыз.

Акыллы кеше сүземени инде бу! Юк, башы фантазия белән тулы җүләр сүзе бу. Янәсе, ышаныгыз: миңа ышанмаска ярыймени?!

Сезгә инде бу аңлашылгандыр, акыллым. Гөлүси, белән дә шундый ук хәл хатларында мине чиксез шатландырган яхшы яклары бар. Йөрәкнең аны (Гөлүсәне) башыннан сыйпыйсы (ярты ятим ул мескенем), менә бит син нинди акыллым! — диясе килә.

---

*Гөлүсә — Х. Туфанның кызы.

Йөрәк әйтә: мин шуны язам. Акыл әйтә: юк, язмыйсың, ярамый. Шуннан аларның икесе арасында айлар буена тартыш бара. Минем акыл ярыйсы, ә йөрәк үзсүзле. Бунтарь.

Мин кайтканчы Гөлүсәнең таянычы булыгыз. Башыннан сыйпагыз. Бу айның унында юлга чыгарга уйлый идем. Туры килмәде. Безнең бер фермада чума (кешегә тими), каты карантин. Чума сүнүгә таба бара инде. Бу ай ахырларында карантин аша үтү мөмкинлеге көтелә.

Казанга кайту юлы буенда абыйлар бар. Көтәләр.

Июльнең беренче атнасы ахырларында Сезнең арада булырмын инде, шаять. Әгәр язсагыз (бу хат барган җиргә яки өйгә), Казандагы икенче тормышның беренче хаты булыр иде ул. Мине анда «хат көтә» дигән уй юлны да күңеллеләндерәчәк.

* * *

Казанга килүләренең берсендә Габдрахман миңа кызчыгыгызны югалтуның Сезгә чиксез авырлыгын аңлаткан иде. Ә мин җүләр: Сезне, шул сагышыгыз белән котларга әзер: сагышлар, авырлыклар, алар безнең ише, кешегә лязем нәрсәләр диеп үк әйтә алмыйм, ләкин зарарсыз нәрсәләр. Алар кешенең җанын баеталар. Моны мин үз башымнан кичереп тә беләм. Һәм Җәлилнең Моабит дәфтәрләрендәге гомере дә моны кояш кебек ачык раслый.

Сәрвәргә (Әдһәмова) һәм Әминә (Җәлил)гә телефон аша булса да миннән сәлам тапшырыгыз. Сәрвәр дә чиксез яхшы, матур йөрәкле. 36 нчы елда Тукай клубындагы зур җыелыш ахырында минем йөрәк баштан сыйпый торган кулга ничек мохтаҗ чагында, беренче буларак, керфекләре яшькә кунган хәлдә шул килгән иде минем янымa. Бу мәңге онытылмаячак.

Сезгә, биредән чыгып киткәнгә кадәр, Сезнең белән уртаклашасым килгән берничә шигырьчыкны җибәрү белән генә чикләнсәм дә, тагын бер язачакмын.

Сәлимә, Сез курыкмагыз: бу хат чумасыз.
Абдрахманга иске адреска яздым.
Ул миңа — Минский, Сездән менә мин Абдрахман диярге өйрәндем инде.
Хушыгыз хәзергә.
Тирән сагыну белән

**Туфан.**

## Хәсән Туфанның бер шигырь-хаты

Кадерле Атилла!

Иң яшьләр дә,— Аязларыбыз да,
Саный бугай сине яшьтәшкә.
Кайсы буын сине күбрәк сөя?
Урын юктыр, бәлки, бәхәскә.

Зур яктамы, кече яктамы син?
Олы эшең әйтсен бу хакта:
Син иҗатың — чын сыйфатың белән
Өлкән якта, Расих, зур якта.

Ихтирамлый сине олы буын,
Таянырга лаек ир итеп,
Һәм кочагын ача сиңа һәр җан,
Талантыңа, Расих, тиң итеп.

Ихтирамлый — талант тәрәзәңдә
Иҗат балкып торган өчен дә;
Зәйтүнәнең —
«Ла шәргыйя вә ла гарбиянең»[1]
Туган улы булган өчен дә.

Отеллога синең, Атиллабыз,
Булмаса да һичбер катнашың,
Иҗаттагы биттә сине, җаным,
Яголардан алла сакласын.

Х. Туфан. 17. IX. 66

---

[1] «Шәрыкта да, гарептә дә тиңе юк» дигән мәгънәдәге Коръән сүзләрен Зәйтүнә Мәүлүдовага атап язган шигырендә Тукай искә ала. Биредә шуңа ишарә. Ред.

*Редакциядән:* Хәсән Туфан бу шигырь-хатын әдип Атилла Расихка 50 яшь тулу көннәрендә язган. Шигырь А. Расих архивыннан алынып, беренче тапкыр басыла.

# Гомәр Хәйям робагыйлары

*Хәсән Туфан тәрҗемәсе*

❁

Кайчангача кайгырачак, көячәксең?
Кайгы төяп кәрвангамы китәчәксең?
Язмышлар бит без дигәнчә түгел алар,
Сайла, ирән*, сабырлыкның ирләрчәсен.

❁

Бу галәмнең иске кәрван сарае бу,
Көн белән төн тулпарының араны бу.
Йөзләп Җәмшид* ду китереп бәйрәм иткән,
Йөз Бәһрамның** гүргә киткән мәйданы бу.

❁

Бу дөньяның чын баласы — без ул, без ул.
Бу җиһанның күз карасы — без ул, без ул.
Әгәр дә бу — божра Галәм — йөзек булса,
Ул йөзекнең гәүһәр кашы — без ул, без ул!

❁

Тик сер итеп кенә миңа әйтте Галәм:
— Язмышны бит син язгансың!— димә, адәм.
Әгәр тәкъдир минем кулда булса иде,—
Туктар идем — мәңге бушка әйләнүдән.

❁

Белә иде, алдан белә иде Хода,
Минемниләр кыласымны менә монда:
Ул бит үзе язган иде язмышымны,—
Ә мәхшәрдә нигә мине җәза кыла?

❁

Бу дәү Яшәү — тик серләрдән яралган ла.
Сер гәүһәрен тишә алган кем бар анда?
Кемдер, нидер әйткән — «сәүдә» өчен генә,—
Яшәү — ни ул? Кем соң шуны әйтә ала?!

❁

Кемдер — килә, алга уза — бу бит — мин!— дип,
Мал-мөлкәткә кулын суза — бу бит — мин!— дип.
Бөтен яктан эшләр бик шәп мәлдә генә,
Кинәт Әҗәл килеп чыга — бу бит — Мин!— дип.

---

* Ирән — ир дип, чын кеше дип әйтергә мөмкин булган зат.

*, ** Җәмшид, Бәһрам — борынгы Иранның легендар патшалары.

Түбәләрдән — түбәннәргә сөргән мәлдә,
Синең белән киңәшәләр димсең әллә?—
Бүген — берәр сәбәп уйлап чыгаралар,
Ә иртәгә — ашыралар гамәлләргә.

Кулны-битне тәяммимләп* тузан белән,
Мәй чүлмәген капласагыз җилән белән,
Сезгә, бәлки, кире кайтыр менә шунда
Хәрабәдә харап булган узган көннәр?..

Мәшһүр булсаң, көнләшәләр, үчләнәләр.
Дәрвиш булып тыйнак торсаң, шикләнәләр.
Хозерсыман* күзгә күренмәсәң генә
Бераз гамьсез яшәп була бездә мәгәр.

Терекнең дә, үлекнең дә раббесе — син,
Безне баскан күгеңнең дә раббесе — син.
Ә мин менә — кара йөзле гасый бәндәң,
Мине шундый зат кылучы, акмы соң — син?!

Берсе — динне, берсе — фәнне хуплый торган
Ике аваз уртасында басып торам.
Куркып куям: «Тегесе дә һәм бусы да —
Дөрес түгел!»— дигән аваз килерсыман.

Базардагы күзә* бүген телгә килде:
Үз хәлләрен, үткәннәрен сөйләп бирде:
— Мин шаһ идем, кулда тулы алтын кадах**,—
Ә мин бүген — бер исерекнең колы инде...

Нигә бәндә маллар җыя бу чүлләрдә?—
Бу галәмдә кеше мәңге тора мәллә?!
Бездәге җан — ул бит фәкать — тик әманәт,—
Әманәт бит синең милек түгел, бәндә!

---

* Тәяммим — су булмаганда тузан-туфрак белән тәһарәт алу.

* Хозер — мифик Хозер Ильяс

* Күзә — эчемлек савыты, кувшин. ** Кадах — рюмка.

❁

Ачык күрәм хәлен бүген бу дөньяның:
Бәхетсезлек баскан аның бөтен ягын!..
Гомер буе кылганымның, кырганымның,
Сөбханалла, җимерәчәкләр тиздән барын.

❁

Безгә язган «яшәү»ләрне, «әҗәл»ләрне
Үзгәртергә әллә берәр әмәл бармы?!
«Тәкъдир» — синең балавызың түгел бит ул,
Үз җаена яраштырып булмый аны.

❁

Мәгълүм безгә, «тәкъдир», синең кылган эшең,
Җәбер, золым чатыры синең торган төшең.
Яманга — аш, ә яхшыга — тик таш синдә,—
Синең бу хәл — тик түбәнлек түгелме соң?!

❁

Сер пәрдәсе аръягына эзләр кайда?
Җаны кайчан китәчәген белгән кайда?
Кереп кунар куыш бары — җир куены...
Бу әкиятнең очын күргән күзләр кайда?

❁

Башйотарның — әллә туйдым дигәне бар?—
Бу язмышны — кемнең әле җиңгәне бар?
Йотылмадым бит әле дип тынычланма:
Сиңа бары — нәүбәт кенә җитәсе бар.

❁

Әгәр гадел булса иде эшең, фәләк*,—
Риза булыр иде һәрбер кешең, фәләк.
Яхшыларны язмыш белән рәнҗетмәскә,
Гаделлеккә җитмидер шул көчең, фәләк?

❁

Дәрвишсыман, җил кумасаң — эшең уңмас,
Каның белән бит юмасаң — эшең уңмас.
Үз исмеңнән танып, әгәр, Мәҗнүнсыман,
Үз-үзеңне җуймасаң син — эшең уңмас.

❁

И, ходаем, син — рәхимсең, син — киң җанлы,—
Сөрдең әмма җәннәтеңнән мин-бунтарьны,

* Фәләк — язмыш, тәкъдир.

Буйсынганны — кем дә аны гафу итә,
Кәрим булсаң, кичер мине — карышканны.

❁

Бу дөньяга, узгынчыга, бирмә ирек,
Яшәмикче аңа һаман башлар иеп.
Язмышларның «азмыш»лары кимрәк булса,
Бәлки без дә бу дөньяга килмәс идек.

❁

Нигә, фәләк, миңа һөҗүм кыласың син!
Нигә минем бәхетем кәефен кырасың син?
Миңа каршы искән җилне — утка әвереп,
Эчкән суга — тузан-туфрак тутырасың син.

❁

Без — курчаклар. Фәләк исә — безнең хуҗа.
Курчак итеп, бераз уйнап алып, гүя,
Безне бераз сикертә дә келәмендә,
Берәм-берәм «сандыгына» салып куя.

❁

Кулның берсе — коръәндә дә, берсе — җамда:
Безнең күңел — я хәләлдә, я хәрамда.
Фирәзәдәй күк астында яшәсәк тә,
Чын кяфер дә түгел бит без, мөселман да.

❁

Гөнаһлансак, ходай аны кичерәмени?
Җан каралса, күңелгә нур сибәмени?
Җәннәтне бит намаз укып түләп алам,—
Ходай аны бушлай гына бирәмени?

❁

— Син — философ!— диде миңа бер дошманым,
Ходай белә,— бу сүзе бит ялган аның.
Андый булсам, ошбу хәсрәт сараена
Килер идемени минем газиз җаным?

❁

Мәңге гөле — бәхетең булып борнаса да,
Яшәү, Хәйям, тик тар кием була барса,—
Тән чатырыңның ышыгына таянма син:
Казыклары дүртесе дә черек ласа.

❁

Фәннәр тулган зиһенем, хәтерем сараенда,
Мин белмәгән серең юктыр, бәлки, дөнья.

Житмеш ике ел буена өйрәндем мин,
Һәм берни дә белмәвемне белдем шунда.

❀

Шәкерт булып килдек тә без бу дөньяга,
Остаз булып гомер иттек зур юлларда.
Без — туфрактан туган идек. Киттек инде,—
Менә тагын — кайттык инде без шуңарга.

❀

Без — ак идек, дөнья, синдә каралдык без.
Көләч идек — басты йөзне караңгы төс.
Түккән яшьләр йөрәкләрне көйдерделәр,
Исраф булып, туфрак белән капландык без.

❀

Без үләрбез — без китәрбез, җиһан — китмәс,
Адәм киткәч дөнья нишләр икән?— димәс,
Безгәчә дә мәңгеләрчә яшәгән ул,
Безнең китү аңа һич тә зыян итмәс.

❀

Китәм инде, дөнья, синнән, китәм менә,
Ышандырдың — золым йорты икәнеңә.
Кем үлемнән качып-посып кала ала,
Шул сөенсен — минем моннан киткәнемә.

❀

Бу яшәүдә — нигез кайда, мәгънә кайда?—
Үлгән мәлне һәрбер бәгырь бата канга.
Ахирәттән беркемнең дә кайтканы юк,—
Кемдер кайтса, сөйләр иде: ни хәл анда...

❀

Бу җиһанның асыл серен белгәннәргә
Шатлык, хәсрәт — икесе дә бер үк нәрсә.
Яхшы-яман, дәрт һәм дәрман — бер өзлексез
Үтеп кенә китеп тора мәңгеләргә.

❀

Көн-төн кәрван үтеп барган юл чатында
Кем бар кайткан, юл хәлләрен сорашырга...
Әй, берни дә калдырмагыз, китүчеләр:
Берәү дә бит кайтмаячак инде монда.

❀

Түгәрәк бер божра булган бу дөньяның,
Башы да юк, ахыры да юктыр аның...

Һичбер кемнең әйткәне юк, адәм, сиңа:
Кайдан килдең, кайда илтә китәр ягың?..

⁂

Тынган инде, зират, синең һәммә кешең.
Бөртек-бөртек туфрак инде һәрбер җисем.
Нинди хикмәт ширбәт эчкән икән алар,
«Мәхшәр»гәчә берни белми «йоклар» өчен?

⁂

Мәгънәләрнең саф энҗесен тиште алар,
Хода кем дип, көн-төн фикер итте алар,
Тик әзәлнең йомгак очын тапмый гына
Берәм-берәм мәңгелеккә китте алар.



# СОҢГЫ МОҢНАР

Мәкаләдә без татар халкының бөек улы Салих Сәйдәшев тормышын тулысынча түгел, ә аның соңгы елларын гына күздән кичерүне максат итеп куйдык. Ягъни Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорны.

Бөек Ватан сугышында җиңүне, башка бик күпләр кебек, халыкның сөекле композиторы Салих Сәйдәшев тә куанып каршылый. Шул шатлыктан ул «Җиңүчеләргә дан» дигән җыр да яза. 1945 елның 30 июнендә исә, ТАССР төзелүнең 25 еллыгы уңаеннан, композитор республика Югары Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

Сугыш тәмамлану белән бергә, матур өметләр дә терелә. С. Сәйдәшев Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына элекке эш урынына кайта. Хатыны Асия Казакова белән театр флигелендә яши башлый. Композиторга кабат иялэшкән коллективта эшләү һәм даими эш хакы мөмкинлеге бирелә. Аның бу чор иҗатына караган бик күп кулъязмалар сакланган.

Театрда С. Сәйдәшев өч ел эшли. Бу вакытта ул Б. Лавреневның «Диңгездәгеләр өчен», Н. Погодинның «Мылтыклы кеше» спектакльләренә музыка яза. Татар драматурглары пьесаларына музыка язганда композитор үзенең иҗади мөмкинлекләрен, әлбәттә, тулырак ача.

1948 елның 1 февралендә Н. Исәнбәт пьесасы буенча куелган «Мулланур Вахитов» спектакле премьерасы була. Т. Гыйззәтнең «Чын мәхәббәт» пьесасына язылган музыка да зур дан казана. Тыңлаучылар албан фольклорына нигезләнеп язылган җырны да бик тиз отып алалар. Спектакльнең бер күренеше Албания тауларында бара. С. Сәйдәшев Казан университетында укучы албан студентларыннан халык җырларын язып ала. Композиторның «Әдрән диңгез», «Динар тавы», «Кошчык» дигән җырлары бөтен илгә тарала. «Әдрән диңгез» җырын эстон җырчысы Георг Отс бик күп еллар буе үзенең репертуарында йөртә.

40 нчы еллар ахырында Сәйдәшев «Наемщик» музыкаль драмасына музыка яза. Шул ук елларда ул балетмейстер Г. Таһировның «Гөлнара» либреттосы өстендә эшли. Балетның нигезенә исә Ф. Бурнаш 20 нче елларда иҗат иткән «Таһир-Зөһрә» спектакле-
Лакин бүген бу балет турында бик аз кеше белә.
нең музыкасы алына.

1948 елда Сәйдәшевнең һәм аның хезмәттәше, иҗатташы Таҗи Гыйззәтнең театрдагы эш урыннары кыскартыла. Театрның ул вакыттагы документларыннан күренгәнчә, Гыйззәтнең рольләре, Сәйдәшевнең музыкаль спектакльләре аз булу сәбәп итеп куелган. Шул көннән алып гомеренең ахырына кадәр композитор кабат «ирекле иҗатчы»га әверелергә мәҗбүр, аның килере дә шактый кими. Әйтик, композиторның радиокомитеттан еллык килере 44 сум тәшкил иткәнлеге, аның шул акчаны кассадан алганнан соң, читкә китеп, «Бу акчага ничек итеп көн күрмәк кирәк»,— дип сызланганы мәгълүм.

Шул рәвешле, халык арасында гадәттән тыш популяр композиторга культура эшмәкәрләре тарафыннан иң гади игътибар да җитми. Аның исеме үзе исән чагында ук легендага әверелеп, әлеге легенда күләгәсе тере композиторның үзен томалый. Матбугатта һәм композиторлар союзында аңа каршы башланып киткән кампания тагын чүп өстенә чүмәлә була.

1948 елның 3 июнендә, иң өлкән һәм иң абруйлы композитор булганга күрә, Композиторлар союзының председатель урынбасары итеп сайланган Сәйдәшев иҗат оешмасы пленумын ачып җибәрә. Шулай итеп, ул үз бакчасына таш атылган утырышларның берсен дә калдырмый йөри.

Ул вакыттагы иҗади обстановка сәнгать кешесенә катгый кысалар куя. Халыкчанлык дигән булып артык гадиләштерү таләп ителә. Парад жанрлары: маршлар, кантаталар модага керә. Нахак тәнкыйтьтән берәү дә читтә калмый. Әнә шундый шартларда һәр иҗат оешмасы үзендә «корбан тәкәләре» табарга тырыша. Татарстан композиторлар союзында исә иң михнәт күргән кеше Сәйдәшев була. 40 нчы елларда союзда үткәрелгән утырышларның беркетмәләрен актарганда Сәйдәшевкә адресланган гаепләүләрнең төрлесенә юлыгасың. Имеш, ул торгынлыкта, союздан аерылган, деградация кичерә, тар жанрда иҗат итә... 1952 елда «Совет әдәбияты» журналында «Сәйдәшев иҗатына карата» дигән мәкалә дә чыга.

Композиторның исеме тирәсендә каты бәхәс җәелеп китә: татар музыкасы тарихында аның урыны кай тирәдә? «Кызыл Татарстан» газетасында Композиторлар союзының музыка белгечләре секциясе белән берлектә үткәрелгән утырышта: «Татар музыкасына нигез салучы дип кемне танырга?» дигән темага бәхәс чыга. Утырыштагыларның берсе тора да болай ди: «Рус музыкасы Глинкадан башлана, профессиональ татар музыкасын Җиһановтан башларга кирәк».

Татар музыкасы тарихында Сәйдәшевнең ролен теоретик, фәнни нигезләргә тырышучыларның барысы да диярлек читтән килгән музыка белгечләре булу гаҗәпләндерә. Мәсәлән, Л. Лебединский РСФСРдагы милли республикалар композиторлары утырышында болай ди: «Сәйдәшевнең татар музыкасына керткән өлеше гаять зур. Аның мәшһүрлеге иң элек көйләрне матур язуы белән билгеләнә. Сәйдәшев ул — татар Варламовы, Алябьевы, Гурелевы. Әмма аның иҗаты ярымпрофессиональ хәлдә катып калган, иҗатында үсеш күренми... Яшь композиторлар Сәйдәшевтән, кызганычка каршы, бик аз әйбер ала ала...»

Композиторның мәшһүрлеген кайвакытта көйләрнең гадилеге белән аңлатмакчы булалар. Ләкин андыйлар чынында Сәйләшев иҗатына хас соклангыч гадилекне түгел, ә талымсыз зәвыкларга ярарга тырышуны күздә тоталар. Аңа «табигый талант», «өйрәнчек» ярлыгы тагарга маташучылар да була. Хәтта бүгенге көннәрдә дә: «Сәйдәшев үз көйләрен нотага сала алмаган икән»,— дигән сүзләрне үз колагым белән ишеткәнем бар минем. С. Сәйдәшев үзе мондый сүзләр ишеткәндә дәшми. Ә халык, трибунадан яңгыраган «акыллы» сүзләргә төкереп тә бирмичә, Сәйдәшевне үлеп ярата бирә. Аның концертларына халык ишекләрне каерып керә, атлы милиция сакта тора. Сәйдәшевне шушы концертлардан мәхрүм итү — бердәнбер чыганактан аеру дигән сүз иде.

...Композитор өчен бүтән заман башлана. Яшьлек талпынуына алмашка үкенү, ачыну килә. Шуңа күрә С. Сәйдәшевнең җырлары тагын да интимрак яңгырый башлый. Ул кешеләрнең ихлас кичерешләрен җырга сала. Аның бөтен музыкасы оригиналь, автор көйләренә нигезләнгән. Һәм, ниһаять, ул беренче булып татар музыкасына симфоник оркестр аһәңнәре алып килә. Аның әсәрләре буенча татар тыңлаучысы Европа классик сәнгатенең увертюра, ария, дуэт, марш, вальс, хореографик сюита кебек жанрлары белән таныша.

«Сугыш елларында Сәйдәшев иҗаты тын торды»,— дигән сүз дә дөреслеккә туры килми. 1943 елда аның М. Юдин белән бергә «Хафизаләм иркәм» дигән музыкаль комедия иҗат итүен әйтү дә җитә.

1949 елда СССР шәһәрләре буйлап концертлар биреп йөрү Сәйдәшевкә зур иҗади һәм материаль канәгатьләнү китерә. Моны илле яшьлек юбилее алдыннан композиторның дуслары оештыра. Җ. Фәйзи җитәкләгән филармониядә җырчылар Р. Ваһапов, Ә. Шайморатова, гармунчы Ф. Биккинин, драма артисты М. Ильдар составында бригада оештыралар. Администраторлары Л. Аитов була. Репертуар тулысынча Сәйдәшев әсәрләреннән тора. Бригадага кергән артистлар аны иң мәшһүр елларыннан ук беләләр. Сәяхәт Сәйдәшевкә зур рухи канәгатьлек бирә. Халык үзенең яраткан композиторын алкышлап каршылый.

Гастроль Уфа шәһәреннән башлана. Кояшлы сентябрь көне була бу. Вокзалда башкорт язучылары, композиторлар, артистлар, журналистлар җыелган. Күбесен С. Сәйдәшев яхшы белә. Әмма гастроль өчен вакыт бик уңайлы сайланмаган булып чыга. Театр ремонтка ябылган. Уфада Сәйдәшевкә кырык кешелек оркестр бирелә. Ике көн репетиция ясаганнан соң, рус драма театры бинасында гастрольләр башланып китә. Тамашачы һәр номерны кабат-кабат сорый.

Икенче көнне газеталарда мактап мәкаләләр басыла. Биш көндә өч концерт куела. Аннары бригада Оренбургка китә. Оренбургта оркестр юнәтә алмыйлар. Бу хәл Сәйдәшевнең ачуын чыгара. Әмма концертлар барыбер уңыш казана. Сәйдәшев үз әсәрләрен үзе фортепианода уйный. Бирегә ул җырчы Оркыя Кушловскаяны да очрата.

Ташкентта да Сәйдәшевне зур хөрмәт белән каршылыйлар. Аның карамагына 60 кешелек оркестр бирелә. Мондый бәхет аңа соңгы вакытта Казанда да бик елмаймый. Дирижер пульты янында тормаганына да күптән инде... Шуңа күрә мондый коллектив

белән эшләү куандыра. Чәчәкләр, алкышлар, соклану — барысы да була. Ә Туган Татарстанында аны язмыш бер дә иркәләми. Ташкентта концертлар, гадәттә, «Кызыл армия» маршы белән тәгәлләнә. Аны кат-кат уйнаталар. Ике көндә Ташкенттагы концертларга өч мең кеше килә, егерме мең акча керә.

Аннары бригада Алма-Атага юнәлә. Казахстан башкаласында Сәйдәшевкә аеруча ихтирам вә илтифат күрсәтелә. Концертларның берсенә республиканың хөкүмәт җитәкчеләре дә килә, концертны радиодан тапшыралар. Шәһәрдән китәр алдыннан соңгы кичне Сәйдәшев, артистлар һәм казах культурасының башка әһелләре белән бергә, Алма-Ата консерваториясе ректоры А. Жубанов янында үткәрә. Алма-Атада 7 көн булганнан соң, артистлар Казанга кайтып китә.

Сәяхәт Сәйдәшевкә фикердәшләре белән аралашу, иске дуслары белән очрашу, иң мөһиме халык каршына чыгу мөмкинлеге бирә. Ул яшьлегенә кайткандай була. Гастрольләргә тагын да чыгасы килеп, канатланып кайта ул аннан.

Казанда исә бөтенесе искечә... Әмма инде ул кабат ашкынулы. Т. Гыйззәт белән бергәләп композитор «Алсу таң» пьесасына керешә. Пьесаның темасы отышлы сайланмаганга күрә, спектакль уңыш казанмый. Спектакльгә язылган музыка исә Композиторлар союзы утырышында тыңлана һәм уңай бәяләнә.

1950 елда С. Сәйдәшевкә 50 яшь тула. Аны җәмәгатьчелек киң билгеләп үтә. Композиторга ТАССРның халык артисты диган исем бирелә.

Кырыгынчы еллар азагында Сәйдәшев балалар өчен җырлар циклын тәмамлый. Һәр бәйрәмне ямьләрдәй бу җырлар төрле башкаручылар өчен языла. «Тынычлык турында балалар җыры», «Укучылар вальсы» һәм башка җырлар балаларны милли аһәңнәрдә тәрбия кылу өчен менә дигән мәктәп була. Җырлар тиздән басылып та чыга.

Композиторның соңгы еллары иҗади эштә, Композиторлар союзында, хезмәттәшләре арасында уза. Җәйне ул гаиләсе белән Идел буенда, Кызыл Байрак авылындагы дачада үткәрә. Кайчагында концертларда, иҗади очрашуларда катнаша. Мәсәлән, 1953 елның февралендә Совет Армиясе сугышчылары белән очрашу үткәрелә, анда җырчы Х. Зәбирова композиторның «Кадерле минутлар» спектакленә язылган җырларын башкара. Еш кына Сәйдәшевне мәктәпләрдә, уку йортларында күрергә мөмкин була. Композиторның соңгы кичәсе Алабуга педагогия институтында үтә. Анда А. Ключарев, Җ. Фәйзи, Ә. Бакиров та була. Очрашу гаҗәп җылы үтә.

50 нче еллар башында композитор берничә мәртәбә зур күләмле музыкаль әсәр язарга талпынып карый. ТАССР Композиторлар союзы планнарында Тукай әкияте буенча Ф. Гаскәров либреттосына язылган балет, М. Садриның «Ак күгәрчен» музыкаль комедиясенә язылган көйләр бар. Композитор кабат «Наемщик» операсына тотына. Әмма ул планнарга чынга ашарга язмаган икән... Сәйдәшевнең соңгы моңы — М. Җәлил сүзләренә язган «Җырларым» әсәре...

1954 елның җәендә Сәйдәшевнең сәламәтлеге кинәт начарлана. Бүтән сузарга ярамый. Кичекмәстән Мәскәүгә дәваланырга җибәрергә кирәк. Сәйдәшев Казаннан киткәндә бик моңая. «Мин бит Мәскәүгә үләргә дип китәм»,— ди ул бер танышына...

26 августта Сәйдәшевне Казан вокзалында озатып калалар. Башта вокзал буфетында, аннары купеда утыралар. Кемдер чәчәк бәйләме суза. Шунда берәү әзгәләнеп әйтмәсенме: «Чәчәкне тизрәк хатынына бирегез. Шундый ырым бар: авыруга чәчәк бирергә ярамый!»

27 августта композиторны Мәскәүдәге Вишневский шифаханәсендәге унынчы палатага салалар. Операция көткәндә ул бик ямансылый. Казаннан хәбәрләр көтә, килүчеләргә бик куана.

Беренче көнне үк профессор Алипов рентген сурәте ясата. Сул як үпкәсендә киста табалар. Сәйдәшев докторны бер күрүдә ошата. Операцияне профессор үзе ясый. Ләкин инде соң була. Салих Сәйдәшев соңгы сулышына кадәр Казанны җирсеп яши. Инде алып кайтырга дип М. Мозаффаровны юлга да әзерләгән булалар. Ләкин 1954 елның 16 декабрендә «композитор вафат» диган хәбәр килә. Мәрхүмнең табутын Казанга Ә. Бакиров алып кайта.

Салих Сәйдәшевне соңгы юлга озатырга халык күп җыйнала. Кайгының чиге-кырые юк. Мәрхүмнең табуты театр фойесына куела. Көн салкын, ә халык агыла да агыла. Оркестр матәм көйләре уйный, ул язган «Сакай маршы» яңгырый...

Шул көннән бирле Салих Сәйдәшев музыкасын ничәмә-ничә буын тыңлап үсте. Ә еллар үткән саен аның бөеклеге, татар халкының музыка культурасына керткән өлеше һаман калкурак күренә бара.

**Ф. СӘЛИТОВА,**
сәнгать фәннәре кандидаты.

## Илдар Юзеев

Юк,
Бер без генә түгел,
Хәтта
    көйләрең дә
Сагына сине — язлар җырчысын.
Салих абый,
Кабатланмас бер матурлык булып
Син тормышны бизәп торырсың.
Менә урам.
Сәйдәш күңеледәй
Киң һәм матур...
Әйтерсең лә
Моңнарыннан аның нурланган.
Менә Сәйдәш,
Илебезнең мәгъруp данын җырлап,
Марш булып үтә урамнан.
Ул моң булып яши күңелләрдә,
Ул рух алып керә өйләргә.
Их,
Исән чакта сине күрәлмәдем,
Сүзем бик күп иде сөйләргә.

## Равил Фәйзуллин

Сәйдәш рухы йөрде фронтларда,
окопларда, алгы сызыкта.
Туплар булып яңгырады «Марш»
фашизмга каршы, коллыкка!
Шифа-омет булып кунды Сәйдәш
Әсирләрнең туңган җанына.
Җиңү булып, яшьнәп керде Сәйдәш
Бранденбург капкаларыннан!
Сәйдәш — җыя бергә, туплый, әйди,
йокымсыраганны да кузгата.
Якты рух өсти ул. Кешелекле
тавыш-аһәңнәрне уята.
Эчке тоем белән рухка үтү —
Сәйдәш талантының иркендә.
Җырлары аның — шәхси үзенеке дә,
шул вакытта — һәркемнеке дә!

## Зөлфәт

Дәште комбат:
    — Кемнәр көйне тоя?
Музыкага кемнең куллар нык —
Сәйдәшевнең
    «Совет Армиясе
Маршы»н оркестрда уйнарлык?
. . . . . . . . . . . . . . .
Каеннарны сарды Сәйдәш маршы.
Юк,
    без ким түгел җирдә һичкемнән!—
Әйтерсең лә
    туган як казлары
Күтәрелде таулар өстеннән.
. . . . . . . . . . . . . . .
Тешен кысты комбат:
— Сәйдәшчеләр!
Без исән-сау чакта бу җирдә
Яңгырыйк
    бер якты аваз булып,
Үзебезгә насыйп гомердә!
. . . . . . . . . . . . . . .
Күтәрелдек...
Житәкләде жанны,
Сәйдәш үзе безне күтәрде:
«И туганнар, бирмик килмешәккә
Тургай сайрап торган күкләрне!..»

# КЫЙММӘТЛЕ ИСТӘЛЕК



Бөек татар композиторы Салих Сәйдәшев биографиясендә ачыкланмаган урыннар һаман да бар әле. Ул үзе тәрҗемәи хәлен язып калдырырга өлгермичә дөнья куйды. Аяныч хәл. Шуңа күрә мәдәниятыбызның якты йолдызы булган композиторыбызның тормышына һәм иҗатына кагылышлы һәрбер яңа чыганакларны җыйнау һәм дөньяга чыгару — намусыбыз эше. Бу уңайдан композиторның 1919 елның көз айларында Оренбургта булуын раслаучы фоторәсем дә игътибарга лаек.

«Кызыл яу» газетасы 1919 елның 13 ноябрь санында Г. Кариевның талантлы шәкерте артист Габрахман Мангушевның 27 октябрьдә вафат булуын хәбәр итә. Журнал укучыларга тәкъдим ителә торган фоторәсемдә күренекле артистны соңгы юлга озатуда яшь композитор Салих Сәйдәшевнең дә катнашканлыгы күренә.

Хәсән **ГОБӘЙДУЛЛИН,**
Сәнгать фәннәре кандидаты.

# ПУБЛИЦИСТИКА

Ибраһим Салахов

# ТОМАННАРГА ТӨРЕНГӘН ЯШЬЛЕК ТУРЫНДА

*Яшьлек, күксел таулар төсле*
*Киткән саен матур, ягымлы*
*Томаннарга төренер яшьлегемне*
*Мин онытмам кайнар чагымны...*

Гаҗәп! Кайдан соң әле бу эпиграф? Ә-ә, әйе бу минем үз шигыремнән. Аны мин әле Күкчәтау татар җидееллык мәктәбен тәмамлар алдыннан, Нури Арсланов белән Мола-Чукы тауларына барып, текә кыяларга үрмәләп-тырмашып менеп, киң дөнья белән танышып йөргән алсу көннәремдә язган идем. 1927 ел. Миңа нибары 16 яшь, балалыктан яшүсмерлеккә аяк атлаган гүзәл чор! Үзем «томаннарга төренер яшьлек» турында язам. Гаҗәп!..

Мин инде җидееллык мәктәпне тәмамладым. Инде укуымны дәвам иттерергә һәм Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Хәсән Туфаннар белән очрашырга (миңа калса, алар әллә кайчан минем Казанга килүемне зарыгып көтеп торалар) барам. Билгеле, буш кул белән түгел — байлык бар — ике калын дәфтәр. Берсе кара, коленкор тышлысы — шигырьләр. Икенчесе үзем эскәнҗәдә (станокта) төпләгән, катыргы тышлысы — хикәяләр. Аның әчке тышлыгын, минем соравым буенча, бик зур тырышлык белән, төрле төстәге буяулар кулланып Нури дус ясады. Текә биек таулар өстендә караңгы болытлар өерелә. Алгы планда — шул караңгы күккә үрелгән ике мәһабәт таш кыя. Кыялар аралыгыннан ачулы, үч алу нәфрәте, гайрәт белән янган ике күз карый. Күзләр арасында булат хәнҗәр! Хәнҗәрнең үткен очыннан кан тамчылый һәм... кыя итәгендә ул кызыл тамчылар хәрефләргә әверелә: «Тау гыйшкы». Хәзер инде бу беренче хикәямнең сюжетын хәтерләмим, әмма ачулы күзләр, очыннан кан тамып торган хәнҗәр әле дә күз алдымнан китми...

Түбәм күккә тиде — Казаннан, педагогия техникумыннан хат! Имтиханга чакырганнар. Бу уку йортына, мине укырга алуларын үтенеп хат-гариза язуымны хәтерләмим, менә аларның чакыруы күңелгә уелып калган.

— Һай-һай, артык ерак җиргә үреләсең, барып җитә алырсыңмы икән?— диде әти көрсенеп.

— И, теле бар ич, табар,— әни сөенеченнән елмаеп, беренче тапкыр аркамнан кагып куйды.— Үзең сыман гомер буе балта күтәртмәкче буласыңмы, укыса, начальник булыр!

Әти миңа фанердан, бик җиңел итеп, клеенка белән тышлап, чемодан да ясап бирде. Биге дә бар. Анда алмашка дигән күлмәк-ыштанны, китапларны-дәреслекләрне, конспектларны һәм беренче әсәрләрем язылган ике калын дәфтәремне салдым. Күтәреп карадым — салмак! Бу мәшәкатьне түр өйдә, ишекне ябып, аулакта гына башкарып маташа идем, алдагы өйдә әтинең тавышы ишетелде:

— Рәбига, Ибрайның китәренә өч кенә көн калып бара. Әйттем бит, юлга бер ярты капчык сохари киптер, дип — кузгалганың күренми...

— Нәрсә?— Әтинең сүзен бүлеп әни әче тавыш белән кычкырып җибәрде.— Ярты капчык! Болай да бер сыер алырлык акча бирергә җыенасың!

— Җитәр!— Әти ачу белән өстәлгә сукты.— Күп сөйләмә, хәзер үк камыр куй! Тышкы ишек шарт итеп ябылды. Әни мышык-мышык елый башлады. Мин

дә хафага калдым. Нигә инде ул хәтле сохари? Үзе бит 45 сум акча бирәм дигән иде. Әллә акчаны азайтырга уйлыймы?..

Ниһаять, кемдер кычкырды: «Казан!»

Мин сәндерәдән очып төшердәй булып, башымны күтәргән идем, вагонның тимер түшәменә шак иттем. Күзләремнән утлар чәчрәде. Юк, күпме талпынмыйм, ашыкмыйм, бу урыннан тиз генә төшеп китеп булмый. Ә йөрәк ашкына. Казанны, бала чактан ук кыйбла саналган моңлы, нурлы Казанны үз күзләрем белән күрәсе иде. Әмма... Вагон дыңгычланган. Юлчылар берсе өстендә берсе утыра диярлек. Дау, дәнҗал, сүгенү, елау һәм күзачкысыз төтен, тәмәке төтене. «Казан» дигәч, вагондагы бар халык, берьюлы ишеккә таба авышты, берсен-берсе этә, кысрыклый башлады.

Халык бераз сирәгәя төшкәч, идәнгә сикердем, тиз генә пальтомны кидем. Әти биргән 45 сум акчалы бумажникны чалбар кесәсендә саклап килгән идем, инде пальтоның эчке кесәсенә күчердем. Алай-болай төшеп калмасын (алла сакласын, бар байлык шул бит!). Кулда — чемодан, иңдә — капчык! Мине шундук ишеккә таба этеп алып киттеләр — хәерле сәгатьтә!

Перронга чыгу белән яхшылап Казанны карармын дигән идем. Кая ул! Күтәреп, очыртып алып баралар. Уң кулда — чемодан, сул кул белән иңемдәге капчыкны тотам. Пальтоның төймәләре вагоннан төшкәндә үк коелып калганнар иде. Хәзер аның бер чабуы артта, икенчесен алдан тартып баралар. Йолкып алып китмәсәләр генә ярар иде. Сулда кызыл кирпечтән салынган бер зур бина. Арырак — тар гына аралык. Мөгаен, капка. Шунда ишелеп кердек тә, бүселеп чыктык. Чемоданым «лып» итеп җиргә төште, аның өстенә капчык ауды.

— Уф алла!

Каршыда ат башлары хәтле ташлар түшәлгән киң мәйдан. Резина тәгәрмәчле, фаэтоннарга җигелгән аргамаклар тып-тып басып киләләр. Берсеннән-берсе сылу, һавалы! Кайсы җирән, кайсы алмачуар, кайсы күмер-кара, кайсы сөттәй ак — акбүз. Фаэтонның алдагы утыргычларында — «күрәсезме абзагызны» дип хуҗалар кукырайган. Әйберләремне күтәреп, фаэтон көтүчеләр янына киттем. Чираттагы юлчылар, кунаклар үз юлларына китеп беттеләр. Мәйданда ялгыз үзем генә калдым.

— Әй, саламторхан, нишләп утырасың?— Башымны күтәрсәм — җирән аргамак җигелгән бер фаэтон.— Әллә Казанга беренче килүеңме?

Сикереп тордым: «Әйе, әйе, абый!»— дим.

— Кайда барасың?

— Менә, абый,— кесәдән теге хикмәтле хатны чыгардым.

— Ахмак, үзең әйт, мин мулла түгел, укый белмим.

— Чернышев урамы, 5 нче йорт.

— Ярар, алып барырмын, алдан йөри торганы бармы соң?

— Анысы нәрсә, абый, алдан йөри торганы, көчекме?

— Аңгыра, акчаң бармы? — дим.— Күрсәт җәтрәк, булмаса — китәм.

— Менә, хәзер!— Тиз генә пальто кесәсенә тыгылдым, бумажник юк. Чалбар кесәләрен актара башладым, буш!

— Нәрсә, җилләр искәнме?— извозчик мәсхәрәләп көлде дә дилбегәләрен какты.— Әйдә, малкай! Башка пассажирны эзлик, бусын тишек чемоданга утырткан-нар, на-а!

Дагалы тояклар урам ташларына шак-шок итте, әйтерсең лә маңгаема типтеләр.

Моң! Сагышлы һәм ләззәтле моң, бер якыная, бер ераклаша, аннан тагын дулкынланып килеп бәгырьне тетрәндерә һәм иркәли. Әллә төш, әллә өн. Күзләремне ачтым — арып килеп егылгач, йоклап киткәнмен икән. Кузгалырга, алай гына түгел, хәтта сулыш алырга да куркам — бу гүзәл җыр, тылсымлы моң минем бер урынсыз хәрәкәтемнән тынып калыр төсле:

— Ай-һай гына диеп бер кычкырсам,
Яңгырыйдыр кыя ташлары.
Табылмаган дөнья малы өчен
Каңгырыйдыр егет башлары...

Минем мондый моңлы татар көен, болай матур итеп татарча җырлауны ишеткәнем юк иде. Могҗиза! Торып утырдым, тирә-ягыма карандым. Зур, якты бүлмә. Тигез рәт белән тезелгән тимер караватлар. Менә шушы инде мин мең бала белән эзләп тапкан, килеп егылган тулай торак. Әнә, иң кырыйдагы караватта минем кебек киемнәрен дә салмыйча яткан бер егет. Өстендә соргылт, таушалган пинжәк, чалбар. Йөзе күренми, стенага борылган. Тузгак соргылт чәчләр. Димәк, ул мин йоклап киткәч, кереп яткан. Хәзер менә шушы егет җырлады бит. Булса да була икән адәм затында шул кадәр моң һәм көр тавыш! Бар кайгыларым таралып китте, хәтта әти бир-

гән 45 сум акчаны урлатуымны да, ул җыр яңгыраган мизгелдә онытып тордым. Ә хәзер! Хәзер ул кара кайгы җаныма тагын ябырылды. Ярый әле сохарилар бар. Ачтан үлмәм. Техникумга кергәч, стипендия бирерләр.

Күршем торды. Миннән аз гына калку, нык коелган егет. Йөзе аз гына тутлы булса да ачык, мөлаем. Үзе килеп кул бирде: «Кәмитов[1]. Бөгелмә ягыннан. Техникумның II курсында укыйм, вакытлыча Устиядә баржа бушатам. Ә сез кайдан?..»

Мин хәлне сөйләп бирдем. Күрше кайдандыр бер чәйнек кайнар су алып килде. Тәрәзә төбенә җайлаштык. Мин сохари капчыгының авызын чиштем...

Мине техникумга алмадылар, тулай торактан куып чыгардылар. Химиядән ниндидер бер кислотаның составы формуласын дөрес язмаганмын һәм балл җитмәгән.

Урамда — яңгыр. Көзге шыксыз яңгыр. Шыбыр да шыбыр, һич туктауны белми. Мин Кремль стенасы буендагы куышта, Казан елгасына карап, аптырап утырам: менә сиңа нурлы Казан!

Инде нишләргә? Өйгә кайтып китәргәме? Пальтоны сатып. «Юк!» Кычкырып җибәрдем дә, үз тавышыма үзем сискәнеп киттем. Кайтмыйм! Бусагадан атлап кергә үги ана, мыскыллап авызын кыйшайтыр.

Казанка өстендәге томан таралды. Яңгыр тукталгандай булды. Суык, дерелдим. Ә көн инде кичкә авыша. Бу төнне кайда уздырырмын? Нәрсә ашармын? «Тукта, булмаса, вокзалга барыйм. Бәлки шунда берәр урындыкта черем итеп алырмын».

Киттем. Үрдән Проломный (хәзер Бауман) урамына төшәм. Тайгак, берничә тапкыр аягым шуып китеп егыла яздым. Ниһаять, таш түшәлгән урам.

— Ибраһим!

Сискәнеп туктап калдым. Тавыш килгән якка борылдым — урамның аргы ягыннан Мостаф-негр килә (соңыннан ул шагыйрь Мостафа Ногман булды). Тулай торакта минем белән янәшә яткан иде, хәзер инде ул техникумда укып йөри.

— Кара әле, күрше, болай итик. Комендант яңа гына өенә кайтып китте. Күрдем. Ул әле иртәгәсез килми. Әйдә тулай торакка! Икәү бер топчанга ятарбыз,— диде ул миңа.— Иртәгә, ул килгәнче, шыларсың. Әйдә, әйдә, киттек!

Без парлашып Проломный буенча түбән төшеп киттек. Мостафа сөйли:

— Кара әле, күрше, мин монда абыйларга килгән идем. Ул «Спартак» фабрикасында эшли. Фабрикага көнлекчеләр кирәк, ди.

Куанып киттем: «Барам!»— дип кычкырып җибәрдем.

Менә мин Казан аяк киемнәре фабрикасы «Спартак»та көнлекче. Иртәнге 8 дән кичке 6 га хәтле фабрика курасындагы әрдәнә-әрдәнә өелгән чи тиреләрне әле бер цехка, әле икенче цехка ташыйбыз. Ул арада машина белән килгәннәрен бушатабыз. Сарык-кәҗә тиреләрé әллә ни түгел, сыер-үгез тиреләре авыр. Икәүләшеп, көч-хәл күтәрәбез. Өс-баш пычрана, майлана. Арыйбыз. Сменадан соң исә кулга 20 тиен көмеш тоттыралар — шәп! Бу инде миңа тәүлек буенча ашап-эчәргә җитә. Төшке ашка фабрика ашханәсенә керәбез. Менә дигән өреле, токмачлы аш — телеңне йотарсың!

Эштән чыккач та әле тулай торакка ашыкмыйм. Комендантка юлыгуың бар. Шулай эштән иртәрәк кайткан бер көнне, киного керерлек акча булмагач, Черек күл буена чыккан идем, искитте. Халык! Барысының да кулларында көрәк, лом, кул арбасы.

— Нишлисез, егетләр?

— Акча эшлибез. Син нәрсә аптырап утырасың, әйдә, әйбәт эшләсәң, бригадама алам.

Шулай бер дә уйламаганда, тире ташуны ташлап, җир казучыга әйләндем. Бердән, бу эш бик якын, икенчедән, чыннан да, «көрәкне батырып эшләсәң», норманы арттырып тутырсаң —70-80 тиен, хәтта бер сумга хәтле «төшереп» була икән.

Беркөнне шулай Чернышев урамы (хәзер Ленин урамы) буенча университетка таба төшеп бара идем, почта янында, каршы килүче бер ханымга бәрелеп киттем: «Гафу итегез»,— дип, оялып башымны күтәрдем һәм... Үз күзләремә үзем ышанмыйча артка чигендем.

— Ибраһим, бу синме?

Каршымда Күкчәтау мәктәбендәге мөгаллимәм Маһитап — «алма апа» басып тора. Телем бәйләнде. Нишләргә дә белмим, катып калдым. Почта стенасына китеп сөялгәч кенә исемә килдем.

— Исәнмесез, «Алма апа»!

— Син кайчан монда килеп чыктың? Укыйсыңмы?

---

[1] Фоат Нуриевич Каметов 1907 нче елны элекке Әлмәт волосте Әлмәт авылында туган. 1926—31 елларда Казан педтехникумында укый. Пединститутны «кызыл диплом» белән тәмамлый. Минзәлә һәм Буа техникумнарында ана теле укыта. Бөек Ватан сугышы фронтларында берничә мәртәбә яраланып, 1942 елда һәлак була.

Хәлне сөйләп бирдем.

— Ярар, бер дә кайгырма,— ул аналарча иркәләп аркамнан какты.— Мин иртәгә үк техникумга барып, директор белән сөйләшермен. Син берсекөнгә бар, мин көтеп торырмын.

— Сез кайда укыйсыз, «Алма апа»?

— КПИдә. Көнчыгыш педагогия институтында.

Ул тагын аркамнан какты, елмайды. Дөнья яктырды да китте.

Мине техникумның I курсының II группасына билгеләделәр. I группада Алабугадагы хәзерлек курсын тәмамлап килгәннәр (Мостафа дус та шунда) үзләре генә укыйлар икән. Элекке елларда Казанда аерым-аерым рус, татар, чуваш, мари, удмурт педагогия техникумнары эшләп килгән булган. Ә бу ел исә аларның барысын берләштереп, зур бер техникум корганнар. Техникум Болакның сул ягындагы, элекке Учительская семинария бинасына урнашкан. (Хәзер анда педагогия институты). Ә студентларга тулай торак итеп, Казанка буендагы элекке хатын-кыз монастырен билгеләгәннәр.

Уф алла, ниһаять, мин дә — тулы хокуклы студент! Иртә белән торам да башкалар белән бергә техникумга йөгерәм — лекцияләр тыңларга! Минем сабакташлар миңа хәтле ике айлап укыганнар. Димәк, минем бурыч — аларны куып җиту, баш күтәрми уку, тырышу. Йокыны кыскартканнан-кыскарта барам, ял көннәре юк. Кино онытылды. Рәхмәт әле, тирә-яктагы иптәшләр булышалар: конспектларын бирәләр, төшенмәгәнне, бергә утырып укып, әйтеп, мәсьәләләрне чыгарышалар. Укытучыларыма да рәхмәт — кат-кат әйтеп төшендерәләр, өстәмә дәресләр бирәләр. Кайберләре хәтта, дәрестән соң калып, минем белән шөгыльләнә. Безне мәртәбәле остазлар укытты: Җамал Вәлиди, Хуҗа Бәдыйги, Гариф Богданов, Габдулла Шынаси, Солтан Габәши, Мөхетдин Корбангалиев, Гасыйм Касыймов, Сәләх Атнагулов, Әминә Хәлитова, Илһамия Богданович, соңрак Салих Сәйдәшев һ. б. Рәхмәт Сезгә, гыйлем хадимнәре! Сезнең якты образыгызны горурлык белән күңел түрендә саклыйм.

Без әле монастырьга күчмәдек, анда — югары курс студентлары. Техникумга быел кергәннәр — Чернышев урамындагы ике катлы бинаның өске катына һәм без, малайлар — Проломныйда. Ул — озынча бүлмә. Почмакка барып җиткәч, ул әле, сулга борылып, тагын бераз дәвам итә. Залның ике як стенасы буйлап топчаннар тезелеп киткән, җәмгысе — 70 тән арта. Уртада — калын тактадан эштер-эштер генә кагылган озын-озын өстәлләр. Ике якта — шундый ук эскәмияләр. Шушында ашыйбыз, шушында ук төркем-төркем булып дәрес хәзерлибез.

Дүрт-биш лампочка кызарып кына яктырта. Кайчакларда бөтенләй сүнеп тә калалар. Әмма без гыйлем эстәүдән чигенмибез. Шушы хәтле халык бер бүлмәдә булуга карамастан, шау-шу, ызгыш юк. Тәмәке тартуларын да хәтерләмим. Аракы турында ишеткәнем дә булмады. Теләк, омтылыш — бары тик белем алу.

Минем Күкчәтаудан Казанга килүемдә икенче максат та бар иде бит. Әдипләр белән очрашу. Гаҗәп, Казанга килгәч, мине Галимҗан Ибраһимов та каршы алмады. Такташ белән Туфан да күренми. Күрәсең, үземә берәр чарасын табарга кирәктер. Сораша торгач, белдем: Галимҗан ага авырган. Аңа операция ясап, бер үпкәсен бөтенләй кисеп алып ташлаганнар. Хәзер ул Ялтада дәваланып ята, ди.

Ә калганнары? Мин инде аларның кай тирәдә йөрүләрен белеп алдым. Безнең тулай торакның аскы катында «Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы» газеталары һәм «Авыл яшьләре» журналы редакцияләре эшли. Арырак — «Кызыл Татарстан» газетасы, «Чаян» журналы, түбәндә — «Азат хатын» журналы редакциясе. Бу — пыяла түбәле «Пассаж»да — Татарстан китап нәшрияты һәм Гажур (газета-журналлар берләшмәсе) дигән оешма. Язучылар, шагыйрьләр, һичшиксез, шушы тирәдә йөрергә тиешләр. Билгеле, бу серле иҗатханәләрнең ишекләрен ачып керергә кыюлык җитми. Шулай да, буш вакытларда бу тирәдә чуалам — бәлкем берәрсен очратырмын.

Шулай беркөнне, кичкә таба, тагын «Пассаж» тирәсендә йөргәндә бер күзлекле абый капылт туктатты.

— Әй, егет, нигә монда йөрисең? Көн дә күрәм.

— Тик.

— Ахмак! Син тик йөрмә, эш белән йөр! Кайда укыйсың?

— Педтехникумда.

— Алайса, әйдә киттек.

Нишлим?! Иярдем дә киттем. «Пассаж»га кердек. Агайның эш бүлмәсе зур гына икән. Каршыда — бар стенаны алып торган тәрәзә. Уртада — өстәл. Шкафлар күп. Идәндә газета-журнал тегелмәләре. Хуҗа арттагы шкафын ачып шүрлегеннән бер юка гына брошюра сыман китапчык һәм берничә төпләмә бланклар алып өстәленә куйды. Камыш урындыгын тартып утырды.

— Менә бу китап, энем, каталог дип атала. Монда барлык газета-журналлар-

ның бәяләре язылган. Менә бусы — подписка бланкы. Төшергеч аша өч нөсхәдә тутырыла. Син, педтехникумыңа кайт та, газета-журналларга язылу оештыр! Акчаңны, подписка кәгазьләреңне сакла, югалтып, хур булма!

Шулай итеп, мин, уйламаганда, матбугат таратучыга әйләндем. Профком да бу эшне мәгкуль күрде. Мин хәтта студенттан акча алып та тормыйм, ведомостька кул гына куйдырам. Стипендия бирелгәндә, бу сумманы кассир тотып кала. Соңыннан мин акчаны алам да, подписка квитанцияләре белән теге күзлекле абыйга тапшырам...

Тиздән кышкы каникуллар. Өйгә кайтасы иде, сагындым. Юлы да буш, акча түлисе юк. Тик өйгә ничек кайтып керерсең, ничек дуслар күзенә күренерсең?.. Каникулга китәр көннәр якынлашкан саен шул бер сорау мине иги дә тора. Бар хикмәт шунда — минем өс-баш бик хөрти. Теге вакытта тире ташып, җир казып, кием-салым майланып, пычранып, таланып бетте. Инде әллә ничә тапкыр пинжәк-чалбарны юып, ямап маташтым. Һич рәткә кертеп булмый. Бер тишекне ямыйсың, икенчесе авызын ача. Бу килеш кайтсаң, ишектән керер-кермәс әни бот чабып көләр.

— Әй аллам, кара әле, әтисе, Казаннан нинди «ширмаш» кайткан! Ә без...— дип, авызын кыйшайтып көләр, теге 45 сумны чәйнәргә тотыныр.

Юк, кайтмыйм, адәм көлкесе булып, әтине җәрәхәтләмим. Калам! Берәр җиргә эшкә кереп, акча табарга — киенергә кирәк... Аптырагач, тулай торакта үзем урын таба алмагач, урамга чыгып киттем, «Пассаж» ягына. Борын төшкән.

— Ибраһим!— сискәнеп башымны күтәрсәм, теге күзлекле абый.— Син миңа бик кирәк идең, ведомостьны ябарга кушалар.

Ул мине җилтерәтеп үзенең кабинетына алып керде дә, кулыма бер кәгазь тоттырды: «Мә, касса ябылганчы алып кал!»

Касса якында гына. Берәү дә юк. Форточка кебек бер тәрәзәчеккә теге кәгазьне суздым. Иөнтәс кул аны тартып алды да кире ташлады.

— Синең өчен мин кул куйыйммы? Соңгы минутка кадәр йөриләр дә!

Кул куйдым да, кәгазьне тагын теге тәрәзәчеккә суздым. Инде китсәм дә ярый-дыр, дип кузгала гына башлаган идем, әчтәге адәм: «Әй, егет, мә!» — дип кычкырды.

Иртәне җиткерә алмыйча алҗып беттем. Төнозын керфек какмадым. Нинди йокы керсен — миндәр астында сиксән сум акча ята! Ышанасызмы? Төп-төгәл сиксән сум!! Подписка җыюым өчен мөкафәт.

Серне иң якын дус Мостафага ачтым. Башта ул да: «Ул хәтле үк булмас! Шартлатасың!» — дип, ышанмаган иде. Миндәр астыннан акчаны чыгаргач, исе китте.

Без, борынны югары чөеп, печән базарына йөгердек.

Бу мәшһүр базарга минем беренче килүем иде. Башта югалып калдым. Биек таш койма буенда зур-зур казаннар кайный. Ак алъяпкыч бәйләгән сакаллы абзый-лар, озын саплы чүмечләр белән шул казаннарны бутыйлар. Тозын татыйлар. Төтен. Бу. Каршыда өстәлләр, эскәмияләр. Безнең кебекләр ашыга-йотлыга нидер ашыйлар.

— Әйдәгез әле, тәти егетләр, үзегезне кызлар кочардай итеп, матурлап чыгарыйм, әйдүк,— дип, якындагы бер чаршау артыннан ак халатлы кеше чыкты да, безнең җиңнән үзенә таба тарта башлады. Көчкә котылдык.

— Әйдә, без дә бөкләп алыйк!— дип Мостафа мине казаннар кайнаган якка алып китте.

— Ярар, син заказ бир, мин өстәл тирәсеннән урын алам.

Ите аз булса да, шулпасы әреле, токмачы куе иде. Кәеф күтәрелде. Хуҗа белән исәп-хисап ясадык та кием-салым рәтенә киттек. Базарның уртасына үттек. Сатучылар монда да үз товарларын мактап, узып баручыларны үз якларына тарталар:

— Мә әле, агай, бу кама бүрекне киеп җиффәр әле, хатының, күрүгә, муеныңа сарылыр.

— Әй, егетләр, монда килегез! Менә диген диагональ чалбарлар. Кияү егетләре өчен, соңгылары! Кайсыгызга? Сезгәме? Менә бу соры төстәгесеме? Менә-менә сезгә бик килешә торганы күк төс икән! Бәясенең дә яртысын киметәм. Күреп торам — студент егетләр. Рәхәтен күрегез!

Акчасын биреп, бу мактаулы чалбарны алып алгарак кузгалдык. Күлмәк-ыштан, постау пинжәк, соры бобрик. Пальто. Шундый ук бобрик. Кепка һәм җылы эчле ботинкалар да алдык. Болай киенгәч, инде каникулда өйгә кайтырга да була, аллага шөкер, сынатырлык түгел...

Әре, салмак адымнар белән, ашыкмыйча гына Такташ чыкты, сәхнәнең уртасына килеп җиткәч, туктады. Башын капылт кына түбән иде, озын, саргылт чәчләр ишелеп төшеп, маңгаен капладылар. Уртача буй, авыл егетләренә хас нык коелган гәүдәгә аксыл-күк костюм-чалбар бик ятышлы. Ак күлмәк якасы һәм күгелҗем

галстук костюмны тагын да яктырта төшә.

Зал ду килеп кул чаба, ишетергә теләгән шигырьләрнең исемен кычкыра. Кинәт баш артка чөелде, чәчләр, чәчрәп таралып, икегә аерылдылар. Зур зәп-зәңгәр күзләр залга төбәлде — һәрбер тыңлаучыны бораулап үтте һәм тылсымлады. Шау-шу тынды.

— Берегезнең дә күңелен калдырмас өчен, бүген сез сораганнарны түгел, үзем уйлаганны, яңа шигырь укыйм.

Бу яңа шигырь соңыннан «Киләчәккә хатлар» дип аталачак мәшһүр поэмадан өзек иде. Без үз-үзебезне онытып, сихерләнеп шигырь тәэсиренә биреләдек.

Мин, шагыйрь үзе исән чакта да, ул безнең арадан киткәч тә, бик күп төрле артистлар башкаруында Такташ шигырьләрен тыңладым. Хөрмәтле нәфис сүз осталарыбызга һич тел-теш тидерәсем килми. Алар барысы да диярлек шигырьнең эчтәлегенә, ритмына, рухына кереп, һәрбер сүзен ачык, дөрес әйтеп, паузаларны, басымнарны саклап, матур сөйлиләр. Рәхмәт һәм ихтирам аларга! Әмма, миңа калса, аларның берсе дә шагыйрьнең үзе кебек, бик гади, шуның белән бергә беренче сүздән үк — аккордтан соң дияр идем — тыңлаучыны үзенә кочып ала торган тылсымга ия түгелләр. Нәрсәдә соң бу хикмәт? Бу турыда мин күп уйландым — нәрсәдә соң бу, могҗиза дип әйтерлек, самими тәэсир? Минемчә, шигырьнең эчке ялкыны, аның дөньяга туу процессы нәкъ менә шушы мизгелдә, тыңлаучылар алдында бара, илаһи чишмә булып ташый кебек. Тагын шуны да өстисе килә, шигырьдәге аерым сүзләрне мишәрчәләп әйтүе дә чыгышны көчәйтә иде, ахрысы.

Туфанның сәхнәгә чыгуын абайламый да калдык. Ул, ничектер җир астыннан чыккан кебек, сәхнә кырыендагы мөнбәр эченнән калкып чыкты. Шома итеп артка таралган, күпереп торган чәч. Киң маңгай. Аксыл, көнчыгыш халыкларына тартым җәенкерәк йөз. Соргылт костюм. Чигүле күлмәк. Аның күзләре төбәлеп-өтеп карамыйлар. Йомшак караш. Ул елмая. Ләкин аның елмаюы да, «менә мин кем» дигән чекерәйгән елмаю түгел, киресенчә, «гафу итегез инде», дигән сыман кыюсыз, мәрхәмәтле елмаю. Туфанның шигырь укуы да бик акрын башланды. Халык арасында сүзләр ишетелгәләсә дә, тавышын күтәрмәде, салмак, тыныч, баритон тавыш белән уйга, фәлсәфәгә, ерак галәмгә чакырды. Хәтерем ялгышмаса, ул бу юлы «Урал эскизлары» циклыннан күп кенә шигырьләр укыды.

Бервакыт сәхнәгә лап-лоп атлап, кирза итекләрдән, таушалган костюм кигән, әмма ак күлмәк, кара галстуктан, соры кепкадан озын, ябык, тузган кара чәчле берәү килеп чыкты. Һәм «һөҗүм»гә күчте.

— Бу кем?

— Кутуй! Кутуй!

Зал яңгырап, чайкалып киткәндәй булды. Ә тавыш һаман көчәйгәннән-көчәя бара. Шагыйрь авыр, салмак сүзләрне берсе артыннан берсен залга ташлый. Алгы рәттә утыручы кайберәүләр (шулар арасында мин үзем дә) утырган җирдән чайкалып киткәндәй була, башын яшереп, иелә төшә, сәхнәдән ташланган «ташлар» имгәтмәсен, дигәндәй. Миңа, кызганычка каршы, Маяковскийның шигырь укуын тыңларга туры килмәде. Әмма бу бәхеткә ирешкән кешеләрнең әйтүләренә караганда, безнең Кутуй да аннан калышасы булмаган.

Кутуй үзенең ул вакытта модалы булган футуристик шигырьләрен туптан аткан кебек атты-атты да, нәкъ килгәндәге кебек, лап-лоп атлап, чыгып та китте, алкышларның бетүен дә көтмәде.

Бу «кит»ларның чыгышыннан соң сәхнә бераз буш торды. Аннан кыюсыз гына атлап, озын, ябык, бик фәкыйрь киенгән, кара чәчле бер егет чыкты. Йөткерде. Борынын тарткалап алды.

— «Тегермән»,— диде.

Халык бераз тына башлагач, шигырен укырга кереште. Шигырь, инде канатлары әйләнүдән туктаган иске тегермән турында, моң, сагыш белән тулы. Бу шигырь миңа бик ошады, тик бу егетнең үзен танымыйм. Болай күренеп тора — студент. Мин уйланып торган арада теге егет шигырен укып бетереп төшеп тә киткән. Шундук сәхнәгә Такташ күтәрелде.

— Хатип Госман әйбәт шигырь язган. Ләкин бу шигырь миңа ошамый. Монда — тегермәненнән колак каккан кулак малаеның зары. Әгәр миндә бу тема булса, мин башкача язар идем, Хатип! Син туры әйткәнгә үпкәләмә, файдасы була. Ара-тирә минем дә борынны каната лар дус-ишләр!..

Бу очрашулар, шигырь кичәләре атна саен Татар мәдәният йорты бинасында уздырыла икән. Монда мине, каникулдан кайткач, Мостафа дус алып килде. Мәдәният йорты безнең техникумга бик якын икән. Болактан чыгып Проломныйга бар-

ганда, беренче кварталның аргы башындагы ярым түгәрәк балконлы матур гына бина. Залы да кечкенә (йөз кешелек чамасында), нәкъ шигърият өчен салынган кебек. Сәхнә белән зал бер-берсенә күзгә-күз карашып, фикер алыша ала.

Менә шунда йөри башладык. Мостафа үзе дә шигырьләр яза икән. Мин үземнең теге, Күкчәтаудан алып килгән шигырь белән шыгрым тулы калын дәфтәрне дә аңа биреп тордым укырга. Редакцияләргә үк алып барырга һаман әле батырлык җитенкерәми.

Алай да бу шигырь кичәләренә йөрү миңа бик файдалы булды — бердән, өр-яңа шигырьләр, бәхәсләр тыңлыйм, икенчедән, инде байтак шагыйрьләрне күреп беләм. Урамда күрсәм, таныйм. Ә менә Хатип Госман белән бик тиз танышып, дуслашып алдым. Мин аның шигырьләрен әле Күкчәтауда вакытта ук «Яшь ленинчы» газетасында укып бара идем. «Хатип Госман-Сулмашлы» дип имзалый иде ул аларны. Ошый иде аның шигырьләре миңа. Хәзер менә без дуслар. Безнең болай бик тиз арада бер-беребезгә ияләшүдә шигърияттән башка да бер сәбәп бар иде. Уртак диярлек язмыш, кагылу-сугылу, фәкыйрьлек, уку йортына керә алмыйча, тилмереп йөрү. Хатип Казанга килүгә Татрабфакка укырга кергән булган, ләкин озак укый алмаган. Кемдер, ул — мулла баласы, дип, өстеннән шикаять язган. Аны рабфактан куып чыгарганнар. Башка уку йортларына да керер әмәл юк. Теләсәң нишлә.

Теге кичәдән соң бергә кайттык. Ул Болак буендагы бер өйнең подвалында тора икән. Укудан соң мин аның янына кереп утыра башладым. Ул — миннән бер-ике яшькә олы, бик кабилиятле, акыллы, басынкы, һәр адымын уйлап баса торган, өметле егет. Ул мондагы күп язучылар, шагыйрьләр белән аралашып өлгергән, мине дә алар белән таныштырырга булды.

(Алга китеп әйтим: 1935 елның көзендә без икебез дә Казан педагогия институтының татар теле-әдәбияты факультетына укырга кердек һәм тулай торакта икәү генә бер бүлмәдә тордык.)

Безнең техникумның уку-хезмәт хуҗалыгы да бар. Ул Казаннан ерак та түгел, күңелгә бик хуш килә торган җирдә — Зәңгәр күл буенда урнашкан. Элек бу Апанаевларның утары булган, диләр. Бик мөмкин. Монда күп кенә торак биналар, хуҗалык корылмалары, хәтта су тегермәне дә бар. Дача биналары зур, ике катлы, агачтан бурап салынган, такта белән тышланган һәм сарыга буялган. Күл ярында төп бина. Ике катлы, асты таш, өсте агач. Аскы катта зур зал (хәзер безнең клуб), икенче башында — бүлмәләр, подвалда — аш-су хәзерли торган урын. Ашау-эчү шул подвал кырында өстә, түбәсе ябылган ачык верандада. Шунда җыелабыз, ашыйэчәбез, киңәшәбез. Өске катта пароходтагы кебек, ап-ак веранда.

Зәңгәр күлгә кечерәк кенә бер елга агып керә дә Казан ягына таба агып чыга. Елганың агып чыга торган төшендә — буа. Буа өстендә — тегермән. Ул әле безнең чорда да техникум ихтыяҗын тәэмин итәрлек он тарта иде.

Бу хуҗалыкта иртә яздан көзгә хәтле студентлар хезмәт практикасы үтәләр. Бездәге студентларның барысы да диярлек үзен-үзе белә башлаганнан ук җирне тырнап, чәчеп-урып үскән, эшчән егет-кызлар. Шуның өчен монда килү — бәйрәм.

Утарда эшләү чират белән, курслап оештырыла, берәр айлап. Без, I курс студентлары, еллык имтиханнарны тапшырып, алдагы курска күчү сөенечендә ирешү белән, Зәңгәр күлгә ашкындык һәм алданмадык. Ул бөтен яктан безгә хуш килде. Минем дус Мостафа Ногман, монда килүгә, «Зәңгәр күл» исемле бик матур шигырь язды. Ул шундук «Яшь ленинчы» газетасында басылып чыкты.

Бу хуҗалыкта бодай, арпа, солы, төрле ярма культуралары чәчәләр, күп итеп бәрәңге һәм яшелчәләр утырталар. Барысы да студент казанына бара — арзан, кыш буена җитәрлек. Егетләр хуҗалыктагы атларга печән дә чабалар. Кыскасы, эш җитәрлек!

Бәрәңге бригадасында мин — бригадир. Иртә белән 7 дә чаң тавышына сикереп торабыз да физик күнегүләр ясау мәйданына чыгабыз. Аннан — юыну. Зәңгәр күлдә коенып булмый, суы бик салкын. Бригадалап иртәнге ашка җыелабыз.

Тагын чаң сугалар: даң-доң!

Хуҗалыкның директоры килә — һәр бригадага эш бүлеп бирә. Складтан эш кораллары алабыз да, бригадалап тезелешеп, җырлап эшкә китәбез. Минем бурыч — кирәк, чиләк кебек кирәк-яракны складтан алу һәм соңыннан тулысынча тапшыру. Петр дәдәйдән ат алып, арбага үлчәп, чәчүлек бәрәңге алу. Утыртуның сыйфатын тикшерү, булышу, су китерү һәм башка мохтаҗлыкларны ат белән башкару. Кичен, кырны үлчәп, эшне директорга тапшыру — нарядны язу.

Бәрәңге кырыбыз — Зәңгәр күлнең аргы башында, кара туфраклы, бик уңышлы җирдә. Аралар 2—3 чакрым булыр. Ат көр, җилдерә генә. Әле колыны да бар. Нәкъ әнисе төсле җирән, кояшта ялт-йолт итеп, ялкынланып тора. Бик шаян, ара-тирә, йөгереп килеп, мине тешләмәкче дә була, күрәсең, әнисен кызгана.

— Мал янында үскән малай күренәсең,— дип, Петр дәдәй мактап куя — түбәм күккә тия.

Берсендә шулай барабыз, җырлагандай итәм үземчә. Кешe алдында җырларга оялам, барып чыкмас.

— Егет, синең тавышың юк,— дип Солтан абый Габәши, мине беренче тыңлаганнан соң ук, хордан чыгарга кушкан иде. Аннан жәлләде, ахры, яныма килеп,— үзең генә калганда кычкырып җырла. Һәр нәрсәгә күнегү кирәк,— дип юатты.

— Абый, тукта әле!

Карасам, юл читендә, чирәмдә бер кыз утыра. Уң аягын яулык белән бәйләгән.

Бу кыз безнең группадан түгел, мәктәпкәчә тәрбия бүлегеннән. Исемен дә белмим.

— Килгәндә ялгыш пыяла кыйпылчыгына бастым, кан күп акты.

— Ярар, мена бәрәңге алып барам да, кире кайтканда, утыртып алып кайтырмын, елама!

Юыртып киттем, кыз, башын иеп, утырып калды. Бик тиз урап килдем, бәрәңгене дәррәү бушаттык, алып та киттеләр, утырта да башладылар. Планны тутырырга кирәк.

— Әйдә, утыр!— Кызым йөзен чыта-чыта торды да бер атлауга авып китте.

Сикереп төшеп, күтәреп арбага утырттым. Чибәр кыз күренә. Түгәрәк йөзле, яшькелт күзле. Толымы биленә хәтле төшкән. Бит алмалары, иреннәре янып тора.

— Исемең ничек?

— Гайшә.

— Гайшә?!— Нигәдер гаҗәпләнеп борылып карадым.— На-на, кашкабай!— Үзем уйга калдым. Кара әле, минем Күкчәтауда яратып йөргән кызымның исеме дә Гайшә иде бит...

* * *

Мин инде хәзер — педтехникумның II курс студенты. Безне монастырьдагы тулай торакка күчерделәр. Монастырь биек, таш койма белән уратып алынган мөстәкыйль бер шәһәрчек — өчәр, дүртәр катлы зур-зур биналар. Малайлар — бер корпуска, кызлар икенчесенә урнашкан. Ара-тирә бер-беребезгә кунакка да йөрешәбез — авылдан күчтәнәчләр килгәндә, посылкалар алганда. Ул заманда безнең кызлар егетләрне шефка алалар, киемнәрен юалар, ямыйлар, төймә-сәдәфләрен тагалар иде. Гомумән, шефка алган кыз «үз» егетенең бөтен, чиста йөрүенә җаваплы. Бу гадәтнең башы гомуми җыелышка бәйле. Курсның старостасы егетләрнең исем-фамилияләрен аерым кәгазьләргә яза да, бөтереп, бүреккә сала. Исемлек буенча кызлар өстәл янына чыгып, бүректән бер төргәкне алып старостага бирә. Староста кәгазьдәге исемне кычкырып укый.

Шул мизгелдән бу егет әлеге кызның «тәрбиясе»нә күчә. Бу хәл беркетмәгә языла. Атна саен санинструктор студентларның чисталыгын тикшерә. Кием-салымы юылганмы, ямалганмы, мунчада булганмы, тырнаклары кисканме? Әгәр егеттә бер дефект табылса, җавапны шеф кыз бирә.

Язмышның шаяруы-көлүе диимме, шобага салганда, минем шеф булып, теге Гайшә килеп чыкты. Икебез дә шаккаттык.

Ниһаять, минем эшләр җайланды, ахрысы. Хәзер инде каләмне очлап, илһамны туплап, шигърият-әдәбият белән шөгыльләнергә вакыттыр, дип дәртләнеп шигъри кичәләргә йөри башлаганда гына тагын — киртә!

Әле былтыр мине үзебезнең курс комсомол ячейкасының секретаре итеп сайлаганнар иде. Өстәвенә, профкомга чакыртып, шул ук курстагы БНҖ (Бетсен наданлык җәмгыяте) рәисе итеп билгеләделәр. Атнасына ике кич үзебезгә беркетелгән Пләтән кварталындагы хәреф танымаучыларны укырга, язарга өйрәтергә тиешбез. Бу такъдимгә бик тиз генә риза булуымның бер «сер»е дә бар иде. Белеп алдым: теге, «аксак» кыз да нәкъ шул квартал тирәсендә «укыта» икән. Шулай итеп, дәресләрдән соң, ашык-пошык кына ашыйбыз да, парлап (техникум халкы күздән югалгач, култыклашып), наданлык белән көрәшергә китәбез. Уку-язуны тәгаллләгәч (анда инде соң була) мин аны үзебезнең чат башында көтеп алам. Гайшә күп сөйләми, нигездә, ул «мәшәкатьне» үзем башкарам, туктаусыз аны-моны сөйлим, сүз бетсә, шигырьләр укыйм. Кайвакытта үземнекеләрне дә, тик авторын әйтмим, оялам. Бу кыз миңа көннән-көн ошый бара. Ярата башладым, ахрысы, үзен, күренмәсә — әлим. Яман сулыйм, сагынам, хәтта көнләшә дә башлыйм.

Бәй, мин киртә турында әйтмәкче идем бит. Нинди киртә ул тагын?— диярсең. Минем шигырь язасым килә, ә монда — техникум комсомолларыхөрмәтле укучым. Минем шигырь язасым килә, ә монда — техникум комсомоллары-

ның отчет-сайлау конференциясе. Бездә бит меңнән артык комсомол. Шул конференциядә мине комсомол комитетының секретаре итеп сайладылар да куйдылар. Әй китте тәгәрмәч тәгәрәп — мине әле райкомга, әле комсомол өлкә комитетына чакырып «парлыйлар». Монда директор, деканнар кыздыра: бу комсомолец начар укый, тегә комсомолец җәмәгать эшеннән баш тарта, фәлән дә төгән. Чыдап кына тор, кайда монда шигырь язу?!

Һай, ничек тиз йөгерә бу еллар! Мин — техникумның III курс студенты. Киләсе елга — дипломлы укытучы! Комсомол эшенә дә иярләштем. Болар өстенә бер маҗараны әйтеп, мактанып та алыйм әле. Минем бер шигырь газетада басылып чыкты, әмма...

Шулай бер көнне комсомол комитеты бүлмәсендә газеталар актарып утырганда, күзем «Яшь ленинчы»га төште. Алып карасам, өченче биттә... аптырап киттем — минем шигырь, Күкчәтау турында. Укып, ахырына җитсәм, имза — Мозаффаров. Мә сиңа, кирәк булса! Кем ул Мозаффаров? Мин бит теге коленкор тышлы дәфтәрне Мостафа Ногманга биргән идем. Киттем аны эзләп. Газетаны күрсәттем. Ул да башта шаккатты, аннан кычкырып җибәрде.

— Вәт карак! Мин синең шигырь дәфтәреңне, бик сорагач, II курстагы авылдаш Мозаффаровка биреп торган идем.

— Әйдә, киттек! Таптык. Газетаны күрсәттек — ә ул йөзен дә чытмады:

— Исегез киткән икән! Гонорары килгәч, Печән базарына барып, туйганчы токмач ашарбыз. Әле рәхмәт әйтерсез,— диде.

Шуның белән бу мәсьәлә хәл ителде.

Инде үземә дә шигырьләремне редакцияләргә тәкъдим итәргә вакыт җиткәндер, дип, коленкор тышлы дәфтәрне тагын кулга алдым. Ләкин әле дә теләкне тормышка ашырырга насыйп түгел икән.

Беркөнне комсомол кәгазьләрен актарып утырганда, директор шалтыратты:

— Ибраһим, тиз генә миңа кер әле,— ди.

Йөгердем. Кабинетта студентлар тулган. Алай да, директор минем кергәнне шәйләп алды да, ым белән «якынрак кил» диде. Килдем.

— Әле генә комсомолның өлкә комитеты секретаре Галим Мөхәммәтҗанов шалтыратты, сине чакырды,— ди.

Татарстан комсомол өлкә комитетының беренче секретаре Галим Мөхәммәтҗанов кабинетына килеп кергәндә, анда халык тулган иде. Барысы да егетләр. Бераздан кулына папка тотып, ашыгып атлап, Галим үзе дә килеп керде. Урта буйлы, тыгыз бәдәнле егет. Йөзе җәенке, күзләр кысынкы. Шома итеп артка таралган соргылт чәчләр. Өстендә өр-яңа яшел френч. Шундый ук диагональдән тегелгән ярым галифе һәм табәнәк үкчәле сафьян итекләр. Өстәлгә ашыгып узышында ук барчабызга да җентекләп карап үтте.

— Исәнмесез, егетләр!— дип, папкасын өстәлгә куйды, урындыкка утырып тормады, өстәл кырыена басты. Сүзен башлап җибәрде.— Үзегез беләнчә, илдә зур борылыш бара,— ул крестьяннарны күмәк хуҗалыкка — колхозга тарту. Беләсезме, сезне нигә чакырдык?

Тынлык. Аптыраш.

— Без сезнең барыгызны да авылларга җибәрергә уйлыйбыз. Сез — комсомолның каймагы, урыннарда аны җитәкләп баручылар. Без сезгә ышанабыз. Бу — партия, иптәш Сталин кушкан бурыч!

Икенче бүлмәдә безгә мандатлар, юллык акча һәм пароходка билетлар да бирделәр. Юл газабы, гүр газабы артта калды.

Кичкә таба район үзәге Акташка килеп җитеп, мәгариф бүлегенә кердек һәм моннан инде иң соңгы фәрманны алдык. Мин Илтән-Бута дигән керәшен авыл мәктәбенә билгеләнәм. Бәхеткә, нәкъ шул авыл аркылы узучы юлаучы да туры килде.

Көч-хәл белән мәктәпне эзләп таптым. Ул тузып, череп бер ягына кыйшайган, агач чиркәү янында икән — зур гына агач өй, калай түбәле (мөгаен, поп өе). Ишек бикләнмәгән. Ачып кердем. Алда — кечерәк бүлмә. Аннан — зуррагы. Ары — өлкән бүлмә. Мәктәп ягылмаган. Суык. Дым.

— Әбәү, сез әллә безнең учительме?

Сискәнеп борылдым. Өстенә озын соргылт чикмән кигән, шундый ук калын шәлгә төренгән хатын тора.

— Әйдә, улым, миңа гына барып җылын! Иртәнчәк начальник кайда торырга икәнен әйтер.

Начальник — авыл советы председателе Марфа исемле апа икән. Миңа бик ошады. Әмма мәктәпкә бу көнгә хәтле утын китертелмәгән. Бернечә тәрәзәнең күзләре ватылган. Мич тә кыршылып беткән.

Икенче көнне үк эшкә тотындык. Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, дип тикмәгә генә әйтмәгәннәр, күрәсең: тырышкач, мәктәп җанланды да китте. Җылынды. Яктырды. Көндез — балалар, кичләрен яшьләр шау-гөр килә башлады.

Мәктәп яшендә саналган 43 баланы яздым, 12 сенең мәктәпкә барырлык өс башы, аяк киемнәре юк. Мәгариф бүлегеннән ярдәм сорарга кирәктер. Кечке укуда — 26 яшь-җилкәнчәк, күбрәге кызлар.

Укыйбыз. I сыйныфта 17 бала. Алар залның алдынгы ягында утыра. II сыйныфта 11 бала, алар — кечкенәләр артында. III сыйныф —9 бала, икенче кырый як тәрәзәләргә каршы утыралар, IV сыйныф —6 бала. Мич артындагы кече бүлмәдә урнаштылар.

Дәрес бирү тәртибен болай оештырдым: беренче сыйныф балаларына кара тактада язу-сызу күнегүләрен алып барганда, икенче сыйныфтагылар үзлекләреннән китап укый, өченче сыйныфтагылар исәп-хисап мәсьәләләрен чишә, дүртенче сыйныфтагылар җир шары картасын өйрәнә. Билгеле инде, дәресләр барысы да мәгариф бүлегеннән бирелгән төп программа нигезендә алып барыла. Карандаш, дәфтәр, дәреслекләр, уку-укыту әсбапларын районнан алдык.

Тагын бер сөенеч — мәктәпкә йөрергә киемнәре булмаган үтә ярлы гаилә балаларына, минем язма үтенечем буенча, районнан киез итекләр, сырган фуфайкалар, бүрекләр җибәрделәр. Барлыгы 12 комплект. Авылда мәктәпнең дәрәҗәсе күтәрелде. Урамда барганда мине күргән һәр агай, туктап, бүреген салып, башын ия: «Рәхмәт, учитель, балаларны сөендердең, школабыз яктырып китте»,— диләр.

Кичке укуга килүчеләр саны мин көткәннән артык булып чыкты. Соңыннан гына төшендем — яшьләр монда бер-берсе белән очрашу өчен дә киләләр икән. Бу авылда башка кайда барсыннар соң дәртле яшь-җилкәнчекләр, бигрәк тә кышын.

...Болытлы төн кичә кар төшергән,
Ә бүген юл елтыр-тасмалы,
Юл буенда үскән өрәңгеләр
Бәс уракып игән башларын.

Йокыдан уянып, тәрәзәдән карауга — исем китте. Бөтен дөнья ап-ак. Беренче кар! Әле кичә генә сөремләнеп, йөзләрен чытып утырган салам түбәле өйләр яктырып киткән — күпереп торган ап-ак шәл ябынганнар. Бүген якшәмбе, ял көне. Тагын бераз урынымда ауныйм әле. Кая ашыгырга?! Гомумән, хәзер минем эшләр җайга салынды бит.

Беренчедән, менә бу пөхтә бүлмә. Туган әнием кебек рәхимле Натук (Наталия) апа. Ул ялгыз. Ире, балта остасы Харитон, моннан ун еллар элек Себер ягына эш эзләп киткән дә югалган. Ике кыз буй җиткән. Олысы Настя, Бута егетенә кияүгә чыккан да Бөгелмәгә күчеп киткәннәр. Кече кызы Ольга белән «танышу» бик кызык булды. Беркөнне апага Казаннан хат килде. Хат эчендә фото да бар икән. Апа: «Кара, минем нинди чибәр кызым бар!» — дип, миңа сузды.

Фотога каравым булды, шаккаттым: апаның Ольгасы янында — минем Гайшә!

— Апа, кайда укый соң Ольга?

— Кайда булсын, Казан педтехникумында. Әллә тегесен таныйсыңмы? — Сынап карады апа миңа.— Бик кадалып карадың лабаса!..

Икенчедән, мәктәптәге эшләрем дә ярыйсы бара, әле күптән түгел генә район мәгариф бүлегеннән инспектор килгән иде. Дәресләрдә утырды, укучыларны сорашт ырды: дәфтәрләрне дә тикшерде, укытып та карады. Ахырдан:

— Әйбәт, шулай алып бар!— диде...

— Улым,— уйларымны бүлеп, Натук апа ишекне кысып кына ачты.— Улым, тор инде! Белен пешердем, кайнар чагында ашыйк! Аннан мин школга китәм.

Кайнар беленне, киндер маена манып-манып, «бөкләп», сөтле чәй эчкәч, минем кәеф тагын да күтәрелә төште.

Апа өстәлне тиз-тиз җыештырды да мәктәпкә мич ягарга, идән юарга китте. Мин, киенеп, урамга чыктым — беренче карны шыгырдатып (суыткан) арлы-бирле йөрдем дә кызарып-дәртләнеп өйгә кердем.

Беренче кар турында шигырь дә язып ташладым (югарыдагы дүртьюллык шул шигырьдән өзек). Аннан Казанга хатлар яздым. Берсе — редакциягә (ул вакытта Казанда авыл хуҗалыгы журналы чыга иде). Мин җибәргән бу шигырьне алар басып чыгардылар. Икенче хат — Гайшәгә...

Беркөнне иртә белән мин әле укучыларыма яңа гына дәрес бирә башлаганда, Марфа апа килеп керде:

— Учитель, икебезне дә райкомга чакыралар. Бик ашыгыч дигәннәр, әйдә!— ди.

Без барып кергәндә, район клубының залы халык белән шыгрым тулы иде. Сәхнәдә — кызыл комач ябылган өстәл. Графин белән су. Өстәл кырыендагы берәү, бер алга атлап, бер артка чигенеп, уң кулын туктаусыз күтәреп-төшереп кычкыра — әйтерсең ул үзенең сүзләрен залда утыручыларның миләренә кадак каккан кебек сугып-сугып иңдерергә тели. Сәхнәдән сөйләүчене таныдым: ВКП(б)ның Акташ райкомы беренче секретаре Афанасьев иде. Озын. Чандыр. Эре сөякле. Йөзе аксыл, күзләр кызарган — әллә авырган, әллә артык арыган. Тамак карлыккан. Тавыш бик авырлык белән генә чыга, ләкин гайрәт җитәрлек сизелә. Һәр сүзен кисеп сала. Караса, өтеп карый.

— Иптәш Сталин һәм большевиклар партиясе бүген крестьян алдында бары бер генә сорау куя: син кем белән? Я ул, колхозга кереп, Совет партия платформасын яклый, я кулаклар белән калып, безнең дошманга әверелә. Бүген авылда иң зур сыйнфый дошман — кулак. Без аны төбе-тамыры белән йолкып алып ташларга тиешбез. Дошман бирелмәсә, аны юк итәләр, ди бөек юлбашчыбыз даһи Сталин... Колхоз! Колхоз!— менә нәрсә сорала бездән. Хәзер үк авылларыгызга кайтып, бу наказны үтәргә керешегез! Барыгыз да райкомның оештыру бүлегенә кереп мандатлар алыгыз. Бүгеннән башлап сез — Акташ райкомының колхоз оештыру буенча тулы хокуклы вәкиле!

Әй, игенче, илең җавап көтә:
— Син кем белән бүген барасың?
Йә, колхозга кереп — Совет яклы,
Йә дошманнар белән каласың?!

Син кем белән? Бу сорау хәзер һәр көн һәр газета, һәр журнал битеннән игенчегә төбәлә.

Районнан кайтуның икенче көнендә үк җыелыш җыярга ашыктык. Кич булды. Мин алып кайткан ике асылмалы лампаны, куыкларын чистартып, туп-туры итеп керосин салып, зал түшәменең ике төшенә асып куйдык. Мәктәп көтә! Марфа апа иртәрәк килде. Нәрсә сөйләячәгебезне килештек. Билгеле инде: райком секретаре әйткәннәрне кабатлыйбыз. «Кунакларны» сабыр гына көттек. Бер сәгать, ике сәгать, өч сәгать. Берәү дә күренми. Хәтта егетләр-кызлар да юк, аларга үзебез килмәскә куштык бит.

Икенче көнне иртәдән үк дежурлар өйдән-өйгә кереп, кичен җыелышка килергә кирәклеген тагын искәртеп, кем дә кем килми калса, штраф салына, дип кисәтеп йөрделәр.

Бу юлы килә башладылар. Берәмләп. Картлар. Ишектән керүгә, бүрекләрен салып, иелеп сәлам бирәләр. Утыралар. Тып-тын. Беркем бер сүз кузгатмый. Утызлап карт-коры килгәч, сәгать уннарда башладык. Җыелышны алып бару өчен, рәис итеп, Кара Данилны, сәркатип итеп мине сайладылар.

Беренче сүз авыл советы председателе (авылдагы бердәнбер партия әгъзасы) Марфа апага бирелде.

— Инде, авылдашлар, безгә дә Илтән-Бутада колхоз оештырырга вакыт,— дип башлады ул сүзен. Һәм өченче көн районда райком секретаре Афанасьевның ни сөйләгәнен бәйнә-бәйнә кабатлады. Үзегез ничек уйлыйсыз, әйтегез,— дип, сүзен түгәрәкләде.

Кемдер шырпы сызды, махра кабызды. Күрәм: тәмәке янчыгы кулдан-кулга китте. Ачы «самосад» исе борынны яра. Түзмәдем:

— Иптәшләр! (Кәрәк сакаллы бабайларга.) Бу бит — мәктәп. Иртәгә сезнең үк балаларыгыз монда укырга килә. Җәлләгез аларны. Тәмәке тартуны хәзер үк туктатыгыз!

— Бик дөрес әйтә учитель,— дип кемдер иң арткы урындыктан мине сөендерде дә, өстәп куйды:— Алайса, безгә өйләребезгә кайтып суырырга кирәк. Ул арада кузгала да башладылар. Марфа апа сикереп торды:

— Юк, юк, кузгалмагыз! Колхоз мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Сүз учительгә бирелә.

Мин, торып, аларны колхозга керергә чакырдым. Хәтердә: миннән соң бу турыда сөйләргә атылып торучы күренмәде.

— Булмаса, өйгә кайтып, җәмәгать белән акыллашырга кирәк,— диде алгы рәттәге бер карт. Калганнар да:

— Әйе, әйе,— диештеләр.

Халык, дәррәү кузгалып, чыгып та китте.

Ә райком һәркөнне сводка көтә:

— Авылдан ничә хуҗалык колхозга язылды?

Бездә берәү дә юк. Марфа апа белән аптырашта калдык. Мин «Син кем белән?»

исемле шигырь дә яздым. Совет власте өчен сугышып, бер кулсыз калган партизанның хәзер, колхозга кермичә, ялгызак булып калуы турында. Шигырь авыл хуҗалыгы журналында шул ук елда басылды.

Ярар, шигърияттән прозага, авылга кайтыйк. Җыелышлар уздырабыз. Ә колхоз юк та юк. Нигә икән? Хәер, без әле үзебез дә (мөгаен, Марфа апа да) колхозның ни икәнен белеп бетермибез. Әйтик, иртәгә колхоз оештырдык — мал-туарны берләштердек, ди. Яхшы. Ә ул мал-туарны, эш кирәк-ярагын кая куябыз? Кайда андый абзарлар, амбарлар?..

Ниһаять, Илтән-Бута да уянды, әйтерсең, ике анага бүленергә җыенган умарта! Урам тулган ир-ат. Авылның әле бер очында, әле икенче очында, яки авыл советы алдында — төркем-төркем халык. Сөйләшәләр, киңәшәләр. Авыл икегә ярылгандай булды: бер якта — Кара Данил белән ярлы-ябага, икенче якта — өч туган бай Шубиннар һәм аларның иярченнәре.

Районның башка авылларында да шундый хәл икән. Марфа апа Өлкән Бута базарында күргән бер вакыйга турында сөйләде:

— Бер крестьян аркасына ярты капчык тары күтәргән дә, базар халкыннан: «Колхоз тары алырмы икән?» — дип сораган. Аннары сүзен-сүзгә бәреп, тезәргә тотынган: «Колхоз таралырмикән? Колхоз таралырмикән?..»

Кыскасы, авыл бик буталды. Туктаусыз җыелышлар уздырып торудан мәктәпнең дә, укуларның да рәте китте. Натук апа җыеп-юып өлгерә алмый. Стеналар тәмәке төтене белән ысланды. Мин шәкертләремнең дәфтәрләрен тикшереп өлгерә алмыйм, җыелышлар бик соң тарала.

Ул көнне дә шәкертләремә дәрес-тапшырмаларны биреп, бер кочак дәфтәрне күтәреп, үз бүлмәмә кереп бара идем. Ишек ачылды да, аңа көчкә сыеп кар сарган толып керде. Мин тизрәк барып ишекне яптым — укучыларга суык бит. Керүче чайкалып селкенде. Идәнгә бер өем кар коелды.

— Толыбыгызны ишек алдында кагып керергә иде,— дим.

— Син кем? Учительме?

— Әйе, учитель.

— Алайса, киен, киттек!— Толыпның якасы каерылды: шинель, кызыл петлица.

Авыл советы ишеген ачып керү белән теге хәрби (ул район ГПУ бүлеге начальнигы икән), урындыгыннан торып, өстәл янына чыккан Марфа апага бер кәгазь сузды. Апа аптырап карады.

— Укы! Менә шушы гражданнарның өенә алып бар! Йолкып алып ташлыйбыз.— Марфа апа нигәдер тетрәнеп, агарынып китте.

— Беренчеләп Шубиннарга бардык. Башлап Иван өенә кердек. Өйдә — ике кыз гына. Берсе идән себерә, берсе сәке кырыена утырып табакка бәрәңге әрчи.

— Ата-анагыз кайда?— диде начальник ачулы тавыш белән.

— Сезгә кем кирәк?

— Иван Шубин!

— Ул Бөгелмә базарына китте.

— Кайчан?

— Кичә.

— Сволочь!— Иван Иванович эшәке сүгенде.— Качып өлгергән! Барыбер тотабыз! Әйдәгез, абзарларны карыйбыз!

Мин конфискация актына: «Иван Шубин. Бер колынлы бия, ике үгез, бер сыер, бер тана, өч дуңгыз», дип яздым.

Аннан каршыдагы Петр өенә кердек. Энесе Трофим да анда икән — чәй эчеп утыралар. Өстәл тирәсендә бер көтү бала-чага. Хатыны чәй ясый. Без килеп керүгә, барысы да сикерешеп тордылар.

— Максим!— Начальник милиционерга боерды:— Хәзер үк икесен дә каталажкага!— Максим, алдан! Шубиннар, аның артыннан — марш!

Минем өчен иң фаҗигалесе соңгы өйгә керү булды. Бу шау-шулар, елау-сыктаулар, каргыш һәм нәләтләр белән буталып, көннең кичкә авышуын да сизми калганмын. Без Бабаевларга барып кергәндә, иң әйбәт укучым, ярдәмчем Әндрәй ишек төбендә нәрсәдер эшләп маташа иде. Капка ачылуга ул, борылып:

— Учитель абый, мине эзләп килдегезме?— диде.

Телсез калдым. Сабыйны ничек алдыйм?! Ул арада каршыдагы абзардан иске бишмәт өстенә киндер алъяпкыч япкан, шәльяулыгын маңгаеннан кысып артка бәйләгән кечкенә генә бер хатын чиләк күтәреп чыкты да, безне күргәч, аптырап туктады. Аннан, икеләнеп, тагын бер-ике адым безгә таба атлады.

— Василий кайда?

— Казанда.

— Акча кериме?

Хатынның гәүдәсе чайкалып китте.

— Казан сезгә якынрак. Сез дә кирәгез.— Ул тамагын кырып, тагын да нидер әйтергә җыенган иде, хәрби киемдәге кешенең абзарга таба атлавын күргәч, гасаби бер тавыш белән акырып җибәрде, әйтерсең йөрәген суырып алдылар.

— Бандитлар!

Чиләк тәгәрәп китте. Әле яңа гына сауган, бу күтәрелеп торган җылы сөт кар өстенә акты. Хатын ава башлады.

— Әнкәй! — Әндрәй, йөгереп килеп, анасын кочаклады.— Елама! Елама, эн-кәй!..

— Әй, учитель! — Начальник кычкыра икән.— Нәрсә катып торасың, ал папкаңны! Яз! Бер колынлы...

Төне буе керфек какмадым. Натук апа да сөйләшми. Иртән мәктәпкә йөгердем. Укучыларым килә башлады. Аларның күзләренә карарга куркам. Гүя аларның һәрберсе миңа: «Син — учитель түгел, бандит! Бандит!» — дип әйтер кебек. Көттем, куркып, сагынып көттем. Юк, килмәде Әндрәй, килмәде. Бөтенләй ташлады ул мәктәпне.

Дүртенче сыйныф укучыларына географиядән дәрес бирим, дип, бүлмәмнән, глобус күтәреп чыгып килә идем, тышкы ишек бусагасында — Натук апа. Күзләре акайган.

— Марфаны... үтергәннәр. Катып калдым. Аннан бөтен тирә-як зырылдый кебек. Әллә глобус әйләнә, әллә мин үзем...

Мин авыл Советына барып кергәндә, Марфа апаның гәүдәсен үзенең язу өстәленә сузып салганнар, битенә ак дебет шәлен япканнар иде. Мәет янына дежур да куйганнар. Данил дәдәй кара кайгыга баткан халыкка аңлатып бирде:

— Бутадан чыккач, эрәмәлек арасындагы бер чокырга ташлаганнар. Пычак нәкъ йөрәгенә кадалган. Ат-чанасын таба алмадык. Шуңа утырып качкан, сволочь. Буран иде. Эз дә күмелгән...

Марфа апаны җирләгәннең икенче көнендә мин Акташка язу-сызу әсбаплары алырга барган идем, очраклы рәвештә, бергә техникумда укый торган керәшен егетен очраттым. Ул Гөлбакча дигән хуторда укыта икән. Үзе — Илтән-Бута егете.

— Николай, әйдә, син үз өеңә кайтып эшлә, мин синең хуторга барыйм,— дидем.

— Бик риза. Тик мондагы начальниклар карышмаслармы?..

Шундук, мәгариф бүлеге башлыгына кереп, хәлне сөйләп бирдек.

Иртәгесе көнне Николай Илтән-Бутага килеп тә җитте. Мин исә, шул ук ат-чанага утырып, Гөлбакчага юнәлдем...

* * *

Моннан егерме еллар элек Илтән-Бута укучыларына хат язып, үземнең берике китабымны салып җибәргән идем — җавап булмады. Хәзер Акташ исемле район да юк, аны Әлмәткә кушканнар. Кем белә, бәлки, Илтән-Бута таралгандыр да. Язмыш, кешеләрне генә түгел, авылларны да талкый бит! Кызганыч. Салам түбәле ул авылны кабат күрер өчен әллә ниләр бирер идем...

Өстәмә. Югарыда язылган вакыйгалардан соң 5—6 ел үткәч, 1936 елның көзендә, пединститутта укып йөргәндә, урамда каршыма бер егет килеп чыкты.

— Абый, сез учитель Ибраһим Салахов түгелме? — ди.

— Әйе, Салахов, үзең кем буласың соң, энем?

— Әй, абый,— ул мине кочып алды.— Мин бит — Тимка.

— Тимофей! — Инде мин кочтым.— Я сөйлә. Әтиең Данилмы әле, исәнме?

— Әти исән. Теге вакытта бераз колхозда председатель булып эшләде дә, грамотасы җитмәгәч, ташлады. Мин монда рабфакны тәмамлагач, авыл хуҗалыгы институтының хәзерлек курсына кердем. Укып йөрим.

— Молодец. Молодец, яхшы иткәнсең.— Кылт итеп исемә Әндрәй төште.— Кара әле, Тимофей, теге Бабаев Андрейның язмышы ничегрәк булды икән? Белмисеңме?

— Ишетмәдегезмени, абый? — Аның тавышы калтырады.— Ул бит асылынып үлде... Үзегез беләсез, атасын, кулак дип, каядыр алып киттеләр. Кайтмады. Андрейны мәктәптән куып чыгардылар. Ул башта колхозда бераз эшләп йөрде. Беркөнне үзләренең мунчасына кергән дә...

Бу фаҗигада мин үземне дә гаепле саныйм. Әндрәйнең ачу һәм нәфрәт тулы карашы әле дә мине эзәрлекли...

*1987 ел.*

# Айрат Садыйк

# ШАХМАТ АЛИҺӘСЕ



Алисә белән тәүге очрашуны яхшы хәтерлим. 1986 елның язында булган иде ул. Әле яңарак кына хатын-кызлар арасында Татарстан чемпионы исемен яулаган Алисә Галләмова журналистлар янына кунакка килде. Очрашу аның берьюлы 10 тактада уйнавы белән тәмамланды. Аңа каршы якка шахматта азмы-күпме фикер йөрткән журналистлар утырган булса да, җиңү шатлыгын беребез дә татый алмады. Арабыздан берәү хәтта үз тактасында Алисәнең бер фигурасын «урлап» та караган иде... Кыз аның каршына килеп басты, ирексездән дигәндәй «урланган» фигурасы торган шакмакка үрелде һәм шундук кулын кире тартып алды да, берни булмагандай, башка фигура белән йөреш ясады. Менә шушы мизгелдә үзенең тыныч калуы, каушау-дулкынлануын сиздермәве белән җәлеп иткән иде ул безне — кызлар арасында өч тапкыр дөнья чемпионы, халыкара гроссмейстер Алисә Галләмова.

Шахмат тәхетенә Казан кызы ничек менде соң?

Казанның Идел буе районындагы «Прометей» клубына беренче тапкыр аяк басканда Алисәнең икенче класста гына укыган чагы була. Шахматны шашкадан да аера белмәгән кыз ни өчен бу уенны сайлагандыр — монысын ул хәзер үзе дә, беренче остазы Олег Игъламов та аңлата алмый. Алисә үз яшендәгеләр өчен катлаулы булган шахмат мәсьәләләрен шулкадәр тиз чишә ки, хәтта Олег Ильясовичны урамда очратканда да яңа биремнәр сорап йөдәтә икән. Мондый талант кызга каян килгән соң? Юк, әшче әтисеннән дә, әнисеннән дә, туганнарыннан да түгел, алар шахмат уены серләреннән хәбәрдар түгелләр. Алисәнең таланты беренче чиратта табигый сәләтенә һәм тырышлыгына, фидакарьлегенә кайтып кала.

Икенче класс кызындагы шулкадәр тырышлыкка, омтылышка Игъламов та сок-
ланып туя алмый. Аннары Алисәгә вакытын да, игътибарын да күбрәк бирә башлый.
Олег Ильясович игътибарлы булмаса, бәлки, бүген дөнья шахматы күгендә Алисә
Галләмованың йолдызы балкып янмас та иде. Кызганыч, спортта күп вакыт беренче
остазлар турында онытып җибәрәләр. Бар дан-шөһрәт спортчыны медальгә, исемгә
китергән тренерга бирелә. Аны тапкан, тәрбияләгән-үстергән беренче остазлар кулә-
гәдә кала. Бәхеткә, бу юлы Олег Игъламовның да хезмәтләре югары бәяләнде — ул
«РСФСРның атказанган тренеры» исеменә лаек булды. Бүген дә ул элеккеге шәкер-
тенең һәр уңышы өчен сөенеп, уңышсыз адымнары өчен көенеп яши.

Алисә Галләмованың уңыш баскычлары тәҗрибәле белгечләрнең дә игътибарын
җәлеп итәрлек. 1984 ел — республика беренчелегендә икенче урын. 1985 ел — чемпион.
Алисә моңарчы Татарстан чемпионы булган Наталья Савинаны бөтенләй «тар-мар»
итеп ташлый. Шул ук елда РСФСР спартакиадасы финалы ярышларында, 36 спорт
мастерын һәм мастерлыкка кандидатны артта калдырып, беренче урынны ала. Түбән
Новгородта үткән Бөтенсоюз турнирында да танылган осталарны җиңеп чыга. Үсмер
малайлар һәм егетләр арасында уздырылган ярышларда да яхшы нәтиҗәләргә ирешә.
Шушы бер ел эчендә генә дә Алисә, ун төрле ярышта катнашып, аларның һәркайсын-
да җиңү яулый.

Беренче очрашуыбызда мин Алисәдән киләчәк планнары хакында да сораган
идем. «Ил чемпионы исемен яулау һәм дөнья беренчелегендә катнашу»,— дигән иде
ул. Дөресен әйтим, мин ул вакытта бу сүзләргә шикләнебрәк карадым. Ничек инде,
13 яшьлек башың белән?..

Әмма шикләнүләр бик тиз юкка чыкты. Алисә Галләмова бик тиз үзенә ышаныр-
га мәҗбүр итте. Хәер, аның биографиясендә үзгәрешләр дә булып алды... Бар көчен,
белемен шәкертенә биргән Игъламовның артыгына инде хәле юк иде. Нишлисең,
камиллекнең чиге булмаса да, кеше сәләтендә чама дигән нәрсә бар бит... Шәкерт һәм
остаз бер-берсен бик яхшы аңлыйлар. һәм Алисә Казанның 131 нче мәктәбен, «Проме-
тей» клубын, яраткан остазын Мәскәүнең Олимпия-спорт интернат-мәктәбенә алыштыра.
Ул вакытта бу адымны хупламаучылар да булды. Янәсе, без талантны үзебездән чит-
кә җибәрәбез һәм ул инде безгә кире кайтмаячак... Тик, нишләмәк кирәк, үсү өчен
Алисәне инде Казан гына канәгатьләндерми иде. һәм аның Мәскәүгә юл алуын бик

дөрес булды дип саныйк. Иң мөһиме — бу адым үз-үзен аклады. Интернат-мәктәптә Галләмова белән РСФСРның атказанган тренеры Рудольф Кимельфельд шөгыльләнде. Бирегә укыганда да Казан кызы байтак ярышларда катнашты һәм, гадәттә, һәрвакыт Татарстан данын яклады, исем арты исем алды.

...1987 ел Алисәнең спорт биографиясендә аерым урын тота. Бөтенсоюз сайлап алу ярышларында уңышлы чыгыш ясап, ул үзенең тәүге халыкара турнирында — 16 яшькәчә (андыйларны шахматта «кадет» диләр) булган кызлар арасында үткәрелә торган дөнья чемпионатында катнашу хокукын яулады. Алисә кебекләрне ике кышкы Олимпиада башкаласы — Австриянең Инсбрук шәһәре кабул итте. СССР командасында Алисәдән тыш тагын бер татар баласы — Ленинградтан Гата Камский да бар иде. Кызганычка каршы, ул биредә үзен әллә ни шәп күрсәтә алмады. Әлбәттә, моның кайбер сәбәпләре дә бар иде, ләкин аларга тукталып торасы килми. Ни әйтсәң дә, шахматта да гаделсезлекләр җитәрлек һәм ул мафия үз позициясен җиңел генә бирергә теләми.

Татар малае Австрияне шаккаттыра алмаса да, татар кызы күпләрне гаҗәпкә калдырды. Ул чемпионат барышында бары 2,5 очко гына югалтты һәм ышанычлы рәвештә беренче урынны яулады. Аның Голландия вәкиле Рената Лимбах белән уйнаган партиясе чемпионатта иң матурларның берсе дип табылды. Журналистлар башта ук якташыбызга бик килешле исем таптылар — «Тироль балы принцессасы». һәм ул ахырга кадәр «принцесса» булып торды. Шулай итеп, Алисә Галләмова беренче тапкыр шахмат таҗын киде. Болгариянең бу хакта хәбәр итүче «Народен спорт» газетасы, аның фамилиясен үзләренә яраклаштырып, Галләмованы «Галанова» дип язып чыкты. Әлбәттә, моның белән чемпионның татарлыгына зыян килмәде.

1987 елның көзендә Казан кызы берьюлы ике катлы ярышта — хатын-кызлар арасында СССР чемпионатында һәм Сочида традицион халыкара шахмат фестивалендә чыгыш ясады. Бу моңарчы күрелмәгән хәл иде. Берьюлы ике шундый ярышта чыгыш ясау, мөгаен, моңарчы берәүнең дә хәленнән килмәгәндер. Шахмат белгечләренең күпчелеге моңа сагаеп карасалар да, Алисә янә үзенең нәрсәгә сәләтле икәнен бик ачык күрсәтте. Ике турнирда да уңышлы чыгыш ясады. Өстәвенә, 15 яшьлек Алисә халыкара мастер исемен алу өчен ике балл туплады.

1987 елны, шәт, Алисәнең балалыктан чыгу вакыты дип атарга кирәктер. Ул чынчынлап зур спортка аяк басты. Ныклы адымнар, ышанычлы адымнар белән басты. Чемпион исемен алуының очраклы хәл генә булмаганлыгын Алисә икенче елны кабат расլап күрсәтте. Румыниянең Тимишоара шәһәреннән ул янә чемпион булып кайтты. Бу юлы 14 яшьлек Гата Камский да сынатмады. СССР чемпионы исемен йөртүче үсмер малай икенче урынны яулады. Хәер, моннан соң да Гата үзен байтак күрсәтте. АКШта төпләнгәч, аның уңышлары тагын да сизелерлек була башлады. Алисәгә килгәндә, аңа чит илгә китәргә сәбәп юк, дип фараз кылыйк. Әлбәттә, кадерен белгәндә...

Язмамның башында «өч тапкыр дөнья чемпионы» дигән идем. Өченче тапкыр чемпион булып Алисә ерак Австралиянең Аделаида шәһәрендә танылды. Бирегә ул егерме яшькәчә булган кызлар арасындагы беренчелектә катнашкан иде. Көрәш, нигездә, ике генә шахматчы — СССР вәкилләре Грузия кызы Кетеван Арахамия һәм безнең Алисә арасында гына барды дисәм, хата булмас. Үзара көрәштә бу юлы Галләмова җиңеп чыкты. Аннан соңгы чемпионатта шулай да Грузия кызы Алисәне икенче урында калдырды.

Мәгълүм ки, спортта һәрвакыт җиңүләр генә булып тормый. Иң мөһиме — җиңүләрне дә, җиңелүләрне дә кичерә белергә кирәк. Миңа калса, Алисәгә шундый сыйфат хас та инде. Юкка гына Австралиядә журналистлар якташыбызга «елмаерга яратучы чемпионка» дигән исем кушмадылар... Татар кызларына хас булганча, бик тыйнак елмая Алисә. Аның һәр елмаюына зур мәгънә яшеренгән шикелле.

Мәскәүдәге интернат-мәктәпне тәмам иткәч, Алисә Казанга кайтмас, дип уйлаучылар нык ялгыштылар. Ул туган Казанына кайтты. Шуның өстенә, аның тренеры — гроссмейстер Александр Панченко да Казанга күчеп килде.

Казанда Рәшит Нәҗметдинов исемендәге шахмат сарае ачылу шатлык өстенә шатлык булды. Шәт, мәрхүм Рәшит ага Алисә шикелле варисы булу белән чын-чынлап горурлана алыр иде: варис бит аны да уздырды — Рәшит Нәҗметдинов халыкара мастер иде, Алисә Галләмова хәзер халыкара гроссмейстер исемен йөртә. Бу исемне алу Алисә өчен бик җиңел булды, дисәм — ялгышамдыр. Дөрес, моның өчен кирәкле өч баллны якташыбыз бик җиңел җыйды җыюын, ләкин шуннан соң аңа байтак көтәргә туры килде... Шахмат мафиясе «тырышлыгы» җимеше иде бу. Ниһаять, узган ел ахырында ФИДЕ (халыкара шахмат федерациясе) башкарма комитетының Швейцариядә үткән утырышы бер төркем шахматчыларга, шул исәптән Алисә Галләмовага халыкара гроссмейстер исемен бирү турында гадел карар кабул итте. Шахматчы өчен бу — иң зур дәрәҗә.

Шулай итеп, Алисә Казан данын, Татарстан данын бөтен дөньяга танытты. Зур шахматчы һәм журналист Савелий Тартаковерның мондый сүзләре бар: «Гроссмейстер булу авыр түгел. Бары күп уйларга, аз йокларга, матурлыкны хатын-кызда гына түгел, шахматта да күрә белергә һәм көндәшләреңнең фикерен сизәргә генә кирәк». Бу сүзләр артында тирән мәгънә ята.

Гроссмейстер исемен зур фидакарьлек белән яулап алалар. Әйе, нәкъ менә яулап алалар. һәм ул, дөресен әйткәндә, теләсә кемнең хәленнән килми. Кайберәүләрнең, илдә Алисәнең яшьтәшләре арасында көчле шахматчылар юк икән, дип фикер йөртүе

ихтимал. Һич алай түгел. Талантлар күп булмаса да, көчлеләр байтак. Мәсәлән, Арахамия, Вәлиханлы, Заец, Софиева... Әмма Галләмова үзенең алардан өстенрәк булганын раслады инде.

Грузия шахматчыларына аерым тукталасы килә. Алар элек-электән көчле. Иано Иоселиани, Нана Александрия, дөнья чемпионнары Нана Гаприндашвили һәм Майя Чебурданидзе... Шахмат тәхетендә әлегә Чебурданидзе утыра. Һәм, әйтергә кирәк, нык утыра. Ләкин якын елларда аның тәхете какшамаслыгына ышандыру кыен. Алисәнең Чебурданидзе белән әлегә көч сынашканы юк югын. Язмыш аларны, бүгенге көнгә кадәр, икесен ике якта йөртә. Бу күпме шулай дәвам итәр? Грузия шахмат мәктәбенең кайбер вәкилләре белән Алисәнең инде уйнаганы бар. Һәм ул аларга ныклы каршылык күрсәтте.

Якташыбыз үзен ир-егетләр ярышларында да сынап карый. (Әлбәттә, ул бу мәсьәләдә Венгриянең бертуган Полгарлары белән ярыша алмый, шулай да...) Узган ел Галләмова Белоруссиядә СССР яшьләр чемпионатында катнашты. һәм 7 тур (!) дәвамында егетләрне артта калдырып, лидер булып барды. Аннары Мәскәүдә ирләрнең Дөнья кубогы ярышларында чыгыш ясады һәм күп кенә дәрәҗәле шахматчыларны артта калдырды. Яшь шахматчыларның Америка Кушма Штатларындагы чыгышларында да иң яхшы нәтиҗәләргә ирешүчеләрнең берсе Алисә булды. Әйе, болар бөтенесе — горурланырлык уңышлар. Ирексездән совет шахматы атасы Михаил Ботвинникның мондый сүзләре искә төшә: «Чемпионда чемпион холкы булырга тиеш»,— дигән иде ул. Алисә нәкъ менә үзендә шундый холык тәрбияләде дә инде.

18 яшьлек кыз бүген Казан дәүләт педагогия институтының чит телләр факультетында укый. Чит телләрне белү, һәрхәлдә, шахмат алиһәсе өчен ят нәрсә булырга тиеш түгел. Аның укуы турнирлар, тренер җитәкчелегендә осталыкны арттыру дәресләре белән чиратлаша. Нишлисең, спортчының тормышы шуннан гыйбарәт.

Бер илдән кайта, икенчесенә чыгып китә Алисә. Ә шулай да ул иң яраткан төбәк кайда дип уйлыйсыз?.. Юк, шахмат алиһәсенең ашкынып бара торган җирен чит илләр арасыннан эзләмәгез! Ул, беләсегез килсә, әнисе Гамбәриянең туган җирен — Актаныш районындагы Татар Ямалы авылын ярата. Алисәнең кайтуы әбисе белән бабасы өчен генә түгел, бөтен авыл халкы өчен бәйрәмгә әйләнә. Үз авылларыннан чемпион кадәр чемпион чыксын әле! Аеруча җәйләрен кайтырга ярата Алисә Ямалыга. Авылдагы бер генә эштән дә читләшеп тормый ул — бар да үз аңа. Ямал мәктәбендә Алисә Галләмова исемендәге шахмат клубы эшли. Шунысын да әйтик, Казанның Идел буе районында оешкан шахмат клубына да «Алисә» дип исем бирделәр. Аның командалары Казан күләмендә үткәрелә торган ярышларда алдынгы урыннарны яулый. Үзеннән-үзе бер сорау туа: Алисәгә алмашка килүчеләр бармы соң? Сәләтлеләр бар барын, ләкин Алисә кебек талантлар дистә елларга бер генә туадыр, мөгаен. Шуңа да без аның турында кайгыртсак иде! «Гата Камский вакыйгасы» тагын кабатланмасын иде! Талантларга үсү өчен, миңа калса, иң беренче чиратта, хөрлек кирәк. Аларны тар кысада тотудан мәгънә юк һәм булмаячак. Алисә — шундый иркенлеккә бәреп чыга алган олуғъ талант. Дан-шөһрәт аңа ничек тәэсир итә соң? Юк, Алисә даннан исерә торган кеше түгел. Алиһәбез мактанырга яратмый. Алиһәләргә андый сыйфат хас түгел. Шахматтан тыш Алисә шәрык әкиятләрен ярата. Тенниска да мәхәббәте бик көчле аның.

Ирексездән 1986 елның язында танышкан 13 яшьлек оялчан кызны һәм 18 яшьлек гроссмейстерны чагыштырам. Алар бер-берсенә охшаган да, шул ук вакытта шактый аерыла да кебек. Ни генә булмасын, ул — безнең Алисәбез, безнең алиһәбез, татар кызы. Ул, һәрвакыттагыча, сөйкемле генә елмая. Үзенең остазларына да, көндәшләренә дә, әти-әнисенә дә, яраткан этенә дә елмаеп карый... Елмая икән, димәк, җаны тыныч, ышанычы нык. Елмаю китмәсен синең йөздән, Алисә! Без аңа мохтаҗ. Шатлану өчен, горурлану өчен, уйлану өчен...

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Нажар Нәҗми**

# СИБГАТ ХӘКИМ МӘКТӘБЕ

Истәлек-мәкаләмнең башына шушы җаваплы исемне куйдым да, үзем уйга калдым: язганнарым аша мин шул мәктәпнең булганлыгын һәм аның асылын ачып бирергә бурычлымын бит. Сибгат Хәким мәктәбе... Нинди соң ул мәктәп? Безнең заманда «Фәлән-фәлән шагыйрьнең традициясе» дигән төшенчә яшәп килә. Ул төшенчә минем аңыма иң тәүдә Маяковский исеме белән килеп керде, аннан соң инде «Тукай традициясе» дигән төшенчә аңыма сеңде.

Күптән түгел Украинаның Запорожье шәһәреннән җибәрелгән сораулар арасында: «Павло Тычина традициясенә ничек карыйсыз?» — дигәне дә бар иде. Шуннан соң: «Тагын нинди шагыйрьләрнең традицияләре бар икән?»— дип уйлап куйдым. Җитмәсә, безнең бит хатта: «Фәлән шагыйрь фәлән шагыйрьнең традицияләрен дәвам итә»,— дип язганыбыз да бар. Сибгат Хәким үзе дә бер мәкаләсендә, традицияләр хакында сүз башлап, туган авылындагы бер картның: «Алай булса, син, энем, Габдулла Тукай урынында калган кеше икәнсең»,— дигән сүзен искә төшерә. «Тукай урынына калу...» бу бик тә тирән һәм мәгънәле сүз. Тукай язганнар, әлбәттә, фәкать Тукайныкы, әмма аның урынына калу, аны дәвам итү — икенче мәсьәлә. Традиция дигәнебез дә, бәлки, ул иҗатчының төп иҗатыннан тыш, әмма иҗатка нык бәйләнгән үзенчәлегедер? Шагыйрьнең иҗади үзенчәлеге һәм иҗади эшчәнлеге аның үз мәктәбен барлыкка китерәдер. Татар поэзиясендә Сибгат Хәкимнең мәктәбе барлыгын без һич икеләнми әйтә алабыз һәм шушы мәктәп Сибгат Хәким традициясе дип әйтерлек аның үзенчәлекләр эченә ала. Нинди үзенчәлекләр соң алар?

Сер түгел, Сибгат Хәкимнең иҗаты — тик үзенә генә, үз табигатенә генә хас иҗат. Шигырьләрендәге, поэмаларындагы уй-моң агышын, интонацияләрен, алымнарын икенче берәүнеке белән һич тә бутап булмый.

Сибгат Хәким поэзиядә Тукай белән теле ачылган, аңа мөкиббән киткән шагыйрь. Тукай аның җаны, сулышы, булмышы.

Сибгат Хәким — татар шигъриятенең үткәне, бүгене, киләчәге хакына җанын фида кылган шагыйрь. Ул — яңа исемнәр, шагыйрьләр эзләүче, табучы һәм үстерүче? Шагыйрьләргә ярдәмче.

Язмамда аның менә шушы ярдәмчелегенә ныграк тукталырга уйлыйм да. Әйе, Сибгат Хәким мәктәбе-традициясе... Шул мәктәп, шул традиция мине дә читләп үтмәде.

1958 елның кышында без — башкорт шагыйрьләре, Мостай Кәрим, Гыйлемдар Рамазанов, Шәриф Биккол, Муса Гали — Казанда үткәрелгән «Татар шигыре төзелеше» дигән дискуссиядә катнаштык һәм берничә урында шигырьләр укып чыгышлар да ясадык. Безнең белән бергә, татар шигъриятенең вәкиле һәм безне озатып йөрүче буларак, Сибгат Хәким дә катнашты. Ул яңарак язылган «Суд залыннан» дигән циклыннан шигырьләрен дә укыды. Шул чакта ул, кайсыдыр очрашудан соң, үземә килеп: «Шигырьләреңне Казанда чыгарыйк. Миңа җибәр»,— диде. Уфага кайтып, кулъязманы аның исеменә җибәргән чагымда «Үземне суд залында, сезнең хөкемегез алдында итеп хис итәм» дигәнрәк хат та яздым. Шулай итеп, күп тә үтми, минем «Сөю сүзләре» дигән, татар телендә чыккан китабым дөнья күрде (Аңа карата шул елда ук Гали Хуҗи, Г. Миңнуллин, Р. Гәрәй иптәшләрнең рецензияләре чыкты. Ул 1962 елда иде. «Булган бит заманалар!» — дип әчтән генә уйлап куям хәзер).

Әйе, заманалар булган... Сибгат Хәким белән беренче очрашу да 1958 елда түгел, ә аннан сигез ел алданрак иде. Казанга минем тәүге килүем. Максатым — Казанга стажировкага киткән Баулы кызын Сабан туеннан эзләп табу иде. Барырга дигән утны йөрәк-

ка Шәриф Биккол салды: бергә эзләп табабыз, диде. Шәриф өйләнергә дип алдан китте, ә мин бер-ике көнгә соңлап бардым. Алдан сөйләшеп куелган җирдә очраштык та, Максим Горький исемендәге паркка Сабан туена киттек. Анда — мәхшәр! Безнең хәл печән кибәненнән энә эзләү белән бер иде. Йөри торгач, кызны табу, очрашу өмете өзелгәндә без икенче бер «энәләр»гә тап булдык. Ул «энәләр» Сибгат Хәким белән Гали Хуҗи иде. Алар икесе дә җәмәгатьләре белән. Шәриф Бикколга алар барсы да таныш, ә минем беренче күрешүем. Без чирәм өстендә табын кордык. Минем кебек «кияү егете»нең янган йөрәген сүндерергә шул гына кирәк иде, йөрәкнең януы түгел, аякларның йөрү сәләте дә сүндерелгән иде инде. Икенче һәм башка очрашкан вакытларда мин бу хәлне искә төшермәдем, Сибгат агай, бәлки, ул кешенең мин булганын оныткандыр да, ә минем өчен ул хакта сүз кузгалту гарьлек тоелды. Безнең шушы тәүге очрашу белән соңгы очрашулар арасында (соңгысы 1986 елның 13 июнендә, яшәргә 20 көн гомере калгач, больницада булды) — утыз алты ел гомер эчендә Казанда, Мәскәүдә, Алма-Атада, Уфада, Трусковецта очрашкан вакытларданиләр сөйләшкәнебезне хәтерләп бетермим, әмма шуларның берсе нык истә калган.



**Рәсемдә:** *(сулдан уңга) Нажар Нәҗми, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Гыйлемдар Рамазанов. 1972 ел.*

1967 елда «Учительская газета»да минем «Татар теле», «Правда»да «Акканнар» шигырьләре басылып чыккач, татар әдипләренең миңа карата ихтирамнарының иң югары ноктасына җиткән чагы булды. Моны Хәсән ага Туфанның телеграммасыннан да, Сибгат Хәким белән Гариф Ахуновның «Москва» кунакханәсендәге минем бүлмәгә керепсөйләгән сүзләреннән дә аңлап була иде. Икенче көнне Гомәр Бәширов, Сибгат Хәким һәм мин ЦДЛда бергә сөйләшеп торганда, көтмәгәндә Ибраһим ага Гази (ул вакытта аның Татарстан Язучылары союзы идарәсенең рәисе чагы), миңа: «Булмаса син, әйдә, Казанга кайт»,— диде? Ә мин шаяру катыш: «Кайт түгел, кил!» — дип җавап биргән идем, Ибраһим агай үзенекен алга сөрде: «Юк, кайт!» Мин аларга үз күргән өчен, якын иткән өчен рәхмәт әйттем, шуның белән сүз дә бетте, сөйләшү бүтән темага күчте. Икенче көнне иртән кунакханә буфетында чиратка килеп бассам — алда Сибгат агай. Ул шунда ук үзенчә әкрен генә, турыдан-туры: «Син Казанга килсәң, миңа марилар китәргә туры килә инде»,— диде. Мин кычкырып көлдем, ә ул чак кына үзенчәлармайды. Аннан соң мин: «Алай булгач, синең арттан мин дә мариларга китәм. Без авыл-да гомер буе марилар белән аралашып яшәдек. Безнең колхозның бер бригадасы мари авылы»,— дип өстәдем. Әлбәттә, Казанга күчү уйлары бер вакытта да минем башыма кергәне булмады, ә ул елларда инде, Әмирхан Еники агай әйтмешли, миңа, карт агачка башка туфракта тамыр җибәрү авыр булыр иде. Сибгат Хәкимнең бу сүзләрендә мин бер төрле дә тар күңелле лек күрмәдем, ә киресенчә, минем хакта аның зур фикердә йөрүен аңладым.

Без бертуган халык әдипләрендә, бер караганда, Уфада яшәдең ни, Казанда яшәдең ни — шигърият өчен аерма юк. Ә Сибгат Хәким белән тын алышыбыз ук бер иде. Гомумән, татар әдипләре белән, бигрәк тә шагыйрьләре белән, Уфада торган килеш тә, Казанда яшәгән кебек яшәлде һәм яшим дә. Шулай түгелмени? Үземчә иҗатымның иң зур әсәре дип санаган «Иблис» поэмасы «Агыйдел» журналында түгел, ә «Казан утлары»нда басылып чыкты. Аның чыгуында гына түгел, языла башлавында да Сибгат Хәкимнең катнашы бар. Ул поэманы язу уе башымда озак йөрде. Тәүге исеме «Мәтрүшкә» иде. 1972 елның апрелендә, шул поэмага бәйле, Кавказ сугышы герое, мәшһүр Шамилнең урысларга әсир төшкән җирләргә — Дагстандагы Гунибка да барып кайткан идем инде. Шул елның август аенда Сибгат Хәким белән Хәсән Туфанны Уфага чакыргач (ул хакта Х. Туфан хакындагы истәлектә җентекләп язылган), икесен дә Башкортстанның тау якларына, кешеләрнең Агыйдел аша басма салып кына йөргән урыннарга, Бөҗән районына алып бардым. Бөтен дөньяга билгеле булган Шүлгән тау куышын кереп караганнан соң, Агыйдел күпере аша «Волга»да үз хуты белән чыкканнан соң, Агыйдел буендагы агачлар төбенә табын җәеп, ашап утырганда «Иблис» поэмасының эчтәлегенә бәйләп Мәдинәдә яшәгән, Татарстаннан киткән татар кешесенең (элекке мулланың) язмышы хакында сөйләдем. Сибгат Хәким шунда ук: «Бүгеннән башла. Харап булуы мөмкин»,— дип өзеп әйтте. Мин башладым. Озак эшләдем. Тәмамладым. Үзебездә басылуына ышандым, чөнки күптән түгел генә А. Твардовский истәлегенә багышланган «Шагыйрь үлеменә» һ. б. берничә шигыремне, корректурасы килгәч, югары урындагыларның әмере буенча, журнал битеннән алып ыргытканнар иде. Поэманы Сибгат Хәкимгә җибәрдем. Ул үзенең сорау билгеләрен куя-куя укып, геройлар хәрәкәт иткән урыннарга ачыклык кертүне теләп, кулъязманы кире кайтарды. Карап чыктым. Яңадан Казанга китте. Һәм «Казан утлары» журналында басылып чыкты.

С. Хәким, «Казан утлары» журналының редколлегия әгъзасы буларак, поэма хакында редакциягә язган хатында (ул хат журналның 1988 елгы 4 нче санында басылды) әсәргә булган карашында, аңа биргән бәясендә — аның олы җанлы кеше хәстәрлеге ярылып ята. Мин кем аның өчен? Мин бит башка милләт, башка халыкның шигырьчесе түгелмени? (Дөрес, поэманың геройлары Зөя буенда туып үскәннәр). Әмма С. Хәким өчен иң тәүдә поэзия бар, ул аның өчен бар нәрсәдән дә өстен. Бары тик тар күңелләр өчен генә безнең араларда чикләнү — җир арасы, милләт һәм тел арасы булырга мөмкин. (Җәя эчендә шуны да әйтмәкче булам: шушы истәлекне язган көннәрдә «Казан утлары» журналында басылган Риза иптәш Шәфиевның мәкаләсен укырга туры килде. Ул бик күп еллар элек Уфада, очраклы рәвештә генә башкорт әдипләренең әңгәмәсенә юлыкканын яза. Башлап язучы бер хатын-кызның роман язганын ишеткәч, башкаларның шуңа шатлануын диалоглар аша күрсәтә дә, шундый нәтиҗә ясап куя: «Барсының да йөзендә сөенү, куану, канәгать елмаю... Нилектән? Җылы атмосфера, җылы теләктәшлектән. Ә бездә?» — ди.

Сибгат Хәким тарафыннан хупланган, аның белән ризалашкан һәм поэманы укыган редколлегия әгъзалары аша үтеп дөнья күргән «Иблис» поэмасы хакында безнең бер әдибебез Уфа педагогия институты студентлары һәм профессор-укытучылар исеменнән, поэма зарарлы әсәр дип, аны фашлап Үзәк Комитетка язды. Ул мәсьәлә белән КПССның Татарстан өлкә комитеты шөгыльләнде. Әйтәсе килә: «Иптәш Риза Шәрәфиев, әсәр хакында сездә куану, канәгать елмаю. Нилектән? Җылы атмосфера, җылы теләктәшлектән. Ә бездә?»)

Сибгат Хәким мәктәбе-традициясе дигәндә «Казан утлары»нда, шагыйрьнең минем поэма хакындагы хатларыннан башкаларына игътибар итсәк, анда ундүрт хат, ундүрт кешенең иҗаты турында хәстәрлек — бу әле редколлегия әгъзасы буларак кына. Ә «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» дигән китапка тупланган башка мәкаләләре? Анда халык, шагыйрь, туган тел хакында уйланулар, ничәмә шагыйрьнең иҗаты турындагы фикерләүләр... Күпме көч, энергия (шигырьләр язудан башка) кирәк! Димәк, табылган! Шулар арасында минем хакта да бар — «Ут күрше» дигән китабыма баш сүз. Баш тартмаган, вакытны җәлләмәгән, язган. Ә ничегрәк язган әле!

Әйе, Сибгат Хәким миңа карата бик игътибарлы булды. Күңеленә хуш килгәнмендер, яраткандыр; бәлки, минем аны яратканны белеп тә яраткандыр. Казан телевидениесе миңа багышланган ике тапшыру оештырды. Беренчесендә (1977) режиссер Әхтәм Зариповның тырышлыгы һәм ихтирамы күн кебек ачык иде. Икенчесендә дә (1986) шулай ук. Шуларның икесендә дә Сибгат Хәким катнашты, вакыт тапты. Телевидение камерасы алдында аның бер язусыз-нисез оста сөйләве дә хәйран калдырды. Бу аның тагы бер үзенчәлеге, талантының бер кыры иде.

Икенче һәм соңгы тапшыруда катнашыр өчен баруыма аерым тукталмакчы булам. Казанга килеп, кунакханәгә урнашуым белән Сибгат Хәкимнең өенә шалтыраттым. Ул минем тавышны ишетү белән: «Нигә озакладың? Сине көтеп утырам. Радиога барабыз. Кил!» — диде. Опера театры янында очрашырга сүз куештык. Килдем. Ул көтеп тора

Күрәм — бик ябыккан, йончыган, йөзе агара төшкән. Инфаркт, димәк, үзенекен иткән. Без радиога киттек. Поэзияне бик тә яраткан, аның чын патриоты — радиода әдәби-драматик тапшырулар редакторы Рөстәм Фәйзуллин, чыннан да, безне нык көткән. Радиога язылгач, Сибгат Хәким мине Г. Тукайның 100 еллыгына багышланган күргәзмәгә алып китте. Күргәзмә искитәрлек тәэсирле иде, мин заллар буйлап йөргән чагымда С. Хәким утырып та торды. Хәлсезлеге сизелә иде. Аннан соң без аның өенә кайттык. Почта тартмасыннан газеталар һәм хатларын алды. Алар арасында Гамил Афзалдан да хат бар иде. «Гамил белән дә хат алыша икән»,— дип эчтән генә уйлап куйдым. Без озак еллар хат алыштык. Аның хатлары барсы да дип әйтерлек поэзия хакында. Теге яки бу әсәр хакында фикер әйтсенме, укырга киңәш бирсенме — аның хатлары үзе бер дөнья. Ул безнең башкорт шагыйрьләрен укып барды. Хатларында һәркемгә карата үзенең фикере дә булды.

Безнең Башкортстан әдипләре арасында Сибгат Хәкимгә караш бер төрле булмады. Кайсыберәүләр яратып җиткермәделәр, хәтта яратмаучыларны да табарга мөмкин иде. Кем яратмаганны ул үзе дә белде һәм моңа һич кенә дә исе китмәде, чөнки үз бәясен үзе белә иде. Йөзәрләгән шигырьләр, унарлаган поэмалар язмыйча, хәтта «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Башка берни дә кирәкми», «Әй, язмыш, язмыш», «Җил исми — яфрак селкенми», «Кайда да йөрәктә», «Фазыл чишмәсе», «Бу кырлар, бу үзәннәр» кебек шигырьләрен, җырларын гына язса да — халык күңелендә яшәр өчен, халык шагыйре булыр өчен шул җиткән. Мондый язмышлы шагыйрь булу һәр кешегә тәтеми. Белмим, ни өчендер шигъриятне бөтен нечкәлеге белән аңлый белгән дусларыма да Сибгат Хәкимнең барып җитмәгән чаклары очрый иде. Андыйларга, кызып китеп, мәсәлән: «Иске портфель — игеннәрен җыйган, көзге кыр сыман» дигән юлларның Муса Җәлил образына нинди штрих икәнлеген «исбат» иткәч, кешеләрнең: «Бәй, кара әле, әй...» — дип аптырап, сүзсез калганнарын да күрергә туры килде. Әй, чын поэзиянең серле гадилеге!..

Сибгат Хәким миннән җиде яшькә олы. Шулай булуына һәм авырудан соң йончыганлыгына карамастан, Казанга шушы килүемдә ул дүрт көн буе минем белән бергә булды: радиодан соң икенче көнне телевидениегә язылдык, өченче көнне безне Тукайның туган көнендә ел да уздырыла торган шигъри митинг, кичен «Без китәбез, сез каласыз» дигән спектакльнең премьерасы. Дүрт көн буе без бик күп сөйләштек, нәрсәләр хакында икәнлегенең байтагы хәтердә калмаган, ә хәтердә калганнарның кайберләрен монда язып та булмый, әмма иң хәтердә калганы — Курск дугасында сугыш барган җирләрне, окоп урыннарын, сугыштан соң барып күргәннән соң алган тәэсоратлары инде. Ул рота командиры булган. Рота һәм взвод командирларының, солдатлар кебек үк, сугышта кырылганнарын беләм. Мин аннан: «Ничек исән калдың? Курск дугасыннан соң да сугышлар каты барды. Кешеләр, командирлар һәлак булдылар»,— дип сорагач, «Мине 1944 елның язында Румыния чигендә пограничник итеп калдырдылар»,— диде. Минем өчен, әлбәттә, бу яңалык иде, чөнки без дә, шул язны беренче булып, Румыниягә кергән идек. Яссы янындагы сугышлар — таулар, яланнар, басулар, окоплар, траншеялар — барсы да күз алдымда.

Безнең бергә булган көннәр Тукайга 100 ел тулу бәйрәме алдыннан иде. Казаннан киткәндә шул 100 еллыкта тагын да очрашуны күз алдында тотып, Кырлайдан кайтышлый, аның туган авылы Күлле-Кимәгә дә кереп чыгарга да хыялланып, аерылыштык. Без июнь аенда бәйрәмгә килдек, ә Сибгат Хәкимне, Тукай бәйрәменә бер атна калгач, больницага салганнар. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрындагы тантаналы кичәдә дә, Кырлайда да Хәсән Туфан белән Сибгат Хәким, берсе арадан бөтенләй китеп, икенчесе чирләп, катнашмадылар. С. Хәким, авыруы көчле булуына карамастан, Тукай көннәрендә катнашырга теләп, тәмам егылганчы, больницага кермәгән.

Бәйрәм үткәч, Сибгат Хәким янына Мостай Кәрим белән икәүләп кермәкче идек, миңа берүземә генә керергә туры килде. Хәле элеккегә караганда җиңеләя төшкәнен үзе дә, Мөршидә ханым да әйткәч, тынычлана төштем. Минем баш сүз белән чыккан ике томлыкның беренче томын нәшриятта бүләк итеп биргәнлекләрен әйтте: «Икенче томына язып үзем җибәрермен»,— дип тә куйды.

Әй, өмет! Шул өмет эчендә авыру шагыйрь белән саубуллаштым. Мин ишек төбенә җитәр чакта гына: «Рәхмәт!» — диде. Бу аның миңа әйткән соңгы сүзе булган икән. Ул сүзе 1986 елның 13 июнендә әйтелгән иде, ә инде 5 июльдә аны җирләргә килгәч, табуты янында шушы соңгы сүзен кабатладым. Бүген дә кабатлыйм:

— Сибгат агай Хәким, искитмәле уй-моңлы иҗатың өчен, халык язмышы белән язмышланып, аның үткәне белән горурланып, шигърият өчен, халкың киләчәге өчен кайгыртып һәм янып яшәгәнең өчен сиңа мең рәхмәт!»

**Мансур Вәлиев**

# БАТЫРЛЫК

Без бу сүзне күбрәк яу кырында, сугыш вакытында кылынган каһарманлыкка карата кулланырга иялөнгән. Һәм, чыннан да, татар халкының дошманга каршы юлбарыстай нык торуы дөньяда күпләргә, бик күпләргә мәгълүм. Моңа тагын бер мәртәбә ышану өчен соңгы сугыш каһарманнарын гына искә төшерү дә җитә. Уртача мең кешегә туры килгән геройлар саны буенча татар халкы, мөгаен, ил буенча иң алдынгы урыннарның берсен алып торадыр.

Әле шуның өстәвенә, сугыш батырларының тагын да күбрәк булуы еллар үткән саен һаман ачыклана бара. Каһарманнар исемлеге торган саен тулылана гына бара! Мисал өчен — соңгы елларда гына Александр Матросовның безнең милләттән булуы расланды. Рейхстагка кызыл байракны беренче булып кадаучының да татар егете икәнлеген «Правда» газетасы язып чыкты.

Мондый зур батырлыклар әле тагын да ачылмас дип кем кистереп әйтә ала?!

Әйе, халкыбыз уллары үзләренең үлемсез каһарманлыклары белән бөтен милләтебезгә дә, үзләренә дә һәйкәл куйдылар.

Ләкин тормыш үз агышында хәлиткеч чорларны тудырып кына тора. Милләткә бүген тагын батырлар кирәк. Аның гомерен саклап калу өчен, халыкның яшәвен дәвам итү өчен бүген яңадан каһарман йөрәкле ирләр сорала. Мәйданга тагын алар — батырлар чакырыла.

Бүген иҗтимагый-сәяси яктан гаять авыр хәлдәге татар халкын терелтү бик күпләрнең фидакарьлегенә бәйле. Хәзер бигрәк тә зыялылардан иң зур иман ныклыгы, үз халкына иң нык тугрылар сорала. «Мин батыр!» — дип йөргән бик күпләр бүген милләт сәхнәсендә яңа имтихан тота.

Татар халкының күз текәгән затлары — иҗат кешеләре дә — соңгы елларда барган милли көрәш фонында яңача күренәләр...

«Бүгенге батырлык» дигәндә минем күз алдына язучы Фәнис Яруллин батырлыгы килеп баса. Аның язмышы безнең укучыга яхшы таныш. Армия хезмәте вакытында һәлакәткә очрау — умыртка сөяген сындыру һәм гомергә урында ятарга мәҗбүр ителү...

Урында килеш, хәрәкәтсез бармаклар белән әкрен-әкрен генә язу — көчне сынап карау... Иҗат сихеренә бирелү... һәм, ниһаять, гаять авыр да, бик серле дә булган әдәбият дөньясыннан бөтенләй аерыла алмастай дәрәҗәгә ирешү...

Менә бүген инде укучы алдында Фәнис Яруллин каләме белән иҗат ителгән 20 китап ята. Алар чын мәгънәсендә, бу сүзнең туп-туры мәгънәсендә тырмашып язылганнар!

Шау-шулы һәм артык ыгы-зыгылы бу тормышта без бик күп нәрсәгә иялөнәбез, күнегәбез. Шулай иялөнеп киткәч, күп кенә күренешләрнең асылына карарга да онытабыз, аларның тышкы чагылышлары белән генә очрашудан риза-канәгать йөри бирәбез... Шулай итеп, безнең күңел күзебез кысыла, сукырая бара.

Әнә шундый куркыныч сукырлык аркасында без үз янәшәбездә яшәүче батырлыкны да күрми башладык бугай. Ак кәгазь алып анда зур киеңлык белән хәреф арты хәрефләр тезүче, аннары шул хәрефләрдән тылсымлы сүзләр ясаучы, көчле тылсым көченә ия җөмләләр тудыручы — мавыгып укыла торган әсәрләр иҗат итүче язучыбызның кеше, шәхес буларак гаять кыйммәткә төшә торган олы батырлыгын да хәзер күрми башладык ахырысы без! Тормышның күп кенә гадәттән тыш хәлләренә күнеккән төсле, үз янәшәбездәге үтә зур каһарманлыкка да иялөндек ахырысы...

Фәнис Яруллин каләме белән иҗат ителгән 20 китапның байтагы — проза әсәрләре. Ул бүген 4 повесть, күп санлы хикәяләр һәм балалар өчен язылган матур-матур әкиятләр авторы. Әле без аның бирегә күп санлы шигырь китапларын һәм театрларыбыз сәхнәләрендә баручы драма әсәрләрен кертмибез. Чөнки сүзне Фәнис Яруллинның проза әсәрләреннән башларга дигән ниятебез бар.

Укучыга башта үзенең шигырьләре белән танылган Фәнис Яруллин бер мәлне матбугатта беренче повестен бастырды. Әсәргә «Җилкәннәр җилдә сынала» дигән исем куелган иде. Әлбәттә, бу повестьның исеме үк безнең укучыга автор язмышы турында хәбәр итте. Аның Фәнис Яруллин тормышы турында булуы ачык иде.

Билгеле, тәнкыйтьтә бу әсәр турында шактый гына сүз булды. Повесть язучының уңышы дип бәяләнде. Хәзер исә сүзне бер сорау тирәсендә генә куертасы килә. Бу повесть укучыга нәрсә бирде һәм аның төп кыйммәте нәрсәдә иде?

Соңгы еллар тормышы кеше гомеренең бәһасен бик тә төшерде. Безнең зур-зур шәһәрләребездә хәзер кеше кыйнау, кеше үтерү бернигә дә тормый кебек. Без хәзер кинога керсәк тә, телевизор экранына баксак та — сугыш, үтереш, кыргыйлык күрәбез. Шулай итеп, бүгенге тормыштагы яшьләр аңыннан «кеше кыйнау, кеше үтерү — җинаятьләрнең дә җинаяте» дигән фикер читкә алып ташланды. Аңга тәэсир итүнең

Ялгызлык. Һәр бәхетсезлек бик үзенчә булган кебек, заманыбызның иң зур балаләреннән берсе булган ялгызлык та кешегә үз юлы, үз сукмагы белән килә. Ләкин аның күпләргә хас типик билгеләре дә бар. Фәнис Яруллин үзенең Сәхиясе аша бу күренешнең социаль тамырларын, сәбәпләрен ача. Алар нindиләр соң?

Ул хатын үзенең бала вакытыннан ук ана назын күрмичә, әтисе тәрбиясендә генә үсә. Димәк, аның холык-характерындагы хатын-кыз сыйфатлары тиешенчә үстерелми кала. Болар урынына ирләр йогынтысы — тупас, кыркурак кыланышлар сеңә... Әсәр героинясы менә шушы урында безнең бүгенге балалар хакында да уйлатып ала. Хәзерге аналар, иртән иртүк торып дәүләт эшенә чабу өчен, үз балаларын кояш чыкканчы ук яслегә китереп тапшыралар бит! Балалар анда көн буена көтү хөкемендә йөриләр. Шулай булгач, безнең җәмгыятьтә әйбәт балалар тәрбия кылырдай, яхшы кешеләр үстерердәй яхшы аналар ничек барлыкка килсен соң? Аларга бит кечкенәдән үк хатын-кыз тәрбиясе бирелми...

Икенчедән, әсәр героинясы Сәхия сыман, безнең бүгенге кыз балалар гел дә диярлек малайлар белән бергә уйнап, бер группада, бер класста аралашып үсәләр. Димәк, малайларда ешрак очрый торган тупаслык аларга да тәэсир итә диген сүз. Шулай итеп, җитенкерәмәгән хатын-кызлык өстәвенә тагын тупаслык та килеп өстәлә... Хәзерге күп гаиләләрне һәлакәткә илтүче хатын-кыз тупаслыгына әнә шулай итеп нигез салына.

Өченчедән, Сәхия үсә төшкәч тә гел диярлек ирләр эшенә туры килә. Башта ат җигә, аннары трактор, машина йөртә һ. б... Нәкъ инде бүгенге «атаклы» совет хатыннары! Ә бит андый пычрак һәм тупас эш кеше холкына нык кына тәэсир ясый... Димәк, холыклары, табигатьләре тагын да начарая төшә безнең «гүзәлләребез»нең...

Бүгенге җәмгыятьнең ярты бәласе — хатын-кызга мөнәсәбәт дөрес булмаудан. Кешечә, гуманлы булмаудан. Нәкъ әнә шуңа күрә безнең яшь буын гаять дәрәҗәдә кешелексез һәм тәрбиясез булып үсә дә инде.

Фәнис Яруллинның «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» повесте үзенең әллә ни зур булмаган күләме белән (ул китапта 90 бит чамасы урын били) гаять зур социаль мәсьәләләр күтәрә, уйландыра.

Танылган язучы Фәнис Яруллин бик күп сандагы әйбәт хикәяләр авторы да әле. Аның кайсы гына хикәясен алып карасаң да — ул тыгыз итеп, хис-кичерешләрне гаять киеренке тасвир кылып язылган булыр. Анда артык эпизодлар, артык персонажлар да очратмыйсың — шул ук вакытта барысы да гади генә, бик тә гадәти генә тасвир кылына.

Алайса аның хикәяләре ничек, нинди юл белән тәэсир ясый соң, дияр кайберәүләр. Әйтик, Фәнис Яруллин хикәяләре үзәккә алынган тормыш күренешенең үткенлеге белән, аның тирән мәгънәви көче аша тәэсир ясый. Менә мисалларга мөрәҗәгать итик. «Фаҗига» исемле бер хикәяне алыйк. Монда барысы да табигый, ышандырырлык. Кыз чибәр, ул кибеттә эшли. Ә егет әле армиядән генә кайткан. Шуңа күрә аларның тиз арада танышып китүе дә бик табигый килеп чыга. Яшьләр эшне кызу тота, вакыйгалар кинодагыча ук куера башлый. Егет өйләнергә үк уйлый. Ләкин кыз үзенең кибеттәннән һич аерылырга теләми — чөнки аракы сату аның өчен күңелле эш, үзе дә исерткечне еш каба. Ул хәтта балага узгач та, әлеге чиреннән котыла алмый. Нәтиҗәсе инде безгә тормыштан да бик билгеле: аларның балалары зәгыйфь булып туа...

Кайсыбер «эстет»лар, бәлки: «Шул да булдымы яңа әчтәлек?» — диярләр. Ә без аларга болай җавап бирик: сезнең бармактан суырып язган ялтыравык әсәрләрегезгә караганда менә моның ише, реаль яшәеш хикәяләре әдәбият өчен дә, кешеләр өчен дә мең мәртәбә кирәгрәк! Мең мәртәбә әһәмиятлерәк! Чөнки боларда — чын тормыш асылы. Кешеләрнең олы бәласе, олы кайгысы. Андый фаҗигалар турында әле безгә язарга да, язарга гына. Аларның тәмам тамыры корыганчы язарга! Ә ялтыравык һәм купшы әсәрләр ышанычсыз бит алар. Тыштан гына матур бит алар!

* * *

«Иҗаттагы батырлык» дигәндә минем күз алдыма кабат-кабат Фәнис Яруллин килеп баса. Утыз елдан артык гомерен урын өстендә ятып иҗат итүче шагыйрь Фәнис Яруллин!

*Авыруым артык борчымый,*
*Ахры, күнегеп киләм.*
*Җилләргә кушылып җырлыйм,*
*Таңнарга кушылып көләм.*

*Тик ишетсәм балаларның*
*Чыр-чу килеп уйнавын,*
*Берәрсе үз әнисенә*
*Яратып сыенганын —*
*Тоям йөрәктә нәрсәдер*
*Чеметеп-чеметеп куйганын...*

Биредә без аның бер шигыреннән өзек кенә китердек. Ләкин анда әсәрнең төп рухы, асыл әчтәлеге шактый тулы чагыла. Шуңа күрә Фәнис Яруллин тарафыннан инде 1965

елда ук язылган һәм шагыйрь иҗаты өчен шактый характерлы булган бу шигырь турында хәзер укучы белән бергәләп тә уйлана алабыз. Безнең күңелне ул ни рәвешле яулый соң?

Шигырь хакында уйлана башлау белән шунысын танырга мәҗбүр булырбыз: бу әсәрдә шагыйрь үзенең йөрәк серен батырларча — күңел түрендәге хисен бер дә яшермичә, эчкерсез рәвештә, ихластан ачып сала. Ул, һич тә курыкмыйча, үз укучысын йөрәк түреннән үткәрә. Анда нинди уе, нинди шатлыгы һәм кайгысы бар — һәммәсен дә ачып ташлый. «Ничегрәк, ни кыяфәттә күренсәм укучыга ныграк ошармын икән?»— дигән салкын рационализм уе аның ихлас җанына баш була алмый. Шагыйрь рыясыз, киң күңелле кешеләрчә уйлый, шуларның яшәү һәм уйлау җирлегенә таяна. Чынлыкта нинди булса, мине шулай кабул итегез... Шулай күрегез, аңлагыз...

*Үсмәсәм әгәр уйнаклап*
*Табигать кочагында,*
*Атынмасам, бәллү ясап,*
*Каеннар ботагында,*
*Югалтуның бу кадәрле*
*Ачысын тоймас идем,*
*Төшләремдә юллар күреп,*
*Һаман ымсынмас идем.*

*Миңа кадәр тормыш мине*
*Сукмаса һәм какмаса,*
*Яңаклыйсы урыннарда*
*Баштан сыйпап якласа,*
*Тормышның мин бу кадәрле*
*Кадерен белмәс идем,*
*Һәр уңышка, һәр табышка*
*Болай сөенмәс идем.*

Менә бу шигырьне инде поэзиядәге бер генә метафора да, бер генә ассоциатив фикер дә алыштыра алмый. Биредә инде кайнар язмыш, җилле-давыллы язмыш ярылып ята! Биредә инде уйлап чыгарылган фикерләр түгел, ә күздән яшь, йөрәктән кан тамызырдай дөнья хисләре! Ә кыска гына итеп әйткәндә, бу шигырь чынлык, табигыйлек, ихлас яшәү гүзәллеге турында никадәр тирән поэтик хакыйкать бирә. Шуны үзәккә үткәрә!

Фәнис Яруллинның ике шигырен укыдык. Икесенең дә үзенең катлаулы язмышыннан алып язылган булуын күрдек. Икесенең дә гаять эчкерсез булуын тойдык. Һәм, гомумән, шагыйрьнең бүтән әсәрләрен укыган чагында да әлеге сыйфатның аерылгысыз икәнлегенә ышанасың. Катлаулы язмыш белән эчкерсез, рыясыз хисләр сине әсәрдән әсәргә, китаптан китапка озата бара, ияртә бара...

Шагыйрьнең китапларын укып чыгасың... Җыентык арты җыентык чыгаручы башка каләм ияләренең дә язмаларын укыйсың. Чагыштырып карыйсың... Һәм күптәннән бирле күңелендә җыйнала, туплана килгән фикерләр тагын да ачыграк төс ала бара, тагын да ачыклана төшә. Чын шигърият өчен иң мөһим сыйфатларның берсе — эчкерсезлек икәнен әнә шул вакыт нык итеп күңеленә беркетәсең...

Шулай итеп, эчкерсезлек... Менә мин дә хәзер үзем белгән берничә шагыйрь шәхесен күз алдына китерәм. Тик аларны бер итеп «ул» дип сөйлим... Ул, гади кешеләр ноктасыннан карап әйткәндә, күп чагында уйламыйча да сөйли. Ягъни — «теленә ни килсә, шуны әйтә» була инде бу. Әнә шул сәбәпле, сөйләшкән чагында ул күпләрне үпкәләтә дә, үз башына байтак кына кайгы һәм бәла да ала... Әйткән сүзләре өчен еш кына очракта үкенгәләп тә куйгалый...

Ләкин бит, игътибар беләнрәк карасак, аның нәкъ әнә шушы сыйфаты чын шагыйрь натурасы турында сөйли! Чын шагыйрьлек турында: димәк, яшәешнең **б е р  с и з г е р  җ а н ы** булуы турында!

Әнә шул сизгер җан кулына каләм алса, инде аның эчендә кайнаган барча хис-кичерешләр кәгазьгә түгелә. Әйе, әйе — нәкъ менә түгелә! Язын боздан арынып ташыган елга кебек, тау битеннән шаулап агып ятучы чишмә кебек — әнә шундый гаять тә табигый бер яшәеш, табигый бер халәттә түгелә ул. Һәм иҗатның иң төп үзенчәлеге дә, әлеге сизгер җанның иҗат һәм әдәбият өчен бөтен кыйммәте, бәһасе дә әлеге **т ү г е л ү** халәтенә кайтып кала түгелме? Шулай: Җанның ташып түгелә алуы — чын иҗат, чын шигърият өчен иң-иң мөһим хасият! Бу инде иҗатның үзенә аерым бер яшәү көче, тормыш көче алуы дигән сүз! Аерым бер стихия туу дигән сүз бу! Нәкъ Фәнис Яруллиндагы кебек:

*Язгы елга бозын каерып аткан сыман,*
*Җитез юрга йөгән салып чапкан сыман,*
*Кара болыт яңгыр булып аккан сыман —*
*Бер бушанып калсаң иде барысыннан...*

Күрәсезме, чын иҗади халәт никадәр дөрес итеп әйтеп бирелгән биредә! Тормыш-

ның яшәүнең үз көчләрен, үз омтылышларын тыймау, ә киресенчә, шуларга нигезләнү, шуларга ышану бирелә. Димәк, кешенең, шагыйрь шәхесенең үзендәге эчке, табигый омтылышларны да тыймау, аларны йөгәнләмәү дигән сүз бу. Үз эчендәге эчке омтылышны туктату — ул язгы елганы тыю, җитез юрганы йөгәнләү, кара болытны янгыр итеп яудырмау дигән сүз!

Әйе, акыл дигән хөкемдар киртә итеп куелмаса, тормыш һәм хисләр үз стихияләре белән тула, ташый башлый. Безнең күңелләрдә объектив рәвештә яши торган, ләкин акыл тарафыннан әле аңланып бетмәгән бик күп халәтләр, рухи нечкә күренешләр әнә шул чакларда үзләренә иркен яшәеш алалар. Бу очракларда музыка кораллары алиһәсе скрипка гына тудыра ала торган гаять нечкә, гаять тиреннән килүче моң, көй, аһәң агыла. Акыл белән уйлап утыра калсаң, акыл белән үлчи калсаң — боларның бик күбесе уләчәк янсә бөтенләй башка тормыш алачак. Болар — чын шигъри күңелләрдә бары тик зур илһам килгән чагында гына ачыла торган ташкын хис халәтләре. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: «илһам» дигән сүзне, ничектер, рациональ шагыйрьләргә карата кулланып та булмый сыман. Алар теләсә кайчан утырып, теләсә нәрсә турында «Шигырь» яза аладыр сыман... Ә сез чын шагыйрьләрнең илһам килгән чакларын карагыз: алар үзләре — тоташлары белән, бөтен барлыклары белән — моңга әверелеп бетәләр бит! Җырлаучы бер табигый затка әверелеп бетә алар. Әнә шундый сихри минутларда инде җирләр белән күкләр тоташа, кешенең яшәеше гаять та киңәя, көчәя. Яшәү үзе бөек бер хикмәт булып чәчәк ата! Менә шундый чаклар инде чынлап та «бөек мизгел» дип атала. Әнә шундый бөек мизгелләр инде кешенең һәм кешелекнең йөрәгенә озакка уелып кала.

Сизгер һәм гаять нечкә күңелле шагыйрь Фәнис Яруллин да әнә шундый бөек халәтләр аша дөньяның, яшәешнең олы эчтәлеген ача.

*Һичбер вакыт*
*Төшми камыт*
*Эш атыннан.*
*Сөрә ул җир*
*Тамганчы тир*
*Камытыннан.*

*Көтми мактау,*
*Тән булса сау,*
*Юлда алар.*

*Кайда күбрәк*
*Җигелү кирәк —*
*Шунда алар.*

*Мин дә шулай*
*Эш атыдай, —*
*Көтмимен дан.*
*Тормыш мине*
*Аермасын*
*Йөк тартудан.*
*Йөк тартудан!*

Инде 1968 елда ук Фәнис Яруллин әнә шулай дип язган.

Эш аты... Безнең холыкка, безнең милли психологиягә ничек нык туры килә бу образ? Билгеле, соңгы елларда аның әйбәт мәгънәсе бераз бүтәнчәрәк төсмерләр белән дә баеды. Халыкның күп һәм тырышып эшләве, ә тиешеннән азрак алуы игътибар үзәгенә куела башлады. Шул уңайдан яшьрәк буын шагыйре Нияз Акмаловның «Абзар баганасына бәйләп куелган ат монологы» да язылды. Менә хәзер кызык кына ситуация килеп чыга түгелме? Ф. Яруллинның 1968 елда иҗат ителгән әлеге шигыре белән Н. Акмалов әсәре үзара каршылыкка кермиме?

Бернидән шикләнмичә әйтергә була: шигырьләрнең икесе дә дөрес, икесе дә тормыш хакыйкатен чагылдыра. Ә ничек итеп? Эш шунда — Н. Акмалов социаль гаделсезлек турында сүз алып бара, кайберәүләрнең — «кайбер «атлар»ның гел бәйрәмдә йөрүләрен, бәхетлерәк, матуррак яшәүләрен әйтә. Баганага бәйләнгән эш атының кызганыч хәлен сурәтли, аңа карата да гадел булырга чакыра. Ф. Яруллин исә шигырендә безнең халыкның иң күркәм сыйфаты булган эшчәнлекне мактый. Үзендә дә шул сыйфат булу белән горурлана, үзенең ныклыгын шунда күрә. Бу — һичшиксез, яхшы һәм урынлы хис. Хезмәт җимешен дөрес бүлү исә җәмгыять күләмендә гадел рәвештә хәл ителергә тиеш... Ләкин хезмәт сөю хисе безгә, барыбер, теләсә генә нишләсәк тә кирәк. Безгә, безнең милләткә, хезмәттән башка берничек тә рәхәт тормыш төзү мөмкин түгел. Шуңа күрә шагыйрь Фәнис Яруллин моннан берничә дистә ел элек язган әлеге шигырьнең эчтәлеге һич тә искерми. Ул беркайчан да искермәячәк тә, чөнки тормышның үзәге — эш кешесе!

Гомумән, шагыйрь иҗатының беренче елларында ук әнә шундый сүнмәс, тоныкланмас хакыйкатьләргә таянган булуын күрәсең. Менә мисал өчен 1969 елда иҗат ителгән тагын бер әсәр.

*Кайчак кешенең*
*Кара урманда*
*Сүнә дә уты,*
*Кабат ягарга*
*Җитми аңарга*
*Бары бер шырпы.*

*Ялкын итәргә*
*Ялгыз юлчының*
*Сүнгән күмерен,*
*Шул соңгы шырпы*
*Булса иде дим*
*Минем шигырем.*

Күргәнебезчә, шагыйрьнең яшьлек хыялы да юлчыларның учагы, ялкыны булу. Һәм без бүген, әлеге шигырь язылганга инде байтак еллар үткәннән соң, ул хыял чынга ашкан дип әйтә алабыз. Әйткәнебезчә, Фәнис Яруллинның бүгенге көндә үз укучыларына бүләк иткән егерме китабы бар. 1978 елда аңа республика комсомолының Муса Җәлил исемендәге олы бүләге бирелде. Кыскасы, ул хәзер укучыларның иң яраткан шагыйрьләреннән берсенә әверелде.

Шигырьлəрдəн иң яхшылары ниндилəр соң?

1988 елда «Шигырь китапханəсе» сериясендə басылган китабын автор үзе биш бүлеккə бүлгəн. Андагы мəхəббəт шигырьлəре дə күңел түренə үтə, шаян əсəрлəре дə елмайта һəм көлдерə. Əмма, шулай да, шагыйрьнең иң-иң уңышлы, иң-иң əйбəт əсəрлəре: яшəү һəм язмыш хакындагы тирəн фəлсəфи лирика белəн сугарылган шигырьлəре. Аларның күбесе «Ил язмышы — ир язмышы» дип бик дөрес исемлəнгəн беренче бүлеккə тупланганнар.

*Бер снаряд чокырына*
*Төшми дилəр икенчесе.*
*Төшə икəн, төшə икəн*
*Төшə тагын да көчлесе.*

*Туры төбəп дошман уты*
*Бер урынга бирə генə, —*
*Төшə бөтен снарядны*
*Теткəлəнгəн йөрəгемə.*

Шигырь сугыш кырында язылган төсле. «Дошман», «снаряд чокыры» дигəн тəкъбирлəр ул тойгыны тагын да көчəйтə. Əнə шуңа күрə, моның ише шигырьлəрне укыганда, аларны язган кешенең дə ир-егетлегенə ышанасың. Анда ир булырга тырышып көчəнү түгел, ə чын ир затының яшəве, көрəше күренə.

Чын ирлəр кулы белəн язылган мондый əсəрлəр безне гадəти битарафлыктан арындыра, йөрəктəге көнкүреш тузанын кага. Халык өчен, гаделлек өчен көрəшүче солдат алгы сызыкка чыккан кебек була. Шигырьне укыганда без дə үзебездə рухи көч арта төшүен сизəбез. Инертлыкка каршы тору хəлəте көчəйгəнен тоябыз. Ə ныклап карасак — бу бит һəр чорда сирəк кенə булса да очрый торган чын ирлəр, чын егетлəр йөрəге икəн! Шигырьлəрдə əнə шундый йөрəк яши!

Чын шагыйрьлəрнең шигъри йөрəклəренə дə ныклык һəм көч миллəт йөрəгеннəн, аның яшəешеннəн, табигатьтəн килə. Фəнис Яруллин поэзиясендə бу көчнең чыганагы бик ачык күренə.

*Болыннарга чыксам, бер ашкыну*
*Билəп ала җанны:*
*Йөрəгемдə минем япь-яшь егет*
*Тук-тук түки чалгы.*

*Кешни-кешни тайлар чабып уза,*
*Дəртле, ярсу тайлар.*
*Якын барсаң, кабынып китəрсең күк —*
*Сулышлары кайнар.*

*Иңнəремə тырмаларын салып,*
*Кызлар килə каршы.*
*Бəхет чүмəлəсен синең белəн*
*Кояр икəн кайсы?*

*Мəхəббəттəй балкып, кайнарланып*
*Кояш яна күктə.*
*Гомер кебек, сиздермичə генə*
*Елга ага читтə.*

*Чүмəлəлəр — болын күкрəклəре*
*Шундый тыгыз, күркəм.*
*Шул күкрəккə кайнар битеп куеп,*
*Туктап яллар итəм.*

*Бер нəрсə дə ялган түгел монда,*
*Бик табигый бар да.*
*Шатлыкларым кибəн булып өелə*
*Яшел болыннарда.*

Бу шигырьгə гүяки туган җир үзенең бөтен көче, сихəте, тылсымы белəн сыйган — ул анда тере бер гүзəллек булып яшəп ята. Карагыз əле нинди куəтле тамырлар анда: һəммəсеннəн җан иясенə яшəү суты, яшəү көче агыла! Шагыйрьнең бик күп əсəрлəрендə шулай — аларда табигый, халыкчан хис бик тə күңелгə якын рəвештə җиткерелə, үткəрелə. Мисал өчен, туган җиргə тартылу, аны сагыну идеясе «Көнбагыш» исемле шигырьдə болай гəүдəлəнə:

*Инде менə күзгə күренеп*
*Җитлегə-тулышасың.*
*Җитлеккəн саен җиргə син*
*Ныграк елышасың.*

Безнең бəрəңге бакчабызда үсə торган шушы гади генə, лəкин бик тə шигъри үсемлек — көнбагыш аркылы олы фикер белдерелə түгелме? Яшьлектə югарыга, каядыр өскə омтылу, ə инде үсə, олыгая барган саен акыл кереп, тəҗрибə туплангач — иң зур бəхетнең бары тик җирдə генə икəнен аңлау, шуңа төшенү процессы матур гəүдəлəнə еклекнең бары тик җирдə генə икəнен аңлау, шуңа төшенү процессы матур гəүдəлəнə түгелме биреда? Əйе, мондый зур хакыйкатьлəр алар аерым шəхес өчен мөһим фəлсəфи баскыч булып тора. Ə инде шагыйрь өчен бу — иҗаттагы олы юл дигəн сүз. Олы адиплəр атлый торган юл бу!

Шигырьлəрдə чагылган лирик герой да безнең үзебезнең туган җирдə үсеп нығыган кеше. Шуңа күрə аның бөеклеге дə ташлар кыяфəте белəн белдерелə торган җансыз һəм салкын бөеклек түгел. Ул — тере, гади кешенең бөтен катлаулы халəтен үзенə туплаган, сыйдырган шəхес. Əлеге сыйфат шагыйрьнең «Китеп барам» исемле бер шигырендə бигрəк тə ачык тасвирлана:

*Гомер агачымның яфраклары*
*Коелып бетеп бара, мин белəм.*
*Калганнары өзелəм-өзелəм диеп*
*Тартышалар əнə җил белəн.*

*Тик шулай да җанда үкенечлəр юк,*
*Анда бары якты моң гына.*
*Китеп барам офыкларга таба*
*Сиздермичə генə, тын гына.*

*Сыкранулар, уфтанулар нигә?*
*Яшәлсе инде яшәлгән.*
*Гомер агачымның яфраклары*
*Туып үскән җиргә төшәлгән.*

*Шуннан артык нәрсә кирәк безгә?*
*Шул бит инде яшәү максаты.*
*Соңгы яфракларым тибри җилдә,*
*Ә күңелдә никтер яп-якты.*

Шигырьдә тормыш белән саубуллашуның җанны өшетә торган нечкә, моңлы аһәңнәре дә ишетелеп ала... Ләкин аңа караганда шунысы мөһимрәк: барыбызга да килә торган әлеге кырыс хакыйкатьне шагыйрь «яфраклар коелып бетә...» дип аңлаткач, үлем дә фаҗига булып кабул ителми, ә табигый бер күренеш сыман күренә. Ә тагын да мөһимрәге: яшәү дәверендә үстерелгән яшел яфраклар, гомер бизәкләре, гомер байлыклары — барысы да туып үскән җиргә төшәлгән! Нинди матур чагыштыру, нинди бай мәгънә! Кешенең туган җиргә хезмәт итүе бик тә тирән итеп әйтеп бирелгән.

Биредә без шагыйрь каләменнән төшкән кыска шигырьләр турында берничә сүз әйтеп китмәсәк, һич тә гадел булмас иде. Чөнки Ф. Яруллинның күңел хәзинәсен чагылдыручы байтак кына шигъри энҗеләр нәкъ әнә шул кыска шигырьләрдә тупланган. Шагыйрь аларны үз иҗатының төрле чорында, төрле дәвердә язган, ләкин аларның барысы да диярлек бер үзенчәлеккә ия — ялкын теле сыман кайнар алар! Бер генә строфалы бу шигырьләр! Менә берсе:

*Әллә күзләр артык тиз җитте,*
*Әллә яшьлек артык тиз үтте.*
*Утын күрдем — җылысын сизмәдем,*
*Болынын күрдем — гөлен өзмәдем.*

Хәзер инде диалог рәвешендә тезелгән кыска әсәрләрдән тагын берсенә күз салып үтик:

— *Кешегә кайчан акыл керә башлый?*
— *Үзенең акылсызлыгын аңлаган көннән.*
— *Кешедән кайчан акыл чыга башлый?*
— *Үзен иң-иң акыллыга санаган көннән.*

Мисалга китерелгән шигырьләрнең беренчесе үзендәге үзәкләрне өзәрдәй хисе белән безгә нык тәэсир итсә, икенчесе исә кешелек өчен һәрчак актуаль булып торган мәгънәсе белән истә кала. Һәр икесе кыска күләм белән тәгалләнгән, нәкъ менә үзенә кирәкле кысаны, рәвешне тапкан.

Шагыйрь Фәнис Яруллинның өлгереп җитмәгән шигырьләре дә бармы соң? Аның иҗатына никадәр генә соклансак та, биредә мондый сорауны да куймыйча узып китү мөмкин түгел. Һәм җавап та бирергә кирәк: әлбәттә, андый әсәрләр бар! Дөресен генә әйткәндә, андый шигырьләр, андый әсәрләр һәрбер шагыйрьдә, һәрбер әдиптә була. Ләкин эш — аларның нинди өлеш тәшкил итүендә. Азмы алар, әллә бик күпме?

Фәнис Яруллинда, һичшиксез, көчле хискә корылган, сәнгатьчә тәмамланган әсәрләр өстенлек итә. Әнә шундый шигырьләр безнең каршыда чын шагыйрь басып торуына ныклап ышандыра. Ләкин «яшелрәк» булып калган әсәрләр хакында да сүз әйтми китү мөмкин түгел. Алар нинди ләр соң?

*Тик бер нәрсә истә яхшы калган,*
*Онытмыймын һаман бер көнне:*
*Ильич уты керде авылыбызга*
*Почмак саен якты бөркелде.*

1970 елда язылган бу шигырь дә, әлбәттә, ихлас әсәр. Без шагыйрьнең чын куанычын аңлыйбыз, аңа кушылабыз. Ләкин, шул ук вакытта, бу әсәрнең башкалар янәшәсендә торганда тоныкк иканен дә шәйлибез. Эш нәрсәдә соң? Юк, эш Ильич утында гына түгел. Сер тирәндәрәк: шигырьгә нигез итеп алынган вакыйга үзе мәгънә ягыннан тар, поэтик эчтәлеккә ия түгел. Димәк, анда чын мәгънәсендә образлы фикер юк.

Мондый әсәрләр шагыйрьнең элеккерәк елларда басылган китапларында очраштыргалый. Сыйнфый дошманнарга отпор бирергә чакырганнары да бар. Билгеле, мондый аң ул чагында һәммәбезгә тәэсир итте. Шагыйрь дә үз чорының баласы иде. Аннан ул да азат була алмаган. Ә шулай да, азат булса — хәзер без аны тагын да ныграк мактар идек!

Кайчак Ф. Яруллин иҗатында үгет-нәсихәткә корылган әсәрләр дә очрап-очрап китә. Мисалга менә моның ишеләр:

*Кешелексезлек чиреннән*
*Безне соң кем дәвалар?*

яки:

*Яшәү шундый җиңел булыр иде*
*Һәркем әгәр башка бераүнең дә*
*Кеше икәнлеген аңласа...*

Моның ише әсәрләр шагыйрьнең башлангыч чор иҗатында гына очрый. Соңгы ел-

ларда инде андыйлар бөтенләй үк күренми. Шагыйрь бары тирән хисле, кайнар рухлы шигырьләрен генә юлга чыгара. Ул кайнар хистән башка шигърият була алмавын хәзер инде бик тә яхшы аңлаган. Үзенең бер шигырендә бу фикерен ул болай дип белдерә:

*Керəп китсәм шигърияткә,*
*Булам шундый халәттә:*
*Гүя ташлап барсын, кайтам*
*Беренче мәхәббәткә.*

Чыннан да, шагыйрь Фәнис Яруллин иҗаттагы Илһам биеклегенә торган саен югарырак күтәрелә бара. Хәтта инде меңләгән иҗатчы тарафыннан язылган мәхәббәт темасы да аның шигырьләрендә өр-яңа йолдызлар булып кабынып китә, бөтенләй яңача балкыш ала. Менә мисал өчен аның «Казан утлары» журналында 1988 һәм 1989 елларда дөнья күргән шигырь бәйләмнәренә тукталыйк. «Яратып бер кара әле күзләремә...» дип башланып китә торган әсәрнең икенче строфасы болай дәвам итә:

*Күзләремнең озын, салкын кичләрендә*
*Соңгы күмер сүнгән чакта мичләремдә,*
*Шушы уттан бәлки җылы алырмын да*
*Бер талпынып куярмын мин хисләремдә.*

Тормышның тирән каршылыклы бер мизгеле сыйган бу кыска гына шигырьгә! Бер яктан — күз, салкын кич, соңгы күмер... Болар укучы күңелендә никадәр трагик кичереш тудыра. Ә икенче яктан хәтергә сеңеп калган бер якты караш... Мәхәббәт утының чагылышы булган бер... тере ялкын. Ләкин шагыйрь алга таба без уйлаганча көчле ут кабынды дип дәвам итми. Кырыс чынлык бүтән:

*Кабына алмам, табына алмам, белəм аңсын,*
*Йодрык кадәр йөрәк тагын күпме янсын?*
*Ә шулай да иң ахыргы җырым өчен*
*Күкрәгемдә бер булса да очкын калсын.*

Менә шундый тормыш хакыйкате. Менә шушындый чын, тирән, ихлас кичереш. Поэзия өчен — чын халыкчан шигърият өчен тагын ни кирәк соң инде?!

Журнал битендә узган ел дөнья күргән «Күрәшләрдә биләр чыдарлык» циклы да Фәнис Яруллин өчен зур бер җиңү буларак бәяләнергә тиеш. Алар барысы да чын шигърият җимешләре. Замананың җитди һәм яңача ачылган хисләре анда. Үзенчәлекле һәм зур шәхес яшәве бар анда. Хатын-кызга багышлап язылган бер шигыре аша автор үзе дә матур яктан истә кала:

*Матурлап, чистартып, агартып*
*Үтәләр гел шулай көннәрең.*
*Аклыкка, пакьлеккә куанып,*
*Җилләрдә җилферди керләрең.*

*Әгәр дә бер әмәл тапсалар*
*Керләнгән җаннарны юарга, —*
*Шикләнми тоттырыр идем мин*
*Аларны тик синең кулларга, —*
*Юарга, юарга, юарга.*

Шуңа охшаш күп кенә яңа әсәрләре белән Фәнис Яруллин мәхәббәт темасына язучы байтак кына яшь шагыйрьләрне дә узды дияргә мөмкин. Йөрәктә яшьлек хисенең, рухи көченең зур булуы әнә шулай бәйгеләрдә алгы сафта йөртә аны.

Юк әле, бер мәхәббәт темасында гына алдынгы түгел шагыйрь. Узган елгы бәйләмдә менә мондый гаять акыллы юллар да бар:

*Яхшы атка камчы кирәк түгел,*
*Ул болай да чаба егылганчы.*
*Тик тормышта начар аттан бигрәк*
*Яхшы атка төшә күбрәк камчы.*

Шулай итеп, Фәнис Яруллинның бөтен иҗатында да чын әдипләргә хас булган асыл сыйфатлар тантана итә. Ул сыйфатлар аның олы шәхес икәнлегенә ышандыра.

## Китап күзәтү

# ЗАТЛЫЛЫК

Без, әгәр шулай әйтү яраса, инкяр итүләр чорына килеп кердек. Электән урнашып катып калган карашлар, карарлар, принциплар җимерелә, бер дә какшамас кебек тоелган, гасырларда яшәр сыман булып, лозунгка әверелгән купшы вәгъдә-ышандырулар сына, ватыла, ишелә. Тарихыбызны ялган чүп-чарлардан арындыру бара. Әдәбиятыбызга да яңача бәяләү таләп ителә. Бу хәрәкәт кискен, рәхимсез, аяусыз булырга охшаган. Әле кайчан гына: «Аһ, нинди актуаль!» — дип мәдхия укылган калын-калын роман-повестьлар, су буедай озын поэмалар «көннең кадагы»на сугып бетерергә дә өлгермичә, бик тиз искерәләр. Күпмедер дәрәҗәдә аяныч, әлбәттә. Ләкин ялган баллы, тыныч, тымызык үткәнне кырыс, ачы хакыйкать чоры алмаштырганда бу — котылгысыз хәл.

Әнә шул басылып чыккан көненнән онытылуга дучар ителгән әсәрләрне мактап, аларга фатихасын биреп утыручы әдәби тәнкыйтьнең язмышы тагын да кызганычрак. Шуңа күрә теге яки бу авторның төрле елларда язылган мәкалә-рецензияләрдән гыйбарәт булган җыентыкларының бүгенге укучыда нинди фикер уятачагын сиземләү читен түгел. Мин үзем дә Фәрваз Миңнуллинның «Затлылык»[1] дигән әдәби тәнкыйть мәкаләләр китабын мәгълүм бер сагаю белән кулыма алдым. Бәлки ул кадәр игътибар да итмәс идем, әмма үз вакытында тәнкыйтьченең «Прозаның гражданлык йөзе» (1984) исемле китабындагы татар әдәбияты өчен янып-көеп, авторларның кимлегенә карамый гадел бәясен биргән язмалары уңай тәэсир калдырганнар иде. Бу җыентыкта да әдәбиятыбызның бүгенге хәле, аның киләчәге өчен авторның борчулы хисе сүнмәгән дә, сүрелмәгән дә икәнен күрәсең.

Ф. Миңнуллинның «Затлылык» китабына соңгы 4-5 елда (1984—1989) язылган мәкаләләре кертелгән, димәк, автор, мөмкинлектән файдаланып калыйм дип (китап бит көттереп кенә чыга торган нәрсә) элеккерәк язмаларын урнаштырудан баш тарткан. Бу үзе үк хуплауга лаек сыйфат. Без дә, хөрмәтле укучы, синең белән китап битләренә сәяхәтебезне башлыйк әле.

Китап ике кисәктән булып, «Традицияләр яктылыгында» дигән беренче бүлектә бүгенге татар әдәбиятының гомум проблемаларына багышланган мәкаләләр урын алган. Укучы хәтерлидер, «Казан утлары»ның 1983 елгы 2 санында А. Гыйләҗевның «Тынычлану зарарлы!» исемле мәкаләсеннән соң журнал битләрендә прозабызның хәзерге хәле турында кызу бәхәсләр барган иде. «Реаль хәлләргә күз салыйк» дигән мәкаләсе белән Ф. Миңнуллин әлеге тәнкыйди бәйгегә кушылып китә. Шунысын да әйтим, җыентык нәкъ менә шул мәкалә белән башлана да, бу исә китапның башыннан ахырына кадәр иҗат сафлыгы, әдәби җәүһәрләр өчен көрәш барачагын вәгъдә итә. Һәм укучы, әгәр дә җанына гамьсезлек чире йокмаган булса, авырттырып тешли, чәнчеп ала, бераз гына дуамалланып та куя торган каләмле тәнкыйтьченең борчылып, кайнарланып язган фикерләренә берничек тә битараф калмый.

Ф. Миңнуллин проза өлкәсендә теге әсәр әйбәт, ә монысы алай ук түгел дигән буш бәхәсләшүләр белән булышмыйча, иң әүвәл әдәбиятның үсешен тоткарлаган нәрсәләргә игътибарын юнәлтеп, уйландыра торган нәтиҗәләр ясый. «Татар әдәбияты элек-электән авыл әдәбияты булып килде, — ди автор, — аның бу теманы яктыртуда гасырлар буе туплап килгән бай тәҗрибәсе бар». Әмма соңгы чирек гасыр эчендә Татарстан эре промышленность, гигант төзелешләр, нефть чыгару төбәгенә әверелде. Шуңа мөнәсәбәттә әдәбиятка яңа эчтәлек, яңа геройлар килде. Ләкин производство темасы әдәбиятта иң авырткан урын булып калды һәм кала бирә. Юк, укылмыйлар мондый әсәрләр, никадәр шау-шу килеп маташсак та, бу өлкәдә казаныш дип әйтерлек роман-повестьларны атап булмый. Хикмәт нәрсәдә? Теманы белмәүдәме? Актуаль теманың чабуына асылынып ашыгудамы? Юк, ди тәнкыйтьче, иң төп сәбәп традицияләр аз булуда, тәҗрибә җитмәүдә, дип раслый. Әр-яңа өлкәне үзләштерү акрынлык белән, дистә еллар дәвамында сантиметрлап-миллиметрлап кына бара икәнен әйтә. Тәнкыйтьченең ни кадәр хаклы булуын вакыт үзе күрсәтер.

[1]Миңнуллин Ф. Затлылык. Татарстан китап нәшрияты, 1989 ел.

Бүгенге прозаның сыйфаты хакында уйланганда автор киң колачлы, катлаулы жанр булган романның язмышы белән дә борчыла. 10-12 ел эчендә 30 га якын роман басылганын әйтеп, шактый кырыс нәтиҗәгә килә: «Шуларның кулга тотарлыгы, әдәбиятның уңышы дип санарлыгы берничә генә». Сәбәп нәрсәдә? «Буыннар алмашуында», — ди тәнкыйтьче. Ягъни, өлкән буынга алмашка килгән урта буын язучыларга олы характерлар, эпик киңлек һәм масштаблылык белән эшләү осталыгы җитеп бетмәгәнен әйтә. Нәтиҗәдә, безнең әдәбиятта повесть активлаша һәм нәкъ шушы жанр прозаның үсеш асылын билгели дә инде. Тәнкыйтьче тематик колачы киңәйгән, сюжет-композиция төзелеше төрлеләнгән һәм эчтәлеге, куелган проблемалары ягыннан гаять чуар булган повестьның эчке үзәк сутын тоеп ала алган һәм, нәтиҗәдә, шул актив жанр аша татар прозасының милли үзенчәлеген ачып биргән. Бу үзенчәлек — әхлакый мәсьәләләрнең алгы планда торуы.

Әдәп-әхлак мәсьәләләре XX йөз башы әдәбиятында көчле бер күтәрелешен кичергән иде инде, менә 70-80 елларда яңа эчтәлек, яңа характерлар, яңа проблемалар белән ул тагын заман таләбенә әверелде. М. Мәһдиев, А. Гыйләҗев, Х. Сарьян, В. Нуруллин, Ә. Баянов кебек язучыларыбыз иҗатлары белән әнә шул традицияләрнең өзелми дәвам итүен расладылар. Әхлак мәсьәләләре, мораль кагыйдәләрнең тотрыклыгы ахыр чиктә җәмгыятьнең, кешелекнең яшәү-яшәмәвен дә хәл итә торган көч булып торалар.

Хәзерге көн чәчмә әсәрләрендә уртак төп сыйфатны анык билгеләгән Ф. Миңнуллин, татар прозасындагы аерым тармакларның үзенчәлеге турында сөйләгәндә, бәхәсләшергә урыннар калдыра. Әйтик, «Безнең прозада сугыш темасы» дигән мәкаләдә катлаулы, четерекле бу өлкәнең хәл-торышы турында сүз бара. Авторның язганынча «Ватан сугышының беренче көннәреннән үк татар әдәбияты дошманга каршы гомумхалык көрәшенә кушыла, матур әдәбиятның бөтен тармаклары һәм барлык жанрлары фронт өчен эшли башлый». Сугыштан соң да бу темага багышланган китаплар даими дөнья күрә тора. Шул әсәрләрне анализлап, тәнкыйтьче мондый фикер әйтә: «Татар әдипләре язган барлык әсәрләрнең үзәгеннән аеруча калку һәм көчле булып бер хис сузыла. Ул — Ватанга мәхәббәт, дошманга нәфрәт хисе!» Бу — бөтен совет халкы өчен уртак хис. Дөрес, сугышның милли йөзе юктыр да инде. Әмма минем украин, белорустан аермалы буларак, татар солдатының сугышка үз мөнәсәбәтен күрәсем, беләсем килгән иде. Татарның буыннар дәвамында тупланган һәм үзенә генә хас булган гореф-гадәтләр, карашлар системасы, дөньяны тану, бәяләве нигезендә тәрбияләнгән кешедә уртак фаҗигане хосусый кабул итү ничек? Башка милләт вәкилләре белән уртак яклары нинди дә, аермасы нәрсәдә? Ә бит безнең сугыш чорында күрсәткән каһарманлыклары белән бөтен дөньяга билгеле никадәр геройларыбыз бар! Һәм без хаклы рәвештә горурланып, татарларның 200 гә якын Советлар Союзы герое бар дибез. Ә бит безнең Татарстанга сугыш килмәде, татарлар яши торган күп өлкаләргә фашист аягы басмады. Шул ук вакытта, тулы булмаган мәгълүматларга караганда, Ватан өчен кан койгыч сугышта ярты миллионлап татар егете башын салды. Герой исемен теләсә кемгә генә бирмиләр, илбасарларга каршы сугышның иң алгы сафында безнең этиләребез бардылар. Ә пуля дигәнең әнә шул беренчеләргә тия дә инде. Шуңа күрә дә Ф. Миңнуллинның «авыр елларда явыз һәм мәкерле дошманны җиңгән халкыбызга лаек әсәрләр иҗат итә алганыбыз юк», дигән тирән, ачынулы сүзләрен тыңлап сызланырга гына кала.

Ф. Миңнуллин күп миллионлаган җаннарны алып киткән сугышны, анда катнашучы кешеләрне шомартып, ясалма патриотизм белән сугарып тасвирлауга кискен каршы чыга. Чынлап та, фашист солдатларын нинди генә кыяфәттә сурәтләмәде әдәбият! Алар коточкыч аңгыралар, өстәвенә пычракка баткан бетле мескеннәр дә, алар барып чыккан эчкечеләр, җенси мөнәсәбәттә кешелек сыйфатының тамчысы да калмаган маньяклар, тагын әллә нәрсәләр... Юк, сугыш нинди дер өтек кабилә белән чәкәләшү түгел, ә ике принципның, көч, акыл, белем ягыннан гаять әзерлекле булган ике капма-каршы системаның рәхимсез, ташламасыз бәрелеше иде. Моны сурәтләүдә нигез булып бары тик кырыс чынбарлык, хакыйкать, тормыш чынлыгы гына булырга тиеш. Шул юнәлештән чыгып, тәнкыйтьче Г. Әпсәләмов иҗаты белән Х. Камалов романнарын чагыштыра да, беренчесенең «социалистик реализм» принципларына нигезләнеп язылган норматив әдәбият үрнәге булуын, ә икенчесенең тормыш чынлыгы белән сугарылган әсәрләр икәнлеген раслый.

Китаптагы мәкаләләр төрле темаларны эченә алса да, аларның һәрберсендә әдәбиятның бүгенге торышы, киләчәге өчен борчылу ята. Әдәби җәүһәрләрне кайнарланып яклау, конъюктур әсәрләрне һичбер ташламасыз элеп алып селкеп салу да шуннан килә. Ә бит көнлекче роман-повестьлар заманында күпме купшы мактауларга, премияләргә ия булганнар иде! «Шома-шома егетләр 25-30 ел эчендә татар нефтен әрәмшәрәм итеп бетерделәр дә, күкрәкләренә алтын йолдыз тагып, башка тарафларга китеп бардылар. Без, язучылар, аларның

шул эшләрен мактап, кул чабып торлык... — дип нәфрәтләнә һәм, — матурелгыр егетләр, республика табигатенең иң гүзәл төшләрен тәмам пычратып, гигант заводлар, яңа калалар салдылар да, күкрәкләренә йолдыз тагып алгач, өскәрәк үрмәләделәр. Без, аларны мактап, том-том очерклар, документаль китаплар яздык...» — дип гарьләнә. Йәгез, уйланыйк, чынлап та, экология һәлакәткә килеп җиткән Татарстан фаҗигасенең башында әнә шул төшемле темага чат ябышып, татар халкы яши торган төбәкнең иминлеген даншөһрәт, гонорар-премия акчасына алыштырган кайбер язучылар да тормадыклармы? Адашмадымы укучы? Буталмадыкмы без? Тәнкыйть әнә шулар өчен дә кайгырырга тиеш иде. Үз алдына мескен-өтек таләпләр кую аркасында аяныч хәлгә калды да инде безнең әдәби тәнкыйть. Ф. Миңнуллин дөрес әйтә, җәмгыять тормышында тәнкыйтьченең катнашы булмаган бер генә мәсьәлә дә юк. Һәм була да алмый. Тәнкыйтьчене татар әдәбиятының киләчәге дә, аны укыр кеше тәрбияли торган мәктәпләр дә, китапның сыйфаты да, тиражы да, ахыр килеп, «Габдулла Тукайның «Секреты Корана» исемле китабын кабат бастырырга» әмер биреп утыручы надан бәндәләрне дә борчырга тиеш. Шуңа күрә Ф. Миңнуллин тәнкыйть китапларына да таләпне югары куя. Халыкның рухи байлыгы, иманы, ил язмышы өчен чын-чынлап борчылып, «бугазыңа төер тыгылмый» икән, иң яхшысы, каләмгә тотынмаска куша.

Үзен әдәби тәнкыйтькә багышлаган, яки шул юлда каләм тибрәтергә ниятләүче һәркем өчен ачы сабак, гыйбрәт аша туган киңәш бу.

Һәр мәкаләдә мин авторның борчулы җанын тоям.

«Кичермәсләр безне, кичермәсләр...» исемле мәкаләдә чын сәнгать белән халтураның буталып бетүенә, «дилбегәне үз кулларына» эләктерергә өлгергән карьеристларның әдәбият язмышын хәл итеп утыруларына ачынган тәнкыйтьче, кайнарланып, шул мүкләнгән күренеш-типларны туздырырга алына. Төссез, талантсыз әсәрләрне рәхимсез камчыларга керешкән автор вакыт-вакыт шактый авырттырып, үзагеңә үтәрлек итеп тә әйтә. Ачы каһкаһә белән сугарылган тәнкыйть утына эләккән Х. Хәйруллин, Җ. Рәхимов, Г. Кашапов һ. б. га ходай түземлек бирсен дә, бу әдипләр «тетеп ташланган» романнарының шактый көпшәк булуын танып, иҗатларына таләпчәнлекне арттыра төшсеннәр иде.

Әмма Ф. Миңнуллин кайвакыт ачынып, эмоциягә бирелеп каударлана башлаганда, үз-үзенә каршы килә торган нәтиҗәләр дә ясап куя. Әйтик, урта кул язучыларны бер «пыр туздырып» алганнан соң ул Ә. Еники, Г. Бәширов, М. Мәһдиев, М. Юныс исемнәрен атаганда җиңел сулап куя (шөкер, ярый әле алар бар!) һәм, тәмам тынычланып, прозабыз өчен сабыр гына сөенеп ала: «Сыйфат ягыннан караганда исә көндәлә өмет уятырдай күренешләрнең, заманчарак тенденцияләрнең көчәя баруы шатландыра». Ләкин бераздан тагын «кызып» китә дә, шушы фикерен инкяр итеп, «соңгы 10-15 ел вакыт эчендә безнең проза сыйфат ягыннан тагын да түбән төште» дип нәтиҗә ясый да куя. Йө инде, алай ук ярамас бит. Прозабызны Ә. Еники, М. Мәһдиевләр күтәргән биеклектә кабул итәргә әзер Ф. Бәйрәмова, М. Галиев кебек менә дигән язучыларыбыз килде әдәбиятка. Бу инде, һичшиксез, безнең прозабызның киләчәге өметле дигән сүз.

Хәер, китап авторының ачынулы-үртәнүле-нәфрәтле хәлен аңлау кыен түгел. Чөнки Фәрваз Миңнуллин — күп еллар буе өметләнеп яшәгән илле яшьлекләр буыныннан. «Бүген килеп җитәр, иртәгә килеп җитәр дип, коммунизм көттек,— дип яза ул. — Без көткән гадел җәмгыять һаман күренмәде. Хыялыбыз тормышка ашмады. Экономик, экологик, социаль мәсьәләләр, ниһаять, милли мәсьәләләр көннән-көн кискенләшә барды. Нигә шулай килеп чыкты? Без кайда ялгыштык? Без кайчан ялгыштык?» Гомер дигәнең бер генә бирелә... Автор инде икенче кат алданырга теләми. Шуңа күрә үткән, киеренке мәсьәләләрне сыйпап-шомартып, сикереп яисә урап узарга азапланган әсәрләргә карата аның карашы кырыс та, урыны-урыны белән рәхимсез дә.

Хуш, тәнкыйтьченең кыл иләге аша кемнәр генә уза алганнар соң? Китапның «Затлылык» дигән бүлеге, исеменнән үк аңлашылганча, шуларга багышланган. Биредә аерым язучыларның (Г. Ибраһимов, И. Гази, Ә. Еники, М. Юныс, Н. Фәттах һ. б.) иҗатлары хакында сөйләнә. Бүлекнең Г. Ибраһимовка багышланган мәкалә белән ачылуы очраклы түгел. Татар совет прозасының башында Г. Ибраһимов тора. Дөрес, 20 нче елларда кызыклы роман-повестьлар иҗат иткән башка язучыларыбыз да бар безнең, ләкин беренчелек, бәхәссез, Ибраһимовта. Ул башка өлкәләрдә дә (әдәби тәнкыйть, тел белеме, тарих, җәмәгать эше һ. б.) беренче булырга омтылган. Ф. Миңнуллин аңа узаманлык хас дип әйтә. Бу минем өчен яңа фикер һәм ул әдипнең характерын, иҗат принципларын ачык күз алдына китерергә ярдәм итә.

«Кайчакларда Галимҗан Ибраһимов күз алдына революция солдаты булып түгел, ә бәлки аның корбаны булып килеп баса»,— ди тәнкыйтьче. Уйландыра торган фикер. Революция солдаты Г. Ибраһимов һәм революция корбаны Г. Ибраһимов... «Безнең көннәр», «Кызыл чәчәкләр», «Ти-

рән тамырлар»да бөтен каршылыгына, киеренкелегенә, кискенлегенә сурәтләнгән сыйнфый көрәш ахыр чиктә совет эшенә жаны-тәне белән бирелгән, хезмәт иткән тугрылыклы солдатын да үз корбанына әйләндерде түгелме соң? Һәм ахыр чиктә, язучы үзе үк үз һәлакәтен дә якынайтмадымы?

Күрәсең, безгә Галимҗан Ибраһимовны ачарга да ачарга икән әле...

Хак: Ибраһимов иҗат мәйданында беренче иде һәм аннан соң әдәбиятка килгән Ә. Еники, Г. Бәширов, И. Газилар аның көчле йогынтысында чын талант булып житештеләр.

Китапта Әмирхан Еники турындагы мәкалә үзгә бер җылылык һәм соклану хисе белән язылган. «Күздән яшь китерә, бәгырьне телгәли аның әсәрләре... — ди автор. — Гүяки алар каләмне язу карасына түгел, ә бәлки хискә-моңга-сагышка манып язылганнар. Аның әсәрләрендә, моң-сагыш белән бергә, сине сафландыра һәм пакьләндерә торган, сине баета, зур эшләргә дәртләндерә һәм канатландыра торган рухи көч тә бар...» Тәнкыйтьче Ә. Еники иҗатының төп үзенчәлеге итеп әнә шул нәфислектән, сүзсез моңнан, якты сагыштан үсеп чыккан «затлылык» сыйфатын атый. Ф. Миңнуллин туган ил, туган җиргә, халыкның үткәненә, аның гореф-гадәтләренә, изге йолаларына тугрылыклы калган язучының әсәрләрен кичке шәфәкътәй үзгә бер моң белән сугарылган иҗат дип бәяли. Кичке шәфәкъ... Вакытның акыл чәчә торган, күңелгә, уйга гамь тула торган мизгеле бу. Чынлап та, җаныңны кая куярга белми бәргәләнгәндә Ә. Еникигә мөрәҗәгать итәсең.

Ф. Миңнуллин Ә. Еники хакында яратып, сокланып, рәхәтләнеп яза. Гомумән, китапның беренче бүлегендә без ачулы, ачынулы, кешенең кемлегенә, урынына-урындыгына карамый йөзенә бәреп әйтә торган тәнкыйтьче белән очрашсак, икенче бүлектә исә, әдәбиятыбызның асыл талантлары турында сөйләүче, матурлыкка, батырлыкка дан җырлаучы зәвыкъле каләм язмаларын күрәбез. Бу бүлеккә кергән мәкаләләр, иҗатны анализлаудан бигрәк, язучы турында язылган кыйссаларны хәтерләтәләр. Ф. Миңнуллин әдәбият дөньясындагы энҗе бөртекләрен таш, балчык, ләм эченнән аралап, аларны бар матурлыгында, бар затлылыгында укучыга күрсәтә белә. Затлылар турында затлы итеп сөйли ала ул...

**Фәрит БӘШИРОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

**Йолдыз Мөхәммәтшин,**
тарих фәннәре кандидаты.

# КЕРӘШЕН ТАТАРЛАРЫ ТУРЫНДА

Татар этносы тармагының зур этнографик бүленешләре арасында, мәгълүм булганча, кечерәк территориаль төркемнәр дә бар. Шуларның берсе — керәшеннәр.

Үзләренең аерым диннәре, үзенчәлекле гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре, этнографик билгеләре белән нык аерылып торган бу татарларның болай үзгә оешулары кайчан һәм ничек булган соң? Керәшеннәрнең Идел буе татарларыннан аерылып чыгу дәвере XVI гасыр урталары һәм XVII гасырның икенче яртысына — урыс патшасы Явыз Иван тарафыннан Казан ханлыгын басып алу вакытларына туры килә. Дөрес, чыганакларда күрсәтелгәнчә, Казан ханлыгы белән Мәскәү арасындагы сугышлар вакытында әсир төшкән татар сугышчыларын көчләп чукындыру очраклары моңа кадәр дә булгалаган.

XVI—XVII гасыр әдәбияты һәм тарихи мәгълүматларга караганда, чукындырылган татарларга карата төрки халыклар әйтелешендә шул вакытларда «керәшен» атамасы барлыкка килә.

XVIII—XIX гасыр урталарында керәшен татарларны «яңа чукындырылганнар» һәм «элек чукындырылганнар» дип атау киң кулланылыш ала башлый. Беренчеләренә XVIII йөз башларыннан алып һәм соңрак, ә икенчеләре исә бабалары XVI гасыр урталарыннан башлап XVIII гасыр башларына кадәр христианлаштырылган татарлар керә.

Чукындыру процессы чиркәү, миссионерлар тарафыннан алып барыла. Бу — дини нигездә халыклар арасындагы бердәмлекне какшату өчен махсус эшләнә. Шулай ук бу эштә чукындырылган бай катлауларның да роле зур була. 1713 елда 2000 татар феодалыннан 100 гә якыны христиан динен кабул итәргә мәҗбүр[1]. 1719 елга, 160 ел буена алып барылган миссионерлык эше нәтиҗәсендә, Урта Идел буе төбәгендә 30 меңгә якын керәшен татарлары булуы мәгълүм. Ләкин дин өлкәсендә шактый гына каршылыклар да барлыкка килә. Казан митрополиты Сильвестрның 1729 елда язган шикаятенә караганда, 170 ел элек чукындырылган татарларда дини тормыш бернигә дә ярамаганлык бәян итә. Чөнки алар чиркәүгә йөрмиләр, урыс телендә сөйләшмиләр, христиан гыйбадәтен башкара белмиләр, балаларын чукындырмыйлар, мәет җирләү кебек йолаларны татарча үткәрәләр. Күпчелеге бары тик җәза бирелүдән куркып кына православие динендә тора, ә мөмкинлек булу белән яңа үз диненә кайта. XIX гасыр башларына 31145 керәшен татарларыннан 13777 кешенең кире мөселманлыкка чыгарга әзер торганлыгы мәгълүм. Мондый күренешләр дәүләтне һәм чиркәүне, билгеле ки, чукындыру сәясәтендә сыгылмалы тактикага күчәргә мәҗбүр итә. Миссионерлар яңадан чукындыру эшләрен җәелдерүне төп максат итеп куймыйча, электә чукынган татарларны христиан дине кысаларында саклап калырга тырышалар. Җирле телне белүче миссионер кадрлар әзерли башлыйлар, җирле телдә христиан дине китаплары бастыралар, чиркәүләр һәм алар каршында мәктәпләр ачалар. Синодның 1804 елгы махсус карары нигезендә, урыс булмаган халыкларны христианлаштыру җирле телдә алып барылырга тиеш була. Бу эшне 1813 елда төзелгән «Библия җәмгыяте» башкара. Җәмгыять күпләп дини китаплар чыгара. Семинарияләрдә, өяз училищеларында татар теле укытуны оештыра.

XIX йөзнең 70 елларда миссионерлар урыслаштыруның Н. И. Ильминский эшләгән яңа методын куллана башлыйлар. Бу метод христиан динен тарату, аны ныгыту эше чукындырылган халыкның үзеннән чыккан миссионерлар, руханилар тарафыннан башка-

[1] История Татарской АССР. Казань, 1968. С. 130 б.

рылудан, китапларны татарча урыс хәрефләре белән бастырып чыгарудан гыйбарәт була. Идел буенда яшәүче халыкларны урыслаштыру һәм христиан динен ныгытуны шул халыкларның үз телләре аша үткәрү — дәүләттән яклау тапкан Ильминский мәсләге. Ул керәшен татарлары өчен урыс хәрефләре белән алфавит төзи, әлифба бастыра, дини мәктәпләр ачтыра.

Әкренләп керәшен татарлар үз телләрендә Библия һәм башка дини әдәбият укырга өйрәнәләр, чиркәүдә гыйбадәт кыла, татар телендә җырлый башлыйлар. Шул ук вакытта яңа язмачылык һәм белем алу көтелмәгән башка нәтиҗәләр дә бирә. Аеруча яшьләр урыс әдәбиятының яхшы үрнәкләре, алдынгы иҗтимагый-сәяси карашлар белән таныша башлый. Бу уңайдан, үзләренең куркуларын белдереп, миссионерлар болай дип яздылар: «Бигрәк тә соңгы вакытта материалистик караштагы әдәбият күбәеп китте, мәктәп белеме исә яшьләргә бу китапларга юл ача».

Өч йөз ел ярым вакыт эчендә үткәрелгән христианлаштыру һәм урыслаштыру сәясәте эзсез генә калмады. Дәүләт һәм миссионерлар элек чукындырылган татарларны христиан динендә калдыруга ирештеләр, шул нигездә аларны татарлардан берникадәр аердылар. Бу мәсьәләдә Февраль һәм Октябрь революцияләреннән соң булган берничә генә мисалга тукталып үтик. 1917 елда «Идел буе вак халыклар җәмгыяте» төзелә. Анда керәшен татар секциясе дә була. Шул ук елның көзендә җәмгыять «Вак халыклар берлеге» итеп үзгәртелә. Бирерәге элекке секция урынына керәшен татарлар җәмгыяте оеша. Җәмгыять кыска гына вакыт эчендә укытучылар семинариясе ачарга өлгерә, газета чыгара башлый, зыялыларны үз тирәсенә берләштерә.

Ул елларда керәшен татарларның бер өлешендә, аеруча клерикаль интеллигенциядә, керәшен татарлар аерым «милләт» дигән фикер оеша һәм ул еш кына бәхәсләр килеп чыгуга сәбәп була.

1919 елда Казанда милләтләр буенча губерна бүлегенең керәшен бүлекчәсе (1920 елда Бөтенсоюз керәшен бүлеге итеп үзгәртелә) керәшеннәрне аерым халык итеп карарга омтыла башлый. Шул ук хәл 1920 елда Бөтенроссия керәшен съездында да кабатлана. Съезд мәдәни-сәяси автономияне яклаучылар һәм татарлар белән якынаерга теләүчеләрне килештерә алмый. 1921 елның март аенда үткәрелгән керәшен коммунистларының өлкә конференциясе, мәдәни-милли автономия төзү РКП(б) программасына каршы килә дип, аны кирәксез таба. 1922 елда керәшен мәсьәләсе өлкә комитеты оештырган махсус комиссия тарафыннан өйрәнелә һәм керәшеннәр белән татарларның нигездә, кушылу мөмкинлеге бар дип таба. Ләкин кушылу югарыдан төшерелгән карарлар белән эшләнергә тиеш түгеллеге дә әйтелә. Моның өчен керәшен гавәмендә әзерлек эшләре алып барырга, алардагы психологик каршылыкларны җимерергә, карагруһчыл идеяләрдән арынырга кирәк була. Шуңа күрә бу максаттан практик эшләр җәя: керәшеннәрнең килеп чыгышы киң яктыртыла, мәктәпләрдә укытуны татар язмасына күчерәләр һәм башкалар. Бу өлкәдә «Киңәш» газетасы да шактый уңай роль уйный.

Дини нигездә ясалма тудырылган аерым «милләт» дигән ялгыш карашлар торабара тотрыклы фикерләр барлыкка килүгә этәргеч була һәм ул вакыты белән кирәксез максатларда файдаланылырга мөмкин. Шуңа күрә боларны ачыклау фәнни планда гына түгел, гамәли яктан да бик зарур. Милли мәсьәләләрдә бары тик хакыйкать кенә бердәнбер таяныч була ала.

Үзгәртеп кору җилләре бүгенге көндә керәшен татарлары хәятенә дә яңалыклар китереп чыгарды. Аның бер нәтиҗәсе буларак, 1989 елның 5 декабрендә Казанның Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында үткәрелгән керәшеннәр этнографиясен һәм халык авыз иҗатын өйрәнүгә багышланган гыйльми конференцияне әйтеп үтәргә кирәк. Бирерә галимнәрнең бу тема буенча ясаган докладлары, төрле төбәкләрдән килгән фольклор группаларының чыгышлары зур кызыксыну уятты.

Шушы елның апрель аенда Татар иҗтимагый үзәге каршында керәшен татарларының этнографик мәдәни-агарту берләшмәсе төзелде.

**Фәридә Шәрифуллина,**
тарих фәннәре кандидаты

# КОСТРОМА ТАТАРЛАРЫ

Кострома шәһәреннән көнчыгыштарак, Кара дип исемләнгән елганың Иделгә койган төбәгендә, татар авылы урнашкан. Ул рәсми яктан, Кострома тау асты Татар бистәсе, дип атала. Кызганыч, аның турында без әлегә бик аз беләбез. Бары тик соңгы елларда гына, бу юлларның авторы тарафыннан тарихи-этнографик тикшеренүләр нәтиҗәсендә, анда яшәүче милләттәшләребез турында кайбер мәгълүматлар тупланды.

Архив материаллары һәм язма чыганакларга караганда, аларның тарихы бик үзенчәлекле. Кострома татарлары күптөрле төрки телле халыклар катнашмасыннан оешкан. Мәсәлән, кайбер гыйльми хезмәтләрдән күренгәнчә (Пирогов В. Материалы для статистики Костромской губернии. 1881), бу кардәшләребезнең бабалары электә әсир ителгән нугайлар булып, Романов каласында (хәзерге Ярослав өлкәсендәге Тутаев шәһәре) яшәгәннәр һәм йомышлылар дип йөртелүләре бәян ителә. Н. М. Карамзин язмаларында Явыз Иванның васыятьнамәсеннән китерелгән текстта моңа нисбәтән шундый юллар бар: «... Иделдәге Романов каласы (аны, улым, нугай морзаларында тот...)».

Мәскәү дәүләтенең 1635—1659 еллар өчен язылган Актларында Романов татарларының патшада хезмәттә торулары һәм моның өчен һәр кешегә 15 әр сум исәбеннән азык-төлек акчасы билгеләнүе язылган.

Романов татарлары, Ярослав һәм Касыймда яшәүче милләттәшләре белән бергә, урыс патшасының хәрби чыгышларында да катнашканнар. Аларның күбесе, мәсәлән, Мөхәммәтовлар, Булатовлар, Билгилдиевлар — морзалар нәселеннән булып, зур җир биләмәләренең хуҗалары булуы мәгълүм. Бу турыда Ленинград Үзәк дәүләт архивында саклана торган документларда яхшы күренә. Әйтик, 1613 елда Сөбшә морза Йосыповка бирелгән кәгазьдә Романов өязенә кергән аның авыллары күрсәтелгән.

XVIII гасыр башларында урыс хакимияте йомышлы татарларның җирбиләүчелеген бетерүгә юнәлдерелгән фәрманнар чыгара. Үзләренең милекләрен саклап калу йөзеннән, күп кенә мөселманнар христиан динен кабул итәргә мәҗбүр булалар. Чукындырылганнарның шактые соңга таба урыс алпавытлары сафына керә. Ә инде чукынудан баш тартучылар Кострома каласы тирәсенә күчерелә. Ләкин әлеге күченү вакытының кайчан икәнлеге төгәл генә билгеле түгел.

Халык телендә «Әби патша» дип йөртелгән Екатерина Икенче аларның тормышын җиңеләйтү өчен кайбер ташламалар ясый. 1767 елда Костромада булган чагында ул, «аларны (Кострома татарларын — Ф. Ш.) чит халыклар итеп исәпләргә мөмкин» дип, воеводага бистә халкының гозерләрен карарга әмер бирә. 1886 елда авылда мәдрәсә ачыла. Бу уку йорты Казанның абруйлы кешесе Апаков акчасына төзелә.

XIX йөзнең азагы — XX йөзнең башларында Костромада татарларның төп шөгыле иген игүдән гыйбарәт була. Алар карамагында 225 дисәтинә сөрү җире һәм 25 дисәтинә чабынлык исәпләнгән. Ләкин игенчелек кенә халыкның көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндереп бетерә алмый башлый. Шунлыктан күпчелек татарлар сәүдә, балыкчылык белән кәсеп итәргә, шәһәрдә ат белән төрле эшләрдә ялланып эшләүгә дә күчәләр. Шулай ук пароходларда эшчеләр арасында да күрергә мөмкин була аларны. Акрынлап шәһәрдә мосафирханәләр тотучы эшлекләләр дә барлыкка килә.

Хатын-кызлар кер җебе кебек вак-төяк әйберләр әзерләү һәм аларны сату белән шөгыльләнгән.

Үткән гасырда урыс миссионеры Н. И. Ильминский Синод оберпрокуроры К. П. Победоносцевка юллаган бер хатында Кострома татарлары турында болай дип язган: «Кострома губернасында яшәүче барлык мөселманнар Кострома шәһәре янындагы зур булмаган бистә белән генә чикләнә. Анда, минем ишетүемчә, татарлар телләре белән бөтенләй диярлек урыслашканнар. Татар телен яртылаш оныткаиннар, бернинди дә мөселманча белемнәре юк. Әгәр дә аларны тормышның үз агымы язмышына куйсаң, берничә дистә елдан соң аларның татарлыкларыннан бары тик томанлы гына бер хатирә калачак».

Урыс арасында яшәүләренә карамастан, Кострома татарлары үз-үзләрен саклап кала алган. 1762 елда алар 128 кеше булсалар, 1811 елда — 204, 1867 елда — 299, 1902 елда исә 525 кешене тәшкил иткәннәр. Бу саннарның арта баруына читтән,

ягъни Казан, Касыйм якларыннан төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә килүче татарларның өстәлүе дә ярдәм иткән, әлбәттә.

Авылда 1880 елларда уртача биш кешедән торган 73 өй була. Өйләр урамның ике ягына тезеп, Идел ярыі буйлап салынган. Авыл уртасында матур агач рәшәткәләр белән әйләндерелеп алынган мәһабәт мәчет күтәрелгән. Көнчыгыш тарафтарак, зур булмаган калкулык артында, бихисап эре агачлар белән капланган каберлек урнашкан. Каберләр таш койма белән уратып алынган.

Иделнең каршы як ярыннан караганда, Татар бистәсе төрле төсләргә буялган өйләре һәм мәчете белән бик хозур бер манзара булган. Хәллерәк кешеләр икешәр катлы кирпеч өйләр төзегәннәр. Шулай ук ак өй һәм кара өйләргә бүленеп йөртелә торган тоташлый салынганнары да була. Ак өйдә, гадәттә, диван-караватр, көзгеләр, йомшак утыргычлар куелган. Уртада мич булган. Стена буйлап, йоклау өчен зур агач сәке, чүпрәк-чапрак ише әйберләрне саклый торган сандыклар, озын кәнәфиләр тезелгән. Өй эчендә кулдан тукылган чаршаулар, чигелгән сөлгеләр, төрле япкычлар эленгән.

Йортта хуҗалык каралты-куралары — мал-туар абзарлары, келәт, карбаз һ.б. корылган. Боларданерактарак, бакчада, ак мунча куелган.

Милли үзенчәлек традицияләре өс киемнәрендә дә сакланган. Ирләр әле 1880 елларда чәчне кырып алдырып, башка түбәтәй, ә урамга чыкканда чүпрәктән тегелгән кырыйсыз эшләпә, өскә киң күлмәк-ыштан, бишмәт кигәннәр. Кыш көннәрендә тун-толыптан, киез итектән йөргәннәр.

Хатын-кызлар исә киң җиңле бизәкле күлмәк, җиңсез тегелгән камзул кигәннәр. Кияүдә булмаганнар болар өстенә янә ак алъяпкыч та бәйләгәннәр. Аякларына ак оек һәм йомшак күн башмаклар, ә бәйрәм көннәрендә чигүле читек кия торган булганнар. Алар чәчләрен ике толымлап үреп йөрткәннәр, башка яулык ябынганнар. Гадәттә, өчпочмак рәвешендә бөкләп, ике яулык бәйләгәннәр: берсе белән ияктән уратып баш түбәсендә, икенчесен җилкәдә төенләп куйганнар. Бәйрәм вакытларында такыялар, калфаклар кия торган булганнар.

Кострома татарлары әзерли торган аш-суда да күптөрле милли үзенчәлекләр күренә. Чәй, катык, әйрән, сөзмә, салма, чумар, боламык, умач, пәрәмәч, катлама, салма, бавырсак һ. б. шуның кебек нигъмәтләр аларның яраткан ашлары булган. Камыр белән итне катлы-катлы аралаштырып чүлмәктә пешерелә торган бәлеш тә традицион ризыклардан саналган.

Кострома татарлары, мөселман буларак, дини бәйрәмнәрне дә җиренә җиткереп билгеләп үткәргәннәр. Янә, кырда, киң болында еш кына күңел ачулар оештырылган.

Кәләш алу, кыз бирүләрне дә мөселман кануннары нигезендә йоласын үтәп башкарганнар. Күпхатынлылык һәм аерылышулар юк дәрәҗәсендә булган. Халык әйтмешли, башлы-күзле булу, гадәттә, егерме яшьтә рөхсәт ителгән.

Дәверләр үтү белән, урыс мохитендә көн итү милләттәшләребезнең рухи һәм матди тормышына кайбер йогынты ясалганын да инкяр итә алмыйбыз. Ул бигрәк тә хәзерге вакытларда ярыйсы ук сизелә...

Бүгенге көндә Кострома татарлары шул ук Татар бистәсендә яшиләр. Аларның гомум саны — ике йөзләп. Инде туган телләрен бөтенләй онытып бетергәннәр диярлек. Тормыш-көнкүрештә гомумшәһәр мәдәнияты элементлары киң таралыш алган. Ләкин милләттәшләребездә гомумтатар мәдәнияты белән кызыксыну бик көчле. Кәләш итеп читтә яшәүче татар кызларын алуны мәгъкуль күрәләр, этник үзаңны сакларга тырышалар.

Милләтебезнең бер өлеше буларак, Кострома татарларының рухи һәм мәдәни мирасы киләчәк буыннар өчен, мотлакан, сакланырга, алга таба һәрьяклап үстерелергә, баетылырга тиеш.

**Рәмзи Вәлиев**

# РЕВОЛЮЦИЯ УЛЫ

Мең тугыз йөз илле алтынчы елның 18 ноябре... Үзәк комитетның партия контроле комитеты җыелышы бара. Биредә 1917 елның март аеннан партия әгъзасы Зәйнулла Хөсәен улы Булушевны аклау эше карала. Төп нотыкчы Филимонов болай дип белдерә: «Х. З. Булушевка карата булган уңай фикерләрне искә алып, парткомиссиянең 1939 ел, 13 октябрь карарына үзгәртү кертергә. Иптәш З. Х. Булушевны 1917 елның март аеннан КПСС әгъзасы дип исәпләргә. 1930 елның февраленнән 1956 елның сентябрь аена кадәрге партия стажындагы өзеклекне гамәлдән чыгарырга. КПССның Ставрополь крае Кисловодск шәһәр комитетына иптәш Булушевка партия документларын бирүне йөкләргә».[1]

Көтүче малаеннан алып партия һәм совет оешмаларының күренекле җитәкчесенә кадәр күтәрелгән Зәйнулла Булушев кем соң ул?

З. Булушев 1886 елда Тамбов губернасы Татарщино авылында крестьян гаиләсендә туган. Башлангыч белемне татар мәктәбендә һәм земство училищесында ала, рус телен үзлегеннән өйрәнә, ә Таганрогта яшәү дәверендә хосусый уку йортында хисап эшләре буенча курслар үтә. Бу вакытларда ул хисапчы белгечлегенең алдагы тормышында һәм эшчәнлегендә мөһим роль уйнаячагын, бәлки, күз алдына да китермәгәндер әле.

1905-07 елларда Зәйнулла Донбасс шахталарында ялланып ат йөртүче, күмер чабучы булып эшли. Бераз үткәч, патша армиясенә алына һәм 66 нчы Бутырск полкында ике ел Польшада солдат хезмәте үтә. Хәрби хезмәт срогын тутырып кайткач, 1909—1917 елларда Юзовка, Чистяковка, Макеевка һәм Горлов-Щербинский районы шахталарында янә күмер чаба.

Ул бик яшьли революцион хәрәкәттә катнаша башлый. Шахталарда эшләгәндә татарлар арасында сәяси үзаңны үстерүдә, интернациональ дуслыкны ныгытуда күп көч куя. Әйтик, 1905 елның гыйнвар аенда Енакиево заводы большевиклары белән ныклы элемтә урнаштырып, алар белән берлектә эш алып бара. Шахтерлар арасында тарату өчен РСДРП Донецк бүлеге Юзовка группасы листовкаларын, стачка материалларын еш кына большевик Петренкодан алып торуы яхшы мәгълүм. Дөресен әйтергә кирәк, бу вакытларда Зәйнулла кайсы партиягә мөнәсәбәтле булу кирәклеге турында ныклап уйланмый. Аны барыннан да элек халык азатлыгы өчен көрәштә мөмкин кадәр күбрәк һәм тулырак эшләргә тырышу мәсьәләләре борчый. Шунысын да әйтик: бу вакытларда, сан ягыннан күпчелекне тәшкил итүне күздә тотып, әгъзалык билетлары урынына гомумязулар белән генә чикләнүче эсер һәм меньшевикларның йогынтысы да шактый була. Шуңа күрә дә З. Булушев һәм аның күп кенә иптәшләренең 1906—1912 елларда формаль яктан эсерлар партиясендә исәпләнүе бер дә гаҗәп түгел. Ул үзе дә бу турыда болай дип язган: «1906—1912 елларда большевиклар, меньшевиклар, эсерлар белән берлектә эшчеләр арасында эш алып барганда, бу партияләрнең карашына һәм программаларына төшенә алмадым. Оештыру күзлегеннән караганда, эсер партиясенә бәйле түгел, аларның әгъзалык билетларын алмадым. Мин эсерлар оешмасы җитәкчеләре белән түгел, ә минем мәсләгемә туры килгән гади эсерлар белән элемтәдә тордым. Алга барган саен, эсерлар белән бер юлда була алмаячагыма инандым». (Күрсәтелгән документ). Табигый ки, З. Булушев февраль революциясенең үсеп баручы вакыйгалары йогынтысында эсерлар партиясеннән читләшә һәм 1917 елның март аенда большевиклар партиясенә керә. Большевиклар партиясе әгъзасы булгач та ул сул эсерлар белән эшлекле элемтәләрен өзми. Аның бу гамәле Ленин куйган большевиклар һәм сул эсерлар блогы турындагы мәсьәләгә бик тә туры килә.

Февраль революциясе тынгысыз татар егете алдына яңадан-яңа бурычлар китереп куя. 1917 елның март-август айларында аның тарафыннан 90.000 эшче-шахтерларны

[1] КПССның Татарстан өлкә комитеты партархивы, 30 ф., 3 тасв., 129 эш.

берләштергән 38 район комитеты төзелә. Таганрог шәһәрендә ул төрки-татар комитетының беренче эшче оешмасын оештыра һәм металлург заводы эшчеләренең гомум җыелышында шушы комитетның инструкторы, рәис урынбасары итеп сайлана.

1917 елның 1-2 май көннәрендә Мәскәүдә Беренче Бөтенроссия мөселман съезды үткәрелә. Анда Зәйнулла Булушев та делегат булып катнаша. Съездда уңнар, эшчеләр мәсьәләсен бөтенләй көн тәртибеннән төшереп калдырырга, дип чыгалар. Биредә бары тик мәдәни-милли характердагы мәсьәләләр генә каралуны сылтау итеп куйган бай һәм муллаларның ныклы таләбе өстенлек ала. Бу һич тә гаҗәп түгел. Чөнки 800 делегатның күпчелеген югары сыйныф вәкилләре тәшкил итә, ә крестьяннар 40-50, эшчеләр 10-15, хәрбиләр 130 кеше генә. Ләкин, шулай булуга карамастан, эшче, крестьян һәм солдат тавышлары көчле яңгырый. Мәсәлән, Кавказдан килгән бер делегат барлык төбәкләрдә дә эшче һәм крестьяннарның мәнфәгатьләре бер үк икәнлеген әйтеп, революцион хәрәкәттә бергәләп, тыгыз элемтәдә торып эш итәргә, үзләренең аерым оешмаларын төзергә чакыра.

«Без, мөселман эшчеләре, сыйнфый көрәштә бер юлдан барырга — социализм юлыннан барырга тиеш. Япония, Германия, Россия, Америка эшчеләренә ни кирәк булса, безгә дә шул кирәк. Алар нинди юл белән барса, без дә шул ук юлдан барачакбыз, безнең маягыбыз — интернационал!» — дип яза «Ирек» газетасы 1917 елның 25 май санында. Эшче делегатлар, зур авырлыклар белән булса да, барыбер эшчеләр мәсьәләсе буенча үзләре тәкъдим иткән түбәндәге резолюцияне кабул иттерәләр: 1) Эш көнен сигез сәгатьтән арттырмаска, сәламәтлек өчен зарарлы урыннарда аннан да кимрәк булырга; 2) Минималь хезмәт хакын закон белән билгеләргә һәм беркемгә дә бу минимумны төшерергә хокук бирмәскә; 3) Эшченең тормышын хуҗалар исәбенә страховать иттерергә; 4) Картлык көндә эшчеләрне гомерлек страхование белән тәэмин итәргә; 5) Атнасына 24 сәгать ял хокукы бирергә, бәйрәм алды көннәрендә җиде сәгать эшләргә; 6) Эшче оешмалар карары нигезендә кирәксез дип табылган урыннарда төнге эшләрне оештырмаска; 16-17 яше тулмаганнар өчен эш күләмен азайтырга; 7) Хатын-кызларны сәламәтлек өчен зарарлы эшләргә җәлеп итмәскә, йөкле хатыннарны бала табарга 4 атна кала, бала тапканнан соң 6 атна эш хакы сакланган хәлдә, эштән азат итәргә; 8) Эшчеләрдән тикшерүчеләр оештырырга; 9) Эш урыннарын сәламәтлеккә зыян китермәслек итеп оештырырга; 10) Хезмәт хакын акчалата һәм һәр шимбә саен түләргә.

1917 елның 17 июлендә Казанда II мөселман съезды ачыла. З. Булушев анда да делегат булып катнаша. Съездда хезмәт ияләре мәнфәгатен кайгыртучы суллар һәм буржуазияне яклаучы уңнар арасында кискен көрәш җәелә. Шулай ук Мәскәү съезды карарлары, платформа мәсьәләләре, Учредительное собрание исемлеге тирәсендә кызу бәхәсләр куба. Формаль яктан уңнар җиңеп чыга. «Аваз» газетасының 1917 елгы 3 саны мәгълүматларына караганда, алар платформасы өчен 60, ә сулларныкына 45 кеше тавыш бирә. Бу хәлнең төп сәбәпләре турында З. Булушев газетаның шул ук елдагы 23 июль санында болай дип язып чыкты: «Мин эшчеләр арасыннан килдем. Бу съездда эшчеләр һәм крестьяннар мәсьәләсе тулырак каралыр, I съезд уңышлары тагын да ныгытылыр, дип уйлаган идем. Съездда 90 эшче һәм крестьян вәкилләре булырга тиеш иде, ләкин алар аз, шуңа күрә дә бу мәсьәлә бары тик гауталар белән генә көн тәртибенә куела». Ул платформаны тикшергәндә кара көчләрнең чын йөзләре ачылганлыгын да билгеләп үтә, башка делегатларны II Бөтенроссия мөселман съездының карарларына каршы чыгарга өнди.

Зәйнулла Булушев съездда составында М. Вахитов, Г. Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, С. Сәлахов, Ш. Әхмәдиев, Гайсин (Финляндия) һәм башкалар булган сул фракциядә була. Съезд эшен тәмамлаганнан соң шундук уңнарга каршы тагын да киңрәк сәяси оешма төзү буенча киңәшмә үткәрелә. Моның өчен Ш. Әхмәдиев (Казан), Г. Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи (Уфа), С. Енгалычев (Саратов), М. Туминов (Мәскәү), Әбдриев (Петроград), Зыя Кадерматов (Сембер), З. Вәлидов (Төркстан), Зәйнулла Булушев (Донбасс өлкәсе), Гайсин (Финляндия) катнашлыгында комиссия сайлана.

Казаннан кайткач, З. Булушев үзенең революцион эшчәнлеген тагын да активлаштыра. Мәсәлән, ул Донецк-Кривой рог өлкәсе эшче татарларның съездын үткәрә. Съездның төп максаты эшчеләр хәрәкәтен берләштерү, урындагы эшче оешмаларын камилләштерү һәм алар белән Россиянең көньягындагы үзәк оешмалар арасында ныклы элемтә урнаштырудан гыйбарәт була. Съезд 1917 елның 12 августында ачыла. Анда завод-фабрикалардан, Лодзовая, Павловка эшчеләр поселокларыннан да бик күп татарлар катнаша. Казанда үткәрелгән II мөселман съезды карарларын тикшерүгә багышланган Нурулла Бикашовның махсус чыгышы тыңлана. Аннан соң Учредительное собраниегә сайлау өчен исемлек төзү мәсьәләсе карала. Шундый сорау килеп туа: мөселманнарны гына тәшкил итүче гомум исемлек кенә төзергәме, әллә берәр партия белән блокка керергәме? Съезд социал-революционерлар белән булуны хуплап чыга. Аннан соң Дон өлкәсендә һәм Екатеринославта Үзәк комитет төзү карала, аның эшчәнлегенең юнәлеше нинди булырга

тиешлегe тикшерелә. Район комитетлары программаларын эзерләгәндә, күпчелек тавыш белән, Мәскәүдә үткәрелгән I Бөтенроссия мөселман съезды карарларын нигез итеп алырга, дигән резолюция кабул ителә. Яңа оештырылган комитет «Көньяк татар Башкарма комитеты» дип атала башлый, ә аның башлыгы итеп Зәйнулла Булушев сайлана.

З. Булушев җитәкчелегендә 1917 елның 25-30 сентябрендә үткәрелгән гадәттән тыш III съезд да зур кызыксыну уята. Ул эшче һәм солдатлар белән берлектә үткәрелүе ягыннан үзенчәлекле. Казанда июль аенда булган мөселман съезды карарларына мөнәсәбәтле резолюция кабул ителә. Съездны оештыруда һәм үткәрүдә Ади Шаһбаров, Абдулла һәм Таһи Шаһбаровлар, Сәгыйть Гыйззәтуллин кебек большевиклар күп көч куя. Ростов шәһәрендә чыгучы вакытлы матбугат бу хәлләрне киң яктырта. Съездда түбәндәге карарлар да кабул ителә: 1) Район комитетлары каршында сугышчан отрядлар оештырырга. 2) Властьны Советларга тапшыруны таләп итәргә. 3) «Рабочие Юга» исемле эшчеләр газетасы чыгара башларга h. б.

З. Булушев 1918 елның 2 сентябрендә Донецк-Кривой рог төбәге Советларының Харьков шәһәрендә булып узган съездында катнаша. Ул анда Россиянең көньягында яшәүче татар эшчеләренең сәяси һәм мәдәни хәлләрен чагылдырган доклад белән чыгыш ясый. Күренекле большевик Артем (Ф. А. Сергеев) З. Булушев белән әңгәмәсендә Көньяк татар Башкарма комитетын Харьковка күчерергә киңәш бирә. Чөнки ул вакытта Россиянең көньягында һәм Дондагы Ростовта хәлләрнең кискенләшүе шуны таләп итә. Мәгълүм июль ае вакыйгаларыннан соң реакция үзенең кара эшләрен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрә. Вакытлы хөкүмәт В. И. Ленинны, большевикларны һәм барлык революцион-демократларны эзәрлекли башлый.

Сентябрь азакларында Көньяк татар Башкарма комитеты Артем һәм Руфимов кебек большевиклар ярдәме белән Харьковка күчерелә. Яңа газетаның мөхәррире итеп С. Гыйззәтуллин тәгаенләнә.

Октябрь коралны күтәрелешеннән соң Донда хәлләр катлауланып китә. Бу эчке контрреволюция һәм немец гаскәрләренең һөҗүм башлавына бәйле. З. Булушев татар эшчеләреннән кызыл гвардия оештыру максаты белән Дон шәһәренә юнәлә. Бу турыда М. Солтангалиев менә нәрсә дип яза: «Иптәш Булушев оештырган отрядның бер үзендә генә дә татар шахтерларыннан торган 6000гә якын кызылгвардияче була».[2]

Тиздән аның үзенә регуляр гаскәрләр сафына басарга туры килә. Аларның частьләре Царицын тирәсендәге сугышларда катнаша. Биредә З. Булушев яралана һәм дәвалану өчен туган якларына озатыла.

Бераз савыгып аякка баса башлагач та ул авылдагы революцион хәрәкәткә кушыла. Контрреволюцион фетнәләрне бастыру һәм Совет властен ныгыту өчен коралны отрядлар төзүдә иптәшләренә зур булышлык күрсәтә. Шул вакытларда Зәйнулла М. Вахитовның милләтләр буенча Халык комиссариатына эшкә чакырып язган хатын ала. Ләкин әле яралары тулысынча төзәлеп бетмәү сәбәпле, ул Мәскәүгә китә алмый кала.

1920 ел башларында З. Булушев партия Үзәк комитеты тарафыннан Донбасска милләтләр буенча Халык Комиссариатына оештыручы-инструктор сыйфатында эшкә җибәрелә. Шулай ук ул анда шахтерларның профессиональ союзларын төзү мәсьәләләрен хәл итү өстендә дә эшли.

1921 елда З. Булушев, үзе сөйләве буенча, В. И. Ленин белән очраша. Бу очрашудан соң ул БҮБК һәм милләтләр буенча Халык Комиссариатының вәкаләтле вәкиле сыйфатында Кырымга җибәрелә.

Соңга табан ул ҮК тарафыннан Татарстанга хокук саклау оешмаларына эшкә күчерелә. Биредә аңа республика прокуроры, хокук саклау буенча Халык комиссары һәм халык хуҗалыгы советы рәисе урынбасары вазыйфаларын башкарырга туры килә. З. Булушев Казандагы кискен хәлләрнең үзәгендә була. Әйтергә кирәк, контрреволюцион «сул уклонистлар»ны фаш итүне таләп итүче мәгълүм «39» документында аның да имзасы бар («Идел».— 1989.— 6 сан.— 29 б.).

1924 елның октябрендә аны Промбанкның Азәрбайҗан конторасы рәисе урынбасары итеп билгелиләр. Аннан соң ул авыл хуҗалыгы банкында, Азәрбайҗан шәрәб эшләү трестында җитәкче була. Монда эшләү дәверендә ул үзен сәләтле һәм компетентлы җитәкче итеп таныта. Мәсәлән, 1927 елда аңа Дагстан шәрәб эшләү комбинатында тикшерү үткәрергә һәм анда үзгәртеп кору бурычларын йөкилиләр. Нәтиҗәдә, бик күп кырын эшләр ачыла.

Аннан соң З. Булушев Кыргызстанга авыл хуҗалыгы банкы идарәсе рәисе итеп җибәрелә. Биредә дә ул шактый гына җитешсезлекләрне ача. Шуларның иң зурысы — колхозлаштыру буенча XV съезд карарларын бозу. Инспекторның тәнкыйтен Кыргызстан партия Үзәк комитеты сәркатибе Шубриков һәм Урта Азия бюросы сәркатибе Зеленский үзләренең хокукларына яла ягу итеп кабул итәләр. Алар тарафыннан З. Булушевка каршы

[2] Солтангалиев М. Татарлар һәм Октябрь революциясе.— Агитатор сүзе.—1989.— 10 сан.— 44 б.

көрәш җәелдерелә. Тиздән ул бөтенләй эшсез кала. Урта Азия бюросы аны Кыргызстаннан чакыртып ала. Бары тик шактый вакыт узгач кына ҮКның оештыру бүлеге аны финанс-банк югары курсларына җибәрә. Болай «югары күтәрү» Зәйнулла күңелендә зур шик тудыра. Чөнки югары күтәрүләр тиз арада түбәнгә тәгәрәтүләр белән алыштырыла торган вакытлар була ул чакта. Үз артында бернинди дә гаеп тоймау сәбәпле, ул алда барысы да яхшы булыр дип өметләнә. Ләкин...

Ил эчендәге сәясәтнең көннән-көн катлаулана баруы кешеләрне «сөйләвең көмеш булса да дәшмәвең алтын» мәсләгенә бастыра башлады. Баш өстендә болытларның куера барганын яхшы тоемлаган Зәйнулла үзенең үткән юлын 1905 елдан башлап кайта-кайта барлый. Бит барысы дөрес кебек. 1930 елның 22 февралендә ул ДПИО (ОГПУ — ред.)ның Шәрык бүлеге тарафыннан кулга алына. Бу эшне Алмаев һәм Айзенберг дигән кешеләр башкара. Заманында буржуаз милләтче һәм Хәрби Шура әгъзасы офицер Алмаев белән Зәйнулла 1918 елда баррикадаларның ике ягында торган кешеләр ләбаса. Мондый аңлашылмаучанлык аңа нык тәэсир ясый.

З. Булушевны «солтангалиевчелек»тә гаеплиләр. Чөнки ул М. Солтангалиев белән 1921 елда милләтләр буенча Халык комиссариатында бергә эшли. Аңа тагын милләтче, советларга каршы көрәшче, пантюркист кебек ярлыклар да тагалар һәм атарга хөкем итәләр...

1931 елның гыйнвар аенда бу хөкем карары ун елга төрмәгә ябу белән алыштырыла. Башта аны ялгыз камерада тоталар, аннан соң җинаятьчеләр янына урнаштыралар. Якыннары белән очрашу, әйбер алу мөмкинлекләреннән мәхрүм ителә. Мондый авыр шартларда да ул бөгелеп төшми. Һаман да хакыйкать җиңәр дип өметләнә, иртәме-соңмы партия тикшерер һәм бу башбаштаклыкларга чик куяр дип ышана.

Гаделсез хөкемне тикшерүне үтенеп, ул партиянең Үзәк комитетына хат артыннан хатлар яза. Ниһаять, аның гозере үтәлә: 1930 елның февраль аенда иреккә чыгарыла. Зәйнулланы азат итүдә аның элекке иптәшләренең тырышлыкларын да искә алырга кирәк.

Ләкин инде З. Булушевны моннан соң партия һәм совет органнарына эшкә алмыйлар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, ул үз теләге белән фронтка җибәрүләрен үтенеп гариза яза. Өлкән яшьтә һәм авыру булуын исәпкә алып, аны сугышка алмыйлар.

Сугыш тәмамлангач, З. Булушев Кисловодск шәһәрендә яши һәм «Нарзан» шифаханәсендә эшли. Биредә чакта ул берничә тапкыр партия сафларына яңадан кайтаруларын сорап шәһәр комитетына мөрәҗәгать итә. Тик мәсьәлә хәл ителми.

З. Булушевның үтенеченә бары тик 1955 елның декабрь аенда — Н. С. Хрущевның үзенә ике хат юллагач кына колак салалар. Хат авторына инде ул вакытта 69 яшь була. 1956 елның 25 августында иминлек оешмасының тикшерү эшләрен күзәтү бүлеге начальнигы Ночвин СССР Югары Советының җинаять эшләре буенча хөкем итү коллегиясенә кире кагу документы тапшыра. Тиздән Н. К. Морозов рәислегендә һәм әгъзалары И. Шевченко, К. Сакач булган хөкем итү коллегиясе болай дип белдерә: «Дәүләт сәяси идарә итү оешмасы (ОГПУ — ред.) коллегиясенең З. Х. Булушев эше буенча 1930 ел 28 август, 1931 ел 13 гыйнвар һәм 1938 ел 22 февраль карарларын гаепләү дәлилләре булмау сәбәпле, гамәлдән чыккан дип исәпләргә». Әйтеп үткәнебезчә, ул шул ук елның ноябрь аенда партия сафларына да кайтарыла.

Үзенең дөреслеген исбат итү өчен 16 ел вакыт сарыф ителеп, ниһаять, бәхетле мизгелләр кичергәндә аңа инде 70 яшь тулган була.

Күренекле партия һәм совет эшлеклесе, революция каһарманы Зәйнулла Хөсәен улы Булушев 1965 елда 79 яшендә вафат булды.

# ГАБДЕРӘШИД ХӘЗРӘТ ИБРАҺИМОВ

Габдерәшид хәзрәт Гомәр углы Ибраһимов җәнабләре 1857 ел Сибириядә Тара шәһәрендә дөньяга килмеш. Габдерәшид хәзрәт ибтидаи гыйлемен Тарага якын урыс авылында укып, соңра Табул, Казан вилаятьләрендәге мәдрәсәләрдә гыйлем тәхсил итмеш.

Шуннан соң Урта Азиядә казакълар арасында муллалык-мөгаллимлек итеп йөрде. Шулай йөреп бераз акча җыйганнан соң 1880 ел Хиҗазга сәфәр итеп «Мәдинәи мөнәүвәрә»гә барып керде. Анда дүрт ел кадәр гыйлем тәхсил итеп Тара шәһәренә кайтты. Тарага имам вә мөдәррис булды. 1892 ел Уфада Духовный собраниядә казыйлык хезмәте итәргә чакырылды. Мөфти Солтанов хаҗ сәфәренә киттектә мөфтилек хезмәтен үтәп торды. Ел ярым казый булып торганнан соң казыйлыктан истигъфа итеп Истанбулга китте. 1896 елда тагы Тарага кайтып яңадан Хиҗазга, аннан Һиндстанга сәяхәт итте. 1899 елда Русиягә кайтып Петроград шәһәрендә «Миръат» исемле, арабызда булган бозыклыкларны тәнкыйть иткән, киләчәгебезгә юл күрсәткән әсәрләрен нәшер итте. Бу әсәре барысы 18 кисәк булып туктады. Шуннан соң 1905 ел ахырында «Өлфәт» гәзитәсен нәшер итә башлады. Бу гәзитәсе илә Русия мөселманнарының бөтенесен үзенә каратып алса да «Өлфәт» күп яши алмады — ел ярымнан соң хөкүмәт тарафыннан туктатылды. Шул вакытта шәкертләр өчен хас «Әт-тилмиз» исемендә чыгара торган мәҗәлләсе дә яши алмады — туктады. Шуннан соң «Өлфәт» урнына «Нәҗат» исемендә бер мәҗмуга чыгарырга башласа да, бер-ике номердан ары бармый, хөкүмәт туктатты.

Шул вакытларында үзенең бөтен фикерен мәйданга куйган «Автономия» дигән әсәрен чыгарды. Рәшид хәзрәтнең бу әсәре хәзерге көндә «федерация» ди торган барыбызның да сүз башы иде. Рәшид хәзрәт шул фикерне шундый кысык-николай заманында ук кычкырган иде(ләкин ул заманда ул фикерне көлке генә санадылар). Шуннан соң Рәшид хәзрәт Сибириягә, аннан Япониягә сәяхәт итте. Аннан Һиндстаннар аша Төркиягә кайтты. Төркиядә «Сыйрател-мөстәкыйм» исемендә бер мәҗәллә дә чыгардылар. Япониягә сәяхәтен күрсәткән «Дур галәм» исемендә бер сәяхәтнамә язды. 1917 елда Истанбулдан гомуми конференциягә дип Истокһүлм шәһәренә килде. Бундан, анда кешеләр чакырып, хат язды.

Рәшид хәзрәтнең Мантыйк тәрҗемәсе, Чулпан йолдызы, Әл-котып Әш-шимали, Мең бер хәдис тәрҗемәсе, Тәрҗемәи хәлем, Мохтәсар тарих гомуми, Һәркемгә кирәк, Вөҗдан мөхакамәсе, Мең өч йөз сәнәлек нәзыйрә, Гыйльме халь тыйбби, Сабах садыйк, Доронкинга рәддия кеби гыйльми әсәрләре дә күп булды.

Рәшид хәзрәт, гомумән, гыйльми вә әдәби эшләргә караганда сәяси эшләрне артык күрде. Сәяси эшләрдә әйтәсе сүзен һич курыкмый әйтте, язды, сөйләде.

Шулай итеп, Рәшид хәзрәт, «Миръат», «Өлфәт ...»ләре илә бер әдип бабабыз саналса, «Автономия»се илә сәяси бабабыз да санала.

**Исхакый Гатаулла.** Әдәбият юллары (Рөшди мәдрәсәләребез өчен дәреслек). Казан, 1920, 110-111 битләр.

Журнал өчен текстны Җәүдәт Миңнуллин һәм Раиф Мәрданов әзерләде.

С ү з л е к  һ ә м  и с к ә р м ә л ә р: ибтидаи — башлангыч; тәхсил — гыйлем алу; вилаять — өлкә, губерна; казый — дини судья; мөфти — ислам дине таралган илләрдә югары дәрәҗәле рухани; истигъфа — хезмәттән азат ителү, эштән чыгу; миръат — көзге; әт-тилмиз — шәкерт; нәҗат — котылу, исән калу; сыйрат — юл, күпер; мөстәкыйм — туры, төз, дөрес, чын; мәҗәллә — журнал, җыентык; дур галәм — дөнья җирләре; мәҗмуга — җыентык, альманах, журнал; мантыйк — формаль логика; мөхтәсар — кыска, кыскача; мөхакамә — судта тикшерү, хөкем чыгару; сәнә — ел; нәзыйрә — үрнәк, өлге; тыйбби — медицинага бәйләнешле; сабах — иртә, таң; садыйк — туры, дөрес, чын, эчкерсез; рәддия — кире кагу, юкка чыгару.

Габдерәшид Гомәр улы Ибраһимов — татар җәмәгать эшлеклесе, публицист.
Истокһүлм — Стокгольм.

## عبدالرشيد حەضرەت ابراهيموف

عبدالرشيد حەضرەت عمر اوغلئ ابراهيموف جەنابلەرئ
١٨٥٧- يل سيبيريەدە «تارا» شەهەرندە دۋنياغا كيلمش.عبد-
الرشيد حەضرەت ئيبتيدائى عيلمى «تارا»غا ياقى روس آولندا
اوقب، صوڭرا «طابول. قازان» ويلايەتەرندەگى مەدرەسە-
لەردە عيلم تەحصيل ئيتمش.

شوندان صوڭ اورتا آرادا قاراقلار آراسندا موللالق-
مۆعەلليملك ئيتب يۆردئ. شولاي يۆرب برآز آقچا جينا-
غاندان صوڭ ١٨٨٠- يل حيجازغا سەفەر ئيتب «مَدينۀ مُنوَّرە»
گەبارب كردئ. آندا دورت يل قەدەر عيلم تەحصيل ئيتب
«تارا» شەهەرينە قايتدئ. تاراغا ايمام وە مۆدەررس بولدئ.
١٨٩٢- يل اوفادا دوخاونى سابرانيەدە قاضيلق حذمەتئ
ئيتەرگە چاقرلدئ. مۆفتى سلطانى حەج سەفەرينە كيتدكدە
مۆفتيلك حذمەتن ئوتەب تۆردئ. يل يارم قاضى بولب
تورغاندان صوڭ قاضيلقدان ايستيعفا ئيتب «استانبول»غا
كيتدئ. ١٨٩٦- يلدا تاغئ تاراغا قايتب ياكادان حيجازغا،
آندان هيندستانغا سياحەت ئيتدى. ١٨٩٩- يلدا روسيەگە
قايتب پيتروغراد شەهەرندە «ميرآت» ئيسملئ، آرابزدا بو-
لغان يۆرۆقلقلارئ تەنقيد ئيتكەن، كيلەچەككە يول كور-
سەتكەن ئەثەرلەرئن نەشر ئيتدئ. بو ئەثەرئ باريسئ
١٨ كيسەك بولب توقتادئ. شوندان صوڭ ١٩٠٥- يل



آخرندا «ألفت» گەزيتەسن نەشر ئيتە باشلادئ. بو گە-
زيتەسئ ئيلە روسيە مۆسۆلمانلاريننڭ بۆتۆنسن ئوريتە
قاراتب آلسادا «ألفت» كوب يەشى آلمادئ - يل يارمدان
صوڭ حكومەت تاراقندان توقتالدئ. شول واقتدا شە-
كرتلەر ئۆچۆن خاص «التلميذ» ئيسمندە چغارا تورغان
مەجەللەسئ دە يەشى آلمادئ - توقتادئ. شوندان
صوڭ «ألفت» اورنينا «نجات» ئيسمندە بر مەجموعە چغا-
ررغا باشلاسادا بر ئيكى نومێردان آرى بارمى حكومەت
توقتاتدى.

شول واقتلاردا ئورينڭ بۆتۆن فيكرن مەيدانغا
قويغان «آفتونوميە» ديگەن ئەثەرن چغاردئ. رشيد
حەضرەتنڭ بو ئەثەرئ حەضرگى كوندە «فيدراتسيە»
دى تورغان ياريزنڭ دا سوز باشئ ئيدى. رشيد حەضر-
ەت شول فيكرن شوندى قسق - نيكولاى زامانندا اوق
چغارغان ئيدئ (لاكين اول زاماندا اول فيكرئ كۆلكى گنە
ساناديلار). شوندان صوڭ رشيد حەضرەت سيبيريەگە،
آندان ياپونيەگە سياحەت ئيتدئ. آندان هيندستانلار
آشا تۆركيەگە قايتدئ. تۆركيەدە «صراط المستقيم»
ئيسمندە بر مەجەللە دە چغاردیلار. ياپونيەگە سياحەتن
كورسەتكەن «دور عالم» ئيسمندە بر سياحەتنامە ياردئ.
١٩١٧- يلدا استانبولدان عمومى كونفيرينسيەگە ديب



«استوقهولم» شەهەرينە كيلدئ. بۆندان، آندا كشيلەر
چاقرب خاط ياردئ.

رشيد حەضرەتنڭ ماتطبو تەرجمەسئ، چولپان يۆلدۆ-
زئ، القطب الشمالى. ملك بر حديث تەرجمەسئ. تەرجمۀ حا-
لم، مختصر تاريخ عمومى. هەر كمگە كيرەك، وجدان محا-
كمەسئ. ملك تۆج بۆز سەلك نظرە، علم حال طبى، صبح
صادق، داروينگە رديە كبى عيلمى ئەثەرلەرئ دە
كوب بولدئ.

رشيد حەضرەت، عمومەن عيلمى وە ئەدەبى ئشلە-
رگە قاراغاندا سياسى ئشلەرئ آرتق كوردئ. سياسى
ئشلەردە ئەينەسى سوزن هيچ قورقى ئەيتدئ، ياز-
دئ، سويلەدئ.

شولاى ئيتب رشيد حەضرەت «ميرآت. ألفت...»
لەرئ ئيلە بر ئەديب باباىز سانالسا، «آفتونوميە»سى
ئيلە سياسى باباىز دا سانالا.

# ТАТАР ТЕЛЕНӘ — КИҢ ХОКУКЛАР!

Соңгы елларда татар телен өйрәнүгә, куллануга, милли мәдәниятьбызны үстерүгә игътибар шактый артты. Татарстан китап нәшрияты, вакытлы матбугаты әдәби мирасыбызны барлау, халыкка кайтару юнәлешендә зур эш башкара. Бүтән өлкә, республикалар шикелле, Ульяновск яклары да уянып килә — өлкәбездә «Туган тел» мәдәни җәмгыяте туган телебезне саклау, милли аңны тергезү, туган культурабызны аякка бастыру буенча байтак көч куя. Ике атнага бер генә булса да телевидениебез татарча тапшырулар алып бара башлады, «Өмет» атналык гәзитебез дөнья күрде, мәктәпләрдә татар теле-әдәбияты дәресләре йә факультатив, йә тулы предмет рәвешендә укытыла...

Әмма болар гына, әлбәттә, җитәрлек түгел, без әле һаман асыл нигезебездән ерак. Күпме генә тырышсак та, ата-аналар балаларын татар телендә укытуга атлыгып тормый. Чөнки туган телне өйрәнүгә, куллануга тиешле шартлар тудырылып җитмәгән. Аларның иң кирәге — туган телдә югары белем алуны тормышка ашыру.

Минемчә, Татарстанның барлык югары уку йортларында татар секторлары оештырып, аларда бөтен предметларны туган телебездә өйрәнү хаҗәт. Бу эшне татар студентлары һәм галимнәре аеруча күп тупланган университет, авыл хуҗалыгы, ветеренария, мәдәният, төзелеш, Казан һәм Алабуга педогогия институтларында башлау җиңел. Казан татар халкының рухи мәркәзе булганлыктан, милли мәктәпләребезне тәмамлаган яшь буын төрле өлкә, республикалардан шушында килеп, туган телендә белем ала башласа, ул тиешле һөнәр үзләштерүдән тыш, күңелен милли сәнгате белән дә сугарыр иде. Милли мөхиттә тупланып тәрбияләнү генә тарихи аңны ныгытырга, гореф-гадәтләрне ихтирам итәргә мөмкинлек бирүен, әхлаклы кеше булып яшәргә нигез салуын һич тә онытырга ярамый.

Туган телдә югары һәм урта махсус белем алуны юлга салу шактый чыгымнар ясауны таләп итә. Әмма Татарстанның моңа көче дә, байлыгы да җитәрлек. Ел саен Союз бюджетына ике миллиард ярым сум саф табыш биреп килә ич ул. Аның нефте генә дә безнең илгә ике йөз илле миллиард доллар күләмендә керем китерде. Бу байлыкның нәни өлеше генә дә югары уку йортлары өчен дәреслекләр, кулланмалар бастырырга, укытучылар әзерләргә бик җитә.

М. С. Горбачев комсомол делегатлары белән очрашканда: «Республикалар суверенитетын чынлап гамәлгә ашырырга, аларга экономик мөстәкыйльлек бирергә, телләрнең мәдәни традицияләрнең иркеле үсешенә мөмкинлек тудырырга кирәк»,— диде.

Димәк, югары белем алуда милли тигезлек тәэмин ителергә тиешлеген илебезнең сәяси җитәкчелеге дә яхшы аңлый. Әмма шушы көнгә кадәр бу эш кайбер союздаш республикаларда гына яхшы көйләнгән, шунлыктан без җан башына югары белем алу буенча грузин, әрмән, урыс, литва, латыш, эстоннардан берничә тапкыр калышабыз.

Шундый хурлыкка гына лаекмыни татар? Эштә, илнең бәйсезлеген саклауда иң алда барган халыкка килешәме соң бу?

Идел-Урал буенда гына түгел, Урта Азиядә дә совет властен урнаштыруда бик актив көрәштек без. Ватан сугышында исә Советлар Союзы геройлары саны буенча урыс, украин, белоруслардан гына калыштык. Күкрәге белән дошман амбразурасын каплаучы, Рейхстагка җиңү әләмен беренче кадаучы татар егетләре дистәләгән булды. Кыскасы, милләттәшләребез Ватан өчен кыен көннәр килгәндә бик кирәк иде, илнең бөек төзелешләрендә дә аларга мохтаҗлык сизелде. Сынатмадык, СССРның барлык казанышларына яхшы ук мул өлеш керттек. Шул бәрабәрдә тырышлыгыбыз җимешен татырга да хакыбыз бар.

Уйлавымча, татар телендә югары һәм махсус урта белем бирүне кичектерү халкыбызның культура дәрәҗәсен үстерүгә, меңнәрчә сәләтле яшьләребезнең сәләтен ачуга комачаулый. Туган телебез үзара аңлашуда, белем алуда, яңа мәдәни байлыклар җитештерүдә үзәк рольне уйнасын, башка телләрне өйрәнүдә дә ул беренче ачкыч булсын. Халкыбызның шуннан башка нормаль яшәвен һәм үсүен тәэмин итү мөмкин түгел!

Шәүкәт **ХАСИЯТУЛЛИН**,
Ульяновск өлкәсе, Чардаклы районы,
Татар Колмаеры авылы.

# *Китаплар дөньясында*

**Хөрмәтле укучылар!**

Татарстан китап нәшрияты соңгы вакытта түбәндәге китапларны бастырып чыгарды:

Агыйделкәй. *Халык җырлары.* 160 бит. Б. 70 т.

**Нияз Акмалов.** Килер бер көн. *Шигырьләр һәм поэмалар.* 112 бит. Б. 40 т.

**Акъегет.** Төнге сулар. *Шигырьләр.* 112 бит. Б. 30 т.

**Порфирий Афанасьев.** Чирмешәннең йотым суы. *Шигырьләр.* 96 бит. Б. 30 т.

**Батулла.** Бишек хикәятләре. *Нәниләр өчен рәсемле китап.* 36 бит. Б. 40 т.

**Мансур Вәлиев.** Каһарманнар кирәк. *Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.* 240 бит. Б. 75 т.

**Мәхмүт Газизов.** Мәйдан. *Шигырьләр.* 76 бит. Б. 10 т.

**Әнәс Галиев.** Намус кушканча. *Повестьлар.* 368 бит. Б. 1 с. 50 т.

**Марсель Гыймазетдинов.** Яшәү мәгънәсе. *Шигырьләр.* 64 бит. Б. 10 т.

**Дамир Гыйсметдинов.** Өметсез шайтан. *Хикәяләр.* 80 бит. Б. 10 т.

**Ришат Нури Гүнтекин.** Чалы кошы. *Роман.* 284 бит. Б. 1 с. 90 т.

**Әнвәр Давыдов.** Муса абый. *Повесть.* 112 бит. Б. 25 т.

**Зөлфәт.** Адашкан болыт. *Шигырьләр, поэмалар, балладалар.* 224 бит. Б. 1 с.

**Галимҗан Ибраһимов.** Алмачуар. *Повесть.* 48 бит. Б. 10 т.

**Нәкый Исәнбәт.** Татар теленең фразеологик сүзлеге. *Ике томлык.* I — том. 496 бит. Б. 3 с. II — том. 366 бит. Б. 2 с. 20 т.

Кайда да йөрәктә. *Татар җырлары нота-лары белән. Татар һәм рус телләрендә.* 152 бит. Б. 1 с. 30 т.

**Барлас Камалов.** Язмыш сәхифәләре. *Роман һәм повестьлар.* 464 бит. Б. 2 с. 10 т.

**Хисам Камалов.** Үлгәннән соң яздым. *Роман.* 432 бит. Б. 1 с. 80 т.

**Шәриф Камал.** Бәхет эзләгәндә. *Хикәяләр, повесть.* «Мәктәп китапханәсе» сериясеннән. 160 бит. Б. 30 т.

**Әнәс Кари.** Тамчы тамганда. *Балалар өчен рәсемле шигырь китабы.* 32 бит. Б. 10 т.

**Газиз Кашапов.** Вөҗдан хәтере. *Повестьлар.* 272 бит. Б. 1 с. 10 т.

**Таһир Корбанов.** Кызыл чәчәкләр. *М. Җәлил турында истәлекләр.* 128 бит. Б. 25 т.

**Владислав Крапивин.** Яшен чаткысы. *Балалар һәм өлкәннәр өчен роман.* 352 бит. Б. 85 т.

**Нәҗип Мадъяров.** Кызыклы шигырьләр. 48 бит. Б. 10 т.

**Мәдинә Маликова.** Шәфкать. *Роман һәм повестьлар.* 448 бит. Б. 1 с. 80 т.

**Рөстәм Мингалим.** Тау астында илле бүре. *Пьесалар.* 312 бит. Б. 1 с. 60 т.

**Мөхәммәт Мәһдиев.** Бәхилләшү. *Повестьлар.* 640 бит. Б. 2 с. 60 т.

**Рашат Низамиев.** Фәрит Яруллин. («Язмыштан көчлерәк»). *Роман-хроника.* 254 бит. Б. 75 т.

**Җәмит Рәхимов.** Кыядагы чәчәкләр. *Роман.* 272 бит. Б. 1 с. 10 т.

**Бари Рәхмәт.** Сабан туенда. *Шигырьләр.* 120 бит, рәс. белән. Б. 50т.

**Фоат Садриев.** Шаһзаманов эше. *Повесть һәм хикәяләр.* 224 бит. Б. 95 т.

**Госман Садә.** Тайфун күзе. *Шигырьләр һәм поэмалар.* 88 бит. Б. 35 т.

**Гомәр Саттаров.** Исемең матур, кемнәр куйган. *Татар исемнәренең килеп чыгышы, исем кушу гадәтләре турында.* 254 бит. Б. 60 т.

**Константин Симонов.** Исәннәр һәм үлеләр. *Роман.* 544 бит. Б. 1 с. 40 т.

**Әхмәт Сәхапов.** Алтын тамырлар. *Әдәби тәнкыйть мәкаләләре.* 160 бит. Б. 45 т.

**Әнвәр Тайсин.** Татарстан АССР географиясе. 199 бит. Б. 50 т.

Татар әдәбияты тарихы. *Алты томлык.* 5 — том. 544 бит. Б. 2 с. 10 т.

Татар халык әкиятләре. 480 бит. Б. 2 с. 20 т.

**Мәгъсүм Хуҗин.** Ерактагы кыялар. *Хикәяләр.* 351 бит. Б. 1 с. 70 т.

**Равил Фәйзуллин.** Сәгать белән Сәгыйть. *Балалар өчен шигырьләр.* 24 бит, рәс. белән. Б. 40 т.

**Мәхмүт Хәсәнов.** Беренче ау. *Повестьлар.* 336 бит. Б. 90 т.

**Мәхмүт Хөсәен.** Яшь җәлилчеләр. *Җырлар ноталары белән.* 72 бит. Б. 40 т.

**Рәниф Шәрипов.** Күк һәм күңел йолдызлары. *Шигырьләр һәм поэмалар.* 80 бит. Б. 10 т.

Яраткан җырлар. IV чыгарылыш. 80 бит, ноталары белән. Б. 50 т.

**Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин.**

**Адреслар: 420057, Казан шәһәре, Октябрьская урамы, 18. «Китап-почта» кибете.**

**420084, Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. 1 — китап кибете, «Китап-почта» бүлеге.**

# «КАЗАН УТЛАРЫ»нда 1990 ЕЛДА БАСЫЛГАН ӘСӘРЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларация. № 9
КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы карары. 1990 ел өчен Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге премияләрен бирү турында. № 6

## ТАТАРСТАН ССР ЮГАРЫ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЫ

Татарстан ССР Дәүләт флагын, Дәүләт гербын, Дәүләт гимнын булдыру буенча конкурс турында. № 12.

## ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Акмал Н. Күгәрчен сөте. Повесть. № 8, 9.
Гыйләҗев А. Балта кем кулында? Роман. № 7, 8.
Гыйматдинова Н. Сихерче. Повесть. № 9.
Маликова М. Фидая. Роман. № 10, 11.
Расих А. Ишан оныгы. Роман-истәлек. № 1, 2.
Тавлин Г. Афәт. Роман. № 3, 4.
Тәрҗеманов Ж. Кичерергә мөмкин түгел. Повесть. № 3.
Төхвәтуллин Р. Сарман балладасы. Повесть. № 7.
Хафизов С. Гомерем фасыллары. Повесть. № 5.
Хөснияр З. Каешлану. Повесть. № 6.
Эйди Т. Елан угы. Роман. № 4, 5, 6.
Үзиле Г. Гыйфрит. Роман-дилогия. № 11, 12.

## ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Мингалим Р. Кунак кызы гел килмәс. Лирик комедия. № 12.

## ХИКӘЯЛӘР ЯРЫШЫ

Гаффар Ә. Утын. Хикәя. № 7
Гыйззәтуллин Р. Сиртмәле кое. Хикәя. № 10
Гыйсметдинов Д. Тамгалы бүрәнә. Хикәя. № 1
Низамов И. Колаксыз Зариф. Хикәя. № 7
Сабиров С. Яшен суккан имән. Хикәя. № 2
Сирматов И. Әткәй сәгате. Нәсер. № 3
Хисмәтуллин Р. Чылбырлар. Хикәя. № 12
Хуҗин М. Кулаклар колхозы. Хикәя. № 3
Хәким З. «Контра». Хикәя. № 10
Хәммәдшин Ә. Ясин. Хикәя. № 3
Хөснияр З. Кичү. Хикәя. № 12
Хөсәенов Ш. Мәхәббәт һәм нәфрәт. Хикәя. № 2
Юныс М. Каравыл йорты. Хикәя. № 10
Яруллин Ф. Күкертле чишмә. Хикәя. № 12.

## ШИГЪРИЯТ

Арслан Н. Көз. Шигырьләр. № 9
Афзал Г. Ике шагыйрь. Шигырьләр. № 2
Баян Ә. Төрле еллардан. Шигырьләр. № 8
Булатова К. Күктүбә дәфтәреннән яңа шигырьләр. № 11
Булгакова Д. Вакытның минутын... Шигырьләр. № 3
Гадел Ә. Заһидулла Яруллин — сабан туенда. Шигырьләр. № 5
Гыйззәтуллина Ф. Иорәгемне эзлим. Поэма. № 7
Гәрәева С. Авылым. Шигырьләр. № 8
Зыятдинова Ф. Ташкын. Шигырьләр. № 3
Зөлкәрнәй Л. Зең. № 10
Игәнәй Я. Ышандырып кара, Заман! Шигырьләр. № 6
Измайлова Н. Язын. Шигырьләр. № 4
Кашапов Г. Кайгы. Шигырьләр. № 1
Латыйп К. Әминә. Шигырь. № 10
Мадьяров Н. Дулкын таулары эчендә. Шигырьләр. № 11
Маннап Ш. Сабырлык. Шигырьләр. № 9
Мингалим Р. Үзгәреш. Шигырьләр. № 1
Миңнуллин Р. Балалар өчен шигырьләр. № 7
Морат Г. Яңа шигырьләр. № 11
Мостафин К. Эзлибез. Шигырьләр. № 4
Мостафин Р. Мин бәләкәй чакларда. Заман фрагментлары. № 3
Муллагалиев С. Зурлыктамының авырлык. Шигырьләр. № 2
Мәхмүд Ә. «Матур» исем эзләүчеләргә. Шигырьләр. № 10
Мәдәрисова Х. Көмеш дага. Шигырьләр. № 3
Мөслимова Ф. Олы кое. Шигырьләр. № 3
Мөэминова Э. Ике җыр. Шигырьләр. № 3
Низами Р. Вакыт җиле. Шигырьләр. № 10
Рәфыйков Б. Нишләттең син, замана... Шигырьләр. № 8
Рәхим Г. Татар кешесе. Шигырьләр. № 9
Рәхимова Б. Кирәк түгел фал ачулар. № 3
Садә Г. Төнге кошлар. Шигырьләр. № 11
Сафин Ф. Ышан, кардәш! Шигырьләр. № 12
Сибгатуллин К. Таныш кеше. Шигырьләр. № 4
Харис Р. Көмеш нур. Шигырьләр. № 11
Хәйруллин Д. Күлле шәһәр. Шигырьләр. № 7
Хәлим А. Яңа шигырьләр. № 2
Хөсәен М. Сонетлар. № 7
Шагыйрҗан Л. Вакыт. Шигырьләр. № 9
Шәмсетдинов Н. Муса Җәлил истәлегенә. Шигырь. № 10

Яруллин Ф. Нәсел агачы. Поэма. № 6
Әгъләмов М. Ничәнче кат. Шигырьләр. № 2
Әхмәтҗанов Р. Ант. Шигырьләр. № 12
Әюп Х. Су хатере. Шигырьләр. № 8

## ӘДӘБИ МИРАС

Исхакый Г. Ике йөз елдан соң инкыйраз. № 1, 2
Исхакый Г. Сөннәтче бабай. Хикәя. № 1
Нуруллин И. Кайту. № 1
Рафиков М. Алар өчен юк мин... Шигырьләр. № 9

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Зөлфәт. Зөлфәт турында Зөлфәт. № 1
Касыймов Х. Өлкәннәр. Шигырьләр. № 5
Ләйсән. Бүләк. Шигырьләр. № 3
Хәким З. Айлы төн. Шигырьләр. № 1
Хөсни И. Җырлар иле. Шигырьләр. № 5
Шәмсуаров Т. Дөнья. Шигырьләр. № 5

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Ү. Маттеус. Җыр. Хикәя. № 6

## БЕЗДӘ КУНАКТА — КЫРЫМ ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

Алядин Ш. Кара күз. Шигырь. № 6
Вәлиев Ә. Кораблар. Шигырь. № 6
Мамбет Б. Яшәү өчен... Шигырь. № 6
Осман Д. Ах, татарлар, татарлар... Шигырь. № 6
Сәламәт Ә. Имә, шагыйрь, башыңны. Шигырь. № 6
Фазыл Р. Нинди гүзәл бу яз... Шигырь. № 6
Черкез-Али. Гафу ит мине. Шигырьләр. № 6
Чобан-задә Б. Дунай ташы. Шигырьләр. № 6
Әмин С.-Г. Өч аршин җир. Шигырь. № 6
Җәвәһирә. Анам. Шигырьләр. № 6

## ОСТАХАНӘ

Зыятдинова С. Хөкем. Хикәя. № 4
Шәрәфи Г. Хисләргә тиронлек бир, каләм! № 4

## ЮМОР-САТИРА

Кәшфелзадә. Һаман «күтәрелүче» бер дуска. Шигырь. № 8
Мостафин К. Хат башы — яз каршы. Хикәя. № 2
Низами. Тәүбә. Шигырь. № 8
Сафиуллин Ә. Нюанс. № 3
Хөснуллин Х. «Саратти агентлыгы». Шигырьләр. № 8

## ПУБЛИЦИСТИКА

Баһаветдинов Ф. Кәрим Тинчуринның соңгы көннәре. № 2
Без бик озак көттек. (Татар иҗтимагый үзәге рәисе М. Мөлеков белән әңгәмә). № 4
Вәлиев Д. Ышанычның эгәр какшаса. № 3
Галиев М. Яшәү белән үлем арасында. № 5
Зәбиров Г. Ата Салих белән әңгәмәләр. № 1
Ил кала, халык кала... (Туфан Миңнуллин белән әңгәмә). № 6
Мәхмүдов Ә. Үзгәреш булырмы? № 4
Мәхмүтова А. Әйдә халыкка хезмәткә. № 3
Рәхимов Җ. Кем син, Нәдер Үрәзмәтов? № 9
Рәхимов Җ. Акланмаган өмет. № 11
Садыйк А. Афәрин, адаш! № 6
Садыйк А. Шахмат алиһәсе. № 12
Салахов И. Томаннарга төренгән яшьлек турында. № 12
Фәизов Р. Илгә бәрәкәт иңәрме? № 10
Хәлим А. Иле барның теле бар. № 11
Хәсәнов А. Җидегән чишмәләрдә — җиде улак. № 9
Юныс М. Телсезләнү: тамыры һәм җимешләре. № 3
Юнысов В. «Әс-сабру мифтах әл-фараҗ...» № 5
Әмит Э. Үлемне җиңгән халкым турында. № 6
Әхмәтҗанов М. Бар бер авыл Урал итәгендә. № 9

## ҮТКЕН МӘСЬӘЛӘ

Мостафин Р. Телебез ярлы түгел. № 11
Әхмәдуллин Ш. Талант милләтне күтәрә. № 4

## ЯЗУЧЫЛАР СҮЗЕ

Язучы депутатларның ТССР Югары Советындагы чыгышларының стенографик отчеты. (Р. Фәйзуллин, Ф. Бәйрәмова, Р. Миңнуллин, Р. Мөхәммәдиев, Р. Вәлиев). № 12
Милләтебез килер көнгә ышана. Котлаулар, теләкләр. № 10

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Бәширов Ф. Тургайсыз яшәп буламы? № 1
Вилданова-Хәкимова М. Шагыйрь хатыны булу авырмы. № 2
Вәлиев М. Мәхәббәт яшәргә тиеш! № 3
Вәлиев М. Батырлык. № 12
Галиуллин Т. «Йолдызлар җитә һәркемгә». № 4
Еники Ә. Сарьян. № 3
Зөлкарнәй Ф. «Арын көн дә коллы гыйшкан!» № 7
Ибәтуллина Д. Беренче буразналар (Әмирхан Еникиның башлангыч чор иҗаты). № 1

Ихсанова Л. Чишмә җыры. Бер хатирә. № 2
Кәшфиева Л. Гамил Афзал көлүе. № 5
Мансуров З. Сиксәненче елларны озатканда. № 9
Миңлебаев К. Хәзинә алмашканда... № 5
Мәһдиев М. Европа — безнең хакта. № 2
Нәҗми Н. Сибгат Хәким мәктәбе. № 12.
Рәмиева Ф. Шагыйрь белән янәшә. № 3
Хафизов С. Политика һәм шигырь. № 1
Хәмидуллин Л. Киңәшле эш таркалмас. № 8
Яңарыш һәм әдәбият (Түгәрәк өстәл янында әңгәмә). № 6
Әдип турында каләмдәшләре (Н. Арслан, А. Гыйләҗев, Р. Батулла). № 8
Әйди Т. Хакыйкатькә яңа адым. № 10
Җамалетдинов Л. Венгр галиме татарлар арасында. № 2

ТУКАЙЛАР РУХЫ

Язучы Р. Батулла белән әңгәмә. № 7
Язучы С. Баттал белән әңгәмә. № 8
Язучы Ф. Бәйрәмова белән әңгәмә. № 10
Язучы Н. Фәттах белән әңгәмә. № 5
Шагыйрь М. Әгъләмов белән әңгәмә. № 4

КИТАП КҮЗӘТҮ

Галимуллин Ф. Шагыйрь иманы. № 6
Гарипов В. Роман-хроникада ниләр бар? № 6
Гыйльманов Г. Сискәндерә торган шигырьләр. № 3
Даутов Р. Фәннилек хәбәрчесе. № 10
Хаков В. Хәзинәләр ачкычы. № 8
Хәмидуллин И. Сәхифәләр калка тарихтан. № 5
Әхмәдуллин А. Рухи мирасыбызны барлаганда. № 10
Бәширов Ф. Затлылык. № 12

МӘДӘНИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫДА

Абдуллин Я. Думавиның дөньяви уйлары. № 1
Бакиров М. Сак белән Сок кайлардан килә? № 10
Баһаветдинов Ф., Әхмәдуллин А. Фәтхи Бурнашның соңгы көннәре. № 10
Вәлиев Р. Монгол яуларына кадәрге чорда Болгар иле белән Русь арасында сәүдә элемтәләре. № 5
Вәлиев Р. Революция улы. № 12
Вәлиев Ф. Себердә белем учаклары. № 9
Гәрәева Р. Кем ул Морад Рәмзи? № 2
Зәйнуллин З. Эстәрлебаш мәдрәсәсе. № 6
Кәримуллин Ә. Суоми иленең татар китаплары. № 9
Нәфыйков Р. Тукай һәм хатын-кызлар. № 4
Мостафин Р. Г. Ибраһимовның соңгы көннәре. № 7
Расих А. Гаяз Исхакый хаты. № 10
Саттаров Г. Исемнәр йолдызлыгы. № 8
Сәгыйдова Э. Галим, педагог, журналист. № 11
Төхфәтуллин Х. Камил Мотыйгый. № 7
Әхмәтҗанов М. Мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси хакында яңа мәгълүматлар. № 7
Әмирхан Р. Иелмәс баш. № 10
Әхмәтов С. «Кыйссаи Йосыф» асылташлары. № 5

СӘНГАТЬ

Горшков В. Дөнья сәхнәсенә сәфәр. № 10
Фәләхетдинов Х. Күзләр нигә моңсу. № 10
Әхмәтова Ф. Мәңгелек юл. № 7

УКУЧЫ СҮЗЕ

Ганиев Ф. Әдипне хуплыйм. № 8
Сөләйманова Р. Моңа без хуҗа. № 8
Хатлардан юллар. № 4, 7
Әдһәмова Г. Өметләр өзелмәгән. № 8
Хасиятуллин Ш. Татар теленә киң хокуклар! № 12

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Вәлиуллин А. Табылдык хатлар ни сөйли? № 5
Кенәри — читлек кошы. Хатлардан өзекләр. № 2

МӘҖИТ ГАФУРИНЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Гафури М. «Милләт мәхәббәте» китабындагы шигырьләрдән. № 8
Рәмиев З. Әдипнең аз билгеле шигырьләре. № 8

ТАҖИ ГЫЙЗЗӘТНЕҢ ТУУЫНА 95 ЕЛ

Сарымсаков Ш. Әйбәт кеше, олы драматург. № 9
Мәһдиев М. Безнең күңелләрдә ташкыннар. № 9

Х. ТУФАНГА 90 ЕЛ

Минская Г. Газиз мирас. № 12
Х. Туфан хатлары № 12
Г. Хәйям робагыйлары (Х. Туфан тәрҗемәсе). № 12

С. СӘЙДӘШЕВНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Гобәйдуллин Х. Кыйммәтле истәлек. № 12
Сәлитова Ф. Соңгы моңнар. № 12
Татар шагыйрьләре Сәйдәш турында. № 12

## ТАТАР ХАЛКЫ: ТӨРЛЕ ТӨБӘКЛӘРДӘ, ТӨРЛЕ ИЛЛӘРДӘ

Вәлиев Р. **Революция улы.** № 12
Исхаков Д. **Нократ татарлары.** № 3
Каримуллин Ә. **Америка татарлары тарихыннан.** № 1
Мөхәммәтшин И. **Керәшен татарлары.** № 12
Таһир М. **Татарлар Кореяда.** № 7
Шәрифуллина Ф. **Касыйм татарлары.** № 5
Шәрифуллина Ф. **Кострома татарлары.** № 12
Әлтәф Р. **Маньчжуриядәге милләттәшләребез.** № 10

## КОРЪӘН СҮРӘЛӘРЕ

Хәйруллин Ә. **«Укыйм тиз-тиз күңелдән бер гаҗәеп сүрә Корьәндин».** № 10
**Фатиха, Аятел-көрси, Рахман, Ихлас, Фәлакъ, Нас сүрәләре.** № 10 **Сүрәтү Иасин.** № 11

**Югалмаска һәм югалтмаска!** (татар укучыларына мөрәҗәгать). № 9

**Әйдә, халыкка хезмәткә...** (академик М. Мәхмүтов белән әңгәмә). № 7

Хәкимҗанов Ф. **Игътибар: Татар энциклопедиясе.** № 6

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Р. Вәлиевага 60 яшь.** № 5
**М. Газизовка 50 яшь.** № 3
**Д. Зөбәеровага — 60 яшь.** № 1
**М. Мәһдиевка 60 яшь.** № 12
**Ә. Нигьмәтуллинга — 60 яшь.** № 11
**Т. Нурмөхәммәтовка — 60 яшь.** № 4
**Җ. Тәрҗемановка 70 яшь.** № 7
**М. Фәйзуллинага 60 яшь.** № 6
**М. Хуҗинга 60 яшь.** № 5
**М. Хәсәновка 60 яшь.** № 6
**Х. Хәйригә 80 яшь.** № 2

## КАЛӘМДӘШЛӘРЕБЕЗ — ССCP ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНЕҢ ЯҢА ӘГЪЗАЛАРЫ

**Наилә Вәлитова, Фирая Зыятдинова, Рафис Гыйззәтуллин, Марк Зарецкий.** № 7

## БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**Илдус Ахунҗановка 60 ел.** № 4
Исхакова-Вамба Р. **АНЫҢ ЯГЫМЛЫ КӨЙЛӘРЕ.** (Композитор З. Хәбибуллинның тууына 80 ел). № 9
**Халикъ Садриның тууына 100 ел.** № 8
**Эдуард Касыймовның тууына 60 ел.** № 11

## ГАРӘП ӘЛИФБАСЫ НИГЕЗЕНДӘ ТАТАРЧА УКУ КҮНЕКМӘЛӘРЕ

Миңнуллин Җ., Мәрданов Р. № 1, 2, 3, 4, 5, 6, 8, 12

## ТАТАР ТЕЛЕ ДӘРЕСЛӘРЕ

Хисамова Ф., Борханова Р. № 1, 2, 3, 5, 6

## КИТАПЛАР ДӨНЬЯСЫНДА

№ 1, № 3, № 7, № 12
Таһир М. **Чит илләрдә татар вакытлы матбугаты.** № 10

## ТЫШЛЫКТАГЫ СУРӘТЛӘР

Алишев С. **Сөембикә манарасы.** № 6
Алишев С. **Казан Кремле.** № 8
**Корьәннән фотокүчермә.** Сүрәтүл-Фатиха. № 10
Миңнуллин Җ. **Кече манара.** № 1
Миңнуллин Җ. **«Шайтан каласы».** № 2
Миңнуллин Җ. **Кара пулат.** № 4
Мөхәммәтшин И. **Бүрәнәне салып бүрәнәгә.** № 5
Хәкимҗанов Ф. **Изге ташлар сере.** № 4
Хәкимҗанов Ф. **Бәһасез ядкарьләр.** № 12
Әмирхан Р. **Мәрҗани мәчете.** № 7
Әмирхан Р. **Әҗем мәчете.** № 9
Әмирхан Р. **Кәрван-сарай.** № 11

**Мәдәният тормышы көндәлеге.** № № 1-12

**Бер сорауга — бер җавап.** № 1

**Журналыбызны кайда күпме алдыралар.** № 8

## Мөхәммәт Мәһдиевкә 60 яшь



Күренекле әдип, тәнкыйтьче һәм галим Мөхәммәт Сөнгат улы Мәһдиев 1930 елның 1 гыйнварында Татарстанның Арча районы Гөберчәк авылында туган. Арча педагогия училищесен тәмамлаганнан соң (1947), ул халыкка аң-белем бирү эшен сайлый, башта авыл мәктәбендә, аннары Казан дәүләт университетында бүгенгәчә укыта.

М. Мәһдиев вакытлы матбугатта мәкаләләрен һәм хикәяләрен алтмышынчы еллардан бирле бастырып килә. Ул — «Борчулы өч көн» комедиясе, дисталәгән татар әдәбияты дәреслекләре авторы. Әмма күпчелек укучылар аны, нигездә, сугыштан соңгы авыл тормышын сурәтләгән үзенчәлекле «Без — кырык беренче ел балалары», «Кеше китә — җыры кала», «Торналар төшкән җирдә», «Ут чәчәге», «Исәнме, Кәшфи абый!», «Бәхилләшү» повестьларын, «Фронтовиклар», «Каз канатлары», «Мәңгелек яз» романнарын иҗат итүче буларак таный, шулар өчен ярата.

Филология фәннәре кандидаты, РСФСРның атказанган культура хезмәткәре М. Мәһдиев татар һәм рус телләрендә егермеләп китап чыгарды, университетның һәм Язучылар берлегенең җәмәгать эшләрендә даими катнашып килә.

Ул — 1969 елдан СССР Язучылар берлеге члены.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсе һәм «Казан утлары» редакциясе каләмдәшебезне иҗтәлекле бәйрәме белән котлый һәм аңа озын гомер, сәламәтлек, яңа иҗади казанышлар тели!

## Укучылар игътибарына!

Журналыбызның 10-11 саннарында Әнвәр Хәйруллин тарафыннан әзерләнгән Коръән сүрәләре басылып чыгу күп меңле укучыларыбыз күңеленә хуш килгән. Редакциягә килгән хатлар шул хакта сөйли.

«Без «Казан утлары» журналын ун ел буе алабыз. Журналның 10 саны безгә бигрәк тә ошады. Барыгызга да рәхмәтләр белдерәбез. Әгәр киләчәктә дә Коръән сүрәләре басылып чыкса, без талон сатып кына түгел, пенсиябезнең ярты акчасына «Казан утлары»на язылыр идек», дип язалар Иҗау шәһәреннән Зөлфия һәм Мирзаәхмәт Салиховлар.

Татарстан Республикасының Куйбышев шәһәрендә яшәүче Миңхәйдәр ага Фәйзуллин хатында да шундый ук фикерләр әйтелгән. Мондый эчтәлектәге хатлар килү дәвам итә.

Журнал укучыларга җавап йөзеннән шуны белдерәбез: киләсе елда да әдәби әсәрләр, халкыбызның тарихына, мәдәниятына караган фәнни мәкаләләр белән бергә Коръән Кәримнән сүрәләр бастыруны дәвам итәчәкбез. Журнал сәхифәләрендә, шулай ук, гарәп хәрефләре нигезендә татарча уку күнекмәләре дә даими рәвештә дөнья күрәчәк.

## ХАЛКЫБЫЗНЫҢ БӨЕК УЛЫ ХӨРМӘТЕНӘ

Илебез җәмәгатьчелеге татар профессиональ музыкасына нигез салган композитор, дирижер һәм музыкант Салих Сәйдәшевнең тууына 90 ел тулу юбилеен киң рәвештә билгеләп үтте. Татарстан шәһәрләре һәм район үзәкләрендә, илебезнең төрле өлкәләрендә аңа багышланган кичәләр уздырылды. Мәскәүнең «Россия» үзәк концерт залында республикабыз сәнгать осталары катнашында театрлаштырылган зур концерт, Түбән Кама шәһәрендә яшь башкаручыларның С. Сәйдәшев исемендәге конкурсы, Биектау районының Өбрә авылында аның музее ачылуы һәм Казандагы музеен оештыру эшләрен башлау, Казан телевидениесенең композитор турында тулы метражлы документаль фильм төшерүе, аңа багышлап телемарафон оештыру, Татарстан җыр һәм бию ансамбленең композитор әсәрләреннән төзелгән «Сәйдәшем» дигән махсус концерт программасы әзерләве, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының С. Сәйдәшев музыкасы белән бара торган спектакльләр декадасы үткәрүе, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының С. Сәйдәшев һәм Т. Гыйззәт иҗат иткән «Наемщик» музыкаль драмасын сәхнәләштерүе, СССР Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге каршындагы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, Казан дәүләт консерваториясе, Татарстан Композиторлар берлегенең юбилейга багышлап фәнни конференция уздырулары һәм Ульяновск, Киров, Куйбышев, Оренбург, Свердловск, Төмән, Пенза, Әстерхан, Ленинград шәһәрләрендә юбилей бәйрәмнәре үткәрелүе — халкыбызның композиторга чиксез мәхәббәте турында сөйли.

3 декабрьдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында Салих Сәйдәшевнең тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды. Аны кереш сүз белән ТССР Югары Советы Рәисе М. Ш. Шәймиев ачты.

Салих Сәйдәшевнең мәдәни тормышыбызда тоткан роле, аның иҗатының әһәмияте турында доклад белән ТССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары, профессор М. Х. Хәсәнов чыкты. Соңыннан Татарстан сәнгать осталары катнашында зур концерт булды.

* * *

Салих Сәйдәшев тууына 90 ел тулу хөрмәтенә «Шәһри Казан» газетасы редакциясе юбилей медале булдырды. Ул С. Сәйдәшевкә багышлап Түбән Камада оештырылган конкурста җиңүчеләргә тапшырылды.

Мондый конкурс-фестивальләр ел саен уздырылачак, җиңүчеләргә Сәйдәш медальләре һәм акчалата бүләк биреләчәк.

* * *

Ноябрь башында, ТССР Министрлар Советының 1990 ел 5 март карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Композиторлар берлеге идарәсе Салих Сәйдәшев язган тулы әсәрләр җыентыгының академик басмасын әзерләү буенча редколлегия составын раслаган иде. Шушы көннәрдә профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов, фәннәр кандидаты Фәридә Салитова, композитор һәм музыкантлар Бату Мулюков, Ренат Еникеев, Әзһәр Абдуллин, Луиза Хәйретдинова, Фуат Әбүбәкиров составындагы редколлегиянең беренче утырышы булды. Анда композиторның зур кыенлыклар белән архивлардан, китапханә, музейлардан җыелган, шулай ук шәхсән кешеләр җибәргән кулъязмалары каралды.

Бу уңайдан редколлегия аерым кешеләргә һәм оешмаларга С. Сәйдәшевнең сакланганниндидер материаллары (ноталар, кулъязмалар һ. б.) булса яки аларның кайдалыгын белсәләр, бу хакта 36-10-00 телефоны буенча редколлегия әгъзаларына хәбәр итүләрен сорап мөрәҗәгать итә.

## ТАТАРСТАНГА — ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

6 декабрьдә ТССР Министрлар Советында Татарстан ССР Фәннәр академиясен төзү буенча оештыру комитетының утырышы булды.

Утырышта академия төзүнең төп принциплары турында белдерү белән оештыру комитеты рәисе, ТССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов чыгыш ясады. Ул булачак академиянең структурасы, якынча бүлекләре белән дә таныштырды. Фикер алышуда Казанның күп кенә галимнәре катнашты.

Мәсьәләнең барлык ягын карагannan соң, утырышта катнашучылар, Татарстан ССР Фәннәр Академиясен төзергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килделәр. Булачак академия концепциясен эшләү өчен эшче комиссия төзелде.

## МӨСТӘКЫЙЛЬЛЕК ЯКЛАУГА МОХТАҖ

4 ноябрьдә Татар иҗтимагый үзәгенең Казан бүлекчәсе һәм «Азатлык» татар

яшьләре берлегенең Казан оешмасы үткәргән митингта резолюция кабул ителде. Анда шактый күп таләпләр куела, шул исәптән:

Татарстан республикасының сәяси һәм экономик суверенитеты турындагы законны кичекмәстән кабул итәргә;

Суверен Татарстан республикасы Конституциясе проектын тикшерүне тизләтергә һәм аны кичекмәстән кабул итәргә;

Татарстаннан сайланган халык депутатларына Россия парламентында эшләүне кичекмәстән туктатырга һәм үзләренең депутатлык вәкаләтләреннән баш тартырга тәкъдим итәргә;

Республика Югары Советыннан РСФСРның халык депутатларын Татарстан республикасы халык депутатлары итеп тану мәсьәләсен карауны сорарга;

Республиканың кайбер җитәкчеләреннән, кайбер сәяси оешмалардан, хәрәкәтләрдән, партияләрдән һәм группалардан, ТССРның кайбер халык депутатларыннан, шулай ук «Советская Татария» һәм «Вечерняя Казань» газеталарының редакция коллегияләреннән суверенитет турында декларация тирәсендәге озакка сузылган мәгънәсез уенны туктауны таләп итәргә һ. б.

### ОЕШТЫРУ СЪЕЗДЫ

25 ноябрьдә Казанда, Актерлар йортында, Татарстан республикасы суверенитеты яклау һәм гамәлгә ашыру комитетының оештыру съезды булды.

Республикабызның күп төбәкләреннән җыелган делегатлар, күрше республикалардан килгән кунаклар башта «Суверенитет» комитетының рәисе, язучы Әмир Мәхмүдовның докладын тыңладылар. Аннары республикабызның дәүләт суверенитетын яклау, аны ныгыту мәсьәләләре турында киң фикер алышу булды. Чыгыш ясаучылар республикабызның мөстәкыйльлегенә куркыныч янавы турында борчылып сөйләделәр, суверенитетны саклап калу һәм гамәлгә ашыру буенча тәкъдимнәрен әйттеләр.

Съездда Комитетның Уставы, Программасы, республикабызның сәяси, икътисади, мәдәни тормышына кагылышлы резолюцияләр кабул ителде.

### «ВАТАН» КИҢӘШ ТОТА

18 октябрьдә чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән эшләүнең әчтәлеген тагын да баету, тирәнәйтү турында «Ватан» җәмгыяте президиумы утырышында сөйләшү булды.

Билгеле булганча, АКШ, Германия, Япония һәм башка илләрдә яшәүче милләттәшләребез арасында төрле һөнәр ияләре, зур галимнәр, белгечләр, менеджерлар бар. Бүген безгә алар киңәшләре белән дә, Татарстанның башка илләр белән мәдәни һәм эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруында да зур ярдәм итә алалар. «Ватан» җәмгыятенең президиум әгъзалары әнә шул турыда сөйләшүләр алып бардылар. Шулай ук Казанда егерменче елларда ябылган Төркиянең консуллык вәкилен яңадан торгызу, җәй көннәрендә «Казан-Варшава-Берлин» поездын булдыру, Гаяз Исхакыйның туган авылында музей ачу турындагы мәсьәләләрне тиешле органнар алдында кую һәм хәл итү турында сүз барды.

Президиумда 1991 елның март аенда «Нәврүз чибәре» дигән конкурс үткәрү, киләчәк Сабантуйларга чит илләрдән кунаклар чакыру һәм башка шундый эшлекле мәсьәләләр каралды.

### ТАТАР ГАЛИМНӘРЕ АМЕРИКАДА

27—30 сентябрьдә Американың Висконсин-Мэдисон университеты каршындагы «Азияне өйрәнү Ассоциациясе» иҗтиһады белән IV Халыкара конференция уздырылды. Ул Үзәк һәм Урта Азиянең башлыча төрки халыклары тарихы, теле, иҗаты, милли һәм иҗтимагый мәсьәләләренә багышланган иде. Әлеге конференциядә Казаннан профессорлар М. Зәкиев һәм М. Госманов, археолог Р. Фәхретдинов, фольклорчы Ф. Әхмәтова докладлар белән чыгыш ясадылар.

### ТАТАР «РЫЦАРЬЛАРЫ» — ИКӘҮ

«Мин бүген Сезгә бик рәхәтләнеп тропик Африкадан үземнең шигырьләремне җибәрү бәхетенә иямен...» Төргәкне актара башлагач, аннан мөлаем ачык йөзле кешенең рәсеме, бер учма шигырьләре килеп чыкты. Бу — Бөтендөнья «Рыцарьлар конфедерациясе» Генераль консуллыгы Президентының, үз оешмасына яңа кеше кабул иткәч, гадәтенчә җибәрә торган котлау сәламе, истәлек бүләге икән.

Төргәк шундый «рыцарь»ларның берсенә — СССР Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәге каршындагы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының бүлек мөдире, тарих фәннәре докторы Сәлам Алишевка юлланган. Хәзер — «татар рыцарьлары» — икәү. Филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллин былтырның башында, татар дөньясында беренче булып, Бөтендөнья «Рыцарьлар конфедерациясе» Генераль консуллыгы (ул Австралиянең Сидней шәһәрендә урнашкан) әгъзасына әверелгән иде.

### БЕРЛӘШЕРГӘ ЧАКЫРУ

Бакуда төрле төбәкләрдәге татар мәдәни җәмгыяте вәкилләренең конференциясе булды. Анда Азербайҗаннан, Төмән һәм Пермь өлкәләреннән, Ташкент һәм Чаллы шәһәрләреннән вәкилләр катнашты. Конференция берләшергә чакырып резолюция кабул итте.

«Хәзерге чорда татар халкы ничек кенә аталмасын (Казан, Касыйм, Кырым, Себер, Әстерхан, Урал татарлары һ. б.), үзенең тарихын, мәдәниятын, телен һәм милли дәрәҗәсен торгызу өчен татар исемен бозып күрсәтүчеләргә каршы бергәләп көрәшүебез мөһим.

Моның өчен иҗтимагый-сәяси демократик, мәдәни, дини һәм башка прогрессив

көчләренең координацион үзәген сайлау буенча корылтай уздыру кирәк. КПСС һәм ВЛКСМның Татарстан республика комитетларыннан, Татар иҗтимагый үзәгеннән бу эшне үз өсләренә алуларын сорыйбыз», — диелә әлеге резолюциядә.

## «НУР» ЯРДӘМГӘ МОХТАҖ

«Нур» татар театры, 68 елдан соң, Уфа каласында яңадан эшли башлады. Шушы гомер эчендә Башкортстандагы миллион ярымга якын татар телле, татар мәдәниятле эш сөючән халык, гәрчә аның хезмәт өлеше республика казнасындагы милли доходның өчтән берен тәшкил итсә дә, үзенең милли сәхнәсеннән мәхрүм булып килгән иде.

Илебез экономикасы нык какшаган чакта зур чыгымнар таләп иткән театр оештыру ифрат авыр эш. Яңа оешкан «Нур» театры үз бинасын булдыруда акчалата ярдәмгә мохтаҗ. Моның өчен республика дәүләт банкында түбәндәге махсус исәп ачылды: Уфа, коммерческий банк «Социнвестбанк», расчетный счет № 609224, МФО 105013. Для татарского театра «Нур».

## ЧАЛЛЫ КАЛАСЫНДА ОЧРАШУЛАР

Галим һәм әдип Әбрар Кәримуллин 5 ноябрьдә Чаллы каласында булып, шәһәр һәм район мәктәпләренең тарих, татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очрашты, татар халкының килеп чыгышы һәм үткәне турында сөйләде. Халкыбызның тарихын бозып күрсәтүнең ерактан килә торган «традицияләре» һәм аның хәзерге көндә дә яшәвенең сәяси һәм шовинистик нигезләрен аңлатты.

Кичке якта Ә. Кәримуллин партиянең шәһәр комитеты бинасында шәһәр хезмәтчеләре белән очрашты. Бирегә галим татар халкының бай язма һәм басма мирасы, аның ачы язмышы турында сөйләде. Әле генә Кырымда булып кайткан Әбрар ага Кырым татарларының бүгенге аянычы хәлләрен сурәтләде, тәэсирләре белән уртаклашты. Туган телебезне ныгыту, халкыбызның милли аңын үстерү, республикабызның мөстәкыйльлеген тормышка ашыру хакында бирелгән күп кенә сорауларга җавап бирде.

## 108 ЕЛ ҮТКӘЧ...

25 июнь көнне Казан шәһәрендә зур вакыйга булды: архитектура һәйкәле булган Пассаждагы сәгатьләр «телгә килде». Бу тирә-юньгә матур тавыш таратучы йөзләрчә килограммлы кыңгыраулар совет-фин фирмасы тарафыннан Воронежда коелган.

Казан сәгать осталары 1882 елгы иске механизмнарны көйләргә җыена. Революциягә кадәр биредән «Боже, царя храни!» дигән император гимны башкарылса, тиздән композитор Салих Сәйдәшев маршы яңгыраячак.

## ЯҢА РӘИС САЙЛАНДЫ

Татар иҗтимагый үзәгенең Казан бүлеге вәкилләр советының отчет-сайлау пленумын үткәрде.

Анда әлеге советның һәм идарәнең яңа составы сайланды. Идарә рәисе итеп тарих фәннәре кандидаты Рифкать Корбан улы Газизов сайланды. Пленум, әлегәчә яшәп килгәнчә, рәис-координаторлар сайлауны кирәксез дип тапты.

## ПРИНТЕР ҮЗЕБЕЗЧӘ ЯЗА

«Терминал» производство берләшмәсендә ЕС-7245 принтерын татарчага көйләп чыгара башладылар. Әлек ул инглиз, француз, урыс телләрендә генә текстлар бирә торган булса, хәзер татарча да яза. Шәхси электрон-хисаплау машиналарына тоташтырыла торган әлеге язу җайланмасы, бирелгән программа ярдәмендә, 78 операция башкарырга сәләтле. Татар телен кулланышка кертү ихтыяҗы көннән-көн арта барганда, оешмалар һәм учреждениеләр, галимнәр һәм журналистлар, гомумән, мәдәниятка омтылган һәрбер татар кешесе өчен шатлыклы яңалык бу.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» КӨННӘРЕ

Һәр елдагыча, быел да көзге айларда, республикада һәм илебезнең татарлар яшәгән башка төбәкләрендә «Казан утлары» көннәре уздырылды.

Журналда басылып чыккан һәм басылачак әсәрләр турында сөйләшү-киңәшүләр, әдәбиятыбызның бүгенге проблемаларын эченә алган әңгәмәләр уздыру максатыннан журналның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин — Киев һәм Әлмәт, Рашат Низамиев — Чаллы, Флүс Латыйфи — Ульяновск, Радиф Гатауллин — Свердловск, Тәүфикъ Әйди — Алма-Ата һәм Ташкент шәһәрләрендә, Шамил Маннапов — Чувашстанда, Рәшит Әхмәтҗанов Баулыда һәм Нияз Акмалов Сарман районында булдылар. Әлеге урыннарда журнал укучылар конференциясе үткәрелде, радио һәм телевидение аша чыгышлар оештырылды.

# БӘҺАСЕЗ ЯДКАРЬЛӘР

Татар әдәбияты тарихында күпләрнең күңеленә «Исмәгыйль ага сәяхәте» дигән исем белән кереп калган әсәр мәгълүм. XVIII гасыр азагында иҗат ителгән бу сәяхәтнамәнең асылында тормыштан алынган бер вакыйга — татар сәүдәгәрләренең Бохарага юл тотулары, ә инде соңыннан рус патшасы әмере белән Һиндстанга илче итеп җибәрелүләре турында тәфсилләп бәян ителә анда. Алар Оренбург каршындагы Сәгыйд бистәсе (хәзерге Каргалы авылы) кешеләре булалар. Бу турыда язманың башында ук түбәндәге юллар бар: «Оренбург янында урнашкан Сәгыйд бистәсенең старшинасы Сәгыйд Салих углы заманасы иде. Аллаһы тәгаләнең тәкъдиренә язылган буенча мелла Нәдер вә мелла Йакуб, вә Исмәгыйль, вә Габдрахман, вә мелла Нәдернең бер хезмәтчесе — шул биш кешене сәүдә итү өчен старшина Сәгыйд ага Бохара шәһәренә юллады».

Шәрык илләре белән сәүдәне юлга салу өчен, 1744 нче елда Саба районы кешесе Сәгыйд Хәялин белән ике йөзләп татар гаиләсе Оренбург ягына күчәргә ризалык биреп, аннан 18 чакрым җирдә торак әзерли башлыйлар. 80 нче елларда бу бистә (аңа Сәгыйд исеме бирелә) зурая, көчәя, сәүдә үзәге генә түгел, мәдәни багланышлар мәркәзе дә булып китә. Габделкәрим Балтаев белән Габдессәләм Ураев ачкан мәдрәсә чорның мәшһүр уку йорты булып әверелә.

Журналыбызның беренче битендә шушы Сәгыйд бистәсе зиратының бер өлеше төшерелгән фоторәсем китерелгән. 200 елдан артык инде бу дөнья белән бәхилләшкән әдәмнәр шушында соңгы сыеныр урын тапканнар. Төрле кыяфәттәге ташлар — якыннарыннан, дусларыннан, танышларыннан куелган бу истәлек билгеләре — һәркемнең үз зәвыгенә туры китерерлек итеп уелганнар. Берәүләре аны кечкенә йортның түбәсенә охшатырга тырышкан, икенчеләре очлы кырлары җилне тырнамасын өчендерме, ташны һәрьяклап түгәрәкләтергә омтылган, өченчеләре исә үзләре генә белгән уйга нигезләнгән корылмалар булдырган.

Минә бу рәсемнең алгы өлешендәге ташбилгенең түбәсенә чалма киертелгән. Ул миңа Төркия кабер ташларын хәтерләткәндәй булды. Анда да дин әһелләренә куелган ташбилгеләрнең түбәсенә чалма чорналган.

Нинди генә хис-тойгылар төшерелмәгән бу ташларга! Югалту кайгысы да, Аллаһы тәгалә үзенең рәхимлегеннән калдырмас әле дигән өметләр дә, гафу сораулар да, фани дөнья әшәкелегеннән бакый бакчага озату өметләре дә — барысы да, барысы да чагылыш тапкан.

Кемнәрнең генә исемнәрен күрмәскә мөмкин аларда! Язулы ташлар — үзләре халкыбыз тарихының җуелмас битләре. Мин югарыда китергән «Исмәгыйль ага сәяхәте»ндәге өзектә дә кульъязманы күчерүчеләр хата җибәргәннәр икән. Каргалы зиратындагы Сәгыйд Хәялиннәрнең бишенче буыны Мостафаның истәлекле язуында Сәгыйднең атасы Салих түгеллеге, ә Аит икәнлеге ачыклана.

Кабер ташлары — кыйммәтле тарихи документ, халкыбыз мәдәниятының бәһасез үрнәкләре. Аларны саклыйсы, өйрәнәсе, андагы мәгълүматларны хәзерге буыннарга җиткерәсе генә кала. Борынгы бер ташта «үзем өчен түгел, халкым өчен яздым мин моны» дигән васыять язуы юкка гына калдырылмагандыр.

**Фәрид ХӘКИМҖАНОВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

**Рөстәм МӨХӘММӘТҖАН** фотосы.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** күренекле әдип, Татарстан ССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Мәхмүт Хәсәнов. (Шушы елның 17 сентябрендә кинәт вафат булды).

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

[redacted]

## ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ МӨРӘҖӘГАТЕ

Тарихи вакыйга булды — Татарстанның дәүләт суверенитеты игълан ителде!

Суверенлык игълан итү — эчке һәм тышкы бәйсезлекне юридик яктан таныган сәяси акт ул. Әмма тулы мөстәкыйльлеккә бару юлында әле бик күп киртәләрне җиңеп үтәсе бар.

Яшән килүче чынбарлыктан чыгып, без шуны танырга тиешбез: бүгенге көндә Татарстан үз вәкаләтләренең бер өлешен Үзәккә бирмичә булдыра алмый. Ләкин халыкларның буйсынган хәлдә яшәвен һәм бер республика вәкаләтләрен шундый ук башка республикага бирүне инде берниндн чынбарлык та аклый алмый. Шуннлыктан без, Татарстан үз вәкаләтләренең берникадәр өлешен ССР Союзына һәм бары тик аңа гына бирә ала, һәм ул үзе биргән вәкаләтләрне үз инициативасы белән кайтарып алырга да хокуклы, дигән позициядә торабыз. Шул ук вакытта без кергән Союз үзе тигез хокуклы дәүләтләр союзы булырга тиеш. Татарстан республикасының башка республикалар белән, шул исәптән РСФСР белән дә мөнәсәбәтләре бары тик тигез хокуклылык нигезендә, тигез хокуклы субъектлар һәм партнерлар арасында үзара файдалы договорлар төзү юлы белән, халыкара хокук нигезендә генә корылырга тиеш.

Татарстанның кайсыдыр вәкаләтләрен Россия Федерациясенә бирү безнең суверенитетның мәгънәсен бетерер, татар халкының гасырлар буена килгән өмет-хыялларын санга сукмау булыр иде.

Теге яки бу рәвештә РСФСРга бәйлелек сакланып калганда халыкның тулы ирекне тоюы мөмкин түгел. Дәүләт берәмлекләре арасындагы тигез хокуклы мөнәсәбәтләрдән тыш халыклар арасында чын тигез хокуклы мөнәсәбәтләр урнаштыру формасын цивилизация белми.

Татарстанның дәүләт суверенитетын игълан итү — татар милли хәрәкәтенең генә түгел, ә республикадагы барлык чын демократик көчләрнең дә уңышы ул. Нинди милләттән булуларына карамастан, аның барлык гражданнары мәнфәгатьләре хакына яуланган суверенитет бу.

Без бар кешене дә шуны аңларга чакырабыз: Татар иҗтимагый үзәге беркайчан да республикада яшәүче татар милләтеннән булмаган гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләү ягында булмады һәм булмас та. Безнең максат — Татарстан җирендә дә, сан ягыннан руслардан кала икенче урынны татарлар алып торган РСФСР территориясендә дә чын тигезлекне тәэмин итү. Һәр ике дәүләтнең прогрессив, гармонияле үсүе өчен бердәй борчылуыбыз һәм кызыксынуыбыз әнә шуннан килеп чыга.

Ирекле Татарстан — аның җирендә яшәүчеләрнең барысының да иле. Аның барлык гражданнарының һәм бу республиканың башка союздаш республикалар арасында тигез хокуклы булуы гына аның халыклары арасында чын дуслыкны, аларның чын тынычлыгын, үзара ихтирам һәм гармонияле үсешен тәэмин итә ала. Татарстанның сәяси һәм экономик суверенитеты өчен республикада яшәүче барлык халыкларның бергәләп көрәшүе — алар арасында ышаныч һәм үзара аңлашуның нигезе.

Үзара ышаныч — бик кыйммәтле капитал. Ул — гомуми бәхет гарантиясе.

Татарстан халыклары!

Суверенитет — безнең уртак байлыгыбыз!

Республиканың суверенитетын чикләүгә юл куймагыз!

Үз хокукларыгызны җилгә очырмагыз! Чөнки аларны кире кайтару бик тә авыр.

Татарстанның данлы интеллигенциясе!

Хәзерге вакытта хәл шундый, әгәр безнең белгечләребез үзләренең акылларын, сәләтләрен эшкә җикмәсәләр һәм Татарстан белән РСФСРның үзара мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча үз программаларын эшләмәсәләр, дискриминацияле шартларны республикабызга көчләп тагу куркынычы һаман реальрәк була бара.

Киләчәктә лаеклы яшәвебез хакына экономистларны, юристларны һәм башка белгечләрне группаларга берләшергә һәм үз инициативалары белән суверенитетны саклап калу, РСФСР белән мөнәсәбәтләрне җайга салу механизмын булдыру эшен башлап җибәрергә чакырабыз.

Энтузиаст-белгечләребезгә керсез өметләр белән мөрәҗәгать итәбез — экономика, үзара исәп-хисап һәм үзара файдалы интеграция өлкәсендә республикабызның РСФСР һәм башка республикалар белән мөнәсәбәтләрен гадел билгеләү эшендә көчегезне, интеллектуаль сәләтегезне кызганмаска чакырабыз.

Шул ук вакытта без: бу мөнәсәбәтләр республикаларны кече яки олы туганнар итеп бүлү принцибы буенча корыла алмый, дип катгый төстә белдерәбез. Безнең РСФСР белән мөнәсәбәтләребез, Украина, Белоруссия, Казахстан, Үзбәкстан һәм башка союздаш республикалар РСФСР белән нинди мөнәсәбәттә торса, шундый ук булырга тиеш.

Татарстанның, анда яшәүче барлык милләт халыкларының суверен хокукларын тормышка ашыру өчен көрәш иң җаваплы этапка керде.

Без халыкның көченә, акылына ышанабыз!

Бергә туплану һәм суверенитет!

1990 ел, 10 сентябрь.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**(ОГНИ КАЗАНИ)**

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРСТАНА
(на татарском языке)